


# КАЗАН УТЛАРЫ

10
ОКТЯБР
1980

# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ ОРГАНЫ
1922 елның май аеннан башлап чыга

**10**

ОКТЯБРЬ
1980

## *Бу санда*

М. ШАБАЕВ. Күзнең якты моңнары. Шигырьләр . 3
К. ТИМБИКОВА. Таңкәле тау. Повесть . . . . . 8
ХӘЙДӘР. Күзгә булып иңде ак болытлар. Шигырьләр . . . . . . . . . . . . . . . 73

ЯКТАШЛАРЫБЫЗ ИҖАТЫ

И. САЛАХОВ. Азатлык җырчысы . . . . . . 77
С. ШӘРИПОВ. Кала чыгу. Хикәяләр . . . . . 78
Р. ХАЛИД. Кояшка туры. Шигырьләр . . . . . 92
Э. МОСТАФИН. Күңел күге. Шигырьләр . . . . 93
Б. РӘФИКОВ. Уй белән Уел. Шигырьләр . . . 95
А. МИФТАХЕТДИНОВ. Келенеут. Хикәя . . . . 97

КПССның XXVI СЪЕЗДЫН КАРШЫЛАП

Н. ФӘТХУЛЛИН. Идарә итү: кемнәр һәм ничек! 102
М. РАФИКОВ. Ташкын. Очерк . . . . . . . . 108
Ә. ГАФФАР. Рәссам. Очерк . . . . . . . . 116

Т. ӘЙДИ. Караңгылык патшасының сердәше. Очерк . . . . . . . . . . . . . . . 120
Н. СТУПНЕВ. Каен урманының тынлыгын саклап. Очерк . . . . . . . . . . . . . . 124
Ф. МАРКОВА. Берьюлы — йөз язмыш. Интервью. 126

И. ЮЗЕЕВ, Д. СИРАЙ. Соңлап килде, чыңлап китте . . . . . . . . . . . . . . . . 129
Е. УТКИН. Мәңгелекнең өне. Шигырьләр . . 129

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Р. МӨХӘММӘДИЕВ. Күңелдәге эзләр . . . . 133
Э. НИГЪМӘТУЛЛИН. Типиклаштыру турында уйланулар . . . . . . . . . . . . . . 143

ӘДӘБИЯТ БЕЛЕМЕ

А. ЯХИН. Җыр жанрының төзелеше . . . . . 149

КИТАП КҮЗӘТҮ

М. ГОСМАНОВ. Яңа сәхифәләр ачыла . . . . 155

КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

ТӨРЛЕСЕННӘН

**И. ЮЗЕЕВ. Чишмәләр кая агарлар!** . . . . 159

НӘНИЛӘР ДӨНЬЯСЫ

**Г. ШӘРӘФИ. Күрше малае.** Повесть . . . . . 163
**Ә. СИНУГЫЛ. Курчак елый...** Шигырьләр . . . 178

**Укучы сүзе** . . . . . . . . . . . . . . . 179

ЕЛМАЕП ТА, КӨЛЕП ТӘ...

**С. БАТТАЛ. Минем үз каләмем бар!** Шигырь . . 184
**Н. ӘХМӘДИЕВ. Хәмдениса.** Хикәя . . . . . . 185

**Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары** . . . . . . 189

**Баш редактор: ЗӘКИ НУРИ**

**Редколлегия: ӘХСӘН БАЯНОВ** (баш редактор урынбасары), **ШАМИЛ БИКЧУРИН, АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВ, МАРСЕЛЬ ЗАРИПОВ, ЗӨЛФӘТ, ФӘРВАЗ МИҢНУЛЛИН, ТУФАН МИҢНУЛЛИН, РӘФЫЙК НӘФИКОВ, АТИЛЛА РАСИХ, КОЯШ ТИМБИКОВА** (җаваплы секретарь), **СИБГАТ ХӘКИМ, НИЛ ЮЗИЕВ**

Техник редакторы *Р. Сөләйманова*
Корректорлары *Ф. Кадыйрова, Т. Шакирҗанова*

**Редакциянең адресы.** Казан, 420066, ул. Декабристов, 2.

**Телефоннар:** баш редактор — 3-07-60, баш редактор урынбасары — 3-07-60, җаваплы секретарь — 3-07-09, проза бүлеге — 3-07-61, поэзия бүлеге — 3-07-61, тәнкыйть бүлеге — 3-07-63, сәнгать бүлеге — 3-07-63, очерклар бүлеге — 3-07-63, хатлар бүлеге — 3-07-61, корректорлар — 3-07-65, техник редактор — 3-07-65, машинисткалар — 3-07-60.

Производствога бирелде 25/VI-1980 ел. Басарга кул куелды 15/IX-1980 ел. ПФ 13158. Кәгазь форматы 70×108¹/₁₆. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 92 600 экз. Заказ У-277. Бәясе 50 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1980 ел.

## Марс Шабаев

# КӨЗНЕҢ ЯКТЫ МОҢНАРЫ

## Өйрәт, Ибәт!

«Кояш уянганчы кузгалабыз,
Көнгә ничә чакрым юл барабыз —
Я, санагыз!
Челләләре безгә, яңгырлары,
Безгә ява бөтен бозы-кары —
Безгә бары!
Көне буе йөргәч арып-талып,
Ах, йоклыйсы иде бер таралып —
Камыр булып!
Сыер-сарык керә һаман төшкә,
Юк, күнегеп булмый безнең эшкә —
Килә көчкә!
Безнең кебек бармы җәфа чиккән?
Гарык булдым, җиткән, быел китәм —
Иман икән!»

Сугыш елларында шулай сөйләп,
Авыр, озын чыбыркысын сөйрәп
Йөрде Ибәт.
Йөрде Ибәт йорт башыннан ашап,
Аны бүген әйтү генә ансат —
Ул бит ач чак!
Сыкрангандай кыланса да үзе,
Юк, чытылмый иде бер дә йөзе —
Ибәт түзде!

Ибәт гомер буе көтү көтте,
Халык аны һәр кич заргып көтте —
Еллар үтте...
Хәзер, имеш, көтүчегә кытлык,
Бик сиздерә Ибәт агай юклык —
Җитми ныклык!

Ул еллардан читкә китә уем:
Дөнья бит ул түгел уен-муен —

Һәр эш кыен!
Дөнья көтүләре авыр бигрәк,
Ул чыбыркы түгел, булмый сөйрәп —
Ибәт, өйрәт!
Әйтә кебек Ибәт:
— Иман кирәк!

## Җимерелгән әкият

Төнге елга яры.
Ник соң кыен
Бу су буен ташлап китүләре?
Учак яктысында —
Су өстендә,
Әйтерсең лә, йолдыз көтүләре! —
Вак балыклар җем-җем уйнаклыйлар...
Ә тирәндә, бәлки су анасы
Сылу кызын тыя, җибәрмидер:
«Кайтып китсен, диеп, җир баласы...»

Су кызының салкын бармаклары,
Калтыранып, кабырчыклар кояр...
Ник, әнкәсе, аны тыясың син?
Тыйган саен тынычлыгын җуяр:
«Ах, күрсәмче, дияр, шул җир улын!
Ничек яши җирнең өсләрендә?..»
Хыялланыр...
Ләкин хыяллары
Судай агып бетәр төшләрендә...

Сихри дөнья!
Төн тынлыгын эчэм,
Илһам өчен татлы шәраб итеп.
Саксыз бер сүз куя сискәндереп,
Шигъриятне ватып, харап итеп:
«И дивана!» —
Узып бара шулай
Кемнәрнең ул гамьсез шәүләләре?

Су кызларын таный белмәүчеләр,
Хыялсызлар, мескен бәндәләрме?
Чәлпәрәмә килде сихри дөнья,
Юкка чыкты сылу су кызы да...
Таралдылар йолдыз көтүләре...
Су-сылусыз гомер итүләре,
Әйтегезче инде, я, әйбәтме?—
Җимердегез нигә әкиятне?!
Минем әкиятне!

# Кичке моң

*Миргазиян Юныска*

Зәңгәр диңгез [illegible]ртларында —
Зәнзибәр.
Яши диләр, Зәнзибәрдә
зәнкиләр.
Зәнзибәрдә тозлы җилләр
зеңлиләр,
Зәнзибәрнең зәйтүннәре
ямьлеләр.
Сагышларын төяп зәңгәр
җилләргә,
Туган-үскән, суын эчкән
илләргә
Йөзәр түгел, меңәр чакрым
җирләрдән —
Зәнзибәрдән кемнәр сәлам
җибәргән?
Баулыларның кагып сары
капкасын,
Хат ташучы җәһәт-җитез
атласын.
Белә Баулы: бәлки бик тиз
кайтмассың...
Бигрәк матур сырлагансың
хат башын...
Көтү кайткач,
кичке эңгер-меңгердә,
Чиләкләргә ак бәхетләр
гөбердәп
Тулган чакта,
эңгерләр белән бергә,
Иңә бер моң...
Әх, иясен белергә!
Морҗалардан чыккан зәңгәр
төтенме?
Тал-тирәкме?
Берәр ялгыз-ятимме?
Гашыйк кызмы моң иясе?—
Я, кемне,
Кем дип әйтик,
Кем дисәк тә, ул булмас...
Туган илдә туган кичке
моң булгач,
Кемнең генә йөрәгенә уелмас!
Ул гомергә күңелләрдән
җуелмас...
Баулыларның садә саба
җилләре
Илтер моңны ерак-ерак
җирләргә —
Зәңгәр диңгезләр гизеп,
Зәнзибәргә:
«Баулым!»— дип син
сулкып елап җибәрмә...

## Көз һөҗүмдә

Революция мени?!—
Җил-Октябрь йөри:
Купшы чаганнарның
Алтын погоннарын
Йолкып ала-ала
Көз һөҗүмгә бара!

Көз безнең шәһәргә
Гастроль-сәфәргә
Килгән кунак түгел,
Шуңар тыйнак түгел.
Рөхсәт сорап тормый,
Җәйнең ямен урлый.
Куркак усакларның
Үтеп форпостларын,
Уртасына керә,
Кызыллыкка төрә.
Көзне көтеп торган:
Кул күтәрә урман!

Булса әгәр яшел,
Уңышыңны яшер:
Көзгә бездән тиеш
Тик өлгергән җимеш.
Арын чүп-чарыңнан,
Арын син барыннан:
Ваклык, хөсетлектән,
Мәкер, көнчелектән,
Гайбәт, ялалардан,
Шома ялганнардан.
Көз утында яндыр,
Яки юсын яңгыр.

Кызыл көз һөҗүмдә —
Җиңелмә үзең дә!

●

Арган инде усак яфраклары
Җәй буена җилдә тирбәлеп,
Җылы җиргә төшеп сыланыр да
Түшәр тиздән якын-тирәне.

Аккордларын барлый,
Шыгыр-шыгыр
Ботак шыгырдатып, имәннәр.
Имәннәрдә көзге симфония
Уйнарга дип җилләр килгәннәр.

Хоккейчылар мыни!
Елтыр каска
Киеп башка,
Әнә, гөмбәләр:
Сезон ачылуга куанышып,
Бер-берләрен коча-үбәләр.

Саксыз караштан да коелалар
Соңгы карлыганнар шыбырдап.
Зәңгәр күктә — өчпочмаклы ямау:
Торна кәрваннары,
Җыр жырлап,
Сагыш җырын коеп канатлардан,
Китеп бара җылы якларга...
Нигә икән туа күңелләрдә
Якты моңнар шундый чакларда?

Бар табигать, бөтен җиһан белән
Минем җаным, минем күңелем
Көзгә әзерләнә, көзне көтә:
Тулышыйм да тизрәк түгелим...

## Йөрәгем

Кайгылы көннәрнең,
Йокысыз төннәрнең
Күпмесен күтәрдең,
Йөрәгем?
Күпмесен күтәрдең,
Күпмесен үткәрдең,
Яшендәй этәрдең,
Йөрәгем?

Сиңа сыйды җиһан,
Гавам,
Галәм —
Җанлысы да, җансызлары да...
Сиңа таныш шатлык-куанычлар,
Сиңа таныш җан сызлавы да.

Сөенеч яңгырлары яуды синдә,
Кайгы бураннары дулады.
Кояш чыкты, ай калыкты синдә —
Тормыштан һич туйган булмады.

Язгы карлыгачлар очты синдә,
Яңгырады гыйшык җырлары.
Өмет чәлпәрәмә килгәндә дә,
Зарыгып көттең килер елларны.

Ялган кермәк булды —
Юк, сыймады!
Мәкер кермәк булды — сыймады!
Тормыш кыйнады да иркәләде,
Бер сыйпады,
Йөз кат сынады.

Сынатмадың!
Ярылыр чиккә җитеп
Какканда да күкрәк читлеген,
Җиңел язмыш күтәртмәдем сиңа,
Авыр булды һәрчак йөк минем.

Сизәм: ардың...
Инде тормыш ритмын
Киметергә кирәк кирәген,
Син тибәсең ләкин:
«Юк! Юк!»— диеп
Нагрузка сорап, йөрәгем.
Шулай булгач, җилә бирәмен!

*1980*

**Кояш Тимбикова**

# ТӘҢКӘЛЕ ТАУ

ПОВЕСТЬ

Самолет һич уйламаган яктан килеп чыкты. Ул күктә әллә ни озак әйләнмәде, яшел чирәм белән капланган аэродромга ипле генә төште дә бөтенләй тынып калды. Аның хәрәкәтләреннән купкан җил генә бер мәлгә тирә-юньдә зилзилә ясап алды: яшькелт дулкыннар йөгерешеп узды, якындагы вак куаклар баскан урыннарында бөгелә-сыгыла биештеләр, каравылчының кош-кортлары чыр-чу күтәрде, тәкәббер әтәч, аяктан егылмас өчен, җилгә артын куйды, койрыгының затлы каурыйларыннан бөркәнчек корды. Аннары бары да үз хәленә кайтты. Олы төеннәр, зур чемоданнар күтәргән пассажирлар һәммәсе берьюлы урыннарыннан кузгалды. Самолетны бөтенләй башка максат өчен зарыгып көткән археолог Харрас Хәсәновны алар искә-санга да алмыйлар иде.

Харрас «кукурузник»ның ишеге ачылуын, борынгыларның күк капусы балкышын күрергә өметләнгәннәре кебек, өнсез калып күзәтте. Аннан сикереп төшкән очучы ачык йөзле, җитез хәрәкәтле иде. «Мондый кеше белән теләсә нинди эшкә тәвәккәлләргә була! — Харрас күңеленнән җан тынычландыргыч уй үтте. — Ул хәзер мине эзли башлар инде. Кулында да безнең институт кәгазьләре җилферди бугай. Каршы барырга кирәк, интекмәсен!»

Ул, елмаеп, исәнләшер өчен кулларын угалап, очучыга таба атлады. Анысының исә кемнедер эзләргә исәбендә дә юк иде, юл уртасында колгадай калкып торучы Харрасны илтифатсыз гына уратып узды да аэропорт бинасына кереп китте. Харрас кулына килеп кергән бәхет кошын ычкындырган мәхлук шикелле, авызын ачып аның артыннан карап калды. Икенче мизгелдә эчтән генә: «Ятып калганчы, атып кал!»— дип, үзе дә очучы эзеннән теркенләде. Белешергә, хәлне ачыкларга кирәк, сорашкан өчен авызга сукмас бит? Ул, куаклар ышыгында кырын ятучы иптәшләренә «теләктә торыгыз!» дигәндәй ишарә ясады да, адымнарын тизләтте.

Аэродром начальнигына Харрасларның теләге күптән мәгълүм иде инде. Акъярның үз кешесе булганга, археологларга биш куллап ярдәм итәргә әзер ул. Бүлмәсенә Харрас килеп кергәч тә, кыюрак бул дигәндәй, күзен кысып, ияген кагып өлгерде.

Очучының исә ашыгуыннан, бары тик пассажирлар турында гына

сөйләвеннән үк археологлар хәҗәте турында һичнинди хәбәре юклыгы сизелеп тора иде. Кыскасы, археологларга җибәрелгән самолет булып чыкмады бу. Шулай да Харрас башта сорамый булдыра алмады.

— Әллә сезгә берни дә әйтмәделәр?

— Кем? Кайда? Нәрсә әйтергә тиешләр иде миңа? — Очучы Харрасны билетсыз калган артык пассажирга гына санады бугай, хәтта үзе биргән сорауларга да җавап көтеп тормастан, диспетчерга борылды. — Менә минем кәгазьләр.

Харраска ашык-пошык үзенең кемлеген, Акъяр авылының көнбатышына урнашкан Тәңкәле тау үзәнендә археологик тикшеренүләр башлап җибәрергә авиация ярдәме кирәклеген аңлатырга туры килде.

Очучы, гозернең җитдилегенә төшенгәч, Харрасның җилкәсенә сугып куйды.

— Теләгегез — изгелектә! — диде. — Әмма ләкин мин экспедициягә ярдәм итә алмыйм. Самолетның һәр хәрәкәте акча тора ул, агайне, акча! Ягулыгы, мае, әзерләүче кешеләре — барысы да акча сорый.

— Безнең акча әллә кайчан күчерелгән булырга тиеш иде, сезгә әйтми җибәрүләре генә...

Харрасны хуплау йөзеннән сүзгә начальник кушылды.

— Әллә соң тиз генә белешеп алыйкмы? — Ул Казан аэропорты белән турыдан-туры элемтәгә кертүче аппаратка ымлады. — Секунд эчендә ачыклыйбыз аны.

Кыяфәтенә караганда, очучы эшнең барып чыгачагына бер тамчы да ышанмый иде. Харрас исә соңгы мөмкинлеккә чатлап ябышты. Аппарат эченнән гыргылдап ишетелгән тавыш: «Юк. Сөйләшүләр барды, без риза идек, акча күчермәделәр», — дигәч тә аптырап калмады. Күен кесәсендә мендәрдәй күперөп торган акчасын капшады, начальникка:

— Шул хакны монда гына, сезнең аша түләргә рөхсәт итсеннәр әле! — дип кычкырды. — Әйтегез әле! Отпускнойны алып өлгергән идем бит, рәхмәт яугыры!

Аэродром начальнигы белән Казан кешесе тагын берничә өзек-өзек сүз әйтештеләр дә элемтә өзелде. Харрас берни дә аңлый алмый калды, очучы барына да төшенгән иде инде. Ул кулларын Харраска сузды:

— Әрсезләнүнең дә файдасы бар шул, котлыйм! — диде. — Миңа барыбер. Әйдә, планнарыгыз белән танышыйк.

Пассажирлар ул арада самолетка кереп кунаклаганнар, күңелләреннән Казандагы туганнарында кайнар чәй эчәргә әзерләнгәннәр иде инде. Очучы:

— А ну-ка, бабуся! — дип, иң кырый урынга чүмәшкән әбигә генә кире чыгарга кушып караган иде, әй китте ыгы-зыгы, әй купты тавыш.

— Нә-әрсә-ә?! — дип, җикеренергә тотынды җирән чәчле хатын. — Мине төшермәкче буласыңмы? Туганыңны алып кайтыр өченме?

— Болай да ничә минутка соңладың! — диде икенчесе.

— Жалоба язарга кирәк моның өстеннән, әнә тегендә куак ышыгында дус-ишләре ята аның, шуларга урын кирәктер!

— Теләсәләр нишләсеннәр, без чыкмыйк!

Бу хәлне күреп торган Харрас пошаманга төште, монысыннан акча түләп кенә котылу мөмкин түгел инде, нишләргә?

Очучы тыныч иде, аның йөзендә бер генә төге дә селкенми, ул мондый «бәрелешләр»не шактый еш кичергән, күрәсең. Самолетның шассиларына типкәләгән булды да, пассажирларга күз дә салып тормастан, борын эченнән генә:

— Нәрсә-ә, җаныгыз җәл түгелмени соң сезгә? — диде. — Самолетка срочный ремонт кирәк. Әллә һавага менгәч кенә төзәтербезме?

Әле генә очып китәргә ашыккан кешеләр, дәррәү кубып, этешә-төртешә ишеккә килеп капландылар, бер-берсенә комачаулап, чыга алмый интектеләр. Берничә пассажир хәтта төенчеген дә алып чыгарга оныткан иде.

Шуны гына көтеп яткан археологлар бердән салонга кереп тулдылар. Һавага күтәрелгәч, экспедиция җитәкчесе булган Харрасны очучы, моннан яхшырак күренә дип, үз янына чакырды.

Сукаланган җир өстеннән мөмкин кадәр түбәнрәк һәм акрын очарга кирәк иде. Мондый очракта самолетны тигез тоту шактый кыен. Егетләрнең күңелләре болгана башлады. Харрасның гына бернәрсәгә дә исе китми, әйтерсең оҗмахка эләккән: күзләре аска төбәлгән, авызы колагына җиткән, иреннәре, дога укучы картларныкы кебек, өзлексез кыймылдый. Аның бөтен торышы серле әкият тыңлаучы сабыйны хәтерләтә. Кара җир өстендә самолеттан күренгән төрле таплар буенча ул үзенә генә мәгълүм хакыйкатьне укып бара. Планга борынгы шәһәр төзелешләреннән калган кадерле эзләр төшә башлады.

Археологлар борынгы шәһәр калдыкларын «шәһәрлек» дип атыйлар. Тәңкәле тау итәгендәге бу зур шәһәрлек, Харрас уенча, ике өлештән тора иде. Эчтә кирпечтән, ак таштан салынган зур биналарның эзе аермачык күренә, тышкы өлештә агач бина калдыклары, көлсу таплар күп. Монда остаханәләр булган, күрәсең — балчыктан савыт-саба ясау, чүлмәк яндыру урыннарын шуннан эзләргә кирәк.

Самолет кыска гына вакыт эчендә тау кадәр мәгълүмат тупларга мөмкинлек бирде. Казу эшләрен кайдан башларга икәне ачыкланды. Казанга да, Мәскәүгә дә, Ленинградка да, Болгария галимнәренә дә хәбәр итәргә була, әйдә, килсеннәр, эш мәйданы әзер!

Ул төндә Харрасның күзенә йокы кермәде. Ел буена сузылган тарткалашулардан соң, ниһаять, өметләнгән нәтиҗәне бүген ачыклау аның хисләрен тәмам кузгатып җибәргән иде. Башына бертөрле уйлар килеп керә дә, Харрас үзалдына елмаеп куя, ә икенче төрле хатирәләрдән ул комачлана, маңгаен җыера. Профессор белән ямьсезләнеп йөрүләре хәзер аңа бер дә кирәкмәгәнгә нерв бозучы, вакытны исраф итүче мәгънәсез бәхәс булып тоелды. Хәер, профессор димәктән... Ул әле бүген дә Харрасны ике кулсыз итә язды бит. Харрасларны озатканда, вәгъдә биреп калды, сүзендә тормаган. Моны ничек аңларга соң? Нәрсәдән генә башланып китте соң бу эчпошыргыч аңлашылмаучанлыклар?..

* * *

Тышта коеп-коеп яңгыр ява иде. Иртәдән бирле бер генә мизгелгә дә тукталганы юк. Эзенә төшеп алган да шыбырдапмы-шыбырдый. Кешеләр инде көннең ачылып китүенә өметләрен өзгән: чыланудан куркып капка төпләрендә ышыкланып торучылар да, кызулатканчы өйгә кайтып җитәргә теләп бәрелә-сугыла йөгерүчеләр дә күренми. Әйтерсең лә, бу яңгыр дигәнең гел шулай явып торган, җирдәгеләр исә һаман шул бөркәнчекләренә төренеп йөри биргәннәр.

Утырыш башланганчы, бүлмәдәгеләр үзара сөйләшмәделәр. Кайсылары тәрәзәдән юеш урамны күзәтте, икенчеләре газета караштыргалап утырды. Берничә минуттан ачылачак киңәшмә монда җыелган тарихчыларны әллә ни кызыксындырмый да иде. Галимнәр һәр экспедициянең нинди «байлык» белән кайтуын күптән ишеткән, рәсми отчетлар тапшырылган. Бүген шул ук нәрсәләрне кабатлап кына утәчәкләр.

Шулай да чыгышлар шактый озакка сузылды. Сүз алып, иптәшләре алдына чыгып баскан һәр галим үз бурычын уңышлы үтәвен расларга тырыша, кат-кат бер үк хакыйкатьне тәкърарлый.

Ниһаять, трибунага археологлар бүлеге башлыгы Хәй Фәләхи менде. Профессор һәрчак бөтен кешенең чыгышыннан соң сүз ала, гомуми эшкә уртак йомгак ясап куя, киләчәк елда үтәлергә тиешле планнарга туктала иде. Ул сабыр гына сөйли башлады.

— Иптәшләрнең чыгышын мин шатланып тыңладым, — диде, — башкарылган эшләр күп, игътибарга лаек табышлар бар...

Профессор уң кулы белән куе бөдрәләрен сыйпады, зур күзләрен тутырып, залдагыларны берәм-берәм карап чыкты. Дәрәҗәсе зур булса да, Хәй Фәләхинең тышкы кыяфәте мондагы башка галимнәрнекеннән бик аерылмый. Әмма иңнәрендә зур җаваплылык ятуы әллә каян сизелеп тора. Буе озын булса да, төзлеген югалтмаган, хәрәкәтләре салмак, күзләре әрле-бирле йөгерешми, сүзләре ачык итеп, өздереп әйтелә — болар барысы да аны башкалардан өстенрәк, затлырак күрсәтә.

Хәй Фәләхи йомгаклауга күчкәч, күпсүзлелектән тәмам талчыгып беткән кешеләр игътибарлырак була башлады.

— Соңгы елларда без, үзебез дә сизмәстән, күп тармакларга бүлгәләндек. — Профессор нинди дер яңалык әйтергә җыена иде. — Минем дә хата бу, башкалар да кисәтмәде. Һәркем үзен кызыксындырган мәсьәләне өйрәнә бирде: Гали — үз эшендә, Вәли үзенекендә булды. Бу метод гыйльми хезмәтләрнең тематикасын төрләндерү өчен кулай иде. Киләчәктә көчләрне берләштерергә туры килер. — Профессор тавышын йомшарта төште, костюмын төзәткәләгәндәй итте, галстугының муенсасын тартып куйды һәм шул арада,— әйтик, Чирмешән буе экспедициясен, — дип өстәде.

Харрас җыелышларны яратмый, аларга «вакыт әрәм итүнең дә иң отышсыз варианты» дип карый. Бүген дә ул көчкә түзеп утыра иде. Аның инде чираттагы ялы алынган, акчасы кесәсендә. Трибунадан ишетелгән соңгы сүзләр аңардагы арыганлыкның, битарафлыкның эзен дә калдырмады. «Ничек? Чирмешән экспедициясен туктатсаң, эш ярты юлда бүленеп кала бит!» Ул шушы сәгатьтән үк ял кешесе булуын онытты. Профессорның теләр-теләмәс кенә әйтеп үткән фикере ялгыш икәнен раслар өчен, ул хәзер үк экспедиция белән чыгып китәргә һәм тәмам хәлдән тайганчы җирдә кабат чокчынырга әзер иде.

Профессор, залда зур кызыксыну уянганны сизмәмешкә салынып, яңадан гомуми сүзләргә күчте. Ике куллап трибуна читләренә таянды, озын гәүдәсен бераз алгарак биреп, башын игәндәй итте, бөдрә чәч толгәшләре күзенә төште. Аның сүзе беткән иде.

Аңардан соң чыгыш ясау, бигрәк тә ул алга сөргән планга каршы чыгу бүлек тарихында булганы юк. Харрас як-ягына каранды: иптәшләре үзара саубуллашалар, чыгып китү ягына агылалар иде. Аларны туктату, миеңә кереп утырган коточкыч уйны аңлатып өлгерү мөмкин эш түгел. Профессор янына керү, эчпошыргыч шик-шөбһәләр турында икәүдән-икәү генә гәпләшү дөресрәк булыр.

Хәй Фәләхи Харрас өчен коеп куйган профессор гына да түгел бит әле. Зур фәнни бүлекнең мөдире саналган бу кеше, Харрас белән беренче очрашканда, гап-гади аспирант Хәйбулла Фәлляхов иде. Фронт күргән, югары белем алуына чиксез шат бу археолог факультетның күз өстендәге кашыннан санала иде.

Студент халкы үзе чибәр, үзе акыллы, үзе гап-гади күренгән Хәйбуллага бераз көнләшеп тә, кызыгып та карый, тәнәфес вакытларында аның тирәсенә төркемнәре белән җыелалар иде. Харрас карашынча, Хәйбулла кеше ирешергә мөмкин булган иң зур биеклек иде.

Озын коридорның иң аргы караңгы башында беренче тапкыр очрашканда Харрас аңа якын килергә дә кыймады.

— Кара, син ник ятим бала кебек читтә генә торасың, — дип аспирант үзе башлап эндәште. — Кайсы яктан син?

— Авылныкы.

— Тарих бүлегенә эләгүләр авыр булгандыр, ә?

— Кыенлыктан курыккан юк ла анысы...

Харрасның сүзе Хәйбуллага көтелмәгәнчә тәэсир итте.

— Әһә! — диде ул.

Шул минуттан аның өчен тәмәке тартучыларның башкалары кызыгын югалткан кебек тоелды. Ул Харрас каршына килеп басты да аны тирә-юньдәгеләрдән аерып алгандай итте.— Безнең бүлектә күбесе шәһәрнеке бит, әти-әни тапканга ышыкланырга өйрәнгәннәр.

— Андый җае булса, әйбәт инде ул.

— Үзләренә ышанып эш тапшырыр хәл юк. Бер тотынгач, алныялны белми, җир җимертердәй егетләр кирәк миңа. — Ул ачылып китеп, көлеп алды. — Үзебезчә итеп әйтсәк, эш атлары кирәк!

— Эштән курыккан юк ла анысы...

Хәйбулланың шатлыгы йөзенә бәреп чыкты. Шул көннән башлап аспирант Хәйбулла беренче курс студенты Харрас Хәсәновның үз кешесе булып китте. Профсоюз комитетындагы форсатыннан файдаланып, студентны университетның иң яхшы саналган торагына күчерде.

— Яшәр җире җайсыз кешедән рәтле эш көтеп булмый, — диде.

— Нинди эш соң ул сезнең? — дип сорады Харрас. — Миңа кайда да бер. — Урнашып бетмәс борын сайланып йөрергә ул иптәшләреннән ояла иде. — Сез кушканга гына күчәм инде.

— Дөрес итәсең. Эше табылыр. Башта шартларын ясыйк.

Хәйбулланың үз бүлмәсе дә шул ук йортта икән. Берсендә ул Харрасны кичке чәйгә чакырды, туйганчы сөйләшеп утырдылар. Хәйбулла күп кенә серләрен чиште. Аспирантурадан соң ул фәнни институтка гыйльми хезмәткәр булып күчәчәк икән. Аның экспедицияләргә йөреп җыйган бик күп материаллары бар, шуларны рәткә салып, диссертация хәленә китерергә кирәк. Сүз кызып җиткәч, Хәйбулла:

— Миңа ашыгырга туры килә, — диде. — Картаям. Кулда — һөнәр, янда гаилә юк. Быел җәй үзем теләгән эшкә урнашсам, ике дә уйламыйм — өйләнәм.

Харрас, синең өйләнүдә минем ни катнашым бар дигән кебек, иңбашларын сикертеп куйган иде, Хәйбулла моңа да игътибарсыз калмады.

— Юк, энекәш! — диде. — Син битараф булып кыланма. Бу дөньяда бер генә нәрсә дә ялгыз эшләнми. Берләшергә кирәк безгә.

Харрас, майлы ипи ашавыннан туктап, көлеп куйды.

— Өйләнгәндә дәме?

— Көлмә. Бик беләсең килсә, ялгыз гына өйләнеп тә булмый. Минем кызның исеме — Гүзәл. Эч поша бит шуңа: нинди пар инде без? Хәйбулла белән Гүзәл! Эчне тырный гына бит шул нәрсә, ә берәүгә дә әйтә алмыйм. Менә сиңа, дус булганга, әйтәм, ике дә уйламыйм. Монысы, әйтик, вак мәсьәлә дә булсын инде. Ә фәнгә керим дисәң... Галимнең ачышларын кем хуплап чыга? Дусты! Башкалар икеләнепмикеләнеп торган арада, яки каршы әйтер сүз эзләп маташканда, теләктәш дустың тора да ярып сала: «Дөрес! ди, иптәш Фәлән Фәләнев әһәмиятле ачыш ясаган!» ди. Төшендеңме?

— Чынлап та ачыш булса ярый ла.

— Анысын алдан ук белер өчен, бергә-бергә эшләргә кирәк тә шул инде. Тәвәккәлләсәң, мин сине менә шул юлга димлим.

Хәйбулла Харрасны чәй эчәр өчен генә чакырмаган икән. Сүзенең азагында ул студентка үз экспедициясендә эшләргә тәкъдим итте. Җә-

ен Фәлляховның үзенә мөстәкыйль бер группа бирәчәкләр икән. Харрасның җавап әйтергә ашыкмавыннан шикләнеп, аспирант аңа әллә ниләр вәгъдә итәргә тотынды.

— Эштә килешеп китсәк, мин синнән первоклассный галим ясыйм! — диде.— Әйткән иде диярсең. Миңа үз кул астымда үскән ышанычлы галим-таяныч кирәк булачак.

Харрас, стакан төбендәге кефирны йотып җибәрде дә Хәйбуллага кулын сузды:

— Әйдә, яз экспедициянә! — диде. — Черт его бей, бабай әйтмешли. Карап карыйк!

Университетны тәмамлагач, башкалар авыл мәктәпләренә укытучы булып билгеләнгәндә, Хәйбулла Харрасны үз янына алдырды. Ул чакта ук инде аларның шактый мул уртак хезмәтләре бар иде...

Профессор ишеге төбенә җиткәнче Харрас күңеленнән шул хәтирәләр узды. Ишек тоткасына сузылган гына иде, кабинеттан яшь кенә бер хатын атылып чыкты. Аның кемлеге дә, коридорны яңгыраткан аяк тавышы да, уйлары бары экспедициясе язмышына гына бәйле Харрасны һич кызыксындырмады. Ул, гадәтенчә, «черт его бей»ны кабатлады да Хәй Фәләхи янына керде.

Профессор, өстәленә капланып, нидер яза иде. Харрас кергән мәлгә кымшана алмый торды — чөнки әйтер сүзе әзер түгел. Никадәр генә күптәнге дуслар булсалар да, Хәй — профессор, диссертация җитәкчесе. Аңа орды-бәрде теләсә ни әйтеп салырга ярап бетмидер: сүз ул — кош түгел, бер ычкындымы, аулап кире кайтара алмыйсың, әйләнеп кайтса да, зурайган була — авызыңа сыймый.

Юньле-башлы сүз эзләп таба алмаган Харрасны профессорның:

— Ник һаман эндәшмичә торасың? — дигән соравы сискәндерде.

Харрас, мәсьәлә тиз хәл ителер, профессор кул гына селтәр: «Башка кайгың булмаса, тынычлан, кайт та рәхәтләнеп ял ит!» — дип әйтер дип өметләнде. Әмма моңарчы гел шәфкатьле күренгән профессор яшь галимнең дәлилләрен ишетергә дә теләми иде.

— Без бит — баштин-аяк дәүләт кешесе. Син моны аңларга тиеш. План бар. Без аны вакытында үтәргә тиеш.

— Мин дәүләт эшенә аяк чаламмы әллә? Идел Болгариясенең тарихын ачыклау җинаять мени?

— Шул кадәр төпченүнең кемгә кирәге бар. — Профессорның тавышына үгетләүгә охшаш төсмер кушылды. — Синең аннан башка да диссертациялек материалың бар. Бер уртак нәтиҗәгә килгән идек бит инде!

Харрасның эче жу-у итеп китте. Ул нәкъ шул нәрсәдән курка иде. Тик бу хакта хәзер үк бәхәсләшергә теләмәде.

— Минемчә, нәтиҗәгә иртәрәк әле, — дип кенә әйтә алды. — Киресенчә, соңгы ачышлар, элекке фараз кылуларның күбесен шик астында калдыра...

Харрас сүзен очлап өлгерә алмады, профессор торып басты:

— Шикләнсәң, ихтыярың. Анда минем эшем юк. Чирмешән экспедициясенә сукыр бер тиен дә бүлә алмыйм!

Куллары кинәт йомарланган Харрас, ярамаган хәрәкәт ясап ташлавыннан куркып, йодрыкларын кесәсенә тыкты. Ишекне дә иңбашы белән этеп кенә ачты.

Кайсы сараны коридордагы утларны сүндереп өлгергәндер, аргы баштагы тычкан күзе кебек кенә бер лампочка калган. Харрас, исерек кеше кебек алпан-тилпән, яктылык сирпелгән якка атлады. Бераз баргач, үзалдына: «Кадалып кына китсен!» дип сөйләнде. Шул чак ярым караңгы тар коридорда күкләрдән иңгәндәй серле тавыш ишетелде.

— Нигә шул кадәр ашыгасыз?

Харрасның берәүне дә күрәсе, сөйләшеп торасы килми иде, алга

баруында булды. Тик бер адым да атлый алмады, йомшак кына итеп аны җитәкләп киттеләр.

— Сез мине беләсез, — диде шул ук тавыш. — Без Хәй Хәеровичның докторлыгын «юган» көнне банкетта танышкан идек.— Хатынның тавышы балаларныкы шикелле еламсырак иде.

Харрас коры гына җавап кайтарды.

— Хәтерләмим, хәтерлисем дә килми.

— Ярый, ярый, яңабаштан танышыйк алайса: мин — Солтания Карачурина булам. Дипломым тарихчыныкы, үзем газетада эшлим. Заманында археологиягә гашыйк идем, хәзер сезнең эш хакында газетага язып юанам.

Харрас бу хатыннан тизрәк котылу өчен тагын да усалрак сөйләшә башлады.

— Мине сезнең газета бөтенләй кызыксындырмый.

— Нигә? Мин менә сездән башка — ике кулсыз. Хәй Фәләхинең иң өметле шәкерте бит сез. Сезнең ачышларны укучыларга җиткерә барсам...

Харрас бу тәтелдек хатынны тыңламаска булды. Тик, урамга чыгып, үзенә кирәкле чатка борылганда, янында әле һаман ят кеше атлавын сизенеп, ялваргандай:

— Бүгенгә, зинһар калдырыгыз мине, — диде. — Барыбер газетага кирәкле сүз әйтә алмыйм.

Карачурина бөтенләй көтелмәгәнчә сөйләнә башлады.

— Мин сезнең кая ашыгуыгызны беләм, — диде. — «Арбузовка»га, шулай бит? Аракы эчәргә.

Җанны көйдереп торган уйлар бер мәлгә артка чикте. Археолог көннең ачылып куюына игътибар итте, яңгыр туктаган, һава саф, җылы иде. Журналистканың да сүзе дөп-дөрес, Харрас чыннан да хәзер кафега кереп, чыгырыннан чыгарга җитешеп дулаган күңелен басмакчы иде. Туры сүзгә җавап бер.

— Әйе шул! — диде ул.

Солтаниягә җиңелрәк булып китте.

— Сезнең эш турындагы мәкалә планга кергән, газетада аңа урын калдырылган.

— Яза бирегез, Карачурина иптәш! — Харрас мавыгып китте. — Фамилиягез кызык сезнең, мин моңарчы Акчуриннарны гына белә идем. Язгыз, яз!

— Язуын язам мин аны, үзем ачкан рубрика ул. — Солтания фирүзәдәй яшел күзләрен Харраска төбәде. — Сезнең экспедициянең киләчәккә планын гына әйтегез!

Археолог елмаерга тырышты, ләкин булмады, йөзе тагын да чытыла гына төште, ул үзен-үзе белештермичә ачынып:

— Аһ, әгәр дә мин киләчәкнең ниндилеген белсәм! — диде дә Карачуринаны җитәкләп алды. — Алай-болай ачыклый алсагыз, миңа да әйтерсез әле, яме?!

Солтания утырышта сизеп алды: матбугатта кузгатырлык ниндидер конфликт куера монда. Үзең ачкан рубрикада шул проблеманы хәл итүдә катнашсаң, матбугат дөньясында тир түгеп йөрүеңә үкенмәскә дә була. Әмма утырыш барышында гына бөтенесен дә аңлап өлгермәде Солтания. Профессор янына керү дә ярдәм итмәде, ул Чирмешән экспедициясе турында бер ни дә әйтмәячәген белдерде. Үзе артыннан ук кабинетка Харрасның да керүен күреп калмаган булса, Солтания әллә кайчан өенә кайтып киткән иде инде. Ахыр чиктә, археологларның йомгаклау утырышы турында шоп-шома информация язып та котылырга мөмкин. Сизеп өлгерде шул ул, бу бүлектә ниндидер «мөгез» чыгуын сизде. Шуның төбенә төшмичә ул тынычлана ал-

маячак, кулына каләм алып, язарга утырмаячак. Солтания бу очракта булырдай хәлләрне фараз кылып карады, язылачак мәкаләсенә берничә исем дә уйлап куйды: «Кем хаклы?» яки «Яшь археологның ялгышы»...

Карачуринаның мәкаләләре укучыларны умарта күченә таяк тыгып болгаткан ій «гөж» иттерә. Аңа бик күп хатлар килә. Казандагы укучылары, редакциягә кереп, аңардан киңәшләр сорыйлар. Хәтта дәгъвачылар да редактордан «минем гаризаны Карачурина тикшерсен иде!» дип үтенәләр.

Кешеләр ышанычын аклау өчен ничек тырышуын Солтания үзе генә белә. Редакциядә аңа бик җиңел яза, теләгәненә тиз ирешә, дип карыйлар. «Выжт» иттереп чыгып китә, «ялт» иттереп язып та куя, дип сөйлиләр. Ә мәкаләдә телгә алыначак кешеләр турында, авыз тутырып сүз әйткәнче, журналистканың төн йокыларыннан уянып, шул язмышлар хакында уйланып ятуларын, акка кара булып төшәчәк һәр тәгъбирне миеннән суырып чыгаруны берәү дә сизми. Солтания һәр язмасыннан соң үзен согы сыгылган әфлисундай суырылып калгандай тоя. Һәр мәкаләсен ул гомереннең вак-вак өлешләре итеп күрә. Шуңа күрә әйтеләчәк фикерләренең тулысынча дөреслегенә ирешергә тырыша.

Солтания Карачуринаның журналистикадагы уңышларының сере шунда: ул, тешләп тартсаң, авызыннан бер сүз чыгармас кешеләрнең дә телен яза белә, вакытын кызганмый. Кая ул эш сәгате белән санашып торулар?!

Бүген генә дә ул ике эш көненә сыймаслык вакытын үткәрде инде. Иртәнге дүрттән торып, баш саф чакта мәкалә язды. Машинистка басканнан соң аны әле тагын төзәтергә туры килде. Ул эше очланып та бетмәгән иде, редактор яңа темалар биреп чыгарды. Барысы да ашыгыч, һәммәсен мең кат тикшерергә кирәк: уннарча кешеләр белән очрашырга, әллә кайларга барырга. Археологларның йомгаклау утырышына катнашырга кирәген Солтания үзе әйтте. Редактор:

— Бар, — диде. — Анысы үзең башлаган рубрика, тик вакыт исраф итү генә булмасын, кызыклы, проблемный мәсьәлә табылмасмы. Аңа кадәр мәктәпкә кереп чык, уку елының беренче сборын үткәрәләр, информация бирергә кирәк.

Сбор бик сүлпән узды, газеталык материал чыкмады. Бөтен өмет археологлар утырышы иде, әмма монда да җеп очы әллә кая кереп югалды. Ничек тә Харрас Хәсәновның телен чишәргә иде!

Солтаниянең эче поша башлады. Ире Дөлфәт өзгәләнеп көтә торгандыр. Ул соңгы вакытта хатынының соңга калып йөрүләреннән бөтенләй башка нәтиҗә чыгара. Әле кичә генә халык театры премьерасыннан кайткач, элеккечә: «Нәрсә, язарлык әйбер таптыңмы соң?» — дип сорап тормады, Солтаниянең туфлиләрен тикшерергә тотынды. Карады-карады да:

— Гаҗәп! — диде. — Урам чатындагы сазлыктан кем күтәреп чыгарды, бер дә пычранмагансың?..

Солтания күңелен кимерүче шомлы уйларын Харраска сиздермәскә тырышып:

— Без шул «Арбузовка»га керәбездер бит? — дип сорады, күңеленнән бөтенләй башка уй үтте. «Уф, аллам, бу кешеләр нигә шулай берсен-берсе интектерә икән? Бер-ике соравыма өзеп җавап бирсә, бер тиенемә дә кирәге калмас иде Хәсәновларның. Тагын соңга калам бит, Дөлфәт тагын тиресенә сыймый башлагандыр»...

Харрас артык киреләнүне килештермичә:

— Ярар соң! — диде. — Сезнеңчә булсын, «Арбузовка»га керик!— Үзе аклангандай өстәде. — Мин кафе буйларында еш йөрмим, гаилә бар, төшкә дә өйгә кайтам.

— Сез күп вакыт өегездә эшлисез бит.
— Анысын да беләсезмени? Институтта кабинетлар җитми.
— Шулай да Фәләхи башкаларга өйдә эшләргә рөхсәт итми.
Бу хатынның институт хәлләреннән артык хәбәрдар булуы Харрасны гаҗәпләндергәннән гаҗәпләндерә барды.
— Ничек шул кадәр барысын да ишетеп торасыз?
— Үзем археолог була алмадым инде, әйтсәм әйтим, күңелдә бер хыял йөри, шул хакта бер китап язып булмасмы, дим.
Харрас, барган җиреннән тукталып, Солтаниягә борылды. Хәй Фәләхи диссертация яклагач, бер мәкалә чыккан иде, эчтәлеге-фәләне истә юк, исеме хәтердә: «Таш гасырыннан татарча сәлам!» Харрас бу сүзне кычкырып әйтте.
Солтаниянең башы күккә тиде, ул барган җирендә сикергәләп алды, елмаеп:
— Ә-ә! Үзегез мине танымаган булып кыланасыз! — диде.
Журналист халкының күңелен күрим дисәң, ул язганны укуың турында сөйлә инде. Аңа шуннан да зуррак куаныч юк.
Алар «Арбузовка»га җиткәннәр иде инде. Харрас һич көтмәгәндә үзенә юлдаш иярүенә, аның да әле хатыннар затыннан булуына уңайсызланып торды. Ялгызы керсә, куәтлерәк бер эчемлек салдырыр иде дә әйләндереп каплар иде. Хәзер Карачурина теләге белән исәпләшми ярамый. Этика!
— Сезгә нәрсә алыйм?
— Сезгә-безгә дип аерып тормабыз инде, тотыйк та бер «Шампански» шартлатыйк. Ял кешесе бит сез, моңа гына хакыгыз бар.— Хатын тагын үзе өчен офтана башлады. «Дөлфәт бүгенгә чыдаса, иртәгә алданрак кайтыр идем»...
Солтания түр почмактагы өстәл янына килеп ишеккә арты белән утырды. Харрасның буфетчы белән сөйләшүе аңа аермачык ишетелә иде.
— Дядя Боря, ач әле бер «Шампанскиеңны»! Отпускыга чыктым, юарга кирәк!
Яһүд карты алтын кысалы күзлеге аша Харраска сынаулы караш ташлады. Кафега сирәк йөрүчеләрдән булса да, бу юлы археологтагы үзгәрешләрне ул да сизде: озын гәүдәсе тагын да сузыла төшкән кебек, керпе энәседәй тырпаеп, кара чәч өстенә ялтыравык бөртекләр сибелгән, йөгерек кара күзләр тагын да тирәнгәрәк төшеп утырган, битендә чыпчык чукырлык та ит калмаган, диярлек.
Картның болай озак карап торуын үзенчә юрап, Харрас:
— Карачурина ул! — дип, иптәше белән таныштырырга ашыкты.— Газетадан, күренекле журналистка!
Буфетчы мыек астыннан гына елмайды. «Мондый җиргә кергән хатыннарның чын исемен әйтәләрме? Юк, әлбәттә. Игътибар итмәвең хәерлерәк».
Солтаниянең исә бөтен җанын сүз белән аңлатып бирергә мөмкин булмаган тынычсызлык урап алды. Харрасны берәз сөйләндерсә, уктай өенә атылыр иде. Шәраб тулы бокалын югарырак күтәрде дә:
— Теләсәгез, буталып беткән бу дөньяда ярдәмчегез булырга әзермен! — диде ул.
Газлы эчемлеккә ваклап салынган шоколад кисәкләре бер аска төшеп, бер өскә атылып уйнаклый башладылар. Харрасның моңарчы бу хикмәтне күргәне юк иде, сокланып ешермәде.
— Кара, дельфиннар кебек!
Солтаниянең зәңгәрсу-яшькелт күзләре Харрасның һәр хәрәкәтен, ябышкак алтын алка киертелгән колаклары археологның һәр сүзен аулый барды. Берсен дә онытмаска!
Яза торган кешегә күргән нәрсәләрен, ишеткән хәбәрләрен саклау

өчен куен дәфтәре белән карандаш бирелгән. Тик аларны теләсә кем алдына чыгарып салып булмый. Солтания хәзер дәфтәрен, каләмен алып куйса, Харрастан ярты сүз дә чыкмаячак. Барын да хәтергә сеңдерергә, чигә тамырың шартлар хәлгә җитсә дә, түзәргә кирәк.

Беренче бокалын эчеп җибәрүгә, нәкъ Карачурина уйлаганча, Харрас йөрәгенә кадалган мәсьәләгә якынлаша башлады.

— Чокчынып ят син җир куенында! — дип куйды. — Кайткан төшенә этлек эшләп торалар. Кем көткән аны Хәй Фәләхидән!?

— Мин моңа ышанмыйм, — диде Солтания. Кире тырнап, хәзер Харрасны тәмам ,чишеп җибәрәчәк ул. — Хәй Фәләхи сезгә бернинди начарлык та эшләмәячәк!

— Их, сез, газетчиклар! Нәрсә беләсез соң?

— Белергә тырышабыз.

— Белә алмаячаксыз сез аны, беркайчан да, мәңге! Мин үзем дә болай тиз бәреп чыгар дип көтмәгән идем аны.

— Ачулы чакта гына шулай тоела ул.

Харрас эчемлекне тагын йотып куйды.

— Ә-әхх! — дип, ләззәтләнүен белдерде. — Нәрсәнең ничек тоелуын гына беләбез инде анысы. Минем экспедиция материаллары Хәй Фәләхинең Болгар дәүләте чикләре турындагы фикерен пыран-заран китерде. Барысы да шуннан башланды.

— Профессор бу хакта миңа үзе сөйләде, сезнең зур ачыш иде бу. Язып та чыктык ич!

— Мин ясаган һәр яңалык профессорның әллә кайчан фараз кылып куйган положениеләрен юкка чыгара барды, анысын яздыгызмы соң?— Харрас читкә караган, гел үзе өчен генә сөйләгән кебек утыра иде. — Әйткәләде ул миңа, синең Болгар чикләрен киңәйтүең үзе генә дә бер диссертациялек материал, диде...

Тик Харрас ярты юлда тукталырга уйлап та карамады. Ул үзе кызыксынган дәүләтнең XIV йөздәге, ягъни Алтын Урда чорындагы хәлен тикшерергә тотынды.

Харрас кулындагы мөлдерәмә бокалына иренен дә тидермичә, кире өстәлгә куйды.

— Менә сез, иптәш Карачурина, беләсезме: Алтын Урда чорында болгарлар үз акчаларын сугып ятканнар. Мөстәкыйльлекме бу? Ә Хәй Фәләхи әйтә, болгарлар баштин-аяк буйсындырылган, ди. Минем кулда Акъяр болгарларының XIV йөздәге акчалары бар! Һе! Аңа нәрсә, белер-белмәс ашыгыч нәтиҗәләр чыгарып куйган да хәзер шуларны Харрастан кабатлатмакчы була, ә? Ай-й-у-ук, булмас!

Сүзләре шул урынга җиткәч, Харрас шып булды. «Эзлим, тарихи дөреслекне табам!» — дип лаф орып утыруның, әгәр профессор рөхсәт итмәсә, сабын куыгыдай шартлый торган буш нәрсә икәнлеген тоеп алды ул. Чыраен сытты, бокалына сузылды.

Солтания моңарчы күбрәк Хәй Фәләхи ачышлары белән кызыксынган — аның татар дөньясы өчен күптән көтелгән шәхес икәненә инанган иде. Харрас кебек яшьләр журналистиканың игътибарын җәлеп итәрлек хезмәт күрсәтә алмаганнар иде әле. Фәләхинең исә фәннәр кандидаты дәрәҗәсе алу өчен язылган хезмәте үк галимнәрне таң калдырды. Алар беравыздан: «...ыз гына киңәйтеп җибәрсәң, бу эш докторлык диссертациясенә торырлык», — диделәр.

Археологларның катлаулы иҗаты турында тын гына уйланып утыручы Карачуринаны сискәндерәп, Харрас кинәт:

— Һа! — дип куйды. — Хәйбулла минем экспедициягә акча бирмәячәк, ә?!

— Анысы кем тагын?

— Шул үзе — яраткан профессорыгыз.

Солтания, бокалдагы «дельфиннар» биюен күзәткән булып, шәраб-

ны авызына да алмый утырды. Хәмер менгән башта нинди фикер торсын. Монда ишеткәннәрне онытырга һич ярамый, әлләниләр сөйли бит бу Харрас...

Исеменнән башта ук канәгать булмаган Хәйбулла, олы галимнәр белән аралаша башлагач, бөтенләй кимсенә иде. Өстәвенә, тупырдап баласы туды. Харрас яхшы хәтерли: Хәйбулланың ата булу шатлыгын уртаклашкан кичне, бу башваткычны икәүләп чиштеләр.

Моңарчы дустының исеме турындагы офтануларын кысыр хәсрәткә санап йөргән Харрас та, Хәйбулла: «Нәрсә, атом чоры егетенә «Хәйбуллович» тамгасы сугыйкмы инде?» — дигәч уйга калды.

— Соң, тот та үзгәрт син аны!

Ике исәп — бер хисап, Хәйбулла тәвәккәлләде. Үзгәртүнең бик җиңел ысулын Харрас тапты.

— Син биюче Шай Заһирны беләсеңме?

— Белмичә!

— Аның тулы исеме Шәйхулла, фамилиясе Заһруллин булганын да беләсеңме?

Хәйбулланың күзе дүрт булды. «Хәйбулла»дан «Хәй» ясау аның үз башына тиз генә килмәс иде мөгаен. Фамилиянең койрыгын кисү үзеннән-үзе аңлашыла: «Фәлляхов»тагы бер «л» хәрефен алсаң, мәгънәсенә кадәр галим файдасына үзгәрә икән. «Крәстиян»лектән «бәхет», «уңыш» нясенә әйләнәсең дә куясың.

Шулай итеп Казанда тарих фәннәре докторы Хәй Фәләхи дигән галим барлыкка килде.

Солтания Харрасның бу «гайбәт»ен бирелеп тыңлады. Һәрвакыт шулай була, язылачак материал янында матбугатка керәге юк дөнья кадәр мәгълүмат кала. Героеңның образын аңлар өчен, язар материалыңа юнәлеш биргәндә исә алар бик ярап куя.

*

* *

Харрасның, хатынына әйтми-нитми, соңга калып йөргәне юк иде. Баскычтан менеп, квартиралары каршына килеп басуы булды, ишекне эчтән Кәримә ачып җибәрде. Борчылуы йөзенә үк чыккан, тавышы тоныкланган.

— Кер тизрәк, бигрәк озак тордың,— диде ул.

Юл буе: «Хатынга ничек аңлатырмын?» — дип баш чатнатып кайткан Харрасның өстеннән тау төште. «Бигрәк беркатлы минем хатын, дип сәерсенде, элеп алып селкеп саласы урында, ишек ачып каршылап тора»...

Йоклар урынны хатын залдагы диванга түши башлагач кына, Харраска шик йөгерде.

— Ник монда җәясең?

— Тегендә бала йоклый, шунда гына ят. Үзеңә дә тынычрак булыр...

Бу сүзләрдә шомлы төрттерү сизеп, Харрас мөнәсәбәтләрне ачыклап куярга теләде. Теле дә сөйләшергә талпынып тора. Ул хатынының солы көлтәседәй аксыл сары чәченә сузылды.

— Беләсеңме, канатым,— диде хатынының туган ягындагы мишәр сүзләрен кыстырып. — Синең иреңне бүген нишләттеләр? Сожрут миңе, беләсеңме, сожрут!

Кашларының җыерылуын иреннән яшерү өчен, Кәримә читкә борылды.

— Калганы житәр, бөтенләй ашап бетерә алмаслар. Безнең яклар әйтмешли, дөнья куласа, әйләнә дә бер баса, безнең файдага да бер басар әле, әйдә, ят, йокла.

Профессор белән Харрасның «чәкәләшүен» Кәримә ишетеп өлгер-

гән иде инде. Күңелсез хәбәрләр һәрчак шулай һич кирәксезгә бик тиз килеп ирешә.

Башта берәү телефоннан шалтыратты, Харрасның өйдә юклыгын ишеткәч: «И-и мескенем», — диде. Кәримә бу сәер тавыш тәэсиреннән айнырга да өлгермәгән иде әле, өйгә күзләре маңгаена менгән Әскәр Шәехович килеп керде. Ул Харрас белән бергә эшли. Археолог егетләр, карьерага омтылуыннан көлеп, аны «Шейх» дип үртиләр. Кызык, үзен мыскыл итеп таккан шул кушаматны Әскәр үлеп ярата.

Кәримәләр «Шейх» белән аралашмыйлар. Бу юлы, тиктомалдан Әскәрнең килеп керүен Кәримә башына сыйдыра алмады. Шулай да: «Узыгыз!» — дими ярамый.

Әскәр ашыгып түргә үтте, Харрасны күрмәгәч, йокы бүлмәсенең ишеген ачты, кухняны айкап чыкты.

— Әле һаман кайтмаган икән, мескенем, — дип мыгырданды.

Кәримә шунда ук телефоннан шалтыраткан кешенең дә шул ук «Шейх» икәнлегенә төшенде. Аның тизрәк чыгып китүен көтте, тик Әскәр хуҗабикә фикере белән бөтенләй кызыксынмый, ишекле-түрле йөренә дә йөренә иде. Атлаган саен ботинкасыннан чумар-чумар балчык төшә. Баласының елаудан туктаган минутларын көтеп торып, Кәримә бүлмәләрне җыештырып чыгарган иде. Ирем кайткан җиргә өй чиста, җанга рәхәт тудырырлык булсын, дип тырышты. Рәхәтләндерә менә!

— Сез, Кәримә ханым, борчылмагыз, кайтыр ул кайтыр. Институтта бер неприятность булып алды, но ничего, чыдар ул...

Тормышта гаҗәеп закончалык яши: күңелсез хәбәрне синең күңел өнәп бетермәгән кеше ташый. Әллә ул кешеләр җан өшеткеч хәбәрләрне үзләре эстәнеп йөриме? Яралы бөркетне сагалаучы козгын кебек.

Кызыксынуы, шомлануы, офтануы никадәр көчле булса да, Кәримә ире хакында Әскәрдән бер генә сүз дә ишетергә теләми иде. Әмма «Шейх» кебекләр өчен кемнеңдер теләү-теләмәве шарт түгел. Ул, каударланып, ашыгып, институтта булган күңелсезлекләрен аңлатырга тотынды.

— Янды Харрас! Бетте! — диде. — Экспедицияне харап итте.

Кәримә агарынып катты. «Харрасның бөтен яшәеше экспедицияләргә бәйле, аны ничек харап итәргә мөмкин? Кем? Хәй Фәләхиме?. Мөмкин түгел! Алар дуслар ич!» Җанын берьюлы меңсорау йолыккалый башлады, шулай да «Шейх»ка сер бирергә теләмәде. Хәтта елмайгандай итте. Әскәр, аны кыздырырга өметләнеп, утка ялкын өсти торды.

— Хәй Фәләхи әйткән сүзеннән кире кайтмый ул. Шул кадәр авторитетный җыелышта үзе билгеләгән курсны тиз генә үзгәртсә, нинди профессор була инде ул?

Кәримә телен көчкә әйләндереп:

— Юкка кайгырмагыз, Әскәр Шәехович! — диде. — Аңлашырлар әле, бергә эшләгән кешеләр бит.

Хатынның сыгылып төшүен көткән «Шейх» бу сүзләрдән үзе зәңгәрләнеп чыкты. Харрас белән профессорның дуслыгы аның талагында таш булып утыра иде. Ник ул профессор шул авыл малаен күкләргә чөеп куя да, ник «Шейх»ны вак-төяк эш артыннан чаптыра соң? Телләрендә гел «Хәсәнов ачышы» да «Хәсәнов экспедициясе», мөстәкыйльлек биреп «Шейх»ны чыгарып җибәрсәләр, шул ук чүлмәк китекләрен җыеп кайтмас идеме? Дуслар, имеш!

— Дуслыклары әллә нишләгән шул әле.— Ә[illegible] ничек тә Кәримәне пошындырасы килә иде. — Харрас җые[illegible] соң шеф янына кергән иде, әрепләшеп кенә чыкты. Монысы инде, Кәримә ханым,

чеп-чи ахмаклык. Диссертация яклавы борын төбендә торганда, боже мой, нинди ахмаклык бу! Әллә кайчан көлләре күккә очкан болгарлар хакында үзеңнең генә түгел, гаиләңнең киләчәгенә аяк чалырга!

Кәримәнең чыдамлыгы чатнады.

— Хафаланмагыз, — диде. — Һәрхәлдә сезгә зыяны тимәс!

«Шейх», ак керфекләрен пелт-пелт уйнатып, төссез күзен Кәримәгә төбәде.

— И-их, сез! Нәрсә аңлыйсыз соң? Сезгә шул әнә бала багу гына төс!

— Минем бала үстерүемне дә гаепләмисездер бит инде?

— Үстер, үстер! — «Шейх» үз запасында әле хатынны аяктан егарлык хәбәре барлыгын исенә төшереп көлемсерәде. — Балаңны кочаклап утырып та калырсың әле.

Ул, коридордагы утларны сүндереп, Харрасны көтүен, соңыннан Харрасның Карачурина белән кафега кереп китүләрен карап калган иде.

Бу хәбәрнең Кәримәне чарасыз итүенә шикләнмичә, балкашык кадәре генә йөзен сытып, «Шейх» ишек ягына борылды.

Башта бөтен ачуын Әскәрдән генә күргән Кәримә тора-бара шиккә төшә башлады. «Нишләп Харрас Карачурина белән киткән? Кая? Нинди кафега?.. Бөтенләй кайтмаса?..» Тышкы ишекнең ачылуын-ябылуын тыңларга тотынды. Кереп-чыгучыларның адымнарына колак салгалады. Бөтенесе арасыннан Харрас атлавын әллә каян танып алыр иде ул.

Бала йокыга талгач, Кәримә ишек янына ук килеп басты, ирен шул хәлендә каршылады.

Хатынының институт хәлләрен ишетеп өлгергән булуы Харраска бик гаҗәп тоелды.

— Син әле бәлки Карачуринаны да беләсеңдер? — дип сорады. Янәсе аңарда бүген яңалыкларның иге-чиге юк.

Кәримә җәпчергә тотынды.

— Танцы булса, иң күп бөтерелүче шул иде инде! — диде. — Тәнәфестә, егетләрдән уздырып, тәмәке төтәтә иде.

Кәримә Солтания тәмәкене нилектән тарта башлавын да белә. Ул вакыйганы студентлар авыздан-авызга сөйләп йөрттеләр.

...Солтания Карачурина, сигезенче классны тәмамлагач, күрше авылның унъеллык мәктәбенә йөри башлый. Өйдә авыру әнисе булганга, Солтания коеп яңгыр яуса да, кышкы буран котырса да, дүрт чакрым араны үтеп өенә кайта, куна калмый. Ялгыз йөрергә дә өйрәнеп бетә ул, җае чыкканда юлдаш табарга да тырыша.

Унынчы классны тәмамлар елны, язгы ташуны сәбәп итеп, авылдашлар барысы да кунарга ниятли. Солтаниягә калырга ярамый, чөнки нәкъ шул араларда әнисенең хәле аеруча начарлана, урын-җирдән тора алмый башлый.

Солтаниянең юлдаш эзләп йөргәнен күргән бер кыз, аны кызганып, үзе мәктәп урнашкан төп авылныкы булса да, классташы белән юлга чыгарга тәвәккәлли.

Юлның юл диярлеге калмаган иде — кар боламыкка әйләнгән, һәр баскан эзгә мөлдерәп су тула. Ярты юлны үткәч, кызлар җәен тар гына инеш булып агучы елга янына җиттеләр. Елга киңәйгән, ярларыннан ташып чыккан, шаулап агып ята. Солтания:

— Кире борылыйк! — диде.

Тәвәккәл кызның үзе башлаган эшне ахырынача җиткерәсе килә иде.

— Кит әле! — дип, батыраеп кычкырды ул. — Уртадагы бозга сикерәбез дә атлап чыгабыз!

— Картлар әйтә: язгы боз, ястык калынлык булса да, ышанма, ди.

— Син, дустым, йөз яшьлек картлар сүзенә ышанма, менә миңа унҗиде яшьлек кенә булсам да ышан! — Гомерендә беренче юлга чыккан кыз, шарык-шорык көлеп, яр читендәге йөгерек судан җитез генә атлап, уртадагы боз утравына сикерде.

Калганы бер мизгел эчендә булды. Боз нәкъ кыз баскан төштән уелды да агып китте, бер-ике метр да үтмәде, урталай ярылды. Кыз шашкан тавыш белән:

— Мин йөзә белми-им! — дип кычкырды.

Солтания, букчасын читкә атып, аяк астына күз дә салып тормастан, суга ташланды, классташы артыннан йөгерергә тотынды. Бозлы су аның резин итек кунычларына тулды, биленә җитте, күкрәгенә якынлашты. Ул арада дустын күздән югалтты. Тирә-юньне Солтаниянең ачыргаланып кычкырган тавышы яңгыратты.

— Син кайда-а-а? — Ул инде аякларында басып тора алмый, боз аккан уңайга колачлап йөзә, үзе дә ага иде. Әле аркага, әле кулбашына бозлар бәрелә, зуррак кисәкләр баш өстеннән үтә, тәмам хәлсезләнгән Солтанияне аска этәләр иде.

Кинәт ниндидер көч Солтанияне югарыга тартты. Ул үзен-үзе белештермичә өскә күтәрелеп караган иде, авылларының ветфельдшерын күрде. Кыз куркынган хәлсез иреннәрен кыймылдатып:

— Мәйсәрә кайда соң? — дип сорады.

— Анысы кем тагын? — Фельдшер карашын кинәт караңгыланып калган офыкка төбәде, анда һичнинди җан әсәре дә күренми иде.

Солтаниянең борын яфраклары киңәеп, күзләре төссезләнеп калды. Соравына җавап ала алмагач, ул ят тавыш белән кычкырырга, бәргәләнергә, йолыккаланырга тотынды. Юлаучысыннан язган кыз баланың хәле табигыйлектән ерак иде. Ветфельдшер:

— Мәле, сеңелем, киемнәреңне алмаштыр! — дип, аңа озын, киң шарфын, курткасын салып бирде.

Кыз һаман кулларын гына бутый, берни дә кирәкмәгәнне аңлата иде.

— Гомерлек чирләшкә булып каласың бит, чишен, карамыйм.

Солтания гүя аны ишетми дә иде. Аптырагач, фельдшер соңгы чарага тотынды. Башта ул «Беломор»ны үзе суырды. Аннары эндәшми-нитми генә Солтаниягә сузды. Папирос очында ут күренми, кыз сабырлана төште, күтәрелеп, коткаручысына карады. Шуны гына көтеп торган фельдшер: «Мәле, суырып ал әле, сеңел, тәмәке төтене күңелне баса ул», — диде.

Солтания тәмәке суырган саен чыннан да тынычлана барды. Киемнәрен дә алмаштырды. Алар атка атланып урта мәктәпле авылга кире борылдылар.

Иртәгесен аңа әнисе улу турында хәбәр килеп ирешә. Сигез көннән соң Мәйсәрәнең гәүдәсен табып алып кайттылар.

Бу коточкыч хәсрәтләрне кичергәндә, тәмәке төтененең хикмәтле тәэсирен Солтания кабат искә төшерде...

Йөрәгенә көнчелек уты капкан Кәримә боларны Харраска сөйләп тормады, әлбәттә. Киресенчә, Карачуринаны мөмкин кадәр ямьсезрәк күрсәтергә тырышты, усал сүзләр эзләп азапланды.

— Тарих бүлегендә укыса да, эшнең җайлысын тапты ул, — диде. — Акчаны күп төшерә торгандыр, язган бер нәмәрсәсенә аерым түлиләр ди бит анда. Иргә чыккандырмы, белмим.— Хатын Харраска күз салды. — Хәер, аның кебекләр бик аптырап тормый, синең ише берәрсен йортка кертеп куяр әле!..

— Ну-у, энкәсе, барын да каян ишетеп өлгерәсең соң, ә?

— Ишетелмәс дип уйлаган иденмени әле?

Ир белән хатын аңлаша алмый калды, ишек кыңгыравы чылтырады.

Бу — Әскәр иде. Ишек ачучы Кәримә белән кабат сәламләшүне кирәксенмичә, ул туп-туры түргә узды. Харрасны күргәч, зур портфелен ачып коньяк чыгарды да өстәл уртасына дыңгылдатып китереп утыртты.

— Артыңнан чаба-чаба, аяк астыннан утлар чыкты, малай,— диде.

Бүген, бүлектәге эшләре чәлпәрәмә килергә торганда, үз өендә «Шейх»ны күрү Харрасның башына сыймый иде. Әгәр аңардан: «Син ни өчен Әскәрне яратмыйсың соң?» — дип сорасалар, Харрас тиз генә җавап бирә дә алмас. Кешеләрнең үзара мөнәсәбәтен сүз калыбына салып бетерү мөмкин дә түгел, күрәсең. Әмма Әскәр үзе Харраска булган карашын бик яхшы белә. Ул Харрасның талантыннан, эшләренең гел уңайга гына агышыннан саташырга җитешеп көнләшә иде. Харрас Хәсәнов экспедицияләре елның елында фәнгә кечкенә генә булса да яңалык алып кайта. Яшь галим ачышларыннан кыйммәтле фикерләр, гомумиләштерүләр ясый белә.

Тарихчыларның киңәйтелгән бер утырышында Харрас шул ачышлардан төзелгән популяр лекция укыды. Утырышны алып баручы Хәй Фәләхи ул вакытта Харрасны:

— Археологлар бүлегенең талантлы яшь галиме! — дип тәкъдим иткән иде.

Лекция башланды. Әскәр, үзе дә сизмәстән, Харрасның һәр сүзенә бәйләнергә тырышып утырды. Тик лекциянең эчтәлеге шундый мавыктыргыч булып чыкты ки, «Шейх» бөтенләй онытылып китте. Бүлектә нибары бер ел эшләгән «малай» Бөек Болгар дәүләтенең яңа шәһәрләрен ачкан. Арада Акъяр шәһәренең язмышы аеруча кызыклы иде.

Бу шәһәр Болгар дәүләтенең иң зур каласыннан саналган. Кызганычка каршы, аның кайчан салынуы әлегә билгесез икән, елъязмаларда ул беренче тапкыр, Андрей Боголюбскийның Болгарга һөҗүм ясавы уңаеннан, 1164 нче еллар вакыйгасын тасвирлаганда телгә алына. Уникенче йөз башында шәһәрдә илле мең кеше яшәгән. Шушы урында Харрас кызыклы бер чагыштыру китерде:

— Беләсездер, — диде, — бу вакыт Лондонда да нибары егерме мең генә кеше булган.

Харрас Акъяр буендагы эзләнүләргә зур өмет баглавын да яшермәде. Бер калкулыктан ике агач өй калдыгы табылган. Өйләрдән аз гына читтәрәк тимер һәм бакыр эретү мичләре булганын раслаганнар. Археологлар бик күп тимер, бакыр көлләре, чүлмәк китекләре, кирпеч ватыклары, сфероконус дип атала торган терекөмеш савытлары тапканнар...

Яшь галимнең шушы чыгышы ук Әскәрнең бөтен тынычлыгын бозды. Ул үзе бүлектә ун елдан артык эшләп тә телгә алырлык бер генә ачыш та ясый алганы юк бит.

Җитмәсә, ни хикмәттер, бу Харрас дигән егет бөтен кеше белән дуслашып та өлгерде, теләсә кем белән ачыктан-ачык сөйләшә, сораша, аңа бөтен дөнья үзе булыша, эшләрен җайга салыша кебек иде. Салкын акыл белән исәпләп карасаң, профессорның Харрасны якын итүе, дус күрүе ачык аңлашыла: булмастайга мең көчеңне сарыф иткәнче, ник әнә шундый уңганнарга ярдәм күрсәтмәскә?!

Харрас әрсез кунакның иңбашына шапылдатып сукты.

— Әйдә, «Шейх», эчик әле алайса бер! — Аннары ул кухня ягына борылып кычкырды: — Әнкәсе! Чыгар әле закускаларыңны!

Җиде төн уртасында, аннан-моннан гына оешкан табынга Кәримәнең әйләнеп тә карыйсы килми иде. Бер-берсеннән ут белән су, җир белән күк сыман аерылып торган бу ике кешенең ни хакында сөйләшәчәген белергә теләп кенә, хатын да өстәл читенә чүмәште.

Харрас чәркәләргә коньяк салды.

— Ну, нәрсә өчен җиффәрәбез? Әйт, «Шейх»!

Тегесе урыныннан торып басты, күзләрен мелт-мелт йомгалады да чәркәсен югары күтәрде.

— Бүген минем күз алдымда иң изге санап йөргән бер нәрсәм — шефыбыз белән яшь талант Харрас Хәсәнов арасындагы самими, иҗади дуслык таркалды. Бичара башкаем гыйльми дөньядагы бу гаделсезлекне һич сыйдыра алмый. Менә шуны йотып куйсак, шәт аңлашылыр.

Ирләр хахылдашып көлделәр. Кулларындагы зәһмәти эчемлек голт иттереп йотылды. Бер көн эчендә һич танымаслык булып үзгәргән Харрас өзелгән сүзне ялгап алып китте.

— Син, Әскәр Шәехович, — диде ул күзен-башын җимереп, — барысын да аңлап бетерергә тырышасыңмы? Ялгышасың? — Харрас имән бармагын тырпайтып, кулын күккә төбәп, әллә кемгә яный-яный кычкырып җибәрде. — У-ух, ялгышасың!

— Бәхәсләшмәгез инде! Әскәр Шәехович, кирәкми, ул хакта бүгенгә сөйләшми торыгыз инде!

Кәримәнең Әскәр алдында авыз җәеп нидер сорап утыруы Харрасның җеннәрен котыртты.

— Әнкәсе! — дип кычкырды ул. «Шейх» белән ничек сөйләшергә кирәген Харрас үзе яхшырак белә. Кәримәнең мондалыгы барын да бозачак. — Бар әле, бала янына кереп ят!

Кәримә иреннәрен көчкә кыймылдатып: «Ярар», — диде дә караңгы якка атлады, мең-миллион хатыннарның хәсрәтле күз яше ачысын белгән йомшак мендәргә капланды. Залдагыларның ни хакында гәпләшүе аны кызыксындырмый иде инде. Күңелен Харраска рәнҗү хисе тутырган, аны беренче тапкыр очраткан чактагы хатирәләр биләп алган иде.

Моңарчы Кәримәнең дөньясы түм-түгәрәк иде. Харрасы иртән эшкә китә, күп көннәрне төшкә дә Кәримә янына кайтып йөри. Кичен, баласын арбага салып, хатын үзе ирен каршыларга институт янына бара. Кәримә уенча, гаилә тормышы нәкъ шулай булырга тиеш тә иде инде. Дөньяда ызгышып-талашып яшәүчеләр дә бардыр, тик Кәримә Харраска алай ямьсезләнер өчен чыкмады.

*
* *

Кәримәнең музейдагы гадәти эш көне иде. Казанга якын гына колхоздан экскурсиягә килгән бер төркем укучы балаларны музей буйлап йөртеп чыкты ул.

Бу эш бер дә катлаулы түгел. Сөйләргә тиешле текстыңны ятлаган булсаң һич куркыр урын юк. Бүлмәләргә урнаштырылган экспонатларның кайсы турында аз гына әйтеп үтәргә, кайсын бөтенләй күрмәмешкә салышырга, кайсы хакында җәелеп китеп аңлатырга — барысы да үз карамагында. Музей хезмәткәре тамаша өчен куелган һәр әйбердән хәбәрдар булырга тиеш, әлбәттә. Аңа мәҗбүрән текстка үз белгәннәрен кушып сөйләргә дә рөхсәт ителә. Сөйләүдән тәм табучыларын туктатып та булмый, әллә никадәр легендалар беләләр, бер сәгатькә билгеләнгән экскурсияне икешәр сәгатькә сузулар була.

Кәриманең эшкә кунегеп кенә килә торган чагы иде. Ул өлкән фәнни хезмәткәр тарафыннан язып тоттырылган текстны тукми-чәчми сөйләп чыга да йомгакларга ашыга. Сүзен ул башкалар кебек: «Бәлки сораулар бардыр?» — дип түгәрәкләми.

— Хәзер, иптәшләр, үзегезне аеруча кызыксындырган экспонатларны кабат, иркенләп карый аласыз! — ди.— Аларның аңлатмалары да бар, рәхим итегез!

Кәримәгә сорау бирүчеләр булмый диярлек. Ул көнне дә экскурсиягә килгән укучылар төркеме инде таралырга ук өлгергән иде. Үз бүлмәсенә кереп китәргә җыенган Кәримане ябык кына, озын буйлы, кара күзле бер егет туктатты.

— Сезгә сорау бирергә мөмкинме?

Укучыларның берәрсе килеп сораган булса, Кәримә ачуын бик сиздермәс иде әле. Яннан кушылган кешенең туйдан соң дөмбергә нидер төпченеп маташуына кыз теләмичә генә:

— Сорап карагыз, — диде.

Тик бу әрсез егеткә рөхсәт итүеңнең кирәге дә шул кадәр генә икән.

— Миңа шуны белергә кирәк: сез үз белгәннәрегезне сөйлисезме, әллә... — Егет, җайлырак сүз эзләп, күзен түшәмгә текәде. — Ягъни нинди мәгълүматлардан файдаланасыз диюем?

Кәримә башта, берәр хата җибәрдем микән әллә дип, яңа гына сөйләп чыккан текстны күңеленнән кичерде. Юк, укучыларга ялгыш сүз ычкындырмады ул. Кулланмада ни язылган булса, шуны гына тезде. Бу егет алдында да йөзе ак.

— Нинди мәгълүматлардан файдалану — безнең эчке эш, — диде. — Берәр нәрсә аңлашылмаган булса, рәхим итеп сорагыз! Музей эшләре турында гына беләсегез килсә, җитәкчеләр янына керегез.

— Ә-ә, алаймы? — Егет сорау эзләп азапланды. — Ни өчен сез Болгар дәүләте турында бик аз сөйлӘдегез. Халкыбызның өлкән бабаларын, Бөек Болгар дәүләтен болай гына күрсәтү, минемчә,— җинаять! Сез бит әби патша арбасы хакында гына да аңа караганда күбрәк сөйләдегез. Татарстан дәүләтенең тарихи музееннан чыккач, кешеләрдән сорасаң, беренче сүзләре шул була: «Вәт, малай, әби патша йөреп тә күрсәткә-ә-ән!»

Кәримә елмаеп кына тыңлый бирде, ә егет шул тотынудан музейның бөтен тәртипләрен, экспонатларның эчтәлеген тәнкыйтьләргә тотынды. Аның карашынча, кирәкле экспонатлар, залларга куелмыйча, фонд складларында тузан җыеп ята. Имеш, бу — зур хата.

Кыз башта: «Сорау бар!» — дигән сүздән шүрләп калган иде, хәзер, егет кызып-кызып сөйләгән саен суына гына барды ул. Тәнкыйтьнең гомуми проблемаларга барып терәлүе, музейдагы эш принципларына кагылуы Кәримане хәтта шатландыра да иде әле. Арба ватылса — утын, үгез үлсә — ит, дип йөри ул. Музей эше бүген бар, иртәгә юк аның өчен.

Бу җаны сөймәгән эшкә Кәримә һич уйламаганда урнашты. Педагогия институтының татар теле бүлеген тәмамлап, шәһәр кешесенә әйләнүләр җиңел түгел, һай җиңел түгел. Әүвәл аны укытучыларның белемен күтәрү институтына эшкә чакырдылар. Август уртасында эшкә дип килсә, кире кага башладылар: буш урын юк, имеш. Сәнәк урынына — көрәк, аңа китапханәгә барырга куштылар. Ничек кенә булса да Казанга төпләнергә ниятләгән Кәримә монысына да ризалашкан иде, тик китапханәгә махсус белем кирәк икән шул. Кәримә, иске бер тиенлек кебек, яңадан шул институтка китте.

— Башта чакырдыгыз, комиссия мине сезгә билгеләде, — диде. — Мин эшсез йөри алмыйм, теләсәгез нишләгез!

Кәримәнең ике арада калуына гаепле саналган агай, телефоннан сөйләшеп, тагын бер урын тапты.

Группадашлары төрле мәктәпләрдә әдәбият укытырга тотынганда, Кәримә, тешен кысып, өр-яңа фән өйрәнергә керешә. Музейга ул яратмыйча, көн узсынга, бишмәт тузсынга дигәндәй генә йөри иде. Вакыт узган саен бер бу музейга гына түгел, бөтен дөньясына ачуы кабара барды. Әллә кайчан тезеп куелган, ни икәне өстенә язылган иске-москылар янына кил дә, әзер сүзләрне сөйләп көн уздыр, имеш. Еллар буе әдәбият укып, хыялланып йөрүнең нигә кирәге булган?!

Кәримә әлеге хезмәтенең бөтен мәгънәсезлегенә күз йомарга, үз һөнәре буенча берәр эш табылганчы сабыр итәргә, эчендәге давылны басарга өйрәнеп килә иде инде. Дөрес, авылга китсә, аңа бүген үзе теләгән эш бар. Кыз: «Авыл җирендә безнең эти-әниләр дә җитәрлек чиләнгән инде! — дип фикер йөртте. — Анда әнә каланыкылар, әнкәләре куенында сазап ятучы Казан кызлары эшләсен! Театрлары, Иделе, серле Кабаны, танцы заллы парклары, йөзләгән кибетләре булган Казанны ташлыйсым юк!»

Музейда эшләргә тотынгач та Кәримә тирә-юньдәге кешеләргә канәгатьсезлеген сиздермәде. Гәүдәсен төз тотып, башны югары чөеп йөри бирде. Аты симез, юлы тигез, дип уйларсың. Музей җитәкчеләре дә аңардан риза иделәр. Тамашачылар да аңа һәр көнне рәхмәт әйтеп чыга — тагын ни кирәк?

Эчтәге ризасызлык кына көн саен үсә барды, яман шеш кебек, ул бер туларга, тишелеп чыгарга тиеш иде. Ниһаять, чегәннекедәй үткен карашлы егет Кәримәне чишелеп китәргә мәҗбүр итте. Музейны тәнкыйтьләүче шушы кеше кызга бердәнбер таяныч, батып барганда кул сузучы булып күренде.

Казанда яшим, дип, үзсүзләләнүе Кәримәне сердәшсез, дус-ишсез калдырган иде. Студентлар дөньясы белән ара өзелү бер хәл. Биш ел буе тәмле теленнән, ачык йөзеннән аермаган фатир хуҗасы да аны ят күрә башлады. Көннәрнең берендә әлеге җаны сөймәгән музейдан кайтып керсә, егылып китә язды: карчык квартирантының бөтен әйберләрен бер төенгә бәйләгән, ишек катына китереп куйган да караватны беренче курстагы студентка тапшырган.

— Эшли торган кеше, фатирга язылып, өч ел яшәсә, өйгә хуҗа да була ала икән, бағалмам, — ди. — Синең язылганыңа биш ел тулыр ашты. Быел гына эшли башлаганыңны белмәсләр, биш ел тушында яшәгән диярләр дә, хур итеп, йортымнан яздырырлар...

Фатиры табылды ла ул. Хәтта аерым бүлмәдә яши башлады Кәримә. Яңа хуҗа да кисәтте кисәтүен: «Финагент килсә, туганыбыз, дип таныштырырбыз. Егерме сум түләгәнеңне әйтмәссең!» — диде.

Аерым бүлмә, ят һөнәр, берсеннән-берсе тәкәбберрәк күренгән хезмәттәшләр — барысы да Кәримәне дөньядан читләштереп бетергәннәр иде инде. Кая китте ул студент ваемсызлыгы?

Музейны тәнкыйтьләүче егет аңа беренче теләктәше кебек күренде. Зәңгәр күзләрен тутырып бар карады да:

— Сер булмаса, әйтегез әле, сез кем? — диде.

— Тарихчы мин, археолог. Харрас Хәсәнов. Болгар чорын өйрәнәм. сез яратмый торган болгарларны...

— Ә мин чыннан да мондагы эшемне яратмыйм, шулай да тиешлесен үтим. Әдәбиятчы булырга хыялланган идем. Болгар дәүләтенең тарихын, оятыма каршы юньләп белмим дә мин.

Харрас кызның ачылып китүеннән үзенчә нәтиҗә дә ясап өлгерде.

— Сезгә аны белми ярамый, үзем аңлатып бирим! — Аңа моннан да күңеллерәк эшне әлегә кадәр башкарырга туры килгәне юк. Мондый гүзәл алдында Харрас бөтен гыйлемен чыгарып салырга әзер. Ян ишектәге бүлмәгә кереп кенә китә күрмәсен!

«Зәңгәр күз» үзе дә егетнең ашыгуыннан курка иде.

— Мин озак тоткарламам. Нindирәк китаплар укырга кирәклеген генә әйтсәгез лә...

— Андый китап юк шул әле, үзем сөйлим, үзем!

Кайгы-хәсрәт ялгыз йөрми, диләр. Харрас яңалык ачты: шатлык-куаныч та өсте-өстенә өелә икән бит! Аңа, һич көтмәгәндә, бары тик күкләрдә генә очрарга мөмкин булган илаһи кыз очрады, ул кинәт Харрас кына белгән гыйлем турында кызыксына башлады, болары гына җитмәсә, шул чакта кызның эш сәгате дә тәмамланган булып чыкты.

Озату-фәлән хакында аерым сүз куертмадылар, урамга чыккач, Харрас кызга иярде дә китте.

— Кайда торасыз, экскурсовод иптәш?

Алар, Кремльне уратып, Казанка буена төштеләр. Кәримә эшкә шуннан йөри икән. Яр буйлап түшәлгән юлда кеше аз, су өстендә — көймәләр, күбесендә, бәлки, гашыйклардыр. Кәримә үзенә тәтеми торган әнә шул ерактагы сәгадәтләргә читтән генә сокланып йөри.

Харрасның юл буендагы күренешләргә исе китмәде. Ул, су киңлегенә күз дә салмастан, алдан вәгъдә бирүенчә, ата-бабалар тарихын, шуларны өйрәнүдә археологиянең гаҗәеп зур әһәмиятен сөйли башлады.

Аның фикеренчә, археология тарихның офыгын киңәйтүче иң изге фән икән. Астрономиягә — телескоп, биологиягә микроскоп никадәр зур җиңеллек китерсә, кешелек тарихының серләрен чишүдә археология дә шундый ук роль уйный.

— Бернәрсә дә эзсез югалмый, Кәримә,— дип сөйли бирде ул.— Язулар янарга, елъязмалар буталырга, хәтер тотрыксызланырга мөмкин. Еллар, гасырлар үтә. Кешеләр кебек үк зур-зур илләр, дәүләтләр дә туа, зурая һәм я картаеп, я сугышлар чыгып, бетә баралар. Тик боларның һәммәсе җирдә үз эзен калдыра.

— Кызык, — диган булды Кәримә. Аңа бу егетнең шул кадәр мавыгып, әкият сөйләгәндәй үз фәне белән таныштырып баруы сәер иде. — Сез бигрәк матур итеп сөйлисез!

Харраска шул гына кирәк, тыңласын гына бу кыз, ул әле тагын әллә ниләр белә.

— Җир куены — калын китап кебек, анда һәр чорның үз катламы бар. Археолог шуны укый... Археология белән безнең эрага кадәр үк шөгыльләнә башлаганнар икән. Дөрес, безнең яклар өчен ул әле шактый яңа фән. Минем шеф — Хәй Фәләхи, профессор, кешенең үзенә кирәк коралларны таштан ясап көн күргән чорын өйрәнә. Фәндә ул чор «палеолит» дип атала.

— Ә сезнең таш пычаклар тапканыгыз юкмы?

— Мин Болгар чорын өйрәнәм, Кәримә. Материал — муеннан, хәл ителмәгән мәсьәләләр аннан да күбрәк.

Алар текә ярга якынлашып киләләр иде. Егет, сүзнең иң кирәкмәгән урыннан өзелүен сизенеп, кызурак сөйли башлады. Асфальтлы юл бетәр, кыз юл читендәге кечкенә йортларның берсенә кереп югалыр кебек иде. Кәримә исә үзе яши торган йорт турында кырт әйләнде дә янадан Кремль ягына атлады. Ник ашыксын әле ул ялгызлыкка?!

Харрас кызны мавыктыргычрак тема эзләп азапланды.

— «Шәһри Болгар» турында ишеткәнең бардыр бит?

— Ба-ар! — Кәримә дә, ниһаять, уртак сүз табылуга шатланды.— Ул хакта безнең әби гел сөйли иде.

— Менә, менә! Шул шәһәр Бөек Болгар дәүләтенең башкаласы да булып торган. Хәзер татар дип аталучы халыкның борынгы бабалары тугызынчы — ундүртенче йөзләрдә Идел буе Болгариясендә яшәгәннәр. Монысын, әлбәттә, беләсең инде.

— Белүдә генә мени хикмәт? Ярата алмадым мин ул тарих фәнен. даталар ятлау үзәккә үтә иде, ә мин ятлауны һич кабул итә алмыйм, аңлап беләсем килә минем, йөрәгем аша үткәреп...

— Шәһри Болгар калдыклары күп галимнәрне кызыктырган. Бәхеткә каршы, Петр патша үзе дә бу мәсьәлә белән шөгыльләнгән, ул шәһәр калдыкларын сакларга, кабер ташларындагы сүзләрне тәрҗемә иттерергә боерган. Шул ук йөзнең икенче яртысында оештырылган бер экспедиция шәһәрнең элекке планын төзи, рәсемнәрен алдыра...

— Казанның үз галимнәре ни көтеп яткан инде?

Харрас, Кәримәнең кызыксынуын тоеп, тагын да кыюлана төште.

— Алар да тик ятмаган, Болгар турындагы беренче китапны Казан галиме Березин яза. Университеттан. Дөрес, соңрак, унтугызынчы йөз башында. Археологик эзләнүләр тагын да соңрак башлана. Сугыш алдыннан гына. Профессор Смирнов болгарлар тормышын шактый тулы күзалларлык материал туплый.

Кәримә, шаярткан булып, эчендәген әйтеп салды.

— Бер галим шул гомер казынгач, ул бичара болгар җирен тагын күпме актарырга була инде?

Егет бу дәүләтнең искиткеч зур булуын, кайбер шәһәрләренең әле һаман археолог килгәнне көтеп ятуын сөйли башлады. Аның үз экспедициясе Кама — Чирмешән буйларында, Болгар дәүләтенең беренче башкаласы урнашкан тирәлекләрдә эзләнә икән.

Кәримә тагын җанланды.

— Бәрәкәт! Мин дә Чирмешән суын эчеп үскән кеше бит!

...Харрас белән очрашуларын искә алган саен, Кәримә гаҗәпләнә бара: беренче күргәндә үк нәрсәсе белән генә күңелне биләп өлгерде соң ул? Хәтерендә: ул көннәрдә Кәримә йокысыз калды. Күзен йомса, каршына Харрас шәүләсе килеп баса. Эшкә барса, үзен-үзе белештермәстән, Болгар чоры экспонатлары ягына ашыга. Әйтерсең, шул борынгы чүлмәкләр — Харрасның дуслары, сердәшләре. Кыз кеше күрмәгәндә, аларны сыйпый, иплəбрәк куя, тамашачыларга матуррак күрсәтергә тырыша.

Егет, Кәримәне беренче озатканнан соң, музейга һәр көнне килә башлады. Я берәр экспонатның кайдан алынуы белән кызыксынган була, я үзе китергән яңа табышның тамаша залына куелу-куелмавын тикшерә. Кайчагында ул сәбәпсез генә ишек төбен каравыллый. Кәримәнең эштән чыкканын сагалый.

Көннәрнең берендә ул кызга яңа хәбәр китерде. Чирмешән буена китүче экспедициягә кешеләр кирәк икән.

— Хәерле юл инде! — диде Кәримә. — Йөрерсез, йөрерсез дә тагын Казанга кайтырсыз әле.— Шуңа ук ялгап, үзенең кызыгуын да сиздерде. — Әй раббем, безнең якларны уратып йөрисез инде. Чирмешән — безнең елга бит ул!

Харраска шул гына кирәк иде.

— Әйдә минем белән!

— Әй, шәп тә булыр иде ул! Шул хәтле туйдым бу музейларыннан.

— Алай димә, Кәримә, син әле үзең тапкан экспонатларны шул музейга куярсың, кешеләргә аларның табылу тарихын сөйләрсең! Директорыгыз белән дә шулайрак килешик!

Кәримәнең директоры белән килешү төзеп йөри-йөри Харрас үз житәкчесенең бу кандидатурага ничегрәк караячагын бөтенләй уйламады. Юлга җыенган группадагы бер сотрудникның кыз кеше икәнлеген ишеткәч, Хәй Фәләхи чыгырыннан чыкты.

— Нәрсә инде бу, Харрас? Вакытлы-вакытсыз шаярырга, эшне өзәргә маташуыңмы? Ике рәхәт бергә килми ул. Менә минем кайчан да булса экспедициягә кызлар алып чыкканым бармы?

— Барысын да сезнеңчә генә эшләргә димәгән бит!

Бәхәсләшә торгач, Харрас бер җаен тапты: Кәримәне группаның пешекчесе итеп алырга булдылар. Башка елны бу эшне авылдагы берәр карчык кына башкара иде.

Кәримә, Харрасның гаҗәпләнүенә каршы, үзен кем итеп билгеләүләренә битараф калды. Бу көннәрдә аның күңелен бары бер генә теләк ашкындырды — ничек тә тизрәк музейның салкын стеналарыннан ераккарак китәргә кирәк иде. Чирмешән суы, яр буенда кызынып ятулар төнлә аның төшләренә кереп чуала башлады. Галимнәр, директорлар үзара тик кычкырыша бирсен!

Кыз төннәр утырып кызыну-коену киемнәре текте. Бер костюмны эре бизәкле сатиннан кисте, махсус кызыну өчен дигән икенчесен нибары ярты метр тукымадан ясады. Күкрәк турысына кавырсын йомрылар куеп тегелгән нейлон костюмын авылга алып бармаска булды ул. Чирмешән комлыгына сатины да ярый.

Ниһаять, юлга кузгалыр көн житте. Ябык әрҗәле машинада, шоферын да кертеп исәпләсәң, биш кеше иделәр алар. Егетләр, беренче күрүдән үк, Кәримәне ят иттеләр. Кызның кызыл, озын тырнакларына, лаклап озайтылган керфекләренә шаккатып карадылар: «Нинди пешекче инде бу?» Харрас, боларны сизмәмешкә салышып, таныштырган булды.

— Бу — Кәримә Әхмәтова, җәмәгать. Татарстанның археология тарихында беренче тапкыр юлга чыгучы иң тәвәккәл туташ! Уңган кулинар, бер тарыдан ботка пешерә белә.

Җитәкчеләре сүзне уенга борырга чамалаганны аңласалар да, егетләр ачылмады. Хәер, Кәримә аларның фикере белән әллә ни кызыксынмый да иде. Буялган тырнакка алар һич урынсызга алай акаеп карыйлар. Кызның ак кофтасына, кыска, тар соры юбкага, бигрәк тә, аяктагы кып-кызыл «чабаталар»га тырнакларның төсе ифрат та килешә бит. Иңбашына тузгытып салган алтынсу чәчләренә, кулындагы шакмаклы чемоданына караганда, Кәримә диңгез буена ялга әзерләнгән кешегә күбрәк ошый иде.

Әйберләр машинага төялгән инде. Утырышырга боерык ишеткәч, ишек янына иң беренче Кәримә атылды. Тик менеп китә алмады, юбкасы артык та тар икән, кычкырып җибәрде.

— Харра-ас, ник бу машинаның басмаларын бик биек ясаганнар.

Алар Акъярга килеп җиткәндә, төш вакыты якынлашкан иде. Харрас авыл советы җитәкчеләре белән тарткалаша торгач, экспедицияне мәктәп карамагына тапшырдылар. Тик фән кешеләрен директор да колач җәеп каршыламады.

— Мена сезгә бер бүлмә, — диде ул. — Әйтергә кирәк, иң яхшы кабинетыбыз: иркен, якты, диваны да бар... Башка классларны бирә алмыйм, парталар яңа гына буялган, кибеп өлгермәделәр.

Егетләр аны-моны әйткәләгәнче, Кәримә кычкырды:

— Миңа ошый! Хәтта көзге дә бар монда!

Директор, шушы хуплауга бик риза булып, чыгып та китте. Харрас аны озата барырга, тагын ниләрдер сорарга мәҗбүр иде. Егетләргә Кәримә белән «алыш-биреш»не очлап куярга җай чыкты.

Сүзне шофер башлады.

— Я, булмаса, урнашыйк инде,— диде.— Син, сеңел кеше, диванга тагын кемне аласың инде? Монда бит кеше саен аерым ятак табып булмый.

Бичара Кәримә шунда гына мәсьәләнең бу якларын исенә төшерде. Бер көтү зимагордай ир-ат арасында айлар буе ничек яшәр соң ул? Бу сорауга җавап табып өлгергәләгәнче, Яхъя исемлесе:

— Төш җитте түгелме соң, җәмәгать? — дип сораган булып кыланды. — Аһ, да, бу юлы безнең атказанган пешекчебез бар бит әле, нигә кайгырырга?

Харрас кергәндә, егетләр Кәримәгә әйтәселәрен әйтеп, эчләрен тәмам бушатканнар, кыз, тәрәзә буендагы ак япмалы диванга менеп, аякларын бөкләп утырган да мышык-мышык елый иде. Мең мәшәкатьне читкә куеп, Кәримәне тынычландырырга туры килде. Егетләр исә ашарга көтеп утыруларында булдылар, Харрастан көләләр иде алар: «Үзең тапкан мал, капчык тутырып ал», янәсе.

Беренче көнне генә шулай азаплансалар, ярар да иде әле. Кәримәнең кыланмышы, торган саен, кырдан узды. Башта егетләр иртә таңнан кырга чыгып олагалар да төнгә каршы гына кайтып егылалар иде. Төшкә-нигә кайту юк. Ашарларына коры-сары ризыклар тутырып китәләр, пакеттагы кипкән аш, консервлар алалар. Төнлә булса да, кайнар аш пешереп каршылаучыны күрсәләр, арадагы низагълар юкка чыгар иде. Мондый «батырлык» эшләү Кәримәнең уена да килмәде.

Кызның үз мәшәкате дә житәрлек иде. Башта ул укытучылар кабинетында үз почмагын җиһазлады. Диван белән көзгене үз ягында калдырып ширма әмәлләде. Икенче көнне комлык эзләп, су буена китте. Чирмешәннең бу төшендә су шактый тирән һәм саф булып чыкты, нәкъ Кәримә теләгәнчә!

Акъярга килүләренә атна тула дигәндә, үз белдеге белән аш исе чыгара алмагач, беркөнне Харрас сүз башларга мәҗбүр булды.

— Бүген сәгать уникеләр тирәсендә тамак ялгарга кайтырбыз, Кәримә. Син тәмле генә шулпа пешереп куй әле! — диде. — Мин председатель белән сөйләштем, итен дә, бәрәңгесен дә, онын да бирерләр.

Әйткән ашамлыкларны кладовщиктан барып та алды Кәримә. Аш кебеген дә пешерде. Кояш чыкканнан бирле җир актарган, бүредәй ачыккан егетләр коштабакларын күз ачып-йомганчы ялт иттереп тәкуйдылар, кабат эшкә дә киттеләр. Китүләренә ике сәгать үткәндерме-юктырмы алар яңадан кайтып тулды. Кәримә Харрасның йөзен читкә борып сөйләвеннән үк яман хәлне сизеп өлгерде.

— Кәримә Хәбибулловна, сезнең белән ачыктан-ачык сөйләшик әле! — Сүз озакка сузылырлык иде, күрәсең, егет аны мәктәптән аулак якка алып китте.

Шактый вакыт сүзсез атладылар. Елга буендагы салкынча һава егетнең ачуын басылдырган да иде инде. Ул хәзер шулай бер сүз эндәшмичә кире кайтып китәргә дә риза. Колак төбендә иптәш егетләренең таләп тавышы яңгырап кына эчне пошыра. Харрас тәвәккәлләргә булды. Аның иң курыкканы шул иде: әйткән сүзләргә үпкәләр дә Кәримә кире Казанга кайтып китәр.

— Кәримә, төшен ни ашаттың соң син безгә?

— А-аш, нигә?

— Үзең кабып карадыңмы соң син аны?

— Мин аш яратмыйм, юанайта ул шулпалы аш.

— Синең ул аш егетләрне, беләсеңме, нишләтте...

Кәримә бераз уйланып торды да көләргә тотынды.

— Бик әйбәт булган, шул кирәк аларга.

Харрасның хәле мөшкел иде: кай яктан һәм ничек аңлатырга?

— Болай без барыбыз да чирләшеп бетәбез, Кәримә. Син әллә пешерү-төшерүне бөтенләй өнәмисеңме? Егетләр аш-су тирәсендә йөрергә авыл карчыгы алуымны даулый башладылар. Икешәр повар тотарга ярамый бит...

Кәримә, сүзне артык озынга сузарга юл калдырмыйча, яшел чирәмгә утырды, Харраска үзе янынан урын күрсәтте.

— Утырыйк әле! — диде.— Минем әби, ачуың килгәндә, аяк өсте булсаң, утыр, утырган булсаң, сузылып ят, дип өйрәтә иде.

Шулай шома гына башлап алды да Кәримә Харраска үзенең бик үк мактанырлык булмаган тормыш юлын сөйләп бирде.

Ул авыл кибетчесе Хәбибулла агайның бердәнбер баласы икән. Ун-

бер ел көткәннән соң хатынының бала табуын ишеткәч, агаең ат менеп урам буйлап кычкырып йөргән: «Ә-әй, ишеттегезме, минем кызым ба-ар, королева туды, ко-ро-ле-ва-а-а!»

Агай кызына хәтта исемен дә «Королева» дип куштырмакчы булган да, тик картлар тыйган: «Син теләгәннең ике хәрефен кертәбез, «Кәримә» дип кушабыз, тилермә, ризалаш!» — дигәннәр.

Дөньяның җил-яңгырын тоймыйча, күз өстендә каш булып, иркәләнеп кенә үсә Кәримә. Дус-ишләре, билдән тузанга батып бәрәңге төбен өеп йөргәндә, бу, ак оеклар киеп, ботинкаларын ялтыратып, үзенә махсус ясатылган утыргычта бакча башында әти-әнисен карап утыра икән. Башта кызга эш кушарга әтисе рөхсәт бирмәгән, аннары үзе теләми башлаган. Бакча тирәсендә буталып йөргәндә, кулына балчык тисә дә: «Әттәм, бармагыма җир тиде-е»,— дип, авызын җәеп елый икән.

Тирә-юньгә тегүче даны чыккан әби дигәне генә, берәүдән дә сорапнитеп тормыйча, кызны үз һөнәренә өйрәтеп калдырган. Кәримә күрше авылның урта мәктәбенә киткәч тә, институтка кергәч тә, атасы кызга аерым фатир табып, хуҗа хатыннары белән килешеп йөргән.

— Хакыннан тормам, түләрмен, кызымны вак-төяк эшләрдән генә коткарыгыз! — дигән. — Ул укырга тиеш, зур кеше итәм мин аны.

Харраска бу хакта сөйләгәндә, бичара Кәримәнең тавышы акренәйгәннән-акренәя барды. Кызарынды-каушады, әмма алласы урынына күреп йөргән кешедән үзенең бу якларын яшерергә ярамаганын аңлаган иде ул. Сүзен түгәрәкләп, бүгенге көн өчен иң кирәген әйтеп бирде:

— Мин аш пешерә белмим бит, Харрас, — диде. — Ихтыярыгыз, теләсәгез нишләтегез.

Кәримәнең тәүбәгә килүе егетне чарасыз итте. Кая ул аны ачуланулар! Эшкә яраксызлыгы фаш булгач, хурланып, үзе генә киреләнә күрмәсен. Ул янда тормагач, Харрас ничек эшли алсын? Аш-су тирәсендә алар икәүләп кайнашырга булдылар.

— Әни эштә чакта, мин гел аш пешерә идем, — диде Харрас. — Аның әллә нәрсәсе юк, өйрәнерсең син аны!

Икенче көнне иртәдән егетләр Кәримәне танымас булдылар. Озын тырнаклар киселгән, пумала чәч җыеп, кыекча-яулык астына кысып бәйләп куелган, хәтта биленә алъяпкыч та буган иде кыз. Чәйдән соң исә тиз генә өстен алмаштырды, егетләрнеке кебек үк куртка, сатин чалбар киде. Ул да эш урынына барырга тели икән.

Анда Кәримәнең үзен ачышлар көтеп торган: өйдә ашаудан башка нәрсә турында сөйләшмәүче егетләр монда пәһлеваннарга әйләнделәр.

Көн кояшлы иде. Акъяр калкулыгыннан тирә-юнь гаҗәп матур күренә. Кул сузымында гына Чирмешән җәйрәгән, калкулык итәкләре урманга тоташа. Якында — өсте актарып салынган чокыр-чакырлар— егетләрнең төп хезмәте шунда бара. Кулларында көрәк тә бар, пычак та, эреле-ваклы пумалалар да күп. Харрас Кәримәгә дә пычак сыман бер нәрсә бирде.

— Әйдә, бераз безнең эш белән таныштырыйм әле! — диде.

Сүзләре аңлашылсын өчен, археолог акрын гына, сеңдереп сөйли иде.

— Әгәр вакыт дигән нәрсә безнең тормыштан барлык истәлекләрне дә бетерә барса, кеше гомере коточкыч мәгънәсезлектән генә гыйбарәт булыр иде. Кызганычка каршы, күп гасырлар әнә шулай үтеп торган: кешеләрнең үзләре генә түгел, аларның казанышлары да, акыллары раслаган хакыйкать тә юкка чыга барган. Бер көн килгән: кешеләр язу-сызуга өйрәнгән, үз тарихларын терки башлаганнар. Ә археологлар, Кәримә туташ, язуларга теркәлмәгән хакыйкатьне эзләп табарга тиеш...

Шул урында Харрасның «лекция»се өзелде. Пычак очы каты матдәгә төртелеп калды. Археолог пышылдауга күчте.

— Тавышланма, Кәримә!

Ул балчыкны валчыклап берәмтекли башлады. Үзе, һаман пышылдап, сорый:

— Йомшаграк пумала алып бир әле, Кәримә!

Шактый озак маташа торгач, кулына иске чүлмәк төбе алды. Шуңа да шатланды, баскан урынында тик тора алмый иде. Тагын төшенчәләргә тотынды.

— Күрәсеңме, бу — болгар чүлмәге! Бернинди лакка-фәләнгә буялмаган, үзләренә хас ысул белән яндырылган...

Башка егетләр күз генә салып алдылар, күрәсең, аларга болар барысы да күптән таныш иде. Кәримә генә Харрас кулындагы яңа табышка, ерак гасырдан ишетелгән серле авазга колак салгандай, әсәрләнеп озак карап торды.

Кәриманең бәхетенә каршы, шофер да учак тирәсендә уралырга яратучан кеше булып чыкты. Харрасның аш-суга карата бирелгән күрсәтмәләрен алар икәүләп башкара иделәр. Казу-эзләү эшләреннән шактый читтә шофер егет учак урыны ясап бирде. Кәримә Тәнкәле тау чишмәсенә суга китте.

Чишмә ярты чакрым чамасы ераклыкта иде. Тауның тирә-юне гел куаклык. Кыз озак та бармады, сукмакта кулларына төрледән-төрле савытлар тоткан кешеләр очрый башлады. Аптырап калды Кәримә: авылның үзенә якын гына чишмәсе дә бар бит, ник шул кадәр ераклыкка йөриләр болар?

Ул беренче очраган кыздан сорады.

— Ник бу кадәр еракка килдең, сеңелем?

— Әбинең башы авырта.

Бу җаваптан берни дә аңламагач, олырак кеше белән сөйләшеп карарга булды һәм тагын да аптырый төште. Монысы чишмәгә авылдан гына да түгел, мари ягыннан ук килгән иде, чире дә хәтәррәк, шуңа им эзләве икән.

Суы дару урынына тотылырлык булгач, чишмә гаҗәп матурдыр дип уйлаган иде Кәримә. Өмете акланмады, энҗедәй су бака шәлләре белән томаланып беткән черек улактан агып ята, ул үзенең изгелеген дә, шифалылыгын да күптән җуйган-оныткан төсле.

Археологлар янына кайтканда, башында туган каршылыклы сорауларына җавап алырга ашыккан Кәримане өр-яңа табыш көтә иде.

Егетләр барысы бер урынга җыелган, Харрас Яхъяга теләр-теләмәс кенә аңлатып тора:

— Синең бу чүлмәк китекләреңне, һичшиксез, теркәргә кирәк, — ди. — Болар аерыла. Төсе дә, балчыгы да, шомартылуы да башка. Бу — Азов буе болгарлары кәсебе...

Яхъяның кулы калтыранып куйды.

— Мә, алайса, үзең! Мин тапмадым моны.

— Кем тапты соң?

— Андый кирле-мырлы нәтиҗә ясарга җыенасың икән, табучысы да үзең бул, миңа кирәкми!

— Куркасың, ә?

— Башыма бәла аласым килми.

Егетләр, күңелсезләнеп, таралышу ягын карадылар. Берни аңламаган Кәримә, Харрас белән Яхъя арасына кереп басты да ызгыш-талаш чыгарган чүлмәк калдыгын үз кулына алды.

— Һи-и, шул юк нәрсә өчен ызгышып торган буласыз! — диде. — Тотам да атам мин аны. Берәү дә тапмады, берәү дә күрмәде. Әзмыни монда андый саяк-сандрак? Челпәрәмә китерәбез!

Яхъяга Кәриманең тәкъдиме ошап та куйган иде, Харрас:

— Иске чүлмәкне яшереп кенә тарих дәреслеген каплап калдырып булмый аны, — дип, зурдан кубып каршы төште.

Кәримәне гүя күрми дә иде ул, аның кулындагы табылдыкны да, жанына иң кадерле кыздан түгел, әйтерсең лә, иске койма казыгы башыннан гына суырып алды.

— Безгә житдирәк булырга вакыт инде, — дип үзалдына мыгырданды.

Андый чакларында Харрас Кәримәгә ошамый башлый, зур мәсьәләләрне дә уенга борып, көлеп-шаярып сөйләшкәндә сөйкемле ул. Китте дә барды кыз. Үз эше дә — муеннан. Шуны гына көтеп торган Яхъя Харрасны кисәтергә ниятләде.

— Слушай, кирәкмәгәнне куертмыйкмы соң әллә, шеф мондый нәрсәләрне кичермәячәк.

Харрас фәнгә шәхси мөнәсәбәтләрне болгатып маташуны һич ничек башына сыйдырмый.

— Карале, — дип, Яхъяга каршы төште ул. — Нигә без төрле тешенчәләрдән ботка ясыйбыз, ә? Фән үзе кычкырып яңа мәгълүмат биреп тора икән, кемгәдер ул нәрсә ошамый икән, безнең аңа ни катнашыбыз бар?

— Хәй Фәләхи мең былтыр Азов болгарларының Идел буе Болгариясенә якынлыгы юк дип раслап чыкты.

— Ялгышкан, димәк. Фактлар киресен күрсәтә!

— Ул — фән докторы, профессор, ялгышмый ул. Бүген — бер, иртәгә икенче төрле хакыйкатьне танып утыру чоры үткән аның.

— Мин бит тиктомалдан аңа каршы чыкмыйм. Бу чүлмәк берүзе генә булса, бер хәл иде. Учагы ук шунда бит, бу ни дигән сүз? Үзең беләсең, нәкъ шундыйларны менә шушы болгар жирендә яндырып, ясап ятканнар, дигән сүз бу.

Мәсьәләнең ифрат тирәнгә китүе Яхъядан бигрәк Харрасның үзен пошаманга салды. Ул егетләргә сүз кушмас булды.

Башка кичләрне алар Кәримә белән икәү генә авыл читеннән әйләнеп кайтырга да вакыт табалар иде. Бу кичтә, кызның көтеп торуын сизгәч, гадәтенчә, Чирмешән буена чакырмады.

— Кәримә, — диде. Тавышындагы салкынлыктан кыз куырылып калды. — Мин сиңа экспедициянең тагын бер эшен кушмакчы булам.

— Әйтеп кара.

— Безгә бу як халкының фольклорын, биюләрен, риваятьләрен белү дә кирәк. Егетләр — жир эшендә, аларны кич клубка йөртә алмыйм, арыйлар.

— Барыйк соң, әйдә.

— Юк, син үзең генә башкар инде. минем бүгенге башваткыч белән утырасым бар.

Кәримә, бичара, әллә ниләр уйлап бетерде. «Миннән туйган, котылмакчы була. Клубтан эзләсен үз ишләрен, дип уйлый. Баш тартсаң, сылана, диячәк...»

Башында юньле бер фикер туганчы теле әйтеп тә өлгерде.

— Әле үзем дә мишәр жырларын сагынган идем! — диде. — Каян чамаладың? Хә-әзер, иң матур күлмәгемне үтүкләп киям дә китәм!

Харраска үч итеп кенә тотынган булса да, клубка йөрү Кәримәне чынлап торып мавыктырды. Отып алган жырларын, такмакларын, риваятьләрне туплый барган дәфтәре тиз арада калыная башлады. Тирәюньдәге авылларның тарихына караган имеш-мимешләрне дә жыя иде. Харрас монысын аеруча хуплады.

— Казып табылган әйберләр кайчак һичнинди кагыйдәгә дә сыймый, нәтижә ясаганда, әкияте дә, имеш-мимеше дә ярап куя, — диде. — Иренмәскә кирәк, барын да язып алырга!

Беркөнне Кәримә мәктәп күршесендә яшәүче Сәгъдия карчыктан

Тәңкәле тау турында сөйләндереп утырды. Шуңа әби үз язмышын да ялгап җибәрде. Кәримә Тәңкәле тау чишмәсенә төрле халыклар йөрүеннән көлгән иде.

— Татары намаз укып утыра, урысы, чуашы чукына!

Әби көләр урын калдырмады.

— Олан шул әле син, белмисең, — диде. — Җансыз тауга җанлылардан өмете киселгәннәр килә. Килсеннәр, ышансыннар, өмет өзелүдән дә яманы юк...

Сүзләренә дәлил итеп, әби үз башыннан кичкәннәргә туктады.

Җиде мәхәлләле зур авылда үскән ул. Башка кызлар кебек үк каз өмәләренә дә йөргән, урагын да урган, киндерен дә суккан. Башкалардан аерып торучы тагын бер ягы булган Сәгъдиянең: ул бик кечкенәдән үк үзәк өзгеч моң белән җырлый белгән.

— Җырлавыңны ташла син, бала, — дигәннәр аңа ата-аналары. — Үз башыңа булмаса, безнең башкадыр синең бу моңлануларың.

Кызның җырларын тыңлап ләззәтләнүчеләр дә, җаннарына дәва алучылар да табылган. Авылның бер көтү остабикәләре, бер-берсеннән уздырырга тырышып, Сәгъдияне мәҗлескә чакырганнар. Кыз корьәнне дә, тавышына әллә нинди бормалар сала-сала мәкамләп укый, ашап-эчеп алгач, остабикәләр үтенече буенча, рәхәтләнеп җырлый да икән.

Мәүлет ае була бу. Мәүләви мулла хатыны Сәгъдияне чираттагы мәҗлескә дәшә. Җырчы кызны түр башына ук менгереп утырталар. Барысы да гадәттәгечә бара. Ашау-эчүләр түгәрәкләнер алдыннан, өрек җимешләре салып кайнатылган хуш исле ширбәт чыгарылгач, остабикә әйтә куя:

— Сәгъдия балам! — ди. — Мулла абзыең өйдә юк, әллә безнең тулган күңелләрне юатып бирәр җыруыңны да көйләп күрсәтәсеңме?!

Кыз әллә кайчаннан бирле шул сүзне генә көтеп утыра икән. Ул мондый мәҗлесләргә дә, бердән, сәдакасы булыр, әтиемә ярдәмем тисен, дип, икенчедән, иркенләп бер җырлау өчен ашкына.

Абыстайның сүзе бетәр-бетмәс, Сәгъдия кыйблага аркасы белән борыла да үзенең яраткан җырларын сузып җибәрә: «Кара урман», «Салкын чишмә», «Сакмар»...

Үсәдер казлар Сакмар су буенда-а-а-а...

Шул чак табындагыларга әллә ни була, йөзләрен каплыйлар, авыз эченнән генә: «Әй, раббем, үзең кичер» — дип ялваралар. Сәгъдия дә өйгә кереп килгән ак чалмалы кешене күреп ала, ләкин җырыннан тиз генә туктала алмый, үз моңына үзе исергән килеш сузыпмы суза:

Үсәдер кызлар әнкәләре куенында-а-а-а.

Ул арада инде хәзрәт әллә кайчан өйгә кергән, табынның аргы башына баскан, күзләрен алартып, кызга карап каткан була.

Остабикә кычкырып җибәрә:

— Йөзеңне яп, бәдбәхет! — Үзе иренә ялвара. — Ширбәт бүлеп йөридер идем, шул арада бу йөзе кара җыру башлаган, кичерә күр, хәзрәткәем!

Табындагылар да, яулык читләре белән авызларын каплап:

— Шәфкатеңнән ташлама, кичер без гөнаһлы бәндәләреңне! — дип пышылдыйлар.

Корьән мәҗлесендә җыр тыңлап утырганнары өчен пыр тузарга тиешле зөбани ир, табындагыларның гаҗәпләнүенә каршы, елмаеп кына эндәшә.

— Х-у-уш, — ди ул, Сәгъдиягә карап, — бу кадәр дә моңлы кем баласы буласың инде син?

Икенче көнне кояш баеганда Мәүләви мулла унбише дә тулмаган Сәгъдияне кече хатынлыкка соратып яучы җибәрә. Фәкыйрь ата тегеләй дә, болай да баш тартып карый. Яучы каты тора.

— Бүгенге эшне иртәгә калдырма, бүгенге үчне иртәгә калдыр! — ди. «Үч» сүзе аерым басым ясап әйтелә.

Авылда әллә нигә бер булып, телдән-телгә бәет итеп сөйләнә торган фаҗига туа.

Карт ир, көндәш абыстай белән өч ел яши Сәгъдия. Бераздан «Сәгъдия кысыр икән, бала китерми» — дигән күңелсез хәбәр тарала. Мулла абзый яшь хатынын җәберләргә ашыкмаган. Им-томчылар китерткән, аллаһе тәгалә җәнаплары ризалыгы өчен корбаннар чалган, ярлы-ябагага сәдака дә өләшкән. Һичничек эш чыкмагач, ат җигеп, арбасына уйнак бер симез тәкәне салып, Сәгъдиясен янына утыртып, изге Таңкәле тауга киткән.

Монда бөтенесе шундый — дөньядан өмете киселгәннәр җыелган: корбанын чалып, корьән укытып, өшкертеп-төкертеп, җаннарына юаныч табалар икән. Җан биргәнгә җүн бирә дигәндәй, тау янында берничә суфи да була.

Мәүләви мулла корьәнен укырга, өшкерергә үзе дә оста була, тик, һәр авылның үз әттәхияте дигәндәй, изге җирнең үз кешесенә мөрәҗәгать итүне килештерә төшә. Серен арада сөйкемлерәк күренгән бер суфига чишә.

Суфи, карап-карап торган да:

— Мин бу тауның иң изге ноктасын беләм, — дигән. — Анда укыла торган догалар хак тәгаләгә тизрәк ирешә. Без ханым-әфәнде белән шунда меник, сез, чишмә буенда калып, без кире килгәнче дога кылып утырыгыз!

Алар биек наратлар, чикләвек агачлары каплаган тауга күтәрелгәннәр. Өстән караганда, чишмә буе гаҗәп матур булып күренә икән: ямь-яшел алан, уртада — көмеш су, аның тирәсенә кешеләр сибелешеп утырган. Шул хозурлыкны күрә алмыйча, мескенләнеп, биек тауга үрмәләүче хатын «суфи»га бик кызганыч булып тоела.

— Яле! — ди.— Ач әле йөзеңне!

Бу вакыт кыз үзенең яраткан җырларын оныткан, ир-ат йөзенә күтәрелеп карамаска, алардан тел яшерергә өйрәнгән була. Бөтенләй дә чит-ят ир алдында йөзен ничек ачсын инде ул?!

— Хажга баручылар хакында ишеткәнең бармы, ханым?

— Ба-ар, әфәндем, хәләл җефетем хажи кеше.

— Алай булгач, йөзеңне ник ачмыйсың? Бу урыннар хаҗ җиреннән һич тә ким түгел, хаҗ юлында исә һәр мөэмин-мөселман, хәтта хатын-кыз җәмагате дә, йөзен ачарга тиеш; монысы сиңа мәгълүмме, ханым-әфәнде?

«Суфи» Сәгъдиянең йөзен каплап торган ак ефәк шәлне иплэп кенә сыдырып алган. Яшь хатынның ахактай балкып янган йөзе, сагыш белән мөлдерәмә күзләре, бөгелмәле озын керфекләре, дерелдәп торучы иреннәре «суфи»ны һушсыз иткән. Ул, кулларын күкләргә сузып:

— Я аллам! — дигән. — Ничә яшь соң сиңа, балакай?

— Унсигез, әфәндем... — Сәгъдиянең үзенә дә әллә ни булган, телен көчкә әйләндереп: — никахланганда унбиш кенә иде, — дигән.

Сакал мыегы ялтырап торган сөлектәй бу яшь егет кызның зиһенен чуалтып җибәргән, күзләре гел аны күрергә тели дә, күңеле яхшысынмый икән. Егет аны үгетләргә тотынган.

— Мин түгел, аллаһе тәгалә үзе өшкерсә дә, бу карт белән яшәгәндә, теләгеңә ирешә алмассың, әйдә минем белән, бәхеткә ирешүнең башка юлын күрсәтәм, — ди икән.

Егет Сәгъдиянең күңеленә аның онытылган җырлары кебек моң булып кергән. Уйлаган, уйлаган да ни белгән догаларын укып, тәвәккәлләгән. «Суфи» — Чистай мәдрәсәсе шәкерте икән. Җәйге ялында, бераз акча җыю нияте белән генә, әлеге «изге» юлга чыккан. Сәгъдияне таунык башка ягына алып киткән ул. Мәүләви мулла нинди бәддогалар укыгандыр, әмма болар бер-берсеннән көч алып, яратышып, рәхәтләнеп яшәгәннәр.

Революция башланган, сугышлар чыккан. Сәгъдиянең авылда мөгаллимлек итүче яраткан ире, кызыл гаскәргә кушылып, сугыш кырына киткән дә вафат булган. Сәгъдия, кеп-кечкенә кызын кочаклап, тол калган. Икенче сугышны да үткәреп, ил тәмам аякка баскач кына, ул Закирҗаны белән кавыштырган изге тау янына кабат килгән, Акъяр авылыннан йорт сатып алган...

Сәгъдия карчык, тора-бара, Кәриманең ярдәмчесенә әйләнде. Борынгы җырлар, әкиятләр сөйләве бер файда китерсә, икенче яктан, тагын ярап куйды: ул һәр җомгада телеңне йотарлык тәмле ризыклар пешерә. Аш-су тирәсенә кулы ятмавын сизгәч, Кәриманы дә өйрәтергә булды.

— Безнең мишәр балалары туганда ук җиң сызганып, бил буып туалар. Ул нинди уңмаганлык? — дип, тирги-тирги өйрәтте. — Үзең кияүгә чыгарга әзерләнәсеңдер әле! Дөньяны ничек куарсың?

Кәримәне камыр куярга да, токмач кисәргә дә, коштел-бавырсак пешерергә дә өйрәтте. Сәгъдия карчык мохите кызның Харрас хезмәтенә булган карашын да үзгәртте. Ул хәзер һәр табыш турында кызыксынып тыңлый, чүлмәк китекләрен үзе дә кадерләп йөртә, әйберләрнең озын гомерле булуына сөенә иде. Алар үткән буыннарның казанышын саклап яшәгән, кеше гомеренең мәгънәсен раслаган.

Бәс шулай икән, тирәндә яткан мәгънәне үз куллары белән ачып йөрүче Харрастан да изгерәк һөнәрле кемне табарсың?

Озакламый, һич көтмәгәндә-уйламаганда, Кәримә үзе дә бу эшнең ләззәтен татыды. Ул көнне колхоз амбарында ит юк иде. Кәримә эчтән генә сөенеп куйды. Аш пешерергә өйрәнсә дә, ике сәгать буе казан тирәсендә болгануны күңел дигәне кабул итми иде аның. Күп кенә бәрәңге алдылар, берничә банка консервланган ит салдылар — төшке ашны шулардан әзерләргә ниятләнелде.

Кәримә, бәрәңге әрчегән арада су кайнарлана торсын дип, башта учакны көйләп җибәрергә булды. Ут кына үрләп китми интектерде. Кыз коры-сарылар әзерли торган кечкенә балта белән учагының бер кырыен төзәтә башлады. Көл белән капланган җиргә балта очын тидергән генә иде, туфракта ниндидер катылык сизеп, өнсез калды. Ул инде, Харрастан күрмәкче, җирдәге һәр каты-котыга колак салырга өйрәнеп килә иде. Балтаны читкә ташлап, кулына пычак, пумала алды. Бөтен сабырлыгын җыеп, валчык арты валчык куптарды, катылыкның ни икәнен белде, чүлмәк катылыгы иде бу. Тик аның читенә генә чыгар хәл юк, һаман йомрылана бара.

Кыз шабыр тиргә батты, инде пәке очы тидерергә дә курка башлады, пумала белән генә сыйпый иде. Шактый азаплангач, кечкенә генә йомры чүлмәкнең күп өлеше ачылды. Ул бөп-бөтен, хәтта чатнаган төше дә юк иде. Кәримә бар куәтенә кычкырып җибәрде:

— Хар-р-ра-ас!

Кәриманең юк кына нәрсәгә дә зурдан кубу гадәтен белгәнгә, егетләр аның тавышына игътибар да итмәделәр. Харрас та шактый көттереп баш калкытты. Кәримә бу вакытта кечкенә чүлмәкне ике куллап баш өстенә күтәргән дә егетләр янына үзе чаба иде.

— Беләсезме нәрсә таптым?!

«Таптым» сүзе егетләргә дә минут эчендә тәэсир итеп өлгерде. Алар Кәримәгә дә, кыз кулындагы чүлмәккә дә түгел, Харраска карап то-

ралар иде. Житәкченең сихерченекенә охшаш үткер күзләре чүлмәккә төбәлгән дә аннан икенче һичбер кешегә танылмаячак сүзләрне укый төсле.

Кәримәнең сабырлыгы житмәде.

— Болгарныкы инде, болгарныкы! — диде. — Үзең әйткән идең, мондый үсемлек рәсеме төшкәне, буялмаганы болгарныкы, дигән идең. — Моңа да җавап булмагач, Кәримә өстәде: — Аның әле эчендә дә нидер бар кебек.

Харрас, яңа туган баланы кулына алгандай, чүлмәкне сак кына тотты, әкрен генә җиргә куйды. Барысы да чүлмәк тирәли тезләнделәр. Яссы капкачны ачкач, чүлмәк эченнән тәңкәләр, кашлы берничә көмеш йөзек, иң астан гаҗәеп матур алтын алкалар килеп чыкты.

— Болары — үземә! — Әйтерсең лә, базардан кайткан атасының юл капчыгын актара иде Кәримә.

Егетләр, бу нинди акылсызлык инде дигәндәй, бер-берсенә карашып алдылар. Яхъя гына түзмәде: «Вот баба!» дип сукранып куйды.

Кәримәнең сүзе, үзенә калса, уенсыз әйтелгән булып чыкты. Ул үзе тапкан малга үзе хуҗа икәнен, алканы Хәй Фәләхинең күзенә кырып салырга да бирмәячәген расларга тырышты.

— Әнә сезгә бер чүлмәк акча, гасыр буе тикшеренергә җитә.

— Колагыңның тишеге генә дә юк бит синең, кай җиреңә такмакчы буласың?

— Тиштерермен, аны хәзер больницада да тишәләр.

— Тиштерсәң дә, синең колак яфрагың бу алкага чыдамый, ертылып төшә...

Алкалар чыннан да зурлар иде. Калын гына бөҗра эченә кош сурәте коелган. Кош канатларын җилпеп очып бара сыман, томшыгында — ярма бөртеге ялтырый.

Харрас иптәшләренең әрепләшүенә игътибар дә итмичә уйланып утырды да кинәт аңлата башлады: «Беләсезме, бу алка болгарларның җир яралуы турындагы легендаларына туры килә».

Барысы да тынып калды. Кәримәнең шушы арада гына ишетеп кайткан риваятен искә төшерделәр. Имеш бүгенге җир кечкенә генә бер орлыктан яралган. Орлык башта тирән су астында, дәрья төбендә булган. Кешеләр яшәрлек коры җир хасил итү өчен, орлыкны чиксез дәрья киңлегеннән бер үрдәк алып чыгып биргән...

Харрас, тезләнгән урыныннан торып, Кәримә янына килде. — Син бик уңган кыз булып чыктың бит әле! — диде.— Мин җиде ел буе экспедицияләргә чыгам, бер генә хәзинә дә ачканым юк. Син менә чүлмәге-ние белән таптың да бирдең! Археология тарихында күп кенә зур ачышлар очраклы кешеләр тарафыннан ясалган, аларның кайберләре соңыннан зур галим булып киткән...

Яхъяга шаяртырга җай чыкты.

— Алайса, безнең поварның да мәшһүр археолог булуын көтәбез инде!

Харрастан шундый сүзләр ишетү, иңбашында аның кул җылысын тою бик рәхәт булса да, Кәримә, яхшысынмыйча, читкә китте.

— Мә, алыгыз, зинһар! — дип алканы да Харраска сузды.— Хан заманыннан бирле җир астында яшәп, череп тә беткәндер инде...

*

* *

Караңгы бүлмәдә мыш-мыш килеп бала йоклый, зал якта кызмача ире сөйкемсез Әскәр «Шейх» белән ике тиенгә кирәкмәгән гәп сатып утыра. Аңа хәзер диңгез тубыктан, дөньякүләм мәсьәләләрне ялт иттереп хәл итәләр дә куялар. Минутына кырык мәртәбә профессор Хәй

Фәләхи исеме телгә алына, берсе азрак мактый башласа, икенчесе каршы чыга — эттән алып, еткә сала.

Шулай да Кәримә бераз тынычлана төште инде, йокыга гына китеп булмый. Әле бер, әле икенче хәлләр искә төшә дә уйлар куера гына бара.

Хатын карангылыкта ирексездән елмаеп ала. Беренче экспедициядән кайткач, Харрас аны профессор белән таныштырды. Аңа кадәр Кәримә кулларын йомшартып, тырнакларын очлатып һәм кызартып, чәчен-башын шәһәрчәләндереп өлгергән иде. Харрас кызны хәзинә табучы кеше белән очраштыру сылтавы белән алып керде. Кәримәнең дә экспедиция буена егетләр теленнән төшмәгән мәшһүр галимне күрәсе килә иде.

Профессор кабинеты Кәримә көткәнчә җиһазланмаган булып чыкты. Монда көзгедәй шома өсле мебель дә, китап шкафлары да, кырыс җитдилек тә юк. Кечкенә генә бүлмәнең стеналарына чүлмәк, таш тәлинкә, сынык пычак, әллә нинди таш кисәкләре тезелгән киштәләр ясалган. Республика археологларын җитәкләүче профессор үзе, тәмәке төтененә уралып, әллә кая, караңгы бер почмакка чумган.

Ишектән Кәримә белән Харрас күренүгә, Хәй Фәләхи, томанлы оясыннан чыгып, аларга каршы килде.

— Һоо! — дип ике кулын алга сузды ул. — Ишеттем, ишеттем, алтын хәзинә ачкансыз, кулыгыз җиңел булсын!

Кәримә үзенә кул сузып исәнләшүче ир-атларны яратмый. Сәламләшкәч тагын кулллар кысышуның нигә кирәге бар? Шулай да Хәй Фәләхи кебек данлы галимнең исәнләшүенә игътибарсызлык күрсәтә алмый иде. Аның алдында ул, гомумән, үзен мөмкин кадәр тәрбияле тотарга тырышты. Күрешкәндә Хәй Фәләхинең күзләренә дә туры карады, әмма озак чыдый алмады, «әһ» дигәнче, карашын читкә сикертте. Профессорның зур күзләреннән алай гына да качып котылырлык түгел иде. Күзгә-күз карамаса да, Кәримә аның һаман үзенә текәлгән икәнен сизеп, оялып бетте. Беренче каушау мизгелен үткәргәч, Кәримә профессорның йөзенә тагын бер күз ташлады. Бу юлы шардай күзләр, ашардай булып, кызның аякларына текәлгән иде. Йөгереп чыгып китәсе килде. Бу ирләрдә кайдан чыккан чир икән: кешенең аягын тикшерәләр.

Кәримәгә нәрсәнеңдер ошап җитмәвен сизенеп, Харрас кабинетта озак тоткарланмаска карар кылды. Чыккач та:

— Ну ничек, безнең шеф ошадымы? — дип сорады.

— Ач күз! — диде Кәримә. Артыгына теле бармады, егетнең әллә ни уйлавы бар тагын. Сүзне эшкә борды. — Ник теге Азов болгарларының чүлмәге турында да әйтмәдең?

Харрас тирән сулады.

— Анысы болай аяк өсте генә хәл ителә торган түгел, — диде. — Отчет биргәндә үзеннән-үзе кузгалачак. Ниләр булып бетәр.

Профессор — аңа республикада бармак белән генә санарлык археологлар арасына керергә мөмкинлек биргән, эзләнергә шартлар тудырган кеше. Үткән ел, институттагы шактый күп галимнәрнең каршы килүенә дә карамастан, Харрасның диссертациясен планга керттерде.

— Авыз тутырып сөйләрлек ачышы бар егетнең, якласын! — диде. Яңа табылдыкларының элекке нәтиҗәләргә каршы чыгачагын ишетсә, ни дияр?

Кәримә Харрасның кинәт уйчанланып калуын кысыр хәсрәттән санады.

— Җир астыннан килеп чыккан әйбер өчен ник шул кадәр борчыласың? — диде.— Син заказ биреп ясаткан чүлмәк түгел бит!

— И-их, Кәримә! Син галимнәр арасындагы мөнәсәбәтләрнең барысын да белеп бетермисең шул әле. Диссертант өчен, җитәкче — ал-

ла ул: теләсә, ожмахның түренә кертеп утырта, теләсә, тәмуг утына сала...

Харрас университетта укыганда ук, җәйге экспедицияләргә йөреп, Болгар тарихы турында күп материал туплаган. Тикшеренү институтының аспирантурасына кергәч, Хәй Фәләхи аңа план-проект төзергә, диссертациягә тотынырга киңәш биргән. Гыйльми совет җыелган. Галимнәр кулында — Харрас төзегән план. Планда Харрас шөгыльләнергә тиешле теманың төп мәсьәләләре тәфсилләнгән.

Утырышны алып баручы директор план-проект турында фикер алышырга кирәклеген әйткәч, сүзне иң баштa Харрасның үзенә бирәләр. Сөйләсен: ни өчен аңа бу теманы ачу кирәк тоела һәм нинди әһәмияте бар?

Харрас берсеннән-берсе җитдирәк галимнәргә карый да коты оча. Аларны Болгар дәүләтенең чикләрен ачыклау һич тә кызыксындырмый кебек. «Мин ни... э-е, ни-и...» ди дә егет баскан җирендә катып кала: Ул инде барысы белән дә ризалаша. Хәзер үзенә: «Бар, ускәнем, авыл мәктәбенә китеп, әйбәтләп, тарих укыт! Белгәннәреңне сөйләргә өйрән!» дисәләр дә, бер каршылык күрсәтмичә чыгып чабар.

Көтмәгәндә:

— Диссертантым турында берничә сүз әйтергә рөхсәтме? — дигән тавыш ишетелә.

Галимнәр Хәй Фәләхи чыгышы тәэсирендә Харрасның беренче каушавын сизми дә калалар. Шуннан барысы да җайланып китә. Утырышны алып баручы:

— Харрас Хәсәнов планы буенча кемдә, нинди сораулар бар? — дип сорагач та артык борчымыйлар.

Хәй Фәләхи бик төшендереп сөйләгәнлектән, проект хәлендәге план раслана. Соңыннан Харрас ояла-ояла рәхмәтен белдерә.

— Коткардың, слушай, мин беткән идем бит, мәңге онытмам! — ди.

— Чирканчык ала тор! — ди аңа Хәй Фәләхи. — Безнең эштә мондый хәлләр еш була. Эчкәрәк кергән саен, коткаручы күбрәк кирәгәя. Өйрән, брат, үзең дә өйрән, мин бер дә юкка тырышмыйм.

Кәримә бу хакта күп ишеткән иде инде. Харрас аны сүз җае чыккан саен кабатлый.

— Андый мизгелләрне онытырга ярамый, Кәримә, — ди. — Ул хәлләрдән бер котылып калуың гомер онытылырлык түгел.

*

* *

«Хәзер нишли ала инде Харрас? — дип хафаланып уйланды Кәримә. — Еллар буе бер-берсен хуплашып эшләделәр, бүген әнә дуслыклары чәлпәрәмә килгән...»

Күңеленең түрендә Хәй Фәләхигә карата шөбһәлерәк фикерләре уянса да, Кәримә үзләренең тормышын шул профессордан башка күз алдына китерми иде инде. Беренче экспедициядән Харрас белән Кәримә аерылгысыз гашыйклар булып кайттылар. Күп тә үтмәстән туйга әзерлек башланды. Хәер, болай гына түгел, алар хәтта Акъярда ук бергә торып китмәкчеләр иде, Сәгъдия әби генә сабыр итәргә кушты.

Өйләнешү турында беренче сүз чыгу вакыты исенә төшеп, Кәримәнең йокысын тәмам качырды. Бер кичне кыз Тәңкәле тау үзәнлегендә атнага бер уздырыла торган кичке уенга барудан баш тартты.

— Һәр көнне кабатлама инде, Кәримә, — диде аңа Харрас. — Бүген Чистайдан яшьләр кайта, уеннарның иң зурысы була. Синең күңелне күтәрер өчен кушылган эш түгел. Барыбыз да үз кәефен генә кайгыртса, нәрсә килеп чыгар соң?..

Кәримәнең үз хәле хәл. Ул инде Харрасның яңа табылдыклар ту-

рында уйлана-уйлана хафаланып йөрүенә, үзенә егетнең игътибары сүрелүгә дә иләнгән иде. Бүгенге киреләнүнең сәбәбе башкада. Клубка йөрүенең беренче көненнән бирле йөдәп бетте инде ул. Акъярда шундый гадәт бар икән: уеннар тәмамлануга яшьләр үзара парлашалар. Һәр кызны кайсы да булса бер егет озата кайта. Теләкләре тәнгәл килсә, бик хуш. Кайчак озатырга алынган егет кызның үз теләгәне булмый. Тегесенең анда-монда эше юк, җаны тарткан кызның клубтан чыкканын көтеп тора да караңгыда култыклап та ала, кычкырта-кычкырта озата китә. Яратмаган кеше белән кайтмас өчен, кызлар ишектән чыгуга җан-фәрманга йөгерәләр. Кайберләре шул кызулык белән өенә кайтып җитә, икенчеләренең озатырга омтылганнары җитезрәк була. Кунакларны яки Кәримә кебек андый-мондый йомыш белән килүче ят кызларны озату егетнең дәрәҗәсен бигрәк тә күтәрә ди.

Кәримә беренче көнне ут белән су арасында калды. Ишек төбендәге ут яктысыннан үтеп, мәктәп урамына борылырга уйлаган гына иде, артыннан лап-лоп чапкан аяк тавышлары ишеткәч тукталып калды. Күз ачып йомганчы җираф буйлыгы егет килеп чыкты, кызның беләгенә чатлап ябышты.

— Ник качтың? — диде. — Барыбер тоттым бит! Озата барам.

Монда әллә ни озатып-нитеп торасы юк, мәктәп борын төбендә генә. Әмма егетнең «озату» дигәне өйгә кайтарып кую гына да түгел икән әле. Ул әллә кайлардан, ындыр артларыннан әйләндереп-тулгандырып йөрергә, соңыннан, кочышып-үбешеп туйгач кына, кертеп җибәрергә ниятли икән.

Авылдагы бу гадәттән исән-имин котылу өчен Кәримә бөтен осталыгын ярдәмгә җикте. Ике метр буйлы Миңлебай исемле бу егет карамагыннан кара төндә йөгереп кенә котыла алмаячагын чамалап өлгерде ул. Сүзен Миңлебайга рәхмәт укудан башлады.

— Мин бик куркак, ярый әле очрадыгыз, — дигән булды. — Мин бит клубка да биергә дип кенә чыкмаган идем, эш шундый безнең.

Шуңа ялгап, ул үзенең экспедициясе, галимнәрнең яңа ачышлары турында сөйләп китте. Миңлебай, бичара, шактый беркатлы кеше икән. Кызның ярым чын, күбрәге арттыруга нигезләнгән фәлсәфәсен авызын ачып тыңлап барды. Кырый урамнарны уратып чыкканчы, археология турындагы мәгълүматы коргаксыды Кәримәнең, үз дөньясына — әдәбиятка күчте, Тукай, Такташ шигырьләрен сөйләргә тотынды. Ул, яттан күп белә. Егет, әрекмән яфрагыдай колак яфракларын сәлперәйтеп, укымышлы кызның такмаклавына мөкиббән китте.

Икенче-өченче көннәрдә клубтан кайту Кәримәгә алай куркыныч булмады. Кайтасы килүгә, ул ишек төбендә яшьтәшләре белән гәпләшеп торучы егетләр арасына керә дә:

— Миңлеба-ай, әйдә, озатып куй, булмаса,— ди. Көн саен яңа кеше алдында хәйлә корып азапланганчы, бер чирканчык алган Миңлебай белән кайтып китү хәвефсезрәк. — Соң бит инде.

Шимбә кичендә Тәңкәле тау итәгендәге кичәгә бик күп яңа егетләр җыелачак. Алар юаш Миңлебай белән исәпләшеп тә тормаслар. Кайтыр юл да ерак, Пушкинның «Евгений Онегин»ын укысаң да очына чыга алмассың. Аннары барысы да Миңлебай кебек шигъри җанлы булмавы да мөмкин...

Моңарчы Кәримә авылдагы бу гадәт хакында ләм-мим сүз әйтмәгән иде. Хәлне аңлатып биргәч, Харрас кызып ук китте.

— Ник син аны миннән яшереп йөрдең? Әллә инде безне егетләргә дә санамый башладың?

— Үзең куштың бит, Харрас.

— Үзең куштың, үзең куштың. Мин сиңа клубтан чыккач ындыр артларында йөрергә кушканым юк. Син аны үзең дә аңларга тиеш инде, әдәбиятчы бит син, һы! Миңлебай, имеш!

— Алай димә, Харрас. — Кәримә җырлар язып барган дәфтәрен сузды. — Менә болар — Миңлебай әйтеп яздырганнары...

Харрасның дәфтәргә карыйсы да килмәде, ашыгып өстен-башын алмаштырырга тотынды.

— Бүген уенга үзем дә барам. Мишәрләрнең бер мәкале бар: берәү карый тамаша, берәү урлый алаша, диләр. Син безне йоклатып калдырып, үзең кырын юлга кереп барасың икән бит.

Таңкаэле тау итәгендәге уен кызып кына бара иде. Моны Кәримә, беренче җырны ишетүгә үк белеп алды. Әйләнәдәгеләр уртага биергә чыккан кешегә багышлап такмак әйтәләр. Күп очракта җырның сүзләре биюченең холкына туры китереп сайлана. Кайчак такмак синең иң яман гадәтеңне фаш итә, чыдасаң чыдыйсың, чыдар хәлең калмаса, егылып үл! Синең кичерешләрең турында берәү дә уйлап тормый.

Кәримә белән Харрас башта читтән тыңларга булдылар.

Сулар ага, сулар ага,
Сулар ага арыктан.

Нечкә генә тавыш белән башланган җырны әйләнәдәгеләр бердәм күтәреп алып китте. Уртада килеш-килбәте бик купшы, үз-үзен тотышы да шактый һавалы күренгән егет басып тора иде. Яшьтәшләре, һич берәүдән тартынмыйча, аңа тамга ябыштырдылар да куйдылар.

...Кызын озатырга баргач,
Куркып качкан сарыктан!

Җырның соңгы сүзләрен ишеткәч, әйләнәгә кермичә, читтә тәмәке пыскытып торучы егетләр дә шарык-шорык көләргә тотындылар. Гомум хөкемгә чыгып басканының дуслары, аны бу газаплы имтиханнан тизрәк коткарырга теләп:

— Кил монда! — дип үз яннарына чакырдылар. — Нәрсә шулардан мыскыллатып торасың?

— Тыныч кына тәмәке суырасың килмәсә шулай ул, ишеттерәләр монда ишетмәгәнеңне!

Тик биергә катнашкан егет кенә җырны алай ук яманга алмады, киресенчә, ул канәгать иде, җанына рәхәт иде, чөнки такмактан соң аңа үзе теләгән кызны чакырып чыгарып бергә-бергә бию хокукы бирелгән.

Уен дәвам итте. Һәр такмактан соң, бәхетле парлар биеп әйләнгән арада җырчылар кушымтаны кабатлый.

...Әй тала, тала, тала,
Тала минем беләгем.
Нигә шулай ялкынланып
Яна икән йөрәгем?

Харрас бик тиз арада мавыгып китте.

— Кара, иҗади уен бит бу, слушай! — Ул Кәримәнең шул егет-кызлар белән уртак тел табып өлгерүенә гаҗәпләнеп тә, сокланып та карады. Авыл кызлары аны инде тәмам үз кеше иткән. Аңа ерактан ук сәлам бирәләр, яннарына чакыралар. Әле янында Харрас булганга гына тартынулары сизелә.

Кәримә бу шаян уенга да нияләнеп беткән иде инде, түгәрәккә кереп баскач, үзенә нинди җыр такмаклаячакларын да белеп тора.

Кунак кызы бас катырак,
Сындыр идән тактасын!
Сындырсаң идән тактасын
Үзем түлим акчасын!

«Харраска ниндиен җырларлар иде икән?» Тик Кәримә бу хакта әйтеп өлгерә алмады, Харрас:

— Кая, күрсәт әле Миңлебаеңны! — диде.

Кыз, көлүен башкаларга сиздермәскә тырышып, әйләнә эчендә бө-гелә-сыгыла басып торучы егеткә ымлады. Миңлебайны кемдер уртага чакырып чыгарган. Ул бүген Кәримә ягына күтәрелеп карарга да кыймый, кызның Казан егете белән килүенә тәмам кәефсезләнгән, үпкәләгән иде. Такмак башлап җибәрделәр.

Арыш башын кистеңме, бодай башын кистеңме?
Телеграмм баганасы булам диеп үстеңме?

Харрас эче катып көлде. Аның күңелендә әлеге җырны башлаган бөтерчек кебек җитез, җор телле кызга рәхмәт хисе уянды. «Шул кирәк ул Миңлебайга, Харрасның Кәримәсенә күз атып йөрмәсен!»

Җырчы да Харрас хәлендә иде бугай, Миңлебайның Казан кызын озатып йөрүенә эче пошкандыр, мөгаен. Ә Миңлебай барысыннан да киңрәк күңелле булып чыкты, ул үзеннән көлеп җыр башлаган кызның каршына басты да, шактый ук килештереп, тыпырдарга тотынды. Биеде-биеде дә, түгәрәктән чыгып өлгермәс борын җырын да башлап бирде.

Озын-озын бүрәнәне өстерләр елгага,
Икебез дә әйле-шәйле, икебез дә дивана!

— Вот, әйттерәләр мишәрләр, ә? — Харрасның йөзеннән елмаю китеп тормады. — Әйдә, Кәримә, без дә уенга керик әле, ни уйлап чыгарырлар икән?

Түгәрәк уенында кунак-төшем булса, аның белән һәркем биеп калырга тырыша, һәркем үз такмагын җырлап, кунакка мөнәсәбәтен белдерергә тели. Уртага Кәримә чыккач, җырны, барлык осталыгын җигеп, Миңлебай башлады.

Чирмешәннән агып килә
Чите бөккән пылатук.
Сүгәнең булса, йөремим,
Сүгәнеңне елатып.

Кәримәнең аяклары үзләреннән-үзләре Харрас каршына биеп бастылар, шуны гына көтеп торгандай, егет тә атылып чыкты, әллә кайчан, моннан ун-унбиш еллар элек үз авылларында уйнап йөргәннәрен искә алып, пырлап биеп китте. Кунакларның тартынмый-нитми, авыл яшьләрен үз итеп уенга кушылуларыннан күңелләре күтәрелеп, әйләнәдәгеләр бердәм җыр башлады.

Сандугачым кунып сайрый
Сәгать чылбырларына,
Нинди җырлар җырлыйк инде
Сәхрә былбылларына?

Бөтен авыл яшьләре алдында Кәримә белән биегәненә дә, үзләренә багышланган җырның гаҗәп матур булуына да Харрасның кәефе күтәрелгән иде. Ул, монда килүенең төп сәбәбен бөтенләй хәтереннән чыгарып, Миңлебайга булган ачуларын кинәт онытып җибәреп, рәхәтләнеп ял итте.

Таңкәле тау үзәнлегенә сиздерми генә караңгылык төшә башлады. Кызларның-егетләрнең йөзләре танылмас булды. Харрас, караңгылыктан файдаланып елгыр егетләрнең берәрсе Кәримәне озата китмәсен дип, кызны кулыннан җитәкләп алды. Янында егете булганнарга алай кагылмыйлар икән үзе.

Харрасның тиз генә кайтып китәсе килмәде. Кәримә дә аннан узып каударланмады, егеткә тулысынча буйсынып, ул нишләсә шуны кабатлап кына торды. Алар, уен барган мәйданны уратып, Таңкәле тау чишмәсенә килеп чыктылар. Караңгыда серле ялтырап әллә кайларга ашыккан су Кәримәгә гаҗәп матур, сәер булып тоелды. Яраткан шагыйренең әсәреннән хәтеренә төшкән юлларны кабатлады:

...Агышың, и агымсу, туп-тулы зар,
Синең ни хәсрәтең, ни моңнарың бар?

Төнге тынлыкта Кәримәнең әкрен әйткән шул сүзләре дә, урманнан кире кайтып, кабат яңгырадылар. Кайтавыздан кызык табып, Кәримә сөйләде дә сөйләде, көлде, шаярды, теле бер мизгелдә дә тик тормады. Кызның яттан шигырьләр сөйләргә яратуы да, юк кына хәлләрне мавыктырырлык хикәяли белү осталыгы да Харраска билгеле түгел иде. Ул сокланып тыңлады, тын алырга кыймас булды, Кәримәне бүләсе килмәде, аның гел шулай сөйләнеп торуын теләде.

— Эчәсең киләме, Харрас? — Бу вакытта кыз чишмә улагы янына барган, кулларына су алып шаяра башлаган иде.

Харрас, кызның үз кыланмышын кабатлап, тел очына килеп кергән җыр сүзләрен кабатлады: «Сусадым ла, җаный, ай су кайда? Дәрья суларыннан юк файда...»

— Син сүзләрнең кыйммәтен белеп бетермисең.

— Анысы нинди кыйммәт инде тагын?

— Безнең мишәр халкы «җаным» кебек сүзләрне гомерендә бер генә әйтә. Җан газиз бит ул.

— Мин бит мишәр түгел, аннары, ул сүзне минем дә телгә беренче генә алуым, — Харрас Кәримәнең чәчләренә сак кына кагылды. — Газиз кешемә генә әйттем мин аны, беләсеңме?

Битен, кулларын, аякларын салкын суга чылатып бетергән Кәримә: «Тотынма», — димәде. — «Кирәкми» — димәде, орды-бәрде итенеп егетне читкә какмады. Төн карасын аралап, гуя, бер мәлгә тирә-юньгә яктылык таратып, ап-ак тешләрен ялтыратып елмайды гына.

— Уф! Суы ла суы! Шундый рәхәт, шундый салкын! — дигән булды.

— Тәңкәле тау чишмәсендә юынсаң, аңа бүләк салып калдырырга кирәк, Кәримә, беләсеңме?

— Салмасаң ни була?

Егет Кәримәнең тыңламавыннан, чишмәгә берни дә бүләк итмичә китеп баруыннан, шуның җәзасын татып, соңыннан риваятьләрдәге шикелле гарипләнеп калуыннан шикләнеп куйды.

— Салмасаң да, берни булмас, бәлки... — дип сузды. — Шулай да син сал инде, халык гадәтен олылау булсын, сал, зинһар!

Кәримәнең Харрастан мондый сүзләрне тагын, тагын ишетәсе килә башлады.

— Гарипләнсәм, ни була инде, кемгә зыян, — диде. — Салмыйм.

— Ярамый, Кәримә, бу тирәдә күзгә күренми торган изге җаннар яши, кирәкмәс сүзне шаярып та сөйләшмик! — Харрас кызны үзенә тартты. — Я, тыңла инде сүзмне!

— Бер юлга гына тыңлыйм, — диде Кәримә, никтер сүзләрен пышылдап кына әйтте. — Мин бит юри генә сүз көрәштерәм, чишмәләр тирәсендә ничек йөрергә икәнен миңа кеп-кечкенә чагымда ук өйрәттеләр. Шул гадәт белән мин Казандагы водопровод краннарына да тасмалар элеп калдыра идем...

Алар бер-берсенә сыенган хәлдә, Тәңкәле тауның йокысын качырып, кычкырып көлеп җибәрделәр. Кыз, бөрмәле кыска җиңеннән хуш исле кулъяулыгын тартып алды да, чишмәнең урман авызына китә торган шарлавыгына ташлады.

— Бер истәлегем калсын әле!

Харрас белән Кәримә кире борылганда, Акъяр авылы тирән йокыга чумган иде. Егет белән кыз сүзсез генә, тирән тынлыкны тыңлый-тыңлый атладылар. Мәктәп янына җиткәч Харрас, кызның кулын тагын да катырак кыса төшеп:

— Әйдә өйләнешәбез, Кәримә! — диде.

Чибәр иде Кәримә. Чәчләре тумыштан аксыл сары, күзләренең зәңгәрлеге аяз күкләрне хәтерләтерлек булса да, кыйгачланып килгән кашлары кап-кара, керфекләре сөрмәле. Хәрәкәтләре дә буй-сынына килешеп тора, кыскасы, аның белән рәттән баруны, кара-каршы биюне һәр егет үзенә мәртәбә санарлык.

Кызның игътибарсызлыкка зарланыр урыны юк. Бию залында да, ял кичәләрендә дә егетләр аның янына сырышырга яраталар. Матур сүзләрен кызганмыйлар — телләреннән, әйтерсең, бал тама. Тау-тау вәгъдә бирүчеләре дә күп булды, әмма әлеге археолог кебек тиктомалдан: «Әйдә өйләнешик!» — дип кистереп әйтүчесенең очраганы юк иде.

Бигрәк сәер булып чыкты бу Харрас. Күңел өчен бер генә мактау сүзе дә әйтмәде, җае чыкса, тиргәп тә ташлый, ярату-фәләне хакында авыз да ачканы юк, кызыгырлык нәрсәләр вәгъдә итеп тә мәшәкатьләнмәде.

Үз уйларыннан үзе сискәнеп, тирән итеп бер сулу алды Кәримә. Харрасның бу сүзенә җавап биргәләгәнче кем беләндер киңәшәсе, күңелне дә тикшереп карыйсы иде. Егет исә очы-очка ялганмаган уйларны чуалта гына бара. Ул гүя Кәримәне үзенә кияүгә чыгарга өндәми, аны кисәтә, алдагы кыенлыклар белән куркытырга чамалый.

— Мин сиңа алтын таулар вәгъдә итә алмыйм, — ди. — Минем таулар, үзең күрәсең, гап-гади балчыктан өелгән. Безнең тормыш җиңелләрдән булмас, Кәримә, сикәлтәләр еш очрар...

Кызның әллә кайчаннан бирле бер сүз дә эндәшми баруыннан гына егет шиккә төште, кисәтергә ашыкты.

— Курыкма, Кәримә! Янымда син булсаң, бергә яшәсәк, мин ул тауларның астын өскә китерәм әле, үзең дә шаккатырсың!..

Икенче көнне, егетләргә иртәнге чәйне әзерләп биргәч, Кәримә яңа фатирга күченә башлады. Мәктәп күршесендәге Сәгъдия әби янына урнашырга булды. Бу гаилә кызга күптән таныш иде — экспедиция егетләренә сөт ала шул әбидән.

Карчык, япь-яшь кызның бер көтү егет-җилкән арасында яшәп ятуын күреп, әллә кайчаннан бирле үзе дә чакырып йөри аны.

— И-и канатым, ялгыз башыңа ыңгайсыздыр ул ир-ат арасында, ничек чыдыйсың? Әдә, тот та күч үзебезгә, алыңгы ызба бетеп сиңа булыр!

Харрасның колхоз идарәсенә ашамак-эчмәккә рөхсәт кәгазе алырга киткән чагын көтеп торды да Кәримә әйберләрен җыештырырга тотынды. Егетләр, бер-берсенә карашып, аптырашып, сүзсез калдылар. Соңгы вакытта алар инде Кәримәне үз күрәләр, якын итәләр иде.

Чыгып китәргә әзерләнгән Кәримәнең кулындагы чемоданын шофер күтәрде, әби йортына кадәр илтешергә рөхсәт сорады. Шул кыска араны үткәнче, Кәримә шофер егетнең дә кичә төндә Харрастан ишеткән олы сүзләрне раславын ишетте.

— Әгәр дә мәгәр,— диде шофер, гадәтенчә бормалый-бормалый. — Безнең берәребез синең алда гаепле икән, син аны үзең әйтергә тиеш! Әгәр дә мәгәр...

— Кит әле! — Кәримә аның азаплануына артык түзеп тора алмады. — Юк сүзне үрчетеп торма! Иркенләп яшәгез, мине Сәгъдия әби кыстады, шул гына.

— Синең китүгә без сәбәпче булсак, Харрас безгә көн күрсәтмәячәк. Гаепле кеше Казанга китәргә тиеш була. Ике сөйләшми ул Харрас, синең өчен любоебызның башын кисеп кулына тоттыра ала!

— Котыгыз алынган икән! — Кәримә, шатлыгын сиздермәс өчен, ашыгып сөйләргә тотынды. — Харрасыгызга үзем аңлатырмын, курыкмагыз!

Әмма Харраска моның сәбәбен ничек аңлатачагын үзе дә белми иде.

Эш урынына, борынгы шәһәрлеккә баргач, аш-су тирәсендә кайна-

ша башлаганчы, кулына археологлар коралы тотып, Харрас янына килде. Егетнең сөмсере коелган иде. Алай да күтәрелеп бәрелмәде, тонык кына сорап куйды:

— Безне ташлап китүең — миңа кире җавабыңмы инде ул?

Кәримәгә кызык та, рәхәт тә булып китте. Шул коры табигатьле, кырыс йөзле, үзалдына усалланып йөрүче кара «малай»ның бер уңай сүз көтеп тузынып йөрүе кызга шатлык бирә иде. Елмаеп, башын аска иеп, сүзсез тик торуыннан бу кичерешне Харрас та тойды. Үзе казып төшкән баз стенасына сөялгән килеш кызга озак кына карап торды. Сүзсез аңлаштылар. Бу урында гәп кирәкми дә иде. Өстә мавыктыргыч авыр эш торганда, кыска вакыт арасында хәл ителә торган мәсьәлә түгел.

Алар кичен Сәгъдия әбиләрдә очраштылар. Харрас башта үзен Кәримәнең җитәкчесе итеп, эре генә тотмакчы булып кыланды. Хәтта эндәшкәндә дә, гомер булмаганча, «Кәримә Хәбибулловна» дип кенә мөрәҗәгать итте. Тик сигезенче дистәсен куалап баручы мишәр карчыгының кемнең кем икәнен билгели торган үз бизмәне бар икән. Бер-берсенә карашып алгач, кызның комачтай кызаруы, сүз әйтә алмый аптырап торуы ук мөнәсәбәтләренең ни дәрәҗәдә икәнен карчыкка түкмичәчми ачып салды.

Шулай да карчык орды-бәрде кыланмады, егетне капка төбеннән үк кире борып җибәрергә ашыкмады, өенә чакырды, түрдән урын күрсәтте.

Башта егет белән кыз, әбинең кече якка чыгып китүен көтеп, эндәшмичә утырдылар. Карчык исә аларның икесе арасындагы урындыкка чүмәшкән, итәгенә бала башы чаклы йомгагын салган, кулына бишнәсен тоткан да чыгып китү турында уйлап та карамый иде. Аның башында ап-ачык хөкем карары әзерләнде: «Әгәр иртә бер, кич икенче егетне алып килеп баш катыра торган гадәте сизелсә, яхшы чакта, бу кыздан котылырга кирәк!»

Әбинең бу бүлмәдән кайчан да булса бер чыгып китәчәгенә өмете тәмам өзелгәч, Харрас серен уртага салырга тәвәккәлләде:

— Әби, — диде, — әллә соң мин дә сезнең янга гына күчеп килимме? — Аннары ул, карчыкның яман нәрсә уйлап куюыннан шикләнеп, ашыгып өстәде. — Без бит Кәримә белән барыбер өйләнешәбез.

Сәгъдия карчык монысын ук көтмәгән иде. Күзләрен челт-челт йомгалап, башта кызга, аннан егеткә карады. Кәримәсе карашын идәнгә текәгән, кымшанырга да, тын алырга да кыймый, өнсез калган. Шул кыяфәте үзе үк кычкырып тора: егет сүзенә бик риза, хәтта шатланып, бишкуллап риза. Ичмасам, йоласы өчен генә булса да каршы төшеп, кирегә тырнап куймас идемени?

— Ала-а-ай! — дип сузды әби. Янәсе, сиздем эшегезне! — Ата-аналарыгыз юкмыни соң сезнең, оланнар?

Кәримә дә, Харрас та бу көннәрдә эти-әниләрен бөтенләй оныта язганнар иде шул. Алар икесе берьюлы:

— Ба-ар! — дип кычкырып җавап бирделәр.

— Булса, сезгә сүзем шул, оланнар: иң әүвәл ата-аналарыгызның рухсатын, картларча итеп әйтсәм, хәер-фатихасын алыгыз! Олы сүзен тыңламаган олыгаймаган, диләр. Дөньяда көңел калу дигән нәрсә бар, ата-ана көңелен калдырудан куркыгыз!..

*

* *

Профессор янына икенче керүләрендә Харрас белән Кәримә аны туй мәҗлесенә чакырып чыктылар.

Хәй Фәләхи туйда берәүнең дә башына килә алмаган бүләк вәгъдә итте. Кунаклар үзара туганлашып, серләр тәмам уртаклашып җиткәч,

яшь галимнәргә теләкләрен әйтергә профессор сүз сорады. Матур гына сөйләде, күп итеп теләкләр теләде дә:

— Без, кулыбызда азмы-күпме мөмкинлек булган кешеләр, изге теләкләребезнең тормышка ашуын да тәэмин итәргә тиешбез, — диде. — Мин үзем, мәсәлән, Харрасны якын дустым санап, хезмәтен зурлап иртәгә үк аларга квартир юллый башлыйм. Институтта сүземне аяк аска салмыйлар иде, бу юлы да Идел буендагы яңа өлгергән йорттан ике бүлмәле квартир алып бирәчәгемә ышанам...

Табындагылар телсез калдылар. Зур корсаклы хуҗа агайның да күзе маңгаена менде. Бичара Харрасны ай буе интектереп йөрткән иде.

— Семьялеләрне кертмим, биш ай үтми бала табалар, аннары чыкмый аптыраталар, юк, булмый. Башка фатир эзләгез. Мин кыз кеше керттем, аны гына тотам, — дип, теңкәләренә тиде.

Харрас төрлечә ялынып карады. Аңа Кәримә урнашкан квартирның аерым бүлмәле булуы бик ошый иде, андыйны тиз генә кайдан табасың? Хуҗа белән уртак тел табуның бөтен чараларын чамалап карагач, бер еллык бәяне алдан биреп куярга ризалыгын белдерде. Шунда гына агай ачылып киткән иде. Анда да әле:

— Суны сез ташырсыз, идәнне сез юарсыз, — дигән шартларын тезде. — Лампочканың кырыклысын гына яндырырсыз, ут бәясен аерым түләрсез...

Хәй Фәләхи яшьләрне әнә шул мең бәлале фатир кайгысыннан коткарды. Ялкау ятыр, ризык артыр, дигәндәй, музей белән ике арада көн узсынга йөрүче Кәримә, шул рәвешле, бөтен мәсьәләләрне шома гына хәл итте дә куйды: һичнинди яклаучысыз кыз бала йортлы-җирле, хөрмәтле ханымга әйләнде.

Иртә дә, кич тә ире белән култыклашып кына йөргән Кәримәгә музейда да караш үзгәрде. Олы ук хезмәткәрләр аңа бил бөгеп сәлам бирәләр.

Кайбер көннәрдә хатынын эштән каршыларга килгән Харрас профессор белән була. Музейның моны күреп калган хатын-кызлары икенче көнне Кәримәгә сорау яудыралар:

— Хатыны бармы аның?

— Ник каршылап йөри, әллә сиңа гашыйк микән?

— Нәрсә хакында сөйләштегез? Татарча сөйләшә беләме?

Кәримә ире белән профессорның сүзләрендәге күп нәрсәне үзе дә аңламый. Әмма аның күз карашыннан шикләнү, читенсенү торган саен кими барды. Кәримә аңлады инде: Хәй Фәләхинең күз майландырып караулары әллә нинди астыртын ниятләр белән булмаган.

Туйлардан соң бераздан яңа квартирага күчкәч, профессор ачыктан-ачык әйтеп бирде. Ул көнне чакырмый-нитми генә кичке чәй алдыннан килеп кергәннәр иде алар. Хатыны Гүзәл, өй котларга дигән булып, бүләк-салак та кыстырган. Йөзләре ай кук балкый, икесе дә бик ачыклар иде. Алар түргә узуга, Харрас кибеткә йөгерде. Кәримә кухнясындагы тансыграк ризыкларын барларга тотынды. Тик, Харрас чыгып китүгә, залдан Хәй Фәләхи тавышы ишетелде.

— Кәримә ханым, ташлап тор әле ул савыт-сабаларны! Миңһим сүз бар.

Кәримә залга чыгу белән, Гүзәл башка бүлмәгә кереп китте. Профессор белән Кәримә икәүдән-икәү генә сөйләштеләр.

— Син бераз чамалагансыңдыр да инде, — дип башлады, Хәй Фәләхи. — Харрасның соңгы экспедициясе безнең арага дошманлык кертеп маташа бит әле.

Аның ачыктан-ачык сөйләргә теләмәвен сизеп алып, Кәримә сүзгә кушылырга ашыкты.

— Әйе, әйе, Харрас та бик борчылды аңа, — диде.

— Үзе борчыла да икән әле. Нигә соң алай булгач, киреләнә?

— И-и аның холкы шундый инде, үтә ул, үтә.
— Мин аңа гел яхшылык кына эшләдем. Бер теләгенә дә каршы килгәнем юк.
— И-и беләм инде, Хәй Хәерович, сез булмасагыз... Сездән күргәннәрне әти-әниләрдән дә күргән юк.
— Киләсе җәйгә, теләсәгез, тагын бергә барырсыз.
— Рәхмәт. Сезнең ул яхшылыкларыгызга без ничек кенә җавап бирep бетерербез инде, белмим.
— А, юк, белергә кирәк! Белми йөрү җиңел ул әлбәттә, тик миңа нәкъ менә сезнең, үз вакытында белеп, миңа да ярдәм иткәләвегез кирәк.
— Шаяртасыз сез! Безнең андый мөмкинлек бармы соң инде? — Кәримә профессорның үкчәгә үткәреп каравыннан котыла алмыйча, аптыраганнан кәләргә тотынды.
— Минем шаяртырга уйлаганым да юк. Миңа синең ярдәм кирәк, Кәримә ханым. — Хәй Фәләхи пышылдауга күчте. Ул үз үтенеченең күрше бүлмәдә утыручы хатынына да ишетелүен теләми иде, күрәсең.— Харрас — синең ирең, синең сүздән чыкмас, аны сабырлык кысасына кертергә кирәк!.Чамасын югалтты.
— Ничек?
— Минем тезисларны юкка чыгармакчы була.
— Ә-ә,— Кәримә яңа табылдыкларны исенә төшерде.— Беләм, беләм.
— Белсәң, аңлат, җаен табып, акрын гына, минем белән сөйләшкәнне сиздермичә генә...
— Ә? Ә-ә, әйе, әйе. — Кәримә тәмам каушады. Зур фәнни яңалык турында сүз бара монда. Чыш-пыш килеп, иренә каршы ниндидер килешү төзеп яту аңа оятсызлык, хыянәт булып тоелды. Як-ягына карангалады ул. Үзалдына: Әйе, әйе, беләм, беләм,— дип кабатлады.

Харрас кайтып кергәндә, өйдә барысы бергә гәпләшеп утыралар иде. Хатынның каушавын берәү дә сизмәде. Табын тезелде, чәй эчү башланды. Бераздан хатыннар үзләренә аерым сүз тапты. Кәримә, яңа күлмәген күрсәтергә, Гүзәлне йокы бүлмәсенә алып керде. Ирләр шул арада калай әтәчләр кебек күперенеп, кызып-кызып бәхәсләшергә тотындылар. Сүзләре нидән башлангандыр, Кәримә игътибар иткәндә, Харрас профессор әйткәннәргә колак та салмыйча үзенекен генә кычкыра иде.
— Мин ышанырга тиеш. Нәрсәгә ышана алам соң мин, фактларга, бары тик фактларга гына! Фактлар Идел буе болгарларының Азов болгарлары белән бер үк булуын күрсәтә. Һөнәрләре бер, димәк...
Хәй Фәләхи артыгына чыдап тора алмады, яман усал карап, чәчләрен тузгытып Харрасның өстенә ук иелеп:
— Мәшһүр галимнәр фикерен чүпкә дә санамыйсыңмы? — дип җикеренде.

Мунча ташы кебек кызган, су бөркесәң, пар булып очып китәргә җитешкән ирләр арасына Кәримә барып керде.
— Харрас дим!
— Нәрсә-ә?

Иренең ул чагында ук профессорга кырт кисеп биргән соравы Кәримәне чарасыз калдырган иде. Хатыннарга гына хас үтенечләргә тотынып карарга булды Кәримә.
— Әллә, мин әйтәм, чәйне кайнарлатыйммы соң? Сүз белән генә сыйламыйлар бит кунакларны, яхшым!

Хатынның сүзләре шулкадәр саф беркатлылык белән әйтелде — Харрасның инде яшен ташыдай кызганлыгы сүрелде дә китте. Хәй Фәләхи: «Молодец!» — диган кебегрәк ишарә белән Кәримәгә ым кагып куйды, хатынның җанын меңгә өзгәләде.

Кәримә хәзер дә бик ачык хәтерли әле, ул көнне Харрас аңа төне буе үз фикерен тәкърарлап чыкты.

— Әй, канатым, — диде. Ул, өйләнешкәннән бирле, Кәримәгә мишәрләрнең иркәләү сүзе белән эндәшә. — Тарихның төп баганалары турында сүз бара. Инде шунда да харәмләшсәк, нинди галимнәр булабыз без?

— Без аңа бурычлы, яхшым, каршы торып маташма!

— Син, канатым, фәнне пүчтәк нәрсәләр белән бутама. Фәләхине беләсеңме, ул син тапкан чүлмәктәге акчаларны да юкка чыгармакчы була.

— Ник?

— Чөнки алар Алтын Урда чорында Акъярның үзендә коелганнар. Ни дигән сүз бу? Бу — болгарлар Алтын Урда чорында да өлешчә мөстәкыйльлекләрен саклап килгәннәр дигән сүз. Белдеңме? Фәләхи әллә кайчан моның киресен раслап азапланган.

Кәримәнең зәңгәр күзләре карасуланып киткәндәй тоелды, үзе тапкан тәңкәләрнең кыйммәтен югалтасы килми иде аның.

— Кызык икән, тикшертсен алайса, — диде.

Шуннан башлап, аның өчен Хәй Фәләхи үтенече үз көчен югалтты. Хатын хатын булып кала бирде. Галимнәрнең бәхәсләре, ачышлары Кәримәнең яңа дөньясы алдында бик кечкенә мәсьәләгә әйләнеп калды. Кияүгә чыгып, ирле тормыш белән яши башлаган яшь хатынның көн саен, сәгать саен ясый торган ачышларына ни җитә! Кәримә моңарчы Харрассыз ничек яши алуына гаҗәпләнә иде. Балага узганын да белгәч, кич җитеп йокларга яткан саен, күз алдына май йомарламы кадәре генә сабые килә башлагач, хакыйкатьнең иң зурысын тапты Кәримә: җир йөзендә аның ире Харрастан да әйбәтрәк бер генә кеше дә юк икән бит!..

Уйлары шундый җан тынычландыргыч ноктага килеп терәлгәч, Кәримә зал ягыннан ишетелеп торган ямьсез тавышларга бөтенләй игътибар итмәс булды, онытылды, йокыга талды.

Шомлы тынлык уятты аны. Зал ягының уты сүндерелмәгән. Кәримә, йоклап киткәннәрдер, уятмыйм дип, песи-песи генә басып түргә чыкты. Бүлмә тәмәке төтене, аракы исе белән тулы. Әскәр «Шейх» юк, киткән, күрәсең. Харрас башын эскәтергә салган да мышык-мышык елый.

Кая ул төпченеп, ачуланып торулар! Иман баганасыдай терәгенең кинәт муртаеп төшүеннән куркып Кәримәнең тез буыннары хәлсезләнде, гәүдәсе тоташ калтыранырга тотынды. Хатыннарның котын алам дисәң, аның үзенә бәйләнеп тә маташма, ирен генә кимсет, иренең генә кул-аягын бәйләп куй икән.

Елавының сәбәбен сорарга да кыймыйча Кәримә:

— Ят инде, ял ит! — диде.

Харрас, шуны гына көтеп торган кебек, тиз арада башын күтәрде, яшьле күзләрен учы белән уып алды да, диван буена сузылып ятып, ачыктан-ачык елап җибәрде.

Кәримә ирен бу хәлдә беренче күрә иде. Артка чикте, караңгы аралыкка басып, кыймылдарга куркып калды, бөтен жаны-тәне белән зал ягыннан, Харрас авызыннан чыккан тынычландыргыч бер сүз көтте. Өзлексез елап ятмас, ачылыр, эндәшер!

Күп тә үтмәде, диван турысыннан йоклап киткән Харрасның гырлавы ишетелде. Кәримә утны сүндерде, авыр уйларына уралып, кап-караңгы өйдә берүзе калды. Хәзер йокы турында өметләнергә дә юк, тизрәк көн яктыруын гына теләргә кирәк.

Күңелсезлек баскан бүлмәдә җанына урын таба алмыйча, хатын кухняга керде, тәрәзә аша урамга, кара төнгә карап тора башлады. «Баланы күтәреп булса да, быел да экспедициягә чыгарга кирәк булган

миңа, дип үкенде ул.— Бергә чыкканнарында ничек тыныч кына эшләгән идек, профессорга да бергә-бергә кереп йөрдек, ул кадәр үк тузынмаган иде бит. Ник кенә бу акыл дигәнең ахырдан йөри соң? Иртәгә әйбәтләп киңәшергә, кирәк булса, Хәй Фәләхи янына да икәүләп барырга. «Шейх» белән эчеп исерүдән кемгә ни файда? Ул бит яхшылыкка йөрми, хәлсез җаннарны сагалаган козгын кебек ул...»

Кәримәнең болай фикер йөртергә нигезе дә бар иде. Үзе катнашкан экспедицияләрнең нинди бай материал туплап кайтуын яхшы белә ул. Кәримәнең фольклор дәфтәренә теркәлгән бер риваять үзе генә ни тора.

*

* *

...Моннан күп гасырлар элек бүгенге Акъяр авылы урынында кечкенә генә бер кабилә яшәгән, ди. Җир-суы да, урман-кырлары да үз ихтыяҗына житәрлек кенә икән. Мәйданы зур булмаса булмаган, әмма ләкин кешеләре гаҗәп уңганнар, ди. Тирә-күрше кабиләләрнең төшенә дә керми торган мул иген үстерәләр, һичкайда күренмәгән мал-туар асрыйлар, елгаларында мыжлатып балык үрчетәләр, имеш.

Җәй үтеп, җиргә салкыннар төшү белән, мондагы халык сугымга, киндер-йон тукырга, тире иләп тун тегәргә, күн эшләргә, итек-читек каерга тотына. Аннары, әзер малны олауга төяп, базар-ярминкәләргә китәләр. Аларның товарларын дөнья базарында алдан көтеп торып, кул сугып алып бетерәләр, ди.

Илнең оста һөнәрчеләре, җир-суының бәрәкәтлелеге турындагы дан еракларга таралган.

Мәшһүр кабиләнең башында этисеннән өйләнергә дә өлгерми калган булдыклы бер егет утырган. Ул якын-тирәдәге җирләргә кызыгу, басып алу белән мавыкмаган. Шунлыктан бу халык еллар буе тыныч кына яшәгән дә яшәгән.

Ил башында утырган егетнең жаныннан да газизрәк күреп йөрткән Тәңкәсылу исемле сөйгән яры булган. Бу кыз да, яшьли ятим калып, бәк сараенда тәрбия алган, бәкләр табынына дип әзерләнгән нигъмәтләр белән туенып буй җиткергән. Кызның инсафлыгы, чибәрлеге, күндәмлеге телдән-телгә сөйләнеп, макталып йөртелгән. Тәңкәсылу белән бәк-егет арасында мәхәббәт барлыгы да телгә кергән, җырларда җырлана башлаган.

Егет, үзенчә, туй итәргә ниятләп куйган көн якынлашканнан-якынлаша барган. Ул, сабырсызланып, кавышу көтеп, гажизләнә икән. Зиннәтле сарайлары жанына тар тоела, ди. Мондый чакларда егет, ук-җәясен ала да, ашкынулы күңелен басу өчен, кара урманга китеп бара, көннәр буе сунарчылыкта йөри. Кояш баеп, җир өстенә пәрдә булып караңгылык төшкәч, егет, күргәннәрен серле әкият итеп Тәңкәсылуга сөйләр өчен, сарайга кайта. Кыз да бу очрашу минутларын түземсезлек белән көтеп тора, бәк-егетне ачык йөзе, тәмле сүзе белән каршы ала.

Шундый көннәрнең берсендә егет, киек җәнлек эзләп, кара урманда йөргән арада бу җиргә явыз дошман басып кергән. Дошман гаскәре үзәктәге сарайга ук килеп җиткән. Гаскәр башлыгы, кылычын һавада уйнатып:

— Үзе кайда? Үзен табыгыз! Үзе чыксын! — дип кычкырган. — Бил бөгеп, тез сындырып каршымда аунасын! Үзен әсир итәбез, башкаларына тимәбез!

Өйдә булса, бәлки, берәр җаен табар, халкын бу вәхшәттән коткарып та калган булыр иде егет. Җитәкчесез төркем нишли ала соң? Халык, кулыннан килгәнчә, каршы торып азапланган. Меңнәр һәлак булган, адәм каны дәрья кебек аккан.

Тәңкәсылу, бу бәхетсезлектән һич хәбәре булмыйча, гөлбакча читендәге көзге сыман түгәрәк күл буенда утыра икән. Сарай хезмәтчеләре дә кызны яшереп өлгерә алмый калганнар. Егетне эзли-эзли хәлдән тайган дошман ялчылары, атларын җан-фәрманга чаптырып, гөлбакчаны айкый башлаган. Арадан берсе күл гүзәллегенә сокланып утыручы сылу кызны күреп ала. Күз салуга, бу кызның «каралар» затыннан түгеллеген, бәкнең кәләше икәнен сизә, чөнки Тәңкәсылуның килешкилбәте хакындагы сүзләр бу юлбасарга да килеп ирешкән була. Ул шатлыгыннан зәһәрләнеп елмаеп ук куя: «Һа-ай, һай-һай-һай, чибәр туташ! — ди.— Килче бире. Мин синең бәктән һич тә ким түгел, иркәлимче үзеңне!»

Кыз, бичара, ары караган, бире тартылган, ачыргаланып, егетен ярдәмгә чакырган. Аның кош сайравы күк нәфис тавышы ерак урман артындагы сунарчыга ничек ирешсен инде?

Дошмани зат, күзләрен яман майландырып, кызга таба үзе килә башлаган. Чарасыз Тәңкәсылу, якты кояшка бер мөлдерәтеп караган да, дулкыннарында үзен тирбәтеп үстергән күл суына ташланган.

Шулчак күл, изге кызның җанын кызганып, үз суыннан үзе ваз кичкән. Күз ачып-йомганчы, күл урынында мәһабәт тау хасил булган. Тәңкәсылу биеклекнең түбәсендә торып калган. Мондый гайре табигый хәлдән коты алынып дошман явы кире чигенгән.

Шәрәләнгән җирдә Тәңкәсылу белән сунарчы егет икәүдән-икәү яши башлаганнар. Аларның бик күп балалары булган. Тик алдан узган вәхшәт, гаделсез сугышта шәһит киткән халык гаиләнең хәтерендә мәңгегә кара кайгы булып кала. Тәңкәсылу аларны юксынып һәр таңда кайнар яшь коя икән. Яшьләре, ул дөньядан киткәч тә, гәүдәсе әлеге бу тау башына күмелгәч тә, кипмәгән. Бүгенге Тәңкәле тау итәгеннән шифалы су булып, шул изге яшьләр ага, имеш...

Харрас Кәримә язып кайткан бу риваятькә ай буе шатланып йөрде. Ул, күрәсең, археологның башка ачышлары белән аваздаш иде. Болгар җиренә килгән вәхши яу, шул шартларда да мөстәкыйльлеккә омтылу, зур серләрнең Тәңкәле тауга күмелгән булуы — болар барысы да Харрас кулындагы дәлилләр буенча да азмы-күпме билгеле. Нәкъ шуңа күрә дә бу тирәләрдәге эзләнүләрне киңәйтергә, ашыктырырга кирәк иде.

Бу җәйдә Акъяр калкулыгына Харрас киңәйтелгән экспедиция оештыруга иреште. Коллективта галимнәр дә, эшче көчләр дә башка еллардагыга караганда артыграк иде. Казу киң мәйданда ике ай буе алып барылды. Моңарчы һич билгеле булмаган зур-зур биналарның нигезе, диварлары чистартылды. Яңа табышлар да, иң әһәмиятле казылдыклар Тәңкәле тау үзәнлегендә, дигән фикергә куәт бирәләр иде. Тик тикшеренүләрне иске ысул белән генә алып барганда, эш бик озакка сузылып, аның очына-кырыена чыгу мөмкин булмаячак. Шунлыктан Харрас, әле бу сезонның мәшәкате бетмәс борын, киләсе елдагы эзләнүләрне тагын да колачлырак итү, кызулату хакында баш ватты.

Җаны тыныч түгел иде аның. Җәй буе шулай хафаланып яшәде ул. Өйдә Кәримәнең яшь бала белән ялгыз калуы да эчне пошырды. Аратирә ял алып, Казанга кайткаларга туры килде. Кәримәсе баланы кулына да тота белми иде бит. Хәер, монда Харрас та ярдәм итә алмый инде. Бала елый башлый да, икәүләшеп йөгереп киләләр — сабыйны кулга алырга да куркалар үзләре.

Инде менә, Харрас ялга чыккач, барысы бергә, авылга, әти-әниләр янына бәби үстерергә кайту иде исәпләре...

Яктылык беленә башлау белән бала кыбырсырга тотынды. Кәримә аның белән әвәрә килгән арада, Харрас торып чыккан да чәй куйган, туалет бүлмәсенең кечкенә көзгесе каршында кырынырга әзерләнеп ма-

таша. Башка иртәләрдә ул уяну белән сабыен иркәләргә ябыша иде. Таң сәгатьләре дә аның эч пошуларын баса алмаган икән.

Кәримәгә бу кадәресе үк аңлашылмый иде инде. Хәй Фәләхи белән телгә килдем дип ник шул чаклы кыйналырга? Бүлмәсенә барып кер дә сөйләш инде төбенә төшкәнче. Юк, монда эш турында кайгырту гына түгел, башка нәрсә бар, теге «Шейх» әйткән хатын болгаткан булырга кирәк аны. Карачурина белән ниләр сөйләшкәнен ничек белергә? Кемнән сорарга? Харрастанмы? Ул үзе дә әйтер әле.

Ире сүз башлаганчы, Кәримә, телен аркылы тешләп булса да, чыдарга тырышты. Ул арада тагын бала чыркылдап уянды, аның мәшәкате барысын да оныттырды. Кызчыкны тынычландырып, корытып, чиста урынга салганчы, Харрас кияү егете кебек киенгән, ислемайлар сөртенгән, кайнаткан чәенең иң куесын сыгып эчеп бетергән дә чыгып китәргә әзерләнгән. Китеп барышлый гына булса да, җанга ятышлы бер сүз әйтүенә өметләнеп, Кәримә иреннән күзен алмады. Тегесенең генә теле һаман ачылмады, авызына күн теккәнмени, валлаһи!

Иркә Кәримәнең, кияүгә чыккач та, моңарчы җил-яңгыр тойганы булмады. Мүзейда эшли дип исәпләнсә дә, туйлардан соң җиде ай үткә, озын ялга чыкты, эше турында борчылып уйланмый. Аның хәзер борынгылар әйтмешли, ашау — байдан, үлем — ходайдан: бае да, ходае да — шул кара Харрас инде. Анысы да, тиз арада гаиләле кешегә әйләнүеннән, өен тәэмин итеп тора алуыннан бик канәгать, горур.

Гөрләп барган шул тормышың челпәрәмә килеп карасын әле!

Харрас, ничек тә Кәримә күзенә чалынмаска тырышып, ишек төбенә килде. «Ичмасам, тотып алып бер кычкырышырга иде! — дип уйланды ул эченнән. — Хатынның мескенләнеп, пысык-пысык килеп йөрүенә караганда, пәрә-пәрә кычкырышуы яхшырактыр». Нәрсәгә ачуланырга белми аптыраган Харрас хатынына әйтер бер сүз дә тапмады. Элгечтән плащын алды да ялт итеп чыгып китте. «Мин киттем әле», — дигән сүзе ишеккә кысыла язып калды.

Әй бу ирләр! Нәрсә дип шул бер авыз тәмле сүзләрен кызганалар икән? Хатынга аның артыгы кирәкми дә бит. Күңелен күреп, җанын тынычландырып куйсаң, синең өчен, тормыш арбасына ат урынына җигелеп, бөтен нужаны берүзе тартырга әзер бит хатыннар.

Хәер, Харрасның үз хәле Кәримәне җайлап утырудан узган иде шул. Әскәр «Шейх» аңа шактый нәрсәләрне аңлатып бирде

— «Шеф» ул, малай, син уйлаганча, гади җитәкче генә түгел, юмарт булып кыланса да, артыгын ычкындырмый. Ул — настоящий циркач, беләсең килсә, ат биетүче.

— Ничек инде ул?

— Безнең ишеләрне үзеннән егерме метрлап читтә тотарга ярата, белдеңме...

Кара каршы әйтешеп утырганда, Харраска Әскәр сүзләре бик вак тоелган иде, вакыты-вакыты белән йөзен җыерып кына тыңлады ул аны. Әмма иртән уянгач, күңел дигәнең тагын шомлана башлады. Харрас тагын бер кат профессор белән сөйләшеп карарга уйлады.

Кеше сүзе кеше үтерә, дип юкка әйтмиләр икән: Харрас кабинетка керү белән үзен тамашачы, ә профессорны ат биетүче итеп тоя башлады. Хәй Фәләхинең сүзләре дә бүген күңел түреннән чыкмый, кыланмышлары да нәкъ артистларныкы кебек.

— Сез әле китмәдегезмени? Кәримә ханым, авылга кайтабыз, дигән иде?

— Мин бу килеш ничек ял итә алыйм, ди.— Харрас профессорга ничек эндәшергә белми аптырады, ык-мык килеп, шактый азаплангач, — Хәй Хәерович, — дип куйды. — Өзеп сөйләшәсе иде.

— Кичә сөйләштек бит инде, слушай. Кайдан чыккан бу үзсүзле-

лек? Дөньядагы бер галим дә бары тик үзе теләгәнне генә эшләп утыра алмый. Аңла шуны.

Харрас хәзер үзен тамашачы итеп түгел, ә биюче ат хәлендә тоя башлады.

— Бүлеккә тапшырылган зур эш бар...

— Сез бит бик яхшы беләсез: ул чор буенча миннән бер файдалы фикер дә чыкмаячак! — Харрасның ат буласы килми, ул хәзер киреләнә, аренага биергә чыкмаска тырыша. — Мин ул чорның әлегә кадәр ачылган нәрсәләренә дә ышана алмыйм, плюс-минус ике мең ел, ха-ха-ха!

Яшь галим үз сүзләренә таләбен тәмам югалтып, бүлмәне күтәреп көләргә тотынды. Аның «плюс-минус ике мең ел» дигәне профессорның бер хезмәтенә карый иде. Ул чакта Хәй Фәләхи, мөһим бер фикерен раслардык дәлилен Ленинградка, махсус лабораториягә җибәрде. Табылдык айга якын вакыт эчендә әллә ничә кулдан үтеп Казанга әйләнеп кайтты. Табылдык өстенә лабораториянең тикшерү нәтиҗәсе, ягъни фараз кылынган дәвер-ел язып ябыштырылган һәм җәяләр эченә «∓ 2000 ел» дип тә өстәлгән. Хәтта Хәй Фәләхи өйрәнә торган чор өчен дә бу якынчалык артык та зур иде. Яшь галимнәр түшәмне кубарып ташларлык тавыш чыгарып көлгәннәр иде ул чакта. Харрас шул хәлне искә төшерде.

Профессор монысын ук көтмәгән иде — телсез калды. Әйтсәң сүз,— төртсәң — күз дигәндәй, уйламый башланган әңгәмә бөтенләй бүтән юнәлеш алды. Профессорның күзләре төссезләнде, ул боздай салкын тавыш белән:

— Сез, иптәш Хәсәнов, безнең элекке дуслыктан усал рәвештә файдаланмакчы буласыз бугай, онытыйк әле ул мөнәсәбәтләрне, — диде. — Һәм ачыклыйк: кем без?

Бу кадәр үк ачыклап тормаса да, кемнең кемлеге билгеле, берсе — илгә мәгълүм галим, икенчесе — әле томшык сарысы китмәгән кош баласы, студентлыктан котылуына да нибары дүрт ел. Бәхәсләш, рәхим итеп, сүз көрәштер!

Харрасның хәтта буе да кыскарып киткәндәй булды. Куллар, кая тотынырга белмичә, сузаеп, гәүдәсе буйлап асылынып төштеләр. Аннары ул, кинәт айныгандай, ачылып китте. Дөнья гел шул бер Фәләхигә генә терәлеп калмаган лабаса! Харрас башын күтәрде, тузгыган чәчләрен сыпырып алды:

— Ул чагында, минем экспедиция мәсьәләсен бүлек утырышына куйыйк. Коллектив ничек кирәк тапса...

Бу юлы дөнья яңгыратып Хәй Фәләхи көлә иде.

— Наивный да кеше соң син! — Артыгын ычкындырмады ул. Уйчанланып калды.

Харрас хәтта, әһә, шүрләттемме дип, сөенә дә башлаган иде инде. Чөнки профессорның йөзенә, яңа фәнни ачыш турында хәбәр ишеткәндәгедәй җитдилек чыкты.

Бүгенге профессорлык аңа җиңел килмәде. Бу малай-салайлар мич башында елап утырганда, ул инде кулына хәрби корал тоткан иде. Соңыннан, кыршылып беткән гимнастерка киеп, заводка эшкә йөрүләр, бала-чага арасында лекция тыңлап утырулар — берсе дә хәтердән китми.

Археология белән «җенләнгәч» махсус планга күчте ул. Егет килеш картаеп барган кешенең авыр көннәр «ашаган» яшьлеген кире кайтарырга зур һәм көчле омтылышы иде бу. Аның бер генә теләге дә көтелмәгән, очраклы җиңеллекләргә юлыкмады. Аны берәү дә, беркайчан да кочак җәеп каршылап алмады.

Ярый әле, башлаган юлы уң булып чыкты. Хәзер аның белән дөнья галимнәре бил бөгеп исәнләшә. Әмма кеше кулына тоттырырлык бер

хезмәт язып өлгерткәнче, Фәләхи меңләгән киртәләрне сындырды, бихисап каршылыкларны җимерде.

Хәзер үз каршында авыз ерып басып торучы Харрасны ул, кыен хәлгә тарыганда таянычым булыр дип, кулыннан җитәкләп йөртте. Башлы егет, эзләнүләре нәтиҗәле, темасы кызыклы. Беренче адымнарыннан ук остазына каршы чыгар булгач, алдарак нишләмәс? Аның кебек чакта Хәй Фәләхи бер командировка алу өчен ун кеше алдында йөз суы түгә иде.

Профессор бик карт кешеләрчә итеп:

— Менә нәрсә, энекәш, — диде. — Инде тавыш күтәреп кычкырырга җыенгансың икән, турыдан-туры гыйльми советка кер син. Бүлектә генә сине берәү дә якламаячак, «Шейх» кебекләр котыртырга гына оста алар.

Хәй Фәләхинең үз-үзен шулкадәр тыныч тотып, горур төстә аңа ук каршы эш йөртергә өйрәтүе Харрасны тагын мөшкел хәлгә төшерде. Моңарчы профессорның үз урынында шулкадәр килештереп утырганын Харрас туры китерде микән? Китермәгән булсаң, күзеңне тутырып кара инде, әйбәтләп кара, аннары эчендәге уйларыңны, түкми-чәчми ак кәгазьгә яз да гыйльми советка кертеп тапшыр. Бүгенгәчә Хәй Фәләхи кулы астында яшәгән идең, ниһаять, үзеңә юл ярыр чагың җитте.

Профессорның сүзләре бетмәгән икән әле. Ул Харрасның аптырабрак калуыннан файдаланып:

— Мин сине бу кадәр ашыгырсың дип башыма да китермәгән идем, — диде. — Канаты чыккач кош баласының очып китәсе билгеле, синең канат та юк бит әле, юньле кош киткәндә дә оясын пычратып калдырмый. Утызың тулмаган бит, утызың!

— Яшьнең ни катнашы бар монда?

— Аңламыйсың, диссертация яклаганда, лихачество белән генә алдырып булмый. «Яклау» дип атала ул, «яклау» — ягъни син нәрсәнедер, сине кемнәрдер якларга тиеш. Дуслар яклый, дуслар, ә синең үз җитәкчеңә каршы чыгуың нәкъ менә лихачество булып күренәчәк.

— Минме лихач?

— Уйлап кара, уйла!

Хәй Фәләхи урыныннан торып басты. Бу — сүзләрнең тәмамлануын аңлата иде. Харраска кабинеттан чыгып китүдән башка чара калмады.

*

* *

Иртәдән үк тагын яңгыр шыбырдавы Кәримәнең үзәгенә тиде. Инде ничә көн буе гел бер төрле сибәли дә сибәли. Кичкә табан гына туктalгандай итә дә, таңга ялганып, тагын тирә-юньне каплап ала.

Тымызык яңгырга кушылып, Кәримәнең дә елыйсы килә. Күңелсез уй башыңа кереп ояламасын гына икән ул, бер җаныңны яулап алса, селкенергә дә юл бирми башлый. Калган барлык хәлләр хәсрәтеңне куәтли генә баралар. Кәримәгә, бәлки, бераз сабыр итәргә, башы җитмәстәй бу вакыйгаларга бөтенләй катнашмаска, читтән генә карап торырга кирәк булгандыр. Кызганычка каршы, аңарда мондый гадәт юк иде шул.

Үзе әле кичтән генә Харрасына теләктәш, аңа ярдәм итәргә мең риза иде. Иренең иртән эндәшми-нитми чыгып китүе хатынның барча кичерешләрен кирәкмәгән якка борды да куйды. «Юньле юлда йөрми бу астыртын, — дигән шомлы нәтиҗә чыгарды Кәримә. — Эштә кем башына нинди күңелсезлек килми. Аның саен бөтен ирләр моның кебек җимерелә башласа, җир йөзен чал чәчле карчыклар басар иде, бер генә кара чәчле хатын да калмас иде. Хикмәт эштә генә түгел, үзе яман юлга баскан ул, үзе!»

Кәримәнең фантазиясе бу юнәлештә электрон машиналардан да җитезрәк эшли башлады. Аның уенча, Харрас белән ике арага ят хатын кергән, мөгаен. Бер уйнамый ир утырмый, диләр бит, моның ире дә шул уйнак дәвергә аяк баскан, күрәсең. Бала күтәреп, тол булып калмассыңмы?! Кулга-кул тотынышып кайтып керерләр дә, без бер-беребез өчен туган, әлегә кадәр очраша алмый гына интекканбез, диярләр. Харрасның кием-салымнарын җыярлар да чыгып китәрләр. Нишчекләр итеп чыдарсың?

Болай тик утырырга ярамый, чарасына керешергә, тамырына төшәргә кирәк. Сыерны батканда кыйныйлар, ычкынып китсә, сиңнән кыйнатып та тормый ул. Яннарына туп-туры барып керергә, күзләренә карап, мәсьәләне бүген үк хәл итәргә!

Харрасны юлдан яздыручы хатынның кем икәнлеген дә Кәримә тиз белде. Карачурина! Ә аның кайда эшләве билгеле.

Хатын, кулына баласын күтәргән килеш, телефон янындагы креслога килеп утырды, саннар җыйды. Трубкадан:

— Карачурина яңа гына өенә кайтып китте, — диделәр.

— Өй телефонын бирегез әле, зинһар!

— Яңа йортта яши ул, телефон кертелмәгән әле.

— Алайса, адресын әйтегез!

Адресын яздырдылар яздыруын, тик шуңа өстәп кисәттеләр: «Бүген өенә барып йөрмәсәгез иде, уйларының бик чуалган чагы».

Әле шул сүзне ишетмәгән булса, Кәримә тиз генә тәвәккәлли дә алмаган булыр иде. Аның күз алдына ап-ачык күренешләр чиратлашып килә башлады. Бизәнеп-ыспайланып чыгып киткән Харрас Солтания янына барып кергәндер, тегесе күзенә кереп китәрдәй булып Харраска карап чекерәеп утырадыр. Солтаниянең бер карауда теләсә кайсы егетне һуштан яздыра торган кара каймалы соры күзләрен Кәримә бик яхшы хәтерли. Җебегән Харраска тагын ни кирәк, күзләрен шарландырып: «Аһ, нинди гүзәллек!» — дип шаккаткандыр.

Кызын күтәреп урамга чыккач, Кәримәнең башына тагын бер уй килде. Хәер эстәнеп йөрүче чегән хатынына охшамас өчен, Нариман урамындагы таныш карчыгына кереп баласын калдырып торырга булды. Әҗерен түртте, озак йөрмәсен әйтте. Аннары ул, Киров урамына чыгып, Ленин районына илтәсе троллейбус тукталышына килеп басты.

Өйдә чакта бик тәвәккәл кыланса да, соңгы адымны ясарга көче җитми торды Кәримәнең. Инде ничә троллейбус үтте. Ул аларны гүя күрми дә, ишетми дә. Хәзер ике дә уйламастан, ул газраил каршына барыр, әмма Солтания өенә аяк басмас иде. Күзенә Харрасы гына күренсен дә ул җанга якын бер сүз генә әйтсен. Бичара хатын ире кайтырга тиешле юлга карап катты. Трамвай тукталса, көтү-көтү кеше арасыннан да Харрасны эзләде. Хәтта выж да выж узгалап торучы таксиларның да тәрәзәләрен күзли барды — ашыгып кайтуы да мөмкин, хатынымны интектермим, тынычландырыйм тизрәк, дип уйлавы да бар бит кешенең...

Ахырда, сабыр канатлары салынып төште Кәримәнең. Буп-буш бер троллейбус килеп туктаган иде, шуңа керде дә утырды. Эчтән генә үзенүзе кыюландырырдай сүзләр тапты: барыйм әле, ятып калганчы, атып ал, диләр. Мин бит әле, начармы-яхшымы, татарларның иң усал төркеменнән саналган мишәр баласы. Хәлгә ачыклык кертүнең гаебе юк, ник килдең, дип, куып чыгармас, ник сорыйсың, дип, авызга сукмас.

Солтания Карачурина уңдүрт катлы йортның иң биектәге квартирасында яши булып чыкты. Беренче карашка, менеп җиткәнче шактый ара кебек тоелса да, лифт җайланмасы, Кәримә тынычланганчы, кирәкле урынга менгереп тә куйды. Тар коридорда, Карачуринаның кап-кара күн белән тышланган ишеге каршында Кәримә тагын да каушый төште. Әмма аның башка чарасы юк иде: калтыравык кулын кыңгырау

төймәсенә сузды. Эчке якта, Кәримәләр өендәге кебек коточыргыч әче чылтырау түгел, моңлы җыр кисәге кебек көйле аваз яңгырады. Озак көттермичә ишек тә ачылып китте. Күз кырые белән генә карап алуга, Кәримә: «Бу каһәр һаман чибәр икән», — дип уйлап өлгерде.

Солтания, чыннан да, очраган кешеләрне үтеп киткәч, кабат артларына борылдырттырып карата алырдай чибәр кыяфәтле иде. Үз өендә, өстенә каралы, кызыллы эре бизәкләр төшкән, ялтыравык тукымадан тегелгән чалбарлы костюм кигән килеш ул теләсә кемнең игътибарын җәлеп итәрлек иде: төз гәүдә, шоп-шома чиста йөз, артка җыеп, кысып бәйләгән дә ат койрыгыдай туздырып салган кап-кара чәч, горур, салмак хәрәкәтләр...

Кәримәгә бик озак вакыт үткән кебек тоелды. Сүзне башларга иде бит югыйсә, ә телгә бер сүз дә килми, тавыш чыкмый, авыз эче кибеп ябышкан.

— Мин — Хәсәнов хатыны, — диде ул ахырда. Тавышын үзе дә чак кына ишетә алды.

— Ә? Нәрсә дидегез?

Журналистканың тавышында сискәнү сизеп, Кәримә аңа күтәрелеп карады. Карачурина, авып кына китмәсәм ярар иде дигән кебек, стенага сөялде, ике куллап чигәләрен кысты.

Шул килеш шактый вакыт ишек катында эндәшешмичә торгач, Солтания, ишарәләп кенә, Кәримәне түргә чакырды. Эчкә үттеләр. Төньякка караган тәрәзәләр бүлмәне саран гына яктырта, ярымкараңгылык исә бүлмәгә серлелек салган. Кәримә, бер генә ноктаны да игътибардан читтә калдырмаска тырышып, ялт-йолт карана-карана түргә узды. Ул әле һаман экияттәгедәй серле бу өйнең бер почмагыннан Харрас та килеп чыгар дип көтә иде.

Солтания исә, киресенчә, залга узарга ашыкмады. Кәримәнең плащын эләргә азапланып, ишек катында калган иде, шунда шактый озак маташты. Кәримәгә шул гына кирәк тә, ул арада бүлмәне күзләп чыкты. Тәрәзә буенда төрледән-төрле гөлләр: эре яфраклысы, чәчәк атып утыручысы, үрмәлесе. Үрмә гөлләрнең берничә чүлмәге стенадагы тоткычларга утыртылган да ботак-тармаклары бүлмә буйлап уратып-уратып үстерелгән.

Тәрәзәсез якларның берсенә — диван, аңа каршы — зур телевизор, коңгырт төстәге пианино куелган, янда — зур сервант. Уртада — бәләкәй көпчәкле аякларга беркетелгән тәбәнәк өстәл, аның ике башында биек аркалы ике кәнәфи. Куш тәрәзәгә челтәрле һәм калын тукымадан тегелгән пәрдәләр эленгән.

Карачурина кая барып төртелергә белми басып торучы Кәримәгә креслоларның берсен күрсәтте, үзе аңа каршы килеп утырды. Шуннан соң гына:

— Кай арада өйләнешеп тә өлгердегез соң әле сез? — дип сорады.

«Ә-ә-ә, бу әле Харрасны өйләнмәгән дип өметләнеп йөргән икән!» Кәримә, журналистканың иң авырткан сөяленә басар җай чыкканына ләззәтләнеп, зәһәр елмайды, утырган җирендә боргаланып куйды.

— Безнең кызыбыз да бар инде!

Бу сүз Карачуринаны тәмам кисте. Шунда тукталса да, Кәримә канәгать иде, әмма тыелып кала алмады, өстәргә ашыкты.

— Харрасның миңа өйләнүенә икенче ел китте.

Карачуринаның күзләре шар булды.

— Нинди Харрас? Нинди Хәсәнов турында сөйлисез сез? Телегез ни әйткәнне колагыгыз ишетми шикелле.

Ул сикереп урыныннан торды. Иреннәре, кул бармаклары әкрен генә, өзлексез дерелди иде.

Кәримә, үзенең хаклы булуына һич икеләнмичә, башлаган сүзне

ахырынача житкерергә, капчыкны төбенәчә селкеп салырга карар кылды.

— Бик ишетәм. Археолог Харрас Хәсәнов турында сөйлим мин. Мина барысы да билгеле, яшереп маташудан файда юк: кичә генә сез аның белән кафеда утырдыгыз, төн буе...

Карачурина тирән сулап, яңадан креслога утырды.

— Уф-ф! Мин тагын әллә ниләр уйлап бетердем. Акылдан язам дип торам — минем иремнең дә фамилиясе Хәсәнов бит. Дөлфәт Хәсәнов. Үзем, юләр булып, кыз фамилиямне йөртәм, вакытында алыштырасы калган икән.

Кәримәнең иң зур шиге юкка чыкты, ире бар икән бит моның.

Солтаниянең йөзенә яңадан сөйкемлелек йөгерде. Ул Кәримәнең чәчләренә сокланып карады. Солтания гомере буе менә шундый аксыл сары чәчле, зәңгәр күзле кешеләргә кызыга. Тукта, тукта, мондый бер кызны ничектер белә иде ич! Хәтере ялгышмавына ышангач, ул:

— Кәримә бит син! — дип кычкырып җибәрде.

— Әйе шул.

— Бәй, аны ник башта ук шулай димисең? Ачу китерев: «Мин Хәсәнов хатыны!» — дигән булып торасың?!

Карачурина шаркылдап көлде, Кәримәнең генә хәле көлү-шаярулардан ерак иде. Ул үзен дошманы янына рәхим-шәфкать сорарга килгән бичара җан кебек хис итә.

— Мин синең янга Кәримә булганым өчен килмәдем, Солтания. Миңа ачыкларга кирәк... — Никадәр батыраеп, кашын-күзен җимереп, сабакташын өркетергә тырышса да, барып чыкмады, сүзен дә төгәлли алмады, өске иренең калтыравын тоеп, туктап калды. Аның шуннан артыгына түзәр чамасы юк иде, авызын җаеп еларга тотынды.

Солтания сүз бүленүдән файдаланып эш бүлмәсенә керде дә аннан авызына сары башлы озын сигарет кабып, пуф-пуф тәмәке төтене төтәттереп килеп чыкты. Чарасыз калган чакларында шунсыз котыла алмый ул. Бу гадәте аны күп дусларыннан аерды, мең дә бер гайбәткә сәбәп булды. Дөлфәте дә хатынының тәмәкече булуын теләми иде. Ул: «Минем янда чакта тартсаң да сүзем юк, — ди торган иде. — Башка ирләр күрмәсен. Синең хакта бер генә яман сүз дә ишетәсем килми!»

Дөлфәтне башка ирләр мыскыл итмәсен дип, Солтания соңгы вакытта тартмыйда башлаган иде инде. Бик эче пошса гына, редакциядән борчылып кайтса, ире аңа үзе үк сигарет тәкъдим итә: — Я, я, тынычлан, баш ярылып, күз чыкмаган, менә суырып җибәр әле!

Кичәге хәлдән соң Солтания үзе суыргалый башлады. Хәзер менә тагын ансыз булмый: каршында бәхетсезлеге йөзенә чыккан сабакташың утырып торганда ничек түзмәк кирәк?!

— Син алай бетерешмә әле, Кәримә. Беренчедән, елап кына Харрасны үз принципларыннан кире чигендереп булмаячак. Аннары-ы...— Карачурина, башын чөеп, төтенен еракка өрде. Бу кыяфәт аңа искиткеч килешә, аны дөнья ваклыкларыннан арындырып, илаһи биеклеккә күтәрә иде. — Аннары, минемчә, монда, гомумән еларлык нәрсә юк.

Кәримә бер генә мизгелгә үз хәсрәтен онытып, журналисткага сокланып карады. Карады да аның бөтен торышын күңеленә үз итеп, якын итеп тойды. Сүзләре дә җанны ашамый, кимсетми, ярсытмый. Бар бит дөньяда кешеләр: аларның күңел сафлыгы тирә-юньдәге ваклыкларны күмеп калдыра, холыкларындагы турылык үрчи алмый интеккән гайбәтләрнең тамырын корыта, эшлеклелекләре аларны өнәп бетермәгән кешеләрнең дә тануына, бил бөгеп баш иеп сәламләвенә китерә.

Кешеләр мөнәсәбәтен саф итеп тою мизгеле тиз үтте, Кәримә тагын үз кысасына керде. Солтаниянең бер нәрсәдән дә шикләнмичә, Харрасны олылап, үз күреп сөйләве саруны кайната башлады. Ул үзенең төп

йомышын, иң мөһим соравын селкеп салырга булды. Кунакка да, сөйләшеп утырырга да килмәгән ич ул монда!

— Харрас белән ике арагыз ничек соң сезнең? — Бу сорауны Кәримә алдан ук әзерләп килгән иде. Тик үзе үк аның ни кадәр мәгънәсез икәнен дә белә. Солтания авызыңа суккандай итеп: «Ник аны иреңнән генә сорамадың?» дисә... Моңа юл калдырмас өчен, Кәримә өстәп тә куйды. — Мин моны белергә тиеш, бигрәк тә синең мөнәсәбәт кызыксындыра.

Карачурина шактый озак эндәшми торды. Аңарда ике фикер көрәшә кебек иде: бу хатынга туры җавап бирергәме, әллә майлап-җайлап кына чыгарып җибәрергәме? Журналистканың йөзеннән елмаю чалымнары да йөгергәләп үткән кебек булды, ахырда ул җитдиләнеп калды.

— Син үзең дә беләсең инде, — диде ул. — Безнең газетаны караштыргалый торгансыңдыр: элегрәк мине Харрас Хәсәнов бөтенләй кызыксындырмый иде. Быел ул... — Солтания тәмәке төпчеген тәбәнәк өстәл уртасында чәчәктәй балкып торган аллы-гөлле калын пыяладан коелган көл савытына басты. — Быел, дөресен генә әйткәндә, тәмам гашыйк итте!

Кәримәнең йөрәге туктады, яшәү беткән кебек тоелды, күңеленнән: «Абау, яшереп тә тормый йөзе кара!» — дигән уй үтте. Бетте, җимерелде, убылды Кәримәнең дөньясы.

Карачурина сабыр гына торып китте, әрле-бирле йөренгәләп, башлаган сүзен аңлатырга тотынды.

— Безнең көннәрдә сирәк була торган хәл — положениесы ягыннан баштан-аяк аңа буйсынган гап-гади хезмәткәр профессорга каршы өр-яңа тезислар белән чыга. Мин ул бүлекне күптән өйрәнәм, бөтен кешеләрен беләм, Харрас кебек берәү дә юк.

— Менә кызык!.. — Кәримә, кабынып китеп, Солтаниягә каршы чыкмакчы иде, тик шул ике сүзен генә әйтеп өлгерде. «Бер генә булгач, аңа барып ябышырга дигәнмени?» кебек дәгъваларын әйтеп бетерә алмады.

Карачурина, Кәримәнең сүз кыстыруын хуплауга санап:

— Кызык шул менә! — дип, дәвам итте. — Ә журналистларга мондый материал еш очрамый. Мин ел саен, җәйге эшләре беткәч, тотам да Хэй Фәләхине мактыйм, аңардан бөтен бүлеккә кагылышлы мәсьәләләрне сөйләтәм, баксаң... — Солтания нечкә озын имән бармагын тырпайтып куйды, — ул барын да үзенә кирәккәнчә генә яктырта, ә институтта гайрәтле яшь галим үсеп җиткән!

Кәримә, авызын ачып, Солтаниянең мәкалә язу өчен ничек әзләнүләрен, ни кадәр материал җыюын тыңлады. Сүз тиз арада Харраслар институтыннан читкә кереп китте, журналистиканың гомуми проблемаларына кагылып үтте. Бу хезмәтнең четерекле һәм кызыклы яклары күп икән. Карачурина шулар хакында сөйләде-сөйләде дә:

— Әгәр менә бу мәкаләдә Хэй Фәләхи белән Харрасны конфликтка китереп чыгарган мәсьәләне ачыклый алсам, үлсәм дә үкенмәс идем! — диде. — Хәер, мин бик күп мәкаләләрне шулай яздым инде, ә үләсе килми.

Солтания хәзер бер Кәримә өчен генә дә сөйләми, сүзе саен үзенә тәвәккәллек җыя, алда очраячак кыенлыкларны җиңәргә көч туплый сыман. Аңлыймы аны Кәримә, юкмы — бусы Карачурина өчен барыбер кебек. Хәер, юк, алай түгел икән.

— Бәй, Кәримә, зәңгәр күзем, син бит миңа бик кирәк кеше! — диде ул кинәт. — Мин синең ярдәмеңә мохтаҗ!

— Ничек? Нинди?

— Беләсеңме, синең Харрасны сөйләштерүе бик кыен, миңа мең дә бер нәрсәне ачыкларга кирәк әле. Кичә төн уртасына хәтле кафеда утырдык, теләгәнемнең яртысын да әйттерә алмадым. Син бит ике ел

рәттән аның экспедициясенә катнашкан, Харрас сөйләде, хәтта алтынлы хәзинә дә тапкансың. Сөйлә әле, зинһар!

Мәҗбүр итеп монда китергән төп мәсьәләнең торган саен арткы планга чигенә баруы Кәримәне сөендерә иде һәм ул, сөйләгәннәренең кемгә ни бирәсен уйлап та карамастан, акрын-акрын әңгәмәгә тартылды.

Урамга чыккач кына уйга талды, бик беләсе килә иде Кәримәнең: Карачурина аның ник килгәнен сиздеме, әллә аңлап өлгермәдеме? Юк бугай, белмәде шикелле. Ул үз һөнәре белән тәмам саташыр дәрәҗәгә җитеп мавыккан, аңарга йөгәнсез көнчелек кебек кешене түбәнсетә торган хисләр бөтенләй яттыр, мөгаен.

Аһ, сизмичә генә калган булса иде Солтания, сизде шул, ничек кенә сизде әле. Әмма тиз арада үзен кулга алды. Кеше булган кешедә ишеткән-сизгәннәренең кайберенә игътибар итми калырлык көч табыла, чөнки арада кешене мыскыллый торганнары да очрый. Нигә исән башка тимер таяк алырга, нигә ямьсезлекне булдырмый калу чарасын эзләмәскә? Солтаниянең фәлсәфәсе әнә шундый иде һәм ул, Кәримәнең утлы карашында меңләгән-миллионлаган дошман чаткылар күрсә дә, үткәреп җибәрде, күрмәмешкә салынды, сүзне үзенә кирәк якка бора алды.

Сүз арасында тиз генә табын да тезде әле ул. Җәһәт кенә кузгалып сервантның бер бүлеген ачты, өстәлгә эре кызыл алмалар өелгән зур ваза, кофе чынаяклары, уймак кадәре генә хрусталь рюмкалар куйды, йомры корсаклы коньяк шешәсе чыгарып утыртты.

Солтания Дөлфәтнең дуслары килешкә һәрчак табын әзерләрлек запас тота иде. Шешәләре дә була, ризыгы да өзелми. Суыткычында салкын ит, колбаса, сыр кебек нәрсәләр бар.

Үзе янына килеп-китеп йөрүче юк Солтаниянең. Әллә тәмәкесе хакында, әллә эшли торган урынын өнәмичә, дуслар читләшеп беттеләр. Бердәнбер иптәш кызы, сиздем бит, мине яманлап язгансың, исемне генә үзгәрткәнсең дип үпкәләп, ташлап китте.

Бераздан ул кухня ягыннан биек кызыл чәйнек күтәреп чыкты, чынаякларга дегеттәй куе кофе агызды, коньяклы бер рюмка белән бер чынаякны Кәримә каршына этәрде. Ул, күрәсең, кыстарга да, кыстатырга да өйрәнмәгән, сабакташына: «Эч!» — дип тә әйтмәде. Рюмкасын алды да, баш белән генә ым кагып, беразын йотып та җибәрде.

Археологиянең яңа каршылыкларына багышланган мәкаләсе турында сөйләп туктагач, Солтания Кәримә күңелендәге газаплану хикмәтен дә тойды. Көнчелектән нишләргә белми монда килеп кергән хатын хәзер үзен-үзе битәрләп, гарьләнеп утыра иде.

Сабакташы Карачуринаның үз-үзен тотышы да, эрудициясе дә, барыннан да бигрәк, киң колач белән фикер йөртеп сөйләшүләре Кәримәнең уйларын бөтенләй башка якка борып салды. Нигә соң Кәримә иренең чалбар балагына тотынып йөрүдән ары китәлми, ә Солтания әллә нинди фәлсәфи әңгәмәләр корып утыра ала? Аның сүзләре һич туйдырмый, ул җиһазлаган бүлмә үзе үк җанга сихәт бирә, кайнаткан кофесына кадәр Кәримәнекенә караганда хуш ислерәк. Бергә укып йөрделәр бит югыйсә, дипломнары бер үк. Үз калебендә булмаса, икегә бөкләнгән катыргыдан гыйбарәт диплом гына ярдәм итә алмый икән.

Карачурина Кәримәне үкенүле уйлардан коткарырга да җай тапты.

— Кстати, син Харрасны шулай юллап йөреп, дөрес эшлисеңдер, мөгаен, — диде. — Кем белә бит: бәлки, гаиләңне саклап калу өчен, нәкъ шулай булу кирәктер. — Ул кулларын як-якка җәеп җибәрде. — Менә минем кулдан, үтерсәләр дә, килми монысы. — Җанын телеп, «Дөлфәтнең тавышын телефоннан гына булса да бер ишетер идем! Шалтыратырга кул бармый, әллә инде горурлык җибәрмиме?..» диган

үй үтте. Фикеренең йомгагын кычкырып әйтте.— Ирләр алар артык горурларны яратмыйлардыр, Маркс булып Маркс та хатыннардагы юашлыкны хуплаган бит...

Нәтиҗә нәкъ көтелгәнчә килеп чыкты. Кәримәнең дә кимсенүе тирәнгә китмәде, Солтания дә әллә нинди бөһтан яла сүзләр тыңлап утырудан котылды. Җәнҗалны булдырмый калуга киткән нервларны кем, кайчан, ничек исәпләп бетерсен?! Карачурина үзе дә бүген ул хакта озын-озак уйланып утырмады.

Кайгы кайгыга охшамый, кайгы савыты бушамый, дигәндәй, Кәримәнең көнчелеге Карачурина өстенә ябырылган кара кайгы алдында бик кечкенә дәгъва иде.

Кәримә хаклы, кичә Солтания өенә кайтып җиткәндә, чыннан да, төн уртасы якынлашкан иде. Соңгарса да, җанын шатлык биләгән, Харрастан шактый мул материал сыкты. Ахырдан археолог аны озата килде, тик Карачурина аңа троллейбустан төшеп тормаска киңәш бирде.

— Безнең өй тукталыштан бер адымда гына, — диде. — Төшеп тормагыз, бу машина, әйләнеп, кабат сезнең якка китә, хушыгыз!

Болдырда утлар сүнгән, лифт тукталган. Ундүртенче катка җәяү менәргә туры килә, дип тә ачуы чыкмады Карачуринаның. Тере тиен тоткан кебек, баскычлардан очып кына узды. «Дөлфәт кенә үпкәләмәгән булсын! — дип теләде ул. — Аны шиккә салмас өчен, «шампанский»ны да йотмадым, бокалдагы шоколад валчыклары дельфиннар кебек сикергәләшеп кызыктырып калдылар»...

Өскә күтәрелгән саен караңгылана, урам лампочкаларының нуры кими бара иде. Ишек төпләренә килеп җиткәч, Солтания шикләнә калды, күзгә төртсәң, күренмәслек караңгы бушлыкта әллә нинди җен-пәриләр поскан кебек. Ул кулын кыңгырау төймәсенә сузган иде, кагылмыйча кире алды. «Дөл-дөл йоклагандыр. Ул бит уннан да соңга калмый ята, уятмыйм». Дөлфәтен ул, яратып, борынгы риваятьләрдәге илаһи җанвар исеме белән атап йөртә.

Ишекне ачар өчен, һәрвакыттагыча, сумканың әллә кай җәһәннәменә кереп кысылган ачкычлар бәйләмен табарга кирәк. Сумкадагы бөтен вак-төякне капшап чыгарга туры килде.

Ниһаять, Солтания — үз өендә. Плащын ишек төбендәге элгечкә элеп, кухняга узды. Гаҗәпкә каршы, монда бүген Солтаниягә бер эш тә калдырылмаган. Гадәттә, Дөлфәт бер кашык ризык ашаса, бер өем савыт-саба буяп бетерә иде. Бүген, рәхмәт төшкере, өстәлен сөртеп, тәлинкә-чынаякларын юып, бүлмәне җыештырып калдырган, хәерлегә булсын!

Юыну бүлмәсендә дә озак тоткарланмады Солтания, талымса су белән аяк-кулларын юды да эше бетте.

«Хәзер йокы күлмәген генә киеп алам да Дөлфәт янына чумам. Мәкаләне иртәгә язармын. Дөлфәт уянса, Хәйбулла Фәлляховның ничек итеп Хәй Фәләхигә әйләнүен, биюче Шай Заһриның чын исемен әйтеп көлдерәм әле!

> ...Бие, бие, Заһрулла!
> Биегән кеше бай була.
> Биегән кеше бай булганчы
> Карт алаша тай була!..

Солтания үз уйларына бирелеп елмаеп куйды. Кече яктагы утларны сүндергәч, ул тагын шомлы караңгылык эчендә калды. Зал аша йокы бүлмәсенә кергәндә, тезен кәнәфи култыксасына бәрде, кычкырып җибәрә язды, тыелды. Дөлфәтнең, уяныл китеп, йокысы бүленмәсен!

Йокы бүлмәсенең ишегеннән салкынча һава бөркелгән кебек иде. Солтания ишек төбендә килеш иренең йоклавын тыңлап алырга теләде.

Бер мизгелдә үк тойды — бүлмәдә җан әсәре юк иде. Солтания ашыгып утны кабызды. Өйнең җаны шикелле иң алдан күзгә ташланучан китап киштәләре шыпшыр калган. Дөлфәтнең китаплары юк! Кем алган аларны?

Хатын атылып залга чыкты, әллә ничә лампочкалы люстраны кабызды. Өстәлнең кыл уртасында кош теле кадәр генә кәгазь кисәге күреп, Солтания кымшанырга кыймый торды. Язудагы сүзләргә ышану һичничек мөмкин түгел иде. «Моннан да артыгына мин чыдый алмыйм. Китәм, бөтенләйгә».

Нигә? Кайда? Кайда кунар соң ул?.. Берьюлы җанга ябырылган мең сорауның сыңарына да җавап таба алмагач, Солтания йөгереп баскыч мәйданына чыкты, күзе төшкән беренче кыңгырау төймәсенә басты. Бик озак утте ул минутлар. Кайсыныңдыр аягы чыштырдый башлаганга гына да мең былтыр бит инде. Үзләре кая китеп олакканнар соң бу адәмнәр? Калтыравык бармаклар төймәгә яңадан ябышып ишек ачылганчыга кадәр, кыңгырау тоташ яңгырап торды.

Ишектә күренгән юан карчык бу тупаслыктан телсез калган кебек тоелды. Солтаниянең исә карчык йокысы бүленүдә дә, кыңгырау чыңгылдавыннан тәмам каушап төшүендә дә гаме юк. Ул, кулын әле һаман югарыда тоткан килеш:

— Хәерле кич, Ида Товьевна! — диде.

— Нинди кич булсын, ди, таң атып килә бит инде!

Бу усал җавап та Солтаниягә тәэсир итмәде, ул үз кирәген сорамый булдыра алмый иде.

— Дөлфәт кая китте икән, белмисезме?

Солтания күршесенең, әле сорауны ишетмәс борын ук, зур сер белгәнен сизеп өлгерде. Карчыкның күзләре тантана итә, нәкъ менә мин кисәткәнчә барып чыктымы инде дигәндәй, явыз елмаялар, шул ук вакытта, әйтергәме-юкмы дигән кебек, сынап та карыйлар иде. Тагын аз гына дәшми азапланса, Солтания аны элеп алып җилтерәтергә дә әзер инде. Карчык, башын үз бүлмәсе ягына борып:

— Белмим, — диде. — Каян белим мин кеше иреңең кайларда йөрүен?..

Ида Товьевна ишеген ябарга да өлгермәде, Солтания бүтән күршеләрнең кыңгырау төймәсенә кулын сузды.

— Ни йөзең белән син арып эштән кайткан кешеләрнең йокысын бүлдереп йөрисең? — диде икенче карчык. — Чылтыратма! Ирең болай да күпкә түзде. Ир хатыны таң алдыннан кайтып, теләсә кай вакытта китеп йөрми ул, хода бәндәсе!..

Бу ишек йозагы да шартлап бикләнде. Солтания караңгылыктан, буш тынлыктан куркып, исерек кешедәй алпан-тилпән килеп үз өйләренә керде.

Ида Товьевна: «... күпкә түзде», — ди. Бу тормыш бары Дөлфәтнең чыдавына гына нигезләнгән иде микәнни?

Тып-тын. Башка төннәрдә, язарга утырсаң, фикереңне чуалтып, аста пианино дыңгырдаталар иде. Ник, ичмасам, бүген дә берәр хыялые музыка яңгыратмый икән? Мәҗлес җыючысы да, эчеп исерүчесе дә булмаган, күрәсең, кычкырышучысы да, елаучысы да юк. Утыз беренче квартирада әле ае да тулмаган яшь бала бар. Шул гына да көйсезләнми, ходаның рәхмәте!

Йокы бүлмәсенә аяк та басасы килми, буш киштәләр җан сораган кебек. Солтания хәлсезләнеп залдагы креслога ауды, башын артка ташлап, авызын ачып, күзләрен түшәмгә текәде. Бөтен әгъзаларны, сулу алырга да ирек калдырмыйча, таштай каты баскан. Чигәдәге кан тамырының гына сәгать кебек тавышы ишетелерлек каты-каты бәреп торуы сизелә.

«Археологның аракысын эчәсе калган икән», — дигән үкенечле уй

үтте Солтания башыннан. Эчкән баштан теләсә нинди кичерешнең җиңелрәк узуын ишетеп белә ул. Тирәннән уйлап ватылырга теләмәгән кеше юк кайгысын бар итеп тә аракы эчәргә өйрәнеп бетә.

Кайчак Дөлфәт тә, эштән кайтышлый, култык астына берәр шешә кыстырып керә. Өйдә чагы булса, Солтания иренең яраткан ризыкларын пешерә, табын тезә. Аннары, түр өстәлгә чыгып, кара-каршы утыралар. Хатын аш-су белән сыйларга тотына, ире иң матур рюмкаларга шәраб тутыра.

— Синең бәхетең шәрәфенә!

Солтания, урыныннан кузгалып, тагын кухняга керде, суыткычны ачты. Анда көтелмәгән кунаклар өчен саклана торган йөзем шәрабының торна муены кебек шешәсе кукыраеп утыра. Ул, гаҗәпләнеп, аның ачылган булуына, шәрабның шактые эчелгәнлегенә игътибар итте. Күңелен кытыклап: «Ул да борчылган, икеләнгән, эчми чыгып китә алмаган!» — дигән уй узды.

Капылт эчелгән бер касә шәраб уйларны тагын да куертыбрак җибәрде.

Дөлфәт соңгы вакытта котырынып, үз-үзен белештермичә көнләшә башлады. Солтания бу шикләрнең кайдан башланып китүен дә хәтерли.

Алар ялларын һәрвакыт бергә алалар иде. Дөлфәт елның-елында: «Мин синең белән генә рәхәтләнеп ял итә алам, матурым, — ди торган иде. — Миңа синең белән бергә урам үтү дә, кино-театрларга йөрү дә, кара-каршы утырып чәй эчү дә рәхәт...»

Үткән ел Дөлфәт үзләренең завкомыннан Казанга якын гына бер ял йортына путевкалар юнәткән. Ул көнгә Солтаниянең ялы билгеле түгел иде әле.

— Мин эшне түгәрәкләп кайттым, иртәгә иртүк ял йортына китәм, икебезгә аерым бер бүлмә билгеләтеп куям, — диде ул. — Ә син иртүк китеп, ял сорап гариза язып бир. Мин сине әзер урында каршылармын!

Ул җәйдә редакциянең кадрларга сусаган чоры иде. Тәҗрибәле ике журналист берьюлы пенсиягә чыкты, җаваплы секретарьны Мәскәү курсына җибәрделәр. Шул сәбәпле Солтаниягә үзе теләгән көнне генә ялга китәргә мөмкинлек тимәде. Редактор аңа таксига түләрлек талоннар сузды:

— Машина белән генә барып, хәлне аңлатып кайт, кызым, — диде. — Ирең ачуланмасын, сине җибәрә алмыйм.

Солтания каршы әйтмәде. Оялмыйча, ирем белән бергә ял итәсем килә дип, йөз меңнән артык тиражда чыга торган газетаны чарасыз калдыра алмый иде ул.

Кояшлы җәйге көн. Карачурина, кара чия төсендәге машинага утырып, ял йортына китте. Капка төбеннән үк — аллея. Солтания, кабинадан төшеп, бер-ике генә атларга өлгерде, каршысына Дөлфәт килеп басты. Ул:

— Көтә-көтә көт булдым бит инде! — диде дә, күбәләктәй хатынын кулларына күтәреп, куакларга күмелгән кеп-кечкенә йортка таба китте.

— Төшер, Дөл-дөлем, кешедән яхшы түгел!

— Кешедә ни эшем бар минем? Син — минем хатыным, көтеп алдым, сагындым, бер түзәр чамам да калмады!

Тәрәзәләрен үрмә гөлләр каплаган кечкенә агач өйдә серле караңгылык.

— Бигрәк матур, бигрәк рәхәт! — диде Солтания.

— Ай буе син шул матурлыкның падишасы булып яшәрсең!

— И-и, Дөл-дөлем, тәтемәс шул бу рәхәтләр, отпуск бирмәделәр миңа. Иртәгә үк командировкага чыгып китәм.

— Ничек?

— Әнә капка төбендә машинам көтеп тора.

Сүнде Дөлфәт. Күтәрелеп карамас булды. Хәтта капкага кадәр озата да бармады.

Бу елның ял айларында алар бер генә көн дә очраша алмадылар.

Кыш кергәч, Дөлфәтнең көнләшүен куәтләрдәй тагын бер күңелсезлек булды. Солтания чираттагы командировкасыннан бер көнгә соңга калып кайтты. Автобус ярты юлда ватылды да шәһәрдән кырык-илле чакрымдагы авылда куна калды ул. Дөлфәт, бик борчылган, хатыны йөргән район үзәгенә шалтыраткан.

— Без аны бүген озатып җибәрдек, — дигәннәр.

Аннары автовокзалдан да белешмә алган, андагы кыз да:

— Безнең бөтен машиналар кайтып бетте, — дип җавап биргән, тик автобусның ватылуын, пассажирларның юлда төшерелүен искәртеп тормаган. Күңелен шик корты кимерә башлаган иргә шул җитеп ашкан.

Бу аңлашылмаучылыктан соң Солтания белән Дөлфәт арасында бернинди көч белән дә кушылмастай ермак хасил булды. Хатын баштарак иренең һич урынсызга кызып-кызып көнләшүенә сөенә дә иде әле. Кайбер хатыннарның ирләре сөяркәләр тотып, читтә кунарларга калгалап, гаиләләрен бимазалавы хакында ишетсә, Дөлфәтенең әле яңа өйләнешкәндәге кебек Солтаниясез бер генә көн дә яши алмавына, мөнәсәбәтләренең һаман гашыйкларныкы шикелле саклануына мең шатлана иде.

Тора-бара Дөлфәт Солтаниянең җыелышларга, тантаналы кичәләргә йөрүен дә күпсенә башлады. Ә һөнәре журналистика булган кеше, иремә ошамый дип, андый нәрсәләрдән баш тарта аламыни соң? Юк, әлбәттә. Солтания дә мондый чикләүләрне кабул итә алмады. Дөлфәтнең һич нигезсез шикләрен искә-санга сугарга Карачуринаның теләге дә, вакыты да, мөмкинлеге дә юк иде. Әмма ләкин шул көнче ирен — гомерлегем дип, мең — миллион кешеләр арасыннан үзе табып алып, гашыйк булып, никахланган хәлалең — ихлас күңелдән, ни бар кайнарлыгы белән яратудан бер генә мизгелгә дә тукталганы юк иде аның. Солтания үзе генә түгел, Дөлфәт тә тугры, дип ышанып яшәде. Акыл белән, әллә нинди анализлар ясаудан чыгарып түгел, хисләреннән тоеп, күзләреннән күреп белә иде ул: Дөлфәт тә аны яратты. Улы белән килененең тормышын күрергә килгәч, кайнана да бу мөнәсәбәткә соклanып хәйран булган иде.

Карчык килгән көнне Солтания төне буе мәкалә язып утырды. Кичтән озак эшләү аңа кыен түгел, иртән генә уяна алмый интегә. Дөлфәт, киресенчә, кичтән озак утыра алмый, ята да йоклый, аннары, хатыныннан алда уянып, өй эшләрен караштыргалый. Гаиләдәге бу тәртип, кайнана килде дип кенә үзгәрмәде, әлбәттә. Солтания сәгать җидегә кадәрле изрәп йоклады. Дөлфәт чәй әзерләп йөрде. Карчык улы алдында бу хәлгә бик сөенгән булып күренергә тырышты.

— Бә-әк әйбәт итәсең, улым, — дигән булды. — Хатын ул — мамык мендәр кебек: кадерен белеп, күперткәләп тотсаң гына озакка чыдый.

Китәр алдыннан, Солтанияне аулакка алып кереп, күңелендәгене ачып салды карчык:

— Ачулана күрмә, килен, — диде. — Күңелем кабул итмәгәнне әйтми китә алмыйм. Син бит минем инҗинир улымнан безнең күрше авылның Иван карты ясагансың!

— Кем соң ул, әнкәй?

— Улмы? Бичара бер җан инде шунда. Иртә торып битен юа да икән, мич башында пыф-пыф йоклап яткан җәмәгатеннән әкрен генә сорый: «Баба, нам щепки надо?» — ди икән. Тегесе киерелә-сузыла җавап бирә: «Надо, Ваня, надо!» Карт калушын лыштырдатып, йомычка ташый, тегесе яңадан йоклап китә, ди. Бабай, бичара, аптырый. Бераз-

дан тагын сорарга итә: «Баба, нам, наверно воды надо, а-а?» — ди. «Надо, Ваня, надо», — ди тегесе. Шулай итеп Иван бөтен эшне үзе эшли: суын да алып керә, самаварын да кайната...

Сүзләре шул турыга җиткәч, Солтания хикмәтне аңлап та алган иде инде, тик карчык барыбер үзе йомгаклап бирде.

— Безнең татарда андый гадәт юк. Ирне ир итә белергә кирәк. Ата-баба йоласын бозып, инжинир улымнан самавыр куйдыртып торсаң, һич риза-бәхил түгелмен! — диде.

Ананың бер дә юкка шулай борчылуыннан Солтания белән Дөлфәт икәү генә рәхәтләнеп көлгәннәр иде. Соңра Иван карт турындагы мәзәкне башка танышларына да сөйли-сөйли көлделәр. Солтаниясенә булыша башласа, Дөлфәт алдан: «Баба, вам щепки надо?» — дигән булып кылана иде...

Аһ, Дөл-дөл, Дөл-дөл! Нинди генә коткыга бирелгән дә кай тарафларга гына китеп барган соң ул? Хәзер кайда? Кем белән? Нишли?

Язмышының аянычлыгын яңа аңлагандай, Солтания кухня өстәленә капланды да үкереп еларга тотынды.

Үз ягында, Солтания квартирасыннан килгән һәр авазга колак салып, бик озак көтеп торган Ида Товьевна, сулкылдау тавышын ишеткәч, җиңел сулап куйды: «Слава богу! Хәзер аңа җиңелрәк булачак. Кайгы-хәсрәт, тәкә түгел, арттан килеп бәреп екмый, эчеңә кереп кимерә ул. Аңардан котылу өчен хатыннарның бер генә чарасы бар, елап күңел бушаталар...»

*

* *

Иртән Солтания ашыгып редакциягә китте. Иң элек үзе утыра торган бүлмәгә кереп, язу өстәленең калын пыяласы астында, Дөлфәтнең гел Солтаниягә карап торучы портретын алып тартмага яшерде. Редакторга кайгысын сөйләп бирде, бу хәлендә бер генә юл да яза алмаячагын аңлатты. Аны өенә кайтарып җибәрделәр.

Өйдәге ялгызлык тагын да яманрак икән. Солтания түземсезләнеп ишек кыңгыравының чыңлавын, янына кемнең дә булса килүен көтте. Хәер, юк, башка берәү дә кирәкми иде аңа. Дөлфәтне көтте ул. Ичмасам, кешеләрчә саубуллашып китсен иде! Язу кисәге генә калдырып бигрәк кимсеткән ләбаса! Әллә күзгә-күз торганда аерылырга көч житмәс дип белгәнме?

Ниһаять, кыңгырау аваз салды. Солтания, йөгереп барып, ишеккә капланды, әмма килгән кеше көткәне түгел, кысыр хәсрәт юллап йөрүче әлеге сытык Кәримә булып чыкты...

*

* *

Үзен-үзе юл буе битәрләсә дә, Харрасы өчен Кәримә тынычланган иде инде, тик ишек төпләрендәге эскәмиядә Әскәр утыруын күреп тагын шомлана калды. «Шейх» аны, төче елмаеп, урыныннан торып каршылады.

— Кайларда гына йөрисез сез, понимаешь,— диде.— Көтә-көтә азапланып беттем. Ниятем яхшылыкта иде, «старик»ның башы авыртмый микән, мәйтәм, эчеп өйрәнгән кеше түгел, мине тиргәп ятмасын, барып, дәвалап кайтыйм үзен, дим.

Башыңа төшсә, өтек каз яныннан да: «Әссәламегаләйкем, ата каз!— дип исәнләшеп үтәрсең дигәннәр. Җанын талкыган сораулар белән ялгыз утырганчы, шул Әскәрнең такылдавын тыңлау да яхшырак. Кәримә хәтта сөенеп тә куйды. Сер бирүе кыен булса да:

— Харрасның кайда йөрүен үзем дә белмим,— диде.

Бергә-бергә баскыч буйлап күтәрелделәр. Ишеккә кадакланган әр-жәдә хат күренеп тора иде. Кәримә Әскәрдән хатны алуын үтенде. Адреска Акъяр авылы язылганлыктан, сүз үзеннән-үзе ялганып китте. Иң элек Әскәр Кәримәне борчып йөдәткән мәсьәләне ачыклап үтте:

— Иртән күрдем мин, Харрас «шеф» янына керде, — диде.

— Дөрес эшләгән, әллә кайчан шулай итәсе бар иде, очына чыкмыйча ярамый.

— Очына чыга алмаганнар шул. «Шеф» бит ул сиңа, Кәримә ханым, телевизор түгел: бер боргычына кагылып кына җырдан биюгә күчерә алмыйсың аны.

Шактый куертып, катлауландырып маташса да, Әскәр сүзләрендә хаклык бар иде. Харрас Хәсәнов белән ике арада туган низагълар Хәй Фәләхинең үзен дә пошаманга төшерде. Кичтән ул тагын бер хат алды, археологларның Бакуда үткәреләчәк Союзкүләм киңәшмәсендә чыгыш ясаучы кешенең тезисларын сораганнар. Казан археологларыннан Идел Болгариясе турында яңа мәгълүматлар көтүләрен дә әйткәннәр. Чыгышның тезислары бер атна эчендә әзер булырга тиеш. Бу хезмәтне кемгә йөкләргә? Профессор яңа ел кичәсендә бүлекнең кайсыдыр бер наяны уйлап чыгарган такмакны исенә төшерде:

«...Елгаларда бетте налимнар,
Дөньяларга тулды галимнәр!»..

Сан ягын караганда, чыннан да, галимнәр буа буарлык, ә җитди йомыш кушарлык кеше таба алмый интегәсең. Харрасны бик җибәрер идең, бәхәсле мәсьәләне куертып кайтуы бар. Иплэп кенә сөйләшү барып чыкмады. Ичмасам диссертация яклаганчы дип кенә дә сабыр итми. Ачышларының бәясен белеп алды да киреләнепме киреләнә.

Аптырагач, профессор Әскәр белән киңәшеп карарга булды. Бу хезмәткәрнең ичмасам тыңлаучанлыгы әйбәт. Кулдан килмәс дип тә тормый, ни әйтсәң, шуны үтәргә ашкына. Башкарганы да — ташка үлчим, нишләмәк кирәк?!

Кабинет ишеген шакуыннан ук профессор «Шейх»ны таныды.

— Уз әле, Әскәр, утыр! Синнән башка киңәшер кешем юк.

Әскәр кеткелдәп көләргә тотынды. Бер башласа, ул тиз генә туктала белми. Хәй Фәләхи ирләрнең шул кадәр бөгелә-сыгыла көлүен һич кабул итә алмый. Мәгънәсез бер кеткелдәү тукталганчы, профессор башын аска иеп, кашларын җыерып, көтеп утырды. Икесе дә тәмам җитдиләнгәч кенә, ул Баку киңәшмәсе хакында сөйләп бирде. Бөтенсоюз археологлары алдында чыгыш ясарга кандидатура сайлау мәсьәләсенә тукталгач, Әскәр урынында утыра алмас булды.

— Хәй Хәерович! — Ул бер утырды, бер торып басты. — Минемчә, бу югары дәрәҗәле киңәшмәгә бары тик сез генә барырга лаеклы!

— Сез бер нәрсәне онытасыз,— Хәй Фәләхи, бурычның ифрат җитдилеген аңлатыр өчен, «сез»гә көчте. — Доклад Болгар чорын яктыртырга тиеш. Минем эзләнүләр башка, яшьлек мавыгуларын гына санамаганда...

— Казан археологларының төләсә кайсы ачышы — сезнеке ул, Хәй Хәерович!

— Туктагыз әле, мин әйтеп бетермәдем: Болгар чоры турындагы иң кыйммәтле мәгълүматлар — Хәсәновта. Ул җитәкләгән экспедиция дистәләрчә шәһәрлекләр ачты, кечкенә урынлыклар, каберстаннар, истәлекләр — бихисап, кулында — картасы. Тик...

Әңгәмә иң четрекле җиренә килеп терәлде. Профессорның алдан өметләнгән чамасы акланды, сыгылучан холыклы галим, аның хәлен сизеп алып, сүзне үзе элеп алып китте.

— Аңлашыла, Хәй Хәерович. Соңгы уңышлардан Харрасның башы әйләнде, беразга ярдәм итәргә, төшендерергә кирәк булыр үзенә.

Хәй Фәләхинең нияте барып чыкты, алар бер-берсен ахырынача аңладылар. Әскәр «шеф»тан алган йөкләмәсен үтәү өчен Хәсәновларның өенә китте. Харрасының өйдә булмавын яхшыга юрады ул, алдан хатын белән сүз беркетеп куйсаң, максатка җиңелрәк ирешеләчәк.

— Уйлап кына кара, Кәримә ханым, профессор белән кычкырышу нәрсә бирә аңа? Болгарлар Азовта яшәгәнме, юкмы, монгол вакытында мөстәкыйль булганмы, түгелме — шулмы мәсьәлә? Харрас кулында алардан башка да өч диссертациялек материал бар. Тапкан шәһәрлекләрен тәртипкә салып кына бирсә дә, аңа менә моннан җиткән! — Әскәр муенына сызып күрсәтте.

— Ни әйттең иде дә бит... — Кәримә фикерен очларга өлгерә алмый калды, Харрас кайтып керде.

Ул, Әскәр белән кул биреп исәнләшкәннән соң, өстәлдә яткан хатны ачты. Болай да йөзенә карарга куркыныч дәрәҗәдә кәефсез Харрас тагын да караңгылана төште, күрәсең, хат язган кеше дә берәр күңелсез хәбәр җибәргән.

Көн кичкә авышкан иде инде. Бүлмәләргә шомлы караңгылык эленгән. Харрас ут кабызырга кузгалган арада, Әскәр кесәсеннән чыгарып, өстәлгә шешә куеп өлгерде.

— Мин, «старик», иртәдән бирле сине эзлим, бергәләп баш төзәтербез дигән идем.— Ул кеткелдәргә тотынды.

Күңелсез хаттан тәмам куырылып калган Харрасның үтенә барып кадалды бу кеткелдәү. Хатның соңгы юллары аңа әле һаман акылын җыеп алырга ирек бирми: «...Таңкәле тау чишмәсен күмделәр, калкулыкны да тигезләмәкчеләр, ди. Чишмә тирәсен казыганда тракторист бер казан тапкан, эчендә — беләзекләр, йөзекләр бар, ди. Сезгә җибәрермен дип, барып сораган идем: «Давай, бер яртылык суз!» ди. Тотсын менә! Сәмикъ Әхәтенә дигән акчалар — чабата кесәсендә...»

Әскәр, көлүеннән тукталмас борын, акыл сата башлады.

— Чуртның юлыннан юырт син, малай! Ник киреләнгән буласың? Бөтен бүлекнең кәефе кырылды, иске дустың нишләргә белми аптыраган.

— Ничек ул — иске? Дуслык искерми ул! Ә бу бәхәскә дуслыкның катнашы юк.

Әскәр сүз арасына Баку киңәшмәсен дә кыстыргалап алды.

— Киреләнмә, «старик», шома гына бер доклад кисәге язып ат! Әле ачыкланып та җитмәгән нәрсәләргә кагылмыйча гына тез дә куй! Күңелсезлекләр юып алгандай бетәчәк!

— Әйбәт план төзеп килгәнсең син. Бөтенсоюз археологларына Хәй Фәләхи тезисларын илтеп биргәч, Хәсәнов аннары үз ачышларын авызына да ала алмаячак! Әйбәт план бу, «Шейх!»

— Аның каравы бер-ике елдан син фәннәр кандидаты буласың, әйдә, күтәрдек! Бүре дә тук, сарык та исән. Шәп бит!

— Әй, акыллы да син, «Шейх»! — Харрас кырысланды. — Ярый, бүре урынындагы профессор да тук булсын, ди. Сарык хөкемендәге мин фәкыйрегез дә башын сакласын, ә син үзең нишләрсең? Кем соң син?

Харрасның салмак кына башлаган сүзе ямьсез кычкыруга әйләнде.

— Бүре белән сарык арасында, гадәттә, аучы йөри, син — аучы, белдеңме?

Әскәр кеткелдәргә тотынды. Гаҗәп, кешеләрнең үзенә ябыштырып куйган кушаматлары һәрчак аңа сөенеч китерә. Әйбәт сүз ич — аучы! Ул йомры башының пеләшен сыйпый-сыйпый рәхәтләнеп көлде.

— Аучының бит аның, хе-хе-хе, мылтыгы да була, миндә монысы юк бит, малай, хе-хе-хе...

Харрас бу кадәр ахмаклыкка артык түзә алмады, урыныннан сикереп торды да:

— Бар ул синдә мылтык, бар! Менә ул синең мылтыгың! — дип, Әскәр аракы белән тутырган озын аяклы чәркәне кулына алды. Аны баш өстенә күтәрде дә тагын кабатлады:

— Менә ул синең мылтыгың, «Шейх!» Син мине шуның белән атып егарга йөрисең!

Иренең гомер ишетелмәгән коточкыч ямьсез тавышыннан сискәнеп, Кәримә дә залга чыкты. Тик соң иде инде. Харрас аракы тулы чәркәне бар куәтенә күтәреп бәрде дә идән уртасына сылап куйды.

Әскәр, китаплар шкафы өстендәге яньчек эшләпәсен эләктереп, тиз-рәк чыгып киткү ягын карады. Ишек шапылдап ябылды.

Инде хәзер ни булыр дигәндәй, гөнаһсыз карашын иренә текәп, Кәримә кухня белән залны тоташтырган тар аралыкта туктап калды. Өй бер мәл тып-тын торды. Моңарчы елап интектергән бала да, әти белән әни иркенләп бер сөйләшсеннәр әле дигән сыман, тын гына йокыга тал-ган иде.

Харрас, кылган эшләренә үзе хәйран калып, диванга килеп утырды. Салкын стена буенда нәүмизләнеп торучы Кәримәнең кыяфәте аны ай-нытып җибәргән кебек булды. Чыннан да, артыккарак китә түгелме соң бу башны юләргә салулар? Харрас уенча, аларга хәзер бөтен дөнья бер булып каршы тора кебек иде. Тегендә — Харрас өйрәнергә кызыгып йөргән тауны җимертәләр, монда — ул ачкан хәзинәдән баш тартуны таләп итәләр, өстәвенә, хатын сукрана, бала елый.

— Кил әле яныма, канатым! — Харрасның тавышы басынкылан-ган, карашы җанга ягымлы булып калган иде. — Кил инде, ичмасам, син миннән баш тартма!

Кәримә шома гына атлап ире янына килеп басты. Харрас аны би-леннән тартып янына утыртты.

— Җебеп төшмик әле без, канатым, яме!

Йомшак сүз әйтү тагын ярамады, көннәр буе җанны ашаган кайгы-хәсрәт бары берьюлы бугазга килеп тыгылды да, күз яшенә әйләнеп, агып чыкты.

Елак кына, пешмәгән генә, баштан-аяк иренә бирелгән хатынының иң өстенә авып төшкән кайнар башы Харраска тынычлык бирде. Ул, Кәримәнең сулкылдап калтыранган гәүдәсен җайлы гына кысып, бала иркәләгәндәге кебек чайкала башлады. «Я, тынычлан, йокла шунда, йокла!» — диде. Бу сүзне ул Кәримәдән бигрәк үзе өчен кабатлый иде. — Иртәгә мин Акъярга чыгып китәм, юл кирәк-яраклары әзерләр-сең, яме?!

*
* *

Харрас Акъярга аяк басу белән, тракторчы Әхәткә китте. Табылдык казанны үз кулына алды. Хәзинәдә тагын Хәй Фәләхи фаразларына каршы килүче дәлилләр — унөченче гасыр акчалары, бер бакыр савыт, бизәнү әйберләре калган иде. Башкаларын тракторчының балалары та-ратып, югалтып бетергәннәр.

Акъярда шуны белде Харрас: тауга һөҗүм ясау динчеләргә, им-том-чыларга каршы көрәш өчен кирәк булган. Чишмәне дә шул ук максат-тан чыгып күмдерткәннәр.

Авыл Советы председателе, кырык яшьләр чамасындагы хатын, Хар-рас алдында аеруча эшлекле булып күренергә тырышты.

— Быелга шуннан артыгын эшләп булмас инде, канаткынам, ки-ләсе елда тагын бер планыбыз бар,— диде.— Яз житүгә, колхоз умар-таларын Тәңкәле тау үзәнлегенә чыгарып тезәбез. Тау сыртындагы вак-тøяк куакларны тамырдан йолкып, алар урынына баллы үлән чәчәбез. Өч яклап отарга исәп — ташландык җирләрдән файдаланачакбыз —

бер, бал табышы арта — ике, өшкерүче-төчкерүчеләрдән котылабыз — менә буладыр өч! Тагын ни диярсез?!

— Ахмаклар! — дип җикеренде Харрас. — Наданнар, чеп-чи наданнар сез! Тагын ни әйтим ди?

Харрасише генә урынлы-урынсызга җикеренгән кешеләрне күп күргән хатын иде председатель. Харрас исә председатель апасының кем икәнен белмичәрәк җикеренеп ташлаган булып чыкты.

Археологның җенләнүенә җавап итеп, председатель өстәл тартмасыннан бер кәгазь кисәге чыгарды. Бу — Акъяр авыл Советының район башкарма комитеты белән берлектә Харраслар институтына җибәргән телефонограммасы иде. Харрас аны укып та өлгермәде, кулына Казаннан алынган җавапны да тоттырдылар. Язуда Тәңкәле тау буена якын елларда экспедиция җибәрә алмыйбыз диелгән, астына Хәй Фәләхинең имзасы сугылган иде.

Харрас бары тик шунда гына мәсьәләнең шактый тирәнгә киткәнлеген, бүлектәге бәхәснең Гыйльми Совет карамагыннан тыш чишелә алмаячагын аңлады.

*

* *

Шулай да гариза язарга ашыгырга кирәкмәгән икән. Ул чагында, вакыйгаларның ничек хәл ителәсен аз гына күз алдына китерсә дә, Харрас Гыйльми Советка мөрәҗәгать итеп тормас иде. Яумаган яңгырга ябынчык корган кебек килеп чыкты. Әмма ул чакта аның тәкате калмаган иде.

Иртәгә Совет утырышы була дигән көнне таң белән телефон чылтырады. Трубкадагы тавышны ишетүгә Кәримәнең йөзе кара көйде.

— «Шейх»ыгыз, сине чакыра,— диде ул иренә, алдан ук бу сөйләшүнең үзенә ошамавын сиздереп.

Әскәр исә Харраска көтелмәгән сөенче хәбәр әйтергә ашыга икән.

— Старик, Карачуринаның мәкаләсе чыккан анда, укыдыңмы? — диде ул. — Исеме беләсеңме ничек — «Профессор да ялгыша», — калганын укып тормасаң да була!

Көнен кара кайгы баскан вакытта Солтания Карачурина, бөтен эшләрен калдырып, берәр якка иҗат командировкасына яки ялга китеп барырга уйлаган иде. Кәримәнең елап килеп керүе журналистны үз хәлен онытып торырга мәҗбүр итте. Баксаң, эш белән мавыгу хәсрәтле җанга иң шифалы дару икән. Авыз тутырып әйтер сүзе булгач, җәмәгатьчелек хөкеменә куярлык чуалышларны белгәч, мәкалә бик тиз, җиңел язылды.

Бүлектәге каршылыкларның газетада фаш булуы галимнәр дөньясын гөж китерде. Язмага исә бәйләнер урын юк, автор мәсьәләне тирәннән өйрәнгән, һәр сүзен нәкъ кирәк җиренә туры төзәгән иде.

Институт таяк тыгып бутаган умартаны хәтерләтте. Күпләр Карачуринаның дөреслекне яклавына сөенделәр. Кайберәүләр. «Алай ук кирәкми иде инде! — дип куйгалады. — Кешедән оят, башка институтларда әллә нинди хәлләр булып тора, берәү дә, берни дә сизми, йөз меңләгән газета битенә чыгып шапырынмый». Өченчеләре газета битләрендә гел мактап кына телгә алынган Харрас Хәсәновны котлап, өйләренә шалтыратып интектерделәр.

Харрас, үзенең беркатлылыгы хакында, профессор, мәкаләне укыгач, ялгышып йөрүләрен аңлар, минннән гафу үтенер, мөнәсәбәтләр элекке хәленә кайтыр, дип көтте. Гыйльми Совет утырышына кергәндә дә ул, газетаны барысы да укыганнардыр инде, озаклап сөйләтеп торулар да булмас, дип өметләнде.

Ләкин утырыш алай шома гына бармады. Моңарчы һәр яңалыкка

ижади карап килгән, башлыча яшьләрдән торган бүлектә эчке низаглар туу, аның бөтен Татарстанга фаш булуы галимнәрне бик борчыган иде. Барысы бер булып шуны төпченергә ябышты — әле күптән түгел генә Хәсәнов диссертациясенең планы белән таныштык, аны расладык, профессор Хәй Фәләхине аның җитәкчесе итеп таныдык, бүген шул ике кеше арасында тау кадәр аңлашылмаучанлык. Каян килеп чыккан бу? Сәбәп нәрсәдә?

Канына төштеләр, авыз ачып беренче сүзне ник әйткәненә үкендерделәр Харрасны. Аның исәбе киләчәк ел экспедициясенә тиз генә рөхсәт алырга да бу бүлмәдән чыгып сызарга иде. Кеүеннән элгәре чыгуыңны уйла, дип, нәкъ менә шундый очракларда әйтәләрдер инде.

Мәгълүм ки, бер-берсенә дәгъвалашып йөрүче галимнәрдән әллә нинди ачышлар көтеп булмый. Аларның акылы да, вакыты да, көче дә шул ыгы-зыгы артыннан йөреп исраф була. Инде бер бүлектә шундый низагъ туган икән, яман шешне кисеп ташлап, яңадан баш калкытмаслык итәргә кирәк.

Харрасны талкып бетергәч, институт директоры тыныч тавыш белән гаризага җавап бирә башлады.

Гыйльми Советтагы киңәшмә шушы урынга житкәч, Харрас үтенечне ник язуына үкенеп утырды. Чөнки Акъяр калкулыгына киләсе елда ясалырга тиешле экспедициянең язмышы аннан башка да хәл ителәчәк булган икән. Моннан калганын Хәй Фәләхи белән Харрас чыннан да үзләре башкарыр иде, мөгаен.

Ә экспедиция мәсьәләсе менә ни өчен бүлектән тыш хәл кылынган. Институтка Мәскәү һәм Ленинград институтларыннан Идел буе Болгариясен өйрәнүдә бергәләп эшләүне үтенеп рәсми хат килгән. Башкала археологлары, әгәр шундый мөмкинлек булса, чит ил галимнәрен дә алып килүләрен хәбәр иткәннәр. Мондый үтенечкә кире җавап бирү гафу ителмәслек тупаслык булыр иде. Шунлыктан институт директоры Хәй Фәләхигә бу хатларга уңай һәм эшлекле җавап бирүне йөкләде. Сүзнең ахырында гына директор:

— Мин моны бүлеккә алданрак белдерергә тиеш идем, әлбәттә, — диде. — Хезмәткәрләр ялга таралганга күрә, әндәшми тордым. Иптәш Хәсәновка, минемчә, урында алдан ук, бик тели икән, хәзер үк барып, беренче тикшерүләр үткәрергә кирәк булыр.

Харрас ялгыш ишетмәдеме соң! Үзенең ике-өч кешедән торган группасына Чирмешән буена китәргә рөхсәт сорагач, колачы дәүләт күләменә, хәтта дөнья күләменә җәелгән экспедицияне әйдәргә кушалар түгелме соң аңа!

Әй, дөнья! Бер утка салып, бер салкын суга ташлап, кешеләренне ник бу кадәр азаплыйсың? Җанын күкләргә күтәргән бу яңалык турында Кәримәсе белән генә сөйләшеп канәгатьләнә алмагач, Харрас кичкә табан урамга чыгып китте, елга портыннан әйләнеп кайтырга булды. Киң Иделгә карап сабырлык табарга, башындагы уйларын бер тәртипкә салырга ниятләде.

Харрас Иделгә каратып куелган эскәмияләрнең берсенә килеп утырды да сигарет кабызды. Пассажирлар аз. Күрәсең, китәселәре көндез үк китеп беткән. Причалларда кечкенә трамвайлар гына тора. Читләре гөлләргә бизәлгән асфальт юл буйлап җай гына үткәләп йөрүчеләр беркая да ашыкмый. Алар су буена көндезге ыгы-зыгылардан арынып, йокы алдыннан тынычлану өчен махсус килгәннәр. Харрас ихтыярсыздан каршысыннан үткән һәр кешене күзәтеп утыра башлады. Күбесе — яшьләр, парлылар. Озын төз буйлы бер егет бөтерчек кебек кенә бер кызны житәкләгән. Боларга Иделең ни дә, тирә-юньдәге кешеләрен, гөлләрен, гомумән, чынбарлыгың ни?! Аяклары алга атлый, күзләре бер-берсенә текәлгән. Баралар, баралар да, туктап, бер-берсенә карашып торалар. Гүя алар:

— Карале, син гади кешеме соң? Җир йөзендә синдәй бәхетле кеше дә була аламыни соң? Юктыр, адәми зат түгелсең син, бәхетнең, матурлыкның кеше кыяфәтенә кергән гәүдәләнешедер син! — диләр.

Төрледән-төрле парлы гашыйклар арасында бер ялгызак та йөри. Башы аска иелгән. Монысы үз кирәгеи җирдән, аяк астындагы асфальттан укып бара шикелле. Ул, миңа тимәгез, комачауламагыз дигән кебек, бөркәнчеккә төренгән, иң өстенә юка бишмәт элгән. Бишмәтенең буш җиңнәре Идел ягына тартылып җилфердәп куялар. Эскәмиядә буш урыннарның күплеген шәйләп, әлеге ялгызак юлын Харрас ягына борды. Алар, аралар шактый якынайгач кына, бер-берен танып алдылар. Кытай макинтошы бөркәнгән ялгызбаш — профессор Хәй Фәләхи иде.

Озын эскәмиянең бер читендә утыручы кешенең Харрас Хәсәнов икәнен бер генә секунд алдан белгән булса икән соң! Хәзер инде кире борылырга соң. Кеше белән кешене көтмәгәндә, кирәкмәгәндә очраштыручы закончалыклар турында уйларга да соң. Күзләр күзгә караштты, алар икәве берьюлы:

— Хәерле кич! — диделәр.

Башта сүз ялганмый торды. Берсе Идел турында, икенчесе кичнең гүзәллеге хакында бер-ике авыз сүз әйтте, араларны ерагайткан төп мәсьәләне кузгатырлык көч табылмый торды. Бераздан Хәй Фәләхи үзәген көйдереп яткан фикерен кабыргасыннан әләктереп әйтеп салды.

— Син барыбер хаклы түгел!

— Әллә бу хакта калдырып торыйкмы?

— Калдыр, калдыр! Мине дә калдыр, институтны да калдыр, синең эшләр хәзер зурдан китте бит! Әмма ләкин кая барып чыгарсың, күрербез!

— Мин сезгә, Хәй Хәерович, мең тапкыр рәхмәт әйтә алам. Миллион кеше алдында! Кирәксә, язмача, кирәксә... — Харрас урыныннан сикереп торды. — Кирәксә, менә шушында шарран ярып кычкырып әйтәм!

— Рәхмәттән тун тегеп булмый. Бурычын башкача түли алмаган мескеннәр чарасы ул — рәхмәт әйтү.

Мондый мыскыллауны үткәрү бик кыен булса да, Харрас:

— Дөрес, бурычлы мин, муеннан бурычлы, — диде. — Сезгә бурычлы икәнемне гомерем буе тоеп яшәячәкмен, түләргә дә тырышачакмын, тик...

— Ә-ә-әй! Сөйләп торган буласың тагын, кистем, суйдым, диген, ичмасам! Ике канатыңны каердым, диген... — Аннары ул үзалдына гына сөйләнгәндәй, тын гына дәвам итте. — Әле яңа гына чыгып килгәләр иде бит ул канатлар, ныгып та җитмәгәннәр иде. — Профессор кан баскан зур коңгырт күзләрен Харраска текәде. — Син идең минем ул канатларым. Хәзер юк инде, юк син минем өчен.

Ул җәһәт кенә урыныннан кузгалды, кире якка ашыгып китеп барды. Идел өстеннән искән салкынча җил аның җилфердәвек чабулы макинтошын куптарып алып китмәкче булып дуылдый. Җил әйтә сыман:

— Туктале, агайне, салып ат әле бу җиләнеңне, дөнья катлаулылыгыннан бөркәнчек ябынып кына котыла алмассың. Телисеңме-теләмисеңме менә бу егет башлаган уенга керергә, аңа ярдәм итәргә мәҗбүр син!

Һәрхәлдә Харраска җил нәкъ шулай сөйли кебек тоелды.

*
* *

Гыйльми Совет карарын канат итеп, Харрас Татарстан тарихында моңарчы күрелмәгән археологик сәфәрнең күз алдына китерә алган планын төзеде. Аның уенча, хәзерге заманда, хәтта бу четерекле фәндә дә көрәк белән пычакка гына ышанып утырырга ярамый, нинди дер яңа

алымнар табарга, эзләнүләрне тизләтергә кирәк иде. Акъяр шәһәрләгән тулаем кузалларга омтылыш Харрас күңелен биеклеккә алып менә иде. Күңел — күктә, аяклар — төптә. Институтның вертолеты яки самолеты булса икән!

Күккә меңү турындагы теләген сәбәп итеп, Харрас тагын профессор янына керергә, татулашуга таба беренче адымны үзе ясарга булды.

Кабинетта караңгылыкны, салкынлыкны исәпкә алмаганда, әллә ни үзгәреш сизелми. Профессор да өстәле янында нәкъ элеккечә гади генә, килештереп кенә утыра. Хезмәткәре керүгә, урыныннан кузгалгач, Харрас аны, миңа кул бирергә килә, дип уйлаган иде дә, алай түгел икән. Ул, ут кабызу өчен, электр кнопкасы кадакланган почмакка юнәлде. Бүлмәгә яктылык бөркелгәч кенә гадәтенчә:

— Шуннан? — дип куйды.

Харрас араларында бернинди дә бәхәс-фәлән юк кебек итеп башындагы уйны әйтте. Әйтте дә, керүенең төп сәбәбе ике арадагы мөнәсәбәтне яхшырту өчен генә кирәк булганлыгын сиздереп, шунда ук үз сүзеннән кире чигенергә тотынды.

— Суга сәнәк белән язылган нәрсә инде бу. Хыял. Көне буе җенләнеп йөрдем дә сезгә керергә булдым. Их, минәйтәм, институтның самолеты булса-а! Юк бит, юк.

Шул чак Харрас профессор күзләрендә дөрләп кабынган ялкынны күреп өлгерде. Күе бөдрәләр дә элеккечә дәртле тибрәнеп куйды. Яшь галимнең йөгәнсез бу хыялы аның сүлпәнләнеп калган күңелен күтәрде.

— Кара, ничек без бу хакта алдан уйламаганбыз?

— Уйлаудан ни файда? — Харрас янә уфылдады. — Булсын икән ул бер сәләмә генә самолет кисәге!

— Ә нигә кирәк ул оешма саен самолет, соратырга мөмкин ич! — Профессор урыныннан кузгалып, тәрәзә буена китеп басты. — Син, слушай, аэропортка барып кайт әле, барысын да белеп, күпмегә төшүен сора, конкрет булсын! Калганын үзем кайгыртырмын.

— И-и, әгәр бу нәрсә барып чыкса, мин быелгы отпускыдан баш тартам, алырмын әле кышка!

Чынлап еласаң, сукыр күздән дә яшь чыга, диюләре шулдыр инде. Ерак шәһәрләрдән галимнәр килгәләгәнче, Казан археологлары кулында тикшереләчәк урынның Харрас группасы төзегән картасы бар иде инде. Үзенең серләрен гасырлар буе кешедән яшереп саклаган шәһәрнең берничә миллион квадрат метрга җәелгән мәйданын Харрас хәзер уч төбендә тота.

*

* *

... Кунак археологлар, яңа сезонга кергәч тә, казу эшләре башланып шактый көннәр үткәч кенә килделәр. Аның шулай булуы хәерлерәк тә иде әле. Вакытның заяга сарыф ителмәве яхшы. Харрас ерак-еракларда килгән археологларның вакытын, эшне нидән башлыйбыз соң дип, баш ватуларга исраф итмәс өчен килү белән эшкә тотынырга мәйдан булдырырга тырышты. Азаплары җилгә очмады. Галимнәр бары тик иҗади эзләнүләр белән генә мәшгуль булды.

Көзен, эшләр бер тирәгә туплангач, кунакларны Казанга алып кайту өчен, экспедициягә институтның башка галимнәре дә кушылырга тиеш иде. Харрас ихлас күңелдән яңа төркемдә Хәй Фәләхинең дә килүен, шул мул фәнни табыш биргән җирдә шатлыкның уртакка әйләнүен өмет итте.

Көннәрнең коры, җылы торуыннан файдаланып, археолог егетләр җир казышуда ярдәмче малайлар белән бергә, кыр куенында палаткаларда кунарга да калгалыйлар иде. Харрас Хәй Фәләхинең дә кырда

йокларга яратуын белә, шунлыктан аның өчен тагын бер ятак та әзерләп куйды. Профессор: «Син, слушай, мине бу мәйдан буйлап йөртеп чык инде!» — дияр. Элегрәк алар гел шулай якын итеп, үз итеп сөйләшәләр иде бит.

Чакрымнарга сузылган мәйданны урату көне буе эшләп арган Харрас өчен җиңел түгел түгелен, әмма дуслык яңарту бәрабәренә ул һәр валчыгы таныш, кадерле бу җирне мең мәртәбә, әллә нинди җәһәннәм аша уратырга да әзер. Ул көнне Харрас белән профессорга ун чакрымлап ара үтәргә кирәк булачак. Тик Харрас профессорын аеруча әһәмиятле табылдыклар чыккан урыннардан гына турылап йөртер.

Юк, әлбәттә, Тәңкәле тау чишмәсе янынннан үтәр. Археолог чишмәнең гыйбрәтле тарихы турында да сөйләр. Бу җирләрне тигезләп, тау итәгенә умарталар китереп тезгәч, чишмә яңадан берничә урыннан бәреп чыккан. Тирә-юньне су баскан, умарталар дым тарткан, тиз арада барын да кире күчерергә туры килгән. Быел Харрас белән Яхья чишмәгә яңа улак, яңа бура әмәлләделәр. Профессор белән бу хакта сүз чыккач, Харрас киңәшеп тә алыр әле:

«Моның суын алып кайтып, биологлардан тикшертергә иде, Хәй Хәерович? — дияр. — Бәлки, им-томчылар юкка гына йөрмидер, шифалы судыр бу». Хәй Фәләхи көләр инде. «Да-а, слушай, син бик тирәннән өйрәнәсең, Акъяр ханы эчкән суның составына кадәр тикшертәсең!»

Чишмә буеннан экспедициянең төп эше башлана. Ә иң аргы почмакка профессорны алып барып йөрмәсәң дә ярый. Анда шәһәрлекнең каберләре урнашкан булган. Археологлар ул төштән өч йөзләп каберне тикшерде. Фәләхи өчен аларның әллә ни кызыгы булмаячак.

Харрас уенча, табылдыклар арасында иң зур кыйммәткә ия булганы — кәрван сарай диварлары. Бинаһая зур мәйданны алып торучы бу таш бина унынчы-унберенче гасырларда ук салынган. Аннан ерак та түгел тагын бер таш бина калдыгы бар. Монысының нигезе бик әйбәт сакланган, искиткеч катлаулы җылыту системасы игътибарга лаек. Дүрткел кирпечләрне беркеткән измәне аерым тикшерергә туры киләчәк, чөнки ул моңарчы очраган измәләрдән күп тапкыр ныграк. Йортның югары катында балкон да булганга охшый, алдагы якта берничә таш багана эзе калган.

Бу корылмаларны күргәннән соң үзеңне ерак гасырлар кочагында кебек хис итәсең. Ибне Фадлан, Әбү Хәмит кебек мәшһүр сәяхәтчеләрнең Бөек Болгар турындагы кадерле истәлекләре матди төс ала башлый.

Профессор бина астыннан табылган көнкүреш әйберләрен тикшерергә ярата. Тик бу йортлардан, кызганычка каршы, кеше сөякләреннән кала кулга тотар әйбер чыкмады. Монгол басып алучылары хуҗалыктагы бөтен нәрсәне талап, кешеләрен үтереп киткәнгә охшый.

Харрас диссертация өчен кыйммәтле дип саналган дәлилләрне бәйнә-бәйнә терки барган иде. Ул үзенең ачышларын да, гомумиләштерергә өлгергән кайбер нәтиҗәләрен дә «шеф»ыннан яшереп тормаячак. Тизрәк килсен, «шәкерт»енең никадәр эш башкаруын үз күзләре белән күрсен иде!..

*
* *

Бөтен эшләр беткән, кайтыр юлга җыенырга кирәк дип торган көннәрнең берсе иде. Харрас, соңгы тапкыр булыр инде дип, кырда куна калды.

Караңгы төшеп килә. Авыл ягыннан, палаткаларга турылап, ике кеше якынлашуы күренде. Тануы кыен. Тавышларына колак салганда, хатын-кыз җәмәгатьләре икәнен генә белергә мөмкин. Хәер, озак баш ватарга туры килмәде, Кәримә ерактан ук аваз салды.

— Әй, канатларым, тәүлекне барыбер озайта алмыйсыз бит инде, чәй әзер, аш әзер, әйдәгез, кайтыгыз!
Харрас:
— Кызны кемгә калдырдың? — дип кычкырды.
— Сәгъдия әби җибәрде, аннары Казаннан килгән кунак кызына эш урыныгызны да күрсәтәсем килде.
«Кунак кызы» үзе дә сүзгә кушылды.
— Мин әле бу, кирәкле кишер яфрагы. — Монысы Карачурина иде. — Ике көн ялны ничек үткәрергә белми аптырап тора идем, галимнәргә ияреп килергә булдым аннары.
Харрас сабырсызланып сорап куйды:
— Институттан тагын кемнәр килде?
Солтания Әскәр «Шейх» исемен телгә алгач, Харрас шиңеп төште. Шулай да күңелен кисеп үткән кимсенү, гарьләнү хисен хатыннарга сиздереп торырга теләмәде, эчтән генә профессор турында: «Кара инде, килсә ни була иде. Кызыксына бит үзе, күрәсе дә бик килә», — дип уйлап алды. Хатыннарга бөтенләй башкача сөйләп китте.
— Бик әйбәт булган! — диде. — Чәй белән бәрәңге әзер чакта өлгердегез, әйдәгез табынга!
Алар табын тезелергә тиешле аулак урынга килделәр. Кисәктән генә яшь хатыннар әңгәмәсенә кушылу сәеррәк булды. Харрас эндәшминитми генә аларга карап тора башлады.
Солтания Карачуринаның кыяфәте сугышчан походларда да ир-атлардан калышмый йөргән борынгы кабилә кызларын хәтерләтә: аксыл свитеры өстенә кара тубал чәчен туздырып салган, чалбар кигән. Кәримә, кияүгә чыкканнан соң, гадилеккә борылды: бүген ул башына каралы-кызыллы кәшимир яулык бөркәнгән хәтта. Монысы, мөгаен, Сәгъдия әбинекедер.
— Кичкырын салкын була, мә, бәлә шыны башыңа! — дигәндер. — Күәз туңмый, калтырый, салкын сугар, бәлә, бәлә! — дип, ачулана-ачулана бөркәндергәндер.
...Төнге учак янында кичке ял башланды. Егетләр, инде тамак ялгап, кайсы кая таралышып беткән. Харраслар табын кора башлагач, учак утын саклап утыручы Яхъя да үз палаткасына кереп китте.
Тирә-юнь тып-тын. Калай савыт читенә бәрелгән кашык тавышы гына тынлыкны бозып куйгалый. Эндәшүче юк. Савыт-саба шалтыраулар басылгач та сүз башларга кыймый тордылар. Ерактан, авыл ягыннан гармун моңы ишетелгәч кенә, Кәримә:
— И-и, бүген шимбә бит әле! — диде. — Минем эш көне башлана, хәзер монда яшьләр уенга җыела!
Гармун телләре, озак көттермичә, моңлы көйне туктатып, шаян такмакка күчте, җырлап та җибәрделәр. Шаулы төркем, археологларның палаткалары яныннан үтеп, Таңкәле тау үзәнлегенә бара иде Бу турыдан ураганда, яшьләрнең һәр сүзе аермачык ишетелә. Бүген алар өряңа көйгә такмаклыйлар.

...Сәхрәләргә чыккан идем,
Былбыл бала тарата.
Синең күңелләр ничектер,
Минем күңел ярата.

Яңа җырның шактый сәер кушымтасына Карачурина да игътибар итте.

Сөймәсәң, сөймә генә, сөймәсәң, сөймә генә,
Сөймәсәң, сөймә генә, ялынмыймын, гүзәлем!
Ташла, гүзәлем, ташла, түзәрлегем бар!
Сиңа түгел, агымсуга каршы йөзәрлегем бар!
Ташла, гүзәлем, ялынмам, түзәрмен,
Агымсуга каршы торып, чумып-чумып йөзәрмен!

Төркем ерагайды, сүзләре аңлашылмас булды, шаян җыр тәэсиренә бирелеп китеп, Солтания:

— Рәхәт сезнең монда! — диде. — Эше дә, ашы да, концерты да бер үк урында. Белсәм әгәр, атна саен килгән булыр идем. Газетага материал да оештырырга мөмкин.

— И-и, газетага гынамы соң, бу мишәрләр хакында китап язсаң да була, вакыт кына тими безнең,— дип, аның сүзен Харрас та хуплады.

— Безнең яклар үзе җыр кебек бит ул, — диде Кәримә. — Әйдәгез кичне бушка уткәрмик, без дә җырлап утырыйк!

Чыннан да, мондый урында, бу тын, саф кичтә гади сүзләр көчсез, кеше үз күңелендәгене көйгә салырга, моңга бирелергә тиеш кебек иде.

Инде шактый еракка китеп өлгергән гармунчыга куәт өстәргә теләгәндәй, Харрас авыз эченнән генә әллә кай замандагы, үзәк өзгеч моңлы көй суза башлады. Бераз тыңлап торганнан соң, карлыга башлаган тавышлы Солтания җырның сүзләрен сузып җибәрде:

...Биек тә генәй тауның ай башында
Болан эзләп йөри пакь җирне.
Каләмкәе минем кулда булса,
Язмас идем яман тәкъдирне...

Караңгы. Сүнеп барган учак тирәли тезелешкән кешеләрнең йөзләре бер-берсенә күренми. Бу халдә, моңлы көйгә салынган борынгы сүзләр аеруча серле яңгырый. Аларны мондагы кешеләр җырламый кебек. Тәнкәле тау ягында, сүла барган шәфәкъ кызыллыгында кара күмер сыман шәүләләр калыккан — Бөек Болгар дәүләтенең гасырлар буе җир астында яткан харәбәләре... Моңлы җырны гүя шулар суза.

# Хәйдәр

## Күзгә булып инде ак болытлар

> Күзгә булып инде ак болытлар —
> Әйләндереп салды өйләрне.
> Узып китте яңгыр.
> Әйтерсең лә,
> Язмыш безгә әкият сөйләде.

Канатларны җилпеп очар идек
күтәрелеп шушы җирләрдән...
Язмыш безгә теләк-канат биргән,
ә канатның үзен бирмәгән...

Маңгайларның ачы тирен чәчеп
муллык җыяр өчен бу җирдән
язмыш безгә житез аяк биргән,
язмыш безгә оста кул биргән.

Язмыш безгә көчле акыл биргән,
хыял биргән, канат бирмәгән:
болай да ул сәях җанлы, дигән,
китмәсен ул туган җирләрдән!

Җан тырпылдый һаман күкрәкләрдә,—
көнләшәбез очкан кошлардан.
Әмма барыбер туган туфраклардан
аерылырга язмыш кушмаган.

Әверелсә дә кошка безнең җаннар,
оча алмас әллә кайларга:
тургай булып зәңгәр күккә менәр
игенчене мактап сайрарга!

## Әйтер сүзем

1

Тел очында тора әйтер сүзем,
сабагында калган җиләк кебек.
Ак күбеккә баткан заман чаба.
Бу болытлар — гүя ап-ак күбек.

Тел очында тора әйтер сүзем,
төсен җуйган, кипкән җиләк кебек.
Сусыл чакта авыз иткән булса,
чабар иде заман уйнап-көлеп.

2

Тел очында тора әйтер сүзем,
мин хәзергә аның — хөкемдары.
Аннары ул миңа хуҗа булыр,
хуҗа булыр — очып китсен бары.

Хуҗа булыр, бәлки, бу дөньяга.
Тик белергә кирәк әйтү җаен.
Бүген шифа булыр асыл сүзләр
төсен җуяр еллар узган саен.

Шунда гына булса хикмәт әгәр!..
Көтә икән безне башка хикмәт:
әйтеләчәк шушы сүзләр өчен
кирәк икән әле иза чикмәк!

Тел очында тора әйтер сүзем,
мин хәзергә аның — хөкемдары.
Зурмы, вакмы — нинди вазифа ул
үз сүзеңә хуҗа булулары?!

3

Тел очында тора әйтер сүзем,
алсуланып пешкән җиләк кебек.
Узып китте заман. Калдым карап.
Ак болытлар күктә, ап-ак күбек...

●

Өметне мансак та яктыга,
дөньяда хакыйкать, чынлык бар...

Әнкәйнең хәлләрен сорасам,
тамчылап күрсәтә болытлар.

Кайчакта аяза һавалар,
нур сибеп күрсәтә кояшы.

Кайсыннан башланган гомерем,
кайсысы аларның җыр башы?

●

Нәрсә булмас?! Ай да, бәлки,
кыңгырау булып чыңлар.
Я йолдызлар, җыелышып,
бер кояш булып чыгар...

Кояш чыгар, якты кояш,
чәчәк кебек балкыр таң.

Яки әйләнер яшенгә,
атылыр ул офыктан...

Нәрсә булмас! Кеше уйлый,
чикләре юктыр уйның:
әле җирдә бәргәләнә,
әле күкләрдә уйный!

●

Ут йөгергән инде кар астына,
тыңла, әнә, шаулый гөрләвекләр.
Җылы язның зәңгәр күзләредәй
карап тора күккә күлләвекләр.

Эремидер кебек күрер күзгә,
җәйрәп ята әле ак киңлекләр.
Ут йөгергән әмма кар астына,
ташкын булыр — шундый мөмкинлекләр.

...Яшибез бит без дә тыныч кына,
чыгармыйча эчтә янган утны.
Һәм бер көнне ярсу ташкын кебек
актарылып агар сәбәп юкмы?!

Бар ул сәбәп, җитә! Кайбер язлар
сызылып кына килә, шауламыйча.
Кешеләр дә, әнә, башын иеп
яши белә кайчак, дауламыйча.

Юанмагыз шулай сабыр гына
яшәрбез дип тын да чыгармыйча.
Йөгерсәме ул ут күңелеңә —
түзә алмас бәреп чыгалмыйча.

Карасамы кояш җиргә туры —
кышны куып карны эретәчәк.
Ашкындыра ташып актарылырга
язны — кояш, безне — ак киләчәк!

## Мөмкин

Үз-үзеңне алдау
мөмкин әле, беләм!
Гомер ялгау-ялгау
юанулар белән.

Кирәк кайчак шулай
үткәннәреңне барлау:
мөмкин икән, әйе,
үз-үзеңне аңлау!

●

Сызылып керде җанга карурманның
еракларыннан килгән шаулары.
Шуны гына көтеп торган, гүя,
тынгысыз җан кушылып шаулады.

Шаулады ул. Бөтен уй-фикерләр
әверелде кочле шау-шуга.
Нигә әле һәрбер күренешне
кабатларга шулай ашыгам?!

Тамчы булып тамам — яңгыр яуса,
чәчәк атам кинәт болында.
Узган юллар сызыла маңгаема,
буразналар эзе — кулымда.

Тиешмени кеше шатлык килсә,
гел елмаеп кына йөрергә,
кайгы-хәсрәт ишелеп төшсә әгәр,
күз яшенә әйләндерергә?..

...Бәреп керсен урман шау-шулары,
алар мине бик тә сагынган.
Һәм әйләнсен моңлы, матур җырга,
яңгырасын, әйдә, «Карурман».

●

Кояш әйләнәсендә — Җир,
төн күбәләге сыман.

Җылы яңгыр, ләйсән яңгыр —
очар кошлар күз яше —
өзелеп җиргә тамганда;

быел муллык килер җиргә,
ишелеп иген уңар дип,
күктән хәбәр алганда...

Ә кемнәрдер иле өчен,
гаделлек, азатлык өчен
утка кереп янганга...

...Җир әйләнә Ут тирәли,
төн күбәләге сыман.

Шул чагында әнкәемнең
ишетәм күңел догасын:
«Улларым, тыныч итегез
заманнарын, дөньясын!»

...Кояш әйләнәсендә — Җир,
төн күбәләге сыман.

# АЗАТЛЫК ҖЫРЧЫСЫ

Ялкынлы революционер, күренекле партия һәм дәүләт эшлеклесе, дипломат, галим, казакъ совет әдәбиятына нигез салучыларның берсе Сабир Шәрипов гаять катлаулы һәм гыйбрәтле тормыш юлы үтә.

Ул 1882 елны Вятка губернасы, Алабуга өязе, Салагыш волосте Барҗы авылында бурлак һәм чыптачы Шәрип абзый гаиләсендә туа. (Хәзер Татарстанның Әгерҗе районы.) Сабирга унике яшь тулганда үпкә авыруыннан әнисе үлеп китә, ике елдан, суык тидереп, әтисе дә вафат була. Унөч яшьлек малай ике сеңелесе белән ятим кала. Сабир өчен авыр еллар башлана. Бер сәүдәгәргә ияреп, малай казакъ далаларына барып чыга һәм шул вакыттан алып Казагыстан аның язмышына әверелә.

Зирәк һәм тырыш үсмер 1903 елны Павлодар шәһәренең авыл хуҗалыгы интернат-мәктәбен тәмамлый. Бирегә сөргенгә җибәрелгән студентлар белән танышып китә, аларның ышанычын казана, дөньяга күзләре ачыла.

Сәяси ышанычсызлыкта гаепләнеп төрмәдә утырып чыккач, аңа кабат балалар укытырга рөхсәт ителми. Ул берничә ел буе төрле эшләрдә йөреп тамагын туйдыра. Егетнең ятимлектә үткән үсмер еллары эзсез генә калмаган күрәсең, аның күптән яшеренеп яткан үпкә авыруы ачыла. Сабирга шәһәрдән далага күчеп китәргә киңәш итәләр, һәм ул Атбасар волостена писарь-тылмач булып урнаша. Хәленнән килгәнчә халыкка ярдәм итә. Шушында үзенең беренче иҗат тәҗрибәләрен ясый.

Патшаны бәреп төшергәч, С. Шәрипов тулысынча революцион эшкә чума. Хәтәр юллар, төрле маҗаралар аны сагалап кына тора, тиф белән авырый, берничә тапкыр үлемнән кала.

1922 елны ул инде Акмолла каласында губерна азык-төлек комиссары, аннан губерна башкарма комитеты председателе. Шул ук вакытта Казагыстан партия Үзәк Комитеты һәм Казагыстан хөкүмәте члены да.

Шушы елларны С. Шәрипов иҗат эшенә керешә. Губерна һәм республика вакытлы матбугатында да актив язып тора. 1926 елны аның «Алтыбасар» исемле хикәяләр җыентыгы чыга. Бу җыентык казакъ әдәбиятында крестьян тормышына багышланган беренче китап була.

Соңрак аны Мәскәүгә чакырып алалар, иң җаваплы эшләрнең берсенә — яшь Совет хөкүмәте нефтькә мохтаҗ вакытта «Эмбанефть» трестына башлык итеп куялар. Бу эшкә С. Шәрипов унбиш ел гомерен бирә, нефть өлкәсендә фәнни хезмәтләр яза.

Шулай итеп С. Шәрипов күңеле тарткан әдәби хезмәт белән ял вакытларында гына шөгыльләнә ала, әмма, шуңа да карамастан, «Алтыбасар» повестенең тулыландырылган вариантын бастыра, бер-бер артлы «Бикбулат» повестен, яратып укыла торган «Сәлия» романын, шәрык дөньясына багышланган «Ләйлә» һәм «Рузи Иран» әсәрләрен, күп санлы хикәяләрен, очеркларын иҗат итә.

Казакъ халкы якташыбыз С. Шәриповның революцион эшчәнлелегенә, совет хөкүмәтенә күрсәткән хезмәтләренә һәм әдәби иҗатына югары бәя бирде. 1959 елны Казагыстанда аның ике томлык әсәрләре дөнья күрде, ул әсәрләр бүген дә кат-кат басылып тора, төрле телләргә тәрҗемә ителә.

Түбәндә Сабир Шәриповның ике хикәясе тәкъдим ителә.

ИБРАҺИМ САЛАХОВ.

## Сабир Шәрипов

# КАЛА ЧЫГУ

ХИКӘЯ



Күчмә халык елына ике тапкыр калага барып чыкмыйча, азык-төлек, кием-салым алып кайтмыйча тора алмый. Анысы-монысы кирәккәндә йөгертеп кенә барып кайта торган каласы да юк бит аның якын-тирәдә. Сата торган малны үткәзеп җибәрә торган базары кайда? Шулай булгач, биш-алты йөз чакрымда яткан калага бармый ни чара.

Яз башында — җәйләүгә күчкәч, бер тапкыр; көзен — кышлауга кайткач, икенче тапкыр базарга чыга ил. Кышкы сугымны суйганнан соң арттырасы мал исәпләнгәч, җәйләүгә чыкканчы җитәрлек кием-салым, чәй-шикәр, он һәм башка кирәк-ярагын алырга кирәк. Менә шул хаҗәтләрне үтәү өчен калага барып килү илдә «кала чыгу» дип атала.

Һәр өйдән яки һәр авылдан бөтен кеше калага бармый. Сата торган малы да чамалы, алдыра торган кирәк-ярагы да аз булса, калага барып килү чыгымы үзе малның башын ашавы мөмкин. Кайберәүләрнең исә я үзенең, я ат-арбасының җае килми. Андый кешеләр малларын әзерләп һәм йомышларын бүтән берәүгә кушып җибәрергә мәҗбүр булалар.

Байлар һәм биләр, билгеле инде, кала чыгасы айны көтеп ятмый. Аның малы үзендә, чыга да китә. Анда — дала тормышына охшамаган кызык дөнья, уен, көлке. Өстәвенә «кала чыгу» үзе бер кәсеп, аның да нинди файдалысы әле.

Язгы яки кышкы базар якынлашу алдыннан берәр бай яки байбәтчә «кала чыгам» дип хәбәр бирсә, әйләнә-тирәдәге авыл халкы шуңа агыла. Берсе бер дөясен, икенчесе — ике-өчне үк җитәкли. Берәүләр җылкы әйди, икенчеләр куй-кәҗә куа. Йонын, тиресен күтәреп җәяү килүчеләр дә күп була. Һәр өй үз хәл-кадәренчә, тормышында ни булса шуның белән ашыга... Алар көч-хәлгә, арып-талып киләләр дә, бар малларын кала чыгучыларга биреп, үзләренә кирәк-яракны алып кайтуны үтенеп аманәт итәләр.

Кала чыккан кешенең малны күпмегә сатып, кирәк-яракны күпмегә алса да үз иркендә. Аның артыннан барып тикшереп йөрүче юк. Кала чыгучы «алай-болай» итмәсен дип, берәр гидай җәһәннәм артында яткан калага ялгыз дөясе белән, әйтик, барсын да ди, ә барып ни кыра?

Кала чыгарга әзерләнгәндә Асарбай хаҗи быел да:

— Җаңабай,— диде бер көнне, улын каршысына утыртып акыл бирә-бирә.— Үткән язда, би сайлау чыгымы буенча, Акылбай өенә ун баш эре мал бирү кирәк

иде. Инде, калкам[1], хәзер шул малны түләү өстенә, кыш чыгарлык азык-төлек, киемсалым кирәк. Бу сәфәрдә кимендә ун баш малны файдага калдырмасаң, рәт чыкмас.

— Атаем,— диде Җаңабай башын күтәрмичә генә итагать белән, ләкин рәнҗүен белдереп.— Ул хәтле малны кайдан тугызаен? Илнең миңа кушкан малы күп дигәндә кырык баш чамасы булыр. Син бер сәфәрдә ун малны файда кыл, дисең. Дүрт малдан берсен янга калдыр дигәнеңме бу? Моны, атай, нинди акыл сыйдырыр? Мин...

— Кит моннан,— Асарбай кычыкырып җибәреп киез өстендә яткан камчыны алып кизәнде,— ни дигән адәм булмас җан син. Ил били торган тәрең булса, мин чалның башын катырмыйча үзең үк җаен табар идең, гуй. Акылдан шашарлык ни нәрсә бар монда?—Чал, камчысын читкә куйды да, тавышын төшереп янә Җаңабайга таба иелде.— Әүвәле, малны сатканда, бәяне азрак күрсәтеп сигез малдан берсен бөгәсең... бу — бер булдымы? Икенче, аны-моны алганда хакын артыграк санап, тагын сигездән берсең бөгәсең... Дүрт малдан берсе итәк астыңа кердеме? Кырык мал дисең, кайдан белдең? Бер-ике көн ил аралап чыксаң, тагын кушылыр. Ходай боерса, илле дә, алтмыш та булыр. Ул чакта, иншалла, биштән берне сөзеп калу җиңелрәк булачак... Төшендеңме инде, ахмак,— дип, хаҗи улын үтә ачуланып алды.

Дөресен әйткәндә, Җаңабай да бу хәйләне белми утырган ахмак түгел. «Адәм булып ил били торган төре» дә бар. Әмма аның үз кирәге өчен дә мал арттыруны чамалап утырганын чал каян төшенсен. Шул хәтле җиргә баргач дус-иш, кордашыру белән күңел ачып, кәеф-сафа кормый яшь җан ничек чыдар? Асарбай аны уйламый да булса кирәк. Ә Җаңабай уйлана, шуның өчен дә ул чалны бераз «какшатып», үзенә дә өлеш калдырырга тырыша иде.

Бу кичне кышлауның икенче башында инде ишелеп барган бүтән өйдә дә кала чыгу турында ата белән уллар арасында сүз барды.

Дәүрәнбай күп гомерен Асарбай хаҗи бусагасында ялчылыкта уздырды. Инде ир җитеп килгән өч улы кышкы буранда туңып, җәйге эсседә көеп бай көтүен көткән өчен тагын берәр җылкы алалар. Бу — аларның еллык хезмәт хакы. Өйдә әле болардан башка да бала-чага тулы. Шул гаиләне асрарга өч җылкы ничек җитсен?! Дәүрәнбай үзе дә тик ятмый — берәүгә арба төзәтә, берәүгә чана бөгә... Аз-маз булса да мал асрый. Кар инде бу өйнең түбәсен әллә кайчан баскан — базарга барып вакыт җитеп узган. Ә өлкән балалар әле һаман җылкыда — ташлап китә алмыйлар. Дәүрәнбай инде бүген-иртәгә чүгеп калу алдында. Андый озын юлга чыгалмый. Шуңа ул да сата торган малын хаҗи улы Җаңабайга кушарга булды. Бала чагасын учак янына җыйды да, карт Дәүрән:

— Балалар,— дип сүзен башлады.— Барны-юкны, кирәк-яракны уйга салсак, дим. Ал... ни кирәк... биш бишмәт тышлыгы, биш чалбарлык һәм оланнарга камзуллык... һаҗәргә чапанлык... ал.— Ул бер тотым ак сакалын учлап озак уйланып калды да, кинәт уянып киткәндәй, башын күтәрде.— Ия... ким куйганда туксан кәз[2] тышлык кирәк булыр, әгәр көзен алтмыш тиеннән исәпләсәк... санасак...— Чал тагын сакалын сыпып уйга калды.— Ия... илле сумнан артык акча кирәк икән. Тагын җиде җанның эчке күлмәге белән ыштанлыгы... Илле кәз ситсы. һаҗәргә урамал[3] һәм тагын кимәчәк[4]. Бер юрган — асты-өсте белән... исәпләп карасак...— Чал саксаул ботаклары кебек тырпайган бармакларын бөгә-бөгә санарга керешә.—Кимендә сиксән кәз чыга икән. Бу, аз дигәндә, уналты сум. Ике пар итеклек күн олтан белән егерме сумга якынаеп калыр. Инде тамак ягына күчик. Кимендә алты капчык он кирәк. Моныс шулай ук кимендә уналты сум. Алты кадак такта чәй, бер савыт керәсин, шырпы...

— Атаем, шикәрне санарга оныттың.

— Онытып утырганым юк... Ал — инде сезнең күңелегез булсын — бер өч-дүрт кадак шикәр дә кушыйк... Боларына да ундүрт сум кирәк булыр. Ал. — Дәүрәнбай, учак янына тыгызланып утырган килеш аталарының авызына карап каткан балаларга

[1] Калкам — кадерлем.
[2] Кәз — аршин.
[3] Урамал — яулык.
[4] Кимәчәк — биткә койрыклы ситсы япма.

күз төшереп, тагын сакалын учлады.— Балалар, инде мин әйткәннәрне берен берене кушып сумасын җыйыйк. Әүвәле илле сум, моңа уналтыны кушсак, әйтик... алтмыш алты сум була. Балтабай,— ата кеше учакка сөялеп, атасы әйткән санны кабатлап, әйтеп утырган шадра битле кара балага эндәште.— Синең башың исәпне югалтмый, монау алтмыш алтыны онытма...— Бала, «ярый» дип баш иде дә, пышылдап «алтмыш алтыны» кабатлый башлады.— Тагын егерме, тагын уналты. Бу утыз алты булса, тагын унбиш белән уналты бар... Ул утыз бер. Шул утыз бергә тагын утыз алтыны салсак алтмыш, алтмыш җиде була... Ал, башта синдә торган ничә?

— Алтмыш алты, атай.

— Ал, алтмыш алты өстенә алтмыш җидене салсак күпме чыга, балам?

— Йөз дә... йөз дә... утыз өч була, атай.

— Уф, алла,— чал авыр сулап башын чайкады.— Я, ходаү, үзең мәдәт бир. Дөнья хәтле акча кирәк, гуй.

— Атай, миңа көпе алып бирәм дигәнең кайда?— диде Балтабай борынын тартып.

— Язын, җәен, күлмәксез йөрдем,— диде атасына терәлеп утырган, өстенә көпе кигән уналты-унҗиде яшьлек түгәрәк йөзле, почык борынлы икенче улы,— бу базарда тагын мине исәпкә кертмәдең... Ертык көпедән шәрә тәнем күренә... Мин инде унҗидегә чыгып калдым, гуй... Кемгә дә булса кердем, күлмәгем юклыктан оялып, көпемне салмый утырам... Битем ертыла...

— Атай, миңа ыштан кайда?

— Атай, минем аякка нәрсә?

Учак янында шау-шу, ыгы-зыгы, елау-сыктау башланды.

— Уй-бай, калкаларым, сездән аяп, булмаса алмаен дип торганым юк, гуй,— дип чал яман сулады. Шау-шу бераз тынгач, өй хуҗасы тагын башын күтәреп сүзен акрын гына ялгап китте:—Үзегез күреп торасыз, гуй. Алай тартсам да җитми, болай тартсам да чыкмый. Әүвәле далада мал багып, безне ризыкландырган агаларыгызның өстен бөтенәйтеп алаек, дигән уем, гуй. Аларга да җитми ятыр, дөньясы коргыры. Акча артса калганнарыбызга да күңел җитәр. Алырбыз... Ал, Үмерҗан,— ул учак янында иягә башын куеп, йокыга киткән өлкән улына карады.— Тор, уян, улым, акыллашып кискән көпе тар булмый.— Үмерҗан көчкә-көчкә күзен ачты:

— Мин ике тән йокламаган, гуй, ата.

— Беләм, беләм... Тик сүзгә колак салып, киңәшеңне әйтмәсәң ярамас, кала чыгу алдында торабыз, гуй... Баягы утыз өч сумга, булмаса тагын бер уналты-унҗиде сум салсак, дим? Шунда, ходай үзе мәдәт бирсен, йөз кырыктан ашып төшә. Инде зиһеннең тәенен чишү кирәк. Мондый сумага ничә мал сата алабыз?— Учак янында утырганнар барсы да башларын түбән иделәр. Өй эче тып-тын калды. Карындык белән ябылган тәрәзә артында ыжгырган буран тавышы ишетелде.— Аз куйганда дүрт җылкы салмый булмый. Ул да җитмәсә, инде ни кылабыз? Түшәк тышлыгы белән һәҗәргә дигән чапанлыкны калдырып торырбызмы?— Мич артында, керләнеп беткән кимәчеккә уралып утырган, җир төсле кап-кара битле карчык борынын мышык-мышык тартып түбән иелде.—Күңелеңә авыр алма, һәҗәр, киләсе базарда, ходай боерса, чапан алырбыз, ходайдан аманлык телә: әгәр дә инде балалар бәхетенә җылкының бәһасе былтыргыдан артык булса, иншалла, барыгызның да сораганы, теләгәне булыр...— Учак янында утырганнар бердәм башларын күтәрделәр. Йөзләр яктырды, әйтерсең лә учак дөрләп кабынып китте.— Ал, Үмерҗан, тик ята бирмә, башыңны эшләт ничә мал чыгара алабыз?

— Атай, үзең беләсең, гуй,— Үмерҗан иярдән башын күтәреп, атасына якынрак шуышып утырды.— Якын арада өчәвемезнең дә көне тула. Асарбай, аманлык булса, өч җылкы чыгарыр. Инде үзең бер җылкы кушсаң, атаҗан?

— Ия,— диде Дәүрәнбай сакалын сузып, уйланып.— Син әйткән өч җылкыга кулыбыздагы күк бияне кушсак... инде кала чыгучының азыгына бер куй бирү фарыз... Алып кайта торган йөккә сала торганыбыз ике дөя, гуй. Азыкка бер куй җитәр, дим.

Бу кичтә Асарбай авылының башка өйләрендә дә нәкъ мөнә шундый киңәш-сүз барды. Бигрәк тә гидай өйләрдә бу киңәш озакка сузылып, шау-шулы, җәнҗаллы булды. Әмма аңа карап сатарга ниятләнгән мал артмады, тишек-тошыкның ябылып бетү ихтималы да күренмәде.

Асарбай өе кала чыгуга хәзерләнә башлады. Авылның тирә-ягына җылкы, дөя,

сыер, куй малы тулды... Алар янына төркем-төркем халык җыелды. Уртада — Җаңабай... Кулында катыргы тышлы кенәгә һәм карандаш — малның исәбен ала.

— Балтабайдан кушылды: ике дөя, ике сыер, биш җылкы тиресе. Азыкка — бер куй. Йөккә — ике дөя... Хәмзәбайдан алты җылкы. Азыкка бер куй. Йөккә ике ат-арба. Бер олаучы. Иргалидән ике җылкы, ике сыер, ун тире, ике пот йон... Дәүрәнбайдан...— Җаңабай карандашын, берничә тапкыр очлап, авыз-борынын шәмәхәгә буяп, сүгенеп, катып-туңып, исәп алуның соңына житкәндәй булды.— Ал, җаным чыкты, язылмый калган мал, адәм юкмы?

— Юк, юк,— диде халык тавышланып.

— Алай булса...— диде Җаңабай, кенәгәсен төлке тун кесәсенә тыгып, һәм бер өем тире өстенә утырды. Насбай атты[1]. Төмләп суырды, теш арасыннан сиптереп бер төкерде дә урыныннан кузгалды.— Үмерҗан, малны бүген яхшылап бак, мин өйгә кайтып хәл алыйм,— дип үзләренә таба атлады. Халык тарала башлады. Үмерҗан «һайт-һайт»лап малны далага таба борды. Базарга әйдәлә торган малның саны болай булып чыкты: 31 җылкы, 10 сыер, 16 дөя, 40 баш куй-кәҗә, юллык азыкка 12 куй. Йөк тәэргә 20 дөя һәм ун ат-арба.

— Атай,— диде Җаңабай бишбармак ашап, корт изгән кужә-шулпа эчеп, җылынып, хәл җыйгач, мендәргә кыйгайган хаҗига карап,— йортның кушкан малы күбәеп китте. Сез биргән дүрт егет ул хәтле малга ия була алмас. Тагын бер-ике егет яллamасак, калага барып житү кыен булыр.

Хаҗи, ачуыннан сискәнеп, мендәреннән күтәрелеп утырды да:

— Миең агып киттеме әллә?— диде.—Яллау дигәнең ни сүз? Як-ягыңа карап азмаз уйлансаң ни була? Авылда инде ничә көн калага укырга бара алмый зар җылап еч-дүрт бүзбала йөри. Шуларга хәбәр салсаң, атылып килеп житмәсләр дисеңме? Юллык азык ала килсеннәр дип әйттер. Ат менеп барган өчен мал әйдәшерләр. Чыгым — юк, файда — бар. Ай бала, бала, ходайга шөкер әле, буең үсте... Акыл, дөнья кору ваемың житми шул әле. Яллау диген сүзеңне эт ашасын.

Асарбайның акылы алтын булды: Җаңабай хәбәр бирүгә, менә дигән еч юлдаш егет азык асып килеп тә житте.

— Туганнарым,— диде Җаңабай атасының акылын отып алып, егетләрне кызгангаң тавыш белән,— сезнең калага китәлмичә утыруыгызны ишетеп җаным борчылды. Барыбыз да бер авыл, бер ата балалары, гуй. Гыйлем юлы — изге юл. Артык ат-арба булмаса да, сезне калага барып житсен, дидем. Иншалла, юлыгыз булады икән. Шөкер. Инде һәрберегез бер атка менеп алып малның артына төшендәр. «Бер көймәгә утырганның җаны бер» дигәндәй, бер сәфәрдә бергә булып малны калага исән-аман житкерәек.

Далага беренче кырпак кар төшкән, көн суыткан иде. Ике кат киездән куыш тегеп, юлга алты куй ите алып — алтысын Асарбай өйгә алып калды — «Я алла» дип малны алга салып, Җаңабай егетләре белән базарга кузгалды. Ил халкы аларны «хәерле сәгатькә, исән-сау барып кайтыгыз, юлыгыз уң булсын» дип озатып калды.

Калачылар уналты көн юлда булып сау-сәламәт, чыгымсыз, базарның нәкъ кызып-кайнап торган вакытында калага килеп керделәр. Укырга җыенган бүзбалалар көндез мал куып, төнлә каравыллап катып-туңып килделәр дә «бу бәлагә кайдан туры килдек» дип зар елап, калага керүгә үк юк булдылар.

Икенче көнне бик иртә торып, Җаңабай базарның кызуында малны мәйданга куып китерде. Шул көнне кечкә кадәр җылкылар сатылып та бетте — башы 58 сумнан үтте. Утыз бер җылкыга 1800 сум алып, куен дәфтәренә «җылкы 43 сумнан сатылды. Акчасы 1333 сум» дип язылды. Ул акчаны көпенең бер кесәсенә, файданы — икенче кесәсенә салып каптырып куйды. Икенче көнне сыерлар 40 сумнан сатылып куен дәфтәренә «ун сыер 300 сум булды» дип язылды. Өченче көнгә базар дөяләрнеке булып, төрлесе төрле бәһа белән үтте. Шулай да урта исәп белән һәр баштан ун сум өлеш Җаңабай көпесенең «файда» кесәсенә кертеп каптырылды. Тире-тирсәк, йон, вак мал да файдасыз булмады. «Ибен тапсаң кар яна» ди торган иде Асарбай хаҗи. Дөрес икән.. Ибен тапкач, Җаңабайның «файда» кесәсенә дүрт көн дигәндә 850 сумга якын мал кереп оялады.

---

[1] Насбай атты — тел астына вак тәмәке салды.

Малны күпмедән сатып ятканны егетләрнең берсе дә белми. Җаңабай сәүдәгәрләр белән озак сәүдәләшкән булып, кулга кул сугып, бер килеп, бер китеп егетләрне таң калдыра да, читкә китеп «эшне пешерә» иде. Шулай да ул егетләрне онытмады. Дүртенче көнне кич, мал сатылып бетүгә егетләрне куышка җыеп алып алларына бер табак ит куйды, берничә шешә сыра ачты. Егетләр ашап-эчеп бераз кызгач Җаңабай сүз башлады:

— Сезнең дә хезмәтегез күп керде. Барыгызга да зур рәхмәт. Ал, менә инде сезгә миннән базарлык... Теләгәнегезне алып яки ашап-эчеп рәхәтен күрегез,— дип һәр егеткә шытырдап торган ун сумлык тоттырды.

— Ай, рәхмәт, Җакә, мең яшә!— дип егетләр үтә риза булдылар.

Итне ашап, сыраны эчеп бетергәч Җаңабай:

— Туышлар, әле сезгә бер үпкәм дә бар. Белмим, әйтергәме, әйтмәскәме?— дип хафаланган кыяфәт белән авыр сулады.

— Әйтегез, Җаңакә, әйтегез.

— Ул нинди үпкә тагы?— дип, егетләр уен-көлкедән туктап һәм аптырап, морзага карадылар.

Әйтсәм әйтим алайса, күңелдә төер булып калмасын,— дип сүзне Җаңабай теләмәгәндәй итеп башлады, —бер көнне малны үзәннән, кала адәмнәре су эчә торган җирдән эчерткәнсез. Сезнең арттан стражниклар килеп «кем малы суны болгаткан?» дип эзләп мине табып алдылар.

— Уй-бай!

Егетләр борчылып бер-берсенә күз салды.

— Шуннан?

— Шуннан стражниклар «син законны боздың» дип беркетмә яза башлады. Ходаның хикмәте, арада бер нугай стражник бар икән. Шуңар ялынып-ялварып, теге кафирларга йөз сум биреп көчкә котылдым.

— Бәрәкалла, үзебезнең мөселман туры килүен карачы.

— Инде тагын мал куышып килгән бүзбалалар бар, гуй. Алар да бер көнне базарда очрап: «Ага, без бит илдә туган-туышсыз калабыз. Бераз хезмәт тә иттек, безгә бераз юлаяк калдырсагыз икән,— дип үтә ялындылар. Күңелем җылап, җылагандай итеп, күземә яшь килде. Гыйлем юлында йөргән балалар, гуй. Шунда аларның һәр кайсысына 15 әр сумнан 45 сум акча бирдем. Ни булса да без үзебезнең авылга кайтып авабыз, алар бит җыен урыс арасында калды, уй.

— Ай рәхмәт, Җәкә, бик изге эш кылгансыз. Үз авылыбыз балалары, гуй.

— Менә шуның барын җыйнап санасаң, бүген эчкән сыраның да сумасын кушканда,— Җаңабай егетләрнең күзенә сораулы карап торды да, аларда ризасызлык күренмәгәч, сүзен йомгаклады,— барлыгы ике йөз сум була. Ал, инде илгә кайткач егетләр аңкаулыгыннан йөз сум штраф түләдем... тагын фәләнчә акчалата бирдем дип дөресен әйтә салсам, сезгә сүз тимәсме дип хафаланам. Ал, инде монда бүтән бер акыл табу кирәк булыр, дим.

— Уй-бай, Җәкә,— диделәр егетләр бер авыздан,— ул акылны үзегез тапмасагыз, безнең баш — буш турсык, гуй.

— Ал... алай булса, миндә бер уй бар. Уртага салаек, — дип, Җаңабай рухланып хәйлә йомгагын урый башлады.— Мәсәлән, болай булса. Калага якынлашып килгән төнне үтә каты буран чыкты. Мал бураннан кала янындагы хуҗаларның кибәненә сыена башлады. Безнең ай-вайга карамый кибәннә...не ишеп, таратып, изеп күп зыян кылды. Шул вакыт хуҗалар чыгып, малны урап алып, «зыянны түләгез, юкса малыгызны бирмибез», дип ай-һайлады. Алай үтенеп, болай ялынып карагач, ахырында ике йөз сум төртеп көчкә котылдык, дисәк?

— Ай, дөрес акыл.

— Бәрәкалла, ибен таптың да соң! — диделәр егетләр, куанышып.

Җаңабайның кала чыгып мал сатканын Акылбай да ишеткән булырга кирәк. Бер көнне кичке аш өстендә ул Җаңабайның фатирына килеп калды. Бишбармак ашап, корт изгән куҗә эчеп илнең хәлен, базарның җаен сорашканнан соң, былтыргы «вагъдәне» искә төшереп, Асарбай әкәгә күп сәлам һәм би сайлаганда күрсәткән хезмәте өчен рәхмәт әйтте. Җаңабай «әйткән сүз — аткан ук» дип, мал башы 45 сумнан

килешеп, акыл байга 450 сумны шытырдатып санап биреп, атасы Асарбайның бурычыннан котылды.

Икенче көнне Җаңабай базарга чыгып илнең тапшырган аманатен үтәргә бил буды. Әүвәле ул алтмышар тиеннән 200 пот, бер сумнан 100 пот он алып, алыпсатарның үзендә үк шул саннарны бер-берсенә кушып — бутап капчыкларга тутырды. Куен дәфтәренә «өч йөз пот он бер сумнан» дип теркәде. Аннан кием-салымлык алып 130 сумны кыстырды.

Базар яхшы булды. Илнең барлык тапшырган эшен генә түгел, «акча җитмәсә, алмассың» дигәннәрне дә алынды.

— Аллага мең шөкер, ил дә риза, мин дә риза, — дип, Җаңабай көпе кесәсендә кабарып, күңелгә рәхәт биреп, җылытып торган янчыкны сыйпап куйды.

— Егетләр, инде сез илгә кузгалыгыз. Авыл безне көтеп зарыккандыр. Мин сезне ярты юлда куып җитәрмен, — дип йөк төяган дөяләрне, ат-арбаларны юлга озатып «Ал, хуш, аман-сау йөреңдәр» дип үзе берничә көнгә калада калырга булды.

Кешеләрен озату белән Җаңабай, каланың көнчыгыш читендә, күл буенда торган хәрчәүне дигән өйгә килде. Монда борынгы дуслар, төрле илнең уртасыннан кала чыккан дүрт егет — Касыймбик, Төксәет, Җакып, Сәрсәнбикләр сыра эчеп, гәп корып утыралар икән.

— Хуш килдең, Җакә, түрдән уз! — дип, егетләр өстәл янында куанып аңа урын бирделәр, тагын бер дистә сыра һәм кабымлык китерергә куштылар.

Калада биш көн кәеф-сафа корып, сыра-аракы чөмереп хушланганнан соң гына егетләр атка атландылар. Каладан чыкканда алар тагын әлеге хәрчәүнәдә «баш төзәтеп» алдылар.

Көн аяз, кояшлы иде. Дала өстенә әйтерсең ак киез җәйгәннәр — күзне камаштырып тора. Каладан чыгып, илгә кайта торган юлга төшкәч, атларын акрын атлатып егетләр үзара гәп башлады.

— Утыз өйнең уртасыннан кала чыккан идем, — диде озын, чандыр, кылыч борынлы егет Касыймбик, ияренә кыйшая төшеп, — үземнән бер тиен чыгармый ике йөз сумлык азык, кием-салым алып кайтам. Тагын алты йөзе — кесәдә.

— Мин, — диде ияргә кочкә сыеп утырган киез өйдәй түгәрәк-юан гәүдәле, җәенке битле Төксәет, — егерме биш өй уртасыннан чыгып мең ярымны суктым...

Кечкенә гәүдәле, кызларныкы төсле ак йөзле, матур егет Җакып та үз чиратын калдырмады, иптәшләренә елмаеп карады.

— Дуслар, мин дә буш кайтмыйм, кирәк-ярак алганнан калган биш йөз сумым кесәдә.

Аннары моңа кадәр сүзгә катышмый читтән барган Сәрсәнбик тезгенен тартып, айгырын борды да сүз ялгады:

— Битемә кызыллык киләсе түгел, ашаган-эчкәннән калган мең сумны атама дип төенләп куйдым.

Җаңабай, юлдашларының сүзен очлап, тамак кырып үзенең өлкәнлеген күрсәтте:

— Менә, ходайның биргәне, өйләнәсе йөз өй уртасыннан кала чыгып дүрт меңнән артык файда таптык... Моннан артык ни кирәк?!

— Ия, чумара аз түгел... — диде Төксәет, бераз уйланып, — әмма бу кыланышыбызны ил белсә җанымызны алмый калмас.

— Уй-бай, — диде Касыймбик, — моңау Төксәет үзе куян икән. Безнең ни алып, ни биргәнебезне кем белә? Йөз өй йөз җирдә таралып ята бит.

— Дөрес әйтәсең, Касыймбик, — диде Җаңабай, — белсә ни кыла? Бездә ни гонаһ? Тапшырган малларын калага исән-аман җиткердек. Сатасын саттык, аласын алдык. Инде ни атасының башы кирәк ул карасөяккә? Әгәр һәр гидай үз малын үзе җитәкләп калага китә торган булса, җаны да калмас. Безгә әле рәхмәт әйтү кирәк! Безнең чумара хәләл.

— Сүзең дөрес, Җакә, мең сум дигәнең кимендә егерме биш җылкы. Кала чыгып бер әйләнгәндә алган табыш. Менә дигән егетләр кышның кыш буе мал багып бер җылкы алганын күзебез күреп торды, гүй. Инде безнең бу табышны ил белсә хәләл дип әйтмәс. Ни булса да төшне кыскан яхшы, — диде Җакып.

— Бу да акыл, — диде Җаңабай, — сазлыкта хурлык юк.

Бу сүзне башкалар да «дөрес» дип хупладылар. «Көннең кабагы төшкәнче алдагы

авылга барып җитик», — дип, егетләр атларын юырттылар. Юл аркылы «ак еланнар» сузыла башлады — җәяүле буран күтәрелде.

Бер атна дигәндә Җаңабай алдан киткән йөкчеләрне куып җитте. Икенче көнне кичкә таба алар инде үз авылларына кайтып керделәр. Бөтен ил Асарбай өе янына җыелды. Алар, Җаңабайны Мәккәдән кайткан хаҗидай зурлап:

— Я хода, аман кайтып җиттегезме? — дип, үтә куандылар.

— Япырмай,— диде Җаңабай, аттан төшеп ата-анасы, илнең өлкәннәре белән сәлам биреп күрешкәч, — күпме тапкыр кала чыгып бу юлыдай азап-хурлык күргәнем булмады. Көне суык. Бураны ачы. Иң әүвәле тәңерем ярдәме, аннан соң үзебезнең чыдамлык белән, менә көчкә кайтып төштек. Юл газабы — гүр газабы диләр, дөрес икән. Кыен булса да бер тиен чыгымсыз баруыбызга куанып калага җитә язган бер төндә буран чыкты. Мал буй бирми ыгып, таралышып кешеләр кибәнлегенә төште,— Җаңабай егетләр белән килешкәнчә, «күргән» хурлык-азабын тагы да кабартып сөйләде: — Ике йөз сум акча түләп көчкә котылдым, — дип хафаланып илгә карады.

— Уй-бай, башның аманлыгын әйтче, — диде илнең өлкәннәре сакалларын сыйпый-сыйпый,— мал башына биш сум сәдака, гуй. Моны рәнҗемәй өстебезгә алабыз, шулай гуй, балалар? —

— Иә, иә! Сәдака булсын! — диде шаулашып тирә-яктагы халык.

— Инде, — диде Җаңабай, ил алдында торган Сансызбай әкәгә карап, — без барудан өч көн алда җылкының башы илле, сыерныкы кырык сум булган. Без барып төшкәндә, коргыры, мал арзанаеп калды. Нугай байлары кирәк малны җыеп китеп өлгергән. Кием-салым, азык-төлек сатучы сәүдәгәрләр дә тарала башлаган икән. Боларның барысы да безнең кичегеп баруыбызның бәласы. Инде, ходай боерса, киләсе калага чыгуда иртәрәк кузгалуыбыз хәерле булыр, иншалла. Шулай да — Җаңабай як-ягына карап, тамак кырып, халыкның күңелен күтәрерлек итеп елмаеп көр тавышына көчте, — шулай да, базарны яман булды дип хафаланырга урын юк. Малны былтыргыга караганда кыйммәтрәк сатып, азык-төлек, кирәк-яракны арзанрак алдым.

— Бәрәкалла! Бәрәкалла! — дип халык күңелле шаулашып, бер-берсенә куанып елмаеп карады.

— Хәтта «акча җитмәсә алмассыз!» дигәннәре дә алынды.

— Мең яшә, балам.

— Ал, туышлар, мин кәгазьдән укып әйтеп тораен, атай, сез әйберләрне тапшырыгыз!

Дөяләр чүктерелеп, йөк сүтелде. Атлар тугарылып, арбаларның җитәкчеләре төшерелде. Асарбай, вәкарь белән атлап барып: — Я, бисмилла... башладык, — диде.

Илнең куанычы куенына сыймый — һәрберсе үз үтенеченең үтәлүенә шат иде.

— Балам, гомерең озын булсын, уллы, кызлы бул. Балаларыңның игелеген күр. Безне куандырган өчен тәңре сине куандырсын, — дип, Җаңабайның аркасыннан кагып, Асарбайга да зур рәхмәтләр яудыралар,— монадай адәм җанлы бала үстергәнең өчен без риза, хода риза, — диешәләр иде.

**Казакъчадан ИБРАҺИМ СӘЛӘХОВ тәрҗемәсе.**

# КУЗГАЛЫШ

ХИКӘЯ

Волость башлыгы Такач җыелган түрәләрнең берсенә:

— Гомәр, син ишеттеңме әле, Тайчым коткычы үзенә бер өер туплап маташа икән, — диде. — Халык тәмам азды. Моның зыяны, иртәмесоңмы, барыбызга да тиячәк.

Ыргыз өязе Кызылҗар волостендагы бер мең өч йөз өйнең барча «хөрмәтлеләре» — Баксак, Сәеткол, Касыйм түрә нәселләре дә, тагын башкалар да җыйналган иде монда. Арада тирә-якка атагы чыккан Гомәр, Агымбай, Сагындык, Куҗак, Бирдән, Куйчыбайлар да бар иде.

Әмәлен тапса, алар гына таба инде, дигәннәрнең бөтенесе дә шушында. Берсе волость, берсе авыл түрәсе, берсе морза, берсе би дигәндәй — һәммәсе дә үз кешеләр. Болар баш кушып сүз берләшсә, аны «бозып» мөгез чыгарырлык адәм илдә юк. Бакчак ыруыннан Тайчым дигән ялгыз тинтәк кенә бу араларда буй бирми йөри. Азгынны авызлыкларга инде күптән вакыт җиткәндер, дип шуны тыңлату чарасын эзлиләр.

Яңа гына чалынган колынның ите казанда богырдап кайный башлады. Багучы булып килгән егермедән артык егет атларын тышаулап, тирлекләрен аска түшәп, өй тирәсендәге яланда утырганы утырып, ятканы ятып, үзара сүз алыша. Әмма гәпнең тәме юк — барысының да башына бердәй хәвеф төшкән: унтугыз белән утыз бер яшьтәгеләр арасын сугышка алалар, дигән хәбәр килде. Патшага солдат хезмәте итүнең нәрсә икәнен белмәгән казакъ халкы аптырап калды. Беренә бере сер әйтеп чишелеп китәргә дә базмыйлар. Аулаграк утырган дүрт-бише генә пышылдашты:

— Атларын иярләп, малларын карап күпме ярарга тырышсаң да, байдан безгә ярдәм юк, гүй, Актүбәдән килә торган сигез йөз солдат башта ярлы-ябагайны кырачак. Монда утырган егетләр арасында безгә иярердәйләре булса, төннән калмый шуларны да алып, Тайчымга кушылырга сәфәр чыгыйк. Башка өмет барыбер юк, сугышсак, үз илебездә кан түгеп үлик ичмаса, — диде егетләрнең берсе.

— Шушы бишебездән башка иярердәй зат күренми. Тәвәккәлләп бүген төнлә качарга вәгъдәләшик,— диде икенчесе.

— Анык хәбәрен белдем, — диде тагын берсе. — Тайчымның хәзер алты йөздән артык егете бар икән. Отрядына көне-төне халык агыла, ди. Теге якта Җомагазы хан булып, ул да егетләр җыя икән. Тауып волостенда Аймамбит, Кинҗәгара волостенда Айҗаркын, Аманкүл волостенда Килтәй дигән кеше — бишесе дә егетләр җыйнап, солдатлар белән сугышырга әзерләнә, кайберләренең меңнән артык гаскәре бар икән. Әмма баягы ниятебез дөрес, мондагыларның барысы да бай нәселдән, безне теләсә кайчан ташлап, үзбаш аерылып китүләре мөмкин, ә бичара фәкыйрь Тайчым үлсә, үзебез белән бергә үләчәк агай ул.

Шушылай пышылдашкан биш егет байларын ташлап, Тайчым отрядына качып китәргә сүз беркетте.

Алты кирәгәле ак тирмәнең ишегеи каравылларга, читтән берәүне дә кертмәскә ышанычлы сак куелган, өй эчендә исә бая телгә алынган түрәләр кызу киңәш кора иде.

— Николай патша ярлыгыннан безгә хәвеф янамайды, — диде Гомәр. — Билгәгән эре малларны иллешәргә бүлеп, һәр көтүне көтәргә берәр егет калдырырга рөхсәт ителәде. Монда утырганнарның теләсә кайсы үз балаларыннан башка тагын биш-ун егетне илдә калдыра ала, чөнки моңа мал саны җитәде, гүй. Утыз-кырык баш эре терлеге бар урта хәлләләр, балаларын җибәрәсе килмәсә, кеше яллый ала. Күз карасыдай патшабызның мондый әмеренә дога кылудан башка ни әйтәсең? Шушындый гадел патшага каршы чыккан залим Тайчымны хакимнәргә үз кулыбыз белән тотып бирсәк, хөкүмәт тә, ходай да безгә шөкерана кылыр иде, сапкан юлыбыз — алла юлы! Теге Ыргыз ягыннан ни майтарып кайтуын Такач үзе сөйләр.

Гомәр түрәгә ялгап волость башлыгы Такач сүзгә кушылды.

— Генерал Лаврентьев гаскәренә боерык бирде инде, — диде ул. — Ноябрьның унбише көнне Беловка, Аксайыс, Калдык волостьларында тузгыган илне бастырырга дүрт-биш йөз солдат чыгачак. Аңа бер көн китсә, иртәгесен Тайчымны кулга алыр. Ыргызның өяз башлыгы Шәриф түрә белән киңәшеп, солдатларны алып килергә унлап кеше җибәрдем. Тайчымны үзегез тотып бирегез, яхшы атагыгыз чыгар, ди Шәриф. Дөрес әйтә, гүй. Әмма киңәштән башка ярдәме тимәс, ахры. Чөнки, мылтык сорагач, ашыкмады. Йөз мылтык кирәк, дигәч ике күзе дүрт булды. Шуннан соң фәләнне бир, төгәнне тап, дип авызымны да ачмадым. Менә шуны гына әйтә алам мин.

Тирмәдәгеләр бер-берсенә карашып, һәркайсы үз уен уртага салды.

— Ышанмаган инде.

— Үз ыруы булмагач...

— Мылтыкны кулга төшергәннән соң я солдатларга каршы файдаланырлар, дигәндер.

— Юкны сөйләмә. Алай дияргә, Такачны әллә өяз танымыймы? Губернатор Евроман үзе дә белә. Мылтыклары җитешмидер.

— Шәрифнең сүзе хак, — диде Гомәр түрә, — Тайчым бәдбәхетне тотып бирсәк, абруе үзебезгә. Минем егете бар, дигәч тә аларның хәле билгеле, гуй. Кораллары сөңге дә айбалта. Кулыма бер-ике йөз егет кенә бирегез, үзем яу чабам, яхшы атка атланган ике йөз егет булсамы,— тотабыз да алабыз! Иң алдан Байморза балалары, сез, илле егет бирерсез. Тайчым тинтәкнең өч йөз баш атыгызны үзләштерүен керфек тә какмый карап утырмассыз ич инде? Йөз атын югалткан Байзак нәселе, сездән егерме егет кирәк. Җәйләү җирләрегезне тартып алучы, өязнең, губернаторның боерыгын санга сукмастан, аны иген кырына әйләндереп, кышлау салучы Тайчым түгелме? Шуны бер авызлыкласак, я юк итсәк, Кушүзәндә иген иккән җир — йөз-ике йөз йортлы фәкыйрь-фокра авылы, басуларын саклый алмый, кайсы кая таралышып бетәчәк түгелме? Ата-баба заманыннан калган киң җәйләүгә яңадан ия булачаксыз түгелме? Тайчымны дөмектерү барыбызга да фарыз уртак эш. Калганнарыгыз да бер-берәүгә салынмый ун-унбишәр егет җыеп килсен. Егерме ел элек сөекле җәйләвемнән аерган Тайчымга рәхим-шәфкать юк, мәлгунь белән мин теләсә нинди хәтәр бәрелешкә дә әзер, — дип, төкерек чәчте Гомәр түрә.

— Ике йөз егет табылуын табылыр, тик аның белән генә мең егеткә каршы яу чабу уңышлы булырмы икән?

— Билгеле, җиңел эш түгел бу. Тик мин болай уйлыйм: әүвәле Ыргызга барып Шәриф белән киңәшсәм һәм аңардан ышаныч кәгазе алып, Актүбәгә юнәлсәм, эш пешәр сыман. Актүбәдән чыгачак гаскәрнең башлыклары белән киңәшеп, аларның Аксайыс иленә киләчәк көнен билгеләп сүз куешырга кирәк, гуй. Аксайыска солдат килгәндә Тайчым Җомагазыга булышмый калмас, икесенең дә уе бер ич. Җомагазыга ярдәм итим, дип, егетләренең күбесен җибәрер дә үзе бер төркем кешесе белән генә утырып калыр. Менә шул көнне, сәгатьне сагалап торабыз да бер-ике йөз егет белән авылына бәреп керәбез.

— Дөрес шул.

— Бәрәкалла!

— Тапкыр да инде үзең, Гомәкә! [1]

— Тайчымнан бер котылыр идек, ичмаса! Алла ярдәм итсен үзеңә Гомәкә! — диди барысы да дошманын бүген үк тотып алгандай куанышты. Колын итен ашап, кангачы кымыз эчеп, ихлас вәгъдәләр бирешкәч кенә бай-түрәләр илләренә таралышты.

Тирмә тирәсендә пышылдашып утырган биш егетнең чаярагы Кодабай Гомәр түрәнең шомлы планнарын ишек төбендә торган сакчыдан сорашып белгәч, төн җитүгә дүрт юлдашын ияртеп Тайчым отрядына шылды.

Кушүзәннең игенчеләр авылыннан ун чакрым җирдәге Җөзек калкулыгына ике йөзләп өй урнашкан. Тирмә, куыш, чатыр бары аралаш. Шаулашып-гөрләшеп өйдән-өйгә йөргән, тышта ыгы-зыгы килгән, якын-тирәдә төркем-төркем укмашып йөргән егетләрнең барысы да коралны: мылтык, кылыч, айбалта асканнар, иярләнгән меңләп ат тау итәгендә утлый. Ике авыл арасында атлы, җәяүле хатын-кыз ашамлык ташый, алар тирәсендә бала-чага кайнаша.

Калкулык уртасына биш кирәгәле тирмә корылган. Түбәсендә кызыл әләм җилфердн, ишек төбендә сакка мылтыклы ике егет баскан, өйгә кергән-чыкканнарны тишәрдәй карап, юньләп танымаган кешеләргә сорау бирәләр:

— Тайчым агага керергә кемнән рөхсәт алдыгыз?

Рөхсәте юкларны ишектән кире боралар.

Өй түрендә аяк бөкләп утырган, ипле киемен каеш белән буган, билбавына таккан хәнҗәренең очы идәндәге киезгә терәлгән Тайчым бүрегә ташланырга торган бөркетнекедәй үткен карашын Кодабайга төбәгән тирә-ягындагы иптәшләренең дә күзе юлаучыда — волость башлыгы Такач өендә Гомәр түрә корган планнар хакында хәбәр китергән иде егет.

— Я, Кодабай, толпар ишен табар, дигәндәй син дә менә үз ишләреңне килеп

[1] Исемне кыскартып, аңа «әкә» кушымчасы ялгап олылау.

таптың, — диде Тайчым көлемсерәп. — Хәбәрең өчен рәхмәт, без менә синдәй ярлылар хакына шушы зәмһәрир суыкта япан далада каныбызны, җаныбызны аямый, язмышыбызны няргә бәйләп куйдык. Патша чирүен җиңә алмасак та, казакъ байгураларын гына туздырырга көчебез җитәр. Хәбәрнең вакытында килеп җитүе яхшы булды.

— Сагынай, — диде ул бер иптәшенә, — Гомәр түрәне кулга төшерү әмәлен үзем уйлап табармын, аңа нинди җәза бирәсебезне Истәк, Ирмәк, Уразымнар белән бергә хәл итегез. Биркембай, Сагындык, Куҗак, Бирдән, Куйчыбай дигән кап-корсакларның Ыргыздагы өяз башлыгына әләк ташып, аннан илгә әйләнеп кайткач, халыкны котыртып йөрүләрен үз колагың белән ишеттең. Алтысына да лаеклы хөкем кирәк. Барыгыз! Ә синең, Кодабай, чын иптәшләрне табуың шәп булды. Хәзер инде юлдашларың белән азык-төлек әзерләргә кереш. Сагынайда кайсы байдан нинди мал, нинди ашамлык, атларга күпме азык аласы язылган исемлек бар. Башта череп баеганнарны савыгыз, урта хәлле, фәкыйрь халыкка тимәскә.

Тайчым Кодабайны озаткач сакчы егетләргә:

— Уразбайны чакырыгыз, — дип боерык бирде.

Ул әле һаман аякларын бөкләгән килеш утыра, кызарган ике күзе уттай ялтырый, үзе һич тә ару-талуны белмәгән кеше төсле иде. Урта яшьләрдә, өсте-башы учак төтененнән каралган, сакал-мыегы да ни кара, ни сары икәнлеген ерактан чамалый алмаслык хәлгә килгән.

Тирмәгә килеп кергән Уразбай:

— Әссәламегаләйкем, Тайчәкә! — дип исәнләште.

— Вәгаләйкемәссәлам. Я, озынга сузмый гына сөйләп бир әле: тимер, күмер, ярдәмчеләр җитәрлекме? Ничә оста җыйналды? Кушканны үтәп өлгертәсезме?

— Кыенрак бит әле, Тайчәкә, күмер җитәр, тик менә тимеребез әзрәк. Тимерчеләр тугызау булдык. Әмма тәүлегенә кеше саен ун кылыч, бишәр айбалта ясау читенрәк, чүкеч белән сандал җитешми. Җан башына көненә унлап кылыч чукибез.

— Озак мыштырдарга вакыт юк, эшләр тыгызга китте, ничек итсәгез дә тугыз йөз егетне коралландырыгыз. Егетләрне хаҗәтегезчә эшкә җигегез. Сафка тезеп, коралларын барлаячакмын, әгәр берәрсе коралсыз була калса, үзеңә үпкәлә. Ишеттеңме? Бар, эшкә тотын!

— Тайчәкә, мине чакырдыгызмы? — диде Амантай кәрә-керешкә.

— Их, егеткәй! Кулда көч барында олтаны бөтен итек, ертыгы юк тун белән бер әйбәт бүрек юнәтә алмадыңмы? Волость кадәр илнең байлары үз карамагыңда, гүй, моннан соң ертык тун, тишек итек киеп бүтән күземә күренмә. Мондый өтек кыяфәттә кеше алдында нинди дәрәҗәң булсын?! Я, кирәк-ярак табылып бетәме инде?

— Өс-баш кайгыртырга кулым тими шул, Тайчәкә. Бүтән кирәк-яракларны бүген бөтенләйтә яздым. Тагын сиксәнләп ат хаҗәт иде. Агымбай, Бирдән, Идрисләр көтүенә егетләр җибәреп йөрим, сиксән юрга кичкә килеп җитәчәк. Теге көнге Акауның өч йөз, Картыбайның йөз аргамагы кеше башына берәрдән бүлеп бирелде, егетләр атланып йөри. Ияр-дирбияне җитәрлек җыйдырдым, йөген-фәләннәр бар да әзер.

— Берсекөнгә кичен егетләрнең барысын да атлары белән сафка тезәм. Әгәр берәрсе ияр-тирлексез җайдак булса, башың белән җавап бирәсең. Бар, юлыңда бул!.. Хәер, тукта әле, сүзем калган икән: байларның тапкан малы, ашаган азыгы, кигән киемнәре барысы да ярлы хезмәтенең җимеше. Ялчылар аркасында маллы булдылар. Байларның кат-кат киемнәре сандык тулы, биргәннән җайлап, бирмәгәннән «майлап» алып, егетләрне тәэмин ит! Әмма кирәгеннән артыгына сузылмагыз. Бу шаламаларыңны юк ит! Ярар, бар! — дип, Амантайны да куып чыгарды. Аның артыннан Үтәмешне чакырып алды.

— Берсекөнгә кузгалырбыз, ахры. Утрак авылга син ия бул, хәлсезрәк егетләрнең кырык-иллесен алып калып, халыкны сакла. Волость-фәләннән килеп, авылны бөлдереп китмәсеннәр. Сәфәребезнең кайда тәгәлләнәсен үзем дә белмим. Бар, әйткәннәрне үтә. Дәзбай керсен әле монда.

— Дәзбай, халык арасында яшерен генә хәбәр тарат, — диде Тайчым яңа кергән егеткә. — Актүбә ягыннан күп гаскәр килә икән, ноябрьнең тугызында Караболактан Мәчетлегә таба узачак дигән. Шуңа каршы барлык егетләрне җибәреп, үзем утызлап кеше белән авылда калам. Шушы хәбәрне яшерен генә тарат.

— Ярар, Тайчакә... тик үзегез авылда калгач, егетләрне кем җитәкләр икән, сездән башка аларга кем боерык бирер? Нишләп авылда каласыз?

— Борчылма. Бу хәбәр хәйлә генә. Гомәр түрә мине патша янаралларына тотып бирмәкче була икән. Кодабай сөйләгәннәрне ишеттең ич. Безнең арада шымчы булмый калмас. Хәбәр шулар колагына кереп, яңалыкны тизрәк дошманга җиткерсеннәр. Ашыгыбрак кыймылдарлар. Аннары, чирүе чамалы, дип үзләре дә әз кеше белән һөҗүм итәрләр. Чынлыкта ныграк егетләр арасыннан йөз кеше сайлап алып, шулар белән калырмын. Патша гаскәрләренә каршы тәп көчне Караболакка таба җибәрә торырбыз. Төшендеңме?

— Менә хәзер барып җитте. Хуплыйм, йөгердем, алайса, — дип, Дәзбай күздән югалды.

Уразбай, Амантай, Үтәмеш, Дәзбай — байларның язмышын хәл итү тапшырылган егетләрнең дүртесе дә баш күтәрүчеләр арасында иде. Монда утраклыкка күчеп, иген игеп көн күрүче халык җыелган: берәвенең баласы яки агасы, икенчесенең сугышка кара эш өчен җибәреләсе энесе яки үзе. Үз урынына кеше яллап җибәрергә яки көтү көтеп калырга мал башы җитми торганнар монда. Инде байтактан бирле көченүче байларның терлеге таптау сәбәпле, ел әйләнә көтү хуҗалары белән сугышучы игенчеләр дә бар. Әлеграк кайберәүләре патшаның гаделлегенә өметләнеп сабыр итә иде. Июнь карары чыгып, байларга авырлык салынмыйча, фәкыйрьләрнең генә балалары сугышка китәчәге билгеле булгач, үз йодрыкларына гына ышанырга мәҗбүр булганнар кайнаша иде. Күзләре ачылган: инде кайчаннан бирле фронтка җибәрүдән саклап килгән Тайчымны башлык итеп сайладылар да аның боерыгын ике әйттермичә үти башладылар. Шунлыктан Тайчым хәзер, киңәшеп тә тормый, әмер бирергә өйрәнде.

Менә санаулы ике көн үтеп тә китте. Тайчым атка атланган тугыз йөз егетне сафлар буйлап карап узды: һәммәсе таза, атлар көр һәм әйбәт, киемнәре җылы, мылтыгы юклар да нинди дә булса корал юнәткән — берсендә кылыч, икенчесендә айбалта — кулдан ясалганы да әлегә ярап торырлык.

Тайчым канәгать. Егетләрне үз төркемнәренә таратып, йөзбашы һәм иллебашын иярләп, түбәсендә әләм җилфердәгән өйгә юнәлде. Аш әзер икән, тамак ялгый-ялгый киңәштеләр.

— Хәбәр тараткан көннең иртәгәсен ике егет юкка чыкты, арабызда дошман шымчылары да бардыр, дип дөрес шикләнгәнбез икән, Тайчәкә, — диде Дәзбай.

— Иртәгә Гомәр түрә кешеләре безне күзәтеп торачак, качкыннар хәбәрне илтеп җиткергәннәрдер инде. Төш вакытында егетләрне алып Караболакка таба китәрсез. Мин исемнәрен атаган йөз егетне аерып алып, утызын янымда калдырыгыз, җитмешен Майлысур уйсулыгына яшерегез. Берәрегез тау түбәсеннән дошманны күзәтеп торып һәм күренү белән сак кына артына төшәрсез. Бу яктан утыз егет белән үзем каршы чыгармын. Миңа да дошман ягыннан хәбәрләр килә: алтмыш кеше җыйганнар, «утыз әләм-әтрәк белән калган ил болгатучы кәнтәйне өшкерәбез», дип бик каты кодрәчләнәләр икән, — диде Тайчым.

Аштан таралышабыз дигәндә генә ул иптәшләрен туктатып:

— Сагынай, сез ничек хәл иттегез? — дип сорады. — Хөкемегез нинди?

— Әйткән кешеләрегезнең һәркайсысын ата-бабасыннан алып бүгенге көнгә кадәр тикшердек. Үз ыруындагы ярлы-ябагайны җәберләүләрен инде әйткән дә юк. Утрак авылның өч йөз фәкыйренә күрсәткән зыяннары да җитәрлек. Шуның өстәвенә алар әле патшага яхшатлыланып, безне җитәкчесез калдырырга җыеналар икән. Боларга үлемнән башка җәза юк, карарыбыз шундый — диде Сагынбай.

— Уртак фикерегез шул икән, без дә аңа кушылырбыз, — дип, Тайчым карарны раслады.

Күк йөзен кара болыт каплаган, җил тынган, көн җылынып киткән иде. Җитмеш егет таң алдыннан Майлысур уйсулыгына барып, атларын тибенгә җибәрде. Калкулык түбәсендәге күзәтче тирә-якны караштырып тора иде. Аның тавышы ишетелерлек ераклыкта тагын шундый берәү, аннары икенчесе, өченчесе... Сигнал бирелсә, хәбәр минуты белән уйсулыкка килеп ирешәчәк иде. Дошман алар күз алдында Җәзек сыртына таба чабып узгач, Майлысурдагы егетләр үзәнлек буйлап аларның артына төшәргә кузгалды.

Кьп төшкә авышты. Бераз элегрәк Тайчымның сигез йөз егете калкулыктагы юлдан Караболакка юнәлгән иде. Күзәтүче шымчылар аны әллә кайдан шәйләрлек булды. Тайчым калган утыз егетенә биш-алты куыштан кала барлык өйләрне сүттереп аттырды. Монысы да хәйлә өчен иде.

Алтмыш егет иярткән унлап бай Гомәр түрә кул астында Майлысурдан ун чакрымдагы җиргә төш җиткәч үк килеп яшеренгән иде. Калку үрләргә менеп куналаган үткер күзләр Тайчым егетләренең Караболактагы Җомагазыга ярдәмгә китүен ерактан карап калды. Гомәр түрә ат өстендәге баш кисәрләрен дәртләндереп:

— Егетләр, Тайчымның үзе белән утыз-кырык кешесе бар, — диде. — Калганнарының кая китеп баруы күз алдыгызда. Урдасында биш-алты гына тирмә калган, моны үз кешебез килеп хәбәр итте. Мәргәннәре, яхшы мылтыгы булганнар барысы да киткән булырга тиеш. Әмма Тайчым үзе батыр кеше, егылганчы тилереп сугышачак. Алар әз, без күп, дип саксыз кыланмагыз, әз булсалар да тиз генә бирешмәсләр. Их, шул ерактан тидерә торган мылтыкның булмавы! Әмма ни чара, күплегебезгә таянырга туры килә. Тәвәккәл таш яра дигәндәй, болай да кыйратабыз без аларны. Бер дошманга без икәү ич. Якыннарым, шуны да истә тотыгыз, миңа китереп сөйләштермичә Тайчымга орынмаска! Коты ботына төшерлек итеп, мәңгегә үкенерлек итеп алырбыз җанын. Я, ходай белән патшаның бер үзләренә тапшырып, кузгалыйк, — диде дә Гомәр түрә, алгы сафка чыкты.

Дошман карачкылары күренүгә, Тайчым да атына атланды һәм утыз егете белән ай-һайлап каршы чыкты. Исәбе — дошманына мылтыктап атып, атларын егып өркетү һәм Майлысурдагы тозакка таба куып китү иде. Дошман өеренә җитәргә ярты чакрым калгач, Тайчым, мылтыктан атып, байгураларның өч-дүрт атын екты һәм бер-ике кешесен яралады. Егылган атларны һәм яраланган иптәшләрен күргән Гомәр түрә егетләре Майлысурга таба чигенә башлады. Тайчымга шул гына кирәк тә иде, мылтыктан күккә ата-ата, качучыларны куа бирде. Гомәр түрә, егетләренә тамагын ертаерта кычкырып, иң арттан юырта иде.

Шулай куышып барып, Майлысурга дүрт-биш чакрым калганда, алдына утыз-кырык кешеле ике отряд килеп чыгып камарга омтылгач, Гомәр түрә әтәчләре бөтенләй югалып калды. Атаманнары:

— Нәрсә карап каттыгыз, ут яудырыгыз! Артыбызда Тайчым үзе, көньякта кеше әзрәк, шунда ургылып, сафларын өзеп чыгып китик! Атыгыз!! — дип үкерде.

Кеше әз якка таба чаба башлаганнар гына иде, алгы яктан яңгыраган мылтык тавышы тагын күпләрне сискәндерде. Шулай да атышырга тотындылар. Ул арада Тайчым егетләре байгураларны бөтенләй чолгап алды һәм сафны ерып үтәрлек якны да каплап куйды. Ике арага килеп кергән Тайчым илчесе:

— Егетләр, барыгыз да казакъ баласы, гүй, — дип кычкырды. — Ачкүз Николай патшадан ярлы егетләрне аралап алып калабыз, дип Тайчым батыр күтәрелде. Аңа каршы ук атуыгыз үзегезгә каршы ату ул. Адашып йөрү. Мылтыкларыгызны алып безгә кушылыгыз, кушылмаганнарыгыз бу капчыктан исән котылмаячак, камалышта калуыгызны үзегез дә күргәнсез. Уйлагыз, бер сәгать вакыт бирәбез. Безгә кушылучылар Караболакка якынлашучы патша гаскәренә каршы сугышка китәчәк!

Тайчым вәкиленең мөрәҗәгате байларга ияргәннәрне төрле уйга салды, дулкынландырды, икеләндерде, ахырда алгы сафтагылар Тайчымга биреләргә кузгалды, аларга арттагылар да кушылды. Байларны, Гомәр түрәне ташларга кыймаган кечкенә төркем генә уртада торып калды. Дошманның бер өлеше үз якларына чыгу белән, Тайчым егетләре байларны тиз тотып алдылар һәм аларны бер-берсенә бәйләгәч, корбаннарны барлый башладылар. Унлап кешеләре авыр, тагын бер ишесе җиңел яраланган икән. Аларга ярдәм күрсәткәч, Тайчым Гомәр түрә котырыгына ирелгән иратны сафтан аерып чыгарды да:

— Менә, агай-энеләр, сезнең кулдан унлап кеше җәрәхәт алган, бәлки үлеп тә китәрләр, — диде. — Тик мин сездән үч алмыйм. Байлар коткысына бирелеп, үз ишләреңнең кемнәр икәнен белмәү аркасында килеп чыкты, гүй, бу фаҗига. Шуңлыктан, гөнаһларыгызны кичерәм, авылларыгызга кайтып китегез. Ә кан түгелүгә сәбәпче булган түрәләрегезне алып калып, тиешле җәзаларын бирербез. Барыгыз!

Гаеплеләрнең берсе:

— Тайчәкә, ни күрсәк тә бергә күрик, авылга кайтып анда ни кылабыз, артыбыз-

дан гаскәр килсә, безне барыбер тынычлыкта калдырмаячак. Нишләтсәң дә, безне үзеңә ал, — диде.

— Сорамагыз, безгә кушылганнан соң да, бүген булмаса иртәгә, арада дау чыгуы мөмкин. Яраланган абый-энеләрнең баласен сездән күрәчәкләр,— дип, Тайчын аларны авылларына таратты.

Әсир төшүчеләрнең байтагын азат иткәч, эш байларга килеп терәлде. Алар арасыннан да начарлыгы тимәгәннәре кайтарып җибәрелде. Агымбай, Сагындык, Кужак, Бирдән, Куйчыбай — бишесе дә кулга алынды. Куйчыбай үзе бай булмаса да, мал ияләренә куштанлыгы белән атаклы зат иде. Өер житәкчесе Гомәр түрә качып өлгергән, аны бер төркем егет куа киткән иде.

Бу биш кешене элек чыгарылган карар буенча җәзага тартып, мәетләрен утка ташлагач, Тайчым отряды авылына әйләнеп кайтты. Качкан Гомәрне куа киткән төркем дә, байны өендә кулга төшереп үтергәч, отрядка килеп кушылды.

Тайчым байлар белән бәрелешкән чакта Караболактан патша солдатлары юлга чыккан иде инде. Аларның бүген-иртәгә Җомагазы батырга һөҗүм итү ихтималы бар иде. Тайчым тирмә-чатырларны яңадан корып, яңа кешеләр җыеп урдасын көчәйтергә кереште. Әчке дошманны җиңгән егетләрнең күңеле күтәрелгән, алар көрәш, ат чабышларын уздырып, шатлыкларын кая куярга белмәде. Тайчым, өлкәннәрне үз чатырына җыйнап, яңадан киңәш-табыш итәргә булды.

— Бер эшне бетердек. Хәзер инде алдыбызда житдирәк дошман. Николай патша гаскәрен теге яктан немецләр тар-мар итә икән. Шушы рәвешчә бераз вакыт чыдасак, ят җирләргә китүдән исән-аман котылыр идек. Ничек итеп? Бу җиңел эш түгел. Байлар белән бәрелешүдән соң безгә чигенер юл да калмады, гүй. Аманкилде җибәргән боерык буенча, Ыргыздан Тургайга юлга чыккан патша гаскәрен тоткарлау безнең бурыч. Аны үтәми кала алмыйбыз. Отрядыбызның күпчелек өлешен аларга каршы җибәреп, йөз илле егет белән мин үзем Җомагазыга булышырга китмәкче. Монда калучылар Тургай юлына ия булыгыз. Мин иртәгә кузгалам. Акпан белән Баймагамбит икегез, Аманкилдегә барып, мондагы хәлләрне хәбәр итегез. Сагынай, син Айжаркын батырга барып, хәлләрен белешеп кайт. Ул — Кинҗәгара баш күтәрүчеләре житәкчесе, хәлләре мөшкелләнсә, булышырбыз.

Барысы да көрәшне дәвам итәргә әзер иде.

Ыргыз шәһәре. Җиргә төшкәнче тәкерек ката торган чатлама суык. Бугазга килеп терәлгән ашыгыч эше булмаса, мондый көнне кеше урамга сыңар аягын да атламас. Әмма җаны тере затларның һәммәсе бүген күпер төбенә җыйналып, ерактан каралып күренгән бер төркем кешегә күзләрен теккән. Җыйналган халыкның алгы сафында бер өязгә караган ундүрт волостьның «хөрмәтлеләре» — волость башлыклары, байлар, алардан да алда — шәһәрнең власть ияләре Каров, Кузьмин, Шубин, Станкович. Барысы да гөр килеп сөйләшә. Алгы сафтагы аксөякләрнең ни сөйләшүен кем белсен, алар янына казакъ адәме якынлаша да алмый. «Хөрмәтле» дигәннәребез үзләре дә әдәп саклап, яхшатлыланып бер якта тәркем булып тора.

«Хөрмәтлеләр» шәһәр түрәләренең колакларына керсен, дип юри сөйлиме, әллә күптәннән җыелып килгән ачулары эчләренә сыймыймы, янау, сүгенү авазлары тынмый. Волость башлыгы Такач:

— Менә шулай ул, агымсу да бер туктый, дигәннәр. Чиру җыйнап, патша хәзрәтләренә каршы мылтык күтәрсәң, әҗерен дә күрәсең! Илнең могтәбәр затларын аяк астына салып, бераүләрнең ата-бабадан мирас булып килгән мал-мөлкәтен талап гидай-апаканатларга өләшкән юлбасар, инде нишләрсең икән? Кулга төштең, гүй, азгын! — дип тавышын күтәрде дә, сүземне ишеттеләрме икән дигәндәй, кокардалы галиҗәнабләргә күз ташлады.

— Тайчым дигән исемне быел гына ишетүем, ниндирәк бәндә иде соң ул элек?— дип сорады ерак илнең бер бае.

— Улмы? Нәрсәсен сорыйсың аның, адәм баласы дип әйтергә дә тел бармый, йөзе караны, — диде Такач кайнарланып. — Безнең Кызылҗар ягын бөлдергән дә шул Тайчым, гүй. Үзе шикелле сукбайларны, ач-ялангач тинтәкләрне котыртып, шулардан бер шайкы туплап, илнең иң яхшы җәйләүләренә йорт салып, иген игә

башлады. Җәйләүгә чыкканнарның терлегенә көтүлек бирми, кырына керсә, малларын тотып, көтүчесен кыйнап, өяз, губернадан килгән боерыкларны санга сукмый, унбиш елдан бирле биләребезне зар елаткан кабәхәт Тайчым, әнә, якынлашып килгән тоткыннар арасында хәзер!

— И-и, алай булгач үзенә лаеклы җәзасын алган инде, явыз!

Тагын кайберәүләр Такачтан:

— Ул яман батыр булып ни түнтәрде соң? — дип сорады.

— Зыяны әз тимәде аның. Тугыз йөзләп кыйбласыз гидайны җыйнап, аларга байларның биш-алты йөз баш атын алып биреп, кыш буе тегендә-монда чабып, малларны тәмам эштән чыгарды. Купме сугым, күпме ашамлык, утын, печән, кием-салым тотса — шуларның барысы да байлардан тартып алынды, гуй. Хөрмәтле ил агаларыннан алты кешене тотып үтерде. Бер якта, Җомагазыга кушылып, патша гаскәрләре белән сугышты, икенче якта, Ыргыздан Тургайга баручы солдатларның юлын бикләп, аларны харап итте. Күп гаскәр чыгып, барлык бозык халыкны акылга утырткачы ирек ачып йөргән иде, менә, ходайга шөкер, үзе дә эләккән, — дип, Такач түрә, киек каздай бер-бер артлы тезелеп, алдан-арттан мылтыклы солдатлар саны астында күпергә таба атлаган кырыклап кешегә ишарәләде.

Тоткыннарның куллары артка каерылып бәйләнгән иде. Алар күпергә кергәндә, Такач түрә, як-ягына күз атып:

— Җәмәгать, зобаныйлардан үчегезне алып калыгыз! — дип кычкырды. — Бу кадәр матур кыяфәттә Тайчым гел кулыгызга төшмәс!

Байгуралар төркемен ияртеп, ул беренче булып тоткыннарга ташланды һәм күпернең бирге ягына чыккан бер кул-аягы богаулы әсирне ерткычларга кыйнау башланды. Монда кемне кем органын белерлек түгел иде, алдагылар дөмбәсләгәч, кызык күрергә килгән арттагылар да, алырлык үчләре булмаса да, өстерәүчеләргә ияреп, мин дә коры калмыйм әле дигәндәй, «юлбасарлар» өстендә йодрык уйнатырга тотынды.

Хәле китеп һуштан язган Тайчымны Кышлаубай, Җылкама, Җылкыбай исемле өч улы һәм утыз алты иптәше белән бергә, сөйрәп килеп, Ыргыз төрмәсенә ташладылар. Баш күтәрүчеләр яндырган биш байгура мәетен сыйныфташлары Майлысурның матур бер җиренә күчереп яңадан җирләп, барысына бер уртак һәйкәл салды һәм аны «Биш шәһит» дип атадылар.

Шуннан соң озакламый Оренбургтагы «Казакъ» газетасы «Ыргызның кара халкы сайлаган «ханнар» 25 апрельдә хәрби суд тарафыннан атып үтерергә хөкем ителде», дип хәбәр итте. Әмма бу хөкем җиренә җиткерелеп өлгерелмәде — 1917 елның башында халык ачуыннан куркуга төшкән Николай патша «мәрхәмәте» белән Тайчым һәм аның барлык иптәшләре төрмәдән чыгарылды.

Керенский заманында, властька шул ук байлар кереп оялагач, иреккә чыккан Тайчымга илдә тынычлык булмады, үтерелгән алты бай өчен аңардан һәм иптәшләреннән кон — бәхилләтү малы түләттерделәр. Аларны иген иккән җирләреннән үк куарга җыенганда власть большевиклар кулына күчте һәм шунда гына Тайчым, тирәяктагы башка ярлы-ябагай кебек, җиңел сулыш алды.

**Казакъчадан ТӘУФИКЪ ӘЙДИ** тәрҗемәсе.

## Риза Халид

### Кояшка туры

...Мин салкын җилләргә сүз куштым,
Эсседән уңдылар күзләрем.
Ялкыннар йоттым мин сугышта,
Утлардан туды бу сүзләрем.

Кодрәтле кояшның очкыны
Балкыйдыр моң тулы йөрәктә.
Йолдызлы галәмгә чакыра
Яшьлегем, хыяллар, әлбәттә...

Күңелемдә мәңгелек бер шигырь:
Юлыңны кояшка тот туры!
Тик олы максатка тугры ул
Халыкның чын улы, зур улы!

### Ышан син

Сайрар кошлар күптән киттеләр,
Ә син, дустым, һәр көн көтәсең:
Ничә айлар, дисең, үттеләр...
Ник бу айлар акрын үтә соң?!.

Карлар эрер, явар яңгырлар,
Һәм тирә-як яшәргән көнне,
Очып килер, ышан, син, алар
Кичеп кайтыр дәрья, тау, чүлне...

Кайтыр ертып төннәр пәрдәсен,
Суыкларны җиңеп, томанны...
Кайтыр алар шаулап-гөрләшеп,
Алып кайтыр шигъри моңнарны...

*Ленинград.*

ӘХМӘТ ГАДЕЛ тәрҗемәләр

## Эдуард Мостафин

### Күңел күге

Күктә йолдыз оялары...
Кем туздырсын аларны?
Кем менеп кыерсытсын ди
Йолдыз хәтле җаннарны?

Агачта кош оялары...
Җил дә, кул да туздыра.
Яңасын кора да кошлар,
Сызгыра да сыздыра.

Оясыннан чыгып йолдыз
Атыла — яныл кала.
Оясыннан оча да кош
Агачта җаны кала.

Без яндык та, яндырдык та,
Оча-туза сайрадык:
Янсак — йолдыз яктылыгын,
Очсак — канат сайладык.

### Су өстенә йолдыз сибелгән

Су өстенә күктән йолдыз сибелгән.
Чиләк тутырып су алдым мин Иделдән.

Суы белән тулып чыкты йолдызлар.
Уйлап куйдым: төнен, диеп, ялгызлар

Йолдыз булмаган Иделдә нишләрләр?
Юл югалтып, кире якка ишәрләр.

Суда булмаган йолдызлар күктә юк.
Йолдыз тапмый адашканга үпкә юк.

Чиләктәге суны кире бушаттым.
Йолдыз белән дөнья тулды — шаккаттым.

### Эшләр уңга китә

Кулдан китсә бер эш, китә имеш-мимеш:
Кортлы булып чыга син үстергән җимеш.
Синең хатының читкә күз салгалый, имеш...
Кулдан китсә бер эш.

Уңга китсә эшең, үсеп китә кешең:
Таза булып чыга синең черек тешең,
Иртүк сәлам бирә дошман күргән күршең...
Уңга китсә эшең.

Бер чак кулдан китә, бер чак уңга китә.
Шуның берсен күреп кеше хәбәр йөртә.
Чын дусларга, мәйтәм, җирдә нәрсә җитә?!
Эшләр уңга китә.

•

Күңел-күлдә камыш үсә,
Бакылдаша бакалар,
Күңел-күлдә төнбоеклар
Чәчәк атып яталар.

Һәр чакта да якты йолдыз
Булмый күңел йолдызы...
Диңгезгәме төшеп калган
Бабайларның кубызы?

Ул кубызда булган, диләр,
Көйләре дала, тауның,
Яңгыраган ди аңарда
Авазы үткән яуның.

Күңел-күлдә шадра дулкын —
Үги баласы җилнең...
Акчарлаклар бик сак кына
Үрелеп ала җимен.

Күңел-күлдә томан ага,
Ай йөзә чалкан ятып.
Күңел-күлдә тал-тирәкләр
Коена сагыш йотып.

Күл генә булса да күңел,
Сыйдырган диңгез кадәр...
Тик бер давыл җитә монда
Әйтергә яңа хәбәр.

Кирәк чакта оркестрны
Бер кубыз алыштыра...
Балыкчылар килде бугай,
Күлемдә тавыш тора.

## «Иске-москы» бабай. Сугыштан соңгы балалар.

«Иске-москы җыям! Чүпрәк-чапрак.
Иске-москы!»
Иске арба тавышыдай таныш тавыш.
Карты — таныш рәсемдәге шамакайдай...
Уйланырга, балачагым — гаҗәп табыш.
Һәрберебез өйдән нидер эләктергән,
Нидер чәлгән — ямалганмы, ямыйсымы.
Арбадагы бар байлыкка карап каттык,
Әйтерсең лә, чүпрәкче карт варисы без.
Кызыл шарлар, китап, каләм, уенчыклар —
Безгә алар. Чүпрәк бир дә ал барын да.
Уйнамыйча сугышканга бәр кешелек,
Уенчыклар тансык иде җир шарында.
Арба тулып ята — сугышларда тузган
Иске шинель, гимнастерка, галифелар.
Үзебезнең хәлләр исә болай әле:
Безгә кирәк уенчыклар, әлифбалар.
Һава кебек кирәк балчык сандугачлар,
Ә чыннары телгә килә генә иде.
Безгә кирәк сары, зәңгәр, кызыл шарлар,
Кояш яңа башлап көлә генә иде.
Икмәк кебек, ана назы кебек кирәк
Арба янындагы цирк, буш тамаша.
Балалыкны онытмаска чүпрәкченең
Әлифбасын,
Сандугачлар барлап ерак еллар аша.
«Иске-москы» бабай дөнья куйды күптән,—
Хоттабычтай олуг маг, тылсым иясе...
Әмма шунсы хәтергә нык сеңеп калган:
Буаз иде җиккән мәхлук карт биясе.

*Казан*

## Басыйр Рәфиков

### Уй белән Уел

Уел белән Уйның сабырлыгын
Күреп һәркем хәйран калгандыр.
Ничә карты уелып уйга киткән,
Ничә яше уйга талгандыр.

Хыяллары белән хушлашканның,
Дулкыннарга яше тамгандыр...
Өметләре йолдыз булып янган —
Күкрәү өчен кодрәт алгандыр.

●

Хезмәт салган ачыткы,
Корычтан безнең камыр.
Йөзъяшәр наратныкы
Казысаң, безнең тамыр.

...Вөҗдан — намус җитәкче,
Бердәмлектә безнең көч.
Уртак — ил, уртак — язмыш:
Бер сандалда мең чүкеч.

●

Авыр состав оча бәрхет юлдан,
Йоклап яткан җилне уятып,
Хәерле юл теләп кала таулар
Каен кулъяулыгын уйнатып.

Зур йөкләрне көтә ерак Себер —
БАМ төзүче чая егетләр.
Ыргып чыга поезд — артта күпер,
Ярсып сикерешә күбекләр.

---

Уел, Уй — елга исемнәре.

Парад кабул иткән маршал сыман
Үрә катып калган кыя таш.
Курил артларыннан күтәрелеп
Машинистны сәламли кояш...

Сәяхәткә күңелем яшьтән гашыйк,
Юл газабын җиңел кичерәм.
Тик көнләшәм үзем җәяү чакта
Локомотив йөрткән кешедән.

## Аккошларым

— Кая юл тотасыз, аккошларым?
— Аяз таңга, тыныч суларга...
Хәерле юл теләп кулым болгыйм
Сәфәр чыккан кыю кошларга.

Рәхмәт әйтеп калам каурый өчен,
Аны очлап каләм ясармын.
Рәхмәт әйтәм якты сагыш өчен
Аны кушып җырлар язармын.

Кабат-кабат баштан кичерермен
Катлаулы зур тормыш мәгънәсен.
Сезнең тугрылыкны үрнәк итеп
Олылармын сөю вәгъдәсен.

Мин дә сезнең кебек, аккошларым,
Бу тормышка гашыйк бер юлчы.
Мин дә сезнең кебек җир өстендә
Мәхәббәткә юлдаш бер җырчы.

— Кайда юл тотасыз, аккошларым?
— Аяз таңга, тыныч суларга...
Хәерле юл теләп кулым болгыйм
Сәфәр чыккан кыю кошларга.

*Троицк шәһәре*

## Альберт МИФТАХЕТДИНОВ

*Альберт Мифтахетдинов — дистәгә якын проза әсәрләре җыентыгы бастырып чыгарган язучы. 1959 елны ул Киев дәүләт университетының журналистика факультетын тәмамлый һәм Чукоткага китә, бераздан Магаданга күчә. Әдәби эшкә чынлап торып университеттан соң керешә.*

*Ул Магадан комсомолының әдәбият өлкәсендәге премиясе лауреаты. Аерым әсәрләре һәм китаплары поляк, болгар, венгр һәм инглиз телендә басылып чыга.*

*СССР География җәмгыятенең действительный члены Альберт Мифтахетдинов хәзерге көндә Магадан өлкәсе язучылар оешмасының җаваплы секретаре булып эшли.*

# КЕЛЕНЕУТ

ХИКӘЯ



Чукча кызы Келенеут, исерек баштан мылтык тотып, авыл буенча тракторчы Ложкинны куып йөри.

Ложкин исә тәмам хурга калып көртләргә ышыклана-поса аннан кача.

Келенеут абынып егыла, русчалатып зәһәр итеп сүгенә, кулындагы карабинны карга ташлый да йодрыклары белән ирнең артыннан яный һәм, мылтыгын кардан алып, тагын Ложкин артыннан йөгерә.

Авыл тын да алмый аларны күзәтә. Мондый чакта Келенеут кулына эләгүдән курыккан хатын-кызлар тәрәзәдән аерыла алмый көлешәләр.

Бу тамашаны күреп, мин дә кыяр-кыймас кына урамга чыктым, коймага ышыкландым. Келенеут минем яннан үткәндә аңа берничә җылы сүз әйттем, кулыннан карабинын алдым һәм, патроннарын көпшәдән чыгарып, затворын кесәгә салдым.

— И-и-и-а-а! — Келенеут үкереп еларга кереште.

Минә ул аягына торып басты һәм кызарынган усал күзләре белән беравык миңа карап торды, аннан билендәге пычагына үрелде (кынысы буш иде) һәм, карга утырып, кабат еларга тотынды.

Бу минутта аның кыяфәте көлке дә, кызганыч та иде. Хәзер ул көйсез баланы хәтерләтә. Йөзендә баягы ачуның әсәре дә калмады. Мин аны күтәреп торгыздым да өйгә алып кайтып киттем.

Ул боек күзләрен термоска төбәп утыра бирә. Бер генә дә чәй эчәсе килми аның хәзер, ә шәраб-фәлән миндә юк.

— Ну, ни булды?!

Келенеут сулкылдап куйды, пычрак куллары белән күз яшьләрен сөртте.

— ...Ложкин... у-у-у... Ложкин... у-у-у...

— Нинди бетмәгән Ложкин ул? Тукта хәзер үк!

Ул тынып калды. Стенага сөялде. Күзләрен йомды.

Мин, ит җылытып, серкә сыеклаган арада, ул гырылдап йокыга да китте.

Бер кырыйга тире җәеп, аны шунда китереп салдым. Мич ягылмаган, өй салкын иде, әмма мехка төренгән Келенеутка суык тимәс.

*

* *

Мин килеп кергәндә Ложкин әшнәсе Воронцов белән бер шешәне төгәлләп утыра иде.

Ложкин — кечкенә буйлы, поляр төн кебек кара чегән — һәрвакыт шапшак килеш йөри.

Берәрсе мунча хакында төрттерсә, күзләрен мут кысып:

— Без, ирләрнең, эше шул... Безгә бары да бата, эше генә кырын ятып эшләрлек булсын... — ди торган иде ул.

Аннан үзе үк бөгелә-сыгыла көләргә тотына, тешләре елтырый да, күзенең агы күренә, негр мыни, валлаһи менә!

Чибәр кеше Ложкин. Чем-кара, куе бөдрә чәчле. Безнең себер якларына ничек килеп чыккан диген? Бөтен Чукоткага бердәнбер чегән, бүтән андыйны таба алмассың.

Воронцов исә ак чырайлы, сары чәчлеябык кына адәм, аңарда гел спирт бар. Фельдшер була торып, спиртсыз яшә, имеш. Дуслыклары гына менә ничектер сәеррәк — аерым-аерым да бәхетле генә яшәрләр иде.

— Болайга киткәч, бетте синең баш, Ложкин!

— Ха-ха,— Ложкинның авызы ерыла.

— Аңа көлке, ахмак!

Воронцов тыныч кына бүлмә буенча йөренә, сүзгә кушылмый.

— Миңа хәзер барыбер,— ди Ложкин, шатланып. — Ике көннән барыбер моннан ычкынасы! Ул вакытта хуш колхозың, хуш Чукоткаң!!!

— Әйләнеп кайтырсың әле!

— Ю-у-ук...

— Кайтырсың. Синнән шәбрәкләр дә китеп карады... кайтып керделәр.

— Юк!

Ул бармагы белән күкрәк кесәсенә төртеп күрсәтә.

— Менә монда путевка ята, курортка, анда тагын күз күрер. Эш тә табылыр, җылырак урыннан. Аккредитивлар да әлегә җитеп торыр! Безгә ни дә бата, эше генә кырын ятып... Ха-ха!

— Ә Келенеут!?

— Нәрсә Келенеут? Ул кем, миңа хатын мәллә? Законный хатыннан качтым, ә аннан инде китәм дә китәм.

— Ярар, безнең эш түгел,— дип куйды Воронцов.

— Андыйларны мин материкта мильонны табам! — Ложкинның тагын ачуы чыкты.

— Син лучше поселок буенча качып йөрүеңне сөйлә,— дим мин.— Нечего әтәчләнергә!

— Бәлки ул акылдан язгандыр! Исеме дә шундый бит аның [1]... Миңа ни... әйдә миңа ди, тиздән китәсең икән ди...

— Моңарчы йөрдең бит янына, бергә тордыгыз...

— Торса ни. Бүтән кем белән торасың монда? Хәзер теләмим. Ике көннән мин материкта буласы. Күрәсем килми, и все!

— Бәлки аның саубуллашасы килгәндер?

— Беләм мин аның ничек саубуллашасын!

— Куркак син, Ложкин...

---

[1] Кэле — явыз рух (чук.)

— Бер дә куркак түгел. Теләмим. Аңлыйсыңмы? Элек йөрдем, ә хәзер теләмим. Минем хәзер перспективалар икенче!

— Алай икән! — Воронцов караңгы гына елмаеп куйды.

Ложкин да елмаеп:

— Хәзер кайда соң әле ул? — дип сорады.

— Миндә,— дидем мин.

— Менә шәп булган. Үзеңә булсын, яме?

— Рәхмәт. Миңа кирәкми...

— Аңа кирәкми имеш, ә миңа кирәк, аның белән йокларга тиеш,— дип тагын кабынып китте Ложкин.

— Сүз ул турыда түгел, кеше булырга кирәк...

— Шул-шул менә... председатель дә бит, түз азрак, тиздән бозаулый башлыйлар, продуктлар ташыйсы бар... кеше бул, ди... Бәлки мин арганмындыр? Яки теләмимдер?

— ...яки бер кабәхәттер? — дип өстәде Воронцов тыныч кына.

— Ха! Сез нәрсә бүген барыгыз да сырт күпертәсез? Берәрегезгә бурычым бар мәллә?

— Юк. Бурычың булса — китә алмас идең...

— Шул-шул...

Воронцов баягыча тыныч кына бүлмә буенча йөренә.

Мин сәгатькә күз салдым — складка барып аучыларга продуктлар бирергә кирәк. Тиздән караңгы төшәчәк, ә складта ут юк.

* * *

Мин складта брезент, патроннар һәм этләр өчен ит кенә биреп өлгерә алдым. Караңгы төшә башлады, склад ишекләрен ачып куярга туры килде. Үлчәү шкаласы бөтенләй күренми башлагач, шәм дә яндырып карадым, әмма барыбер накладнойлар язарлык түгел иде.

— Калганнарын иртәгә иртән алырсыз, ярыймы? — дип сорадым аучылардан.

Алар риза булып:

— Ярар,— диештеләр һәм китеп тә бардылар.

Бераздан тышка чыксам, урам буйлап алпан-тилпән килүче Ложкинны күреп алдым. Ул өенә кайтып бара иде. Димәк, склад янынннан үтәчәк. Ә сукмак янындагы кар көрте күләгәсендә посып утыручы хатын-кыз шөйләнә.

* * *

Авыз эчендә нидер көйли-көйли Ложкин складка да килеп җитте. Шунда артында кемнеңдер:

— Мәй! — дип дәшкәне ишетелде.

Ложкин туктап калды һәм тавыш килгән якка борылды.

Үзеннән биш адымда гына кулына карабин тоткан Келенеутны күрде.

— Син нәрсә, иншләвең бу, Келенеут,— диде Ложкин сагаеп. Ул аңа таба атламакчы булды, әмма Келенеут артка чигенде.

— Складка кер, Ложкин,— диде Келенеут шыпырт кына.— Керсәң — атмыйм. Бер дә атмыйм.

Ложкин борылды да акрын гына атлап склад караңгылыгына керде.

— Тегендә бар, түргә, тиреләр янына.

Болан тиреләре складның түрендә үк иде. Анда җылы, хәтта бөркү. Арттан Келенеут үзе керде, ләкин түргә узмады, шырпы сызып яктыртты да, шәм төпчеге табып, ут кабызды. Ә аннан соң пычагын тартып чыгарды (кендез кынысы буш иде бит, югыйсә), бу аның түшкәләр бүлә торган пычагы иде. Ә тунаганда ул иксенче пычак белән эшли. Анысы тар һәм очлы. Эшкә шунысын алып бара.

Келенеут зур пычакны бүрәнәгә китереп кадады да йөзенә шәм төпчеге утыртты. Барып склад ишеген япты, ишек ябылып бетмәде, ырмауга кар тулган иде.

Бу вакыт Ложкин тын гына тиреләр өстендә утырды.

— Без менә шушында булырбыз,— диде Келенеут.— Без шушында булырбыз,— дип кабатлады ул.

— Юк,— диде Ложкин.

Ул әйкыды шикелле. Келенеут баягыча складның теге башында утыра, тезендә карабин ята. Бу инде бүтән карабин иде, тегесенең затворы минем кесәдә калды бит.

Ложкин сигарет кабызды. Аның кулдары калтырый, шәм ялкыны киң пычак йөзендә, карабинның кара көпшәсендә уйный. Келенеут дәшми. Дәшми утырганда хатын-кыз бәлки нәрсәнедер исенә төшерәдер?

Беренче тапкыр килгәндә Ложкин аның белән тупасрак кыланды. Ул төнне Келенеут озак вакыт йокыга китә алмый ятты, яңагын аның аркасына куеп ятты да ятты ул, уятудан куркып сак кына иренең кулларыннан сыйпады. Ә иртәгесен аңа төнге буе күзенә йокы кермәгән кебек тоелды. Уянып киткәч, өйрәнгән гадәт буенча, инде төш күрүен уйлагангадыр, бәлки. Ә бу төнне ана төш кермәде, шуңа күңелендә бушлык иде — ни кайгы сида, ни шатлык.

Ложкинга кадәр ул берәүне дә белми иде дип әйтү бигүк дөрес булмас иде. Өченче елны пароход белән килгән шат күңелле боцманны ул әле дә хәтерли. Сакаллы яшь полярник та аңа ошый иде, хәзер ул икенче районда кышлый, карта белән дүрт көнлек юл. Кайвакыт аның исенә теге олы яшьләрдәге геология партиясе башлыгы да килеп төшкәли; бу ягымлы кешенең чәчләрен әллә инде еллар агарткан иде, әллә үзе шундый ак — төкя аңлый алмады Келенеут. Ул ирләрнең һәрберсенең үз гадәте, үз холкы бар иде, ә Келенеутны аларга гади кызыксыну тарткан булгандыр, мөгаен. Сагындырмагач, төшләренә кермәгәч — мәхәббәт мени инде ул? Ә төш күрсә, Келенеут бик тә куана иде.

Ә Ложкин аның йөрәгенә үк үтеп керде. Аның турында кайгыртасы килә башлады.

Ложкин китәчәк, бөтенләйгә китәчәк дигән уй бүген иртән үлем куркынычыдай аның йөрәген телеп төшерде.

Телегә кузгалган чакларда Ложкин һәрвакыт аның янына килә иде. Ул бер вакытта да карышмады, авыр сүз әйтмәде. Ә бүген ул, соңгы сәгатьләрне бергә үткәрик дигәч, «юк!» дип баш тартты.

— Чишен,— диде Келенеут тыныч кына.

— Син нәрсә, тилердең мәллә?— дип кычкырды Ложкин.

— Чишен... бөтенләй...

— Карале, матурым, шаярмале, яме! — дип тә карады Ложкин.

Келенеут аягына торып басты. Шәм ялкыны, тибрәнеп, пычак йөзендә, карабин көпшәсендә һәм Келенеутның алышынган күзләрендә чагылып алды. Кинәт мылтык шартлады. Шартлау тавышы складның җылы тынлыгына сеңеп югалды. Пуля Ложкинның баш өстендәге бүрәнәгә кереп утырды.

Ложкин бу мәлне хатынның күзләреннән башканы күрмәде, йөрәге жу итеп китте.

Менә ул ашыкмый гына курткасын салды. Свитерын. Аннан күлмәген.

Келенеут мылтыгын һаман төшермәде.

Киез итеген дә салды Ложкин. Чолгауның берсе сүтелгән, икенчесе аягына ябышкан иде. Аннан ул сырган чалбарын салды.

Келенеутның сагаеп кысылган күзләре һаман Ложкинда иде.

— Ну... хәзер нәрсә?— дип куйды ир төшенке тавыш белән.

...Урамнан ишетелгән аяк тавышлары икесен дә сискәндереп җибәрде. Аяк тавышлары якынайганнан якыная иде. Кар шыгырдавы мылтык тавышы булып ишетелә.

Тораташ булып катты Келенеут.

— ...үлчәү...— дип пышылдады ул.— Курортка барасың... Үлчәү...

Мәгънә Ложкинга сүзләр аша түгел, тизрәк телепатия буенча барып җитте.

Кайчандыр Келенеут үзе дә Талаяда булып кайткан иде, Колымада шундый курорт бар, поселок медпунктында путевка алган чакта да, курортның үзенә баргач та, аны үлчәгән нәрсә белгәч бернич тапкыр үлчәгәннәре хәтерендә. Ул чакны гаҗәпләнеп: «Мин ит түгел... Нигә үлчәүгә бастырасыз?» дип көлгән иде бер. Ложкинның курортка китәсен белгәнгә, бу уй яшен тизлегендә башыннан үтте, һәм соңгы минутта ирне хурлыктан коткарып каласы килде.

Ложкин, үлчәүгә басып, рычагны күчергәндәй итә, ә үзе, колагын сагайтып, урамны тыңлый. Аяк тавышлары ераклаша иде.

Келенеут, беренче күргәндәй, Ложкинга төбәлгән.

Шунда кинәт башына сәер уй килеп, анадан тума ирне беренче тапкыр күрә кебек тоелды... Теге чакны, шат күңелле боцманның җайлы каютасында башта ут сүнә, ә бераздан соң алар икәүләшеп кечкенә өстәл янына килеп утыра торганнар иде... Ә Ложкин белән булганнар ничектер хәтердә калмаган. Келенеут гел аннан иртәрәк тора иде, кухняга чыга да берәр нәрсә әзерли, ә ул соңрак уяна, юына, аңа төрле мәзәк сөйли, матур сүзләр әйтеп үсендерә иде.

Ә хәзер ул менә бөкрәеп аның каршында басып тора, майкадан, тез тиңентен трусик... карабин җеппәседәй нечкә аяклар... Үзе үлчәү өстендә...

Келенеут сулыш алды. Сулышы пыркылдап көлгәндәй килеп чыкты.

Бу мәлне Ложкинның һәр күзәнәге хатынның җирәнүен сизә иде.

Келенеут, патронны кептәдән суырып чыгарып, аяк астына ыргытты, ә карабинны сак кына шүрлеккә, ак һәм кызыл ракеталар тутырылган банкалар янына куйды.

Ложкин ашыга-ашыга киенә башлады: кабаланудан кулындагы киеме төшеп киткәли иде. Иелгән башын күтәреп хатынга карарга көче җитмәде. «Менә киеним генә,— дип уйлады ул,— киеним генә...бетерәм... үтерәм... Киеним генә...»

Киенеп бетергәч, ул үлчәүгә килеп утырды да идәнгә төбәлгән килеш тарта башлады. Үзен юк итеп кенә бу хатыннан котыла алачагын белми иде әле ул.

Русчадан СОЛТАН ШӘМСИ тәрҗемәсе.

# ИДАРӘ ИТҮ: КЕМНӘР ҺӘМ НИЧЕК?

*Заман хуҗалык җитәкчесе партиянең экономик политикасы асылын яхшы аңларга һәм дәүләтчә киң фикер йөртергә, производство резервларыннан тулысынча файдаланырга тиеш.*

**Л. И. Брежнев.**

## Фәннән — тормышка

КамАЗда СССР Автомобиль промышленносте министрлыгының җитәкче хезмәткәрләр һәм белгечләр осталыгын күтәрүне максат итеп куйган институт филиалы эшли. Биредә әзлекле рәвештә урта буын җитәкчеләр — мастерлар, производство участоклары башлыклары һәм аларның урынбасарлары, цех начальниклары һәм аларның урынбасарлары күнекмә ала. Югары буын институты исә Мәскәүдә эшли. Безнең филиалда күнекмә узу — автомобиль төзелеше тарихы һәм теориясе, техника һәм җитештерү технологиясенең яңа казанышлары, хезмәтне оештыру һәм эш хакы түләүнең иң яңа тәртипләре, партиянең җәмгыять экономикасын үстерүдәге политикасы, идарә итү теориясе, шул исәптән җитәкчелек итүнең төп стильләре һәм ысуллары белән тирәнтен танышу дигән сүз ул.

Идарә итүнең социологик һәм психологик нигезләрен өйрәнүчеләр семинарлары кызыклы үтә. Шулай булмыйни! Аудиториядә производство «казанында» кайнаган җитәкчеләр утыра. Алар инде күпне күргән, күпне белә, шактый яңалыкларны биредә — КамАЗда «ачканнар». Аларның шулай ук биредәге тәртипләрне, канун, стиль һәм ысулларны илебезнең башка зур яки кечкенә предприятиеләре белән чагыштырып карау мөмкинлекләре бар.

Мәгълүм булганча, идарә итүнең демократик һәм авторитар төрләре, стильләре шактый киң таралган. Авторитар стильгә тәгаллек һәм бер үк вакытта кырыслык, каршы килүләр белән килешмәүчәнлек хас: җитәкче һәр хезмәткәргә төгәл бурыч билгели һәм аның һичсүзсез үтәлүен таләп итә. Ул кыю һәм карарларны мөстәкыйль рәвештә кабул итә, властьны тулысынча үз кулына алудан курыкмый, тәвәккәл. Ләкин, бөтен эшне үз кулына алып, ул үз буйсынуындагы җитәкчеләрне узып, хәтта эшчеләргә дә күрсәтмә бирә, кайчакта ярдәмчеләренең фикерен дә тыңламый, бик еш кына аерым факторлар белән исәпләшмичә карарлар кабул итә.

Демократик җитәкчелек стиленә идарә итүгә күпчелек хезмәткәрләрне катнаштыру хас. Җитәкче-демократ карарлар әзерләгәндә һәм кабул иткәндә үз буйсынуындагы кешеләрнең киңәшләрен һәм тәкъдимнәрен файдаланып кына калмый, алар-

---

Ахыры. Башы 9 нчы санда.

да шулай ук иҗтимагый активлык һәм иҗат дәрте уята. Ул ярдәмчесенең сәләтен һәм тәҗрибәсен исәпкә алып эш итә. Максатчан тикшеренүләр һәм тәҗрибә күрсәткәнчә, демократик идарә итү шартларында коллективның җәмәгать оешмалары өчен дә киң мөмкинлекләр ачыла, тәнкыйть һәм үзара тәнкыйть тиешле югарылыкта, күп очракта әйбәт социаль-психологик климат, үзара дуслык мөнәсәбәтләре барлыкка килә. Димәк, демократик стиль яхшырак.

Тик авторитар җитәкчелек төрен дә тискәре генә бәяләргә ярамый. Моны семинар укуларда катнашучылар да яхшы аңлыйлар иде. Мәгълүм эш шартларында ул бердәнбер яраклы һәм үзен аклаган стиль. Әйтик, үзәктән еракта, утрауларда, корабльдә яшәгәндә һәм эшләгәндә, шулай ук, әгәр коллективта бер-берсе белән яңа гына очрашкан төрледән-төрле халык җыелган булса, мондый шартларда демократик стиль ярап бетми.

Демократик идарә төре күбрәк социалистик иҗтимагый мөнәсәбәтләрнең рухына һәм асылына туры килә. һәм авторитаризм куллану гадәттән тыш зарур булмаганда, безнең карашыбызча, совет җитәкчесе демократик стильгә таянып эш итәргә тиеш. Дөрес, демократик стильне кулланышка кертүе авыррак, чөнки ул күбрәк кешеләрне өйрәнү һәм белүне, аларның сәләт һәм мөмкинлекләреннән идарә эшчәнлегендә нәтиҗәле файдалануны таләп итә.

Демократик эш стильле җитәкче, кирәк булганда, авторитар нормаларны да куллана ала, чөнки бу эш төре гадирәк. Авторитар җитәкче, кагыйдә буларак, демократик стильгә күчә алмый. Мәгаен, профессор А. Г. Ковалевның «Кайчак авторитарлык шәхеснең профессиональ компетентсызлыгын яисә җитәкчелек эшчәнлегенә сәләтсезлеген яшерә торган битлек булып кына хезмәт итә» дигән фикере белән килешми мөмкин түгелдер. Ул, шулай ук, зур абруй һәм аның алдында даими баш ию дә авторитар җитәкче формалаштыруга китерә дигән фикер белдерә.

Мастерлар һәм начальниклар, семинар барышында мөнә шушы белемнәрне үзләштереп, үз тәҗрибәләре нигезендә эшләрендәге мәгълүм хәлләрне тикшерделәр. һәм тулысы белән демократ яисә авторитар җитәкченең бик сирәк күренеш булуын әйттеләр.

Шулай булуга да карамастан, мин аларга КамАЗдагы үземә таныш бер җитәкче хакында сөйләп бирдем, исем-фамилиясен атамыйча гына, аның эш стиленә хас кайбер мисаллар китердем. Әңгәмәдәшләрем сүзнең кем турында барганлыгына тиз төшенеп алдылар һәм аның тулысынча авторитар җитәкче булганлыгы белән килештеләр. Менә, кыскача, ул кешенең эш стиле: иртәдән кичкә кадәр тынгы белми — хәрәкәттә. Көн дәвамында күп эш эшләргә сәләтле. Уннарча кешегә күрсәтмә бирергә һәм аларның эш хакындагы хисапларын тыңларга өлгерә. Аның янында һәрвакыт ыгы-зыгы. Информация сорап, берәр мәсьәләне җайга салуны үтенеп, докладлар белән аңа гына мөрәҗәгать итәләр, чөнки мәсьәләне ул гына хәл итә, бөтен власть аның кулында. Беркемнең дә аның тыныч кына сөйләшкәнен күргәне юк, ул күрсәтмә яисә киңәш биргәндә дә тавышын күтәрә. Ул — бердәнбер командир, калганнар барысы да — сүз тыңлаучылар, эш башкаручылар. Ул кешеләргә өстән карый, теле тупас, үз фикеренә каршы килүчеләрнең «җанын ала». Әзерлек, җир эшләре, төзелеш чорында аның зур хезмәт урынындагы кеше булганлыгын әле бирәдә күпләр хәтерли. Бу чорга нәрсәнедер җир тишегеннән табу, кемнедер мәҗбүр итү хас. Башлангыч чорда басым ясау да уңай нәтиҗә бирә, ә кимчелекләр ярылып ятмый. һәм шунысы кызыклы: ул чакта аңа эшчеләр һәм ярдәмчеләр дә түзгән һәм аның кимсетүләрен дә гафу иткән; аның дәртле холкы файда китергән. Ә менә җиһазларны көйләү-җибәрү эшләре башлангач, технология процессларына тирәнтен төшенергә кирәк була башлагач, «әйдә-әйдә» стиле көткән нәтиҗәне бирми һәм бу кешенең энергиясе файдага эшләми, киресенчә, зыянлы яккарак тарта башлый. Авторитар идарәгә, кычкыруны һәм тупас сүзләргә аның урынбасарлары һәм эшчеләр дә түзмәс була. Нәтиҗәдә аны авторитарлык «кими төшә» торган эшкә күчерәләр.

КамАЗдагы моның кебек хәлләрне тикшереп, квалификацияне күтәрү институты филиалында шөгыльләнүче җитәкчеләр бик кызыклы һәм тирән фикерләр әйтте, зирәк һәм үткен күзәтүләреннән чыгып, үзләре өчен файдалы нәтиҗәләр ясады. Бу семинар дәреснең максаты әлеге җитәкчеләрне катлаулы социаль процессларга партиячел якын килеп, социаль-политик анализ ясарга өйрәтү иде бит.

## Практикның төпле фикере

1977—1978 еллар КамАЗында кайсы стиль тотрыклырак соң? Стильләрнең үзгәрүе мөмкинме? Бу мәсьәләләргә аныклык кертү өчен, дәресләрдәге кайбер чыгышлардан өзекләр китерик.

1) Кыска һәм катгый:

«Тәртипсезлекләрне бары тик авторитар җитәкчелек стиле белән генә җиңәргә мөмкин. Демократик идарә итү стиле өчен башта аңа ныклы җирлек әзерләргә кирәк».

2) Көчле субъективизмга бирелеп:

«Чагыла торган авторитаризм күренешләре — КамАЗ производствосындагы урта һәм түбән буын җитәкчеләрнең компетентсызлыгы нәтиҗәсе. Яхшы производство башлыклары иске шәһәрләрдән Чаллыга килмәячәк, чөнки биредә иске шәһәрләрдәге кебек уңайлыклар юк. Бирегә начар сыйфатлы «кеше материалы»ның гына килүе ихтимал. Авторитаризм демократик стильгә юл бирергә тиеш, эш башкаручылар авторитар стильгә озак түзә алмый».

3) Югарыдагы ораторлар чыгышына карата тәҗрибәле практикның төпле фикере:

«КамАЗда төзелеш башыннан алып хәзергә кадәр дәвам итә торган авторитар, катгый идарә итү төре объектив шартлар белән, аерым алганда, кыска вакытта зур эш күләме башкару зарурлыгы белән аңлатыла. Моңарчы мондый кызу темпларның беркайда да булганы юк иде ич! Демократияләштерергә, бәхәсләшергә вакыт калмый, тапшырылган эшне берсүзсез үтәп чыгарга кирәк. Моны аңлау гаять зур әһәмияткә ия. Идарә кадрларының аеруча еш алышынуы нәкъ менә шуны аңламау һәм боерыкларны үтәргә теләмәүдән, яисә кайберәүләрнең биредәге темпларга чыдый алмауларыннан килә. Нәтиҗәдә кешеләр эштән китә».

4) Шартларны исәпкә алып:

«Җитәкчелек стильләренең табигатен дөрес билгеләү өчен аның сәбәпләрен һәм шартларын җентекләп тикшерергә кирәк. Шуңарга игътибар итегез: кайбер категория эшчеләр авторитар басымга чыдамрак, ә кайберләре түзми. Ни өчен? Үз сүзләре белән әйткәндә, «тылсыз», ягъни өлегә квартиры, балалар бакчасы, теләгән разряды булмаган эшчеләр башлыкларның каты басымына түземлерәк. Ә калганнары каты идарә итү төрләренә түземсезрәк, алар белән демократик «телдә» сөйләшергә туры килә. Күпчелек эшчеләр «тыл» белән тәэмин ителгәч, авторитар стиль демократизмга юл бирәчәк дип уйлый. Моңа эшчеләр мәҗбүр итәчәк».

Бу чыгыш ясаучы тулысынча хаклы булмаса да, ул гаҗәп күзәтүчән һәм конкрет фикер йөртә. Дисциплина бозучылар, эшкә соңга калучылар, эчү белән мавыгучылар квартиры юк кешеләр арасында чагыштырмача азрак. Социологлар шундый күренешне күзәтте: эшкәләүчеләр дә квартир алганчы түземлелек күрсәтә — югыйсә, чиратны арткарак чигерүләре ихтимал.

Кызганычка каршы, семинарда чыгыш ясаучыларның берсе дә һаман саен белемлерәк була барган эшчеләрнең югары культуралы мөгамәләгә омтылуын идарәнең кырыс төрләре белән килешмәүчәнлек сәбәбе дип күрсәтеп үтмәде. Ә бу — төп сәбәпләрнең берсе. КамАЗ эшче тулай торакларының берсендә «Син үз җитәкчеңне нинди кеше итеп күрергә телисең?» дигән темага үткәрелгән бәхәс тә шуны раслады. Диспутны комсомол комитеты һәм социологлар оештырды. «Комачауламасыннар өчен», җитәкчеләрнең берсе дә чакырылмады. Хәтергә аеруча нык уелып калганы — бер яшь эшченең чыгышы: «Миңа 22 яшь, урта белемем һәм дүртенче разрядым бар. Үз эшемне беләм, яратам. Әгәр мастер миңа тик тормасын дип кенә юк-бар эш куша икән, мин аны эшләмим. Янау, кычкыру, басым ясау да файдасыз. Эшнең кирәкле һәм файдалы икәнен беләм икән, мине үгетләп торасы юк, берсүзсез вакытында эшлим»,— диде ул. Чыгыш ясаучыларның күпчелеге аны яклады. Димәк, мондый кешеләр авторитаризмны бик авыр кабул итә.

Семинардагы тагын кайбер чыгышларны күздән кичерик.

5) Тирәнгәрәк карау омтылышы:

«Идарә итү төре нигезләре һәм табигате турында мин башкачарак фикердә торам. Әйтик, «аста», «мастер-эшче» дәрәҗәсендә авторитаризм бик аз, гомумән, эштә

демократик мөнәсәбәтләр киң кулланыла. Киресенчә, югары инстанцияләрдә авторитар мөнәсәбәт һәм идарә кануннары өчен мөмкинлекләр күбрәк. Моның хикмәте шунда, «өстә» эшчәнлеге белән туры мәгънәле һәм формасы белән төгәл һәм катгый боерыклар, күрсәтмәләр бирелә. Ә бу императивлар «аста», цех начальнигыннан башлап, тагын да түбәнрәк рангта, ягъни турыдан-туры материаль житештерү өлкәсендә тормышка ашырыла. Биредә «өстәгеләр» идеясен гамәлгә ашыру чараларын эзләү башлана. Бу исә ижади, бер мәсьәләгә карата төрле, хәтта капма-каршы фикерләр дә белдерелә торган процесс. Бу демократизм түгелмени? Иң уңышлы вариант табылгач, демократизм бу эшне иң яхшы башкара торган кешене сайлап алырга да мөмкинлек бирә. Ә ахыргы чиктә коллективка тапшырылган бу бурыч уртак тырышлык белән гамәлгә ашырылыр».

Идарә стильләрен бүлү логикасы турындагы бу чыгыш бәхәсне җанландырып җибәрде, семинарда катнашучылар берсеннән-берсе кызыклырак фикерләр белдерә башладылар.

6) Катгыйлек һәм фәлсәфилек катнашмасы:

«Өстәге» авторитаризм «җитәкченең җитәкче» белән эш йөртүеннән килә. Аларның ранглары гына башка. Тик бу рангларның төрлелеге власть һәм аңа буйсыну мөнәсәбәтләрен билгели, ягъни аларның берсенә күрсәтмә бирү, икенчеләренә аны башкару хокукы бирелгән. Бу югары буында массовыйлык, «демос», җәмәгатьчелек даирәсе бик кечкенә. Бу дәрәҗәдә аерым кешеләрнең «эшкә түгел, аерым кешегә хезмәт итүе» кебек мөнәсәбәтләр барлыкка килүе ихтимал дип тә әйтергә мөмкин. «Астагы» мөнәсәбәтләр табигате исә аерым кешеләргә түгел, уртак эшкә хезмәт итү зарурлыгы белән билгеләнә. «Өстә» аерым шәхескә хезмәт итү яхшы һәм югары бәяләнергә мөмкин, «астагы» эш исә үлчәп янсә санап карарга мөмкин булган ахыргы нәтиҗә — җитештерелгән продукция яки башка күрсәткечләр белән бәяләнә».

7, 8) Практиклар зирәклегенең чиге юк:

«Кешеләрне «кысу» янсә өйрәтү сәләте булса, «өстә» компетентсыз кеше дә озак утыра ала. «Үзе эшли белмәүче, бүтәннәрне эшкә өйрәтә. Әгәр өйрәтә белмәсә, югарырак күтәрелә һәм кешеләрне ничек өйрәтергә кирәклеген өйрәтә башлый». КамАЗда бу анекдот тикмәгә сөйләнми. Материаль җитештерү сферасында исә мондый компетентсызлыкны битлеккә яшереп булмый: станок янына баскан кеше, станокны белмәсә эшли алмый, тимерченең продукция бирмәве аның булдыксызлыгыннан, я эшләргә теләмәвеннән килә... Биредә эшлеклелекне реаль продуктка карап бәялиләр. Менә шуңа күрә мастер янсә цех башлыгының эшчегә мөнәсәбәте ихтирам хисе белән дә белдерелә. Димәк, бу очракта демократизм эшкә ихтирам буларак чагылыш таба».

Һәм, ниһаять, мастер сүз ала һәм, үз тәҗрибәсеннән чыгып, бәхәскә йомгак ясый: «Производство участогында авторитаризм белән эш итүе бик кыен: эшчеләргә янау янсә аларны нәрсә беләндер куркыту яхшы бетми — кеше эштән китә, аның урынына шундый ук яхшы белгеч табасы була. Ә «өстәге» җитәкче кайвакыт үзенең кул астындагыларга янай да ала, чөнки аның урынбасарына башка урынга китүе куркыныч, яңа эш табуы да кыенрак: икенче урында минем җитәкчелек итү сәләтенә ничек карарлар бит дигән сорау аны җитди уйланырга мәҗбүр итә».

Фикер алышуларны туктатып, семинар дәресен тәмамларга вакыт җиткәч, иң соңгысы итеп, тикшерүгә саф социологик мәсьәлә куела: бүгенге көндә типик камазчы бармы? Ягъни КамАЗ производствосы үзенә кирәкле җитәкче һәм башкаручыны формалаштыра алганмы, юкмы? Билгеле, «камазчы» дигән төшенчә заманның иң яңа җиһазлары һәм технология процесслары, шулай ук производствоны оештыруның яңа формалары таләпләренә җавап бирә торган кешене күздә тота. Әлеге сорауларга җаваплар бер төрле булды: юк, әле КамАЗ кешесе «тумаган». Бүгенге производство әле аның үзе өчен дә типик түгел. Баһадирның икенче чираты төзелеп бетү алдында тора, тик җайлап бетерәсе эшләр бик күп әле, тиешле дәрәҗәдә югары җитештерүчән ритм җитенкерәми. Димәк, югары дисциплина һәм җитештерү культурасы сыйфатларын гәүдәләндерәчәк типик камазчы да соңрак туачак.

Мондый фикер белән тулысынча килешмәсәм дә, дәшмәдем — чөнки алдымда чын камазчылар утырганына ышана идем: аларга кимчелекләр белән килешмәүчәнлек, тәнкыйтьчел фикер йөртү хас һәм бу сыйфат күпчелек дәрәҗәдә биредә фор-

малашкан. Камазчы — кыю фикерле, тирән анализлаучы, үз эшенә бирелгән, тырыш кеше. Аның ялгышуы, нәрсәгәдер дөрес бәя бирмәве ихтимал, ләкин ул үз эшенә, КамАЗга һич тә битараф түгел!

Ә идарә стильләренә килгәндә, иң дөрес стиль — үз эшеңә бирелгәнлек. Дөрес, һәр кешенең үз идарә ысулы булуы мөмкин, ләкин идарә итү ленинчыл идарә стиленнән читкә чыкмаска тиеш. Ә ленинчыл стиль — барыннан да элек, эшкә һәм хезмәт кешеләре интересларына тугрылык, эшлеклелек һәм оешканлык ул.

КамАЗда хәзергәчә төрле стильләрнең янәшә яшәве бер дә гаҗәп түгел. Бирегә җитәкчеләрнең күп санлы армиясе илебезнең төрле урыннарыннан тупланды һәм һәркайсы үз тәҗрибәсен, үз ысулын алып килде. Аларның бәрелешен бер-берсен аңлап җиткермәү һәм эш киеренкелеге китереп чыгаруы ихтимал. Әмма бу КамАЗның үзенә, уртак эшкә зыян китерергә тиеш түгел. Менә шунысы әеруча куркыныч.

«Минем зур тормыш тәҗрибәле танышым «технарь» В. Г. Носков — мин типик камазчы дип саный торган кешеләрнең берсе. Ул болай фикер йөртә: «Ике һава агымы очрашкач, җил-давыл чыга. Биредә, КамАЗда, иске һәм яңа технология һәм производство принциплары, иске гадәтләр һәм яңа нормалар очраша. Ә бу бәрелешләр — чын кешеләр дәрте бәрелеше!» — диде бер камазчы.

Виктор Гурьянович Носков белән мин берничә тапкыр очраштым. Башта ул станоклар ватылу, җиһазларның сафтан чыгу сәбәпләрен ачыклау белән шөгыльләнә иде — биредәге уникаль станокларның, миллионнарча сумлык пресcларның кыйммәтен белә. Чөнки ул технарь, югары класслы белгеч... Әңгәмәне дәвам итү өчен аны икенче тапкыр шактый озак эзләргә туры килде: ул инде башка эшкә күчерелгән, станокларның сафтан чыгу сәбәпләрен анықлау белән шөгыльләнми иде. Тик кимчелекләр аны элеккечә үк тирәнтен борчуын белдерде: «Ветеран-камазчыларны биредән ничек тә җибәрмәскә тырышасы иде. Аның урынына шундый ук белгеч әзерләү өчен ике-өч ел вакыт кирәк булачак лабаса. Һәр станокта югары квалификацияле ике станокчы булырга тиеш. Станоклар меңнәрчә — димәк, станокчылар үн меңнәрчә кирәк. Ә алар әлегә аз, шулай да китәләр, «алтын фонд» китә!.. Кызганычка каршы, инженер-техник хезмәткәрләр, аеруча түбән буын җитәкчеләр, күп китә. Күрәсең, алар берничә ел рәттән киеренке эшләүдән арганнардыр, бераз ял итәргә дә кирәктер. Мондый стильгә чыдамыйлар».

Белмим, бу очракта ул стиль сүзен нинди мәгънәдә куллангандыр, ләкин аның фикер агышы бик аңлашыла һәм шуңа ачыклык кертеп тә үтәргә мөмкин: кемнеңдер тәкъдиме буенча, әйтик, тәҗрибәле механик чакырыла. Әмма аны электроника һәм электрончылар белән эш итәргә куялар. Ә бит ул электроника белгече буларак түгел, механик буларак кына яхшы эшләячәк.

Миңа электрон-хисаплау машиналарын көйләүче Николай Костин: «машина нормаль эшләсен, «алдамасын» өчен, көйләүче аның белән «туганлашырга» тиеш,— дигән иде. — Чөнки һәр машинаның үз көе бар, холкына төшенсәң, аның төзек булмаган җирләрен табуы да җиңел». Менә шушы электрончы-белгечнең җитәкчесе — механикларча фикер йөртүче кеше. Ул аларны бик еш «эшлексезләр» дип атый һәм җиһазлар корылачак урыннарны себерү-җыештыру кебек эшләрдә файдалана — янәсе, нормаль эшче һәрвакыт нәрсәдер кырдырырга, ясарга яисә шөреп борырга тиеш...

Мин үземә таныш фәнни-тикшеренү институты физикларының кысан эш бүлмәләреннән бик еш коридорга чыгып тәмәке тартулары һәм шунда да теге яки бу идея турында фикер алышулары, аннары аны шактый уңышлы тормышка ашырулары турында ишетеп беләм. Аларның эше яхшы барган. Тик җыештыручы апа: «Бу хөрәсәннәр кайчан эшли соң?» — дип мыгырдана икән.

Тагын бер мисал: җитәкче кеше эксперименталь цехка килә һәм: «Менә бу узелны эшләтә башлау өчен сезгә өч көн вакыт бирәм»,— ди. Шул цех белгечләренең берсе (фамилиясен хәтерләмим) миңа болай дип зарланды: «Биредә ашыгырга ярамый, бу машинаны, бала кебек итеп, кадерләп «үстерергә» кирәк. Ул гасырлар буе торырга тиеш. Файдаланугa дефектлар белән тапшырсак, ул гомер буе гадәтсез бала кебек булачак».

Стильләр бәрелеше дәвам итә. Дөрес, КамАЗ вакыты белән үзенә генә хас бердәм эш стиле булдырыр. һәм ул демократик стильнең бер төре булырга тиеш.

Моның өчен биредә хәзер менә шундый җирлек бар:

1) Күпчелек производстволарда югары квалификацияле эшчеләр эшли. Ул — социаль өлгергән шәхес тибы, инженерларча фикер йөртә торган белгеч. Аның белән демократик стильдә. генә идарә итәргә мөмкин.

2) Якындагы бер-ике ел эчендә коллективларның нигезе тәмам ныгыячак, ягъни алар үзләренең тәрбияви ролен үтәү өчен өлгереп җитәчәкләр. Бары тик демократик стиль белән идарә иткәндә генә коллективларны тәрбияви максат өчен файдаланып була. Ләкин әлегә меңнәрчә җитәкчеләр киләчәк стилен формалаштыру дәверендә тупланган тәҗрибәне «үзләре аша» үткәрергә тиешләр. Прогрессив идеяле кешеләргә чын көрәшчеләр дә булырга кирәк. Аларга үз карашларын ныклы эзлеклелек белән яклау өчен бик күп көч сарыф итәргә туры килә. Мәсәлән, Г. Малышев менә шундыйларның берсе. Ул — экономист, КамАЗда ВАЗ системасын кертү өчен үзен кызганмыйча бик күп эш башкарган кеше. Күпме консерваторлар аннан котылырга тырышты, аны кая гына күчермәделәр! Мәсьәләне аңламыйча яисә аңлап та аңа каршы чыгучылар күп булды. Әмма ул бирешмәде: консерваторлар килә торды һәм китә барды, әмма алдынгы система тормышка ашмый калмады. Әйе, көчлеләр җиңә һәм көчлеләр кала.

Борынгылардан килгән бер хакыйкать яши. Аның мәгънәсе шундый: «Әгәр үз идеяңне соңга калып, ягъни күпчелек кешеләр белгәч әйтсәң, синнән көләчәкләр. Бик алдан әйтсәң, киресенчә, син туган җиреңнән сөреләчәксең». Хезмәт оештыру бүлекләренең берсенә башлык В. И. Евтушенко: «Кеше эшкә вакытында килә белергә генә түгел, вакытында кайтып китә дә белергә тиеш. Югыйсә ул рәтләп ял итә алмый, аның икенче көнне хезмәт җитештерүчәнлеге түбән була», — дигән принципны яклаганы һәм тормышка ашырырга тырышканы өчен заманында эшеннән китәргә мәҗбүр булды. Хәзер бу хакыйкатьне КамАЗда күпләр яхшы аңлый.

Төрлечә каршы килүләргә карамастан, моннан берничә ел элек ремонт эшләрен тикшерү һәм планлаштыру, технология җиһазларына хезмәт күрсәтү бүлеге начальнигы В. А. Яковлев үзенең хезмәткәрләре белән автомобиль җыю заводындагы барлык технология җиһазларының нинди хәлдә булуы турындагы оператив информацияне үзәкләштерде. Вакыт белән исәпләшмичә, ул үз куллары белән барлык кирәкле җиһазларны һәм сигнализация урнаштырды. Моңарчы иске җиһазлы предприятиедә эшләп иске эш алымнарына күнеккән җитәкче, табигый ки, Яковлев һәм аның иптәшләре башкарган эшнең никадәр зарурлыгын һәм мөһимлеген аңлап җиткермәячәк.

Наил Фатыйхович — КамАЗ ветераны, ул КамАЗ парткомы секретаре урынбасары булып озак вакыт эшләде. Бу кешенең дәртенә һәм тынгысызлыгына сокланасың. Инде КамАЗ алдындагы бурычларны намус белән үтәп, байтак кешеләр тынычрак урыннарда эшли башлады, ә ул һаман авыр йөкне тәпкә җигелеп тарта һәм шуның белән тормыштан канәгатьләнү таба. Белеме белән журналист, матбугат органнарында да уңышлы эшләгән бу кеше. Һәр эштә, һәр мәсьәләне хәл иткәндә — новатор, алдынгы юлдан баручы. Мин аны төрле тәртипсезлекләрнең, эленке-салынкылыкның, производствода комачаулаучы консерваторларның килешмәүчән дошманы, кимчелекләргә карата төнкыйтьчел фикер йөртүче кеше буларак типик камазчы дип саныйм. Андыйлар — КамАЗның намусы һәм вөҗданы. Алар беркая китми, биредә калалар, КамАЗ андый кешеләрсез яши алмый.

...Чаллыдан нур тасмасыдай булып бетон юллар төрле якларга сузыла. Алар буйлап өр-яңа «КамАЗ»лар чаба. Алар — Татарстан автогигантының төп продукциясе. Кабул ит, Ватан, безнең пәһлеваннарны!

Ләкин гигант заводның баш продукциясе — кеше! Ул биредә кала, аның биредә бик күп эшләр эшлисе бар әле.

Нариман ФӘТХУЛЛИН,
философия фәннәре кандидаты.

Мәрди Рафиков

# ТАШКЫН



1979 елның язында Зөя гомер булмаганча ташыды. Елга кайный, актарыла. Су өстеннән тулып килгән калын, зәңгәрсу бозлар тимер-бетон күпернең баганаларын бертуктаусыз тукмыйлар: дөңк! дөңк! Шуны күтеп һәм табигатьнең күңелле тамашасын карарга күпер өстенә җыелган кешеләр хисләрен яшермичә өзлексез авазланып тора. Нидәндер тоткарланган бозларның кат-катлап өелүләре һәм ватылып яңадан суга гөрселдәүләре кешеләрдә, бигрәк тә малай-шалайда гаҗәпләнү уята, алар тагын бер рәхәт гүләшеп алалар иде.

Зөя иртәнге боздан тәмам ачылган, суы арткан иде.

Ә аннары язның бөтенләй яме китте. Иртән җир өстенә кырау ята. Агачлар басланә. Гөрләвекләр тик әйлә җиткәч кенә бер сөйләшеп алалар да, дәрт юк диган сыман, тагын тынып калалар. Кояшның сүрән нурлары аларны икенче көнне дә озак уята алмый тора.

Ташуның куәтлесен кырда куян ятарлык кар калгач көт диләр. Ул вакытта урман сулары кузгала. Алар, хәйран тамашалар ясап, әуный-әуный төшеләр дә, хәтта елга уйсулыкларына җәелеп, ташкынланып ага башлыйлар. Күпер караучы Мисбах карт белә: Зөя егерменче, илленче еллар агырында шулай шаулады. Алтмыш тугызның язында да шактый мәшәкатьләрен күрсәтеп алды, зыянын калдырды. Быел нишләр? Зөя кебек үзенчәлекле елга үз кырыслыгын көтмәгәндә күрсәтергә мөмкин. Ул бит юлны да көньяктан башлаган. Идел белән янәшә үк, ләкин аңа капма-каршыга ага. Араларында Урта Идел калкулыклары гына ята. Зөя чал агасын шулай таулар аша сөйләшә-сөйләшә таба, аның белән тизрәк кавышырга димме, иртәрәк уяна һәм, тамагында әле Идел ачылмауга карамастан, йөзләрчә километр ташкынланып, хәтәрләнеп килә.

Мисбах карт күпер кырыена атлады. Апрель узып бара. Ә елга һаман сер булып торамы — тора. Ни кылмак була икән тагын?

Зөя апрельнең соңгы ике көнен көткән булып чыкты. Көньяктан исә башлаган коры эссе җил карны ялады да алды. Урман-кырлардан су аунап төште. Инешләр ташыды. Зөя ярларыннан ургып чыкты һәм үзенең киң тугаена җәелде. Хәзер аңа елга дисәң, ничектер, кимсетү сыман гына булыр кебек. Чөнки ул ун чакрымнан артык киңлекне биләгән һәм диңгезне хәтерләтә иде.

Су һаман арта. Үзәнлек аркылы салынган юл дамбасы да күренмәс булды. Хәзер аның урыны гына шарлавыкланып тора.

Зөя өстендә, Кыз тавы борылышында, күчмә нәрсәләр күренде. Мунча. Шуны бүрәнәсен дә селкетмичә кубарып алган. Күл бозлары кипкан, кыштырдавык камышлары белән бер-бер артлы, атау-атау булып киләләр. Тугай басуларына җәелгән ташкын салам эскертләрен дә күтәреп Зөя суына куган. Өрләгәнә ташкын җитә язган күпер нинчак каршылар да, ничек үткәреп җибәрер ул эскертләрне?

Мәһабәт күпергә чын куркыныч янады.

Су эчендә калган авыллар, кешеләр!

Хәл җитди иде. Партия райкомында ашыгыч киңәшмә булды. Ярты ташкын белән көрәш оештыру өчен гадәттән тыш комиссия төзелде.

Җитмеш тугызынчы елның беренче май иртәсе. Коялы. Җылы һәм тын. Тик шашынган елга тына шаулап ага. Каршыдагы яшь каеннар агым белән тартылып чайкалалар.

Шәһәрләр дә уянадыр инде. Халык кайнап агып да бәйрәм демонстрациясенә чыгар. Бәйрәм булгач, көнне буе күңел ачар.

Ә монда язмыш башканы юллаган. Иртә таңнан тау итәгенә җыелган кешеләр — гадәттән тыш комиссия членнары — су астында калган авылларга китәргә әзерләнәләр. Төнлә хәбәр килде: су баскан районнарга ярдәмгә хәрби машиналар белән солдатлар җибәрелгән. Тиздән амфибияләр[1] монда булыр дип көтелә. Комиссия членнары шул машина экипажлары белән бергә китәчәкләр. Алар ташкынга каршы күтәрелгән халыкка булышу өчен шулай бергә барачаклар.

Еллар... Заманалар... Кеше күңеленә кичәгедәй хатирәләр кагыла. Кайберсе Һәркемнәргә мәңгелек сызлау булып калган Зәй ярыгындагы калкулыклар астында, әнә, урман сызылып күренә. Аның колач чыгышы агымында ашлык җиләкләре җәелгән Ышна җире... Крестьяннар тормыш өчен, тамак хакына мең яшәр урманнарны, карт имәннәрнең тамырын актара-актара, түгәрәкләп җир даулаганнар. Ә җиде кат тир түгеп алган бу җирне байлар күзләгән. «Тарих мең дә сигез йөздә туксанынчы елларда шушы Ышна җире хакында дәгъва куба. Искә төшерсәң, тарих булып тарих ачылыр.

Губернатор киләдер,
Казаклары артында
Балыкчылар Себер китте
Ышна җире хакында.

«Ышна бәете».

Патшаның ышанычлы ялчысы булган губернатор алтындашыклы кылыч белән килеп, имбары җир-су теләгән крестьяннарның кулларына богау салдырып, ятәр рәттән киемнәрен кидереп, күрмәгәнне күрсәтә». Ул урынны Шөмбәлинчыда бүген дә сызлану белән «казаклар кыры» диләр.

Казаклар кыры... Андый җирләр туфы битлә яшь егетнең җире мыгыздай сызылган әле дә урман артында да бар. Тарих үзе шаһит моңа.

Беренче рус революциясеннән шаккатып куркынган патша хөкүмәте авылда үзенең куәтен арттыру максатында кулаклар катлавын ныгытырга була. Моның өчен Столыпин реформасын эшли. Гомер-гомергә изә чиккән, Россиянең башка кешеләре кебек ач-ялангач яшәгән Олы Подберезье авылы крестьяннарының байтагы реформаның асылын төшенмиләр, хатта аннан файдаланырга омтыланалар. Ләкин алдануларын аңлыйлар һәм общинадан чыгып хуторларга китүчеләргә җир бирергә теләмиләр. Солдатлары белән тагын губернатор килә. Икмәк даулаган авыл өстендә мылтык тавышлары яңгырый. Кан түгелә. Тагын богау чыңы...

Патша Россиясенең бу якларга җибәрелгән кораллы солдатлары изелгән халыкка шулай гел хәсрәт өстәгәннәр. Ә хәзер заманалар башка. Ярдәмгә һәрчак халык бәхете, аның тынычлыгы сагында торучы совет солдатлары ашыга. Шинельле егетләр халык җилкәсенә төшкән авырлыкны үз өсләренә дә алырга, бәлагә тарыган кешеләрнең куркынычсызлыгын тәэмин итәргә, хәлен җиңеләйтергә әзерләнгәннәр.

Тимер юл станциясеннән елгага таба хәрби машиналар колоннасы килә. Гадәттән тыш комиссия председателе, партиянең Алес райкомы беренче секретаре Абдулхәй Кадыйрович Абдулкадыйров та игътибарын шунда юнәлтте. Җиңел машинага урнаштырылган рация аша бер дә китми, су баскан хуҗалыкларның җитәкчеләре белән тел элемтәдә торә. Олы юлдагы хәрби машиналарны күргәч исә йөзе яктырып киткәндәй булды. Ул микрофонны кулына алды.

---

[1] Амфибия — корыда да, суда да йөри һәм суда йөзү өчен җайланган машина.

— Башак-үзәк! — Ул техниканың район берләшмәсендә урнашкан үзәк радиостанциясе чакыра иде. Диспетчер кыз тавышы ишетелде:

— Үзәк тыңлый.

— Ярдәмгә килгән хәрбиләрнең командирын дәшегез!

Күп тә үтмәде, микрофонда офицерның рапорты яңгырады.

— Көтәбез, бик көтәбез үзегезне,— диде комиссия председателе.—Амфибияләр белән монда, уңъяк ярга кичәргә кирәк.

Амфибияләр актарылып торган елгага керделәр. Кичү башланды. Комиссия председателе инде «Җиңү» колхозын чакыра иде:

— Башак-утыз сигез, безне ишетәсезме?

— Тыңлыйм.— Бу колхоз председателе Дәүләтшин тавышы иде.

— Урындагы хәлне аңлатыгыз. Кешеләрнең барын да коткардыгызмы?

Комиссия бу колхоздан хәтәр хәбәр алган иде. Ташкын фермадан кайтучы сыер савучыларның юлын кискән. Шул кызларны баладан коткарырга алынган ирләр үзләре ишкәкле көймә белән көчле агымга килеп кергәннәр һәм ага башлыйлар. Ярдәмгә вертолет чакырыла. Комиссия председателе шул кешеләрнең язмышы өчен борчыла.

— Кешеләр коткарылды. Бары да исән-сау,— диде Дәүләтшин.— Су һаман күтәрелә. Фермаларга куркыныч яный. Анда әле савылган сөт тә калды.

— Ярдәмгә хәзер үк кешеләр белән БТР[1] җибәрәбез. Хушыгыз!

Ул шунда ук кун тужурка, резин итекләр кигән һәм өмер көтеп, былтыргы кипшенгән чирәмдә утыручы таза егеткә — райкомның бүлек мөдире урынбасарына эндәште:

— Зыятдинов!

— Мин монда.

— Кешеләрең әзерме? Хәзер группагыз белән БТРга утырып, Югары Ындырчыга китәсез. Бурыч билгеле.

— Мостафин!

Сөзәк тау итәгендә, яр читендә торган автомашина янына, кара дерматин сумкасын тотып, калын битле, чал чәчле ир йөгереп килде: район авыл хуҗалыгы идарәсенең баш агрономы Әнәс Мостафин.

— Тыңлыйм, Абдулхәй Кадыйрович,— диде ул, ашыга-ашыга.

— Сезнең группа икенче амфибия белән «Гигант» колхозына китә. Бөтен кешене күтәрегез. Дуңгыз фермасын күзәтү кирәк. Зөя аръягындагы вакытлы амбарга күчерелгән чәчүлек орлыкны коткару чарасы күрелсен. Кешеләрне саклагыз. Урындагы хәлгә карап эш итәрсез.

Мостафин ярга якынлашып килүче «үз амфибиясен» каршыларга йөгерде. Абдулхәй Кадыйрович аның артыннан озак карап торды. Чөнки ул үзе белән озак еллар бергә эшләгән тынгысыз, тапшырылган һәр эшне үтәүдә җаваплылык күрсәтә торган бу иптәшне аеруча хөрмәт итә иде.

Чын кеше үзен һәрчак сыный, шул сынаулар аша үсә, ныгый, камилләшә. Бүгенге хәлне генә күз алдына китер. Язгы чәчүгә әзерләнделәр. Машиналар кат-кат тикшерелде. Җир куенына салачы орлыкны күңел биреп эшкәрттеләр. Яз килгән, игенченең басуда сыналыр, чыныгыр чагы җиткән иде. Ләкин башта кешеләрнең кыюлык һәм чыдамлыгын Зөя үзе сынарга булган икән.

Абдулхәй Кадыйрович тә уйлана. Кешеләк сыйфатларының җыелмасын йөрәгеңә якын йөртсәң һәм бүтәннәргә күрсәтә, тоткан ите белсәң генә сине чын секретарь дип танырлар һәм ышанырлар. Әгәр дә мәгәр аның авыллар, фермалар, машина парклары аша шашып аккан елга ярындагы кичерешләрен йөрәгең белән тойсаң, бу минутларда үзең аның урынында булсаң, секретарь эшенең авырлыгын күбрәк белер идең.

Микрофон телгә килде:

— Башак — бер, ишетәсезме?

— Яхшы ишетәм. Хәлне аңлатыгыз!

---

[1] БТР — броня транспортер.

— Орлыкның күбесен чылатмыйча алдык. Яшь терлекләр куркынычсыз урынга күчерелде, җәнлек фермасында коткару эшләре бара...

Моны Муса Җәлил исемендәге колхоз председателе Мәгъруф Шараев белдерде.

Бирелә коткару эшләре утызынчы апрельдә үк оештырылган иде. Аның белән партком секретаре Фәрит Айзатов коммунистларны һәм иң актив колхозчыларны җыеп сөйләшкән. Су басу куркынычы булмаган Карамасар, Иманле Бортас авылларыннан дистәләгән кеше техниканы әзерләп куйдылар. Азбаба авылындагы амбарлар тирәсенә туфрак өю, чәчүлек бөрчак һәм арпаны башка бригада амбарларына озату, фермадагы яшь терлекләрне сәндерәләргә күтәрү — Беренче майга каршы төн шундый авыр, ашыгыч эшләр белән узды. Кешеләр җиңделәр. Күп байлык саклап калынды. Шараев райком секретарена шул хәбәрне җиткерергә ашыга иде.

— Авыл кешеләре арасында төшенкелеккә бирелүчеләр юкмы?

— Сизелми. Нык торалар,— диде ул.— Су һаман күтәрелә. Мунчаларны агыза башлады.

— Аңлыйм. Ярдәм җибәрдек. Баш зоотехник Сәлахов амфибия белән зур группа кешеләр алып китте. Киңәшеп эшләгез. Тагын бер амфибия җибәрербез.

Амфибиягә солдатлар белән бергә мең буханкага якын пешкән икмәк, сулы савытлар, башка иң кирәкле әйберләр төяделәр. Экипаж командиры яшь капитан маршрутны ачыклады да:

— Алга! — дип боерык бирде.

Хәрби машина урыныннан кузгалып суга кереп китте, Зәянең үзәгенә килеп чыкты. Елга монда актарылып ага. Машина калтыранганда хатын-кызлар, куркынып, як-якка карананлар. Алар өчәү. Берсе — сәүдә хезмәткәре, авылга азык-төлек алып бара. Икенчесе — тәбәнәк буйлы, урта яшьләрдәге хатын — санаторийга җыенып чыккан. Өченчесе — кара тутлы, юл ясап тараган кара чәчле, бераз чегәнгә охшаган яшь хатын — ире белән бара. Яңа өйләнешкәннәр, бәйрәмгә егет йортына кайталар. Алары поезд юлына әлегергә ниятли.

Агым уңаена моторын бөтен көченә эшләтеп барган машина урманга якынлашты. Агачлар күкрәк тиңентен суда тора. Урман гүя сыкрана. Агып килгән салам эскертләренең кайберсе имән араларына тыгылып калган, агачлар сынар хәлгә җиткәннәр.

Капитан баш зоотехник Гобәй Сәлаховичның җиңенә кагылды да урман ягына төртеп күрсәтте. Ике агач арасына кысылып калган салам өеменә бер поши менеп баскан иде.

— Тәвәккәллимме? — Капитанның күзе малайларныкы кебек елтырый, ул «Мазай бабай» булырга чамалый иде.

— Булмый! — диде Сәлахов, яшь капитанның бөтен өметен әлеге бер сүз белән өзеп.— Коры кул белән машинага күтәреп булмый. Ләкин дөрес уйлыйсың: коткарырга кирәк.

Сәлахов амфибияне шунда таба боруларын сорады. Бу хәлне күргән поши пошкырып куйды, бер урында таптана башлады. Салам ишелеп төште, поши суга барып төште һәм ашыга-ашыга урман эченә, коры җиргә таба йөзә башлады...

Баш очыннан кызыл йолдызлы яшел вертолет очып узды, ә амфибиянең үз юлы бар иде. Ул суга чумган әрәмәләр арасыннан бара торгач, Үләмә елгасы тамагына килеп чыкты. Үләмә кырлар-болыннар аша йөзләрчә чакрым килә дә Зәягә яңа куәт булып кушыла. Ике елга кавышкан урын актарылып тора.

Көтелмәгән хәл булып алды. Мотор кинәт сүнде дә амфибия хәтәр агымга әләгеп чайкала башлады. Хатын-кызларга коткару билбаулары киярга булыштылар. Экипаж членнары үзләренә хас осталык белән моторны карап чыктылар. Бераздан амфибия юлын дәвам иттерде.

Уңда таулы яр башланды. Зәя бу яр белән гасырлар буе бәрелешкән, ләкин җимерә алмыйча сулга, тугай ягына каерылырга мәҗбүр булган. Муса Җәлил исемендәге колхозның иген кырлары да шуннан башлана. Амфибия, елга үзәген кал-

дырып, такыр чакта автомашиналар утын ташыган урман юлына кереп китте һәм бераздан колхозның җәйге сугарулы көтүлекләренә килеп чыкты. Авылга инде ерак түгел иде. Әйләнә-тирәдә гел су, су, су иде.

Партком секретаре Фәрит Айзатов культуралы көтүлек мотористы Гайфетдин Мәрдәнов белән көймәдә Зөя буендагы калкулыкка урнашкан Суыклы Алан авылына киттеләр.

Гайфетдиннең бу көннәрдә бер генә минут та буш вакыты юк. Кайларда гына булырга туры килми. Фермага су бәреп кергәч, таң белән шунда барып җитте. Абил Курамшин һәм дежурдагы сыер савучы коммунист Һәния Мәрдәнова белән бергәләшеп яшь терлекләрне коткарырга кереште. Моторлы көймәдә терлекчеләрне җыеп килде. Икенче карагандa ул, кешеләр утыртып, умарталыкка юл тоткан иде инде.

Үз өенә берәзга гына кереп чыга. Көймәсендә арт капкадан килеп керә дә, көймәсен, ат шикелле итеп, болдырга бәйләп куя. Өйдәгеләрнең хәлен белеп, бер уңайдан тамак ялгап чыга. Йортта терлекләр дә бар. Бер кайтуында сарыкларын печәнле әвеслеккә күтәрде, киртәләп алды: яшәсеннәр, азыклары күп. Сыерны такта салга бастырды. Шыңшып утырган маэмайга да коры урын ясап бирде.

Суыклы Аланга юл игеннәр, әрәмәләр арасыннан бормалана-бормалана бара иде. Ә хәзер — су дәрьясы, теләсә каян шудырт. Гайфетдин дә җитез көймәсен турыдан тота, тик агачлыкларны гына әйләнеп уза.

Авыл күренде. Юк, ул кайчандыр авыл булган, ә хәзер нибары ике йорты бар. Аның берсендә карт белән карчык, икенчесендә апалы-сеңелле ике әби тора. Нигездән беркая китәргә теләмичә, шунда көн күрәләр.

Гайфетдин көймәне болдырга ук терәп туктатты. Шомланып, ишеккә күз салды.

— Җан иясе күренми. Әллә...

Өйгә үттеләр. Анастасия Васильевна оныгы Рома белән чәйләп утыра иде.

— Исән торасызмы, Анастасия Васильевна?

— Бик әйбәт, улларым.

— Куркыныч түгелме?

— Күнектек инде. Су ел саен була ул.— Аннары көрсенеп куйды.— Хәер, быел күбрәк. Умарталарны да алды. Әтәчемне дә агызды, нәләт. Газ савытын да.

— Менә бит, бәлале булгансыз. Зур авылга күчик, Анастасия Васильевна, Югары Аккуҗага.

— Гомер иткән нигезне ташламабыз шул инде, ни күрсәк, монда күрербез,— диде әби, эчке кичерешләрен ачып.— Бераз чәй суы җибәрсәгез ярый. Юкса, коебыз су астында калды.

— Ярар, Анастасия Васильевна. Су китерерләр. Икмәк тә бар, ала килгән идек.

— Зур рәхмәт, улларым, онытмавыгыз өчен рәхмәт.

— Сергей Иванович кая соң?

— Күрше карчыгы белән терлекләр саклыйлар.

Сергей Лукоянов утыз еллар колхозда умартачы булып эшләде. Исеме зур, хөрмәте бар. Хәзер нинди мәшәкатьләр белән яши икән?

Аны утрау булып калган агачлы калкулыкта очраттылар. Сиксәнне тутырып килгән күрше карчыгы Анна Павловна белән җилдән ышыкланырга шалаш корганнар. Сарыкларга печән салынган.

— Кәеф ничек, Сергей Иванович?

— Зарланырлык түгел.

— Нинди ярдәм кирәк?

— Рәхмәт. Безнең өчен борчылмагыз.— Ул Зөя аръягындагы тауда утырган авылга ымлады.— Алай-болай булса, һавага ике мәртәбә мылтыктан гөрселдәтәм дә... хәзер килеп җитәләр. Шулай сөйләшкән идек.

Секретарь картка сокланып карап торды. Нинди тыныч! Гади кешенең иң хәвефле чакта кайдадыр посып яткан куркаклыкка шытып чыгарга җирлек бирмәве аның ихтыяр көчен, рухи ныклыгын күрсәтеп тора түгелме соң? Секретарь шулай уйланып канәгатьләнү, ниндидер эчке рәхәтлек кичерде. Ә бераздан ташкын урта-

сында терлек саклаучы әби белән бабайга сәламәтлек теләп басу өстеннән Малалла авылына юл тоттылар.

Малаллага түбән очтан керделәр. Авылда зур хәвефләнү сизелми. Кырыйдагы карт-карчыкларны — Федотовларны — куркынычсыз урынга күчергәннәр. Су йортларның тәрәзә астына җиткән.

Партком секретаре бригадирны очратты.

— Кудряшевны шартын китереп озаттыгызмы?

— Онытылмаслык булды.

Кудряшев Армия сафларына чакыру буенча, беренче май иртәсендә юл алырга тиеш иде. Солдатка кичегеп бару ярамый. Авыл да солдатын кадерләп озата. Өйне су басса да, түргә табын әзерләделәр. Тәрәзәләр ачып җибәрелде. Өйгә йомшак җил белән бөре исе һәм кыекта очынып-очынып сайраган сыерчык җыры бәреп керде, бәйрәмне зурлап, күңелне рәхәтләндереп җибәрде.

Туган-тумача, күрше-күлән, озатырга килүче башка авылдашлар көймәләрен стенага ук терилэр дә... тәрәзә аша өйгә төшәләр һәм озын кунычлы резин итекләр белән өстәл янына килеп басалар. Булачак солдатка җылы сүз шулай салкын кар суында басып торган килеш әйтелә.

— Яшьләр, көймәләргә утырып, Кудряшевны станциягә озата киттеләр,— диде бригадир.— Хәерле юл үзенә.

— Хәерле юл!

Кеше гомерендә бер генә мәртәбә була торган мондый су басуга карамастан, авыллар гадәти тормыш, күп төрле мәшәкатьләре белән яши бирәләр. Халык нык тора.

Гаиләсе белән бу авылда көн күрүче финанс инспекторы Алис Газиев тугайга ташкын килеп төшкәндә өендә иде әле. Кылт итеп колхоз умарталары исенә төште: харап булалар лабаса! Ул бал кортларын ярата, үзенең дә умартачы булып эшләгән чаклары бар. Нишләргә? Умартачы Наил Нигъмәтҗанов та бәргәләнәдер инде. Баксаң, күңелләре тарткан икән: ашкынып чыкканнар — умартаны коткарып калдылар. Гайфетдин Мәрдәнов икесен дә моторлы көймә белән әрәмәдәге умарталыкка илтеп куйды. Берләш авылыннан ярдәмгә Равил Әмирханов белән Ривал Гайнуллин да килеп җитте. Күп умарталарны ташкыннан йолып калдылар. Газиев өйгә көч-хәл белән төн уртасында гына кайтып ауды.

Иртән ул чорма аша өй түбәсенә күтәрелде. Кояшлы матур көн. Сыерчыклар сайрый. Болын турысыннан киек казлар очып үтте. Бөреләре бүрткән тирәкләрнең өчкелтем исе борынны кытыклый. Биткә кар суының салкыны бәрелеп тора. Тирәякта гел су. Азбаба авылының түбән очына гына керә торган иде. Ә бүген югары урамны да басып киткән. Кече Мәми авылы үзенең тал-тирәкләре, биек каралты-куралары белән ялан су өстендә утыра. Гомер булмаганны, су Имәнле Бортас һәм Югары Аккуҗа авылларына кадәр менеп җиткән. Газиев өй түбәсеннән тирә-якны күзәтеп шактый утырды.

Янәшә йортның болдырына бер хатын килеп чыкты.

— Исәнме, күрше. Бәйрәм белән үзеңне!

— Рәхмәт, Наталья Ивановна.

— Безнеке, итеген киеп телевизордан Мәскәүне карый әле.

Чолан ишегендә бер егет күренде.

— Исәнме, Славик.

— Бик шәп, Алис Сәлимоанич.

— Училищеда нилэр бар? Уку барамы?

— Барысы да тәртиптә.— Ул Газиевка күз кысып куйды.— Кызыл мәйданда демонстрация башланды. Мәскәү бәйрәм итә. Ә без кыекта утырабыз.

— Соң, улым, гаеп түгелдер ич, сез дә бәйрәм итегез.

Славик бармакларын шартлатып куйды:

— Чыгар әле, әни, күчтәнәчне!

Славик рюмка һәм шешә алып әвеслеккә сикерде. Рюмкага шәраб салды да күрәккә куеп Газиевка сузды.

— Бәйрәм белән, Алис Сәлимҗанович!

— Бәйрәм белән!

Ике күрше бәйрәмне шулай билгеләде. Аннары терлекләргә азык салдылар да телевизор карарга төштеләр.

Халык бөтен хәвефне онытып һәм мәшәкатьләрен җиңеп, Майны бәйрәм итә иде. Өйләргә яңа пешкән икмәк тараттылар, бик мохтаҗларга су китерделәр. Кеше нәфесле түгел, артыгын кыстагач та алмый, барысына да тигез тисен ди.

Һәр авылның шундый матур сыйфатлары, үзенчәлек һәм уртак гадәтләре бар. Хәбәр бер урамда сөйләүче кеше авызыннан чыкмас борын икенче урамга ишетелә. Өй түбәләрендә, әвеслекләрдә утыручылар орлык амбарларында, фермаларда төне буениләр булганын җентегенә кадәр белгәннәр. Башка хәбәрләр дә кыектан-кыекка күчә:

— Бая авыл өстеннән яшел вертолет очкан иде, әйе, бит. Кече Мәмигә китапханәче Роза Токсарованы алырга килгән. Бүлнискә, операциягә алкиткәннәр. Авыруы да таба лабаса вакытын.

— Сырхаулаганын каян белгәннәр?

— Ире Петр Ильич чакырткан. Кече Мәмидә төшәргә җир таба алмыйча йөдәп беткәннәр. Әллә инде тирес башына гына туктаганнар ди шунда...

— Тимофей Аблиевларда кызык хәл булган. Хуҗа үзе фермада икән. Өйдә хатыны белән малае гына. Боларның симергән дуңгызлары бата башлаган. Коткарырга Павел Майданов, Николай Бабанов, күршеләре кергән. Көймәгә салып бәйләгәннәр мыркылдыкны. Хайван бит, аңламый. Урамга чыккач, талпынып җибәргән дә көймәне каплаган. Аннары кешеләр аны, күкрәктән су ерып, тирес өемнәренә кадәр колагыннан сөйрәп барганнар. Кыектан бегемот булып күренә икән.

— Ярый ла тирес өстендә торса. Әнә, Павел Майданов урам башындагы калку җиргә сыерын илткән булган. Йортта бозавы калган. Шул бозау өчен агымга каршы урам үкертеп йөзеп кайткан. Пошкырганда борыныннан кан килә икән. Сыерны әйтәм, хайван булса да, бозау җанлы.

Хәбәрләр шулай йорттан-йортка йөреп тора.

— Володя Антонов белән Афанасий Кудряшев үлә язган, ишеттегезме?

— Кая, ничек?

— Кул астына эләккән иске көймәгә утырып, фермага барырга чыкканнар. Бакча башын узу белән, үзәнлектәге куәтле агым бөтереп алган боларны. Каерып ишә торгач, ишкәкләре сынган. Иделгә агасылар икән, бәхетләре, каен туры килгән. Шунда килеп бәрелгәч, көймә урталай ярылган. Володя белән Афанасий ботакка ябышып котылганнар. Ярдәмгә кешеләр чакырып карлыгып беткәннәр, бичаракайлар. Валерий Чернов ишетеп барган.

— Шулай да батыр алар. Ишкәкле көймәгә утырып, терлекчеләргә ярдәмгә барам дип, агымга каршы чыгарга кемнең кыюлыгы җитәр иде? Яшьлек куркусыз була шул.

Яшьләр, бүгенге егетләр һәм кызлар. Тәрбияви якларын тикшергәндә, кайчак, үлчәмичә, шактый нахак сүзләр дә әйтәбез түгелме соң үзләренә?! Имеш, тәрбиясез, йөгәнсез үсәләр, өлкән буынга охшамаганнар. Болай уйлап хаталанабыз икән ләбаса! Бүгенге яшьләр нәкъ менә өлкән буыннан алган батырлык, кыюлык, игелек бөреләрен саклыйлар, авырлык килгәндә өлкәннәрчә борчыла, көрәшә, җиңә беләләр икән. Ташкында калган гади генә шушы колхозда да бу сыйфатларын ачып, исбатлап бирделәр.

Авылга кунакка кайткан Володя, үзенең тормышын куркыныч астына куеп, фермага булышырга ашыккан. Күрше бригададан ярдәмгә килеп коммунист тракторчы Хәмзә Ногманов, Галимулла Гайфуллин соңгы центнер орлыкларын дамба өстеннән шаулап аккан судан алып чыгалар. Алар батырлыгын механизатор егетләр Әгъләм Әхтәриев белән Мәсгут Курамшин кабатлый. Фермаларны су басканда шофер Володя Чернов рейстан кайтып төшә. Ул ике дә уйламыйча колхоз терлекләрен коткарырга керешә. Ә йортындагы үз сыеры агып китә. Гайфетдиннең унынчы класста укучы улы Марс куркыныч килеп чыгуга ук әтисе белән фермага китә. Ә аннан арынгач флягаларга чәй суы тутырып, ишкәкле көймә белән урам буйлап карт-карчыкларга өләшеп йөри, Гөлнар апасы, Касыйм, Әмир абыйларның рәхмәтен ишетә.

Авыл, ташкынга исе китмәгәндәй, шулай тулы тормыш һәм онытылмас вакыйгалар белән яши. Икенче хәрби амфибия килеп хәлне җиңеләйткән. Районның баш зоотехнигы Гобәй Сәлахов группасы бу машиналар белән фермаларга салам һәм фураж китерүне оештыра. Икмәк кайтаралар. Икмәкне һәм суны урам буйлап өләшеп йөриләр. Авыл хәвеф белми, тук һәм тыныч яши.

Гадәттән тыш комиссия председателе вертолет белән су соңрак баскан колхоз үзәкләрендә булып кайткан, кешеләрнең бердәмлеген, тәвәккәл эшен күргән. Урынбасарларның да юанырлык хәбәрләрен тыңлаган. Ләкин күңеле барыбер тыныч түгел. Ташкын югары көчәнешле электр линиясен җимергән. Алты авыл, фермалар караңгылыкта калган. Анда хәл мөшкел. Комиссия председателе элемтәгә авариячеләрне чакыра.

— Вертолет килде. Хәзер күтәреләбез.

— Аварияне кичекмәстән бетерергә тырышыгыз.

— Була ул.

Сулда, сабан туе үтә торган мәйданда, моторлы көймәләр пырылдый. Моторларны Казаннан вертолет белән китергәннәр. Ташкынлы зур суга чыкканчы, монда сынап карыйлар.

Су кырыенда ук көнө буе элемтәчеләр кабалана. Приборларын ачканнар. Рация аша кемнәрдәндер киңәш сорыйлар. Ләкин эш алга бармый. Ташкын өзгән элемтә линиясен ялгый алмый изаланалар. Кабель очын көймәгә тагын сөйрәтеп карадылар, тик барып чыкмады. Су астында калган дамбаны чамалап, кабель белән трактор барып карады. Куркыныч тәвәккәллек. Дамбаны су юган иде, кешене чак һәлак итмәделәр.

Абдулхәй Кадыйрович элемтә өчен бик борчыла иде. Тиз генә хәрби вертолет экипажының командиры белән сөйләшеп алды. Ярдәм күрсәтергә булдылар. Беравыктан вертолет юан кабельнең очын алып, каршы ярга чыкты. Шәһәрара элемтә линиясе кабат эшли башлады.

Ташкын, үч иткәндәй, бәйрәм чакка туры килде. Кемдер кунак каршылаган, кемдер, эшкә килеп өлгерермен әле дип, авылга туганнары янына кайткан. Әмма юллары бүленгән. Тау итәгенә, әнә, никадәр җыелганнар, кичү көтәләр. Ә диңгез булып җәелгән елганы кичәрлек түгел. Моны бөтенесе дә аңлап бетерми. Комиссия председателенә киләләр, үтенәләр, ялваралар, нигезле сәбәпләр табып таләп итәләр. Алар бер яктан хаклы: эш урыннарына ашыгалар. Тик су баскан авыллардагы киеренке хәл, амфибияләрне бушатырга, кичүгә куярга мөмкинлек бирми. Бәлки очучылар буш вакыт табар?

Кичкырын кичүгә хәрби вертолетлар чыкты. Алар киң Зәя аша һавадан «күпер» салдылар.

Ә бу вакытта комиссия председателе тагын «Спартак» колхозын чакыра иде:

— Башак — ундүрт!

— Тыңлыйбыз.

— Елга нишли?

— Үләмәдә су төшә башлады.

Вак елгаларда су кими — бу күңелле хәбәр иде.

Комиссия председателенең колагына музыка тавышы ишетелде. Яр буена килүчеләрнең кайсыдыр магнитофон уйната икән.

Ташкынлы Зәя берничә көннән соң гына үз ярларына кайтты. Дамбаның су юган урыннарын төзәтергә бульдозерлар чыкты. Солдатлар елга аша йөзмә понтон күпер сузып машиналар үткәрә башладылар. Механик чүкеч белән гөрселдәтеп агач күпер баганаларын кагарга тотындылар. Тормыш авылларда да үз хәленә кайтты.

Мисбах карап торган күпер агып киткән иде. Ул Зәянең тамчылардан җыелган кыргый куәтен тагын бер кат күрде. Озак онытмас инде ул аны. Бүтәннәрнең дә исеннән чыкмас.

Әхәт Гаффар

# РӘССАМ

Миңзәлә урамнардагы юкәләр чәчәк аткан вакытта бигрәк тә матур. Шул чаклары белән aерата истә кала. Һәм кешеләре белән. Соңгы вакытта мин анда кызыклы бер сәнгать әһеле белән танышу, уртак иҗат уе белән яшәү бәхетенә ирештем.

Ул — күзгә бәрелеп тормас гап-гади бер кеше. Һәр әйткәнендә аның эчке фикер байлыгын тоясың. Ул тышкы гадәти, күнегелгән күренешләрнең дә эчке серле асылын тоеп яши белә.

Киеме — үтә гади. Әмма пинжәге якасында зур зәвык белән үзе ясап таккан значок булыр, анда — үзенә генә билгеле хикмәтле сүз. Ул сүз аның тоткан кыйбласы, рухи омтылыш мәгънәсен чагылдырыр.

Аның театрдагы эш бүлмәсе кечкенә генә бер комырыкта. Андый кысанлыкта эшләве читен. Бастырып, сөяп куярдай бар нәрсә идәнгә, урындыкларга, шүрлекләргә тезелгән. Бер карыш та буш урын юк. Хәер, ул эш бүлмәсендәге әйберләрнең күзгә чәчрәп кереп торган тәртип белән урнаштырылуын әнәп тә җиткерми. Тик шунда беpаз утырсаң, тышкы тәртипсезлектә тирән эчке пөхтәлек ятканын күреп аласың. Бөтен нәрсә аның аңына буйсынган, аңа хезмәт итә, кадерле, йөрәгенә якын. Каяндыр түбәннән кырыс рәвешле рус иконасы карап тора. Югарыда үтә модалы киенгән бер кыз сурәте. Иң караңгы стенаны ап-ак каеннар рәсеменең сүрән нуры яктырткан, шул каенлыкка бүтән бер рәсемнән хатын-кыз кыяфәтендәге гүзәл ат омтыла. Офорт калайлары, чүкеч, кайрак, буяулар, пәке. Ишектән кергән һәр кешене төрле җирдән тактага уеп һәм яндырып ясалган өч портрет каршылый: моңсу Тукташ, уйчан Достоевский, арыган, картайган, әмма искиткеч горур, хәтта күзе һәм иреңе сарказм белән тулып торган артист. Йоннары туздырып беткән, тапчыккан, тик җиңелмәгән карт бөркетне хәтерләтүче җил тегермәне рәсеме... Ясала башлаган эскиз... сәхнә макеты... Әйе, аның эш бүлмәсе — үзенә күрә натюрморт; әйтерсең, ясалып бетмәгән картина. Һәр нәрсәдә байтак мәңгай тире агызган көндәлек хезмәт чагылышы.

Һәм ул үзе... Ачык йөз. Бәйсез кыяфәт, тупланганлык. Авызында карандаш. Җиңнәре сызганулы. Озак вакыт дәшмичә, сөйләшмичә утыра ала. Чөнки ул әңгәмәдәшкә күп фикерне сөйләшмәгән чакта әйтеп булганын яхшы белә. Минем үземә дә сөйләшмәгәндә рәхәт. Кайберәүләр буш, фикерсез булуларын өзлексез сөйләшү белән каплап хәйләләмәкче була. Кешенең кем икәнлеген сүзсез торган чагында яхшырак таныйсың кебек. Кирәкмәгәнгә эндәшмәү — эшлеклелек билгесе. Төп сүзеңне эндәшмичә булдыра алмаганда гына әйт. Әнә ич: табигать тын чагында тулып, эчтән ташып тора, мәгънәле. Җәйге болынны гына күз алдына китер: тын, ә шул тынлыкта меңнәрчә бөҗәк, кош, чәчәк, җәнлек мәшәкате, ис, төс, тәм...

Минем әңгәмәдәшем шундый тын холыклы. Безгә бер-беребезне аңлавы гаять җиңел, рәхәт. Карашлар охшаш, омтылышлар якын.

Ул — театр рәссамы.

Театр — катлаулы синтетик сәнгать. Театрда берьюлы әллә ничә сәнгать әһеленең дөньяга карашы, тормышны аңлавы, киләчәкне сиземләве, идеалы кисешә. Яраша, тәңгәл килә, көрәшә. Драматург, режиссер, артист. Композитор, рәссам. Ахыр килеп, тамашачы. Тамашачының да театрга турыдан-туры катнашы бар. Ул — сәхнәдән әйтелгән фикернең мишене. Мишень булмаса һәм аңа тидерә алмасаң, атудан мәгънә юк. Ләкин мишеньнең сии тезәп атарга лаек булуы бик мөһим. Кайбер эшлекләләр тамашачылар арасыннан иң таләпсезенең, зәвыксызының ихтирамын казануга исәп баглый, аңа, аның күңеленә хуш килсә, иҗат максатына ирештем дип саный. Мәгълүм бер уңышка да ирешә. Тик бу вакытлы алдану түгелме? Сәнгать әһеле киләчәкне нечкә сиземли торган зур зәвыклар өчен иҗат итәргә тиеш. Иртәгә үтеләсе юлга маякларны бүген тезеп чыгарга кирәк. Узган көн өчен иртәгә эшләү гафу ителмәстәй эш. Эш түгел, ә бәлки хата.

Болар барысы да — аның фикере.

Мин аның киләчәкне сизгер тоемлавына, бүгенгене сизгер кабул итүенә, тамашачыны яратуына, аны үзе белән бер баскычта басып торган шәхес итеп күзаллавына мөкиббән. Кайберәүләр шикелле, «аңлармы соң?» дип, түбән зәвык өчен иҗат итүне башына да китерми. «Башмагым» (Җ. Фәйзи), «Һәйкәл» (Ә. Баянов), «Мария» (А. Салынский), «Кара бүре» (А. Арбан), «Язлар моңы», «Соңгы ләкләк» (Ә. Гаффар), Ардуан батыр» (Г. Ахунов) һәм башка спектакльләрнең бизәлешен ул сәнгатьчә фикерли, хыяллана белә торган, киләчәк хакындагы идеаллары ачык булган тамашачы өчен иҗат итте. Метафора, символ, киң һәм тирән фикер — аның иҗат коралы. Ул халыкның күңел көзгесендәге образларны, бай нурлар чагылышын тоя, күрә.

— Төп максатың нинди? — дип сорадым мин аннан.

— Табигатькә якынаю, — дип җавап бирде ул.

— Гадилек һәм ассоциациями?

— Әлбеттә. Табигатьтәге матурлыкны кешә гадилек белән катлаулылык арасыннан эзләп таба.

— Сәхнәнең бизәлеше дә тормышны чагылдырмача түгел, ничек бар — шул рәвешчә тасвирлаудан гына тормаска тиеш.

— Сәхнәнә пьеса авторының идеясенә ярашып торырлык итеп корсаң, канәгать каласың. Кызганычка каршы, безнең байтак драматургларыбыз көнкүреш темасына яза. Бизәлешне метафорага кору читенләшә. Тәңгәллек югалырга мөмкин. Мин режиссерга һәм художникка фикер мәстәкыйльлеге биргән драматургларны яратам. Берәү «сулда ишек, уңда тәрәзә, алгы планда өстәл, стенада картина» дип, синең бар фантазияңне йозакка бикләп куя. Икенче берәү «җил тегермәне» дип кенә яза. Монысы инде, синең хыялыңа канат куя. Миңа шундый әйберләр охшый. Бәхәс яратам. Иң элек — үз-үзем белән бәхәсләшүне. Ул чагында башкаларга синә аңлавы җиңеләя...

Ул 1970 нче елда МХАТ студиясен тәмамлаган. Диплом эше — Фонвизинның «Недоросль»е нигезендә куелган спектакльне бизәү. Күп эзләнгән, күп тапкан. Зур гына уңышка ирешкән, байтак кына ялгышлар җибәргән. Ләкин ялгышу — үзе дә табыш, ачыш. Чөнки бер ялгышны акыллы кеше икенче кабатламый.

Диплом практикасын Новосибирск театрында үткән. Беренче мөстәкыйль эше — К. Симоновның «Докторша»сын бизәү. Җитәкчесе — бөек якташыбыз В. И. Качаловның улы В. В. Шверубович. Аннары — Минзәлә театры. Иҗат эшчәнлегенең нәтиҗәсе — дүрт дистәләп спектакльне бизәү. Бай, махсус өйрәнүгә, гомумиләштерүгә, ниһаять, берәр сүз әйтергә лаек хезмәт. Әлегә исә җәяләр эчендә генә диярлек атап әйтүдән узганнары юк. Кызганыч. Аның зур күргәзмәләргә куярлык офортлары бар.

Ә офорт — рәсем сәнгатенең иң югары баскычында тора торган, коточкыч түземлек таләп итә торган иҗат.

Ул менә шуның белән дә шөгыльләнә. Шөгыльләнә генә дию төгәл түгел, — иҗат итә. Байтак эше бар. Офортка карата «байтак» сүзе «күп» мәгънәсендә кулланылырга хаклы. Чөнки ул — күп көч салына торган сәнгать. Офорт — гравюраның бер төре. Ул сурәтә соңыннан кәгазьгә төшерелә торган форманы кислоталар белән яндырып ясаудан гыйбарәт. Кәгазьгә төшерү өчен кулланыла торган форма итеп бакыр яисә цинк калай алына. Металл, кислоталар, гравюрлау кораллары, лак, буяулар, сурәтне кәгазьгә төшерү станогы... Энә белән кое казу. Калайга сурәт чокыганда яисә уйганда һәр ноктаң, һәр сызыгың, хыялыңдагы рәсемең күзгедәгечә кирә чагылышта эшләнергә тиеш. Ә бу — гаять читен. Ясаган күренешеңдәге күләгә,

яктылык, сызык, перспектива ялгыш уелса, картинаң ялган булачак.

Мин аның җыйнак, җанлы, йөгерек, җиңел, нечкә сызыклы һәм тәэсирле офортларын зур кызыксыну белән карап чыктым. Алар җитдирәк, нәтиҗәлерәк, файдалырак һәм киңрәк кызыксынуга лаек, дип саныйм. Бу кадәресе белән Татарстан Художниклар союзы кызыксынса икән.

Ул — театр хезмәткәрләре гаиләсеннән. Атасы — Нур Яһудин — Минзәлә татар дәүләт театрында 1937 нче елдан бирле эшләгән. Анасы — Рабига Терегулова — кырыгынчы еллардан бирле. Ә ул үзе — театрның җитмешенче елларда килгән вәкиле. Ул баштанаяк театр рухы белән сугарылган. Театр аның өчен эш урыны гына түгел. Театр — аның йөрәге аша үтә торган кан чисталыгы.

Инде таныштырырга вакыт: сүз Минзәлә татар дәүләт драма театрының баш рәссамы Альфер Яһудин хакында.

Минем столярларның эшләгәненә сокланганым бар. Аның өчен һәр такта үзгә, үз холык-фигыльле, җанлы... А. Яһудин кулындагы гади карандашның да терекөмеш тамчысыдай йөгерек булуына гаҗәпсенеп карап тордым. Ә ул үзе бу турыда:

— Рәссам — инженерлык эше яки балта остасы һөнәре кебек үк гади бер эш, — дип кенә куйды.

Ышанам. һәр эшнең — үз остасы. һәм һәр останың үз урыны.

Яши, хезмәт итә, шатлана яки кайгыра. Аның өчен ат дагасы да сәнгать, карт артистның моңсу күзе һәм тыйнак сүзе дә сәнгать. Театрдагы кысанлыкка, тарлыкка, мөмкинлекләр аз булуга бирешмәү дә сәнгать. һәр яңа спектакль саен рәссам сәхнә кысанлыгы белән алыша башлый. һәм җиңә. Сәнгать җиңгәндә башлана. Чын сәнгать — җиңү дигән сүз ул.

Кечкенә сәхнәләр өчен эшләү материалны кыса, фантазияне чикли. Театр художнигы ирексездән шартлы билгеләр белән генә канәгатьләнергә мәҗбүр була.

Матди һәм техник яктан хәзергә Минзәлә театры бик ярлы. Артистлар кысан сәхнәдәге юк нәрсәне тасвирлап уйнарга мәҗбүр булалар. Ә бу ясалмалылыкка китерә. Хәзерге заман театр художнигы алдында ике юл бар: я син инде кемдер уйлап тапканны кабатлыйсың гына, я үзенчәлекле яңа формалар эзләү, яки ялгышлар аша авыр булса да шатлыйклы табышларга тап булу.

Театрның үсеше өчен икенче юл кирәк. Эксперимент булмаган җирдә иҗат юк. Соңгы елларда Минзәлә театрында бу якка мәгълүм уңышлы адымнар ясалды. Шунысы кызык: традиционлыгы белән танылган һәм дан тоткан бу театрның иҗат коллективы яңалыкка бик сизгер, кыю эзләнүләр, тәҗрибә ясауларны ярата һәм бу нәрсә җитди генә уңышларга да китерде. Бу җәһәттән яшь, яңа драматурглар иҗатына мөрәҗәгать итү бәрәкәтле булды. Баш режиссер Мулланур Мостафин заман рухын, кешеләр холык-фигыле диалектикасын, тормыш динамикасын нечкә тоеп иҗат итә. Спектакльләр шартлы алымнар, символ дәрәҗәсенә күтәрелгән ишарәләр, бәрәкәтле чишелешләргә мул.

Бу үсеш спектакльләрнең декорациясендә дә ачык чагыла. Декорацияләр бүлмә, урам, колхоз идарәсе, завод цехының турыдан-туры күчермәсе түгел. Режиссерның автор идеясен сәхнәдә гәүдәләндерү алымына яраклы рәвештә рәссам вакыйга бара торган урынны эчке бер мәгънә салып эшли. Авыл өенең гомуми күренешен һәр тамашачы ачык күзаллый. Шуңа күрә аны бөтен вaклыклары белән күрсәтү хәҗәт түгел. Пьесаның жанрын искә алып, бүлмәдәге әйберләрнең төре, торышы, төсе һәм яктылык сайлана. Аларның һәркайсы геройлар яшәгән заманны, халәтне капшап карагандагыча, күз алдына бастырырга, тамашачының күңелен шул халәт рухы белән сугарырга тиеш. Сер түгел, кайвакытны театрларыбыз иске, геройларның характерларына ярашып бетмәгән әйләнә-тирә күренешне тәкъдим итә. Ул гына да түгел: артистларны нинди дә булса хәрәкәт белән мәшгуль итү өчен генә персонажлар бүген инде хаҗәте булмаган урындыклар ясыйлар, камыт тезәткәлиләр, такта ышкылыйлар. Ә заман бүтән! Элеккеге театр эстетикасы яңарышлар белән алышынса гына байый! Тормышның актуаль мәсьәләләре, таләпләре, кеше психологиясе турында тикшеренүчән акыл белән уйланыр, автор белән театр идеясен тирәнрәк һәм тирәнрәк ачар өчен рәссамга яңа формалар эзләнү шарт. Хәзер хәтта буш стена яисә кара бәрхет тә бүтәнчә файдаланырга хаклы. Пәрдәне тиз яки әкрен ачу да өстәмә тәэсир итү чарасы йөзендә хезмәт итә ала.

Кызганычка каршы, республикабыздагы күчмә театрларда спектакльләрнең ритмын, аларның төзелеше формасын үзгәртүе яки яңартуы чиктән тыш кыен. Шулай да театрлардагы рәссамнарга бүгенге мөмкинлек-

ләрне, хәтта ул мөмкинлек булмавын да файдалану сорала. Кемдер җитешсезлекләрне үзенең осталыгы юклыгын каплар өчен сылтау итеп файдалана. Тик Альфер Яһудин андыйлардан түгел. Ул театрга яңа мөмкинлекләр тәкъдим итә. Тик ниндидер стереотип фикерләү, халык аңламас дип өркү аның байтак башлангычын эскизларда гына калдыра.

А. Яһудинның спектакльләр өчен ясаган декорацияләрендәге үзенчәлек нидән гыйбарәт? Бер төрле генә җавап бирү дөрес үк булмас иде: һәр спектакль — кабатланмас сәнгать. Шулай да аның иҗатына хас гомуми бер үзенчәлекне атап булырдыр. Ул да булса вакыйганың төп фоны. Ул аны һәрвакыт бәрәкәтле хәл итә. Бердән, моны күчмә театрның эш шартлары таләп итә. Режиссер һәм рәссам һәр көрәш мәйданы, һәр почмакны файдаланырга тырыша. Икенчедән, тамашачыга гомуми күренешне тулысынча хыялында күзаллау өчен иң төп детальләрне күрсәтү дә җитә. А. Яһудин сәхнә мәйданын мөмкин кадәр иркен, буш калдырырга ярата, вакыйга һәм актерлар өчен иң кирәкле әйберләрне генә куллана.

Форма ягыннан никадәр генә яңалык кулланмасын, ул традицион рухта иҗат итә. Макетлар белән мавыкмый. Аның өчен иң югарыгы омтылыш — төсләр. Аларны ул еш кына контраст итеп, бер-берсенә каплама-каршы куеп, динамикада куллана. Чөнки төсләр көрәшенең тамашачыга тәэсир итү көче зур. Бу җәһәттән ул «Соңгы ләкләк» спектаклендә бирелеп эшләде. Гаять саран сәхнә. Караңгы һәм кызыл төсләр көрәше. Иске җил тегермәне һәм тупас бер корылма. Ярык тегермән ташы һәм учак. Таш вакыйгага катнашучы геройлар арасындагы бәйләнешләрнең ярыклыгына ишарә, ә учак — суынган мәхәббәт, үткәндәге ялгыш, бүгенге саран мөнәсәбәтләргә каршы куелган кайнар тормыш, яшәү мәгънәсе.

Альфер Яһудинның арткы рәсемнәре тәэсирле. Алар спектакльне үзенә генә хас бер шигъри рух белән өртеп, образлар дөньясын тутырып торалар. Кайвакыт алар романтик хистә, тормыштан әз генә күтәрелеп торучан. Ә. Баяновның «Һәйкәл» дигән драматик поэмасы нигезендә эшләнгән спектакльнең бизәлеше шушындый иде. Костюмнар, вакыйгада катнашучы әйберләрнең төсләре дә арткы рәсемгә яраштырып, килешле итеп алына.

Декорация эскизларының спектакльдә кулланганнары белән генә чикләнмичә, ул аларның берничә вариантын үзе өчен дә ясап куя. Һәм алар мөстәкыйль иҗат үрнәге итеп каралырга хаклы тулы канлы сәнгать әсәре булып чыгалар. Аларда Ык буе таллары, ул яшәгән төбәк каеннары, Минзәлә ягы кешеләренең киң күңелләре, олы җаннары чагылыш таба.

Сәнгать күп сөйләгәнне яратмый. Сәнгать — сүз түгел. Сәнгать — йөрәк ярасы һәм маңгай тире ул. Син яралы йөрәгең, тирле маңгаең булу белән бәхетле, рәссам. Вөҗдан сафлыгына, намусның тугрылыгына, дөреслек горурлыгына шундый бәхет белән генә ирешеп була.

Иң мәһиме — барып җиту. Тамашачы күңеленә, үзеңнең хыялыңа. Мин синең киләчәк авыр юлыңны күрәм. Ул юлны кызыксыну һәм игътибар нуры яктыртып торачагына ышанам. Яшәүнең мәгънәсе ышануда һәм ышандыра алуда.

# КАРАҢГЫЛЫК ПАТШАСЫНЫҢ СЕРДӘШЕ

...Нева буендагы таш түшәлгән урамнан атлаганда баш очында еш кына бернинди күк җисеме дә күренми. Теоретик астрономия институты шушында, кышын-җәен томаннан арынмаган Ленинградка урнашмаса, ни була инде? Йолдыз күзәтүчеләргә ачык күк йөзе дә кирәктер ләбаса?!

...Урта гасырларда математика магистры исеменә имтихан тотучы һәр кешегә Пифагор теоремасын исбатлауны бирә торган булганнар. Шуны белгән кеше генә математикада зур гыйлем иясе исәпләнгән. Хәзер инде без бу теореманы ничәнче класста өйрәнгәнлегебезне дә оныттык. Белем хәзинәбез бермә-бер ишәйде...

Ләкин... теоретик астрономия институтында эшләүче якташыбыз Шәфика Шәрәфнең монографиясе күпләрне тәмам аптырашта калдырачак. Чөнки аны кирәк башыннан, я кирәк ахырыннан укырга кереш — барыбер: сәер хәрефләрдән төзелгән су буе тигезләмәләрнең серен чишү һич мөмкин түгел. Бер укучысы турында фикерен сорагач, күренекле немец математигы Давид Гильберт: «Ә-ә, аны әйтәсезме? Ул шагыйрь булып китте. Математик булу өчен аның хыяллану куәсе җитәрлек түгел иде»,— дигән...

Ш. Шәрәф монографиясен укып баш каткач, астроном булыр өчен бәлки чыннан да Гильберт күздә тоткан сәләт кирәктер? — дип уйларга мәҗбүрсең. Күзгә дә юньле-башлы күренмәгән планетаның галәм киңлекләре буйлап миллионнарча чакрымга сузылган юлын ике гасырга алдан исәпләп һәм сызып кую уен эш мени?!

Әлеге Плутон планетасы безнең заман өчен билгесезлек ачылмаган серләр сандыгы була. Моңа ышаныр өчен берничә дәлил китерү дә җитә: бу күк җисеме Җирдән Кояшка караганда уртача кырык тапкыр чамасы ераграк, ә аның диаметры исә Кояшныкыннан 218 мәртәбә кечерәк. Җитмәсә, мул хәбәр китерерлек нурлар да таратмый ул — планетада 230 градуслы чатнама суык. Менә шуңа күрә егерменче гасыр башына кадәр аның барлыгын кешелек дөньясы белмәгән дә. Кояш системасының иң ерак планетасы Плутонны 1915 елда теоретик рәвештә П. Ловелл, практик төстә 1930 елда К. Томбоу ача. Яңа күк җисеме турында мәгълүматлар туплау гаять читен була. Плутон тирәсендәге билгесезлек томанын таратуга Шәфика Шәрәф берничә дистә ел гомерен багышлый. Әгәр соңгы елларда басылган энциклопедияләрдә Плутон хакында мәгълүматлар киңәя төшкән икән, монда, әлбәттә, аның да күренекле өлеше бар.

Казанда кемдер: «Шәфика Шәрәф дигән астроном кызыбыз теоретик рәвештә яңа йолдыз ачкан икән, хәзер шуны Америка астрономнары телескоп белән эзләп тапкан һәм аңа, галим хөрмәтенә, Шәрәф исеме кушкан»,— дигән иде. Әмма Нева яры буенда Шәфика Шәрәф үзе бернинди йолдыз да ачмавын бик тыныч кына белдерде.

«Ай белән кояш бер генә, йолдыз сиксән мең генә»,— дип җырлыйлар җырлавын, әмма эшләр катлаулырак бит әле безнең,— диде ул елмаеп.— Унберенче зурлыкка кадәрле йолдызларның гына да каталогка кертелгән саны бер миллионга җитә. Егерме беренче зурлыкка кадәрле ике миллиардлап йолдыз фотоатласта күренә. Бу — безнең галактиканың барлык йолдызларын да әченә алмый әле. Ә бүгенге фән

һәм техника инде егерме беренче зурлыктагы берничә миллион галактиканы рәсемгә төшереп алырга мөмкинлек бирә...

— Ул галактикаларның һәрберсендә тагын икешәр миллиард йолдыз тупланганмы икән?

— Бик ихтимал!

Тукта, әгәр безнең техника тагын да камилрәк, зуррак диаметрлы телескоп ясаса, егерме дүртенче зурлыктагы йолдызлар яки галактикалар күренәчәк икән ич — берьюлы меңләгән яки миллионлаган йолдыз ачылачак! Болай булгач, һиндидер бер күк җисемен ачу вакыйга да түгел икән ләбаса. Алайса ни белән дөнья шаулата соң бу астрономнар?

— Хикмәт бер яки ике яңа йолдыз ачуда түгел,— ди Шәфика ханым,— кешелек күк җисемнәренең табигатен танып-белергә ашкына. Бәлки сезгә дә мәгълүмдер, ерак йолдызлар гына түгел, инде әллә кайчаннан бирле билгеле, Зөһрә дип, Чулпан дип җырларга кергән якын күршедәге планетабыз да сер пәрдәсен бик үк ачып бетерми ич әле безгә...

Шәфика ханымның үз өлкәсе хакында сөйләве гаять зур кызыксыну уята.

— Күк җисемнәренә карап диңгездә йөзү, вакытны төгәл исәпләү, геодезик һәм картографик тикшеренүләр үткәрү кебек эшләр эшләнсә дә, астрономия фәне гасырлар буе күп кенә ягы белән барыбер абстракт фән булып кала бирде. Әмма соңгы чорда электроника, радиофизика, кибернетика һәм космик техниканың бик тиз үсүе аркасында байтак яктан традицион практик кулланылышын югалтты. Хәзер аның бөтен тырышлыгы нигездә саф космик күренешләрне өйрәнүгә кайтып калса да, астрономия бүгенге табигать фәненең алгы сафына чыкты. Чөнки фән-техника революциясе фундаменталь гыйльми тикшеренүләрне алгы планга этәрде, нәкъ менә шушы юнәлештәге ачышларның фән-техника прогрессына тәэсире көчәйде. Безгә әлегә билгеле булмаган физик шартлар һәм күренешләрне, материянең яңа яшәү формаларын, яңа энергия чыганакларын күп төрле космос лабораторияләрендә генә өйрәнергә мөмкин. Шуңа күрә дә астрономик күзәтүләр хәзер табигать һәм аның законнары турындагы карашларның үсеше өчен әһәмияте гаять зур булган гаҗәеп физик информация чыганагына әверелә бара. Фәннең иң алгы сафында булганлыктан, астрономнар гадәттән тыш сәер объектларны, көтелмәгән күренешләрне, серле проблемаларны башкаларга караганда ешрак очратса да гаҗәп түгел. Шунлыктан, алар гадәттәгегә охшамаган аңлатмаларны ешрак эзләргә, элеккеләреннән аерылып торган өр-яңа физик концепцияләрне күбрәк иҗат итәргә һәм яңадан-яңа идеяләр табу белән шөгыльләнергә мәҗбүр. Аларның бу эше, әлбәттә, башка белемнәр өлкәсендәге шикелле үк, төрле дәлилләр җыю, тәртипкә салу һәм аларның дәрәслеген тикшерү буенча үткәрелә торган гаять зур тырыш хезмәткә таяна.

Шәфика ханым үзе дә нәкъ менә шундый дәвамлы эшләр белән мәшгуль була. Алар арасында җир климатының астрономик теориясенә бәйле тикшеренүләр бигрәк тә мөһим урын тота.

Безнең гасырның егерменче елларында ук күренекле югослав галиме Миланкович Җир орбитасы һәм Җир күчәре авышлыгы үзгәрү планетабызның һава хәленә тәэсир иткәнлеген ачыклый. Ш. Шәрәф, бу күренешне өйрәнүне дәвам итеп, кояш системасындагы зур планеталарның тартылуы һәм башка сәбәпләр аркасында вакыт узу белән Җир орбитасы, Җир күчәре авышлыгы үзгәрүне җентекләп тикшерә. Шундый эффектлар нәтиҗәсендә Җир өслеге температурасы үзгәрүен исәпли, югарыда әйтелгән күренешнең климатны озак вакытка җылыта яки суыта торган сәбәп икәнлеген исбатлый. Аның бу хезмәте климат өйрәнүчеләр һәм геофизиклар тарафыннан югары бәяләнә.

Шәфика ханым әле дә бу өлкәдәге тикшеренүләрен дәвам итә, тик хәзер инде ул Марс климатын өйрәнә.

Әмма фән дөньясында якташыбызның исеме күк механигы буларак атаклы. Астроном галимнәрнең әнә шулай үтә гадәти җир һөнәренә бәйле исем алуына сәерсенүне күреп булса кирәк, Шәфика ханым тагын бер халык җырын телгә алды:

«Һавада йолдыз ничәдер, Ничә генә баксаң, күчәдер...» — диләрме әле? Халык элек-электән күк йөзен игътибар белән күзәткән, күрәсең. Әйе, йолдызлар да, пла-

неталар да — барлык күк җисемнәре дә мәңгелек хәрәкәттә. Безгә инде шул хәрәкәтне өйрәнергә туры килә,— ди галим.

Кояш системасында астероидлар боҗрасы дигән бик кызыклы күк җисемнәре бар. Марс белән Юпитер орбиталары аралыгында хәрәкәт итүче бу җисемнәр ике меңгә якын. Аларның диаметры берничә чакрымнан алып мең ярым километрга хәтле җитә. Бу җисемнәрне кече планеталар дип тә атыйлар. Аларның иң зурысы һәм яктысы — Церера.

Церера 1801 елда итальян астрономы Дж. Пиаццио тарафыннан ачыла. Атаклы математик К. Гаусс аның орбитасын исәпләп чыгара.

Кече планеталарның хәрәкәте санлы интегралны табу ысулы белән өйрәнелә. Әмма хәзер планеталар хәрәкәтенең аналитик теориясен барлыкка китерү көн тәртибенә куелды. Церера планетасына карата В. Ф. Проскурин башлаган бу эшне Шәфика ханым дәвам итә. Бар тырышлыгын һәм иҗади көчен шушы хезмәткә багышлаган галим якын киләчәктә аны тәмамлау алдында тора.

Шәфика Шәрәф турында язу җиңел түгел: эше белән танышу өчен махсус әзерлек кирәк, иҗат процессы һәм тормышы белән кызыксынганны исә ул үзе һич тә өнәми.

— Мин сезгә искитәрлек берни дә хәбәр итә алмам,— диде ул, мәсәлән.— Извицкая журналистларга 134 төрле салат әзерли белүен белдергән. Ә минем андый осталыгым да юк...

— Миңа нәкъ киресен сөйләгәннәр иде шул. Әдәбият, музыканы яхшы белүегезне дә әйттеләр.

— Кирәген бирермен әле мин аларга... Гомумән, безнең эшебез кызыклы түгел. Китап, кәгазь, карандаш, теория. Менә Габдрахман ага Таһирҗановның «Казан утлары»нда басылган мәкаләләре, ичмасам, һәркем һәвәсләнеп укырлык. Алмаз Монасыйповның «Тукай аһәңнәре»н, Рөстәм Яхин романсларын кат-кат тыңларга була. Ә безнең эш...

Кыска гына әңгәмә вакытында да аның Р. Нәфигов мәкаләләрен, Ә. Еники әсәрләрен яратып укуын, татар сәнгате белән дә яхшы таныш булуын чамалау кыен түгел иде. Тик әңгәмә үзенә кагылдымы — сүз өзелә дә кала.

Шәфика ханым Казанда туган, Вахитов исемендәге мәктәптә укыган һәм җечкенәдән үк математика, физика белән мавыккан. Шуңа күрә ул Орел педагогия техникумыннан соң белем алуын Ленинград университетының физика-математика факультетында дәвам иткән. СССР Фәннәр Академиясенең теоретик астрономия институтында аспирантура узган. Аның Плутон планетасына багышлап язган бер доклады СССР Фәннәр Академиясе член-корреспонденты М. Ф. Субботинның игътибарын җәлеп иткән. Күренекле галим шуннан соң сәләтле кызга Плутонны тирәнрәк өйрәнергә киңәш биргән.

Плутон — караңгылык патшасының исеме. Планетаның исеме җисеменә туры килә — бик ерак булуы аркасында аңа кояш нуры җиргә төшкәндәгедән 1600 мәртәбә кимрәк төшә икән. Күк йөзендә гади күзгә күренә торган алты мең йолдыз бар, яктырту зурлыгы буенча алар алты төркемгә бүленә. Алтынчы зурлыктагысы беренче зурлыктагыдан йөз тапкыр тоныграк җемелди. Ә Плутон исә яктылыгы буенча унбишенче зурлыктагы йолдызга тиң. Плутонның диаметры һәм авырлыгы Җирнекеннән ике тапкыр, күләме һәм массасы исә ун мәртәбә кечерәк. Ул үз күчәре тирәсендә 6,4 Җир тәүлегендә бер әйләнеш ясый, Кояш тирәли әйләнеп чыгар өчен исә аңа 251 Җир елы кирәк! Шәфика Шәрәф үзенең тикшерү эшләрен әле югарыда саналган мәгълүматларның хәтсезе фәнгә билгеле дә булмаган чорда башлап җибәрә.

Планеталарның хәрәкәт теориясен төзү астрономия өчен һәрвакыт фундаменталь әһәмияткә ия. Сигез зур планетаның хәрәкәт теориясен эшләү нигездә XX гасыр башында ук тәгәлләнә. Плутонның аналитик теориясен барлыкка китерү бу планетаны танып-белү өчен генә түгел, күк механикасының классик алымнарын тагын да үстерү, башка планеталар хәрәкәте теориясен камилләштерү өчен дә әһәмиятле була. Чөнки Плутон, бүтән планеталар сыман, түгәрәк орбита буенча түгел, ә бәлки сузынкы эллипс буенча хәрәкәт итә һәм Нептун орбитасы эченә дә кереп чыга. Нептун һәм Плутон орбиталарының болай урнашуы хәрәкәт теориясен эшләгәндә галәмәт зур кыенлыклар тудыра. Шуның өстенә, галимнәр күзәтә башлаган чорда әле

Плутонның үз орбитасы буйлап бик аз юлын гына узуын да истән чыгармыйк. Әле башка планеталар белән үзара тәэсир итешүләр дә бар ич!

Әмма Шәфика ханым барлык кыенлыкларны уңышлы җиңеп чыга. 1950 елда ул «Юпитер йогынтысы нәтиҗәсендә Плутон хәрәкәтендәге үзгәрешләр» дигән темага кандидатлык, 1965 елда исә «Плутон хәрәкәте теориясе» дигән темага докторлык диссертациясе яклый.

Совет галименең бу ачышы турында ТАСС агентлыгы түбәндәгечә хәбәр итте: «Ленинград астрономы Шәфика Шәрәф тугызынчы планета хәрәкәтенең аналитик теориясен төзеде. Бу астрономнарга Плутонның элек кайсы вакытта кайда булганлыгын һәм киләчәктә кайсы вакыт берәмлегендә кайда булачагын белергә мөмкинлек бирде. Шәрәф теориясе Кояш системасы турында безнең белемнәребезне тулыландыра, киләчәктә ул планеталарның барлыкка килүе турындагы кайбер гипотезаларны тикшерергә дә ярдәм итәчәк. Бу фәнни эшне башкару өчен Шәрәфкә бихисап күп исәпләргә туры килгән, чөнки хезмәтенең беренче өлешен ул гап-гади арифмометр ярдәмендә үтәгән, бары тик соңгы елларда гына аңа аналитик-исәпләү машиналары ярдәмгә килгән».

«Шәрәф теориясе шул яктан да әһәмиятле — бу эшне ул дөньяда беренче булып башкарып чыкты,— дигән аннары теоретик астрономия институты директоры профессор Глеб Александрович Чеботарев. — Шәрәф ачышыннан соң берничә ел үткәч, Америка галимнәре, тулыландырылган фактлардан файдаланып һәм яңа алым кулланып, Плутон хәрәкәтен ер-яңадан исәпләп чыгардылар. Алар да, нигездә, Шәрәф ясаган нәтиҗәләргә килде».

Теоретик астрономия институты безнең илебездә үз өлкәсендә бердәнбер фәнни үзәк булганлыктан, «СССР астрономия берьеллыгы», диңгезчеләр һәм очучылар өчен ел саен чыгарыла торган астрономия белешмәлекләре дә әзерләнә. Бу белешмәлекләр кораб һәм самолетларның юлын дөрес билгеләү өчен бик әһәмиятле. Карталар төзегәндә дә, Җир юлдашлары һәм космик кораблар җибәргәндә күк җисемнәренең торышын ачыклау һәм шуларга бәйле рәвештә юнәлешне сайлау кирәк.

Шәфика ханым күп еллар буе мондый белешмәлекләрне төзүдә даими катнашып килә. «Теоретик астрономия институты бюллетене», «Теоретик астрономия институты хезмәтләре» кебек басмаларны да дәвамлы рәвештә ул редакцияли.

«Хатын-кызларга да тамак кайгыртырга туры килә,— дип яза Шәфика дөньяга килгән елларда «Вакыт» газетасы,— ләкин кулдан килгән һөнәре булмагач нишләсен? Чарасыздан кер юарга, кассапларда эч-карын тазартырга вә башка шуның кебек кара хезмәтләргә керешәләр. Булмаса, ул да юк! Әллә никадәр яшь һәм сәламәт кызлар хөерчелеккә яки угрылыкка керешә». (1913, № 1251).

Татар кызлары язмышында бер буын гомере эчендә нинди искиткеч үзгәреш! Физика-математика фәннәре докторы, Ленинград теоретик астрономия институты өлкән фәнни хезмәткәре, гыйльми советның иң актив әгъзаларыннан берсе, дәүләт бүләкләренә лаек булган Шәфика Шәрәф Бөтенсоюз конференциясендә доклад укый. Эш арасында классик музыка концертына йөри, сәнгать җәүһәрләрен карарга сәяхәткә чыга, чаңгы шуа, аннары Америкада басылган мәкаләсе белән таныша...

Нева буеннан астроном якташыбыз атлый. Халкыбызга дистәләрчә фән кандидаты һәм докторы, язучы, композитор, мәгърифәтчеләр биргән атаклы Шәрәфләрнең — Татарстанның Буа районы Аксу авылыннан таралган укымышлы нәселнең бер вәкиле. Аның атасы Гыйльметдин абзый культурабыз тарихында йөздән артык китап чыгарган «Матбагаи Шәрәф» нәшриятын оештыруы, җөмләдән, халкыбызның сөекле шагыйрьләре Г. Тукай, М. Гафуриларның беренче җыентыкларын бастыруы белән мәшһүр. Шәфика ханымның даны исә тагын да киңрәк таралган — аның исемен ерак илләрдә яшәүче укымышлылар да яхшы белә: ул караңгылык патшасының галәм төпкеленә яшергән байтак серләрен ачкан, төзегән теориясе инде дөнья күләм танылу тапкан.

Гомер буе эшли торган эшеннән берничә сәгатькә дә аерылырга теләмәгән Шәфика ханым нәкъ менә астрономик исәп-хисаплардан шигърият тапкан бәхетле зат.

**ТӘҮФИКЪ ӘЙДИ.**

# КАЕН УРМАНЫНЫҢ ТЫНЛЫГЫН САКЛАП

Таң алдыннан сөттәй ап-ак томанга төренгән авыл белән каен урманын чак-чак кына шәйләргә мөмкин. Ә авыл янынннан гына ташларга бәрелә-бәрелә челтерәп инеш ага. Үләннәргә кунган чык дымы озак йөреп арыган аякларга ниндидер бер рәхәтлек бирә, җиңеллек өсти. Рәфкать ашыга-ашыга атлый, аның тизрәк, офыкта кояшның беренче нурлары күренгәнче үк, үзе яраткан урынга, таныш чоңгыл янына барып җитәсе килә.

Менә ул күе таллык янына килеп җитеп туктады да кармак җебен сүтәргә керешә. Бераздан ул, яр читендә яткан агач өстенә утырып, тоныкк су өстенә карап уйга калды. Ничә ел инде биредә булганы юк, балачактан таныш урыннар аз гына да диярлек үзгәрмәгән. Бары каеннар гына, буй җиткән кызлар төсле, тагын да үсә, матурая төшкәннәр.

Шулчак аның колагына таныш тавыш ишетелде. Ул офыкка күз ташлады. Таң кызыллыгы иңгән иксез-чиксез киңлектә, үз артыннан бөдрәләнып торган эз калдырып, көмештәй ялтырап самолет оча иде. Ирексездән Рәфкатьнең уйлары дуслары-иптәшләре янына әйләнеп кайтты. Алар да менә хәзер, колач җитмәс Ватаныбыз имин-леген саклап, зәңгәр күктә үз буразналарын сызалардыр!..

Дусларын, яраткан эшен сагынырга да өлгерде инде ул. Гәрчә аңа монда, үзе кунак булып кайткан туган йортында, күңелсезләнергә һич сәбәп юк: сый-хөрмәт дисеңме, күңел ачып сөйләшеп утырулар дисеңме. Яки әтисе йөрткән автобуста Чиләбе якларында, Кунашак районы юллары буйлап сәяхәт кылып йөрүләр үзе ни тора! Хәер, очучы кайда булмасын — су буенда балык тотамы, әллә әнисе пешергән коймак белән сыйланамы, төмләп һинд чәе эчәме — барыбер аның уе бер тирәдә әйләнә. Ул үзен хезмәт иткән частенда, үз самолетының кабинасында итеп тоя. Ә самолетның штурвалына кагылып алу синдә бәр ни белән дә чагыштырып булмаслык дәрәҗәдә горурлык хисе уята. Үзең белән, дусларың белән горурлану хисләре бу. Мондый чакта күңел ерак киңлекләргә ашкына...

Мөмкин чаклы биеккәрәк, кошлар очып менә алмас югарылыкка күтәреләсе килә! Рәфкать Шакировта бу теләк-омтылыш күптән, үзе әле яңа очарга өйрәнә башлаган училище елларында ук туган иде. Менә синең алда якты кояш нурларына чумган зәңгәр күк гөмбәзе ачыла. Ул сине һәрчак алга әйди, үзенә тарта. Шул көннән башлап Рәфкать бөтен җаны-тәне белән серле, могҗизалы биеклеккә ашкына. Анда асыл ир-егетләрнең чын характеры ныгый, ихтыяры чыныга, осталыгы арта.

... Ул көнне Шакиров экипажы өйрәнелгән, таныш маршрут белән оча иде. Һәммәсе иппе генә кебек, барлык система һәм приборлар карусыз эшли. Бер ни дә хәвеф-хәтәр турында искәртми. Ләкин авиациядә көтелмәгән хәлләр дә килеп чыккалый. Бүген менә Рәфкать һәм аның экипажы шундый хәлгә юлыкты.

Прибор уклары биеклекне күрсәтә: җирдән ераклык 15 километр... 20 километр. Кинәт сулдагы двигатель параметрлары бик тиз үзгәрә башлады. Ләкин Шакиров югалып кала торганнардан түгел: килеп туган очраклы һәм хәтәр хәлне тиз арада бәяләп, өйрәнү очулары башкарган самолетлар группасын алып баручы, җитәкчегә

зобәр итте. Аннары салкын кан белән, класста күнегү үтәгән кебек, кискен, кыю һәм җаваплы очышны уңышлы башкарып чыкты.

Шушы очыштан соң коммунист Шакировка кыюлык һәм осталык күрсәткәне өчен флот командующие тарафыннан рәхмәт язуы тапшырылды.

Нинди генә кыен минутларда да югалып калмау, рухың белән һәр нәрсәгә әзер булу — капитан Шакировка хас төп сыйфатларның берсе шушыдыр, мөгаен. Бүтәнчә булуы мөмкин дә түгел! Һавадагы хәзерге сугышта үз һөнәренең бөтен серен үзләштергән, катлаулы техниканы һәм коралны белеп файдаланган, шуның өстенә куркуның ни икәнен дә белмәгән, гаять чыдамлылыкка ия булган, иң хәтәр, иң хәвефле минутларда тәвәккәллеккә барырга әзер торган, дошман белән алышта төп җаваплылыкны үзенә алган, иптәшләрендә өмет, дәрт уяткан кеше генә җиңеп чыга ала.

Тегә чакта хәтер түрендә онытылмаслык булып уелып калган очышта Рәфкать нәкъ менә шундый сыйфатлар күрсәтте дә. Бу сыйфатлар аңа, әлбәттә, әтисеннән, Бөек Ватан сугышы ветераны, элеккеге сержант-элемтәче Мөхәммәт агадан күчкәндер. Ул да бит аяусыз сугыш кырында ничәмә тапкыр үлем белән күзгә-күз очрашкан. һәм аның һәркайсында җиңеп чыккан.

Рәфкатьнең дә характеры тиз генә, үзеннән-үзе генә чыныкмады, билгеле. Ләкин бөтен кыенлыкларны сыкранмыйча җиңеп чыгарга, коммунистларча алдан барырга омтылу аны чын очучы итте. Чираттагы очышта иң катлаулы бурычны үтәп, капитан Шакиров һәрвакыт җиргә рухи күтәренкелек, үзенә һәм дусларына карата олы ышаныч алып кайта. Әгәр аның алдына җаваплы эш куела, зур бурыч йөкләнә икән, Рәфкатьнең бөтен җанын ялкын биләп ала, ул фәкать шушы эшне, шул бурычны үтәү уе белән генә яши башлый. Очучы йөрәге — күктә. Рәфкать белән кем генә очрашмасын, аның оптимистлыгы, иң кыен очышның да уңышлы тәгәлләнәгәченә ышанычы бу кешегә дә күчә.

Аңарда да шул уй, шул хис кабына.

— Җиңелдән булмас, — ди экипаж штурманы уйчан гына итеп, картаны җентекләп карый-карый, — һаваның рәте китте, җитмәсә, биеклек...

— Бурыч катлаулы шул, — дип куәтли аны оператор. — «Үзәккә» тидерә алмавың да бик мөмкин.

— Юк, һичшиксез тидерәчәкбез! — дип кычкырып әйтте Рәфкать. — Отличнодан башка билгә алу егетлек түгел. Гомумән, төшенкелеккә бирелү килешми безгә.

Авиаторлар, бер-берләренә карашып, елмаеп куйдылар.

— Характерыгызны әйтер идем, иптәш командир, ут икән! — ди штурман. — Сынатмабыз, бомбаларны нәкъ тиешле ноктага «яудырырбыз», мишень «үзәгенә» тидерербез.

Егетләр сүзләрендә тордылар — уңышлы башкарылган өйрәнү очыш өчен «бишле» билгесе куелды.

...Рәфкатьнең уйларын бүлеп, су өстендә калкавыч селкенеп куйды. Ул җәһәт кенә кармак сабыннан тартты. Кискенрәк тартылды, ахры. Кармактан ычкынган алабуга көмеш тәңкәләрен кояшта чагылдырып алды да чалт итеп суга чумды. «Менә сиңа балыкчы! — диде Рәфкать үз-үзенә эчтән генә. — Күп нәрсә онытылган икән».

Капитан үзенең кирәк-яракларын җыйды да, чыклы үләннәрне ерып авылга таба атлап китте. Ә кояш нурларына коенып, иркәләнеп, гүя тибрәлеп торучы зәңгәр күк гөмбәзендә очып үткән теге самолетның ап-ак эзләре әле дә ярылып ята... Тагын берничә көннән ул да, Рәфкать Мөхәммәтович та, үз частена әйләнеп кайтыр. Ә анда аның сугышчан дуслары, көннең көнендә Ватан күгенә күтәрелеп, шушы кояш, шушы каен урманы тынычлыгын уяу саклыйлар.

**Н. СТУПНЕВ.**

# БЕРЬЮЛЫ — ЙӨЗ ЯЗМЫШ

ИНТЕРВЬЮ

*Кадерле редакция!*

*«Икмәк тәме» исемле күпсерияле кинофильмда артист С. К. Шәкүрев гәүдәләндергән Сечкин образын без аеруча ошаттык. Картлар Сергейнең Мәскәүдә яшәгән авылдашыбыз Каюм абзый улы булырга тиешлеген әйткәч, кызыксынуыбыз тагын да арта төште. Сез талантлы артист Шәкүрев иҗаты белән киңрәк таныштыра алмассызмы икән?*

Ульяновск өлкәсе Бакырчы авылы яшьләре.

## Актер иҗат үрендә...

Сергей Шәкүрев турында бүген менә шулай дияргә мөмкин. Театр һәм кинода ул инде күптәннән һәм бик җитди эшләп килә. Әмма киң катлау тамашачыларга ул үзен экранда соңгы чорда күренгән берничә роле белән генә кабатланмас оста икәнлеген таныттты. «Балачактан соң йөз көн»дә вожатый Сережа, «Икмәк тәме»ндә совхоз җитәкчесе Сечкин һәм «Сибириада» фильмында кулак Спиридон Соломин бер-берсенә бөтенләй охшамаганнар.

Шундый капма-каршы кешеләргә ничек әверелә ала икән соң ул.

Әңгәмә бик кызыклы булыр сыман тоелды. Сүземне танышудан башладым.

— Сез кайсы яктан?

— Арбатта туганмын, — диде Сергей. — Әтием Мәскәүгә Идел буендагы бер татар авылыннан утызынчы елларда ук күчеп килгән.

Башкаланың борынгы урамын телгә алу әңгәмәбезне ирексездән үткәнгә, мәктәп елларына ук алып китте.

Бөтен малайлар бервакыт кем булырга, кайсы юлдан атларга белми аптыраган минутлар кичерә. Сергей Шәкүрев исә максатының ачыклыгы белән иптәшләрен дә, укытучыларын да таң калдыра. «Спорт, спорт һәм тагын бер мәртәбә спорт!» Унсигездә инде ул акробатика буенча спорт мастеры исемен казана.

— Аңлашылсын өчен ничек әйтим икән соң? — дип җафалана әңгәмәдәшем. — Мин — никтер, эшемне яратам, әмма спортны әле дә үз язмышым саныйм.

— «Хобби» дигән бер модалы сүз бар, — дим мин аңа булышырга теләп.

— Юк лә! Туры килми ул бу очракта. Актер хәлендә дә спорт белән шөгыльләнүемне дәвам итәм мин: йөгерәм, футбол уйныйм. Яхшы форма саклар өчен генә түгел. Спорт минем өчен шатлык, ихтыяҗ, гомерлек мавыгу. Юк, мавыгу гына түгел, чөнки мин аңа бөтен җаным-тәнем белән бирелəм һәм җиңүгә омтылам. Әгәр футбол икән, тупны капкага үзем кертергә ашкынам (әле берне генә дә түгел!)... Холкым тәэсирләнүчән, спорт миндә киртәләрне үтеп чыгарлык сүрелмәс рух тәрбияли, уңышсызлыклардан башны югалтмаска өйрәтә.

Шәкүрев көлеп:

— Сез тагын актер һөнәрен икенче урынга гына куя икән бу, дип уйлый күрмәгез,— диде.— Мин тормышны чамадан тыш яратам. Комсыз, тыелгысыз, туймас рәвештә. Кайчак миңа үзеңне тулысынча нинди дә булса бер генә нәрсәгә бирсәң, бер генә гомер дәвамында барлык дөньяны колачлап булмас шикелле тоела. Җирдәге бөтен гүзәллекне күрер өчен йөз гомер кирәк сыман.

Артист һөнәре нәкъ менә берьюлы күп тормышны кичерергә мөмкинлек бирә. Шуңа күрә дә бер-берсенә һич охшамаган, минем биографиядән бик ерак торган рольләрне уйнау бөтен барлыгымны били. Үзем өчен дә, тамашачылар өчен дә яңалык ачам...

Әмма мәктәбенең горурлыгы саналган спортчы Сергей Шәкүрев актерлык һөнәренә дә бик яшьли тартыла. Йортлар идарәсе каршында Үзәк балалар театры артисты Валентин Захода җитәкчелегендә драмтүгәрәк оештырылгач, бүген инде киң танылган В. Смирнитский, А. Чернова, В. Бочкарев белән бергә Сергей да үзешчәннәргә кушыла. Шәкүрев алар арасында беренче булдымы икән — хәзер бу хакта әйтүе кыен, әмма «Борис Годунов»та ялган патша ролен аңа тапшырулары хак.

— Бу кеше миңа театр дөньясын ачты, — ди Шәкүрев Захода турында. — Яңа мавыгуым искиткеч күп вакытны һәм рухи көчләремне ала иде. Бервакыт Захода спектаклебезне карарга драматург Виктор Розовныияртеп килде. Розов мине сәхнәдә күргәч, Үзәк балалар театры каршындагы студиягә укырга керергә үгетләде. Язмышым шулай хәл ителде.

Драмтүгәрәктә хөкем сөргән ирек, уйнаклыктан махсус гыйлем үзләштерүгә күчү җиңел булмый, билгеле. Әмма актер Шәкүревкә ярдәмгә спортчы Шәкүрев килә: эш яңа киртәне алуга кайтып кала ич! Аннары, студиядә шөгыльләнүдән тыш, театр һәм анда студентларга күзәтеп тору рөхсәт ителгән репетицияләр дә бар ич әле. Үзара бәхәсләр, әзләнүләрне әйтеп тә торасы юк!

— Нәрсә хакында бәхәсләшә идегез?

— Тормыш хакында. Спектакльгә, рольгә алыну белән, без аның драматург иҗат иткән әсәр икәнен оныта идек. Тирә-ягыбыздагы чынбарлык, аны күрү һәм аңлау сәләтебез хакыйкатьнең бердәнбер үлчәменә әйләнә иде. Бәлки бу билгеләмә бераз корырактыр, әмма дөрес: нәрсәне яратам, нәрсәне кабул итә алмыйм, ни хакына сугышка керәчәкмен, ни белән берничек тә килешмәячәкмен — болар төп юнәлешне ачыклый. Студия һәм театр, актерның шәхесен дә, талантын да эстетик мавыгуларын да хөрмәт итеп, бу һөнәргә карата мәхәббәт уятты. Соңрак бүтән театрларда эшләгәндә дә мин яшьлегемдә алган шул игелекле «оеткыны» кадерләп саклый торга... булдым...

Бәхеткә каршы, актер Шәкүревкә театрда да, кинода да (ул 1965 елдан бирле фильмнарда катнаша) гаять талантлы иҗат әһелләре белән очрашырга, дуслашырга, алардан өйрәнергә туры килә.

— Актерлык осталыгына өйрәнергәме?

— Барыннан да элек гомер итүгә. Тормышның катлаулылыгын тоярга, эчкәреге якларын күрә белергә. Бу — актер һөнәрен үз каһарманнарының тормышы белән яшәргә хокук бирә сыман.

Театр режиссерлары А. Эфрос, Л. Хейфец, кинорежиссерлар А. Столпер, В. Жалакявичус, С. Соловьев, Н. Михалков, А. Михалков-Кончаловский, А. Сахаров — алар холыклары белән бер-берсенә охшамаган төрле-төрле иҗатчылар. Бу шулай ук Шәкүревнең бәхете иде. Алар өйрәткән һәр яхшыны тамчылап үзенә сеңдерә-сеңдерә үз сукмагын сала Сергей.

Шәкүрев уйнаган фильмнар бер үк югарылыкта түгел иде. Әмма ул кайсы ролене дә икенче чираттагы, әһәмиятсез нәрсә итеп карамады. Чөнки әгәр роль кызыксыз тоелса, ул аны экранда гәүдәләндерә дә алмас иде. Үз гомерен өлешләп бирә барган һәр образны якын күрә ул. «Солдат булып тумыйлар»дагы политрук Ильинны гына түгел, кинодагы беренче эше — «Мин солдат, әнием»дәге Пегановны да, «Ятлар арасында — үз, үзебезнекеләр арасында — ят» картинасындагы атта кылычын ялтыратып чабып килүче Забелинны да, «Май ие иде» телефильмындагы тынычлыкның беренче көннәре бәхетеннән исергән Маргослинны да, «Дуртенче»дәге Дикны

һәм, хәтта, бик ук уңыш казанмаган «Мухинны уятыгыз» тасмасындагы уңмаган Мухинны да ярата.

— Безнең иҗатта гаҗәп процесслар бара, — дип сөйли Шәкүрев, — образга үз сыйфатларыңны, тәҗрибәңне бирәсең, шул ук вакытта үзең дә аңардан өйрәнәсең. Әдәби образ сине дөньяга аның күзләре белән карарга, аныңча яшәргә мәҗбүр итә.

Әлбәттә, теге яки бу образны гәүдәләндергәндә һәрвакыт үз шәхесеңнән чыгып эш итәсең, югыйсә рольне башкаруда ихласлык җитмәячәк. Аның урынында һәм хәлендә мин нишләр идем? — актер иң элек шул сорауга җавап эзләргә тотына. Тапса, мәсьәләне чишелгән санарга мөмкин. Әмма эш тиз генә ачыкланмый.

Менә вожатый Сережа. Мин аның белән сценарий буенча таныштым, ләкин ул аңымда, хәтеремдә инде бик күптәннән яши иде. Эш, билгеле, аның Леонардо да Винчи яки Лермонтовка гашыйк булып, малайларда камиллеккә, гүзәллеккә омтылыш тәрбияләргә тырышуында гына түгел. Аларның гадилек һәм әдәп белән балаларда шәхес формалашуга этәргеч бирүе әһәмиятле. Үземне вожатый Сережа урынына куйганда мин шундый ук этәргечне тамашачыларда да уяту турында уйландым.

Ә Сечкин? Андый халәттәге кешене мин, шәһәр егете, кайдан белә идем соң? Барыннан да элек очерк, китап, фильм, спектакльләр аркылы. Чирәм җир үзләштерүчеләр уңышына, газеталарда басылган мәгълүматларга шәһәр халкы да битараф калмады. «Икмәк тәме» төшенчәсе һәркемдә булырга тиеш — шунсыз намуслы яшәү мөмкин түгел.

Сечкинга мин баштан ук гашыйк булдым. Аның хәрәкәтләре һәм омтылышлары җанга якын. Әгәр кесәмдә агроном дипломы ятса, мөгаен мин дә, Мәскәү тирәсендәге имин хуҗалыкны ташлап, татлы җиңү ләззәтен авыз итүне күздә тотып, шундый ук авыр көрәшкә ташланыр идем. Кинога төшерүләр башлангач, вакыйга булып узган якларга экспедицияләргә чыккач, мин инде шундыйрак язмышлы кешеләр белән якыннан таныштым. Холыклары белән алар бер-берсеннән аерылса да, һәммәсендә «чирәм җир» кешеләренә хас уртак сыйфатлар таба идем. Болар миңа образны сурәтләүдә ярдәм итте.

— «Сибириада»дагы Спиридон Соломин? Ничек һәм «кемнән» алып юл саптыгыз аңа? Үзегезне аның урынына куюу җиңел булмагандыр?

— Бер төрлелектән котылып, тулы канлы образ тудырасым килгән чак иде. Мин аның рухи халәтен, януларын-көюләрен, ошаткан нәрсәләрен, консервативлыгын, канына сеңгән күнекмәләрдән баш тартырга сәләтсезлеген аңларга тырыштым. Мондый кеше усал гына була ала дип уйларга ярамый. Бер җилкуарга ияреп, өйдән качып киткән сеңелесен ярата ич ул! Еланьга бөек үзгәрешләр рухын алып кайткан туганнан үгән энесенә дә кулы күтәрелми аның. Кыскасы, Спиридон — фаҗигале язмыш иясе.

— Ә алда сезне нәрсә көтә?

— Монысы әлегә сер, — дип шаярта Шәкүрев. — К. С. Станиславский исемендәге Мәскәү театрында эшлим. С. Соловьев куя торган «Коткаручы» картинасында уйныйм (тагын каһарманыма гашыйк булдым, тик... шыпырт!), тормыш итү турында уйланам. Мин ул уйларымның кайберләрен якташларым — Ульяновск өлкәсе Бакырчы авылы яшьләренә язган җавап хатымда уртаклаштым.

**Ф. МАРКОВА.**

# СОҢЛАП КИЛДЕ, ЧЫҢЛАП КИТТЕ...

Егор Уткин әдәбиятка шактый соңлап килде. «Беренче карлыгачлар» сериясендә «Кырлар сәламе» дигән беренче җыентыгын чыгарганда аңа инде 35 яшь иде.

Әмма соңлап килсә дә, чыңлап китте ул. Шигырь сөючеләрнең күңелен кузгатырлык, дулкынландырырлык матур-матур китаплар язып калдырды: «Минем романтикам», «Төнге яшен», «Офыкларда алсу болытлар».

Егор лирик шагыйрь иде. Нигездә бүгенге авылга, аның соклангыч табигатенә, хезмәт сөючән кешеләренә дан җырлады. Күп кенә шигырьләрен Ватанга, халыкка, илебездә барган зур төзелешләргә, яшьлеккә һәм мәхәббәт темасына багышлады.

Шагыйрь озак еллар Алабуга районының Менделеевск шәһәрендә төпләнеп яшәде, шунда урнашкан химия заводында эшләде. Завод һәм эшчеләр тормышын яхшы белүе аның шигырьләрендә дә чагылыш тапмый калмады. Тырыш хезмәт, Кама буеның искиткеч матур табигате белән рухланып, илһамланып ул соңгы вакытта «Туган якка кайта бер генә юл» дигән шигырьләр җыентыгы өстендә эшли иде. Ләкин вакытсыз үлем аңа китабын тәгалләргә мөмкинлек бирмәде — иҗаты инде шактый җитлегеп, камилләшеп килгән чакта, 45 яшендә безнең арабыздан китте.

Укучылар игътибарына тәкъдим ителә торган түбәндәге шигырьләр шул җыентыктан сайлап алынды.

Илдар ЮЗЕЕВ, Дифгат СИРАЙ.

## Егор Уткин

# МӘҢГЕЛЕКНЕҢ ӨНЕ

### Бер генә юл

*Генерал Беловка*

Кагылып үтте туган авылына
Башкалага үтеп барышлый.
Кырга чыкты тыңлар өчен бары
Тургай җырын, шавын арышның.

Сирәк кунак. Эше тыгыз, диләр,
Даны олы — илгә таралган...
Тынгы белмәс җаны
Даннан олы
Туган якка тугры яралган.

Җил биргәндер аңа тынгысызлык,
Уйчанлыкны — авылым кичләре,

Тугрылыкны кырлар биргәннәрдер,
Моңны чишмәләрдән эчкәндер.

Барсын бергә туплап туган җире
Кайнар йөрәк биргән янарга...
Туган яктан мең юл алып китә,
Бер генә юл кайта аңарга.

## Таңнар, таңнар...

Таңнар туа, таңнар китә тора,
Баскычларга тиңлим мин аны.
Таңнан таңга күтәрелгән саен
Матурлыгы ачыла дөньяның.

Әллә таңнар — кабатланмас таңнар
Җиргә гашыйк булып янамы?
Таңнар гына түгел, үзем дә мин
Таңнан таңга янам, янамын.

Өмет яна, яна сөю хисе,
Кайгылардан яна күңелем.
Яшел кырда янам, җырда янам,
Янам шатлыкларга күмелеп.

Өмет кебек алга дәшкән таңны
Серле итеп тормыш яраткан:
Таңнан таңга күтәрелеп була,
Төшеп булмый ләкин кабаттан.

●

Изге эшнең агы-карасы юк,
Хак уйның юк агы-карасы.
Изге нәрсә һәрчак ак, пакь булыр,
Хет кай яктан алып кара син.

Пакь җаннарга кара фикер йокмас,
Ак уйларны халык яраткан.
Кара сүзен ипигә кем кушкан,
Кемнең теле барган, кем таккан?

Гади халык, игенчеләр әйтмәс,
Юк, юк, әйтмәс! Һаман бит әле
Алар берчак кара ипи дими,
Алар әйтә: арыш икмәге!

●

Бер анадан туган гүзәл кызлар,
Бер анадан туган иркәләр —
Бер-берсенә охшаш, берсен-берсе
Кабатламый туа иртәләр.

Сукмаклар да бер-берсенә охшаш:
Тар, тап-такыр. Дәшә «әйдә!» дип...
Берсе аның тауга алып менә,
Берсе уза тауны әйләнеп.

## Дәшми калмый...

Ныгытмалар чыдамаган — ауган,
Илен саклап, ирләр кырылган.
Ирләр белән шулчак сафка баскан,
Ирлек белән бергә җыр туган.

Байрак булып, әйдәп күтәрелгән:
— Илен сөйгән ирләр буйсынмас.
...Җыр — шуңа җыр, өзелеп тә кала,
Дәшми калмый ләкин бер тугач.

## Монда мәңгелек өне

Күл буенда яшел камыш,
Ямь-яшел иркен болын.
Күлдә кояш, ул да хәтта
Күренә яшел булып.

Еракта яшел тирәкләр
Ямь-яшел ташкын булып
Шушы болынга чыгалар —
Ямь-яшел алар юлы.

Яшел юлны хуплый күңел,
Яшел юл — хәрәкәт лә!
Ансыз җирдә булмас иде
Яшәү дә, мәхәббәт тә.

... Тирбәлә яшел үләннәр,
Яшел нур, яшел агыш.
Монда мәңгелекнең өне —
Яшел моң, яшел сагыш.

## Тынлык җитми

Җирдә кырлар безгә җитәрлек,
Җирдә җырлар безгә җитәрлек —
Исең китә дөнья зурлыкка,
Бер мизгелдә туа мең мәхәббәт,
Бер мизгелдә табыла мең сәбәп
Батырлыкка, данга, хурлыкка.

Кеше туа. Туа чишмәләр.
Давыл куба, җилләр исәләр.

Барысы да җирдә җитәрлек,
Барысын да җирдән табабыз:
Шатлык, сөю, дуслык хисенә
Тулган чишмә, сулар, һавабыз.

Барсы да бар җирдә кешегә,
Дөньябыз бай, бай ул шул тикле...
Ә тынлыкка урын азая,
Кешеләргә менә шул җитми.

## Күпләр аны сагынып искә ала

Җиңел эшне җаны үз итмәде,
Нидер эзләп янды, сызланды.
Күпләр аңа карап гаҗәпләнде,
Күпләр көлде, күпләр кызганды.

Сусыз кала авыл чишмәбезне
Су баскач, дип, язгы ташкында,
Көрәк алып ул беренче чыкты,
Эш башлады авыл башында.

Ә аннары чыкты бөтен урам —
Тирән итеп кое казылды.
Күпме халык шунда суга килә!
Ә ул юкка ничә яз инде.

Язын килгән җиргә, язын китте
Яшәде дә янып, талпынып,
Юлсыз эзләр аны илткән икән
Күңеленә авылы халкының.

Аның исемен йөртә шушы кое,
Бирмәделәр моны киңәшеп...
Күпләр аны сагынып искә ала,
Күпләр көлеп, күпләр көнләшеп.

## Рәхмәт

Гаделсезлек безгә чит бер нәрсә,
Гаделлек ул бездә артыктыр да.
Кемгә генә рәхмәт әйтмибез без
Каерылып иген уңгач кырда.

Рәхмәт — кояш җиргә җылы бирде,
Яңгыр бирде игеннәргә дымын.
Рәхмәт — җилләр җиргә кабат койды
Уҗымнарның көмеш төсле чыгын.

Рәхмәт — күктә тургай җыр көйләде,
Игеннәргә сөенеп ул таң калды.
Рәхмәт... никтер кайчак онытабыз
Әйтергә без җиргә-кырга аны.

## Туган бусага

Ил йөкләрен иңгә алган ирне
Ил язмышы авыр сынаган:
Танк изгән, Днепрда аккан,
Балчык күмгән, янган — чыдаган.

Дүрт ел рәттән утлар-сулар кичкән,
Күккә ашкан таулар — чыдаган.
... Тәбәнәк өй, синең бусагаңда
Түзалмаган солдат — елаган.

Ринат Мөхәммәдиев

# КҮҢЕЛДӘГЕ ЭЗЛӘР

Әдип, прозаикмы ул, шагыйрьме үз иҗатында, бар нәрсәдән бигрәк, тау кәҗәседәй кыядагы бер таштан икенче ташка күченеп, сикергәләп йөрүдән сакланырга тиеш. Ул билгеле бер чор, буын вәкиле. Тамыры белән шул чорга береккән. Тамырлар тирәнгә китәргә мөмкин, яисә як-якка киң җәелергә, әмма җирлегеңнән, халкың һәм үз буыныңнан ерак китеп булмый. Китүләре я үзәк тамырларны өзү, я туфрагыңнан аерылу бәрабәренә генә — югалтулар аша гына мөмкиндер. Шуңа күрә һәр иҗатның үз кыйбласы — темасы, тоткан юлы, яратып сурәтләгән, үзләреннән аерыла алмый газапланган образ-геройлары булырга тиештер. Чын әдипне, чын художникны башкача күз алдына китерү мөмкин дә түгел.

Әмма шунда ук тагы бер факторны, бу очракта инде объектив түгел, субъектив факторны да искә алмау дөрес булмас: әдипнең бер үк вакытта, бер заманда яшәп тә, каләмдәшләреннән үзгә буларак, тормышта үзен аеруча борчыган яшәү принциплары, әхлак нормалары булырга мөмкин. Мөмкин генә түгел, тиеш тә!

Әлбәттә, шулар өстенә конкрет тормыш биографиясе дә аның иҗат принциплары формалашуда — тема сайлауда, йөз тоткан проблемаларны билгеләүдә соңгы рольне уйнамый — ә хәлиткеч өченче фактор булып тора. Һәрхәлдә әсәрләреннән үзенең шәхси тормышы, кеше буларак формалашу юллары төсмерләнмәгән әдип булмас. Тарихи темага язамы ул, заман проблемалары кочагында тартышамы, киләчәк турындагы татлы хыялларга биреләме — ничек кенә итмә, үз биографияңнән, җанны утка салган, бәгърәңне телгәләгән сораулардан, чынбарлыктан качып булмый. Аяклар басып торган җирдән башның әллә ни ерак китә алмаганы кебек. Фәкать аяклардан күпмедер югарырак булу, киңрәк офыкларны күрә белү генә мөмкиндер.

Язучы-прозаик һәм драматург Аяз Гыйләҗев иҗаты соңгы еллар татар совет әдәбияты барышында тематика күзлегеннән булсын, идея-эстетик эзләнүләр киңлеге белән булсын, ничек кенә димә, бу әдипнең иҗат эзләнүләре — шатлык һәм газаплары махсус игътибар объекты булуга лаек. Әдәбият мәйданында өч дистә еллар өзлексез һәм актив эшләп килгән әдипнең иҗат портретын язар өчен аның тау-тау әсәрләрен өр яңадан өйрәнеп, анализлап чыгу гына түгел, ә тормыш юлын, шәхси биографиясен, дөньяга карашын, уй-кичерешләрен, холкын, әйләнә тирәгә һәм кешеләргә мөнәсәбәтен бөтен ваклыкларына тикле төпченеп белергә кирәк. Бу очракта мин авторның төрле журнал, җыентыкларда, китапларда чыгып килгән, укылган әсәрләре турында, шагыйрьчә әйткәндә, исемдә калганнар белән генә уртаклашырга булдым. Теләгем — күңелдәге эзләр белән уртаклашу.

### «БЕРӘҮ», повесть (1959)

Бу әсәр авылда үсеп, авыл белән элемтәсе сакланган кешене битараф калдыра алмас. Персонажларның язмышлары якын, үз-үзләрен тотышы таныш, һәркайсын күңел белән якын итәсең.

Әлбәттә, «Берәү»дә тасвирланган авыл бүген тамырдан үзгәрде инде. Анда Нурулла һәм аның гаиләсе кебек аяныч язмышларга социаль нигез калмады. Туган җиргә Нуруллдадай җаны-тәне белән бирелгән принципиаль һәм тугры җаннар бүгенге авылның үзәген, умырткасын тәшкил итәләр — җир җимертеп эшлиләр һәм муллыкта матур тормыш корып, кем әйтмешли, әйттереп дөнья көтәләр. Ә әсәрдә сөйләнелгән колхозлашу, яңа тормышның нигезен салу елларында мәкерле дошман белән көрәш җиңелдән булмаган. Бәркетне — кыя бөркетен хәтерләткән Нурулла туган авылында яңа хуҗалык төзүнең бөтен кырыслыкларын татып, кулак калдыклары белән тартышулардан сыңар канатлы кош кебек әйтеп бетергесез олы һәм җан җәрәхәтләре белән чыга.

Повесть «Бераү» дип исемләнгән икән, кем соң ул бераү, нигә ялгыз калган, аны әйләнә тирәлектән, дусларыннан кем аерган, дигән табигый сорау килеп баса. Ул,



әлбәттә, әсәрнең үзәк герое — Исхак. Бу егеткә дә язмыш җиңелләрдән бирелми. Иң элек, ул — ятим. Шуның өстенә үзен туган авылына, туган якларына гомергә багышларга әзер торган, көче тәненә сыеша алмаган гаярь егетнең тамырына балта чабучылар табыла. Хаклык, турылыктан башканы белмәгән, әле яңа формалашып килгән шәхес өчен Гыйлми Салихлары, Тазюковлар — Нурулланың канатларын каерган кулак калдыклары — бер уйласаң алай җиңә алмаслык куркыныч көч тә булмас иде. Аның үзәгенә үткән нәрсә күпкә катлаулырак, нечкәрәк һәм тиз җиңә, үзгәртеп яңадан булдыра торган нәрсә түгел — авылдашларының бөтен хаксызлык, корткычлыкның нигез башы булган яңа тормыш дошманнарына пассив мөнәсәбәте. Кешеләрне күрә, таный белмәгән, политик зирәклекләре сай, сукырларча буйсынучан авылдашларының пассивлыгы өметсезләндерә Исхакны. Үзенә ишләрне таба алмавы сәбәпле ялгызлыктан качып җан аткан туган-үскән җиреннән китеп бара. Чит җирләргә бәхет, озын берлек эзләп тә түгел, ә бары җанын кая куярга белмәүдән, протест йөзеннән китә. Бу язмышның бар катлаулылыгы, драматиклыгы да шунда — тирәнтен ялгыша Исхак. Колхоз председателе булып эшләгән, яңа тормыш дошманнары белән бил алышуга калгач, үзендә шулай ук ахыргача җиңеп чыгарлык ихтыяр көче, ныклык таба алмаган Хәсәен һәм шуның кебек күпләгән башка намуслы кешеләрне үзенә тартып, бергәләп көрәшү юлын күздән ычкындыра. Бу аның төп хатасы һәм аны бер ялгызы калдырган сәбәп тә. Ныклабрак уйлап карасаң, авылдашларын пассивлыкта гаепләгән Исхак үзе дә шул ук чирдән газаплана, аның үзенә дә иҗтимагый-политик активлык җитенкерәми, җәмгыятьнең нигезендә булган ныклы таянычны ул үзе үк күрә алмаган икән.

Повесть, А. Гыйләҗевнең күпчелек әсәрләренә хас җор тел, шаулап, ургып аккан судай ярсу рухта, стильдә язылган. Андагы күп кенә оригиналь чагыштыру, сынландыруларны гыйбрәтле һәм шул чор авыл тормышына хас образларны яратып яисә нәфрәтләнеп искә алырга мөмкин булыр иде. Ләкин игътибарны, барыннан да бигрәк, әсәрнең төп идея-эстетик җегәре һәм бүгенге шартлардагы әһәмияте, анда күтәрелгән проблемаларның актуальлегенә юнәлтәсе килә. Әйтик, совет иле гражданнарының иҗтимагый-политик активлыгы һәм зирәклеген берөзлексез күтәрү, дөреслек һәм хаклык өчен ахыргача принципиаль рәвештә көрәшергә кирәклеге турында уйлану кемнән таләп ителми. Димәк, әсәрдәге вакыйгалар инде бүгенге чынбарлыгыбыздан шактый ук ерагайса да, анда кузгатылган проблемалар әлегә көн тәртибеннән төшкәне юк. «Бераү» бүген дә актив яшәвендә дәвам итә.

### «ӨЧ АРШЫН ҖИР», повесть (1962)

Туган җир, туган якның кадере хакында, кешелеклелек турында үзәкләрне өзгеч тирән фәлсәфәгә корылган әсәр. Мөгаен, бер артык җөмлә, бер артык сүз юктыр кебек анда, ничек йотлыгып укый башлаган булсаң, шулай тәмамлыйсың да. Повесть жанрының иң бөтен, җыйнак һәм камил үрнәге диярсең...

Язмышлар. Тетрәндергеч, һәм гаять дәрәҗәдә олы тәэсир итү көченә ия язмышлар... Аянычлы, бушка узган гомер. Бумеранг сыман үз башына әйләнеп кайткан ачу һәм нәфрәт. Семья дип, ир хакы дип җирсеп үткән көннәр, айлар, еллар... һәм мә сиңа — үлем.

Мирвәли һәм аның тугрылыклы хәләл җефете Шәмсегаян башыннан үткәннәр, бәлки, типик вакыйгалар да түгелдер. Шулай да аларның тормыш юлын, яшәү рәвешен һәм төзәтү мөмкин булмаган олы хатасын кат-кат күңелдән кичерү, гыйбрәт итеп искә алу беркайчан да зыянга китмәс.

Шәхси милекчелек психологиясендә тәрбияләнеп, мин-минлеге чамадан тыш зур булган Мирвәли әтисе җыйган мал-мөлкәтнең, колхозлашу чорында авылдашлары белән уртакка бүленүеннән куркып, барын юкка чыгара, яндыра. Моның белән генә колхоз зур югалту күрми, әлбәттә, ә Мирвәлинең үзе өчен ул кыйммәткә төшә. Авылдашларыннан, туып-үскән җиреннән аерыла, кешеләргә булган ышанычын, кешелеклелек хисләрен югалта. Үзсүзлелек, усаллык, нәфрәт һәм мәкер белән тулы гомер уздырган кешенең язмышы ничек, ни дәрәҗәдә ямьсез һәм мәгънәсез рә-

вешта тәмамлана икән — Мирвәлинең соңгы көннәре һәм шул көннәрдә аның башыннан, күңеленнән узганнар моңа табигый һәм ышандыргыч дәлил булып тора. Бердәнбер тормыш юлдашы Шәмсегаянның җансыз гәүдәсен ат арбасына салып, үз кичерешләре белән бер ялгызы гына калып үтелгән 58 чакрым юл аны үкенечле кичерешләр дәрьясына чумыра. Чамадан тыш психологик киеренкелек һәм тирәнлек белән тасвирланган Мирвәлинең туган авылына кайтып баш июе һәм авылдашларыннан үзенә туган җирдән өч аршын ялваруы әсәрнең олы һәм актуаль яңгырашлы финалын тәшкил итә.

Шәмсегаянның, туган якларын сагынып, соңгы көннәренәчә үзе уйнап үскән болын-кырларны күрергә сусап атлыгуы да әсәрдә күтәрелгән проблемаларның киң планлырак, тулырак һәм ышандырырлыграк булуын тәэмин итә. Гомер сәгатенең соңгы минутларын иген басуыннан барган ат арбасында — арыш башаклары шавын, тургай җырын ишетеп, кыр чәчәкләре һәм чиста зәңгәр күкнең матурлыгына сокланып, арба чәкүшкәсенең шыгырдавына кадәр хәйран калып каршылый ул. Гомере буе кемнеңдер кирелегенә буйсынуы сәбәпле, кемгәдер булган ярату хакына туган якларыннан аерылу газабын кичкән бу гүзәл һәм нечкә табигатьле хатын язмышы шулай ук байтак кына җитди уйлануларга этәрә.

Җыеп кына әйткәндә, «Өч аршын җир» повестен укыганда күңелне, уйны шул рәвешле кешелекле, беркайчан да актуальлеге кимеми, югалмый торган олы һәм җитди дөньяви мәсьәләләр биләп ала. Бу исә — әсәр яши дигән сүз.

### «ЗӘЙ ЭНҖЕЛӘРЕ», повесть (1963)

Язучының күп кенә башка әсәрләреннән аермалы буларак, бу повестьны тәнкыйть бик җиңел һәм бертавыштан дип әйтерлек хуплап каршы алды. Укучылар мөнәсәбәте нинди булганын хәзер әйтүе кыен. «Зәй энҗеләре» авторның күп кенә повестьларыннан үзгә стильдә, тормышның кайнар эзе буйлап, кайсыдыр яклары белән документаль җирлектә язылган төсле. Әлбәттә, авторның үз-үзен төрле яклап сынап каравы яхшы нәрсә. Шуның өстенә әле «Зәй энҗеләре» әдәбиятыбызда производство тормышыннан, эшче темасына язылган әсәрләрнең дә беренчеләреннән иде.

### «УРТАЛЫКТА», повесть (1969)

Үзенең язылу стиле, үзәккә куелган фәлсәфәсе белән үзенчәлекле әсәр. Сюжет катлаулы түгел, вакыйгалар да авторның башка әсәрләрендәгечә эзлекле булып, ачык кына бер юнәлештә сузылмаган.

Гомеренең урта җиренә, урталыкка җиткән Сәгыйтьнең уйлары, тормыш хакындагы фәлсәфәсе, әлбәттә, тормышчан, игътибарны җәлеп итәрлек. Ләкин, ни дәрәҗәдә гомумиләштерелгән фәлсәфә ул? Түгел икән, ул, фәлсәфә булудан туктап, үз мин-минең тирәсендә генә чикләнеп гәп сатуга кайтып калмыйммы... Повестьны, тулаем, кызыксынып укыган кебек идем, шулай да, каян килептер, шундыйрак шик калган. Әсәрдә тасвирланган эпизодлар, мөнәсәбәтләр хәтердә ачык саклануга да карамастан, төер булып яткан ул шикне куып чыгара алмадым. Тагы шунысы да бар, автор өчен билгеле бер чорда гаять әһәмиятле булып тоелган ул уйланулар укучы өчен ни дәрәҗәдә кызыклы булыр һәм прозада, поэзиядән аермалы буларак, шәхси кичерешләргә генә нигезләнгән күләмле әсәр үз-үзен аклыймы икән?

Дөрес, бу очракта бәлки тагы бер факторны искә алу кирәктер. Повестьта автор Сәгыйть белән аннан егерме яшькә кечерәк кыз Рузалиянең үзара аңлаша, берберен аңлый алмауларына, тормышка мөнәсәбәтләренең төрле булуына игътибар итә. Бу юлларның авторы да, баксаң, дөньяга автордан нәкъ ике дистә еллар чамасы соңрак килгән икәү. Кем белә...

### «ЯЗГЫ КӘРВАННАР», повесть (1972)

Әсәр кыска, анда алай катлаулы, үтә каршылыклы сюжет җепләре дә үрелмәгән, бер карашка, үзәккә алып тасвирланган масштаблы образлар да күп түгел. Вакыт һәм пространствода артык киң җәелүне дә максат итми автор. Шулай да бу әсәр, һич нәрсәгә карамастан, язучы иҗатында үзенчәлекле урын алып тора. Моны ни белән аңлатырга? Автор әлеге җыйнаклык аша масштаблыкка ничек ирешә соң? Повесть, барыннан да элек, үзендә сугыштан соңгы чор татар авылының, авыл кешесенең бетмәс-төкәнмәс мораль көчен, рухи матурлыгын һәм батырлыгын вакыйга һәм картиналар аша характерлы рәвештә үтә җылы итеп чагылдырган булуы белән гыйбрәтле. Фашизмны җиңгән халыкның, тиңдәшсез зур кыенлыклар кичергән, көндәлек тормышында олы авырлыклар белән генә очын-очка ялгап барган, арыган һәм талчыккан халыкның, бу очракта авыл кешеләренең, гүзәл бер бөтенне тәшкил иткән матур образы күңелләрне тетрәндерерлек детальләр, характерлы эпизодлар ярдәмендә күз алдына китерелә. Халык вәкилләре — алар бер үк вакытта үтә гадиләр, күңелләрендәге телләрендә, уйларындагы кылган эшләрендә дигәндәй, аларның кан тибешен, изге омтылышларын һичнинди кыенлыкларсыз тоеп барасың.

Шул ук вакытта повестьта тасвирланган халык индивидуаль сыйфатлары белән үзенә җәлеп итеп торган кабатланмас образлар системасыннан гыйбарәт. Сабираттәйне генә алыйк. Колхоз эше өчен, киләсе ел икмәге өчен авылдашлары җан атып йөргән көннәрдә ул үзенең сәламәтлеге хакында онытып башкалар белән бергә 65 чакрымдагы глубинкага чана тартып чыгып китә. Аны һичкем мәҗбүр итми бит югыйсә, авылда калырга да киңәш итәләр. Әмма ул — сугыш чоры авылының бөтен кыенлыкларын үз җилкәсендә тартып бар-

ган мәһабәт авыл хатыннарының берсе — әлеге җаваплы эштән читтә калуны күз алдына да китерә алмый. Чанада язгы авыр юлдан 3 пот сортлы солы тартып кайткан җирдән, бәйгедә егылып калган аргамактай, йөрәген тотып язгы ап-ак, йомшак, көпшәк карга ава — дөнья белән, авылдашлары, өч баласы белән бәхилләшә. Әлбәттә, бүгенге көндә мондый адымны ясау да һәм аны аклауның ихтыяҗы юк, әмма ул чор өчен бу үтә дә типик образ һәм характерлы эпизод. Авыр сугыш елларында фронтны икмәк белән тәэмин итеп торган, ирләрне алыштырып, колхоз һәм хуҗалык эшләрен бер үзләре төпкә җигелеп тарткан авыл хатын-кызлары өчен бу гадәти хәл. Сугыш батырлары белән бергә без менә шундый аналар, апалар, алдында да баш ияргә, күңелләрдә үзләренә мәңгелек һәйкәлләр куерга тиешле икән бит дип уйлап куясың. Чынлап та без ватан өчен, уртак максат өчен кирәк булганда үзләренең гүзәл, нәфис заттан булуларын онытып тормышның барлык мәшәкатьләрен күтәрә белгән хатын-кызларыбызның олы образларын һичкайчан онытырга тиеш түгел — авторның әлеге повестьта әйтергә теләгән иң җитди фикерләреннән берсе шундый. Шунда ук Сабирәттәй образы янәшәсендә автор тарафыннан үзгә бер мәхәббәт белән тасвирланган Кәсле авылыннан Сәрвәр апа һәм Әдилә образлары да күңелләрдә якты нур сызып җылылык калдыралар. Һәм, миңа калса, алар хакында да аерым туктап уйланыр урын бар, чөнки алар да шул чор хатын-кызларының иң матур сыйфатларын чагылдырып килгәнләр. Әйтик, Сәрвәр ападагы күңел киңлеге, юмартлык, кешелеклелек сыйфатларына сокланмый һәм аңарда шул сыйфатларны тәрбияләгән җәмгыять, халык вәкиле булуың белән горурланмый мөмкинме?! Җиңел еллар, бөтен еллар түгел югыйсә. Шуның өстенә ире сугыш инвалиды, контузия алган, бернечә балалары бар. Ә ул авылларына орлыкка килгән, үзенә моңа кадәр бөтенләй таныш-белеш тә булмаган уннан артык кешене ачык йөз һәм сый-хөрмәт белән каршы ала. Арыган-талчыккан кешеләргә күңел һәм өй җылысын һич кызганмый, тарсынуны белми аларны каршы ала һәм озатып кала. Һәм боларның һәммәсе кемдер кушу буенча түгел, башкача ярамаган, шулай гына булырга тиеш кебек, табигый рәвештә эшләнә. Нинди гүзәл, ни дәрәҗәдә кешелекле сыйфат! Уйлап куясың: үз халкыңны, үз җәмгыятеңне үзеңдә булган шундый сыйфатлар белән тасвирлау әйтеп бетергесез олы әһәмияткә ия ич. Яңа шартларда үсеп килгән яңа буын алдында, тугандаш милләт укучылары алдында, дөнья алдында...

«Аркада җылы мич, тиздә бушап бара торган кайнар табак... Өй эчендә әйтеп, сөйләп бетерә алмаслык рәхәтлек. Һәркем үз күршесенә бәрәңгенең тәмлерәген кузарга тырыша, күңелне күтәрә торган татлы сүзләр әйтелә... Бәрәңгене ялт иттердек. Аннан чәй килде. Чын чәй, куе итеп ясалган такта чәй. Сәрвәр апа чоланнан бал керткәч, барыбыз да ах иттек. Бал, бердән, бик кадерле кунакка гына куела торган нәрсә, зур сый, икенчедән, март ае булса да аларның баллары шикәрләнмәгән, ягъни утырмаган, кичә генә суыртып куйган төсле сап-сары, сөмих сагыз диярсең!» — Шул рәвешле яратып һәм үзгә бер җылылык белән тасвирланган юлларны укыганда безгә, юк-юк та утыз-кырык еллык араны үтеп, бүгенгегә кайтып уйлану зыян итмәстер. Юк, авыр елларда халкыбызны мең бәлаләрдән йолкып калган, өстен иткән ул туганлык, ярдәмчеллек, кешелеклелек сыйфатлары югала, онытыла бара дип расларга, чаң сугарга җыену түгел. Бәхетсезлек килсә, авырлыклар килсә кешенең, җәмгыятьнең асылында булган ул сыйфатләр, һичшиксез, яңадан һәм тагы да матурырак формаларда калкып чыгарга һәм чагылыш табарга мөмкин, шулай да бу хакта бер генә минутка да онытып тору да ярамый. Муллыкка, бөтенлеккә һич алданмый коммунистик яшәү нормалары һәм югары әхлак өчен — Кеше өчен көрәш берөзлексез дәвам итәргә тиеш. Аяз Гыйләҗевнең «Язгы кәрваннар»ын укыганда күңелдән шундый уй китми газаплады. Чөнки ул матур сыйфатларның бер Сәрвәр апада гына түгел, ә башкаларда да мул булуы ачык тасмерләнә әсәрдән. Олы кәрван булып ерак юлга чыккан Югары авыл кешеләренең төшке әбәткә туктау күренешендә дә уртак ватанда уртак тормыш, уртак борчулар белән яшәүче кешеләрнең бердәмлеге, үзара кайгыртучанлыгы, киң күңеллелеге гаять гадәти һәм матур детальләр аша сурәтләнә. Ул юлларны тыныч кына укып, аларга битараф калу мөмкин түгел. Әсәрдә автор аеруча яратып тасвирлаган Әдиләне читләп узсак хакыйкатькә хилафлык китергән булырбыз. Аны да сугыш чорының бетмәс-төкәнмәс олы борчулары, мәшәкатьләре читләп узмаган, билгеле. Шуның өстенә кызның күрше авылга тормышка чыккан апасы үлеп китә. Башлыаяклы булып өлгермәгән бер табын балалары ятим кала. Төшергәләргә яратучы холыксыз җизнәсе өйләнгәнгә кадәр Әдилә озак кына вакыт шул балаларны тәрбияләүне өстенә алырга, аларны карап үстерергә тиеш була. Чөнки башкача мөмкин түгел, ул башкача булдыра да алмый. Элек-электән шулай килгән: туганың түгел, чит кешене дә авыр чакларда бер ялгызы калдырырга ярамый, аңарга ярдәм кулы сузу һәр намуслы кешенең изге бурычы. Яшь, чибәр кыз Әдилә әсәрнең башында әнә шундый язмышка дучар булып, үз өстенә төшкән җаваплы бурычны намуслы рәвештә башкарып чыккан образ буларак үзенә хөрмәт, игътибар яулап ала. Аның киләчәк тормышында нинди генә хәлләргә калмасын, кешелекле гүзәл зат булып калачына шикләнмисең.

Шуның өстенә Әдилә әсәрне туплап торучы образ да әле. Авылдашлар һәм дуслар Ибраһим белән Дамирның аңарга булган мәхәббәте дә кызга булган игътибарны көчәйтеп җибәрә. «Сименәгә» бару

вакыйгасында да Әдилә энергияле, бетмәс-төкәнмәс ялкын, хезмәт интузиазмына ия кыз булып күз алдына килә. Әдилә татар хатын-кызларына хас иң матур сыйфатларны үзендә җыйган, Сабирәттәй һәм Сәрвәр апаларның дәвамы булган, олы әхлакый казанышларны, рухи байлыкларны түкми-чәчми дәвам итүче, дәвам итәчәк яңа чор кешесе буларак кабул ителә.

Аяз Гыйләҗев кеше характерларын, күңелдә барган рухи драмаларны, бәхәсләрне, тартышларны тасвирлауда күзгә күренерлек уңышларга ирешеп килгән прозаик. Менә бу очракта ул үз иҗат үзенчәлегенең бу ягыннан гаять урынлы файдалана белгән. Дамир образы мисалында да шуны ачык тәсмерли алабыз. Аның Әдиләгә һәм атларга мәхәббәте нәкъ тормыштагыча гади һәм бер үк вакытта күңелнең иң нечкә кылларын тибрәтерлек дәрәҗәдә отышлы детальләр, эпизодлар аша бирелә. Һәм ул яратуларның үз драмасы да бар. Әйтик, Әдиләне ул яшерен рәвештә өзелеп сөя, ә кызның исә күңеле башкада — Ибраһимда. Нишләргә белми газаплана Дамир — дустына тугрылыклы калыргамы, әллә мәхәббәте өчен көрәшергәме? Өзгәләнә ул, Ибраһим белән Әдилә арасын суытырга теләп үзенчә мәкерле уйларга да барып карый (чөнки башка чара юк), әмма булдыра алмый, ни генә кылмасын, аңарда кешелеклелек сыйфатлары өстенрәк чыга, мәкер аның табигатенә, рухи дөньясына сыешмый, ятышмый. Бердәнбер юл кала — яшерен янып, яшерен сөю, газаплану... Өлкән конюх булып эшләгән Дамирның атларга табынуы да кичерешләргә аз җирлек бирми. Әйтик, кыш көннәрендә азык табу проблемага әйләнгән чакларда аның ут йотып йөрүләре аз булган дисеңме. Гомумән, повестьта сурәтләнгән күп кенә башка образлар — һәркайсы кабатланмас дәрәҗәдә кызыклы, гүзәл табигатьле булган образлар арасында да Дамир үзгә бер якынлык белән кабул ителә.

Повестьтан күп эпизодларны, образларны кайтып-кайтып искә алырга мөмкин булыр иде әле. Әмма бер эпизодик образ (исеме хәтердә калмаган) — сугышта бер кулын калдырып кайткан гармунчы, җыр, музыка ишеткәндә сыңар кулы белән хатынын чытырдатып кочып, аннан күңеленә тулган ташкынны кая куярга белмәгәндәй өче иттерәп сызгырып җибәрүче кешенең кичерешләре күзгә яшь булып килә. Психолог, исең-акылыңны җибәрерлек тирән психолог бу Аяз Гыйләҗев, вакыт-вакыт аның тормышны ни дәрәҗәдә күрә, таный һәм эләктереп алу осталыгына, сизгерлегенә сокланып туймыйсың.

«Язгы кәрваннар» хакындагы уйлануларны бу әсәр хакында танылган рус совет тәнкыйтьчесе Юрий Суровцев әйткән сүзләрне искә төшереп тәмамлыйсы килә: «Бу повесть сугыш чорында үскән буынны чагылдырган әсәрләр арасында безнең күпмилләтле прозабызда үзенчәлекле урын алып тора».

## «МӘХӘББӘТ ҺӘМ НӘФРӘТ ТУРЫНДА ХИКӘЯТ», повесть [1973]

Мәхәббәт һәм нәфрәт. Уйлый калсаң шушы ике төшенчәгә (әгәр төшенчә генә булса) ай-һай күп нәрсә сыя икән. Кешенең акылы белән, алай гына да түгел, аның бөтен барлыгы, рухы, холык-фигыле, хыял-омтылышлары белән дә шулар, иң элек шул ике хис, тойгы, рухи халәт җитәкчелек итә түгелме... Һәрхәлдә мәхәббәт хисеннән азат кешене минем әлегә очратканым да, белгәнем дә юк. Һәм андый кеше юктыр да диган ныклы ышаныч белән яшим. Чөнки үзеңә тормыш биргән ананы, туган төбәкне, ватанны, кешеләрне һәм ким дигәндә бер гүзәлне яратмый яшәү мөмкин түгелдер. Юкса, нигә, ни өчен дигән сорауга җавап бирергә кирәк булачак. Авыр сорау. Кемдер үзалдына көлемсерәп «ә үзеңне генә яратып яшәү мөмкин түгелмени» дип тә куяр. Мөмкин, әлбәттә, ләкин ярату сүзе керсә дә, бу фаҗигале яшәү, кызганыч һәм бер үк вакытта куркыныч яшәү булыр иде. Дуска түгел дошманга да язмасын! Ә нәфрәте нигә тагы, мәхәббәт булган җирдә аныңсына ни калган? Гаҗәп, әмма хакыйкать шундый — чынбарлыкта ни галәмәттер, бер-береннән шулкадәр ерак булган шушы ике төшенчә һәрвакыт янәшә йөри. Мәхәббәт артыннан калырга теләмәгән бер шәүлә янсә күләгәме әллә ул нәфрәт? Нигә алар күңелләргә чиратлашып килә, бер-берен мәңге эзәрлеклиләр, өзлексез качалар һәм өзлексез очрашалар. Кешегә һәм кешелеккә мәхәббәт хисе генә дә җитеп ашкан бит югыйсә. Шулаен-шулай, әмма нәфрәтсез, нәфрәтләнми генә яшәргә омтылу да утопиядән башка берни булмас иде. Дөньяда илләр генә түгел, халыклар гына түгел, партияләр һәм аерым группа кешеләр генә дә түгел, конкрет бер шәхес тә үз-үзе белән берөзлексез аңлашып, килешеп тора алмый. Акылга хис буйсынмый, хискә акыл буйсынмый газапланган, тартышкан чаклар аз буламыни. Башта, күңелләрдә күпме фикер тартыша, өзгәләнә, кайный. Билгеле бер очракларда үз-үзеңнән канәгать булмаган, үз-үзеңне тиргәгән, хәтта аерым бер кыланышыңа, кылган эшеңә үкенеп, үз-үзеңә нәфрәтләнгән чаклар да була. Әмма шушы урында, бераз чабуны җыя төшеп дигәндәй, мәхәббәт һәм нәфрәт хакындагы гомуми уйланулардан арынып торып, конкрет әдәби әсәр җирлегендәге конкрет язмышларга тукталу дөресрәк булыр. Аяз Гыйләҗевнең «Мәхәббәт һәм нәфрәт турында хикәят»е бу очракта шактый гыйбрәтле җирлек. Әсәрдә сугыш чорындагы тыл, авыл тормышы тасвирлана. Батырлык һәм гомуми фидакарьлек еллары — туган илгә, ватандашларга булган мәхәббәт хисләренең сыналган чагы. Мәхәббәт, бары тик мәхәббәт, башка һич ни булырга мөмкин түгел кебек мондый чорда. Чөнки нәфрәт тойгысы тулысы белән изге ватанга басып кергән дошманга юнәлтелгән вакыт. Авылда, бөтен авырлыкларны үз җилкәсенә салырга әзер булып, яңа, яшь буын үсеп

килә. Аларның дөньяга, тирә-юньгә мөнәсәбәтләре ныклап формалаша, утыра башлаган вакыт. Туган ил төшенчәсен, ватан төшенчәсен, үз ындыр артлары белән чикләп караудан аерылып, тулы мәгънәсендә аңлый башлаган чор. Тормышка, кешеләргә булган романтикларча карашның дөньяви аек фикер белән алышынган еллары. Кыскасы, олы юлга чыккан яшьләрнең юллар чатында торган чагы. Искәндәр һәм Рәфгать, Арзу һәм Кәримә, Сирайларның үз язмышларыннан килеп мәхәббәт һәм нәфрәт объектларын ачыклаган чорлары. Әмма максатларның бөтен ил күләмендә уртакка әверелгән, бер ноктага тупланган чорында да, тыл тормышында мәхәббәт белән янәшәдә нәфрәт объекты булырлык кешеләр, күренешләр әледән-әле очрап тора. Мәүлиха кебек үз-үзен генә сөючән, көнчелеге ташып торган, башкаларның һәр уңышлы адымыннан үзенә усаллык эзләгән икейөзле, мәкерле хатын һәм кешеләргә этлек эшләүдән үзенә бер рәхәтлек, юаныч эзләгән чулак Гыйбадулла кебек затлар белән очраша яшьләр. Дөрес, болар ачыктан-ачык хәрәкәт итү мөмкинлегеннән дучарлар — замана башка, чор башка, кешеләр һәм җәмгыять башка. Шуңа да карамастан, алар, тырмашып булса да, үзләренең агуын чәчәргә җай эзлиләр.

Бер-берсен алыштырып килгән киеренке драматик вакыйгалар, мәхәббәт һәм нәфрәт хисләре ташып торган тирән кичерешләрдән торган әсәр бер сулыш белән дигәндәй укыла. Күп кенә урыннары сине күз алдыннан китми газаплый. Бу очракта да авторның хисси кайнарлыгы, тасвирлаудагы масштаблыгы, максималист булуы, эпизодларны бер-бер артлы чигеп баргандай эзлекле һәм табигый рәвештә үстерә, дәвам итә килүенә гаҗәпкә каласың (дөрес, повестьның азагы бераз схематиграк, ясалмарак килеп чыккан кебек — автор язмышларны ахыргача күрсәтеп бетерергә, аларга дәрәҗәләр өстәргә омтылып ялгышкан булса кирәк. Чөнки Искәндәр һәм Рәфгатьнең нинди батырлык, фидакарьлекләргә сәләтле булуы инде болай да аңлашылган иде). Шунда ук символларның янсә вакыйга барышында алай зур әһәмияте булмаган детальләрнең сәнгатьчә тулы картина тудырудагы роленә игътибар итми мөмкин түгел. Әйтик, гаять киеренке эпизод — Арзуның бабасы Хәбибрахман нахакка гаепләнеп хөкемгә тартылырга тиеш. Атлар җигелгән, аны менә-менә алып китәчәкләр. Шул чакны бер мәлгунь кәҗә арбага ук менеп печән чемченә, бер чанадан куып төшерәләр, шундук икенчесенә килеп менә. Драматик киеренкелек һаман үсә бара, ә кәҗә аның саен әрсезләнгәннән әрсезләнә төшә, йөдәтеп бетерә. Онытылды дигәндә генә яңадан игътибарны җәлеп итеп аренага килеп керә. Ниһаять, атын манма тиргә батырып, җан фәрманга чаптырып, Сирай килеп җитә. Ат халыкны ерып керә, аңа юл бирәләр. Ул Хәбибрахманның гаепсез булуын исбат итә — шатлык алып килә. Тагы шул кәҗә генә ат аяк астында калып таптала, аяксыз кала яза. Кәҗә бу очракта нахак бәла яккан, бөтен намуслы кешеләрнең кәефен җибәргән Гыйбадулла һәм Мәүлихаларның күңелендә, уенда барган вак, мәкерле, кешелексез кичерешләрне символлаштырып килә.

Кешелекнең мәңге игътибар үзәгендә булган төшенчәләр турындагы фәлсәфәгә бай тормыш материалы нигезендә күтәреп чыккан бу повесть язучы иҗатында шулай ук әһәмиятле урын алып тора.

**«МЕҢ ЧАКРЫМ ЮЛ», повесть [1977—1978]**

Күләмле һәм озын повесть. Әскәр Моратовның һәр адымын сурәтләү белән генә чикләнеп калмыйча, берсеннән-берсе кызыклы булган һәм табылган башка образларга беркадәр игътибар үсә төшкәндә аның роман булып җитлегүен дә көтәргә мөмкин булыр иде. Хәер, әсәр язылган, димәк, автор максатын башкада күргән.

Бер себер картының Ләйлә исемле кызга сөйләгәннәре игътибарга лаек: «һәр кешенең гомере билгесезлеккә мең чакрым юл әле ул! Аны үтәсе бар! Берәү дә беркемгә дә туры сызык сызып, як-ягына маяк кадап куймаган. Билгесезлеккә бара кеше, үзе белән иртәгә ни буласын берчакта да белми...» Әскәр исә әнә шул мең чакрым юлны үткән кеше. Үтүен үткән, ләкин шул кадәр юл үтеп, гомер кичеп тә дөньяда үзеннән һичнинди файдалы эз калдырмаган. Эгоизм, үз-үзеңне генә ярату һәм карьеризмнан башканы белми, гомер буе әвәрә килеп йөргән бу адәм актыгының файдасызга үткән язмышында автор зур гыйбрәт күрә.

Аяз Гыйләҗев максималист дидек. Яраткан геройларын ул кабыргасы сынганчы дип әйтерлек шапылдатып сөя белә, яратмаганын эт итә, бер карарлык җирен калдырмый адәм хуры, рисвай итә. Әскәр Моратовка эләккәннәрнең дә чиге юк. Ул үз максатларына ирешү юлында туган якларыннан йөз чөерә, бердәнбер әнкәсен җирләргә дә кайтмый, семьяга, малаена да көн күрсәтми, туганнарын туган итми. Кыскасы, булырга мөмкин булган бөтен әшәкелекләргә сәләтле тип. Авторның язу, тасвирлау стиле шундый, каләменең үзенчәлеге шундый.

Повестьның әһәмияте шул дәрәҗәле мәкерле һәм рухи яктан ярлы, череп таркалган кешенең тормыш юлын күрсәтеп бирүдә генә, сәнгатьчә чагылдыруда гына түгел, әлбәттә. Авторның позициясе, шул образ аша әйтергә теләгән төп фикере, үткәрергә теләгән идеясе нидән гыйбарәт соң? Кешеләр өчен һичнинди файдалы эш кылмый торып, кешеләрне бәхетле итәргә омтылмый гына, үзең дә бәхет табам димә! Намуслы кешенең авыр минутларында барып сыеныр урыны бетми, ә инде намуссызга бер җирдә дә җылы, хөрмәт күрсәтергә атлыгып торучы табылмас. Эгоист үз-үзен чамасыз яратуы белән, иң элек, үз-үзен юкка чыгара, шәхес буларак тарката. Карьерист вакытлыча ниндидер урында эшләп торырга мөмкин, ләкин моңарга ул кешелеген, кешеләр арасындагы хөрмәт һәм җылы мөнәсәбәтләрне югалту

бәрабәренә генә ирешә ала. Иртәме-соңмы барысы да үз җәзасын алачак. Әскәр Моратовның мең чакрымлык озын юлы безгә әнә шул хакта гыйбрәт бирерлек дәрәҗәдә нәфрәтләнеп, чиркanып язылган. Ничек кенә булмасын, повесть һәркемне үзенең яшәү максатлары һәм яшәү рәвеше турында кайтып-кайтып уйландырырга сәләтле. Без барыбыз да дөньяга мең чакрым юл узарга, кешелеклелектә сынаырга туганбыз. Ничек узарбыз ул юлны, сынатмабызмы?..

## «ҖОМГА КӨН, КИЧ БЕЛӘН» повестен укып чыккач (1980)

Иҗат — кызык нәрсә, аның закончалыкларын һич кенә дә белеп, аңлап бетермәле түгел. Әкиятләрдәге тавыкларның да һәр салган йомыркасы алтын булмаганны, иҗатта гына һәр язганың чын сәнгать әсәре була алмас. Менә А. Гыйләҗевнең шактый озын һәм катлаулы иҗат юлын күздән кичереп, бер ише әсәрләрдән калган хатирәләрне искә алудан күңелгә рәхәтлек килеп, яңадан кешелекле һәм татлы уйларга чумып утыруым. Авторның барлык повесть, пьесаларын, роман һәм хикәяләрен бер дәрәҗәдә хәтерләү мөмкин дә түгел, әлбәттә. Бәлки кайсы берләре күздән дә ычкынгандыр, кайсыларын ниндидер сәбәпләр аркасында хәтерли алмаганмын, һәрхәлдә, күңелдә калган тойгыларымның зур өлеше белән уртаклашырга омтылдым.

«Җомга көн, кич белән...», барыннан да элек, үзәгендә эре планлы, масштаблы уңай образ булган әсәр. Бу яктан ул авторның беренче әсәрләренә, әйтик, «Бәрәү» һәм «Зәй энҗеләре» кебегрәк повестьларына тартым. Ләкин яңа повестьның урыны үзгә. Бибинур образы. Бу исемгә, бу образга игътибар итик әле! Ул, әдәбиятыбызда Г. Ибраһимов, Ш. Камал, М. Әмир, Г. Бәшировлар һәм Ә. Еникиләр тудырган гүзәл, кешелекле, шул сыйфатлары белән эре планлы һәм кабатланмас та булган хатын-кыз образлары галереясында да югалып кала торганнардан түгел. Кешелеклелек — бар нәрсәдән бигрәк, Бибинурга әнә шул сыйфат хас. Аңарга башка һичнинди гүзәллек, олылык, мәшһүрлек сыйфатлары эзләп тә, тагып та торасы килми. Ул кешелеклелеге белән гүзәл дә, кабатланмас та, типик та, уникаль да. Кешелеклелеге белән милли һәм интернациональ да. Чөнки милли телдә генә түгел, бөтен ил күләмендә дә бер кадәр зур яңгыраш тапкан кайсы гына рус һәм башка тугандаш халыклар әдәбияты үрнәгенә мөрәҗәгать итмә, аның үзәгендә, кагыйдә буларак, иң элек кешелеклелек сыйфатлары белән кабатланмас һәм гүзәл эре планлы образлар булуын күрербез. Кешелеклелек үзенең табигате белән интернациональ, ә кеше табигате белән кешелеклелеккә омтылучан. Автор яңа әсәрендә әнә шундый мәңгелек хакыйкатька тугрылыгын югалтмаган, алай гына да түгел, әлеге сыйфатны илаһилык дәрәҗәсенә күтәргән эре планлы шәхескә мөрәҗәгать иткән. Хәер, Бибинур шәхес сүзенең ни икәнлеген дә белмәгән, бәлки ул сүзне гомерендә бер кабат та ишетмәгән булырга мөмкин. Чөнки гаять олы масштаблы образ дигәнебез, күпме гомер итеп үз районы чикләреннән ары чыкмаган, бәләкәй генә гәүдәле, авылдашлары күзенә дә алай артык чалынмаган тыныч холыклы, сабыр татар карчыгы. Менә шул татар хатынының (әйе, аны карчык дип атау зур хата булыр иде) катлаулы һәм бер үк вакытта гадәти дә булган тормыш юлыннан берничә чорны искә алып һәм бер атна чамасы дәвамында булып узган уй-кичерешләрен күрсәтеп, язучы безне тетрәндергеч һәм шул дәрәҗәдә үк гыйбрәтле дә булган олы язмыш белән очраштыра. Белмим, мондый очрашуны бәхетле дип атау мөмкинме икән, шуңа да карамастан, андый очрашуларга ихтыяҗ көндәлек тормышыбызда бар һәм ничек кенә бар әле.

Кеше өчен изге теләктә булганнар гадәттә үзләре дә бәхетле тормыш итәләр дигән хакыйкать бар. Әйтеп киткәнебезчә, Бибинурга бу сыйфат чама белән генә бирелмәгән. Димәк, ул үзе дә чамасыз бәхеткә лаек булып чыга. Ләкин бәхетлеме соң бу ялгызак? Штрихлар формасында гына булса да аның тормыш юлын күздән кичереп карыйк. Иманага җир бүлгән чорда болай да кызлардан гына торган ишле гаиләдә игезәкләр булып дөньяга килгән кызларның берсе була ул. Бәхетенә каршы бу бәла озакка бармый. Бөек Октябрьдан соң ул үзен тулы хокуклы кеше итеп тоеп үсә, формалаша. Игезәкләрнең икенчесе Зөһрәбану, ни сәбәптәндер, үтә дә явыз, усал холыклы булып үсә — Зәһәрбану атлы кушамат алуга кадәр җитә. Хуш, игезәк булуларына да карамастан, Бибинурны танучылар табыла — яхшы гына эшкә урнаша, үзенә җан аткан егет тә табыла. Шуңарга чыгасы да, семья бәхетенә чумасы гына бит югыйсә. Нәкъ шул чакны авылда колхоз төзеп йөргән активистның үзе дип уйлап, кулак калдыклары аның хатыны Гайшәне үтерәләр. Яңа тормыш һәм яңа хуҗалык өчен җан атып йөргән коммунист Габдуллаҗан өч баласы белән бер ялгызы торып кала. Бу сабыйларның бәхетсезлегендә, аларның ятимлегендә кем гаепле? Бибинур түгел! Ләкин балалар бакчасында эшләгән кыз өч нарасый хакына үзенең яшьлеген, матурлыгын да кызганмыйча, йөргән егетен калдырып Габдуллаҗан йортына күчә. Бу адымны кешелеклелек дигән олы төшенчәне аңлаган, бөтен тирәнлегенәчә аңлый алган тәкъдирдә генә кабул итәргә мөмкин. Тиздән сугыш башланып, семья башлыгы фронтка китә һәм Ватан өчен башын сала. Үз гомерендә әле бер тапкыр да чын мәхәббәтнең ни икәнен кичермәгән Бибинур ана булу бәхетен дә күрми бер ицак бала белән тол кала. Бөтен көчен куеп, тырышып-тырмашып дигәндәй, балаларның тамагы тук, өсләре бөтен булсын өчен кулыннан килгәннең барын да эшли. Үзе турында, үзенең шәхси бәхете хакында уйлап карарга да җөрьәт итми, дөресрәге, бу очракта да ул үзенең яшәү бәхетен өч ятимне тәрбияләп, аякка

бастыруда күрә. Алар өчен ана пәм ата да булуы белән бәхетле саный үзен. Бибинур балаларны укыту турында да онытмый: һәркайсы югары белем алып, зур шәһәрләрдә тормыш корып дәрәҗәле урыннарда эшлиләр. Ятимнәрне кеше арасына кертә алуы, кеше итүе белән чиксез горурлана Бибинур. Ләкин шунысы аянычлы — туган якларына, туган җиргә, атабаба туфрагына күңелләре суына балаларның. Ике күзен офыктан алмый үзләрен көтеп торган Бибинур барын, әни дип үскән якын кешеләре — ата-ананы алыштырган изге җанлы кеше барын онытлалар. Һәр елны сабан туйлары җиткәндә киек казлар кебек тезелешеп ерак-ерак җирләрдән авылга кунаклар кайта, туган җирне сагынып, җирсеп кайта аксыргаклылар. Шулар арасында үзенең аккошлары, күңел парәләре булмауга өзгәләнә, телгәләнә Бибинурның бәгыре. Повестьтагы вакыйгаларның төп өлеше авыл өчен аеруча олы бәйрәм булган сабан туй алды көннәрендә бара. Бөтен авыл кунаклар каршылый, телеграммалар җибәрә, хат һәм посылкалар ала — тантана һәм бәхетнең чыганагы авылга килә торган юлларда һәм Бибинурның салам түбәле иске өе каршында гына урнашкан почтада. Бер ялгызы һәм көтеп яшәгән хатынның күңелендәге кичерешләр, ышаныч һәм өмет җепселләре, борчу һәм авылдашлары каршында кимсенү, гарьләнү тойгылары бер-берен алыштырып тора, кайсы өстен чыкканны да аңламаслык дәрәҗәдә үзара үрелеп, чуалып, болганып беткәннәр. Әмма хатын кешелеклелек бәрабәренә үз кичерешләреннән өстен, югары тора. Аларның исән-имин, бәхетле булуларын гына тели. Әлеге эчке драма, Бибинур күңелендә барган борчу һәм уйларның якалашуы, повесть гаять дәрәҗәдә сәнгатьле итеп күрсәтелгән. А. Гыйләҗевнең психологик анализ осталыгы, кеше күңелен укый һәм үтә нечкә кичерешләренә кадәр түкми-чәчми укучыга илтеп җиткерү сәләте бу очракта аеруча тулы чагылыш тапкан.

Әсәрдәге вакыйгалар моның белән генә тәмамланмаган, шулай да бу урында алардан читләшеп, бераз үзебезнең чынбарлыкка күпер салып узасы килә. Юк, туган җирдән китү, туып-үскән төбәктән материаль тамырларның аерылуын күреп карааыл кычкырырга җыену түгел бу. Әмма гаять җитди һәм тирәнтен уйлануны сорый, таләп итә торган проблема. Кемнәрдер кайчандыр шул туфракта канат чыгарган, кемнәрдер шул чирәмнәргә ятып аунаган бит югыйсә. Каядыр китеп урнашкан тәкъдирдә дә нигә алар үзләрен һәм ата-балаларын, иң кадерле җирне мәңгегә ятим калдырулары хакында уйланып карамыйлар... һәм шунда ук мәсьәләнең аерата ямьсез ягы — авылда торып калган ата-ана алдындагы бурычны да оныткан кешеләр бар бит әле. Капка төбендә таягына кулын куеп утырган ялгыз картларның күпмесе чит җирләрдә, калаларда көндәлек мәшәкатьләр чоңгылына кереп чумган улларын, кызларын уйламый һәм сагынмый икән. Ачык тәрәзәдән карашлары еракларга барып тоташкан аналарның күңелендә нинди уй, нинди сагыш... Бибинурның язмышы безне, барыннан да элек, шундый кешелекле һәм заманыбызга хас актуаль уйлануларга чакыра.

«Җомга көн, кич белән...» повестеның үзәк проблемасы шулардан гыйбарәт. Әмма әсәр хакындагы сүзне кырт кына кисеп өзү әлегә мөмкин түгел. Чөнки берсеннән-берсе кызыклы һәм тормышчан образлар — Галикәй карт, Зәкия һәм Зөһрәбану хакында бөтенләй искә дә алынмаган кебек булды. Аксыргак авылының кабатланмас пейзажы һәм Ташлыяр суы, әйләнә-тирәдәге искиткеч гүзәл табигать турында сүз булмады. Авторның зәвыкъ белән генә берсеннән-берсе кызыклы портретлар, кабатланмас гүзәллеккә ия күренешләргә җан өрүдәге осталыгы, табышлары искә алынмады. Бибинур образын капылт кына яктыртып алган, аны бөтенләй көтелмәгән яктан тулыландырган олы мәхәббәт турында бер авыз сүз әндәшмәү гөнаһ булыр иде. Инде теге дөньядан чакыру килгәнне көтеп йөргән чакта Бибинурга олы хисләр — беренче мәхәббәт килә. Көтмәгәндә, болытлы кичтә офыктан алсу нурларын сирпеп күренеп алган кояш сыман килә. Аңарга яшәү оптимизмы, ялкын, бетмәс-төкәнмәс көч һәм кодрәт биреп килә. Дөрес, авылда председатель булып эшләгән, үзеннән күп яшь Җиһангир Сәфәргалингә булган бу олы хисне аңардан башка һичкем белми. Хәтта Җиһангир үзе дә. Бибинурның дәртсенеп яңадан тормыш көтәргә керешүе, күзгә күренеп яшәрүе автор тарафыннан үтә матур штрихлар ярдәмендә, романтик югарылыкка җиткерелеп тасвирлана. А. Гыйләҗевнең бу очракта да төп максатка ирешү юлында үтемле һәм кулай эстетик чаралардан ни дәрәҗәдә пөхтә файдалануына сокланмый мөмкин түгел. Әйтик, аның Миңлекамалларда фатирда торган Җиһангирга бер изгелек эшләү теләге белән (бу очракта да кешелеклелек!), хуҗа хатынга ярдәм дигән булып, күңеле, җаны үз иткән кешенең күлмәкләрен юган чакны хәтерлик: «Кая китте Бибинурның өлкәнлеге, тән арганлыгы, җан талчыгуы — аның ун бармагы арасында ак күбек диңгез ярындагы су кебек кабарынып уйный, тирә-якка пар атып су чәчри, ак майкалар, күлмәкләр, ак кульяулыклар ак камыр кебек изеләләр, сыгылалар, чупырдый-чупырдый сөенешеп тагын да агаралар. Изә Бибинур, баса Бибинур, сыга Бибинур. «Һай, көчең дә бар икән соң, Бибинур!» ди аның янына ук килергә дә шүрләп Миңлекамал. Бибинур дәшми, ялтыр, чиста маңгаена юешләнеп төшеп ябышкан чәчләрен кул сырты белән күтәреп кенә куя. Бәхетле көн бүген аның өчен — чөнки ул яраткан кешесенә яхшылык эшли ала — хатын-кыз яхшылыгы. Яраткан кешесенең эшен башкара».

Бибинурның соңгарып килгән, ни вакытлар көттереп килгән мәхәббәте, әлбәттә, аның үзе эчендә генә ялкын биреп торган булыр иде. Тик Җиһангир көтмәгәндә йөрәгеп тоткан җирдән китеп тә бара.

Бибинур тагы бер ялгызы торып кала. Колхоз рәисен зурлап соңгы юлга озатканда Бибинурга игътибар да итмиләр, машина тартмасы читенә генә елышып аның Җиһангир янында мәрхүмнең туган авылына кадәр озатып киткәнен дә күрүче, абайлаучы булмый. Зират янында да ул кеше күзенә чалынмый. Ә төн җиткәч, бер ялгызы калып зират коймасы читендә учак ягып чыга. Яшерен яратуны, беркемгә дә сиздерелмәгән мәхәббәтне шул кадәр символлаштыру дәрәҗәсенә җиткереп автор Бибинур образының масштаблылыгына ирешүдә тагын зур гына адым ясый...

Җыеп кына әйткәндә, повесть авторның чираттагы уңышы, җитди уңышы саналырга лаек әсәр. Бибинурның кабатланмас гүзәл образы әдәбиятыбыз барышында лаеклы урын алыр дип ышанырга нигез бар.

## АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВ ДРАМАТУРГИЯСЕ ХАКЫНДА БЕРНИЧӘ СҮЗ

Аяз Гыйләҗевнең проза жанрында зур ачышлар ясаганын әйттек. Табигый рәвештә аның драматургиясенә дә үзгә бер игътибар һәм саклык белән киләсең, мәтурны күрү — олы гомумиләштерүләр, гыйбрәтле табышлар, гыйбрәтле язмышлар белән очрашу теләге билəп ала күңелне. Әмма шул ук вакытта прозадагы фикер оригинальлеге, форма камиллеге, эстетик букет кимемиме дигән ярым шик, ярым борчу да юк түгел. Чөнки әдәбият тарихында берничә жанрда бер үк дәрәҗәдә уңышлы иҗат иткән, табигый илаһият белән йөзә алган авторлар бик сирәкләр. Булган очракта да, аларның кайсыдыр бер өлкәдә иркенерәк, колачлырак йөзүен тоемларга мөмкин.

Драма әсәре, барыннан да элек, сәхнә өчен, тамашачы өчен языла, бу моментны бер генә минутка да онытып торырга ярамас. Авторның әйтергә теләгәне актуаль булып, режиссер проблемага, драматургик нигезгә сәнгатьчә ачкыч тапкан очракта гына уңышлы хәл ителә аның язмышы.

Әмма «Җиргә тапшырылган серләр», «Эңгер-меңгер», «Югалган бер көн», «Кар астында кайнар чишмә» пьесаларын укып та аларда куелган, кузгатылган уй-борчуларга, фикри һәм рухи халәт агышына битараф калу мөмкин түгел. Әдәби әсәр буларак алар (һәм алар гына да түгел, әлбәттә), һичшиксез, яңа һәм оригиналь күренешләр. Безнең күңелләрдә йөреп тә дөньяга чыгарга өлгермәгән уйланулар, заманча актуаль, киләчәк өчен кичектергесез уйланулар бар аларда. Актуаль дигәндә йөри-йөри тузып беткән иске башмакны хәтерләткән, шаблонга әверелгән, телгә кереп, эч пошкан чакларда ирексездән бәреп чыгарга әзер булган уй-фикер күздә тотылмый. Бүгенге яшәешебез өчен, аны тагын да ямьләндерү өчен үтә дә кирәк булган, алга таба хәрәкәт өчен котылгысыз мәсьәләләр күздә тотыла. Әлбәттә, пьесаларда күтәрелгән мәсьәләләр А. Гыйләҗев фантазиясе җимеше түгел, бәлки ул хакта беренче уйланучы да ул түгелдер. Чөнки үзара мөнәсәбәттәге, әйләнә-тирә һәм тормыш-көнкүрештәге яңа шартлар рухи нормаларның да яңаруын таләп итә. Гасырлар буе формалашып, тупланып килгән гадәт-кагыйдәләрнең көннән-көн яңа вариантлары туа тора. Моны иҗтимагый һәм рухи прогресс, камилләшү хәрәкәте итеп күз алдына китерү дөрес булыр. Язучының новаторлыгы, аның батырлыгы һәм иң олы бурычларыннан берсе — яшәештә булып та әле игътибарны махсус җәлеп итеп өлгермәгән, күңел белән сиземләнеп тә әле җәмәгатьчелекнең игътибарына тәкъдим ителмәгән әнә шул «нәни» һәм җитди четерекле мәсьәләләрне мәйданга чыгару, аларга киң җәмәгатьчелекнең карашын җәлеп итү.

Ә инде югарыда искә алынган әсәрләргә килсәк, алар укучыны һәм тамашачыны нинди уй-фикерләргә этәрергә сәләтле соң? Авторның әйтергә теләгәне беркадәр пәрәвез оясын хәтерләтә сыман. Бер карашка бигүк ачыкланып та бетмәгән, буталчык төсле. Автор позициясен турыдан-туры кычкырып торган монологлар да, аның рупоры булган үзәк геройлар, эре планлы, масштаблы образлар да юк кебек. Әмма шул ук вакытта вакыйгалар үзара үрелгән, буталчык булсалар да кабатланмас бер тәртипләре бар. Әйтик, «Җиргә тапшырылган серләр»не укыган кеше, ирексездән, үзенең көндәлек тормышын, әйләнә-тирәдәгеләргә мөнәсәбәтен, яшәү максатын һәм принципларын яңа анализларга керешер. Үз-үзенең кешеләрне таный белүен, дусларны сайлый белүен күздән кичерер — уйга калыр, хаталарын күреп көенер, хаталана белмәгән бәхетлеләр дә бар икән, олы канәгатьләнү тойгысы кичерер. Һәрхәлдә, әлеге әсәрнең нәрсә турында икәнлеген кисеп кенә әйтү җиңел булмаса да, аны укыган кеше, һичшиксез, билгеле бер юнәлештәге уйлануларга бирелəчәк, әсәрдә моның өчен җитди драматургик җирлек бар. «Эңгер-меңгер»дә дә бөтенесе шәрехләнеп, тамашачы һәм укучы өчен алдан ук хәл итеп куелмаган. Авторның позициясе Алим һәм Роза ягында булса да, бу ике геройның яшәү принциплары әлегә чалт аяз күк гөмбәзен хәтерләтми, алар үзләре дә эзләнүдә, томаннан, эңгер-меңгердән яктылыкка чыгу юлын эзлиләр. Көндәлек тормышларында бер карашка җайлы гына, шома гына яшәп яту — рухи кабатлану аларны канәгатьләндерми. Үзләренчә бәхет табып, үзләренчә көрәшеп, үз язмышларын үзләре иҗат итеп яшәүгә омтылалар. Табарлармы ул бәхетне?.. Һичшиксез табарлар, чөнки җәмгыятебез үзенең асылы белән торгынлыкка, катып калган нормалар белән генә яшәүгә түгел, ә өзлексез яңарып, камилләшеп, рухи яктан баеый барып, һәрьяклап гармонияле булып яшәүгә нигез бирә. А. Гыйләҗев Алим белән Роза образлары белән әхлакый, рухи торгынлыкка каршы баш күтәрергә җөрьәт итүчеләрне яклап чыга. Алар үз буынының үз йөзен, үз матурлыгын, киләчәк каршында бурычын аңлап, рухи гүзәллек юлындагы табигый эзләнүгә ашкынучылар,

ә бунтарь яки киребеткәннәр түгел. Дөрес, сәхнә әсәрләренә аеруча хас шартлылык алымнары, символлар белән эш итүдә вакыт-вакыт автор чаманы да оныткалап куя кебек. Кем белә, бу очракта да яшьләрнең табигый ашкынуы бераз тормышчанрак вакыйга-эпизодлар аша күрсәтелсә сәхнә әсәре бәлки тагы да ота төшкән булыр иде.

Драматургик шартлылык һәм символлар белән эш итү җәһәтеннән «Җиргә тапшырылган серләр» аеруча кызыклы һәм гыйбрәтле. Чыгарылыш класс укучыларының бер кызык ясап дигәндәй, күңел серләрен җиргә тапшыру вакыйгалары бары тик символик мәгънәгә ия. Нинди дә булса эчке, потенциаль уй-фикерләр үткәрелмәсә, бу вакыйга балалыклары чыгып бетмәгән үсмерләрнең бер уены булып кына калыр иде. Ә чынлыкта исә, кешелеклелек, җәмгыять һәм әйләнә-тирәдәгеләр өчен дә янып яшәү бәхете турында, үзара дуслык һәм иҗади матур тормыш хакындагы олы сөйләшү килеп чыккан. Алдагы әсәрдән аермалы буларак, бу пьесада яшьләрнең романтик ашкынуына, үз-үзләрен табуга омтылышларына олы тормыш тәҗрибәсе туплаган, утны-суны кичкән өлкән буын вәкиле ярдәмгә килә. Зәнә, Илшат, Шәрифҗан һәм Рәдиф кебек шәхес буларак формалашу чорын кичергән чыгарылыш класс укучылары өчен Кәрим Хәернасов әнә шундый кеше. Автор укытучы Кәрим абыйлары һәм үсмерләр арасындагы мөнәсәбәтне тормышчан һәм фәлсәфи яңгырашка ия булыр дәрәҗәдә гыйбрәтле дә итеп бирүгә ирешкән. Миңа калса, әсәрнең аеруча уңышлы моменты да шул. Тормышта үз-үзен табарга омтылган кеше, бигрәк тә яшьлек хисләре белән генә яшәүчеләр, гадәттә, ашкынып эзләнүчән булалар. Һәм таптым дигәндә генә үзе эзләгәнне танымау, акыл белән уйлап җиткермәстән, үзе эзләгәнгә тискәре реакция ясау, аңардан качып котылырга, арынырга омтылу хас була. Бу очракта укытучы белән укучылар арасындагы мөнәсәбәттә әлеге парадоксаль закончалык гыйбрәтле чагылыш таба. Әсәрнең оптимистик рухта тәмамлануына кадәр вакыйгалар шактый кискенлек белән бара икән, моны, барыннан да элек, авторның сюжетны әлегедәй фәлсәфи нигездә кора белүе һәм шул фәлсәфә аша киң яңгырашлы проблемалар күтәрә алуы белән аңлату дөрес булыр.

Гомумән, Аяз Гыйләҗев драматург буларак та кызыклы язмышлар, әһәмиятле мәсьәләләр күтәрергә сәләтле автор. Әмма аны бу жанрда үзен ахыргача тапты дип әйтергә дә иртәрәк кебек әле. Беренчедән, аның иҗатында, масштаблы мәсьәләләр кузгаткан пьесалар белән янәшәдә генә, артык берни алып килмәгән, интригаларга корылган сәхнә әсәрләре дә юк түгел. Икенчедән, ни сәбәптәндер, аның пьесаларындагы драматургик нигез еш кына спектакльләрдә ачылып бетми. Монда, югарыда искә алганыбызча, вакыйгаларның, язмышларның пәрәвез оясы җепләре кебек катлаулы үрелеше зыян итәме? Режиссерларның вакыт-вакыт вакыйгаларның тышкы агышы белән чамадан тыш мавыгып китеп, төп фәлсәфәне алып килгән, тудырган нәни энҗе бөртекләренә игътибарсыз булуы, кирәк кадәр басым ясап җиткермәүләреме әллә? Һәрхәлдә бу драматург әсәрләреннән дә чын сәхнә сәнгате үрнәкләре тудырган, тудыраячак режиссерлар табылачагына ышанасы килә. Театр сәнгатебезнең киләчәген форма һәм стиль төрлелекләреннән башка күз алдына китерү кыен. Ә инде драматургның үзенә килгәндә, ул, һичшиксез, иҗат принципларына, олы сәнгатькә хыянәт итмәскә тиеш. Үзешчән сәхнә өчен язам дип һич кенә дә үзешчәнләшү кирәкми. Аерым режиссерга, аерым сәхнәгә ятышсын дип иҗатта чигенүләр ясау дөрес булмас. Үзешчәннәрме, төбәкләрдәге профессиональ коллективлармы, һәр очракта төп максат— олы сәнгать. Бу һәрбер художник истән чыгармаска тиешле таләп. Авторның үз сүзләре белән әйткәндә, «драматург тамашачы фикерен билгеләүче дә, аны раслаучы да, тәрбияләүче дә»[1] бит.

Әдипнең иҗат юлын кыскача гына күңелдән кичереп чыгу да шактый озынга сузылды. Ә иҗат әле тукталмаган, иҗат дәвам итә. Тынгысыз эзләнүләрдә башланып, өзлексез эзләнүләр белән дәвам иткән газаплы һәм бәхетле иҗат алга таба да эзләнү, бары тик эзләнүләргә генә йөз тотып дәвам итәр дип ышанасы килә. Сайлап алган ныклы бер юнәлеше, проблемалары, принциплары булган әдипкә ышанмый мөмкин түгел. Автор үзе ул юнәлешне гади генә билгели: «Минем үземә тормыш һәм кешелек турында актив уйланып яшәүче, яхшылык өчен көрәштә үз урынын табарга омтылган кешеләр якын»[2]. Максат изге. Алга таба да шулай булсын!

---

[1] Гыйләҗев А. «Җиз кыңгырау» китабына соңгы сүздән. Казан, 1975.
[2] Шунда ук.

Энгель Нигъмәтуллин

# ТИПИКЛАШТЫРУ ТУРЫНДА УЙЛАНУЛАР

Типиклаштыру — гаять катлаулы, киң колачлы проблема. Ул проблема әдәбият белеме белән бергә, тәнкыйтьне дә үзенә җәлеп итеп килә. Тәнкыйть әдәбиятта үсеп килгән художество-эстетик бөреләрне күреп ала һәм шуларга үсәргә булыша. Әдәбиятта шытып чыккан яңа тенденцияләр искерә төшкән карашлар алмашуын тизләтә, яңа художестволы концепцияләргә юл ача. Таза тенденцияләрне әдәби күренешләр чуарлыгыннан чүпләп, ниндидер бер ышанычлы бизмәндә үлчәү зарур. Бүгенге фән андый бизмәнне системалы анализда күрә.

Типиклаштыру әнә шундый системаларның берсе. Проблеманың бүтән тармакларына кул сузмыйча, бер генә мәсьәлә— язучының дөньяга карашы мәсьәләсенә тукталыйк.

Язучының дөньяга карашын тәкыйтьчеләр конкрет җирлектә һәм торган саен әтрафлырак планда үзләштерергә омтылалар. Р. Мостафин аны кибернетика, биология, философия фәннәре ирешкән югарылыктан торып өйрәнергә чакыра. һәм «сәнгать әсәрендә идеологик категорияләр эстетик категорияләр аша тормышка ашырыла» дигән нәтиҗәгә килә.

Гомумән, бу идея яңа түгел. 20 нче елларда Г. В. Плехановның социаль (идеологик) энергиянең эстетик энергиягә күчүе хакындагы фикере популярлык казанган иде. Дөрес, кайберәүләр аны үз вакытында вульгар социологизм кануннарына ябыштырып аңлатырга да күп сорамады.

Художникның дөньяга карашы нинди юллар һәм нинди энергия ярдәмендә әсәргә күчә соң?

Дөньяга караш художникның эмоциональ-эстетик пафосы белән өретелгән була: «синә борчыган әйбер, син язган әйбер башкалар өчен дә әһәмиятле булырга тиеш» (Ә. Еники), «язучы бик каты хыялланырга тиеш» (Г. Әпсәләмов).

Иҗат процессында рациональ һәм эмоциональ башлангычларның үзара аралашып хәрәкәт итүе хакында язучыларның үз күзәтүләре дә ачык сөйли. Мәсәлән, «Ак чәчәкләр» язылганчы ук Г. Әпсәләмов күңелендә врачларга карата зур ихтирам сакланган. Язучы хәтерендә фронт тормышы да уелып калган, хәзерге врачлар, авырулар, больница күренешләре дә өстәлә бара. Кичерешләрнең эмоциональ куәте пружина рәвешендә уз вакытын көтеп тора. Таркау образлар, күренешләр бер төергә йомгаклануны көтә. Ниһаять, автор күңелендә җанлы конкрет образ туа һәм ул ак халатлы кешеләрнең авыр хезмәтләре бербөтен булып оеша, күз алдына баса. Үлем һәм яшәү. Үлем язучы яткан палатадагы электр лампасына яшеренгәндәй, ә тәрәзәдән сирпелгән йомшак нурлар, аяз күк чите — тормыш.

Дөньяга караш бөтен бер системаны тәшкил итә. Системаның чикләвек төше— философик карашлар. Чөнки алар политик, социологик, фәнни, әхлакый карашларны оештыручы һәм шуның өстенә әдәби әсәрнең офыгын билгеләүче. Х. Сарьян әдәби әсәрнең логикасын язучының фәнни һәм фәлсәфи яктан хәзерлекле булу-булмавы белән тыгыз бәйләнештә алып карый. Бу инде әр-яңа фәнни принциплар һәм идеяләрне дә танып-белү дигән сүз (Х. Сарьян. Уеңны уйдырып сал... Казан, 1977).

Язучының фәлсәфи фикерләре, социаль-политик һәм башка карашлары белән берлектә, әсәргә төрле юллар белән керә. Әйтик, теманы сайлау. М. Мәһдиев, мәсәлән, Г. Ахуновның «Ардуан батыр» повестена соклануын белдерә. Чөнки автор хәзерге чынбарлыкның магистраль темасын — эшчеләр сыйныфы темасын һәм аның чыганакларын таба, аны сәнгатьчә гәүдәләндерүгә ирешә. «Заман темасымы бу? — дип сорау бирә М. Мәһдиев һәм җавап кайтара: — КамАЗ һәм БАМ төзи торган укучы өчен нәкъ менә заман темасы бу. Чөнки язучы беренче бишьеллыкларның героик хезмәт сәхифәләре аша бүгенге көнгә күпер сала» («Казан утлары», 1975 ел, 9 сан, 164 б.). М. Мәһдиев фикеренчә, автор теманың тирән чоңгылларын күрә алган. Бу инде автор-

ның фәлсәфи карашлары киңлеге турында сөйли.

Язучының фикер куәте әдәби әсәргә анализ ясауда да ачыклана. Мәсәлән, Б. Камалов Ш. Маннурның «Агымсуларга карап» исемле повестена структуралы анализ ясый. «Әсәрне баскычлы-баскычлы итеп күз алдына китерәсе килә, — дип сүз башлый ул. — Беренче баскыч — бәләкәй авыл малаен, сабыйны сурәтләү... Тора-бара аң-белем туплап килүче, тирәюньгә күзен ачкан яшь егет дөньясы ачыла. Азак өлештә инде без дөньяның әчесен-төчесен татыган, тормыш тәҗрибәсен туплаган, каләмен чарларга өлгергән шагыйрьне күрәбез» («Социалистик Татарстан», 1974 ел, 21 февраль). Әсәрне шул рәвешчә бербөтен итеп күзаллау югары осталык билгесе.

Фәлсәфи киңлек образны күп мәгънәле итеп төзи белүдә дә чагыла. Бу яктан Р. Төхфәтуллинның «Йолдызым»дагы Гөлзифа образы характерлы. Гөлзифаның уй-тойгылары, моң-зарлары, рухи кичерешләре йолдыз образына чолгана. Йолдыз символы Гөлзифаның идеалларын, өметләрен, саф күңелен фәлсәфи масштаблы итеп яктырта.

Әдәби традицияләребезне дәвам иткән Гөлзифа образы Н. Юзиев, Ф. Мусин, Х. Миңнегулов, Р. Мостафиннар тарафыннан бер тавыштан уңай бәяләнде. Чөнки образның структурасы отышлы. Ул халкыбызның чыдамлыгын, тырышлыгын, туган туфракка ихтирамын һәм башка күркәм сыйфатларын, яшәеш тамырларын ачып сала. Һәм бу структура әдәбиятыбызда үстерелә бара. Аңардан соң язылган «Гыйльмениса», «Соңгы васыять», «Берананың биш улы», «Көннәр язга авышкач» кебек күп кенә проза әсәрләре шул хакта сөйли.

Образның фәлсәфи мәгънәсен, символик аһәңен аңлап бетермичә кайбер тәнкыйтьчеләр аны уңышсыз, катып калган, артык идеаллаштырылган дип санадылар. «Уңай образ, барыннан да элек, хәрәкәттә, көрәштә, тормыш каршылыкларына органик чумып чарлана», — дип язды Ф. Хәсни («Социалистик Татарстан», 1962 ел, 28 апрель). Гали Халит та шул ук фикергә кушылды. Бу фикерләр сәбәпсез тумаган, әлбәттә. Романтик-лирик буяулар белән төсмерләнгән Гөлзифа образы повестьның икенче бүлегендә бөтенләй башка, реалистик планга күчереп куела һәм шуның аркасында образның бөтенлеге какшый. Образны уңай бәяләүчеләрдән Нил Юзиев та авторның икенче бүлектә ашыкканлыгын, схемалылыкка таба шуышуын искәртүне кирәк таба.

Совет әдәбиятында яңа жанр җитлегеп килә, аларда автор монументаль һәм диалектик-хәрәкәтчел образны синтезлаштыра. Әйтик, Мариэтта Шагинянның «Четыре урока у Ленина» әсәре шуның бер үрнәге. Язучы, бер яктан, Ленинның тормыш белән чиксез контактларын эзләп таба, ул яшәгән күп кенә Европа җирләре турында мәгълүмат бирә һәм, икенче яктан, М. Шагинян Ленин образын фәлсәфи үрләргә менгерә, гомумиләштерә.

Язучылар юл уртасында басып калган киеренке шәхескә йөз тота башладылар. Үзәк образ яңашәсенә автор аның «айресен», «дошманын» китереп куя, геройның ныклыгын сынап карый. Ә. Еникинең «Рәшә» повестен искә төшерик. Дәһшәтле сугыш еллары, бөтен ил бихисап корбаннар биргән чорда Зөфәр Сабитов аулак почмакка ышыкланган. Зөфәр исән-имин калган, ләкин тормыш геройны барыбер яралый, үзен гаепле дип тоярга мәҗбүр итә. Шуның өчен дә автор Зөфәрнең зәһәр фәлсәфәсенә, яшәү рәвешенә тәпле, тормышчан һәм шул ук вакыт якты идеаллы, саф күңелле образны каршы куярга кирәк тапкан. Язучы рухи таркаулыкка юл тоткан геройны матур образ белән очраштыра. Ул — Рәшидә.

А. Расихның «Ике буйдак» һәм Х. Хәйруллинның «Картлык, ...кемгә шатлык?» әсәрләрен искә алыйк. «Картлык, ...кемгә шатлык?» повестенда Хәсән белән Асыл, ике дус — дошман бар. Икесе дә ярлы крестьян токымыннан. Тик Асыл дөньяга нык ачулы: «Бу дөньяда кешеләр бер-берсенә бүре, бүре... Үзең ашамасаң, өлгермәсәң, ул барыбер кайчан булса да сине тотып ашаячак». Бер карашка, Асыл ямьсез фәлсәфәгә бирелә кебек. Шуның өстенә, Габдрахман байның малтуарын суя, ярлылар комитеты рәисе булып йөргән чакта авылдашларын наган белән куркыткан, ачларга килгән ризыкны дөрес бүлмәгән. Ләкин шул ук кеше авылдашларын колчаклылар кулыннан коткара. Ватан сугышында, ике полкташын ияртеп, пленнан кача, тапкан алтынын хөкүмәткә тапшыра. Төрмәдә утырган чакта да совет властен хурлаучыларга юл куймый: «Тел тидермә син хөкүмәткә! Сез паразитлар белән утырсам да, үпкәләмим мин аңа. Мин бит аңа сезнең кебек кисеп ташланган, корырга тиешле ботак түгел». Укучы аптыраштa калырга мөмкин: ничек инде ул алай, әллә яман, әллә яхшы — белмәссең, буталчык бер бәндә бу Асыл. Ул, — ди автор, — яхшы күңелле кеше, тик кайчандыр рәнҗетелгән бу кешедә психик тыйнаклык чамалы.

Мондый очракта янында дуслык кулын сузарга әзер торган кеше булу кирәк. Бармы андый? Кемдер үз йомышлары белән мәш килеп, битараф та калыр. Ләкин арадан берәү янына килер, хәлеңне белер, аңлар, кайгыларыңны уртаклашыр. Ул кеше — Хәсән. Хәсәнгә дә авыр килде. Ул семьясын югалта. Хәсәннең тормыш юлына әйләнеп карыйк: Казан гарнизоны, Октябрь революциясе көннәре, Казан Кремлен алу, Беренче татар полкында хезмәт, колхозны аякка бастыру...

Нәтиҗәдә Хәсән белән Асыл образлары бер-берсен тулыландыра. Ике кеше бер язмыш белән яшәгәндәй тоела башлый.

«Ике буйдак» романында ике галим көч сынаша. Тәнкыйть Рәхим белән Заһид Сафич арасындагы кытыршылыкны күбрәк игътибар үзәгендә тота. Рәхим коеп куй-

ган «уңай» герой, практикага таянып эш итә, Заһид, киресенчә, җилкуар, принципсыз бер тип икән. Инде чынлап исәп йөртсәң, Рәхим дә әллә ни ерак китмәгән. Экспериментала базасы ташка үлчим, эрудициясе җитми, балаларын рәтле карау юк, хатын-кызга күл күтәрүдән дә тартынмый. Рәхимнең психологик кичерешләргә ярлылыгын тәнкыйть тә сизми калмады (И. Нуруллин). Заһидта исә интеллектуаль һәм эмоциональ байлык башлангычлары күзгә бәрелеп тора.

Бу роман турында мин озак уйландым. Галимнәр буш җирдә тумыйлар, аларга югары әхлак кагыйдәләре, тормышка, табигатькә олы мәхәббәт, эш-хезмәтне сөю сыйфатлары да мул бирелгән. Бу сыйфатлар халык казанышы, халык мирасы. Димәк, галимнәр турында сөйләшү җитди булырга тиеш. Аны гел ике кеше арасындагы низаглашуга гына кайтарып калдырырга ярамас. Монда автор позициясе зур әһәмияткә ия. Автор Заһидны фәннән читкә алып ташладымы? Бу бит аның иркендә иде. Ә ул аны фәндә калдыра. Рәхим белән Заһид арасындагы конфликтны автор киләчәктә дәвам итәр, үстерер һәм чишәр дип уйларга кирәк.

Тагын бер мәсьәләне юлга саласы бар. Тәнкыйтьчеләрне тыңлыйк: Хәсән Хәйри уйлавынча, роман язучы «образлар бердәмлеген булдырырга тиеш» («Социалистик Татарстан», 1969, 14 февраль). Фәрваз Миңнуллин «әдәби геройлар диалектикасы»н телгә ала (Ф. Миңнуллин. Якты юллар. Казан, 1975).

Образлар диалектикасы... Сөйләве җиңел, иҗат итүе, тормышка ашыруы ифрат читен. Хикмәт шунда ки, һәр персонаж өчен тулы нагрузка, күпләгән шартлар җитенкерәргә тиеш. Еш кына әсәрләребезне персонажлар көтүе ту[illegible]а. Геройлар өстенә ташламасыз нагрузка йөкләүне классиклардан өйрәнү кирәк безгә. «Сугыш һәм тынычлык» романында Л. Толстой исәпсез-хисапсыз персонажларның һәркайсына бер эш йөкли.

Хәрәкәт — гомумфәлсәфи категория, яшәешнең бишеге. Әсәрдә һәр өлеш хәрәкәткә буйсына. Гадәттә без анда хәрәкәтнең тышкы ягын, «айсберг»ның өстә яткан өлешен, ягъни сюжет, фабула, конфликт кебек, хәрәкәтнең эре блокларын гына күрәбез. Хәрәкәт мәсьәләсе алар белән генә чикләнми. Тәнкыйтьчеләр арасыннан яңа авазлар ишетелә башлады. Нил Юзиев «конфликт эзлеклелеге һәм дәвамлылыгы, вакыйгаларны сурәтләү ритмы, характерлар ачылуда вакыт роле» дигән төшенчәләрне эшкә җигәргә чакыра (Н. Юзиев. Әдәбият хәзинәләре. Казан, 1978). Хәсән Сарьян тарихи вакытның сәнгать әсәрендәге вакытка нисбәтен күрсәтә.

Кайбер тәнкыйтьчеләрнең хәрәкәтне читкә тайпылудан, бормалы юллардан арындырып, туры гына алга ургылган агым сурәтендә күрәселәре килә. Мәсәлән, И. Нуруллин: «Бер-берсенә бәйләнгән ике эпизод бар, — ди, — № 2 № 1 дән соң килгәндә генә үзенең мәгънә иңеген тукми-чәчми укучыга җиткерә ала». («Казан утлары», 1966 ел, 9 сан). Иҗат мондый арифметик хисапка бирешми, минемчә, ул югары математика законнарына буйсына. Образларның йөрешләре гел бер үк тизлектә, бер үк вакытта узмый. И. Нуруллин метафорасын кулланcак, алар «молекулалары тәртипсез хәрәкәтләнә торган эремә»не хәтерләтә. Бу турыда әдәбият белгече А. Ф. Киселева түбәндәгечә яза: «Бер геройдан яки вакыйгадан икенчесенә аркылы-торкылы сикереп кую, характер-вакыйгаларның сәбәп-чыганакларын югалту... болар яңа элемтәләрнең әдәби структура төрләре» (Проблемы художественной формы социалистического реализма, т. 2, М., 1971).

Әдәби әсәрләрдәге хәрәкәт «субъектив-психологик һәм объектив-тарихи вакыт»ка бүленә (Филологические науки, 1974, 6 сан). Гомумән әдәбиятчылар бу ике тип вакыт белән таныш, ләкин күбесенчә аларны аерып-аерып күрсәтәләр. Монологик жанр («Кызлар хатлары», «Гомер ике килми» һ. б.) белән эпик жанр («Идел кызы», «Каз канатлары» һ. б.) әлегә бер-берсенә керешмичә, янәшә, параллель яшәп килә.

Объектив-тарихи вакыт А. Расих тарафыннан уңай кулланыла. Аның «Каһарманнар юлы» әсәрендә вакыт образы бар. Беренче татар укчы бригадасы узган юл ул. Аның ярдәмендә автор берничә максатка ирешә: беренчедән, «аталар һәм балаларны» берләштерә (Хәбибрахман белән яшь тарихчы Альфредның дуслашып китүе), икенчедән, тарихтан информация бирә һәм, ниһаять, мавыктыргыч маҗаралар өсти (казачканың агулануы, Сәгадәтне басмач кулыннан коткару, Бохара әмире хәзинәсенә юлыгу). Татар бригадасы узган юл объектив-тарихи вакыт функциясен башкара һәм үз чиратында субъектив-психологик вакытка (Латиф кичерешләре) йогынты ясый. Латиф хат ала. Хат аны тетрәтә, дөньяга карашын какшата. Тарих шаукымы агымдагы тормышка бәреп керә һәм шәхеснең рухи драмасы үткәннең кайтавазы булып ишетелә башлый.

Субъектив-психологик вакыт геройның фикер, хис агышында чагыла. Бөтен хикмәт тә шунда, гади ачыш түгел бу. Герой гүя ике планда, — фани һәм «җүләр» (соңгысы романтик мәктәпнең йогынтысы) планда — фикер йөртә. Бу бүленешнең сәбәбе нәрсәдә? Әсәрдә (роман, повесть, хикәя, драма) яшәүче персонажлар урта кул булудан качалар. Һәрберсенең үз «тавышы» бар. Һәм аның үзенчәлеге арткан саен тавыш иясе башкаларга (укучы, бүтән персонажлар) сәеррәк тоела. Мәсәлән, Л. Н. Толстой драмасындагы «тере мәет» — Федя Протасов, А. П. Чехов геройлары һ. б.

Менә Азат Ганиевнең «Сүзсез җыр» дигән фәлсәфи повесте. Анда Хәят исемле кыз бар. Хәят уйланучан, үзенчә фикерләүче шәхес. Аны барыннан да бигрәк киләчәк, космос хәлләре борчый:

«— Габделхак, киләчәктә тормыш ничек булыр икән?

— Шуны да белмисеңме? Җир шарында бернинди дәүләт чикләре калмас, планета кешеләре бер гаилә булып яшәр. Ул чагында гаскәр дә, сугыш кораллары да кирәк булмаячак. Һәр кеше ике телдә сөйләшә белер. Үзенең туган телендә һәм барлык кешеләр өчен уртак интернациональ телдә».

Чит күзгә Хәят кебекләр тиле-милерәк күренер. Тормыш ыгы-зыгысына битараф ул. Йорт эшләренә кендеге белән ябышкан әнисе аны аңлап җиткерми. Хәят күзе аша автор табигатьнең бинһая тирәнлекләрен капшап карый.

Гәрәй Рәхимнең «Кәннәр язга авышкач» исемле повесте да байтак уй-тойгылар уята. Ул да баш геройны сәеррәк кеше итеп тасвирлый: «Укытучылар аны унынчыны укып бетергәнче аңламадылар. Шуңа күрә күбесе яратмый да иде. Ләкин бик сирәк һәм зирәк укытучылар гына: «Фәкилә апа, бу балаңнан бер-бер кеше чыга. Ул безнең бөтенебездән дә акыллы», — дип әйткән. Автор шул герой җилкәсенә фикер йөген (үлем һәм яшәеш турында) сала. Урта кул кеше андый йөктән бөгелеп төшәр иде.

Барлас Камаловның «Ялыкмаслар» повестенда реалистик метод бердәмлеге сакланмаган, романтизм алымнары да (баш геройның мәхәббәт маҗаралары) урын тапкан. Тәнкыйтьчеләр Хафиз Кадергуловның шәхси тормыш линиясенә сагаебрак карыйлар. Нишлисең, Б. Камалов тормышны шулай күрә. Үзе гел юлда, корреспондент эшендә. Салмак кешеләрдән үзгә буларак, аның эш ритмы башка. Ритмга тәңгәл фәлсәфәсе дә. Шуңадыр әсәрдә фикер иләгеннән үткәрелеп җитмәгән һәм характер дәрәҗәсенә күтәрелмәгән байтак кына персонажлар урын алган: Иршат, Таһир, Әхтәм, Айрат, Азат, Мәгъсүмә, Рәхилә... Язучыда барысы да бар: тормышны белү, үткен күзәтүчәнлек, канатлану, әйбәт тел. Ә менә жанр дөрес сайланмаган. Хафиз Кадергуловлар өчен повесть рамкалары тар. Герой ил язмышын өстенә алган. Шуңа күрә аның шәхси романтикасы халык тормышы романтикасын чагылдырмый калмый. Ә анда мең төрле ситуацияләр, һәркайсында җитдилек тә, мәзәк тә бар. Авторга романтик чаткыларны аерым маҗараларга түкмичә, микроситуацияләргә күчерергә иде. Үзен роман жанрында да сынап карарга түгелме икән Б. Камаловка.

Субъектив-психологик вакыт икенче төрлерәк тә чишелеш таба: герой тирә-як дөньяны гүя симфония итеп тоя. Геройның хис-тойгылары берьюлы дистәләгән ноктада кабынып китә. Һәм шул ноктадагы «утлар» бер яна, бер сүнә. Бу күренеш Шәйхи Маннурның «Агымсуларга карап», Рафаил Төхфәтуллинның «Җиләкле аланнар», Әмирхан Еникинең «Гөләндәм туташ хатирәсе» повестьларына аеруча хас.

Ш. Маннур повестенда туган яклардан дөньяның олы юлына атлаучы герой. Ул кеше табигатенә соклана. «...Кеше ул әле үзе дә белмәгән олы талантлар серен, искиткеч могҗизалар тудырырдай сәләтләр кодрәтен потенциядә саклый торган, берәү тарафыннан да әле тулысынча өйрәнелмәгән, ачылып бетмәгән һәм, ихтимал, ачылып бетүе мөмкин дә булмаган бөек көч». Кешене шулай бөек итеп күргән геройның эмоциональ дөньясы киң җәелгән, төрлечә төсмерләнгән (монда пантеистик карашлар да кушыла). Кыска гына вакыт эчендә герой әллә ничә кичереш йогынтысына бирелә, аның күңелендә санап бетергесез психологик чаткылар хасил була: теләктәшлек (Шәйхигә карата), оялу (кеше гармунын сораусыз алгач), җирәнү (Мәүләдән), таңга калу (Җиһангир абыйның пычаклы кешегә каршы чыгуын күреп), гарьлек (шахтерларның үз интересларын яклый алмаганын абайлагач), ис китү (Җиһангирның актык акчасын бүләк итүенә) h. б.

Р. Төхфәтуллинның «Җиләкле аланнар»ында вакыйгалар бала күңеле аша тасвирлана. Күзәтүчән герой каршылыкларга тап була, аларны аңларга тырыша. Сәер кешеләр арасында элекке мулла Кәрим бабай бар. Кулакларны кысрыклаган заманда председатель Фазыл абый аны кумый, авылда калдыра. Малай өчен гаҗәп бу. Инде исән котылдың, күсәк күтәрмә. Кая анда! Авылдагылар мәчет манарасын җимереп төшерәләр, Кәрим бабай шунда тагын чыга, председательне эт итеп сүгә: «Бирән! Бүре! Кяфер!» Ут йотып йөргән алайса! Юк, ашыкмыйк әле хөкем чыгарып. Мәчет архитектурасын, аның матур төзелешен кызгана бит бу карт. Борынгы китаплар белән кызыксынып йөргән кешегә ул берничә кыйммәтле китап бүләк итә. Карурман шул кеше күңеле... Фазыл аб[illegible]ы кара тагын. Китап җыючы: «Вәхше син», дип орыша аны. Усал, буйсынмас Фазыл абый коела да төшә, башын аска игән килеш, дәшми басып тора. Әкәмәт! Касыйм абзый да әнә җене сөймәгән яңалифне ятлый. Кешеләр, кешеләр... Фәритне дә белми йөргән икән. Ялкау, имеш, укуын ташлаган. Рәхмәт Алиш абыйга, аңлатып бирде хәлне.

Яшь герой алдында чиксез дөнья: әнә, кызлар алъяпкычы төсле ак каеннар тезелешкәннәр, анда-монда агач яфрагы кояшта җемелдәп куя; көмеше, яшькелткүгелҗеме, җангә җылы биргән миләүшәләр, яшьлек чагында отыры тәмле тоелган каен суы. Куе хуш ис. Урман, болын, җиләкле аланнар...

Ә. Еникинең «Гөләндәм туташ хатирәсе» повестенда вакыйгаларны күзәтү, психологик симфония Гөләндәмгә йөкләтелә. Гөләндәм музыка дөньясында яши. Героиня күңелендә дә төрле авазлар тартыша, сынаша, күңелне чыбыркылый: Кем белән син? Әти-әни сине күз карасыдай кадерләп саклый. Син бәхетле. Укытучы абыең сиңа гашыйк. Нинди талант үзеңдә! Ә карап торырга гади бер кеше, оялчан, тәкатьле. Халык көйләрен ничек яхшы аңлатып бирә. «...Ярларына сыя алмагандай бөтерелеп, кызу гына аккан Идел

үзе... Аргы якта, киң тугайда киез эшләпә кигән агайлар тезелешеп печән чабалар... Ә бирге якта, су читендә ап-ак казлар канат кагына».

«Гөләндәм туташ хатирәсе» — Ә. Еники иҗат юлында яңа табыш. Мәсьәлә темада яки яңа тормыш материалы сайлап алуда гына түгел. Хикмәт баш герой карашларының симфоник-полифоник яңгырашында, дөньяны мул итеп, энергияле сурәттә күрүендә. Монда нинди фәлсәфә,— дип сорарсыз. Моң дип әйтсәк, дөресрәк булмасмы? Әйе, моң бар, настроение бар, яхшы музыка бар. Автор — сихерче. Ләкин ул философ та. Ике җан кавыша алмады. Бу темага күпме әсәр язылмады. Күп очракта әсәрләр трагик финал белән тәмамлана иде. Идеалист язучылар андый финалдан файдаланып, фани, «гамьсез» дөньяга ачынып кара, «иланһи», «җан-күбәләк» тормышы турында хыяллан, аны төшеңдә күреп сөен, дигән пессимистик фәлсәфәгә өйрәттеләр. Ә. Еники героиняның эчке дөньясы какшаганын яшерми. Үлеп ярата иде ул Салих Сәйдәшевны. Шунда да үз-үзен җиңгән, мәхәббәтен күңел почмагына яшереп бикләп куйган. һәм аның яктылыгы белән яшәгән, дөньядан йөз чөермәгән. Илен, халык музыкасын, яшәү бәхетен яраткан. Фәлсәфә түгелмени бу? Фәлсәфәнең дә нинди әле!

Әйтергә кирәк, прозабызда объективсубъектив вакытны аралаштырып күрсәтү артык кызыксынып торган уңышларга китермәде әле. Эчке монолог, мәсәлән, нибары башлангыч чор кичерә. Балтик буе романында исә ул инде чәчәк аткан. Килешеп буламы бу хәл белән? Геройларыбыз күп очракта мәш киләләр, вакыйгаларга катнашып йөриләр. Анысы яхшы. Ә мәнә фикер йөртү дәрәҗәләре сыек. Хәтта фикергә бай «Ямашев» романы да кимчелекләрдән хали түгел. Кем белән чынлап торып бәхәсләшә «Ямашев»? «Безнең көннәр» романы традицияләрен дәвам итәме? Хәтергә фәлсәфи полемикага бай Г. Ибраһимов прозасы килә. һәм бу очраклы хәл түгел. Г. Ибраһимов үзе көчле философ, ул Платон, Сократ, Аристотель, Спиноза, Кант, Гегель, Руссо, Ибн Хәлдуннар белән бәхәскә керергә дә ике сорамый иде.

Яхшымы-яманмы, хисләр дөньясын сурәтләргә шомардык. Ә менә фикерләүче геройлар прозабызда бармак белән санарлык. Фикерләүче геройлар өчен конфликтның иң югары ноктасы — фәлсәфи конфликт кирәк, башкача әйткәндә, диалог, язучының тарих, дәвер тарафыннан уртага куелган иң мөһим сорауларга җавабы. Яшәү яки үлем, оешканлык яки энтропия, прогресс яки реакция, тынычлык яки сугыш... Безнең прозада бармы андый конфликт? Бар! Тик кайбер тәнкыйтьчеләр аны күреп җиткермиләр. Бездә Ә. Еники язган «Соңгы васыять» хикәясе тәнкыйтьчеләр тарафыннан бер тавыштан диярлек олы фикерле, тирән фәлсәфи әсәр дип кабул ителде (Г. Халит, Г. Ахунов, Р. Мостафин, Р. Свиригин, Ф. Хатипов, М. Вәлиев). М. Эйдельман Ә. Еникинең «Глядя на горы» («Тауларга карап») исемле җыентыгына анализ ясаганда, авторның фәлсәфи сәләтенә басым ясый («Литературное обозрение», 1975, 8 сан). Тәнкыйтьчеләр фикере белән тулысынча килешәм. Ә менә «Без дә солдатлар идек» дигән кечкенә генә, ләкин күп мәгънәле повесть тәнкыйть игътибарыннан ни өчендер читтә калып килә. Геройлар бәрелеше юк монда, бердәм коллектив күрсәтелә. Төрле милләт кешеләре солдат хезмәтен намуслы үтиләр, гәпләшәләр, тәмле аш әзерлиләр, уйланалар. Автор ике дөньяны капма-каршы куя. Беренчесе гуманизм дөньясы — төрле милләт вәкилләреннән тупланган бер сулышлы коллектив. Алар туганнарын сагынып, уен-көлке белән яши, иркенләп, тәмләп чәй эчә дә беләләр. Икенчесе тупас дөнья — ул туплар ата, миналар шартлата, бомбалар сиптерә, кешедән җансыз, куркак бәндә ясарга көчәнә. Бу чын мәгънәдә фәлсәфи конфликт.

Ш. Бикчуринның «Каты токым» романында да үзенчәлекле фәлсәфи конфликт куела. Коллектив я оеша, я таркала. Нәрсә җиңә? Бригада члennары интернациональ бердәмлектә үзләренең иң матур, иң күркәм сыйфатларын ачалар. Әсәрнең композицион үзәге игътибарга лаеклы. Фазыл Зөбәеров бораулаучылар бригадасы җитәкчесе, коллективта иң олы кеше, авангардта атлаучы. Галиҗанаб Эшче сыйныфының вәкиле.

Г. Ибраһимовның «Безнең көннәр», Ш. Усмановның «Легион юлы», К. Нәҗминең «Якты сукмак», Г. Әпсәләмовның «Сүнмәс утлар» әсәрләре эзеннән атлап, Ш. Бикчурин татар әдәбиятының данлыклы традицияләрен дәвам итә. «Каты токым» романында ул күпмилләтле эшчеләр сыйныфының рухи дөньясын ачарга омтылды. Роман Советлар иленең төрле милләт кешеләрен бер чылбырга җыйган хезмәтне, рухи-мораль атмосфераны ышанычлы итеп күрсәтә. Интернациональлек хисләренең ныгуы белән бергә яңа мораль барлыкка килә, кешеләрдә социаль бердәмлек, яңа коммунистик психология һәм дөньяга караш бөреләнә, көчәя, чыныга.

Дөньяга караш фәнни өлгергәнлек мәсьәләсен дә үз эченә ала, әлбәттә, һәм аның нигезендә дә тормыш ята. Бу бәхәссез хакыйкать. Ләкин тормышны ничек аңларга кирәк? Тормыш төшенчәсенә киң мәгънәдә культура төшенчәсе дә кермиме?

Мәсәлән, А. Расих күп төрле чыганакларны күрсәтә: архив материаллары, истәлекләр, фәнни әдәбият. Барлык материалны язучы эстетик яктан үзләштерә, тарихи шәхеснең эш-хәрәкәтен бүгенге көн югарылыгыннан торып аңларга тырыша. «Ямашев темасы өстендә эшләгән чорда мин шуны белдем, — дип язды ул, — язучыга гыйльми әдәбият ачкан вакыйгалар һәм фактлар гына җитми. Аңа, художник буларак, персонажларның үзен-

чәлеген, ул заманның рухи халәтен, телен, кием-салым һәм гореф-гадәт үзенчәлеген бик нык өйрәнергә кирәк була» («Татарстан яшьләре», 1977 ел, 1 май).

«Әтил суы ака торур» романын язарга рухландырган беренче этәргеч турындагы сорауга Н. Фәттах түбәндәгечә җавап бирә: «Этәргечләр күп булды кебек. Шуларның берсе, әлбәттә, китап булгандыр. Хәзерге заман темасына язучыга, барыннан да элек, бүгенге тормыш тәэсир итсә, тарихи темага язучыга китап, язма әдәбият тәэсир итә дисәк, ялгыш булмас дип уйлыйм. Тарих бит ул үзе китап... Бу урында мин атаклы Ибне Фазлан язмаларын укуымны һәм үземнең 1957 елда Болгар хәрабәләрен казуда катнашуымны да искә алмасам, «беренче этәргеч»ләр мәсьәләсе тулы булмас дип уйлыйм» («Казан утлары», 1972 ел, 6 сан, 176 бит).

Г. Ахунов яшь язучыларга шундый теләк белдерә: «Әгәр дә яшь язучы ил язмышын үз иҗатында чагылдыру миссиясен өстенә ала икән, көне-төне архивларда утырырга, тарихи дөреслекне документаль төгәллек белән ачып салырга, кенәнә 16—17 гасыр сәгать эшләргә батырчылыгы җитә икән — профессиональләшә бирсен...» («Социалистик Татарстан», 1973 ел, 28 октябрь).

Фәнни әлгергәнлек, информациядән тыш, фәнни концепцияләр булу белән дә билгеләнә. Бу җәһәттән «Хатын-гольц турындагы легенда» исемле казакъ хикәясе үрнәк булырлык. Кечкенә хикәя рамкасына автор искиткеч идея диапазонын сыйдырган, тормышны төш күрү белән тиңләү, кешеләрне уенчыкка әйләндерү галәмәте, беркемгә буйсынмаган, чикләнмәгән идарә итүче шәхес, ирек һәм чикләнгәнлек һ. б.

Фәнни концепцияле әсәрләрдән, әйтик, Джонатан Свифтның «Гулливер сәяхәте», А. М. Горькийның «Клим Самгин тормышы», А. С. Пушкинның «Евгений Онегин»ы үрнәк булып тора. Соңгысына гына күз ташлыйк. Нинди генә фактлар тулып ятмый анда! Безнең әсәрләргә кайбер очракта андый идея багажы җитенкерәми.

Олы язучылар һәр очракта да тутыккан художество кануннарын җимереп, геройларны чикләнгән пространстводан «орбитага» чыгаралар, конкрет герой язмышын замандашларына якынлаштыралар, стереофоник образ төзүгә юл тоталар. Безгә алардан өйрәнү отышлы булыр иде. Дөрес, андый тенденция бездә дә ярала: Г. Бәширов («Җидегән чишмә»), Ә. Еники («Без дә солдатлар идек», «Соңгы васыять»), М. Мәһдиев («Фронтовиклар») һәм кайбер башка әсәрләрне күрсәтеп була.

Ф. Хәсни, чын талант тормышны бөтен каршылыклы, четерекле яклары белән колачлый, дигән кыйммәтле эстетик проблема куя һәм Толстой иҗатына күз ташлый, мәкаләләренең берсендә. Лев Толстойда, аның хыялының гүзәл чәчәкләре булып, Платон Каратаев һәм капитан Тушин образлары туган кебек, шул ук Толстой художникның җанында Сергей попның кыска аяклы җилбәзәк Мариядән башы әйләнеп, гөнаһыга батуын сурәтләү кебек ямьсез картиналар да туа һәм тирәнтен кичерелә алган. Художник күңеленә барлык гөнаһлар да һәм барлык кимчелекләр дә сыя ала. Шулай итеп, Ф. Хәсни художник хыялында туган әдәби образның каршылыклы булу мөмкинлегенә, аның нечкә рухи тибрәнешләренә әһәмият бирә.

Язучыларыбызның идея позицияләре уртак — коммунистик идеаллар белән рухланып, кешенең физик һәм рухи матурлыгына сокланып кына иҗат итәр заман. Дөньяга карашта безнең дәвердә каршылыклар булу мөмкинме соң? Ярый, Тукайлар, Толстойлар башка заманнарда яшәгән. Безнең тормыш башка. Шул йөгенсез каршылыклар белән якалашып гомер уздырыргамы?

Иң тәҗрибәле, иң тыйнак художник та каршылыклардан азат түгел. Марксизм тәгълиматы буенча алар үсү каршылыклары дип атала. Хикмәт карашның структура элементлары үзенчәлегендә. Язучыларыбыздан Ф. Хәсни һәм М. Мәһдиевне чагыштырып карыйк.

Ф. Хәсни иҗади проблемаларга туктаусыз күз атучы, «теплица шартлары»ннан качып йөрүче, бәйләнчек сораулар белән телгәләнеп иҗат итүче художник. Ул «тормыш фактларының асыл мәгънәләрен, аларның берсе белән икенчесе арасындагы диалектик бәйләнешләрне» эзләтереп алып эш итә. Язучының эстетик йөзек кашы — сүзгә елгырлык, юмор.

М. Мәһдиев шулай ук юморга һәвәс, штампларга кул-аягы белән каршы торучы, диалектик фикерләүче. «Фронтовиклар» романындагы юмор, Ф. Хәснинеке кебек, үтә борычлы. Бу художникларны нәрсә аера? Ф. Хәсни, үз сүзе белән әйткәндә, «тормышны күп планлы итеп чагылдыру» дип атала торган купшы «теория»ләр»гә сагаеп карый, колачлы системага корылган сурәтләүне өнәп бетерми, фактлар ташкынына, факт ягына тайпыла. Шуңа күрәдер, роман язудан бигрәк ул новеллага хирыс. М. Мәһдиев исә, киресенчә, киң планлы күренешләрне тасвирлаучы әдип.

Бу язучылар иҗаты белән танышкач, дөньяга караш талант белән дуслашканда гына чын художестволы әсәр туа икән, дип куясың. Художникның талант үзенчәлеге — үтә катлаулы һәм киеренке проблема. Анда төрле-төрле факторлар роль уйный: хәтер, фантазия көче, ассоциацияләр чылбыры, күзәтүчәнлек, аң һ. б. Боларны өйрәнү — совет әдәбияты алдында торган мөһим бурыч.

Инде шундый нәтиҗәгә дә килергә мөмкиндер, типиклаштыру — бөтен иҗади процессны колачлап торучы мөһим бер мәсьәлә икән. Ә әдәбият-сәнгать дөньясы очсыз-кырыйсыз тылсымлы дөнья.

*Казан дәүләт университетының татар һәм рус әдәбиятлары кафедраларында матур әдәбиятны система итеп һәм комплекслы тикшеручеләр уңышлы гына эшләп килә. Быел СССР Фәннәр академиясе татар әдәбияты кафедрасы нигезендә шул метод белән өйрәнү өчен махсус группа төзергә карар бирде. База итеп төзелгән бу группага (җитәкчесе профессор Йолдыз Нигъмәтуллина) Казандагы берничә институт галимнәре керәләр. Әлеге мәкалә шушы группа эшенең бер үрнәге.*

Альберт Яхин

# ҖЫР ЖАНРЫНЫҢ ТӨЗЕЛЕШЕ

Сәнгатьнең мөстәкыйль күренеше буларак, җыр жанры да үз закончалыкларына буйсынып яши. Барлык дүртьюллыклар өчен уртак булган сыйфатларны, строфаларны төркемнәргә берләштерүче үзенчәлекләрне белгәннән соң гына җырны халык иҗатының башка жанрларыннан аерып өйрәнергә мөмкинлек туачак. Бу мәкаләдә шундый тар, әмма мөһим мәсьәләне күзәтү максат итеп куела.

Тикшерү материалы сыйфатында СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институты хәзерләгән «Татар халык иҗаты» сериясеннән «Кыска җырлар» томы алынды[1]. Моңа кадәр дөнья күргән җыр җыентыкларын да эченә алган бу китап тулылыгы һәм фәнни яктан эшкәртелүе белән анализ өчен уңайлы һәм күләме ягыннан гомумиләштерүгә нигез бирерлек дип исәплибез. Китерелгән мисаллар шул томнан алына, ә чыганак урынына китаптагы строфа номеры куела.

### ИҢ ВАК БЕРӘМЛЕК

Татар халык җырларының иң вак берәмлеге булып дүрт юллык строфа исәпләнә. Ләкин бу иң вак берәмлекнең үзен тагын да ваграк өлешкә — сурәт-метафора һәм төп мәгънә әйтелгән икешәр юлга бүлергә мөмкин.

Ике җирән пар кашка,
Басып баралар ташка.
Көнен хәсрәт, төнен сагыш,
Ниләр булды бу башка? (202)

мисалында баштагы ике юлда сүз ат турында бара. Соңгы икесендә исә кешенең хәсрәте турында әйтелә. Ташка басып бара торган атлар кайгының сәбәбе дә, нәтиҗәсе дә, вакыйгасы да түгел. Соңгы ике юл белән алдагыларының мәгънәви уртаклыклары да, бәйләнешләре дә абайланмый. Шул ук вакытта бу ике өлешне мөстәкыйль кисәкләр дип тә исәпли алмыйбыз. Кешенең кайгысы турында сөйләнгән өлештә мәгънә ярылып ята, ә менә кемнеңдер җирән кашкасының ташка басып килүе нинди дә булса төгәл бер мәгънәгә ия дип әйтеп булмый.

Табигать сурәте белән кеше турында сөйләгән юллар арасында мәгънәви таңгаллек күп кенә җырларда ачык сиземләнә. Бу күренеш психологик параллелизм дип йөртелә.

Ай яктылары бик якты,
Көн яктысы күк түгел.
Башка дусларым юк түгел,
Син дускаем күк түгел. (2414)

мисалында, мәсәлән, мондый охшашлык җиңел абайлана. Ләкин бу строфада да алдагы ике юл, күп дигәндә, үзеннән соң килгән мәгънәне көчәйтә, тирәнәйтә, яңа төсмерләр белән баета ала, ә мөстәкыйль рәвештә яши алмый.

Бер строфада нинди дә булса фикер төгәлләнә кебек. Шуннан чыгып булса кирәк, ул аерым җыр рәвешендә өйрәнелә. Аның төрле яклары — параллелизмы, рифма һәм ритмикасы, эчтәлеге галимнәр тарафыннан шактый җентекле тикшерелгән. Әмма бу дүрт юллы берәмлекнең болай да кысан калыбы «тиешле» мәгънә өчен генә файдаланылмавы аптырашта калдыра. Чыннан да, әгәр дә строфа җырның бөтен

[1] Төзүчесе һәм эшкәртүчесе И. Надиров. Казан, 1976.

бер берәмлеге итеп санала икән, ни өчен ул үз калыбын күп очракта бөтенләй диярлек кирәкмәгән нәрсәләр белән тутыра?! Һәм, гомумән, җыр үзенең бик чикле мөмкинлеге белән халык тормышы кебек катлаулы чынбарлыкны ничек чагылдыра ала?

Халык җырларының шундый үзенчәлегенә Габдулла Тукай да игътибар иткән. Ул татар халык җырларын яраткан. Аларда тышкы гадилек астында күзгә күренмәгән, әмма күңел белән бик яхшы сиземләгән эчке тирәнлек ятканын тойган. Шагыйрь дөрестән дә дуртьюллыкларның каршылыклы табигате турында күп уйланган булса кирәк. 1910 елда халык әдәбияты турында укыган мәшһүр лекциясен ул башлыча халык җырларына багышлый. Анда җырларга зур бәя бирә, аларны җәүһәр белән якуттан да кыйммәтрәк, ди. Строфалардагы беренче ике юлның, яңа мәгънә өстәмәсә дә, әһәмиятле мәгънә өлешен күтәрү кебек мөһим вазифа үтәгәнлеген әйтә.

Татар халык җырларын халык күңеленең тутыкмас саф көзгесенә тиңләп Тукай жанрның төп сыйфатларыннан берсен ачкан. Көзге буларак җыр күңелне төрле яклап, барлык ваклыклары һәм хәрәкәте белән чагылдырырга тиеш. Ә бу эшне бер-берләренә үзара бәйләнмәгән строфалар башкара алмый. Димәк, дуртьюллыктагы гади мәгънә башка мәгънәләр белән тулыландырылырга, баерга тиеш була. Шундый нәтиҗә чыгардык исә, ялгыз дуртьюллыкның гамәлдәге бербөтен берәмлек булуын шик астына алырга туры килә. Чөнки строфа бөтенлеккә үзе кебек үк башка дуртьюллыклар белән янәшә килгәндә генә ирешә ала. Ә нинди строфалар белән? Нинди тәртиптә? Бу сорауларга җавапны дуртьюллыкларга анализ ясап табабыз.

## КАЙГЫНЫҢ ДӘРӘҖӘСЕНӘ БӘЯ БИРҮ ТӨРКЕМЕ

Иң элек кайбер дуртьюллыкларның танып белү объектын билгелик, ягъни Габдулла Тукайның «күңел көзгесе» төшенчәсен киңрәк җәеп, таркатып карыйк.

Кара болыт киләдер,
Яңгыр микән, кар микән?
Минем кебек хәсрәт күргән
Бу дөньяда бар микән?

дуртьюллыгының алдагы ике юлы, югарыда әйтелгәнчә, мөстәкыйль мәгънә аңлатмый. Күп дигәндә төп өлешне баетып кына килә ала. Төп өлештә исә геройның үзе турында сүз бара. Лирик герой хәсрәт кичерә, ул кайгылы. Һәм кайгысының зурлыгын, күплеген чагыштырып күрсәтә: үзен дөньядагы иң кайгылы кешеләр рәтенә куя. Әлеге дуртьюллыкта кешенең башка яклары турында да, чынбарлык күренешләре турында да ул-бу әйтелми. Әмма герой хәсрәтенең зурлыгы икеле уйланырга урын калдырмый.

Кайгының ни дәрәҗәдә авыр булуы турындагы барлык дуртьюллыкларны аерым бер төркемгә җыйсак, биш йөздән артык строфаны эченә алган төркем килеп чыга. Алар барысы да кайгы дәрәҗәсе турында сөйлиләр, ләкин кабатланмыйлар: аның бик күп баскычларына тукталалар. Мисал өчен кайбер дуртьюллыкларның төп мәгънәләрен генә китерик.

Күкрәгемдә бер төен бар,
Хәсрәт микән, уй микән? (367)

Әллә айның да нурларын
Безнең кайгы күмгәнме? (527)

Уйсу җирдә күл булырлык
Минем түккән яшьләрем. (241)

Күренгәнчә, бу юлларда кайгының башлануы, зурлыгы, нәтиҗәсе бәяләнә. Димәк, бу төркемдә сүз кеше кайгысын танып белү, ягъни аңа бәя бирү турында бара. Кайгы — кешенең чынбарлык күренешләренә эмоциональ бәя бирү нәтиҗәсе ул. Кеше ниндидер күренешне ихтыяҗлары күзлегеннән чыгып бәяли. Аның ихтыяҗларын канәгатьләндермәгән чынбарлык күренеше кире эмоция тудыра. Кайгы шул тойгыларның аеруча тотрыклысы, көчлесе. Әмма без төркем итеп җыйган строфаларда кешенең нинди дә булса күренешкә бәя бирү моменты гәүдәләнми, ә бәлки бәянең ак тарафыннан инде танылган, кайгы, хәсрәт төшенчәсе рәвешендә формалашкан нәтиҗәсе аерып алына. Бирелә кешенең эмоциональ бәядән соңгы рухи халәте факт итеп китерелә дә аның үзенә кабат бәя бирелә. Җырчы кеше, әйтерсең лә, үзенең кайгылы рухи халәтенә читтән торып карый, үз-үзен читтән торып белергә тырыша. Кеше үзенең кичерешләрен танып белә, аларга эмоциональ бәя бирә булып чыга.

Бу төркемгә кергән җырларда кеше үз хәсрәтенең төрле дәрәҗәләрен кичерә дип нәтиҗә ясасак, ике сорауга җавап бирергә тиеш булабыз: беренче төркемдәге дуртьюллыклар (шартлы рәвештә без аларны «А» төркеме дип атыйк) бер-берләре белән үзара якын бәйләнешкә керә алалармы? «А» төркеменә кергән строфаларда да кешенең үз-үзен танып белүе мөмкинме?

Кайгы-хәсрәтнең төрле дәрәҗәләрен күрсәткән дуртьюллыклар берсе артыннан икенчесе җырланса, алар үзара капшылыкка килерләр иде. «Агач булсам янар идем эчемдәге ялкынга» дигән ике юлда, мәсәлән, кайгының соң дәрәҗәсе турында сөйләнелә, ә «уйнар да идем, көләр идем, әллә нигә күңелем шат түгел» мисалында башлангыч чоры турында гына белешмә бирелә. Алар янәшә килгәндә бер үк кешедә бер үк вакытта кайгы зур да, аз да булып чыгар иде. Ә инде иң югары дәрәҗә кайгыны гәүдәләндергәннәрен янәшә куйсак, әледән-әле кабатланырга тиеш булыр идек. Димәк, «А» төркемендәге дуртьюллыклар башка эчтәлекле строфалар белән янәшә килергә һәм алар да ниндидер бер уртак нигездә аерым төркемгә җыелырга тиешләр.

## КАЙГЫНЫҢ СЫЙФАТЫН КҮРСӘТҮЧЕ ДҮРТЬЮЛЛЫКЛАР

Без бу мәкаләбездә биш меӊ ярымнан артык строфага ясалган анализның һәм гомумиләштерүнеӊ кыскача нәтиҗәләренә генә тукталып үтәбез. Кайгының сәбәбен күрсәтүче строфалар меӊгә якын. Эчтәлекләренеӊ уртаклыгын нигез итеп алып, аларны да аерым төркемгә (шартлыча «В» төркеменә) җыярга мөмкин.

Мал кайгысы безгә кайгы түгел,
Баш кайгысы бездә күбрәк. (139)

Ялгыз башым, юк ярдәмчем,
Йөрим язмыш буенча. (184)

Бу юллар кешене чынбарлык белән турыдан-туры бәйли кебек. Алар шәхесне нинди дә булса вакыйга эчендә күрсәтәләр: туган илдәй якын кешеӊнән аерылу, мал-мөлкәтсез калу турында сөйлиләр. Башка дүртьюллыкларда вакыйгаларның яшь гомер узу, атадан яшь калу, сөйгән яр белән кавыша алмау кебекләре дә очрый. Шулай итеп, меӊгә якын строфа үз төркеме эчендә дә төрләргә бүленә. Ләкин бу төркемгә кергән дүртьюллыклар башлыча кешенеӊ кемнәндер яки нәрсәдәндер аерылуына багышланганнар. Фәкыйрьлек, ятимлек, яшь гомернеӊ узуы кебек күренешләр дә күбрәк аерылуга китергән сәбәпләр яки аерылуның нәтиҗәләре булып тора.

Шуннан чыгып аерылуны бу төркемгә кергән дүртьюллыкларның төп эчтәлеге итеп карый алабыз. Мал-мөлкәтсезлек турында китапта нибары унөч строфа булып, алар арасында да бер-берсен кабатлаганнары бар:

Ай, зиһенсез кеше түгел идем,
Зиһеннәрем китте малсыздан. (98)

Әй, гакылсыз кеше түгел идем,
Гакылларым бетте малсыздан. (25)

Дивана да түгел, бик гакыллы,
Малсыз йөреп кенә ябыккан. (36)

Аерылу турындагы строфаларда гомумилектән конкретлыкка күчү тәртибе күзгә ташлана. Югарыда китерелгән мисалларда сүз гомумән аерылу турында бара. «Сез торасыз туган илдә...» ди җыр һәм туган илнеӊ авылмы, шәһәрме, Ватанмы икәнлеген әйтми. Сагындыручы якын кешеләр турында да мәгълүмат бик гомуми: «сез», «безнеӊ», «азакны күрүләрем», дип эндәшә. Бик тә гомуми бу төшенчәләр мәгънәсенә сөйгән ярны һәм авылдашларны да, ата-ананы һәм балаларны да, туганнарны һәм дусларны да, картларны һәм яшьләрне дә кертергә мөмкин. Татар телендә «род» дигән грамматик категория булмаганлыктан, кыз кеше егете турында да, егет кеше кызы турында да уйлап җырлый ала.

«В» төркемендәге аерылу турындагы дүртьюллыклар гомумилекне өч төрле юл — аерылуның сәбәбен, кемнән, нәрсәдән аерылуны һәм аның төрле фазаларын белдерү юлы белән ачыклый. Күрүебезчә, сәбәпләр күп түгел. Аларга, нигездә, мал-мөлкәт эзләп киту турында строфалар керә:

Авылдагы авыр тормыш
Чыгарды чит илләргә. (802)

Дөнья малы — дуӊгыз каны,
Шул кайтармый башларны. (820)

Чит илләрдә йөри-йөри
Туйдырабыз тамакны. (830)

Аерылуның сәбәбен әйткән дүртьюллыклар арасында солдатка алыну турындагы строфалар да очрый:

Нарасый ла чакта үлгән булсам,
Китмәс идем быел солдатка. (947)

Кызларның, кияүгә чыгып, төп йортларыннан китүе менә мондыйрак җырларда гәүдәләнә:

Кыз баланың яткан урны
Караватта бер такта;
Шул бер тактаны кызганып,
Озаталар ят якка. (1391)

Лирик герой туган иленнән, ата-анасыннан, сөйгән ярыннан, дусларыннан аерыла. Аерылу исә китәргә җыену, киту, читтә яшәү һәм әйләнеп кайту кебек фазалар белән ачыклана:

Чит илдә бик күп йөргәнгә
Сары калды битемдә. (814)

Мин китәмен, син каласың,
Бәхиллеккә кулың бир. (1045)

Азакны көн, азакны көн,
Азакны күрүләрем. (3125)

«В» төркемендәге җырларның төрләре шактый күп булып тоелса да алар уртак эчтәлеккә ия. Ул төрләр нибары гомуми төшенчәне ачыклап кына киләләр, бу төркемгә кергән дүртьюллыкларда кайгының зурлыгына игътибар ителми, аның сәбәбе һәм аны тудыручы вакыйгалар турында сөйләнелә.

Икенче төркемдәге строфалар да кичерешләрне аңлау, аларның сыйфатын күрсәтү вазифаларын үтиләр, дип әйтә алабыз. Алар кичерешләрне сагыну, юксыну, ялгызлык, нужа күрү, аннары кемне, нәрсәне сагыну, ни өчен «ут эчендә яну», саргаю кебек тагын да awраk сыйфатларга бүләләр.

«В» төркеменә тупланган җырлар да мөстәкыйль җырлана алмыйлар, чөнки алар вакыйганы белдерү белән генә чикләнә, аңа бәя дә бирми, дәвамын да әйтми.

Ә менә:

Бик күп йөрдем, бик күп йөрдем,
Бик күп йөрдем чит илдә;
Чит илдә бик күп йөргәнгә
Сары калды битемдә. (814)

Биек тауның башларыннан
Күренә Уфа флагы;
Сагындыра да саргайта,
Их, араның ерагы. (3129)

кебек дүртьюллыкларда кичерешнең дәрәҗәсе дә, сәбәбе дә әйтелгән. Аларда строфаның баштагы ике юлы параллелизм вазифасын үтәми. Ул төп мәгънәгә тыңлаштерелгән. Шуңа күрә мондый строфаларны «А» һәм «В» төркемнәре үрнәкләренең кушылмасы дип карау дөрес булыр кебек.

«В» төркеменә җыйналган строфаларның бер-берләре белән янәшә килүләре шулай ук шик тудыра. Болай эшләгәндә бер ук вакытта бер үк кешенең кайгысын төрле сәбәпләргә нигезләргә, яисә:

Илдән китеп җиһан гизә
Газиз ата баласы;

Ялгыз башым, юк ярдәмчем
Йөрим язмыш буенча,

— рәвешендәге бер үк сыйфатларны кабатларга тиеш булыр идек.

Беренче төркемгә кергән җырлар икенче төркемдәге җырлар белән логик бәйләнештә торалар. Кайгының дәрәҗәсен күрсәткән җырлар белән янәшә килгәндә, соңгылары аның сыйфатын ачыклыйлар, гомуми төшенчә рәвешендә алынган «кайгы», «хәсрәт», «әчем яна» кебек төшенчәләрне мәгънә ягыннан баеталар һәм алар шул вазифаны үтәү өчен иҗат ителгәннәр дә. «А» төркеме кайгы дәрәҗәләренә бай, әмма аларда кичерешләрнең сыйфаты турында әйтелми, «В» төркеме җырларында исә кичерешләрнең дәрәҗәсе турында сөйләнми, аның каравы, ул төркем сыйфат төрләренә ифрат бай. Янәшә килгәндә ике төркемдәге җырлар кешенең рухи халәтен ике төрле яктан ача.

## КАЙГЫДАН КАЧУ ЮЛЛАРЫ ЭЗЛӘҮ һӘМ ЧИШЕЛЕШ ТӨРКЕМНӘРЕ

Татар халык дүртьюллыклары ике төркемгә генә җыелып бетми. Аларның җиде йөзгә якын өлеше, эчтәлекләренең охшашлыгыннан чыгып, кайгыдан китү, юл эзләү төркеменә җыела.

Тагы да ниләр булыр икән
Бу бәхетсез балага? (181)

Бер елыймын, бер уйлыймын,
Һич белмимен нихәл итәргә. (20)

Әллә кайгыларым авыр,
Әллә үзем сабырсыз, (488)

— кебек, кешенең үз-үзенә биргән сорауларын, әлбәттә, мөстәкыйль берәмлек дип булмый. Аларның танып белү объектын да кешедән читтә эзләү ялгышлык булыр иде. Бу төркем строфалары («С» төркеме) кешенең канәгатьсезлек тойгысыннан китү юлларының төрләрен чагылдыралар һәм «А», «В» төркемнәренең дәвамы буларак кына карала алалар. Шуңа күрә аларның төркем эчендәге төрләре дә алдагы төркемнәрдәге үзенчәлекләрнең чыгарылмасы булырга тиеш.

«С» төркемендә дә гомуми төр бар. Югарыдагы мисалларны, мәсәлән, кайгының теләсә нинди сыйфатлысына, теләсә кемне сагынуга, теләсә нинди яшьтәге кешегә яраштырып була.

Рәсеме бар кулларымда,
Телләре юк — сөйләшми, (2992)

— кебек ачыклана төшкәне, ягъни сагынган кешесен атаганы да,

Замананың авырлыгы
Безгә генә микәнни, (349)

— кебек, замана авырлыгына караганы да, солдат тормышыннан котылу юллары, шахтерның авыр эшенә түземе калмау турындагылары да бар.

Җыр жанрын өйрәнүчеләр, гадәттә, бу төркем җырларга тукталмыйлар, җиде йөз дүртьюллыкны бөтенләй күрмәгәндәй, дәшми генә үтеп китәләр. Чөнки арада аерүча мәгълүмат бирмәгәне, буйсынып кына яши ала торганы, чынбарлыкны чагылдыру планына караганда, аңлашылмаганы да бар. Бер бөтеннең өлеше итеп алганда, бу төркем дә эчтәлегенең әһәмияте ягыннан үзеннән алда килгәннәреннән калышмый. Ул аларның дәвамы, чишелешкә китерүче өлеше, кешедәге рухи конфликтның иң югары ноктасы булып тора.

Соңгы зур төркемне чишелеш төркеме дип атап булыр иде. Анда кергән дүртьюллыклар лирик геройның үз кайгысыннан качу юлы, яхшымы, яманмы, ләкин тынычлану рәвеше турында сөйлиләр. Беренче төркемдәге текст кеше кайгысын күпме генә зурайтып күрсәтмәсен, «С» төркемендәге текст аннан китү мөмкин түгеллеген ничек кенә өзгәләнеп әйтмәсен, соңгы төркем тексты («Д» төркеме дип атыйк) барыбер тынычлану әмәлен таба:

— Дуслар кирәк дөнья күтәргә, — ди. Айга карап, кошлар сайравын тыңлап тынычлануын әйтә. Герой, бер дә булмаса, бәхетсезлеген язмышында язылган, дигән фикергә килә, замана авырлыгы бар кешегә дә төшкәнгә, ил кайгысы булгангә, сабыр итәргә карар кыла.

## ҖЫРНЫҢ ЭЧКЕ ТӨЗЕЛЕШЕ

Алдагы бүлекләрдә күренгәнчә, дүртьюллык бер ялгызы гына чын мәгънәсендә җыр була алмый. Ул башка төркем вәкилләре белән янәшә килеп кенә эзлекле сюжет төзи һәм җырга әверелә. Бер үк төркем вәкилләре бер-берләре белән янәшә килгәндә эчтәлек я кабатлана, я каршылыкка әйләнә. Димәк, җыр берәмлеге дүрт төркем вәкилләре кушылганда гына туа. «А» төркеме вәкиле кайгының теләсә нинди дәрәҗәсен күрсәтсә дә, җырның өлеше булуыннан уза алмый, үз төркеменең төп сыйфатын — кичереш дәрәҗәсен күрсәтү белән чикләнә. «В» төркеме вәкиле кайгының теләсә нинди сәбәбен,

ягъни сыйфатын күрсәтә ала, ләкин барыбер үз төркеменең чикләренә чыга алмый: кайгы сыйфатын белдерүче булып кала. «С» һәм «Д» төркеме вәкилләре аяныч хә..дән китү өчен теләсә нинди газап белән теләсә нинди юл эзлиләр һәм нәтиҗәгә киләләр. Ләкин аларның мәгънәсе барыбер алдагы ике төркем вәкилләре белән янәшә килгәндә генә аңлашыла ала.

Меңләгән строфаны бик аз санлы төркемнәргә җыя алу җырларны өйрәнү эшен шактый җиңеләйтә. Уртак мәгънә нигезендә җыелган төркемнәрнең үзара мөнәсәбәтен, нисбәтен, бәйләнешен табу җырның эчке закончалыгын абайлауга китерергә тиеш.

Җырның закончалыгын табу өчен безгә төркемнәр арасындагы мөнәсәбәтләрнең тотрыклысын, тышкы үзгәрешләргә бирелми торганнарын аерып алырга кирәк.

Аерым җыр төзегән дүртьюллыклар даими түгелләр — алар үзгәреп, алмашынып тора. Бу алмашыну һәркемнең үз рухи халәтенә ярашлы комбинация сайлавы белән генә дә чикләнми. Вакыт үтү белән, төрле сәбәпләр аркасында кешенең рухи халәте шулай ук үзгәрә. Шундый үзгәреш нәтиҗәсендә элеккеге җыры аны канәгатьләндерми башлый. Хәзер аңарга үзенең яңа рухи халәтенә ярашлы яңа комбинация төзәргә кирәк була. Тарихи планда алганда, кичерешләрнең кайбер сәбәпләре, ягъни сыйфатлары югала, яңалары туа. Дүртьюллыклар үзләре онытылып, яңарып торалар. Җырның дүрт төркеме шундый өч баскычлы үзгәрешләргә җайлашкан. Алардан теләсә кемнең рухи халәтен чагылдырырлык комбинацияләр оештырырга мөмкин. Тарихи җирлеге югалган теләсә нинди дүртьюллыкны башкасы алыштыра һәм шул ук төркемгә урнаша. Чиксез төсмерле рухи халәтнең бөтен байлыгын чагылдыру өчен иң экономияле төзелеш — җыр төзелеше.

Ләкин дүртьюллыклар җыр эчендә күпме генә үзгәрмәсеннәр, алар фәкать үз төркемендәге вәкил белән генә алмашына алалар. Бер дәрәҗә — башкага, бер төрле сәбәп — бүтәнгә, бер нәтиҗә икенче нәтиҗәгә генә үзгәрергә мөмкин. Шулай булмаса, югарыда әйтелгәнчә, җыр үз эчендә я каршылыкка килергә, я кабатланырга тиеш була. Аның сюжет кысасы барыбер тотрыклы булып кала: кайгы дәрәҗәсе — сәбәбе — юл эзләү — нәтиҗә. Бик гадиләштереп әйткәндә, рухи конфликт һәм аны хәл итү сюжеты җырның тотрыклы кысасы, бу кыса эчендәге аерым дүртьюллыклар — шул сюжетны төзүче өлешләр. Шуның өчен алар арасындагы мөнәсәбәтне дәвамлылык, бөтен һәм өлеш нисбәте дип әйтергә хакыбыз бар. Бу мөнәсәбәт җырның логик яктан дөрес комбинациясендә дә сакланып кала. Шулай булгач, дүрт төркем вәкиле бөтенләгән һәм аның өлешләргә ваклануын жанрның эчке закончалыгы дип әйтә алабыз. Дүрт төркем шул закончалыкны чагылдыра, шуңа буйсынган сыйфатларны гомуми планда күрсәтә.

Җыр төзелеше кайсы төркем вәкиле белән башлана? Җырда дүрт строфа булу мәҗбүриме?

Казан дәүләт университетының кырык биш студентыннан үзе яраткан һәм үзе өчен генә җырларлык дүртьюллыклар язып бирүен сорадык. Язмалар күрсәтүенчә, фәкать нәтиҗә төркеме (Д) генә «үз урынында», ягъни ахырда булып чыкты, ә калганнары арасында тәртип табуы кыен иде. Җиде студент өч строфа гына язды, ләкин бер үк төркемнән ике строфа кабатлаучы булмады. Күпчелек сөйгән яраннан һәм туган авылыннан аерылу комбинацияләрен корган. Җырга дүрт төркем вәкилен кертергә омтылу жанрның тотрыклы принцибы икәнлеге тагын бер кат расланды.

Әйткәннәрдән чыгып, мондый нәтиҗә ясый алабыз: җырның гамәлдәге бөтенләнгән, хис дәрәҗәсен, сыйфатын, конфликттан китү юлын эзләгән һәм нәтиҗә ясаган строфалар тезмәсе тәшкил итә. Аның дәвамлылыгы — өлешнең бөтенгә буйсынган мөнәсәбәте — жанрның эчке закончалыгы, ягъни тотрыклы асыл сыйфаты. Җырның поэтик үзенчәлеген шул бөтенлек эчендә генә өйрәнергә мөмкин. Аның хәрәкәтчән асылы хиснең бик күп дәрәҗәләрен һәм сыйфатларын җыйган төркемнәрне тулаем күзаллауны таләп итә. Аерым строфа, иң кечкенә берәмлек булса да, мөстәкыйль җыр булып яши алмый. Татар халкының аерым көйгә салынган тотрыклы җырларыннан нибары «Гөлҗамал» гына бер строфа, бер кушымта белән чикләнә. Ләкин, беренчедән, анда кушымта да «А» һәм «В» төркемнәре вазифасын башкара:

Энҗе дә мәрҗән кызларның кул бавы,
Авыр җан сөйгәннәрнең булмавы.

Бу юлларда хиснең дәрәҗәсе — авырлыгы һәм сыйфаты — җан сөйгәннең булмавы әйтелгән.

Нинди генә егеткә барырбыз, дип
Гөлҗамал,
Колактан колакка алар сөйлиләр,

— дигән юлларда күңелгә ярашлы егет эзләү конфликтын чишү кыенлыгы строфаның өченче төркем вәкиле икәнлеген әйтеп тора.

Икенчедән, бу җырның ахыры булган «Гөлҗамал»ны беренче мәртәбә 1929 елларда Хива шәһәрендә язып алучы Г. Таһирова сүзләренә карaганда:

Яшь егетләр кызларның мулласы,
Насыйп кына итсен лә мәүләсе;

— строфасы (дүртенче төркем — кияү буласы егетнең яшенә туктaлу) төшереп калдырылган.

Җырдагы һәр төркем — кеше кичерешенең бер фазасы. Психологлар эмоциональ бәя күренешен процесс, хәрәкәт итеп өйрәнәләр. Эмоциональ бәя кичереш аша күренә. Кичерешнең көче бәяләнүче объектның кеше ихтыяҗын канәгатьләндерү яки, киресенчә, зыян ясау дәрәҗәсенә бәйле. Объектның кешегә файдалы (фай-

дасыз)лыгы кичерешнең сыйфатын билгеле. Эмоциональ бәя киракмәгән объекттан качу, кирәклесен үзләштерү өчен акылга этәргеч ясый. Акыл, шартларны анализлап, качу яки үзләштерү юлларын таба — нәтиҗәгә килә. Бу ике процесс үзара тыгыз бәйләнештә булып, фәкать бергә генә яшиләр.

Татар халык җырларындагы дүрт төркем кешедәге эмоциональ бәя хәрәкәтенең шундый эзлеклелеген чагылдыра. Психология фәне нәтиҗәләреннән чыгып караганда, җырның дүрт төркеме бик табигый күренеш икәнлеге чагыла. Шул ук вакытта дүрт төркем вәкиленең кушылмасы гына тәмамланган бер бөтен процесс икәнлеге тагын бер тапкыр — әмма инде башка яктан — раслана.

## ҖЫР ТӨЗЕЛЕШЕНЕҢ ЮГАРЫ БАСКЫЧЫ

Моңа кадәр сүз канәгатьсезлектән туучы кире хисләрне һәм уңышсыз мәхәббәт кичерешен чагылдыручы җырлар турында гына барды. Мәхәббәт тудырган уңай хис, шаян җыр, зимагурлар җыры дип йөртелгән дүртьюллыклар телгә махсус алынмады. Кеше, әлбәттә, үзенең кайгысы турында җырлаганда, хисен, тонын кинәт үзгәртеп:

Оренбургтан кайтып киләм
Туры атым атлатып;
Сөйләгән дошман сөйләсен,
Йөрик бармак шартлатып,

— дүртьюллыгын кушып җибәрә алмый. Бу иш строфалар шул ук кеше тарафыннан башка шартларда, башка вакытта гына җырланырга мөмкин. Димәк, алар безнең система төзелешенә берничек тә керә алмыйлар. Шундый нәтиҗә чыгардык исә: бу типтагы дүртьюллыкларның үз тәртипләре бармы соң? Алар җыр жанрына керәме? — кебегрәк сорау туа.

Мәҗлесләрдә, аулак өйләрдә, туйларда җырлана торган дүртьюллыклар лирик геройның үзен чагылдырмыйлар: әйтештә (җырда) катнашучы кешегә яки ул әйткән строфаның мәгънәсенә җавап рәвешендә киләләр. Күпчелекне тәшкил иткән дүртьюллыклардан алар танып-белү объектының башка булуы белән аерылып торалар. Үзенең мәшһүр лекциясендә Габдулла Тукай бу төр текстларны «бер-берсенә каршы җырлашу» текстлары дип, җыр жанрыннан бик хаклы рәвештә аерып куйган.

Анализ күрсәтүенчә, бу типтагы строфалар да дүрт төркемгә җыелалар. Мәхәббәткә караганнары а) герой хисенең дәрәҗәсен әйтә; б) сәбәп итеп кызның яки егетнең матурлыгы, уңганлыгы турында сөйли; в) кавышу юлын эзли; д) кавышу, уртак тел табу, очрашу бәхете хакында белдерә.

Зимагурлар турындагы шаян җырларда кайгы юкка чыгарыла:

Кайгырсалар кайгыралар
Тәмәкеләре юкка. (851)

Читтә йөрү алар өчен уен гына:

Брискийда эрәт беткәч,
Ычкыналар Кучкарга. (859)

Кыенлыктан китү юллары көлкегә әйләнderelә:

Әйттер-типтер булмаса,
Закускага колбаса;
Илгә кайтып булмас инде,
Әткәй акча салмаса. (843)

Нәтиҗәләре күптән хәл ителеп куелган:

Безнең башлар китми катор,
Китсә дә әйләнеп кайтыр. (1040)

Мисаллардан күренгәнчә, шаян җырлар кайгы җырларына капма-каршы мәгънә белән төзелгәннәр. Алар канәгатьсезлек тойгысын, ягъни кайгыны я дөньяга кул селтәү я лирик геройның бәясен күтәрү белән юкка чыгаралар. Шуның өчен бу типтагы җырларны кайгы җырларына җавап рәвешендә, аны кире кагу һәм уңайга үзгәртү яки башка тойгыга алмаштыру өчен иҗат ителгәннәр дип әйтергә хакыбыз бар. Шулай итеп, дүрт төркем вәкиле монда да аерылмас берәмлек төзи, ягъни кайгы җырларының киресен кабатлап килә һәм шул ук тәртипкә буйсына. Бер үк объектны чагылдырып, бер үк тәртиптә төзелгән кайгы һәм уңай хис җырлары үзара тыгыз бәйләнештә торалар, берсе икенчесенең дәвамы, аңарга җавап рәвешендә киләләр. Алар жанрның ике өлешен тәшкил итә, шуңа күрә гомумиләштерүнең тагын да югарырак баскычында бер бөтен итеп каралырга тиеш. Җырларның бу ике классы кешенең рухи диалектикасын колачлый, алар фәкать икесе бергә генә кеше күңеленең катлаулы байлыгын, хәрәкәтен нечкәләп һәм тулы итеп чагылдыра алалар.

Уңай эмоцияле җырлар сан ягыннан күп түгел, дөресрәге, фольклористлар тарафыннан аз теркәлгәннәр. Бу күренешне кеше психикасының үзенчәлеге белән аңлатырга мөмкин. Психология фәне кире эмоцияләрнең кешедә тотрыклы булуын раслый, уңай хискә кеше тиз иялә, шул сәбәпле хиснең уңайлыгы күпкә бармый. Тиз сүнүчән уңай тойгыга бәя бирүче җырлар вакытында туып та, хаҗәте калмаганга, тиз онытыла дип фараз итәргә нигез бар. Димәк, алар да күп туганнар, хәзер дә күп иҗат ителәләр, ләкин хәтердә озак сакланмыйлар. Уңай җырларны да күп дип исәпләсәк, андагы дүртьюллыклар да кире эмоциянең бик күп төрле төсмерен чагылдырган комбинацияләргә җавап бирерлек байлыкка ия дип әйтә алабыз. Шулай итеп, жанрны система итеп алсак, кире һәм уңай эмоцияләрне чагылдырган җырлар аның ике ассистемасын, диалектик бәйләнештә һәм каршылыкта торган ике компонентын тәшкил итәләр. Алар, тулаем, бербөтен итеп алганда, кешенең үз-үзен җиңүен, үзенә охшамаган чынбарлык күренешләреннән өстен була алу тантанасын күрсәтәләр.

# ЯҢА СӘХИФӘЛӘР АЧЫЛА

XIII йөз шагыйре Кол Гали иҗаты язма әдәбиятыбызның «елга башы» булып исәпләнсә дә, әлегә кадәр җитәрлек дәрәҗәдә өйрәнелмәгән иде. Шуңа күрә Н. Хисамовның «Фән» нәшриятында «Кол Галинең «Кыйсса-и Йосыф поэмасы» исемле китабы[1] басылып чыгуы һичшиксез сөенечле хәбәр булды.

Шулай да, китапны күрү белән, күңелдә берничә сорау да туды: күптән көтелгән кирәкле хезмәт үзен аклап җиткерәме? Әсәрнең телен, чорын, табигатен аңлау өчен зарур тарихи фон тиешенчә ачылып беттеме икән?..

Яшермим, мондый объектив, ягъни һәр яңа хезмәткә карата куелуы мөмкин сораулардан тыш, «субъектив» сәбәпләр дә юк түгел иде. Н. Хисамовның исеме матбугатта шактый еш күренгәләп килә. Ләкин каләме, әйтер сүзе-фикере булган автор кайчакта зур мәсьәләләрнең чит-кырыйларыннан гына «чеметкәләп» уза шикелле иде.

Яңа китап, өстәмә исеменнән үк аңлашылганча, XIII йөз әдәби истәлеген тарихи-чагыштырма, димәк, текстологик һәм теоретик планда өйрәнүгә багышланган. Бу исә төрле нөсхәләрне, димәк, төрле теллардәге версияләрне белүдән тыш, автордан теоретик нигез дә, әдәби зәвык та таләп итә. Өйрәнелә торган иҗатны гомум әдәби фонда, ягъни башка күпләгән факт һәм күренешләр белән эзлекле мөнәсәбәттә карау сорала.

Әгәр монографиянең Кол Гали иҗатына багышланган беренче махсус китап икәнлеген дә искә алсак, әлеге таләпләрне үтәү аеруча мөһим.

Кыскача керештә һәм беренче бүлек башында Н. Хисамов «Кыйсса-и Йосыф» поэмасының өйрәнелү тарихын яктырта, әсәрнең туган җирлеге, эстетик кыйммәте турында үзеннән элгәрге галимнәрнең фикерләрен китерә.

Шагыйрьнең ватаны, шәхесе хакында берниндн мәгълүмат сакланмаган. Шуңа күрә әйтелгән фикер-фаразлар төрлечә һәм каршылыклы. Әгәр Г. Утыз Имәни, Ш. Мәрҗани һәм башка соңгы дәвер татар галимнәре, шул җөмләдән мәрхүм Җәвад Алмазов, истәлекнең бары бездә генә мәгълүм һәм киң таралган булуына, шулай ук гомуми стилистик рухына игътибар итеп, аның болгар-татар җирлеге җимеше икәнлегенә ихлас ышансалар, икенче төркем галимнәр поэманы Төркиядә, яки Урта Азиядә язылган дип исәпләгәннәр (К. Брокельман, М. Ф. Күпрүлүзадә һ. б.). Хәер, бүген дә әле «Кыйсса-и Йосыф» поэмасын, тел үзенчәлекләреннән чыгып, Идел буеннан читкәрәк тибәрергә омтылучылар юк түгел. Гомумән, поэма хакында моңарчы әйтелгән фикерләрнең төбенәрәк төшәргә теләсәк, без иң элек бәхәснең әлеге дә баягы «кайсы җирлек әсәре?» дигән сорау тирәсендә куерганлыгын күрер идек. Ләкин Н. Хисамов «Кыйсса-и Йосыф»— төрки халыкларның шактые өчен уртак ядкяр дигән фикергә кушылып, әлеге бәхәсне бер читкә калдыра да, әсәрнең төп тукымасына — эчтәлек һәм сюжет, идея һәм фәлсәфә, образлы сөйләм үзенчәлекләренә күчә, шуларны тарихи-чагыштырмача планда өйрәнә. Фикеребезчә, китап авторы иң дөрес юлларның берсен сайлаган.

«Йосыф образы һәм әсәрнең идея проблематикасы» дигән беренче бүлектә, югарыда күрсәтелгән бәхәстән тыш, сюжетның чыганагы, геройны сурәтләүдә традиционлык һәм автор яңалыгы, ата һәм угыл, ана кабере мотивлары, түбәннән күтәрелү һәм гаделлек проблемасы кебек, бер карашка аерым-аерым, мәгәр поэманың эчтәлеген, эстетик һәм иҗтимагый кыйммәтен билгеләүче төп мәсьәләләр яктыртыла.

Поэманың сюжеты, фәндә күптән исбат ителгәнчә, борынгы яһүдиләр традициясенә — Тәүратта тасвирланган Гүзәл Йосыф хакындагы гыйбрәтле маҗарага барып тоташа. Соңрак бу сюжет исламга кадәрге сүрияле авторлар тарафыннан эшкәртелә, аннары Коръәнгә дә үтеп керә. Мөселман көнчыгышында иҗат иткән соңгы дәвер әдипләре, мәсәлән, Тәбари, Фирдәүси һәм Әнсарилар сюжетны шул Коръән версиясеннән алып үстерәләр. Н. Хисамов этрафлы рәвештә исбатлаганча, Кол Гали, аларның барысын да белгән хәлдә, беренче чиратта Әнсариның фарсыча чәчмә версиясенә таянган һәм сюжетны тагын да үстереп, баетып җибәргән. Гомумән, бу мәгълүм сюжетның чордан-чорга, телдән-телгә күчкәндә ничек үзгәрүен, динилектән дөньявилыкка, схематизмнан сәнгатьчәлеккә таба авыша баруын китап авторы җентекләп, хәтта мавыгып күзәткән. Сюжетның

[1] Хисамов Н. Ш. Поэма «Кысса-и Юсуф» Кул' Али. Анализ источников сюжета и авторского творчества. М., «Наука», 1979.

эшкәртелү үзенчәлекләрен Хисамов «әлгәргеләр һәм Кол Гали» дигән планда гына түгел, бәлки «Кол Гали һәм аннан соңгылар» дигән юнәлештә дә, ягъни хәрәкәттә һәм үсештә тикшерә. Тарихи-чагыштырма алымнан киң файдалану борынгы төрки әдәбиятта сәнгатьчәлек формалашуына, гуманистик принциплар ныгуына Кол Гали керткән өлешне, ул алып килгән яңалыкны калку һәм тарихи яктан дөрес аңларга мөмкинлек тудырган.

Шундый эзлекле күзәтү процессында Н. Хисамов ирешкән казанышларның берсе сыйфатында түбәндәге нәтиҗәне күрсәтергә мөмкин: соңгы вакытка кадәр берәүләр Кол Гали версиясенең төп сюжет сызыгы дип, гадәттә, Йосыф белән Зөләйха арасындагы мәхәббәт маҗараларын күрсәтәләр, ә икенче төркем галимнәр игътибарны ата белән угыл мөнәсәбәтенә — аерылышу хәсрәте һәм бик озак вакыттан соң гына кавышу шатлыгына юнәлтәләр иде. Монография авторы исә, бу ике сюжетның да әһәмиятен кире какмаган хәлдә, нигезле дәлилләр ярдәмендә гуманист шагыйрь тарафыннан беренче планга «түбәннән күтәрелгән гадел ил биләүче» мәсьәләсе куелуын исбатлый.

Монгол яулап алуларына кадәрге төрки телле дөньяви әдәбиятның гомум торышына, проблематика һм үсеш тенденцияләренә игътибар итсәк, автор ирешкән әлеге нәтиҗәнең дәреслеге тагын бер кат раслана: «гадел дәүләт башлыгы һәм халык мәсьәләсе» бары Кол Гали поэмасында гына кинәт калкып чыккан өр-яңа проблема түгел. Борынгы төрки руник язулы ядкярләрдән Билгә каган, Күлтәгин һәм «хикмәт иясе» Тоньюкук кебек заманының күренекле дәүләт эшлеклеләре исеменнән яңгыратылган эпитафик манифестларда, төгәлрәк әйткәндә, әдәби-тарихи публицистикада, шулай ук иң тәүге төркичә поэма дип исәпләнгән «Котадгу билик»тә дә үзәк проблема итеп шул ук ил-дәүләт һәм падишаһ мәсьәләләре куелган иде. Күрәсең, VIII—XIII йөзләрдә төрки телле язма традициядә дәүләт белән идарә итү, гадел хаким һәм халык темаларының эзлекле рәвештә кабатлануы очраклы күренеш түгелдер. Минемчә, мондый хәл шул чорларда төрки дөньяда барган катлаулы социаль үсешнең, ягъни сыйнфый бүленеш көчәеп, иҗтимагый көрәш кискенләшүнең, шул рәвешчә «падишаһ һәм халык» проблемасы актуальләшүнең әдәбияттагы чагылышы булса кирәк. Фактларга менә шушы күзлектән караганда (киләчәктә автор мәсьәләнең бу ягына аерата игътибар итсен иде), «Кыйсса-и Йосыф» поэмасының иҗтимагый әһәмияте тагын да калкурак күренә. (Сүз уңаенда әйтеп узыйк: җәмгыятьтәге югары һәм түбән катламнарының — хасс-у-гамның — үзара мөнәсәбәте мәсьәләләрен яктыртуны соңрак дәвер татар әдәбиятында Мөхәммәдьяр дәвам иттерә. «Хасс-у-гам» проблемасының бездә иң элек Кол Галидә куелуын, аннары Котб аша узып, Казан ханлыгы чорында кабат күтәрелүен искә төшерсәк, борынгы әдәбиятыбызның иҗтимагый йөзе тагы да ачыграк күренә.)

«Гадел падишаһ» мәсьәләсенең яктыртылышында төрки әдәбиятка Кол Гали алып килгән яңалыкның берсе түбәндәгедән гыйбарәт. Борынгы төрки эпитафияләрдә, шулай ук «Котадгу билик» поэмасында нәселдән ил биләп килә торган, «тәхет өстендә» туган һәм гел шунда утырган «асыл зат» («илаһи зат» булуы да фараз кылына) падишаһларның гамәлләре һәм бурычлары хакында сүз статик рәвештә бара. Кол Гали исә үз героен (аны «пәйгамбәр нәселеннән» дип кабул иткәне хәлдә) бер югары күтәреп, бер түбән төшереп, ут һәм су кичтереп, булачак ил башлыгының характерын хәрәкәттә сыный, аны үсештә, эволюциядә тасвирлый. Гәрчә бу сюжетның төп сызыгы традициядән килсә дә, Кол Гали аны яңа детальләр һәм идеяләр белән баета: ил-дәүләт белән идарә итәчәк зат, хәзергечә әйтсәк, гади халык тормышын яхшы белеп, гаделлек идеалына тугрылыклы булып калырга тиеш икән. Миһербанлы ата кочагыннан йолып алынып коллыкка сатылган, аннары сарай хадиме дәрәҗәсенә күтәрелгән, шунда ук зинданга төшкән, ниһаять, тагы югары калкып, падиша булган Йосыфның һәрвакытта да «сиддыйк»лык — тугрылык сыйфатын саклавы Кол Гали идеалының чагылышы ул.

Әлбәттә, монография авторы әсәрдәге иҗтимагый мотивка басым ясавы белән урта гасыр әһеле кулына (Кол Галигә дә, Йосыфка да) XX йөз көрәш факелы тоттырырга җыенмый, яисә борынгы чор вәкилләреннән яңа дәвергә генә хас фикер һәм әхлак нормалары таләп итми. Поэма авторының дөньяга карашын, әсәрдә гәүдәләнгән идеалын, шулай ук әсәр геройларының омтылыш һәм характерларын Х. Хисамов мәгълүм тарихи чор фонында, реаль мөмкинлек кысаларында карарга омтыла. Шуңа күрә әсәр идеясендәге шартлылык, каршылык һәм чикләнгәнлекләр эзлекле рәвештә ачыла бара.

Истәлекнең социаль-иҗтимагый идеясен беренче планга чыгару белән бергә монография авторы башка сюжет сызыкларының әһәмиятен киметми, аларның үз урыннарын, эстетик кыйммәтләрен табарга тырыша. «Атаның балага мәхәббәте» яисә «угылның атага тугрылыгы» дигән гуманистик идеяләрнең гәүдәләнешенә карата Н. Хисамов бик игътибарлы. Шул мәсьәләләргә багышланган сәхифәләрне укыган чакта татарларның «Кыйсса-и Йосыф» әсәрен — халыкның үзенчә әйтсәк, «Йосыф китабын» — ни өчен бик үз итүе, гасырлар дәвамында күңел түрендә саклавы төгәлрәк аңлашыла. Татар әдәбияты өчен «гадел падишаһ» темасы әкренләп икенче планга күчә; мәхәббәт мәсьәләсе исә, интимрак өлкә булганга, ачык дискуссиягә куелмый. Туган җирләреннән кысрыклана барган, бәхет эзләп зимагурлыкта каңгырган, патша хезмәтенә газиз уллары егермешәр елга солдатка алынган, аз гына каршылык өчен Себерләргә сөрелгән, кыскасы, һәр гаиләдә диярлек аерылышу ачысын татып яшәгән халык өчен Ягкуб — Йосыф трагедия-

се аңлаешлырак, якынрак, актуальрәк булып яңгыраган. Димәк, «Кыйсса-и Йосыф» китабының бездәге популярлыгын, гомум сәнгатьчә сыйфатыннан, күңелгә эстетик якынлыгыннан тыш, аның икенче хасияте: халыкның тарихи конкрет рухи халәтенә аваздашлыгы — олы моңы тәэмин иткән икән.

Дөрес, поэмадагы мәхәббәт сызыгы да зур эстетик-фәлсәфи әһәмияткә ия. Китап авторы махсус билгеләп үткәнчә, Кол Гали бу традицион сюжетны үзеннән элгәрге, хәтта соңгы шагыйрьләрдән үзгә буларак, шактый оригиналь һәм мөстәкыйль рәвештә хәл кылган икән: аның Зөләйхасы кайбер башка версияләрдәге кебек җансыз курчак, яки ирләрне юлдан яздыручы «чибәр» пәри генә түгел, бәлки олы хис утында яна белүче, шул олы хисенә ахыргача тугры булып кала алган көчле ихтыярлы җир кызы. Н. Хисамов фикеренчә, Йосыф—Зөләйха сюжетында Кол Гали «тигез мәхәббәт» идеясен алга сөреп (әлбәттә, мәсьәләне традиция һәм чор биргән мөмкинлекләр югарылыгыннан хәл кылып), үзенең гуманист фикер иясе икәнлеген раслаган.

Йосыф образында, монографиядә дәлилләнгәнчә, кеше аңына, ачык фикергә, тугрылыкка гаделлеккә дан җырлана. Зөләйха образында исә гадәти җир кешесенең көчле, мәгәр дөньяви хисе гәүдәләнә, мәхәббәттәге ныклыгы олылана. Кол Гали симпатиясе, һичшиксез, беренче тип герой тарафында, ләкин ул, кайбер урта гасыр әдипләре кебек, икенче башлангычны кире какмый, бәлки аның да яшәү хокукына ия булуын раслый. Шагыйрьнең Зөләйханы кимсетмәве, әсәр ахырында аны Йосыф белән кавыштыруы, ягъни җир мәхәббәтен суфыйларча инкяр итмәве шушы нәтиҗәне куәтли: Кол Гали — аң белән хис гармониясе тарафдары. Монографиянең икенче бүлеге менә шундый кызыклы һәм мөһим нәтиҗәләр белән тәмамлана.

Өченче бүлектә поэманың индивидуаль һәм стилистик үзенчәлекләре тикшерелә. Монда да автор истәлекне башка версияләр белән чагыштырып карый. Йосыф—Зөләйха сюжетына корылган күп телләрдәге әсәрләрне күзәтүдән тыш, Н. Хисамов татар халык иҗаты материалларын да өйрәнә, төрле чор язма әдәбиятыбыз фондына да актив рәвештә үтеп керә ул. Кол Гали табышларының Котб, Мөхәммәдъярдан алып Муса Җәлил иҗатына кадәр ачылып килүе «Кыйсса-и Йосыф» поэмасының татар әдәбияты үсешендәге урынын һәм әһәмиятен тарихи яктан дөрес итеп күрсәтергә булышкан. Җыеп әйткәндә, истәлекнең индивидуаль һәм стилистик үзенчәлекләрен җентекләп күзәтү нәтиҗәсендә Кол Гали поэмасының болгар-татар җирлеге җимеше икәнлеге, бары шул җирлектәге төрки әдәбиятка аерылгысыз рәвештә үрелүе тулысынча диярлек расланган. Шул ук вакытта Н. Хисамов Кол Гали поэмасының борынгы гомумтөрки әдәбият хәзинәсендә караларга тиешлеген, димәк, башка туган-даш халыклар әдәбиятлары тарихында да өйрәнелү мөмкинлеген инкяр итми. Истәлек иҗат ителгән мохитны ачыкларга омтылу исә Н. Хисамовка поэманың әдәби сыйфатын, тарихи кыйммәтен һәм аның әдәби процессыбыздагы урынын дөрес аңлау, гадел аңлату өчен кирәк булган.

Дөрес, китапта Кол Галинең «биографиясен» ачыкларга омтылу белән артык мавыгып киткәләгән моментлар да бар. Мәсәлән, Н. Хисамов XIX йөз язучысы Таҗетдин Ялчыгол угылының шәҗәрәсенә мөрәҗәгать итеп, анда очрый торган «Кол Гали» дигән исемне «Кыйсса-и Йосыф» авторына нисбәт итәргә тырыша. Беренче карашка изге нияттән туган бу омтылыш үзен акламый. Иң әүвәл, хәзерге шәҗәрәдәге исем белән поэма авторының тәңгәллеген раслый торган бернинди документ юк. Икенчедән, Т. Ялчыгол шәҗәрәсенең борынгы өлешендәге бер исемне тарихи дөрес дип кабул итәбез икән, ул чакта анда очрый торган башка исемнәргә карата да шундый ук мөнәсәбәт таләп ителә. Димәк, Т. Ялчыголның тагын да элгәрерәк бабасы сыйфатында шәҗәрә авторы үзе тәртеп күрсәткән юнан-грек фәйләсуфы Сократ хәкимне дә танырга тиеш булабыз?! Өченчедән, Кол Гали дигән исем әлеге шәҗәрәгә XVII йөздә үк теркәлеп калган «Дәфтәри Чыңгыз-намә» истәлегеннән килеп кергән. Ләкин анда сүз Ялчыголның бабасы хакында түгел, бәлки Биләр шәһәрендә XIV йөздә яшәгән мәшһүр бәкләрнең берсе турында бара. Димәк, монография авторына Кол Галине Болгар җиренә «ныграк бәйләргә» теләгәндә дә, куян шулпасының юынтыгына барып кергәнче, менә шушы беренчелрәк чыганакка таянырга мөмкин иде. Дүртенчедән, иң мөһиме, Кол Галинең Т. Ялчыголга «баба» икәнлеген әлеге сүзне куштырнакларга алуы белән (20 нче биттә) Н. Хисамов үзенең шәҗәрәгә ышанып җитмәвен күрсәтә. Шулай булгач, ни өчен аны кабатлап, мичкә балга бер кашык дегет кушкандай, зур хезмәтнең сыйфатына зарар китерергә?! Ә бит «кечкенә» мәсьәләләрдә эзлеклелек югалуның зур проблемаларга буталчыклык кертүе бик табигый. XIII йөз башыннан алып, XVI гасырның урталарына кадәр Идел буе төрки халыкларыннан болгар-татарларның «тар» этник составы (ягъни төркилек әчендәге сан һәм сыйфаты) өзлексез үзгәреп тора. Хәрби-политик чайкалулар дәвамында ыру һәм кабиләләрнең кушылулары һәм аерылулары күп булган. Шуңа күрә вакыт-вакыт болгар кешеләренең ерак Харәзем һәм Мосул, Бәлх һәм Бәгъдад якларына барып чыгып, икенче этник дөнья мәдәнияты җирлегендә әдип һәм галим булып формалашулары, димәк, башка этник культурада үсешенә катнашулары табигый, хәтта киң таралган. Шулай ук «читтән» килгән төрки дулкын вәкилләренең дә Болгар рухи культурасына өлеш кертүләре бик мөмкин. Икенчерәк итеп әйткәндә, тегеләр яки бу борынгы язучының мирасы нинди милли әдәбиятка каравын аның биографиясендәге кайбер факт кисәкләренә таянып түгел (әйтик, бер бабасы негр булган А. С. Пушкиннан эфиоп шагыйре ясауның мәгънәсезлеге кебек), ә шул иҗатның нинди җирлектә

бөреләнеп, чәчәк атып, нинди халык әдәбиятының тукымасына үрелгәнлеген, димәк, кайда дәвамлы яшәгәнлеген аныклап кына билгеләргә мөмкин. Мәсьәләгә шушы яссылыктан карaганда, Н. Хисамов үзе әтрафлап исбат иткәнчә, Кол Гали иҗаты бары борынгы татар әдәбияты процессында гына үзенең урынын тапкан. Истәлекнең XIX йөзгә кадәр кайбер төрки төбәкләрдә (урта Азиядә) бөтенләй мәгълүм булмавы, икенче регионнарда исә (Төркиядә — угыз телле илдә!) тәрҗемәсез аңлашылмавы һәм тагын башка бик күп фактлар әлеге нәтиҗәне куәтли.

Ниһаять, «Кыйсса-и Йосыф» китабының тел үзенчәлегенә килгәндә дә, хәзерге төрки телләрнең формаль күрсәткечләренә генә таянып, шуларны турыдан-туры борынгылыкка күчереп фикер йөртергә ярамый, борынгы төрки әдәби телләр стихиясен дә исәпкә алырга кирәк. Монгол яулап алуларына кадәрге Идел буенда кайсы төрки шивәгә нигезләнгән язма тел өстенлек итүен әле беркемнең дә төгәл ачыклаганы юк. Монгол яулап алуларына кадәр үк Идел буе кыпчак һәм болгар кабиләләре дөньясында бер ара угыз телле язма традиция көчәйгән, шуңа күрә формаль галәмәтләре белән угызчылыкка, ләкин эчке рухы һәм аңлаешлылыгы җәһәтеннән кыпчаклык стихиясенә якын «Кыйсса-и Йосыф»лар иҗат ителгән булса, бер дә гаҗәп түгел! Без шушы фаразны алга сөрү ягында. Чөнки татар археографиясе материаллары арасында «Кыйсса-и Йосыф» поэмасының «ялгыз имән» булмавын күрсәтә торган башка «угыз телле» истәлекләр дә шактый.

Менә шуларның һәммәсен дә исәпкә алган чакта, югарыда инде әйтелгәнчә, Н. Хисамов хәзерге тел-грамматик бәхәсләргә артык кереп тормыйча, дөрес эшләгән. Чөнки Кол Гали мирасының урынын бары элекке дәвер әдәби фон һәм аннан соңгы әдәби процесс материалын синтезлау ысулы белән генә билгеләп була. Ә бу юнәлештә эшлисе эшләр бик күп әле.

Җыеп әйткәндә, яңа чыккан китап үзенең төплелеге, фәнни колачы белән аерылып тора. Авторның мөһим мәсьәләләрне хәл кылганда үзенең дә зур җаваплылык тоюы аерата тәкъдиргә лаек.

Хезмәттә конкрет текстологик, ягъни Кол Гали поэмасының тәнкыйди текстын төзү бурычы куелмаса да, Н. Хисамов төрле нөсхәләрне (басмадан тыш 20 дән артык кульъязманы) үзара чагыштырып, шулай ук шигырь закончалыкларына таянып, элекке басмалардагы хаталарны төзәтә бара. Безнең алда зур эрудицияле гыйльми тикшеренү генә түгел, бәлки нечкә зәвык белән өртелгән әдәби күзәтү дә!

Китапның яхшы полиграфик базада басылуын да махсус күрсәтергә кирәк. Истәлектән китерелгән өзекләрнең борынгы графикада бирелүе хезмәтнең документаль, димәк, ышандыру нигезен бермә-бер көчәйткән. Кыскасы, әдәбиятыбыз тарихы өчен дә, шулай ук үз йөзен, киләчәк юнәлешен тапкан автор өчен дә куану хисе белән хезмәтнең соңгы битләренә җитәсең.

Әмма зур сөенечләр белән рәттән кайбер көенечләр дә бар. Китап бик аз тираж белән басылган. Ә ул — Кол Гали иҗатын өйрәнү дә, күп гасырлы бай, мәгәр әле барланып җитмәгән, шуңа күрә тиешле бәясен алмаган әдәбиятыбызның тирән тамырларын аңлау өчен дә бик кирәкле хезмәт. Бәлки монографиянең төзәтелгән, тулыландырылган һәм, ниһаять, укучыларның киң катлавына адресланган яңа редакциясен басмага әзерләргә кирәктер?

Әлбәттә, хезмәтнең яңа редакциясен эшләү белән бергә, Кол Гали мирасын тагын да әтрафлырак итеп өйрәнүне дәвам иттерү көн тәртибендә кала. Чөнки «Кыйсса-и Йосыф» поэмасын чын-чынлап өйрәнү эше, Н. Хисамов үзе үк икърар иткәнчә, башлана гына. Җиде-сигез гасыр дәвамында халкыбыз күңелендә урын биләгән, шул моңлы күңелне җылытып, нурландырып килгән бөек Кол Гали мирасының ачылачак серләре, ялтыраячак «кырлары» күп әле!

**МИРКАСЫЙМ ГОСМАНОВ,**
**тарих фәннәре кандидаты.**

# ЧИШМӘЛӘР КАЯ АГАРЛАР?..

Күптән түгел Лениногорск районындагы «Чишмә» әдәби берләшмәсе үзенең 20 еллык юбилеен билгеләп үтте. Шушы кечкенә чишмәдән татар әдәбияты дигән олы диңгезгә шигырьләр, хикәяләр һәм роман килеп кушылган. «Каты токым» романының авторы Шамил Бикчурин әдәби иҗатка сусаган яшь талантларны туплаган, оештырган, иҗатларына ачылырга мөмкинлек биргән. Ул, әлбәттә, үз иҗаты планнарын да берләшмә члennары белән уртаклашкан, әсәрләреннән өзекләр укыган, тәнкыйть фикерләрен файдаланган. Хәзер «Каты токым» романы Мәскәүдә һәм демократик илләрдә басылып чыкты...

Без әдәбиятыбызның үсешенә билгеле бер тәэсир ясаган кечкенә чишмәләргә һәрвакыт шундый ихтирам белән карыйбыз. Талант беркайчан да буш урында гына тумый — аның әдәбиятка килүе өчен ниндидер бер өйрәнү мәктәбе, әдәби мохит кирәк. Шул хакта фикерләрен ишетергә теләп, мин хөрмәтле язучыларыбызның кайберләренә мөрәҗәгать иттем.

**Нәкый Исәнбәт:** 1916 елда Казанда «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә әдәби түгәрәк төзедек. «Бал корты» дигән кульязма журнал чыгардык. Сатирик-сәяси юнәлештә булганлыктан, шикләнеп, чыгарудан туктаттылар.

Фатхи Бурнаш та әдәби түгәрәк оештырды.

1922 елны Мәскәүдә Шәрык Коммунистик университетында укыган чорда Мәхмүд Максуд белән бергә «Чаткы» дигән журнал чыгардык. Шул журнал тирәсенә яшь язучылар тупланды. Такташ та килде. Шушы түгәрәкнең тәэсире күп кенә яшьләрне әдәбиятка тартты.

**Хәсән Туфан:** 1917—18 елларда Уфада «Галия» мәдрәсәсендә әдәбият укытучыбыз Галимҗан абый Ибраһимов безне бер тирәгә туплады. Монда Ш. Бабич, С. Кудаш, Г. Нигъмәти, Ченәкәйләр бар иде. «Парлак» дигән кульязма журнал чыгардык.

**Риза Ишморат:** 1917—18 елларда Уфада «Госмания» мәдрәсәсендә укыганда, укытучы Габдулла Сәйфи әдәбият-сәнгать түгәрәге оештырды. Кульязма журнал чыгардык. «Бетсен сугыш» дигән беренче шигырем шунда дөнья күрде. Әдәбиятка, сәнгатькә килү юлында бу түгәрәкнең йогынтысы зур булды.

**Мирсәй Әмир:** Татарстан Язучылар союзы оешканга кадәр Казанда «Кызыл яшьләр» газетасы каршында яшь язучылар түгәрәге бик актив эшләде. Бюро составында Г. Кутуй, Г. Минский, И. Хәйруллин, Д. Фәтхиләр бар иде. Түгәрәккә Һади Такташ та килеп йөрде. Утырышларга, яшь язучыларның әсәрләрен тикшергәндә, бик күп халык җыйнала иде. Анда Ф. Кәрим, И. Гази, Г. Кашшаф, А. Алиш, Ә. Еники, Ф. Хөснилер бик теләп йөрделәр. Бу түгәрәк безгә — әдәбиятка килергә омтылучы яшьләргә — зур әдәби мәктәп булды.

**Фатих Хөсни:** 1924 елларны Казанда Вахитов исемендәге күргәзмә-тәҗрибә мәктәбендә Нигъмәт Булат әдәби түгәрәк оештырды. Үзебез иҗат иткән язмаларны түгәрәк газетасында язып чыгара идек. Беренче шигырьләрем түгәрәк һәм газета йогынтысында язылды.

**Атилла Расих:** 1931—34 елларда Вахитов заводында әдәби түгәрәк эшләде. Җитәкчесе Абдулла Алиш иде. Иҗат белән шөгыльләнүче эшче яшьләр янына Х. Туфан, И. Гази, М. Әмирләр дә килеп йөрделәр. Шул вакытта ук инде повесть язган идем. Тикшергән вакытта А. Алиш мине бик дәртләндереп җибәрде. Повесть басылып чыкмаса да, түгәрәк мине әдәбиятка китерүдә зур роль уйнады. Соңыннан, үзем язучы булгач, иҗат яшьләренең ярдәмгә мохтаҗлыгын аңлап, үзем дә аларга ярдәм итәргә тырыштым. Моторлар төзү заводында түгәрәк җитәкләдем. 50 нче елларда җитәкчелек Гали Хуҗи, Шәрәф Мөдәррисләргә күчте.

**Җәвад Тәрҗеманов:** Казанның 13 нче мәктәбендә Һади Такташ әдәби түгәрәк төзегән. Соңрак аның җитәкчесе Фатих Кәрим булды. Ул түгәрәккә йөрүчеләр арасында М. Әхмәтгалиев, Г. Хәсәнов, Л. Фәттахов, Х. Якупов, Г. Галиуллин, Ф. Сафин, Ә. Галиев, М. Зариповлар бар иде. «Әдәбиятчы» исемле газета һәм журнал чыгарып, аларны үзебез бизи идек. Шушы түгәрәктән кемнәр чыкты? Мин, үзегез дә беләсез, техник фәннәре кандидаты һәм язучы булып киттем. Талантлы яшь шагыйрь Мөхәммәт Әхмәтгалиев Ватан сугышында батырларча һәлак булды. Ул чакта шигырьләр язып йөргән Лотфулла Фәттахов, үзебез чыгарган газета-журналларны рәсем белән бизәгән Харис Якупов — танылган рәссамнар. Гарәфи Хәсәнов исеме билгеле — балалар язучысы. Бик матур шигырьләре белән журналыбызда катнашкан Ә. Галиев — кибернетика профессоры, түгәрәкнең актив члены Габделхак Галиуллин — Мәскәүнең Лумумба исемендәге Халыклар дуслыгы университеты профессоры, Мәхмүт Зарипов — физика фәннәре кандидаты. Түгәрәктә шигырьләре тикшерелгән Фәрит Сафин — медицина фәннәре кандидаты.

**Ләбибә Ихсанова:** Әдәбиятка килүдә Казан дәүләт университеты әдәби түгәрәгенең тәэсире зур булды. Мин укыган елларда җитәкчесе Латыйф Җәләй иде. Түгәрәк утырышларына Ә. Фәйзи, Ә. Ерикәй, Ш. Мөдәррис, С. Хәким, А. Шамовлар килеп йөрделәр. Матбугатка беренче шигыремне Л. Җәләй тәкъдим итте.

**Ибраһим Нуруллин:** Университет әдәби түгәрәге эшен без — фронттан кайткан яшьләр — башлап җибәрдек. Башта — мин, аннары М. Хәсәен җитәкләде. 1946 елны «Әдәби сүз» дигән газетаны чыгара башладык. Соңрак «Тавыш» исемле кульязма журнал да чыгардык. Бу түгәрәк татар әдәбиятына берничә буын язучылар тәрбияләп бирергә ярдәм итте. Без Казан педагогия институтының яшь язучылары белән иҗади дуслык урнаштырдык.

Үземне шул чорның әдәби хәрәкәтеннән үсеп чыккан, әдәби түгәрәкләрдә тәрбияләнгән әдип дип санап, минем әйтер сүзләр дә нәкъ шундыйрак: Ватан сугышы чорында Башкортстанның Тәтешле һәм Яңавыл районнарында Һади Такташ исемендәге әдәби берләшмә барлыкка килде. Аны оештыручы мәктәп пионервожатые, яшь шагыйрь Әнгам Атнабаев иде. Безнең беренче шигырьләребез — ул чакта Нил Юзиев та шигырьләр яза иде — ул чыгарган кульязма журналда дөнья күрде. Берләшмә үрнәгендә без үзебез дә Ямады урта мәктәбендә әдәби түгәрәк оештырып «Сигнал» дигән кульязма журнал чыгардык. Казанга укырга килгәч, тагын әдәби түгәрәкләр тәэсиренә эләктем. 1950 елларда без Казан педагогия институтындагы әдәби түгәрәкнең иң актив членнары идек. Бу түгәрәккә Х. Камалов, Г. Мөхәммәтшин, Р. Әхмәтҗанов, М. Шабаев, Л. Айтуганов, Д. Зөбәерова, З. Гыйрфанова, С. Сафуанов, С. Гыйзарисов һ. б. йөрделәр. Бездән алда әдәби альманахта Ә. Атнабаев, Г. Зәйнашевалар үзләренең шигырь, поэмаларын калдырып китканнәр. Без альманах чыгаруны дәвам иттек. Шул ук елларны «Яшь сталинчы» газетасы каршында Шәрәф Мөдәррис җитәкләгән әдәби берләшмәгә дә йөри идем. Минем күңелемдә Шәрәф Мөдәррис әдәбият сөюче яшьләрне туплаучы, игътибарлы һәм таләпчән оста, талантлы оештыручы булып та истә калган. Яшьләрчә җитез, оператив эш итә: ошаган әсәрне шунда ук газетада чыгара...

Тулы булмаган шушы кайбер тарихи мәгълүматларга карап, без шуны әйтә алабыз: иҗади түгәрәкләр, берләшмәләр әдәбиятыбызны яңа көчләр белән тулыландыруда бик зур эш башкарганнар, әдәбиятның олы шәхесләре яшь әдәби алмаш тәрбияләүдә иҗат түгәрәге формасын файдаланганнар.

Үзе дә күп кенә түгәрәкләрнең тәэсирен күңеленә сеңдергән Муса Җәлил Ватан сугышына кадәр Мәскәүдә «Кечкенә иптәшләр» һәм «Октябрь баласы» исемле балалар журналларының редакторы була. Шул ук вакытта ул татар клубы каршында әдәби түгәрәк оештыра. Җәлил түгәрәгенә йөргән мәктәп укучысы Габдрахман Әпсәламов соңыннан әдәбиятның олы юлына чыга. «Әдәбиятка килергә кем ярдәм итте?» дигән сорауга, олы әдип горурлану белән: «Муса Җәлил!» — дип җавап бирә торган иде. Әһәмиятле тагын бер факт. Муса Җәлил түгәрәгенә ул чакта әле беркемгә дә билгесез яшь шагыйрь Әхмәт Симаев та йөри. Муса аның талантын күрә, үсәргә ярдәм итә. Язмыш аларны кабат авыр сынау елларында, фашистларның үз оясында, очраштыра. Дошманга каршы көрәштә җәлилчеләр әдәбият-сәнгатьнең көчен оста файдаланалар: алар, талантларны җыеп, музыкаль капелла оештыра. Шагыйрьләрдән, музыкантлардан, артистлардан төзелгән бу әдәбият-сәнгать түгәрәге әсирләр арасында фашизмга каршы пропаганда алып баруда, патриотизм рухы тәрбияләүдә әйтеп бетергесез зур эш башкара. Биредә дә Җәлилгә һәм Алишка, мөгаен, элек әдәби түгәрәкләр оештыру тәҗрибәсе ярдәм иткәндер?! Җәлил үзенең элекке түгәрәк члены Әхмәт Симаевка юкка гына иң җаваплы эшләрне ышанып тапшырмаган, билгеле.

Истәлекләргә караганда, Ватан сугышына кадәр, әдәби түгәрәк җитәкчесе буларак, Муса Җәлил яшь язучыларга әдәби юнәлеш бирү белән бергә, аларны чын гражданин итеп тәрбияләүгә дә бик нык игътибар иткән. Менә шуңа күрә дә аның тәрбиясен алган яшьләр, Ватан солдаты һәм язучы буларак, ил-халык алдында сынатмадылар. Әдәбият түгәрәкләрендә коллективлык, дуслык, бердәмлек тәрбиясен алган йөзләгән яшь язучы Ватан сугышында катнашты. Бик күп яшь әдипләр туган ил азатлыгы өчен батырларча һәлак булдылар. Үз сүзләрен әйтергә өлгерми калган, киләчәктә әдәбиятыбызның алтын фондында урын алырлык әсәрләр язачак күпме талантларны югалттык без! Бу исә әдәбиятыбызның санында да, сыйфатында да чагылмыйча калмагандыр. Р. Саттар, М. Әхмәтгалиев, Д. Фәтхи, Х. Рахман, М. Гаяз, В. Мифтахов, Гиз-эль-Габид, Ә. Камал, И. Закиров, Ш. Гәрәй, И. Шәфиев һ. б. бик күп яшь язучыларны без бүген, аларның батырлыклары өчен горурлану, шул ук вакытта әрнү хисе белән дә искә алабыз. Әмма әдәбиятыбызның киләчәгенә төбәп аткан дошманнар явыз ниятләренә ирешә алмадылар, мең елга якын тарихы булган татар совет әдәбияты яшәүчәнлеген, тамырлары ныклыгын раслады. Яраланган, кисәләнгән тамырлардан яңадан-яңа үрентеләр үсеп чыкты, әдәбиятыбызда яңа буыннар калыкты. Бүген без, үзебездә булган мәгълүматларга таянып, яшьләрнең әдәбиятка килүе елдан-ел арта бара дип, зур сөенеч белән әйтә алабыз.

Сугыштан соңгы еллардагы әдәби хәрәкәткә яңа бер күренеш хас: яшь язучылар зур масштаблы төзелешләрдә тупландылар. 50—60 нчы елларда Татарстан нефте күп кенә яшь язучыларны Әлмәт, Лениногорск, Азнакай, Баулы якларына җыйнады. Анда барлыкка килгән әдәби берләшмәләр нигезендә Әлмәт язучылар оешмасы ачылды. Әдәбиятыбызга күп кенә талантлы язучыларны биргән нефть ягында әле дә Лениногорск, Азнакай берләшмәләре яшь язучыларны тәрбияләүдә зур эш башкаралар.

70 нче елларда исә яшь язучыларны Кама автогиганты — КамАЗ үзенә тартты. «Ләйсән» әдәби берләшмәсе членнары әдәбиятыбызны яңа тормыш материалы, яңа кеше образы белән баеттылар. КамАЗны үз куллары белән төзегән, төзелешне йөрәге белән тойган Чаллы яшьләренең иҗаты ил аренасына чыкты.

Заман сан ягыннан да, сыйфат ягыннан да үзгәргән яшь язучылар белән эшләүнең яңа формаларын таләп итте. Татарстан Язучылар союзы, әдәби берләшмәләргә якынрак килү теләге белән, Апас, Чаллы, Арча, Азнакай, Кукмара зоналарында республика конференцияләре уздырды. Мондый масштаблы чаралар урындагы берләшмәләрнең, түгәрәкләрнең эшен җанландырып җибәрде, яшь язучыларның әсәрләрен дөньяга чыгаруда ярдәм итте. Апас, Кукмара, Арча, Лениногорск, Мамадыш районнары һәм «Татарстан яшьләре» газетасы каршындагы берләшмәләр активлыкларын тагын да арттырдылар. Гадәттә бернича дистә яшь язучыны берләштергән түгәрәк бер яки бернича язучыны мәйданга чыгарырга ярдәм итә. Хәтта бер генә язучы чыкмаган түгәрәкләр дә файдалы эш башкара: алар шигъри җанлы, әдәбият сөюче башка профессия кешеләрен тәрбияли. Әйтик, Һади Такташ оештырган, Фатих Кәрим

дәвам иткән түгәрәктән өч язучы, ике рәссам, техника, математика, физика, медицина буенча танылган галимнәр үсеп чыга. Уфа мәктәбендә әдәбият укыткан язучы Нәкый Исәнбәт йогынтысында кечкенә Рәхим Саттар үзенең язмышын әдәбиятка тапшыра. Соңыннан Рәхим Саттар — Җәлилнең уң кулы булып, шигырь белән дә, корал белән дә фашистларга каршы көрәшүче солдат, шагыйрь. Әмма тормыш никадәр генә яңалыклар тудырса да, яшь автор белән индивидуаль эшләү әдәби алмаш үстерүнең иң акланган бер формасы булып кала.

Дөрес, әдәбиятны аерым, талантлы шәхесләр ясый. Әдәбиятка берләшмә аша килү — яшь язучы тәрбияләүнең бердәнбер юлы түгел. Әмма әдәбиятка юнәлеш бирүдә кайсы да булса укытучының, остазның хәлиткеч тәэсир итүен барча әдипләр дә әйтә. Шулай да яшь талант туу урыны буларак, әдәби түгәрәкләр дә үзләрен аклыйлар.

Күп еллык тәҗрибә яшь талантлар белән мәктәптә ук шөгыльләнә башлауның дөреслеген күрсәтә. Ватан сугышына кадәр сәләтле мәктәп укучылары белән эшләүнең үзәгендә Абдулла Алиш торган. Сизгер һәм кайгыртучан остаз буларак, ул күп кенә кечкенә талантларга әдәбиятка килергә булышкан, әдәбият түгәрәкләре белән бәйләнеш тоткан. Ул вакытта беренче шигырьләре белән әдәбиятка атлаган М. Хөсәен һәм С. Шакирда Алишның кайгыртучан һәм таләпчән хатлары һаман да саклана. Без Г. Ибраһимовлардан, Такташ, Кәрим, Алишлардан калган шушы әйбәт традицияне дәвам итәргә, мәктәп әдәби түгәрәкләренә игътибарлы булырга бурычлыбыз. Үзләре укыткан мәктәпләрдә иҗат түгәрәкләре оештырган Клара Булатова, Рушания Низамова, Әлфирә Фәтхетдинова кебек укытучыларның әйбәт эшләре барыбызны да сөендерә.

Хәзерге вакытта безнең республикабызда кырыктан артык әдәби берләшмә эшләп килә. Кайбер түгәрәкләргә шефлык итү өчен тәҗрибәле язучылар беркетелгән. Г. Ахунов, С. Хәким, Т. Миңнуллин, Ш. Галиев, А. Гыйләҗев, Ә. Баянов, Р. Гатауллин, Л. Ихсанова, Г. Шәрәфетдинов кебек язучыларыбыз, урындагы берләшмәләрдә еш кына булып, аларга ярдәм итәләр. Гаять зур җаваплылык, осталык таләп иткән бу эшкә әдәбиятыбызның киләчәге турында борчылып яшәүче әдипләребез үз теләкләре белән алыналар. Кызганычка каршы, күп кенә берләшмәләр тәҗрибәле каләм осталарының ярдәменә, таләпчән киңәшләренә мохтаҗлар әле.

Барлык әдипләребез дә киләчәк көн язучыларын тәрбияләүдә Тукайча йөрәк җылысын биреп эшләсәләр, әдәбиятыбызның киләчәктә яңа биеклекләргә күтәрелүендә шик юк. Ә яшь язучылар үз чиратларында, гел игътибар гына көтеп ятмыйча, партиябез һәм халкыбыз алдындагы олы җаваплылыкны тоеп, үзләренә таләпне бермә-бер арттырырга тиешләр. Партия Үзәк Комитетының яшь талантлар турында кайгыртып кабул ителгән карарларына без идея ягыннан да, художество ягыннан да югары сыйфатлы әсәрләр язып җавап бирергә тиешбез. Бөек юлбашчыбыз В. И. Ленинның «Татар әдәбиятында Тукайны дәвам итүчеләр бармы?» дигән соравына: «Бар! Ул — без, Владимир Ильич!» — дип җавап бирерлек булсын!

ИЛДАР ЮЗЕЕВ.

Габдулла Шәрәфи

# КҮРШЕ МАЛАЕ

ПОВЕСТЬ



Күршебездә чандыр гына бер малай бар. Айдар исемле ул. Җәнлекләрне бик ярата. Эттер, мәчедер ише җан иясен күрсә, тәкатьсез була. Тегеләре дә малайны никтер үз итәләр, нинди генә усал эт булмасын, янына Айдар килсә, койрыгын болгап, шунда ук сырпалана башлый. Әллә шуңа инде, ишегалды малайлары үзен доктор Айболит дип йөртәләр. Әлегә менә шул, калганын алдарак күрерсез.

## Куштан

Көннәрдән бер көнне иләмсез зур эт ияртеп кайтты Айдар. Дөресрәге, Айдар ияреп кайтты эткә. Ишек шакуга килеп ачсалар, яньчек танаулы, түм-түгәрәк чекри күзле койрыксыз эт атылып керде. Бульдог нәселеннән котсыз гына бер нәрсә шунда. Ә Айдар, кош тотканмыни, әтисе каршында бертуктаусыз тәтелдәп этне мактый.

— Менә, әти, боксер бу, боксер. Матур бит, әти, әйеме?

— Инде дә, улым, инде дә...

— Фәрит абыйларныкы ул. Куштан исемле. Баласы булгач, берсен миңа бирәм ди. Алырбызмы, әти, ә, алырбызмы?

— Белмим әле, улым, куштаннарны бер дә яратмыйм шул мин...

Ул арада токмач кискән җиреннән бүленеп, кулына уклау тоткан килеш, әниләре килеп чыкты.

— Алырмын менә мин сиңа, алырмын. Эте эт төсле булса икән ичмасам. Хәзер үк чыгарып җибәрегез шул кыяфәтсезне!

— Кыйфәтсез түгел, матур ул, әни, матур. Эң-эң дип елый да белә!..

— Шулайдыр, шулай булмыйча. Көлә дә белмиме тагын?! Кил менә, колбаса бир дә югалт күземнән, — дип, әниләре кабат кухняга кереп китте. Әнисе артыннан барган Айдарны узып, Куштан да кухняга атылды. Моны һич тә көтмәгән әниләре куркуыннан уклавын төшереп җибәрде. Эт тә, кинәт туктап, арткарак чигенеп куйды. Аннары, кухня уртасына ук узып, идәндә тәгәрәп яткан уклауны аркылыга тешләп күтәрде дә, күзләрен тутырып, хатынга карап тора башлады.

Хатын исә, нишләргә дә белмичә, баскан урынында катып калган иде. Ә Айдар, юньсез, шырык-шырык көлә:

— Ал, әни, ал, курыкма. Фәрит абый шулай өйрәтә аны. Таякны ыргыта да алып килергә куша. Өйрәнгән бит, әни, әйеме?! — ди.

— Өйрәнгән, өйрәнгән. Мәхәббәтсез. Исеме тагын... Бу хәтле тугры килер икән үзенә. Үтерәсез инде...

Айдарлар өенә башлап аяк басучы җанвар әлеге шул Куштан булды.

## Багира

Эттән соң күпмедер вакыт узгач, аклы-каралы песи баласы күтәреп кайтты Айдар. Кайсы тоттырган да кайсы шулай мактаган, теле телгә йокмый малайның. Моннан да матур, моннан да акыллы песи баласы дөньяда да юк, имеш. Үзе аклы бу, үзе каралы бу, кыскасы, песиләрнең иң дә, иң дә, иң дәсе икән бу.

— Бездә торсын, әти, ярыймы?! — ди.

Никтер әтисенә дә бик сөйкемле булып күренде шул чуар йомгак. Я, нишләтәсез мине? — дигәндәй, күзен тасрайткан, мескен. «Ярар, торсын» диюен сизми дә калды.

Шул чагында арага әниләре килеп кысылды:

— Әй, олы юләр, олы юләр. Ул ни күтәреп кайтмас. Барысына да ярар дип торсаң. Җитмәгән иде әле миңа үзегез генә. Торсын имеш. Синдә генә булган ди малайлар. Ни әйтсәләр, шуңа күнеп тик йөри.

— Я инде, әнисе...

— Әнисе, әнисе! Авызын ерган. Әнә үзе карар. Ишетәсеңме, Айдар, үзең ашат, үзең эчерт, артыннан җыештыр. Гадәтсезләнүен күрсәм, кулам да чыгарам песиең белән икегезне.

Бактың исә песи баласы сөт тә эчә белми икән әле. Үлә ич инде ул ашамагач. Кара кайгыга батты Айдар.

— Бар, кире илт әнисе янына, имезсен тагын бераз, — диләр малайга. Кая ул, шундый матур песине. «Башкалар алып китә ич!»

Карап торып үтерсеннәрмени җан иясен, нидер эшләргә кирәк иде. Борыны белән дә төртеп карыйлар савытына, кашык белән авызына да тамызалар сөтне, юк, булмый. Тора торгач, әтиләре әйтеп куйды.

— Берәр нәрсә чәйнәп, тастар итеп каптырсак? Үстек ич әле тастар суырып.

Айдары бернәрсә аңламады. Каян белсен ди тастарны алты яшьлек малай. Әниләре исә сәер генә итеп көлемсерәде дә китте тезеп:

— Әй, дивана, дивана, үз авызың дип белдеңмени син аны?! Хан заманындагы тастарларны искә төшермәсәң!..

Көлсәңи, әйдә көлсен. Аның каравы әнә, файдасы тиде ич. Тастар ук итмәсәләр дә, Айдар белән әтисе икәүләп, барыбер рәвешен китерделәр. Сөткә манчып, марля кисәген суырта башладылар песи баласына. Нишләсен ди, тугач яшәргә кирәк, тырышты, мескен, тәки тернәкләнде. Тора-бара имезлеккә күчте...

Песи баласы күзгә күренеп песи була барды, чаяланды. Идән буйлап чабуларын, чаба торгач, тиктомалга тәгәрәп китүләрен күрсәң... Үзе бер дөнья да үзе бер тамаша. Ә исеме әле һаман юк иде. Ниндидер бик матур, бик тә хәтәр бер исем кушасы иде дә... Күрше тирәдә Кечкенә бар, Шаян, Миауша, хәтта Җулик та бар, ә менә Айдар теләгәне һаман табылмый. Соң инде, Миаушалар ише генә мени аның песие!

Бер көнне әтисе эштән кайтса, каршысына Айдар атылып чыкты.

— Әти, таптым!

— Ни таптың, улым?
— Песигә исем таптым!
— Яле, әйтеп кара, нинди икән?
— Багира! Менә нинди!

Багира, Багира... Таныш исем дә кебек үзе. Тик хәтерли генә алмый этисе.

— Каян алдың соң? — ди, аптырагач.
— Бүген «Маугли» киносын карадык. Шунда Багира бар. Пантера ул!
— Шул мени? Кара син, ә...
— Матур исем бит, әти, әйеме?!
— Шәәп, улым, менә дигән исем тапкансың!

Шулай итеп, чуар йомгак гап-гади бер песи баласыннан әллә кайдагы джунглиләр пәһлеваны Багирага әверелде. Тик менә йорттагы әбиләр теленә генә йокмады бу исем. Багыйра, Багыйра дип быгырдатып карадылар да, тешләре үтмәгәч, үзләренчә йомшартып, «Бәһирә»гә әйләндерделәр дә куйдылар. Айдар: «Баһирә түгел, Багира ул», — дип үпкәләп, песиен яклап караса да, эш чыгара алмады. Багираны эзләп Айдар ишегалдына чыкса, «Улым, Бәһирән әнә тегендә китте», «Айдар, Бәһирән менә монда», — дип малайның күңелен табалар. Шулай булгач, тагын ни кирәк. Килеште Айдар. Ә песигә барыбер. Өйгә керсә, Багира, йортка чыкса, Бәһирә булып йөри бирде. Моңа карап йоны гына да селкенмәде ичмасам. Ашыйсын ашады, үсәсен үсте, мәчеләргә тиешле бер генә гадәтне дә калдырмыйча кабатлый башлады.

## Канатлы кунак

Күршеләрдән кемдер үләр-үлмәс берничә балыгы белән Айдарга кечкенә генә аквариум биреп керткән. Үзләренеке дә бар иде югыйсә. Анысы зур, шар кебек. Икесен дә тәрәзә төбенә куйдылар. Кайчагында Айдар Багираны да шулар янында калдыра. Песи күзен тасрайтып утыра-утыра да тәмам әсәрләнә, ялт-йолт килгән балыкларны тотарга чамалап, әле бер, әле икенче аквариумга ташлана. Түгәрәгенә туры килсә, аяклары шуып, тигезлекне саклый алмыйча, я бер якка тәгәрәп китә, яисә идәнгә үк мәтәлә. Ләкин бу хәл аның гайрәген һич тә чигерми. Бала шул әле, бичара, нарасый, күтәреп куйсалар, тагын шуны ук кабатлый...

Инде песи бар, аквариумы бер генә түгел, икәү, читлектә әнә кызылтүшләре чыркылдаша, шулар белән шул булыр дип уйлаганнар иде өйдәгеләр. Юк икән әле, агаем, сабыр ит.

Безнең йорт шәһәр читендәрәк. Ишегалдында элеккедән калган биек-биек агачлар үсеп утыра. Нараты да бар, юкәсе дә. Агач башына ел саен каргалар оялый. Карылдый башласалар, колаклар тона. Алай да зарланмыйбыз, инде күнектек. Әле киресенчә, тавышлары чыкмый торса, җанга нидер җитмәгәндәй борчылып, агач башларын күзләргә тотынабыз. Ничектер шулай бер агачтан карга баласы егылып төшкән иде. Хәер, «егылган» дип кистереп үк әйтүе бәлки дөрес тә булмас. Килешенә караганда, кайсыдыр бер явызның кулы уйнаганга охшый. Югыйсә, берьюлы аягы да, канаты да имгәнмәс иде. Ничек кенә булмасын, сыңар канатын җиргә бәргәләп, карга баласы әнә юан гына карт юкә төбендә ята. Тирәсендә дүрт-биш малай. Чүгәләшкәннәр дә хәйран калганнар. Нишләтергә дә белмиләр. Ул арада якында гына «карр», «карр» дигән тавыш ишетелде. Башларын күтәреп карасалар, әллә ни биек тә түгел, юан бер ботакка карга килеп кунган. Канатлары җыелыр-җыелмас, муенын түбәнгә, карга баласына таба сузган. Шул кычкыра икән. Күрәсең, әниседер. Малайларга бик тә ямансу бу-

лып китте. Әмма имгәнгән кошчыкка кагылырга куллары бармый иде. Шул чагында берсе, балконнарында нидер кыландырып маташкан Айдарны күреп:

— Әнә, доктор Айболит, дәшимме? — диде. Иптәшләре ни дип әйтергә дә өлгермәде, малай:

— Айдар! Айдар! Чык әле монда, чык! — дип кычкыра башлады.

— Нәрсәгә?!

— Чык инде. Менә карга баласы...

— Карга баласы?! Хәзер...

Озак та үтми, Айдар да инде малайлар янында иде. Доктор дип йөртәләр дә бит... Нишләтсен ул аны? Канатын күтәреп карамакчы иткән иде дә, карга баласы яман да ачы тавыш белән карылдап куйды. Айдар, сискәнеп, кулын кире тартып алды. Малайлар тагын аптырашта калдылар. Тора торгач, берсе әйтеп куйды:

— Калсын шунда. Үзе терелер әле. Әнә ич әнисе, бәлки алып менеп китәр.

— Китте ди бар, — диде икенчесе. — Жулик тырнагына эләксә!

Айдар, башын күтәреп, әле һаман да юка ботагында утырган каргага карап алды. Аннары, олысымакланып:

— Күтәрә алмый, зур инде баласы, — дип куйды.

Алай да малайларның карга баласын бу килеш калдырасылары килми иде. Шул чагында берсе, ниһаять, чарасын тапкандай, янында торган иптәшенә төртеп алды:

— Карале, Рашат, синең әниең врач ич!

— Булса соң, — диде Айдарны чакырып чыгарган малай.

— Әйдә, сезгә алып керәбез!

— Чыннан да, Рашат, әйдә шулай итик, — диештеләр калганнары да.

— Эштә ич ул.

— Кайткач карар.

— Бүген кайтмый шул. Дежурга кала.

Малайлар тагын тындылар. Карга баласы да, авызын ачкан килеш, хәлсезләнеп тын гына ята. Бары тик ачык авызыннан күренеп торган нәп-нәзек теле генә селкенгәләп куя.

Айдар карап-карап торды да:

— Әйдәгез, алайса, поликлиникага илтәбез, — дип күлмәген сала башлады.

Малайлар карга баласын ипләп кенә күлмәккә төрделәр дә поликлиникага алып киттеләр. Ә ана карга «карр» дип бер кычкырды да, юка ботагыннан күтәрелеп, янәшәдәге нарат башына кунды. Малайлар күздән югалгач та әле, агачтан агачка күчеп, байтак карылдады ана карга.

*

* *

— Исәнмесез!

— Исән әле без, — диде керү ундаеннан өстәл янында утырган бер апа. Аннары күзлеге өстеннән сөзеп кенә малайларга карап алды. — Я, ни йомыш?.. Көтүегез белән килгәнсез?!

— Менә карга, — диде Айдар, төенчеген күрсәтеп.

— Аягы сынган, — диде Рашаты.

— Канаты да каерылган, — дип өстәде өченче малай.

— Нигә монда китердегез аны? Белмисезмени, балалар поликлиникасы ич бу!

Беләләр, белмиләрме соң! Башка вакыт булса, әйләнеп узарлар иде. Уколлары бер дә онытылмаган. Әле үзләре килгәч тә...

Малайлар боегып калды. Китәргә дә, китмәскә дә белмичә, баскан

жирләрендә таптанып тик торалар. Тора торгач, күзлекле апа, чак кына көлемсерәгәндәй итеп:

— Рогаткадан аткансыздыр әле, — диде һәм шундук йөзе тагын кырысланды. Аның көлемсерәвен күреп, малайларның эчкә жылы йөгерә башлаган иде дә, болай булгач, тагын сүрелделәр. Алай да бөтенләй үк сүзсез калмадылар.

— Юк, без атмадык, — диде берсе юаш кына тавыш белән.

— Юкмы? Сез түгелме?

— Юк, юк, без түгел! — диештеләр һәммәсе берьюлы. Ә Айдары өстәп куйды:

— Карагыз инде, апа, бала карга ич ул...

— Бу да бала дисеңме? Кара син аны. — диде күзлекле апа, баягыча көлемсерәп. — Ярый, алайса, шушында гына торыгыз, хирург абыегызга әйтеп карыйм, — дип коридор буйлап каядыр китте.

Озак та утми, әйләнеп тә килде.

— Кайсыгызныкы соң бу карга? — диде килә килешенә. Малайлар аптырап калдылар. Берсе дә дәшмәгәч:

— Синекеме? — диде майкачан гына торган Айдарга карап.

— Минеке, минеке... Минеке булыр, — диде Айдар, ашыгып. Һәм карга баласын үзенә кысарак төште.

— Алайса, әйдә минем белән, — дип күзлекле апа Айдарны хирург бүлмәсенә алып китте. Башкалар ишек төбендә калдылар.

«Хирург абыегыз» дигәне олы кеше түгел икән. Мыегы гына инде. Анысы да әле чын мыек төсле түгел. Айдар әтисендә менә мыек дисәң дә мыек. Үзе калын, үзе киң. Ә моныкы әллә ничек шунда, борын астына күләгә генә төшкән кебек. Хәер, Айдарга барыбер түгел мени. Карганы гына бәйләсен.

Бәйләде, бик әйбәтләп бәйләде. Башы белән койрыгы да сыңар канаты гына калды тырпаеп. Киткәндә әйтеп җибәрде:

— Үз иркенә куй, борчыма, тарткалама, — диде.

*
* *

Айдар кайтканда өйдә берәү дә юк иде. Бүлмәләренә керде дә карга баласын бер почмакка куйды. Багира да шул тирәдә чуала. Әмма бу кунакның нәрсә икәнен белеп бетерми әле песи. Карга тыныч кына торгач, бөтенләй дә игътибар итмәс булды. Тик озакка түгел, карга баласы сыңар канатын кузгатып кую белән, песи сагая калды. Ул да түгел, янына ук барып утырды да, күзләрен уйнаткалап, күзәтә башлады. Шул чагында кыңгырау чылтырады. Айдар ишек ачарга чыгып китте. Әнисе кайткан икән.

— Кайттыңмы, әни!

— Кайттым, улым. Бик арыдым. Мә, кертеп куй, — дип авыр гына сумкасын Айдарга тоттырды.

Әнисе, эшләпәсен салып, чәч төзәтим дип көзге каршысына баскан гына иде, балалар бүлмәсеннән «карр» дигән тавыш ишетелде. Ана сискәнеп китте, кулындагы тарагын чак кына төшереп җибәрмәде. Аннары, тагын ишетелмәсме дип, сагаеп торды да ашыга-ашыга бүлмәгә атлады. Керсә, ни күрсен, түр почмакка сыенган карга баласының тетмәсен тетә иде Багира. Тегесе, бичара, кырын килеп төшкән дә тыпырчынудан башка берни дә эшли алмый. Ә Багира аның саен узына, аның саен гайрәтләнә иде. Я очынып өстенә ташлана, я койрыгыннан каптырмакчы була.

Ул арада Айдар да йөгереп керде...

— Монысы тагын нигә инде, улым?!

— Карга баласы ул, әни.

— Күрәм, ат түгел... Әй, мескенем, нишләттегез соң аны?

— Егылып төшкән ул, әни. Поликлиникада бәйләп бирделәр. Аягы сынган аның, канаты каерылган.

— Нигә дип син генә ташыйсың шуның ишеләрне, бала. Кара ул күлмәгеңне... Ник кидең ичмасам?! Пычратып бетергән бит карган. Үләм инде синең белән. Менә әтиегез кайтсын әле!

«Әтиегез» дигәч, Айдар, күзләре белән генә елмаеп, башын түбән иде. Моны күреп, энисе көлеп үк җибәрде.

— Әй, улым, улым, атагыз да шул... Сезнең төсле үк бер бала. Я, монысына нәрсә ашатабыз инде?

— Белмим...

— Белмисең шул менә. Бар, сорап кер энисеннән, — дип ана тагын бер көлеп алды.

Ул арада әтиләре кайтып керде.

— Менә, әтиҗе, кара, тәмам зоопарк итте малаең өйне. Үтерәсез инде!..

Үзе шулай дип сукранган була, ә үзе акка төрелгән карга баласының башыннан сыйпый. Шул арада, сиздермичә генә, Айдарга да күз сирпеп алгалый. Һай бу әниләрне!..

Әти кеше кап-кара мыегы астыннан ап-ак тешләрен ялтыратып елмайды да:

— Чү, энисе, чү, үлә күрмә. Нишләрбез синнән башка. Семья үрчи бит менә,— дип карга баласын үз кулына алды, караштыра башлады. Аннары:

— Кайсы фронтта булган бу батыр? — дип аквариум тирәсендә кайнашкан Айдарга таба борылды. Тегесе ишетмәмешкә сабышты.

— Айдар, ник дәшмисең?

— Көләсең лә син, әти...

— Нишләп көлим ди, юләр. Инвалидтан көләләрмени? Ярар алайса, мә, яхшылап кара, Багираң бумасын, — дип әтисе карга баласын Айдарга тоттырды.

Бер өйдә булгач, карап кына бетереп буламыни. Кем керми дә булмәгә, кем чыкмый. Әле ишеге ачык кала, әле үзләре кертеп җибәрәләр Багираны. Юри түгел, әлбәттә. Аяк астында чуалгач... Карга гына мыни истә? Ә Багирага шул гына кирәк тә. Иптәш ич, ниндидер туп янсә җансыз бер шакмак түгел инде ул карга баласы...

## Уеннан уймак

Байтак вакыт узды. Айдарның өйдәге дуслары арасында да төрле хәлләр булып алды. Багира кымтырыклый торгач, поликлиникага барып, карга баласын тагын бер кат бәйләтергә туры килде.

Ничек кенә булмасын, карга баласы аякка басты. Алып кайткан да, җансыз-өнсез дигәндәй, өтек кенә бер нәрсә иде. Ә хәзер шактый зурайды, ыспайланды, канатлары ялт-йолт килеп тора. Ул йөрүләрен күрсәң! Әйтерсең, бүлмә бары тик аныкы гына. Әле өсталгә очып менә, әле тәрәзә төбенә куна. Күрәсең, канат ныгытуыдыр. Багира да инде элеккечә эрсезләнми. Әллә шүрли шунда, әллә хәйләсе артты, уйлапнитеп тормыйча, минут саен ташланмый башлады карга баласына. Башта көтә, җаен эзли. Бер почмакка поса да тын гына утыра. Җае чыгу белән, идәнгә сеңеп, үрмәли-үрмәли килә дә капылт кына сикерә. Ләкин, күренеп тора, явыз ният белән түгел, уйнавы шулай. Моны кошчык та аңлый, ахрысы, канатларын җилпеп читкә тайпыла да, берни булмагандай, авызын ачып катып кала. Алай да уеннан уймак чыгып куйды берсендә.

Көннәр узу белән карга баласы идәннән бөтенләй диярлек бизде.

Аның урыны хәзер — я өстәл өсте, я тәрәзә төбе. Алай да булмаса, китап киштәсенә кунаклый. Кунаклый да, идәнгә таба муенын сузып, Багираны үчекләгәндәй, «карр» дип куя. Ә песи, мин дә синнән ким түгел дигәндәй, аның артыннан я урындыкка сикерә, я диванга үрмәли. Карга исә, үч иткән төсле, урынын алыштырып кына тора. Берсендә ул тәрәзә төбендәге зур аквариум кырыена килеп кунды. Карганың бу кыланышы Багираны тәмам тилертте. Әнә ул, идәнгә утырган да бөтен гәүдәсен бер төенгә җыйган. Әйтерсең лә кысылган пружина, карга янына сикерергә чамалый. Әмма биек шул, тәвәккәллек җитми. Ләкин бер кысылган пружина язылмыйча, атылмыйча каламы соң? Багира да атылды. Тик тәрәзә төбенә түгел, үзеннән читтәрәк торган каурый шарга ташланды. Ә шар, шома нәрсә, ычкынып китеп, тәрәзә ягындагы стенага таба тәгәрәде. Багира да шунда сикерде. Барып җиткәч, песи никтер шарга бүтән кагылмады, идәнгә кадәр асылынып төшкән пәрдә итәген тарткалап шаяра башлады. Ул да түгел, тырмаша-тырмаша, пәрдә буйлап тәрәзә төбенә менеп китте. «Менә икән ич юл!..»

Ниһаять, песи теләгенә иреште. Күрсәтсен әле шул мактанчыкка кем икәнен! Тик очмасын гына. Юк, карганың исе дә китми. Башын әле бер, әле икенче якка боргалап утыруын белә. Утыра карга, кымшанмый да. Ә Багира әкрен-әкрен һаман якынлаша. Әнә инде ул карга баласы кунаклаган аквариум белән янәшә генә торган кечкенә аквариум өстенә үрмәләде. Менде, бер почмагына иплəп кенә утырды. Хәзер каргага да ерак түгел, тәпине генә сузасы. Һәм менә песи, арт аякларына басып, үрелмәкче генә булган иде, әлегәчә гамьсез бер кыяфәттә утырган карга баласы томшыгы белән «дык» иттереп кундырды моның башына. Үзенә һаман юл куеп килгән кошчыктан Багира моны һич тә көтмәгән иде, ни мырылдауга, ни чыелдауга охшамаган кыргый бер тавыш чыгарып алды да сырты белән аквариумга чумды...

Кошны моннан соң да өйдә асрауның инде кирәге калмаган иде. Айдар аны балконга алып чыкты, култыксага бастырды. Тәрәзә пыяласын чукый-чукый, иреккә зарыгуын сиздерә башлаган карга баласы шундук очып китәр дип уйлаган иде. Ә ул, канатларын җәяр-җәймәс талпынгалап куя да, тирә-юнендәге иркенлектән, биеклектән куркып, тагын торып кала. Әйе, дөнья матур, иксез-чиксез булып күренсә дә, аңа чумып кына китүләре, ай-һай, җиңел түгел, ахрысы. Әнә карга да, анда-санда муенын артка боргалап, «нишлим икән?» дигәндәй, әле хәзер генә үзе чыккан бүлмә тәрәзәсе төбенә басып, ал тәпиләрен пыялага терәгән Багирага һәм ишек янагына сөялгән Айдарга карап куя. Тик һәркемнең үз дөньясы. Айдар, кошны кулына алып, күккә чөйде. Әллә куркудан, әллә инде хушлашуы булдымы, карга баласы «карр» дип куйды да, канатларын җәеп, кайчандыр үзе егылып төшкән карт юкәгә таба очып китте. Хуш инде, хуш, табигатьнең әрсез баласы! Явызларга юлыкмыйча, дусларыңны онытмыйча иркенлектә гизеп яши бир.

## Кайсы чукыды икән?

Карга барында Айдар балкон ишеген гел ябып тотты. Шуңа күрә әнисе: «Бүлмәгезгә керер хәл юк, тынчу, җиләт ичмасам», дип Айдарга һаман саен әйтә килде. Карганы очырткач, бүлмә чистарып, сафланып калган иде. Ләкин, кирәк бит шулай, көннәрдән бер көнне балкон идәненә җәелгән палас өстенә күгәрчен йомырка салып киткән. Нәкъ урта бер җиргә. Бичара кош,— мәхлук түгел диген син аны,— рәвешен китерим, оя төсле булсын диптер инде, тирәсенә нәзек кенә чыбык-чабык салып чыккан. Барлыгы ун-унбиш чыбык. Әнә шул «оя» уртасында ике йомырка ята. Моны башта әтиләре күреп алды һәм шунда ук Айдарны чакырып чыгарды.

— Менә, улым, карга җибәргәндер бу күгәрченне. Югыйсә, каян белсен икән ул синең доктор Айболит икәнеңне?

Айдарның мондый да бәләкәй йомырка күргәне юк иде әле. Кулына тотып карамакчы булган иде дә, әтисе рөхсәт итмәде, «хәзер инде монда чыгып йөрмә, куркытырсың», — дип балкон ишеген ябып куйды.

Ләкин икәү булып чыкты ул күгәрченнәр, аталы-аналы. Ояда да чиратлашып утыралар. Кайсы ата, кайсы ана күгәрчен икәнен генә аера алмый Айдар. Парлы икәннәрен дә әле соңрак кына белде. Әтисе балконга чыгарга кушмагач, тәрәзә аша гына күзәтеп йөргән иде. Кайчан карамасын, күгәрчен һаман утыра. Малай борчыла башлады. Ничек борчылмасын, ашыйсы киләдер ич аның?! Инде менә ничә көн, кая да булса киткәнен һич тә күргәне юк. Ниһаять, Айдар түзмәде, ярма сибим дип балконга чыкмакчы булды. Ишекне ачкан гына иде, күгәрчен, оясын ташлап, балкон култыксасы артына посты. Айдар оя тирәсенә ярма сипте дә ишекне кабат ябып куйды. Кош, шундук оясына кайтып, ярма чүпләргә кереште. Чүпли-чүпли дә, башын кырын салып, тәрәзә аша күзәтеп торган малайга карап ала, хәйлә кормаганмы, янәсе.

Тора-бара күгәрчен Айдарга тәмам ияләште. Ярма сипсә дә, болай гына чыкса да оясын калдырмый, кузгалмас булып китте. Тик менә бер көнне... Кызык булды Айдар бер көнне. Көндәгечә, ярма сибим дип кулын сузган гына иде, ояда утырган күгәрчен, куркә кебек кинәт күперенеп, яман да хәтәр пырхылдап малайга сикерде, кулын чукып алды. Күгәрчен дә шулай усал буладыр дип Айдар башына да китермәгән иде. Көтелмәгән бу хәлдән ул каушап калды. Ә күгәрчен үзе, берни булмагандай, кабат килеп оясына утырды. Тик муен, күкрәк тирәсендәге йоннары гына әле һаман да шул күпергән килеш иде. Айдар тиз генә бүлмәгә кереп балкон ишеген ябып куйды.

Озак та үтми, балкон култыксасына икенче күгәрчен килеп кунды. Ә теге усалы, шуны гына көткән төсле, ояны калдырып, читкәрәк китте. Аның урынына яңа кайтканы сикереп төште. Усал күгәрчен «сак бул!» дигәндәй, гөлдер-гөлдер килде дә очып китте. Аларның икәү икәнен малай әнә шунда гына белде.

Алай да кайсы чукыды соң әле аны? Анасымы, әллә атасымы? Мөгаен, атасыдыр. Ә нигә анасы түгел? Бәлки, балалары чыгар вакыт җитеп, усалланганлыр?

Әтисе эштән кайту белән, Айдар аңа һәммәсен дә сөйләп бирде.

— Шул кирәк сиңа, — диде әтисе. — Әйттем түгелме соң? Ник чыктың, ник борчыйсың?!

— Ачтан үлә дип курыктым.

— Үләрлек булгач, монда килеп йомырка саламы соң ул, тиле малай!

— Белмәдем бит мин.

— Белмәгәч, әйткәнне тыңлыйлар аны. Кошлар ул... Кеше кебек, барысын да аңлыйлар.

Айдар көлеп җибәрде.

— Ник көләсең?

— Аңлыйлар дисең ич. Үзең әле... аларда инс... инс... инстинтет, дигән идең.

— Ничек төшендерим соң. Әнә, әйтә дә белмисең бит әле. Инстинкт дидем ич мин сиңа. Менә тыңла алайса. Каяндыр укыдыммы, ишеттемме шунда, хәзер инде хәтерләмим...

Тыңламыйммы соң. Бик ярата Айдар сөйләгәнне. Кайчагында әтисе әйткәннәрне тыңлап кына бетерә алмый. Сабырлык, түземлек дигәннәре чамалы. Ә болай ул үзе ярыйсы гына малай. Шулай булмаса, әтисе әнә башыннан сыйпамас иде әле.

— Ярый, менә тыңла, — диде ул аннары. — Кайсыдыр шәһәрдә,

кайсыдыр йортның чормасына бер вакытны күгәрченнәр оялашкан. Шәһәр җирендә шуннан да аулак, ышыграк җирне тагын каян тапсыннар. Яши бирганнәр шунда, бала чыгарганнар. Ә чормага алар ватык тәрәзәдән кереп йөри торган булганнар. Ә бер көнне тәрәзәгә яңа пыяла куеп киткәннәр. Күгәрченнәргә юл бикләнгән. Нишләсеннәр инде бичаралар, балалары калган бит чормада. Бу ягыннан да очып карыйлар түбәнең, теге ягыннан да килеп карыйлар, ләкин бер турысыннан да керер урын тапмыйлар. Шуннан соң, өерелешеп, тагын тәрәзәгә ябырылалар, әле берсе, әле икенчесе килеп, пыяланы чукып карый, ватмакчы итәләр. Алай да эш чыгара алмагач, каршыдагы икенче йорт түбәсенә килеп куналар да, ни турындадыр үзара гөрелдәшергә тотыналар. Озак та үтми, барысы берьюлы күтәрелеп, тагын тәрәзәгә ыргылалар. Шул чагында берсе, алгарак чыгып, чормага җитәм дигәндә генә, канатларын кинәт кушыра да тәрәзәгә таш кебек килеп бәрелә. Пыяла челпәрәмә килә. Ә күгәрчен...

Ата, сүзен түгәрәкләп бетермичә, туктап калды. Айдар да, күзен бер ноктага төбәгән килеш, тын гына утыра. Малай һаман көтте, әтисе менә тагын башлар, дәвам итәр дип уйлады. Ә ул балкон тәрәзәсе янына килеп басты да, анда утырган күгәрченнәргә карап, дәшми-тынмый тора бирде. Айдар түзмәде, әтисе янына килеп:

— Ә шуннан, әти, нишләгән ул күгәрчен, үлгәнмени?! — диде.

— Нишләсен, шул кадәр бәрелгәч... — Әтисе Айдарны иңбашыннан кысып алды һәм инде бөтенләй икенче, көр тавыш белән:

— Менә шулай ул күгәрченнәр. Ә син... Бер чукыганга исең киткән, — дип куйды.

— Авыртмады да әле. Курыктым гына әзрәк... Ә теге күгәрчен үлгәч ни булган?

— Ни булсын, күгәрченнәр тагын кереп йөри башлаганнар. Югыйсә ачтан үлгән булыр иде балалары. Шуңа күрә атылган да инде тәрәзәгә ата күгәрчен.

— Алайса мине чукыганы да ата күгәрчендер, әти, әйеме?

— Куркыныч килсә, берсе дә карап тормый. Ана кош бигрәк тә хәтәр була андый чакта.

Айдар уйга калды. Болай булгач, кайсы чукыды икән соң аны? Берсе дә карап тормый ди ич әтисе. Мөгаен, шулайдыр. Авылга кайткач, анда утырган ана каз да бер чукып алган иде ич үзен. Казга беркем бернәрсә әйтмәде. Айдарның үзен гаепләделәр, «тиктормас» дип ачуландылар. Ничек тик торасың ди, узган-барган саен ысылдап калгач. Томшыгыннан кысып алмакчы иде дә... Ярый әле, күзенә тимәде. Айдар, үз уйларыннан үзе үк көлеп, бу хәл әле хәзер генә булгандай, кайчандыр каз чукыган иягең капшап куйды.

Шулай да ничек белергә, кайсы ата, кайсы ана күгәрчен булды икән?

## Карак

Подрык чаклы гына әрлән, өйгә алып кайткач, тау кадәрле мәшәкать тудырды. Балкон ишеген ачарлар иде, күгәрчен утыра, Багирадан куркыныч. Ачмас идең, җәй көне ләбаса, ничек түзмәк кирәк. Мәче белән әрләнне дә бер бүлмәдә асрап булмый. Айдар, әйткәнемчә, Багираны ябып караган иде дә, кая ул, тавышына түзәр әмәл калмады, үзе кереп утырыр хәлгә җитте малай читлеккә. Әрләнне япса, Багира тынгы бирми, читлек яныннан китүе юк. Аптырагач, әрләнне залга — олы якка чыгардылар. Иркенләп йөрсен дип, Айдар аны еш кына бүлмәгә җибәрә. Рәхәтләнә әрлән. Кермәгән тишеге, тертелмәгән почмагы калмый. Яңаклар һәрвакыт кабарган. Лерт-лерт килеп, үзе һаман йө-

герер. Әйтерсең лә аның ашыгыч бер эше бар. Ләкин ничек кенә ашыкмасын, — бүлмәме ул, ачык ишек турысымы, — һич кенә дә ар-кылып чыкмас. Стена кырыйлатып, шыныктан гына йөри. Шуңа күрә җәнлек күзгә ныклап чалынмый да. Күз алдында булмагач, кайчагын-да аны онытып та җибәрәләр. Шундый бер араны, кайсысыдыр ишеген ачык калдырып, балалар бүлмәсеннән Багира да чыккан. Чыккан да... Хәер, ул турыда бераз соңрак. Башта мин сезгә икенче бер хәлне сөй-ләп үтим әле.

Ял көне иде бу. Айдар белән әтисе олы якта шашка уйнап утыра-лар. Әниләре кухня ягында чуала. Ял көне җитте исә нинди дә булса мич ашы пешерә ул. Инде тотындымы, һәркемгә эш таба. Бу юлы да кухня ягыннан тавышы ишетелде:

— Әй, егетләр, чыгыгыз әле монда!

Әтиләре бу яктан җавап бирде:

— Икебез дә чыга алмыйбыз, Айдар сартирга ябылды!..

Ләкин әниләренең шаярырга исәбе юк иде. «Егетләрне» шактый кырыс каршылады:

— Кая куйдыгыз дөге ярмасын?! Ник чәчтегез? Капның төбендә генә калган бит. Гөбәдия пешерәсем иде ләбаса...

Әтисе Айдарга, Айдар әтисенә карап, иңбашларын гына җыерды-лар. Белмиләр, янәсе, алар эше түгел. Әниләре тагын да кыза төште:

— Бу күгәрчен күгәрчен генә булмады инде. Ике тиле икәүләшеп ярма ташыйлар да ташыйлар.

Әтиләре төзәтмә кертүне кирәк тапты:

— Өч тиле өчәүләшеп, диген, әнисе!

— Мин дөге сипмим. Башкасы да бетмәгән. Барыгыз, алып кайты-гыз миңа дөге. Җебетәсе дә бар әле аны.

*

* *

Ничек кенә булмасын, пешәсе гөбәдия барыбер пеште. Табын җәеп утырышканнар гына иде, кухня ягыннан чыйкылдаган, мыраулаган тавыш ишетелде. Йөгереп чыксалар, ни күрсеннәр, Багира әрләнне җилкәсеннән каптырып алган! Әрләнн ычкынырга теләп тыпырчына, чыйкылдый. Чыйкылдаган саен авызыннан дөге ярмасы коела. Ә песи аның саен мыраулый, корбанын җибәрергә уйламый да. Әле ярый, әтиләре югалып калмады, тиз генә иелеп, Багираның яңагын кысты. Әрләнн ычкынды. Әмма ул торып кына китәр хәлдә түгел иде. Бер-ике генә талпынды да тынды. Алгы аякларын күкрәк турысына җыерып китергән дә кырын яткан. Киндер орлыгыдай бәләкәй генә күзләренең берсе ачык. Яңаклары шиңгән. Шул килеше, шул кыяфәте белән ул «Мөнә мине нишләттегез!» дигәндәй, кызганыч бер мәгънәне аңлата иде кебек.

Айдар, читкә борылып, үкси-үкси елый башлады. «Күпме саклады, күпме карады бит югыйсә. Ә ул... явыз!» — дип Багирага рәнҗеде. Ә Багира, гаебен аңлап гафу үтенгәндәй, малайның аяк тирәсендә сыр-палана. Ләкин бу минутта Айдарның күңеле песидән тәмам бизгән иде. Тик нишләтергә, нинди җәза бирергә? Монысына аның әлегә ба-шы җитми. Шулай изаланып торганда, җиңелчә генә итеп, иңбашына кемдер кулын салды. Әйләнеп караса — әтисе икән. Никтер елмая.

— Бар, карале, кайда әрләнең? — ди.

Айдар әле генә әрләнн яткан җиргә карады. Ләкин җәнлек хәзер анда юк иде. Авызыннан коелган ярма бөртекләре генә калган.

— Кайда соң ул, әти?!

— Качкан бит энә. Аңгырайган гына булгандыр.

— Беләсең ич, әти, әйт инде?!

— Газ плитәсе астына кереп китте.

Табып чыгардылар эрләнне. Тик нигә ул болай?! Яңаклары тагын кабарган! Түшенә дә өч-дүрт бөртек дөге сырышкан. Аталы-уллы кабат плитә астына иелделәр һәм, карый торгач, иң түргә, почмакка ук яшерелгән ярма өемен күреп алдылар.

— Кара син аны, — ди этисе, Айдарның кабыргасына төртеп. — Карак икән ич синең бу эрләнең. Әниең әнә безгә сылтый.

Бу хәлдән соң малайның бөтен рәнҗешләре онытылып, үрсәләнгән күңеле урынына утырган иде. Аңа хәзер Багирасы да элеккечә үк якын, бик кадерле булып тоелды. Шуна күрә әнисе белән этисе алдында да песиен аклыйсы килеп китте:

— Уяу шул Багира, акыллы! Ярма урлаганда тоткан ул аны, — дип куйды.

— Акыллы, акыллы. Күренеп тора, — ди этисе.

— Шулайдыр, шулай булмыйча. Мулла кебек тәүфыйк иясе, — дип өстәде әнисе.

Айдар көлеп җибәрде. «Тәүфыйклы песи» шигырен өйрәнгәндә, «тәүфыйк» сүзен әйтә алмыйча, гел «тәфикъ» дип җәфаланган иде. Шул исенә төште. Ул арада этисе, шкафның аскы бүлегенә ымлап, сүзне икенчегә борды:

— Күгәрченнәргә сибәм дип ярма аласың да шкаф ишеген ачык калдырасың. Әнә бит хәзер дә ачык. Эрләң дә шуннан ташыган. Кышка дип җыя.

— Нигә алай итә, ашатам ич мин аны.

— Табигате шулай. Инстинкт.

— Тагын шул инс... тин... тинктмы?

— Шул шул менә, тагын инстинкт. Хәзер теләсәң кайсын сайла: я Багираң, я эрләң. Икесен бергә асрап булмый. Онытасың ич эрләнеңне. Мәченең дә үз инстинкты. Барыбер буачак ул аны бу килештән. Тагын еларсың бит.

Ник еламасын, ди. Елар иде, әлбәттә. Монысын Айдар бик яхшы белә. Эрләннең азык җыюын да аңлый кебек. Ә Багира? Ник ул аны буа?! Нигә кирәк шундый явызлык? Эрләң аңа тими ич.

Бу көнне Айдар төшендә дә шулар белән саташты. Имеш, эрләң белән песи дуслашканнар. Имеш, эрләнгә дип икәүләшеп шкафтан ярма ташыйлар. Тик мәченең авызында ярма тормый, юл буе чәчелеп йөри икән. Ул да түгел, аларга күгәрчен килеп кушыла. Багира авызыннан коелып калган ярманы чүпли, имеш. Шул арада, тешен ыржайтып, әллә кайдан гына инстинкт килеп чыга. Мәче дисәң, мәче, күсе дисәң, күсе түгел — кап-кара бер хәшәрәт! Үзе һаман Багира тирәсендә бөтерелә, ыржайган танавы белән аны бер эрләнгә, бер күгәрченгә таба төрткәли, дусларына ташланырга куша. Моны күреп, Айдарның җен ачуы чыкты. Тибеп җибәрим дип аягын кузгаткан гына иде, инстинкт сикереп балтырына ябышты... Шул чагында малай сискәнеп уянып китте. Ләкин ни галәмәт! Уянгач та шул ук хәл, балтырына чыннан да нидер ябышкан ич! Аягын селкегән саен тырнагын катырак батыра. Чак кына кычкырып җибәрмәде. Ярый әле абайлап өлгерде. Югыйсә, оятын кая куйган булыр иде. Инстинкт дигәне Багира үзе икән ләбаса!

Шуннан бирле Айдар Багираны юрган астына алмас булды.

## Каракныкын бур урлаган

Эрләң белән Багираны бергә асрап булмасына Айдар инде үзе дә тәмам ышанган иде. Хәер, эрләнне һаман ябып, читлектә генә тотса, әлбәттә, асрый да алыр иде. Тик моннан ни кызык та, ни файда. Һәр гадәтен, һәр кыланышын иркенләп күзәтерлек булмагач, ниемә дип

аны интектерергә. Шуңа күрә Айдар ərlәнең күрше йортта торучы дусына бирде.

Ул арада балкондагы күгәрченнәр бала чыгардылар. Айдар моны сизми дә калды. Әле кичә генә ул бу күрәсмми иде. Иртәгесен күзе төшсә, күгәрчен тирәсендә, йодрык чаклы булыр, ике кошчык кайнаша. Кайчан чыкканнар да ни арада үскәннәр.

Озак та үтми, әниләре белән бергә «чүпләнә» дә башладылар. Ана күгәрчен сипкән ярманы кырыйдан гына чүпли, ә балалары уртага ук кереп басалар. Басалар да, чүпләнүгә караганда, томшыклары ярмага тимичә, күбрәк буш идәнне чукып интегәләр. Аннары, күрәсең, арыптыр, кинәт туктап калалар. Күгәрчен башта моңа игътибар итми, бу хәл озакка сузылса гына, яннарына килеп, әле берсен, әле икенчесен чукып ала: янәсе, чүпләгез, тик тормагыз! Шулай итеп, балаларын ашарга өйрәтә.

Күгәрчен балалары көннән-көн үстеләр, ныгый бардылар. Җим сипкәндә кулын чукыган теге ата күгәрчен дә Айдарга тәмам иялəште, юашланып калды. Тик анысы башта читтәрәк йөргән кебек тоелган иде. Никә карамасын, балалары янында һаман да ана күгәрчен генә була. Ә бервакыт Айдар, күгәрченнәр тирәсендә чуалган җиреннән, кухня тәрәзәсе төбендә утырган Багираның балконга сикерергә чамалавын күреп алды. Күп булса, бер метр ара, песигә ул чүп тә түгел. Шул чагында малай баш өстендә генә күгәрчен гөрелдәп куйганын ишетте. Күгәрчен балалары шундук аналары тирәсенә елыштылар.

Айдар сузылып өскә карады. Ә анда, балкон читендә, ата күгәрчен утыра иде. Ул да түгел, күгәрчен кунаклаган җиреннән кинәт кенә купты да, Багираның борын төбеннән генә очып, аскы каттагы балкон култыксасына кунды. Көтелмәгән бу хәлдән песи аптырап калды. Аның хәзер бөтен игътибары ата күгәрчендә иде. Ә кош урынын алыштырып кына тора. Я ул өй каршындагы рәшәткәгә барып куна, я кире балконга кайта. Һәр кайтуында, урап булса да, Багира яныннан уза. Бу шулай байтак дәвам итте. Багира ниятеннән сүрелеп, тәрәзә төбеннән төшкәч кенә, күгәрчен тынычланып калды.

Әлеге вакыйгадан соң Айдар, балконга чыгу белән үк, як-ягына карана торган булып китте. Кайчан гына карамасын, ата күгәрченнең я өстәге, я булмаса күршедәге балкон кырыенда утыруын күрә. Бер дә читтә йөрмәгән, һәрвакыт бик уяу, балалары тирәсендә — якында гына сакта тора икән ата күгәрчен.

Тора-бара күгәрченнәр әрсезләнә дә башладылар. Айдарның инде ничә тапкыр күргәне бар, урамнан кайтып бүлмәгә керсә, ана күгәрчен дә, атасы да, балалары да шунда була. Кайсы шкаф, кайсы диван астыннан атылышып чыгалар да балкон ишегенә таба йөгерәләр. Бер көнне әтиләре белән кайтып кергәннәр иде. Анда да шул ук хәл кабатланды.

— Кара син боларны, бөтенләй басымчак итәләр икән ич. Багираң каптырса әле...

— Багира барында мин ишекне ябып куям. Нигә алар һаман да диван астына керәләр икән, әти, ә?

— Мәнә карыйк әле, аннан соң белербез, — дип Айдарның әтисе диванны стена кырыеннан уртагарак тартып куйды. Ни күрсеннәр, диван торган урында солы ярмасы чәчелеп ята. Шкаф астын карасалар, анда да шул ук хәл, монысында инде тары ярмасы сибелгән иде.

— Мин беләм, әти, мин беләм! — дип Айдар баскан урынында сикерергә тотынды.

— Нәрсә беләсең?

— Боларын да әрләән ташыган!

— Шуңа охшаган. Кара син аны, хәйләкәр. Төрлесен төрле җиргә, аерым-аерым җыйган.

Ул арада әниләре дә кайтып керде. Айдар аңа суларга да ирек бирмичә, җиңеннән тарткалап бүлмәгә дәшә башлады.

— Тизрәк инде, әни. Әнә, эти белән без ярма таптык!

— Һа-а, куанычыгыз зур икән. Тапсагыз соң, кая китәр дип беләсең, шул кадәр ашыктырмасаң... Авызларын ерганнар. Ике тиле!

— Әрләп җыйган аны, әни, әрләп яшергән. Ә күгәрченнәр кереп чүпләгән.

— Шәп иткәннәр. Каракныкын бур урлаган икән алайса.

— Нәрсә соң ул бур?

— Нәрсә булсын, әрләп төсле карак була, вор була. Рус сүзен бозып әйткәннәр.

Читтән генә карап, көлемсерәп торган этиләре дә сүзгә кушылды:

— Күрдеңме, малай актыгы, әниебез ниләр белә. Син дә белеп кал. Кирәге чыгар.

— Белер, белер. Белдерәсез... Кара инде бу бүлмәне. Кеше керерлеге калмаган. Үләм инде сезнең беләп. Хәзер үк җыештырыгыз, — дип әниләре бүлмәдән чыгып китте.

Кызык та инде Айдарның әнисе: үзе ачуланган була, үзенең көлүен, борылып китсә, артыннан да сизәсең.

Әтисе Айдарга күз кысып, башын кагып куйды:

— Бар, себерке алып кил, — диде.

Алар, көлешә-көлешә, бүлмә җыештырырга тотындылар.

Бер-бер артлы көннәр шулай уза торды. Күгәрчен балалары тагын да зурайдылар, менә-менә очып китәрләр төсле иде. Шул минутларны Айдар зарыгып та, сагаеп та һаман көтте, очуларын күреп калырмын дип өметләнде. Ләкин өмете акланмады. Кичтән балконда калган кошлар иртәгесен инде юк иде. Балкон идәнендә шәмәхә төстәге бик матур ике каурый гына калган.

Малай, каурыйларны тотып, нәүмиз генә өйгә керде. Аңа бик тә ямансу иде. Моны эшкә җыенып йөргән әтисе дә күреп алды, сораштыра башлады.

— Әнә, күгәрченнәр киткән, — диде Айдар яшь аралаш. — Каурыйлары гына калган.

— Әй, юләр малай, — ди әтисе, — исән-имин очып киткәч, шатланырга кирәк. Ә син балавыз сыкмакчы.

— Булсыннар иде шунда, мин аларга тимәдем ич.

— Тимәвең бик әйбәт. Шуның өчен сиңа әнә — каурыйлар. Изгелек күргән кешеләренә каурый ташлап калдырган кошлар турында әкияттә дә сөйләнә...

Малай уйга калды. Кем белә, бәлки дөрестер дә. Бәлки әле күгәрченнәр тагын килерләр, тагын шулай бала чыгарырлар. Айдарга каурый калдырып китүләре юкка гына түгелдер.

## Өйрәнеп җиткәч кенә

Айдар кемнәндер: «Мәчеләрне тыңлатуы, нигә дә булса өйрәтүе бик читен». — дигән сүзләрне ишетеп калган иде. Ләкин малайның моңа һич кенә дә ышанасы килмәде. Ничек килсен ди, аның әле шуны да ишеткәне бар ич: арысланнар, юлбарыслар, капланнар һәм тагын әллә нәрсәләр — барысы да мәчеләр нәселеннән икән. Менә шул җанварлар, мәчеләрнең бары тик нәселеннән генә була торып та, циркта ниләр генә кыланмыйлар! Өйрәнәләр ич, тыңлаталар. Ә мәчеләр үзләре? Шулай ук кире, булдыксыз микәнни алар? Юктыр, дөрес түгелдер бу. Багира да мәче лә, ә нинди тыңлаучан. Өстәлгә менгәнен күрсә, «перес» дип малай бер генә кычкыра — мәчеңнән җилләр исә. Йомышын үтәр өчен дә хәзер үзенә куйган комлы әрҗәгә йөри. Өйрәтте ич Айдар. Шулай булгач, тыңламый буламыни? Алаен алай да, тик менә бер

гадэтеннэн һич тэ бизлерэ алмый мэчесен. Я диванга, я булмаса йомшак урындыкка менеп утыра да тырнашырга тотына. Сусэртеп бетерде инде тышлыкларын. Э энилэре сукрана: «Бетерэ, харап итэ эйберлэрне», — ди. Шундый чакта Айдарга бик авыр була, эйтерсен лэ Багира диванны түгел, э малайның җанын тырный. Аптырагач, этисеннэн дэ сорап карады:

— Эти, нишлэтергэ инде моны, тырнаша да тырнаша?

— Нишлэтэсең... Тырнатма, саклап тор, — ди этисе. Үзе көлэ.

— Көлэсең син, эти. Эйт инде, нигэ алай итэ ул?

— Соң, җылыйммыни? Тырнакларын чарлый ич.

— Ничек инде ул — чарлый?

— Ничек икэнен күреп торасың бит. Ныгыта, көчле, үткен булсыннар, ди, тычкан тотасы бар ич эле аның...

Кызык кына: саклап тор, имеш. Эйтерсең Айдарның бүтэн эше юк. «Тычкан» ди тагын, каян тотсын ул булмаган тычканны. Үзенең дэ юньлэп күргэне юк эле аны. Авылга кайткач бер күрде инде — бары шул.

Үзе түзсэ түзэ, эмма Багирага сүз эйттерэсе килми иде Айдарның, олылар алдында аны ничек тэ акыллы, булдыклы итеп күрсэтергэ тырыша. Шул ниятеннэн ул Багираны цирк уйнарга өйрэтэ башлады. Ике урындыкны кара-каршы китереп куя да берсенэ мэчене бастыра. Икенчесе янына үзе чүгэлэп, кулына кечкенэ генэ итме, колбасамы кисэге тоткан килеш, Багираны чакыра. Анысы да кыстатып тормый, бер карыш араны сикерүе мэчегэ ни, «айт» дигэнче малай янында була, ит белэн сыйлана. Э урындыклар аз-азлап бер-берсеннэн һаман ерагая барды һэм Багира, сыйга кызыгып, хэйран гына араны сикерэ башлады. Лэкин инде Айдарга бу гына аз, цирк икэн, чын цирктагыча булсын дип, энисенең чигү чигэ торган киерге-коршавы аша сикертергэ тырышып карады. Эмма Багира коршауны бар дип тэ белми, тота да идэнгэ сикерэ һэм аннары гына, йөгереп килеп, икенче урындыкка менэ. Озак азаплый торгач, күңелең булсын инде дигэндэй, мэче тэвэккэллэп тэ караган иде, тик коршауга бэрелеп, идэнгэ мэтэлде. Шуннан соң гына чамалады Айдар, коршау тар икэн, бэлэкэйрэк икэн шул Багира өчен... Э нигэ, зурайтып була бит аны, икэү ич коршау! Икене бер итеп ялгыйсың да куясың. Һэр ике коршауны өзеп, җеп белэн бэйлэштерэ-бэйлэштерэ, эмэллэп тэ куйды Айдар. Сигезле саны төслерэк килеп чыкса да, зарар юк, аның каравы энэ нинди иркен, рэхэтлэнеп сикерэ хэзер Багира! Димэк, программаның беренче номеры булды. Инде икенчесен эзерлэргэ кирэк. Эмма ничек итеп? Эһэ, тапты бугай, эйдэ пианино уйнап карасын Багира! Э өченче номеры эллэ кайчан эзер.

Айдар зарыгып көткэн ял көне дэ килеп җитте. Кичтэн ул Багираны бөтенлэй диярлек ашатмаган иде, шуңа күрэ мэченең кухнядан чыгуы юк, савыты янына эйлэнэ дэ килэ, эйлэнэ дэ килэ, я булмаса «мияу, мияу» дип аяк арасында чуала. Барысы да сизэлэр, мэченең ашыйсы килэ, лэкин Айдар өйдэ вакытта аңа ни дэ булса бирергэ берэүнең дэ хакы юк. Артистны бозмагыз, дип кенэ җибэрэ малай. Тик элегэ артистның һөнэрен генэ күргэн кеше юк.

Ниһаять, энилэре түзмэде, бүлмэдэ нидер маташтырган Айдарны дэшеп чыгарды.

— Ник ашатмыйсың Багиранны? Аяк атларга ирек бирми бит!

— Ярамый элегэ, формасы бозыла!

— Ярар алайса, икенче менэ үзеңнең дэ формаңны саклармын, нишлэрсең икэн?

Айдар көлде дэ тагын бүлмэсенэ кереп китте. Озакламый тавышы ишетелде:

— Эни! Эти! Монда керегез, цирк күрсэтэм!

Әтисе дә, әнисе дә, бүлмәгә кереп, диванга янәшә утырдылар. Әнисенең утыруы булды, Айдар кулындагы коршауны күреп, «Аh!» дип куйды. Тик әтисе шундук аның беләгеннән тотты: шаулама янәсе. Айдар аны-моны сизмәде, чөнки ул үз эшенә чумган иде. Ә Багира, бичара Багира... Күзләре ут яна! Айдарның итне күрсәтүе булды — ялт коршау аркылы малай янына.

Бу шулай берничә тапкыр кабатланды. Аннары Айдар икенче номерны игълан итте:

— «Тыпыр-тыпыр» көенә пианинода уйнау!

Айдар пианиноның капкачын ачып куйды да бер башына Багираны утыртты. Ә үзе икенче башына барып басты һәм мәчегә таба ит кисәген сузды. Багира клавишлар өстеннән шундук Айдар янына атылды. Аяк астыннан тик до, ре, ми, фа, сольләр генә сибелешеп калды...

Программаның бу номерын тамашачылар көчле алкышлар белән хуплады. Малайның башы күккә тиде. Шуңа күрә ул өченче номерны тагын да дәртлерәк, тантаналырак итеп белдерде:

— Мәчеләр чабышы!!!

Шулай диде дә, Багираны бүлмәдә калдырып, кухняга чыгып китте. Озак та үтми, кухня ягыннан тавышы ишетелде:

— Багира, ашарга чык!

Мәче, мескен, бәреләә-сугыла Айдар янына томырылды...

Багираны күтәреп кире бүлмәгә кергәндә Айдарның авызы колагына җиткән иде.

— Я, ничек безнең цирк?!

— Шә-әп, — диде әтисе. — Бер дигән!

— Шәп, шәп... Тиләләр! — диде әнисе. — Киергене нишләттең?

— Я инде, әнисе... Икенчене алып кайтырбыз, — диде әтиләре. Аннары өстәп куйды:

— Миңа программаның соңгы номеры бигрәк тә ошады. Кабатлагыз әле шуны, улым.

Айдар, Багираны тагын бүлмәдә калдырып, кухняга чыкмакчы булды. Шул чагында әтисе сорау бирде:

— Ә ул син чакырган бөтен җиргә шулай чабамы?

— Чаба, әти, чаба!

— Алайса, без болай итеп карыйк: хәзер барыбыз да залга чыгабыз. Ә син Багираны да шунда чакырырсың.

Айдар залдан торып: «Багира, ашарга чык!» — дип кычкырган иде, мәче икенче бүлмәдән туп-туры кухняга атылды. Зал ягына әйләнеп тә карамады. Кухняда Айдарны күрмәгәч, савыты да буш булгач, «мияу» дип сузды.

— Бар әнә, — ди әтисе, көлеп, — Багира үзеңне чакыра, хәзер син йөгер кухняга.

Айдар уңайсызланып калды. Алай да сер бирәсе килмичә:

— Ялгышты гына ла ул, — дип куйды.

— Шулайдыр, шулай булмыйча... — диде әниләре. — Өйрәнеп житкәч кенә.

*Ахыры киләсе санда.*

## Әдхәт Синугыл

### Курчак елый

Уяндым мин бүген
Бик иртән.
Күрәм: курчак елый...
Ник икән?

— Матур апам, кулым
Сынды бит...
Элек ничек иде,
Шундый ит!

— Абау, нәнәм, абау,
Сылуым,
Чынлап икән кулың
Сынуы.
Елама син юкка,
Елама.
Ремонт ясыйм хәзер
Мин аңа!

...Җилем сөрттем һәм ... кул
Ялганды.
— Менә,— дидем,— эшең
Җайланды.

### Зоопаркта

Зоопаркка барган идем,
Кайттым үкенеп менә:
Бары да бар җанварларга,
Фәкать юк ирек кенә.

Нинди яхшы булыр иде,
Булсалар иреклe дә!

*Ташкент.*

# «АККАН СУ ЮЛЫН ТАБАР»

Бәхәс!.. Ул кешенең зиһенен сыный, дөньяга карашын, аң-даирәсен, фикер йөртү куәтен киңәйтә. Шул җәһәттән Башкорт дәүләт университетында һәр яңа чыккан әдәби әсәр хакында диярлек тепле, нигезле, бәхәсле сөйләшүләр оештырыла. Кирәк икән, фикер алышуга автор үзе дә чакырыла. Бу юлы Вакыйф Нуруллинның «Аккан су юлын табар» исемле повесте буенча китап укучылар конференциясе булды. Әсәр тормышчанлыгы, теленең табигыйлеге, герой-персонажларның күңелгә сеңеп калырлык булуы белән ошады. Фикер алышуга автор үзе дә чакырылды. Шыгрым тулы залда университетның уку-укыту бүлеге мөдире профессор М. Гайнуллин, филология фәннәре докторы, шагыйрь Г. Рамазанов, татар филологиясе кафедрасы мөдире профессор Г. Әхәтов, тәнкыйтьче Р. Баимов, К. Әхмәтҗәнов, бер төркем укытучы һәм студентлар бар иде.

— Мин Вакыйф Нуруллинның һәр әсәре белән танышып барам,— диде Г. Рамазанов. — Ул үткен ситуацияле әсәрләр язучы. Аның «Әгәр син булмасаң», «Күпер чыкканда», «Шинельсез солдатлар» әсәрләре дә укучыларда күп бәхәсләр тудырган иде. «Аккан су юлын табар» язмышлар повесте булып тора. Повестьта әхлак проблемасы күтәрелә. Җитәкчелек проблемасы да уңышлы хәл ителгән.

Дөрес, әсәрдә озынгарак сузылган эпизодлар да бар. Ләкин бу бер селтәнүдә алып ташлана торган кимчелек.

Доцент Ә. Нигъмәтуллин әсәр композициясенең гаҗәп кызыклы булуы хакында сөйләде. «Ул дәфтәрләр формасында бирелгән, — диде ул. — Г. Кутуй «Тапшырылмаган хатлар» формасын кулланган иде. Димәк, Вакыйф үткәнгә таянып эш итә. Сюжет үзәгенә кеше язмышы куела. Автор геройларның күңел диалектикасын оста бирә. Телне индивидуальләштерүгә дә зур игътибар итә».

III курс студенткасы Р. Нәбиуллина әсәрнең тел-стиль үзенчәлекләре турында сөйләде. Ул язучының традицион образларга игътибар итүен, аларны үзгәртеп куллануын, үзенең дә яңа поэтик бизәкләр иҗат итүен әйтте. Чыннан да, Булатның бер урында «сиздергәнне сиздермичә генә сиздерергә иде» дигән фразасын язучының озак уйлануы нәтиҗәсендә барлыкка килгәндер.

III курс студенткасы Ә. Хәмитованың чыгышыннан бер өзек: «Булат Вәлиев образы — намуслылык һәм гаделлекнең тулы бер чагылышы ул. Намуслы, гадел кешегә бернинди киртәләр дә каршы тора алмый. Вәлиев тә тормышта үз юлын таба». Яки менә II курс студенткасы М. Ильматова чыгышы: «Безгә, булачак укытучыларга, киләчәктә күп авырлыклар белән очрашырга туры килер. Булат образы безне түземле рәвештә көрәшә белергә өйрәтә».

IV курс студенткасы Р. Закирова чыгышы: «Без тискәре геройларны тәскә ямьсез, килбәтсез итеп, ә уңай геройларны, киресенчә, чибәр, батыр итеп күрсәтергә өйрәнгәнбез. В. Нуруллин үз әсәрендә бу шаблон юл белән бармый. Булат — уңай герой. Ләкин ул төскә Шәйхигә караганда ямьсезрәк. Шәйхи, киресенчә, төске чибәр, таза кеше. Ләкин Булатның эчке дөньясы матур. Ул халык арасында ышанычлы кешегә әйләнеп китә. Шәйхи, киресенчә, торган саен ышанычын югалта бара.

Профессор Г. Әхәтов йомгаклау сүзендә болай диде:

— Мин бүгенге сөйләшүдән бик канәгатьмен. Иптәшләр тепле фикер йөртәләр. Әсәр, һичшиксез, һәркемне уйландыра, фикер уята. Залның шыгрым туп-тулы булуы да шуны раслый. Повестьны мин рәхәтләнеп укып чыктым. Укыла, бәхәс уята, әдәбиятыбызның үсешен билгели торган әсәр бу.

Материалны СУФИЯН ПОВАРИСОВ әзерләде.

# «ГӨЛБАДРАН»

Әлмәт шәһәренең үзәк китапханәсендә язучы Саҗидә Сөләймانованың «Казан утлары» журналында дөнья күргән «Гөлбадран» повесте буенча бу ел башында китап укучылар конференциясе үткәрелгән иде.

Чорыбызга лаек герой кем ул, аңарга нинди сыйфатлар зарур, нинди бурычлар йөкләнә? Әледән-әле кабынып киткән бәхәсләр, нигездә, шул тирәдә барды.

**Әлмира Әхмәдуллина,** пионервожатый:

Әсәрдә миңа иң ошаган һәм иң дулкынландырган образ — Баязит Аллаяров образы.

Аллаяров зур һәм кырыс тормыш юлы үткән чын ир. Ул фронтта яраланган. Еллар узгач, үзе хирург булып китә. Аллаяровтагы тагын бер сыйфат мине бик тә, бик тә сокландыра. Ул матур итеп ярата белә. Бу матур хисне кайбер яшьләребез дөрес аңламый сыман. Әдәбиятта да ихлас, зур итеп, олы мәхәббәт белән яратучы геройлар бик аз. Баязит абыйның үзенең хатыны Дәлиягә булган хисе, мөнәсәбәте чын йөрәктән, гади, тормышчан, матур.

Аллаяровның прототибы безнең шәһәрдә яши икән. Бөтен тирә-юньгә билгеле ул хирург белән Аллаяров арасында уртаклыклар, охшаш вакыйгалар табалар. Больница тирәсеннән узганда, мин һәрвакыт гаҗәпләнә идем. Монда иртәсен дә, кичен дә кырыс тынлык хөкем сөрә. Килгән кешеләр дә тавышларын күтәрмичә, пышылдап диярлек кенә сөйләшәләр. Баксаң, шушы йортта да көрәш бара икән. Кемнәрдер, үзләренә карьера ясау теләге белән, Баязит абый кебекләрнең ялгышын көтеп тора. Уңай моментны ычкындырмыйча, шунда ук аяк чала. Баязит Аллаяров мондый кешеләрдән өстен. Алар белән бәхәс, гауга корып торырга вакыты юк аның. Мин үзем кечле, рухы белән матур булган кешеләр хакында укырга яратам. Аллаяров һәм артистка Бибиса образлары әнә шундыйлар.

**Насимә Миңлеханова,** татар теле һәм әдәбияты укытучысы:

Саҗидә Сөләймановапы мин күптәннән беләм. Безнең мәктәпкә ул еш килә. Укучылар каршында чыгышлар ясый. Повестьны язган чорда да ул безгә килгән иде. Әсәреннән өзекләрне беренче тапкыр безгә укыды. Шуңа күрәдерме, әсәрне дулкынланып кулга алдым. Рәхәтләнеп укыдым. Иң элек җәй айларында «Социалистик Татарстан» газетасында барган заманчалык мәсьәләсе хакындагы бәхәсләр күңелгә килде. Шунда профессор Ибраһим Нуруллин мәкаләсе бик тә охшап калган иде. Шушы җәһәттән «Гөлбадран» повесте соңгы елларда басылып чыккан әсәрләр арасында үзенә лаеклы, дәрәҗәле урын алды дип уйлыйм.

Хәзер әсәрнең геройлары хакында. Повестьны укып чыккан әлмәтлеләр күп кенә геройларны «таныганнардыр», әлбәттә. Язучы белән аралашканга күрә яхшы беләм: Аллаяров образын иҗат итү өчен автор күп эшләде. Ул көннәр, атналар дәвамында больницага йөрде. Катлаулы операцияләрне, хирургларның эшен күзәтеп иртәдән кичкә кадәр шунда булды. Артистлар белән гастрольләргә йөрде ул. Саҗидәнең тынгысызлыгы, эзләнүләре бушка китмәде.

Авторга киңәш төсендә, берничә теләкне тә әйтер идем. Беренчесе. Әсәрдәге кайбер исемнәр бөтенләй уңышсыз, колакка ятышлы түгел. Язучылар борынгы, хәзерге кулланыштан төшеп калган исемнәр белән мавыга башладылар. Әйтик, Бибиса дигән исем. Бибиса гаҗәп матур, кешелекле, хискә, кичерешләргә бай образ. Таһир-Зөһрә урынына Миңлемөхәммәт-Бибиниса исемнәре килмәгән кебек, Бибиса исеме бу образга ятышмый. Медицина терминнары да күбрәк түгел микән?

**Котуфә Хафизова,** район культура йорты директоры:

Чыгыш ясаучылар белән нигездә килешкән хәлдә, әсәрдә сурәтләнгән берничә хатын-кыз, аларның үз-үзләрен тотышы хакында сүз әйтәсем килә.

Аллаяровның хатыны Дәлия. Дөрес, безнең тормышта мондый хатын-кызлар бар. Алар шул хәтле бер-берсенә охшашлар, уйлары, эшчәнлекләре бер чамада, бер тирәдәрәк бөтерелә. Шушы хәл миндә ризасызлык уята. Дәлия тәскә-биткә чибәр, зифа, хәлык алдында ихтирам казанган хирург хатыны. Горур, эре. Хезмәттәшләренә һавалы итеп, өстән карарга ярата, иренең шәһәртән үзенә бөркәнчек итеп каплаган. Аның бөтен уе үзе, малае һәм ире турында гына. Менә бер мисал: кат-

лаулы операция кичереп, үлемнән кире кайткан Бибиса сәхнәгә чыгарга тиеш. Тамаша залында утыручы врачлар үзләренең күп айлык көрәшләре җиңү белән тәмамланганга горурланып, хисләнеп утырганда, Дәлия, үзе дә медицина хезмәткәре булуга карамастан, боз кебек салкын. Бирелеп-бирелеп, хатын-кыз көлмәгә тикшерә, аңа, иренә игътибар итәләрме — шуны күзәтә. Мещанлык сереме белән капланырга өлгергән шушындый хатын-кызларны сатира алымы беләнрәк сурәтләп булмый идеме икән?

Медицина сестрасы Фәрхәнә. Бу кызның яшь вакыты, беренче мәхәббәте әсәрдә гаять оста, уңышлы сурәтләнгән. Әмма Фәрхәнә зураеп, больницада Аллаяров белән эшли башлагач, хатын-кыз буларак, ул миңа ошамый башлады.

Фәрхәнә Аллаяровны ярата. Шуның өчен ул башка кешегә кияүгә дә чыкмый. Безнеңчә әйтсәк, гомерлеккә карт кыз булып кала. Әмма мин ышанам, әгәр хирург өз генә йомшаклык күрсәтсә дә, Фәрхәнә аңа тагылыр иде. Әлмәт шәһәрендә тагын бер семья бозылыр иде. Монда төп киртә булып Аллаяровның мораль ныклыгы, чисталыгы тора. Фәрхәнәнең Аллаяровка булган мөнәсәбәте, әсәрдән аңлашылганча, зур мәхәббәт итеп тәкъдим ителә сыман. Нинди генә хисләр белән янма, әгәр ул семьялы кешегә юнәлтелгән булса, бу мәхәббәт түгел, минемчә. Безнең заман кешеләре үз хисләрен тыя белмиләр. Әдәбият бу юнәлештә үз сүзен әйтергә тиеш дип уйлыйм.

**Рәмзия Руянова:**

Әсәр миңа бик тә ошады. Журналны укып чыккач, Бибиса Сабанаева күз алдымнан китми торды. Аның исеме дә, үзе дә бик матур. Һәркемне сокландырырлык. Кешеләр тормышны, матурлыкны яратырга тиешләр. Җирдә яшәү, халыкка хезмәт итү иң зур бәхет ул. Бибиса үлем белән көрәшеп ятканда да башкалар хакында кайгырта. Алар өчен шатлана, борчыла. Аның илһам, яшәү чыганагы — халыкка хезмәт итү. Бибиса үлем дигән мәкерле дошманны җиңеп чыга. Бу образ повестьны гына түгел, ә безнең татар әдәбиятын да бизи. Саҗидә Сөләймановага «Гөлбадран» повестен иҗат иткәне өчен рәхмәт хисләребез барып ирешсен иде.

**Матбугатка ФӘРИТ ГЫЙЛЬМЕТДИНОВ әзерләде.**

# ТОРМЫШ СЫНАУЛАРЫ ҖИҢЕЛ ТҮГЕЛ

*Журнал битләрендә Атилла Расихның «Сынау» исемле романы басылып чыгу тәнкыйтьчеләрдә дә, киң катлам укучыларда да зур кызыксыну уятты. Роман хакында сүз күп булды. Аның күтәргән әсәр булуын әйттеләр, «Социалистик Татарстан» газетасында тәнкыйтьчеләр Ибраһим Нуруллин белән Ринат Мөхәммәдиевнең романга багышланган рецензияләре басылып чыкты. Авылларда укучылар конференцияләре уздырылды. Редакциягә дә, автор исеменә дә укучылардан күп хатлар килде. Алар кызыксыналар, бәхәсләшәләр, авторга киңәшләр бирәләр. Түбәндә шул хатларның берничәсен урнаштырабыз. Апас районының Сатмыш авылы китапханәсе оештырган китап укучылар конференциясендә катнашучыларның кайбер фикерләре белән таныштырабыз.*

Шушындый роман язган өчен өлкән язучыбыз Атилла Расихка рәхмәт белдерәсем килә. Кешеләргә җан азыгы булырлык әсәр ул.

Күп кенә әдәби әсәрләрнең ахыры ничектер шатлыклы, без теләгәнчә тәмамлана. Мин дә шундыйрак бер кичереш белән «Сынау»ның ахырына якынлаштым, ләкин... тукта, ашыкма. Тормыш син көткәндәгечә генә гади түгел шул. Чын тормышның асылы әнә шул чишелеп бетмәгән төеннәрдә. Менә Фәритнең хаты. Барлык уйларымны, йөрәгемне әшеткәнә Фәритнең шушы хаты булды. Мин һич кенә дә андый хат көтмәгән идем. Шулай да була икән! Әсәрнең иң тетрәткеч моменты — шушы хаттыр, мәгаен.

Мине бу роман күп уйландырды, аның һәрбер бүлегеннән үземә үрнәк булырлык сыйфатлар, киңәшләр һәм башка файдалы мәгълүматлар алдым. Әсәрне бөтен-бөтен кешегә укытасым, алар белән бәхәсләшәсем килдә.

**Мөхтәрәмә Гайфуллина.**

Казан.

Исәнмесез, хөрмәтле Атилла абый!

«Сынау»ны журналның һәр санын көтеп алып укыдым. Күп төрле уйлануларга уятты ул әсәр. Фәлсәфәсе тирән, темасы зур, алган проблемалары киң, күп төрле. Киң колачлы әсәр. Ул тормышның үзе кебек үк катлаулы. Тормышта җавап биреп булмый торган хәлләр бик күп бит. Әсәрдәге күп әйберләргә «нигә алай?» дигән сорау куелса, аларга тиз генә җавап табып булмас иде. Минемчә, әсәрнең кыйммәте дә шунда.

Ләкин тормыш күпме генә чуалчык булмасын, без өмет итәргә, аннан яхшылык көтәргә өйрәнгәнбез. Бу — кешенең табигатендә. Ә менә «Сынау»ны укып чыккач, мин шул көтәргә өйрәнгән өметемнең чаткыларын да күрмәвемә ярсындым. Моның өчен тормышка да үпкәләдем, сезгә дә. Чыннан да, әле буласы-булмасы билгеле булмаган бәхет чырагын көтү иллюзиясеннән дә мәхрүм иткәнсез, Атилла абый.

Әсәрегезгә карата язылган тәнкыйть мәкаләләрен дә укыдым. Шуннан соң сезгә хат язу теләге туды. Мин менә шушы фикердә.

Фәүзия Хәйретдинова.
Арча.

Хөрмәтле Атилла дус!

Әсәрне дөньяга чыгару өчен сарыф иткән көчегез һавадагы төтен булып кына калмаган. Ул бүгенге яшь буынны коммунистик рухта тәрбияләүче әсәр булып чыккан. Әсәрнең уңышы шуннан торадыр ки, анда бүгенге үзебезнең күз алдыннан үткән хәлләр, вакыйгалар чын хәлендә тасвир кылынганнар.

Г. Хисмәтуллин.
Башкортстан, Кумертау шәһәре.

Хөрмәтле редакция һәм Атилла иптәш!

Сезнең журналда басылган романыгызны укып чыканнан соң Сезгә һәм редакциягә үз фикеремне язарга булдым.

Романыгызны ярыйсы гына мавыгып укырга мөмкин. Шактый гына гыйбрәтле күренешләр бар. Ләкин геройларыгызның күпчелеге бозыклар һәм көчсезләр, алар арасында үз максатларына ирешә алган бер генә герой да юк. Романны укыганда яки кино караганда һәр кеше аның уңай бетүен көтә бит, ә сезнең «чыш-пыш» килеп чыккан.

Минем туры язуыма хәтерегез калмасын, әле мондый хатлар булгалар дип уйлыйм.

Зәмирә Хәйруллина.
Әлки районы, Түбән Әлки авылы.

Хөрмәтле Атилла агай Расих!

Бик ошады бу романыгыз. Ул тормыштагы дөреслекне ача кебек. Чыннан да, кайбер әсәрләрдә язылганча, бәхетле генә була алмый кешеләр. Уйламаган җирдән әллә нинди бәхетсезлекләр, сынаулар, авырлыклар килеп чыга. Ә без, кешеләр, югалып калабыз. Бер сезнең романдагы Фәрит кенә түгел, бик күпләр...

Р. Хәсәнова.
Буа шәһәре.

Иптәш Атилла Расих!

Мин сезнең «Сынау» исемле романыгызны көтеп алып, бик яратып укып чыктым. Ул җиңел тел белән, дөрес һәм табигый итеп язылган, персонажларның кичерешләре бик урынлы. Роман татар әдәбиятында үзенең лаеклы урынын алыр дип ышанасы килә...

Ф. Хәкимов.
Азнакай.

Атилла Расих үзенең яңа әсәрендә кешеләрне борчый торган, кайбер ихтыяр көчләре йомшак булганнарны тормыш упкынына сөйри торган ямьсез күренешләрне — ялкаулыкны, эгоизмны, бала тәрбияләү һәм гаиләдә җаваплылык хисен югалтуны «камчылауны» төп максат итеп куйган. Бүгенге көндә кайбер яшьләрнең хезмәтне сөймичә җиңелрәк кәсеп белән яшәргә омтылуларын да искә алсак, романның актуальлеге бермә-бер арта. Роман үзенең эчтәлеге белән укучыларны хезмәтең белән

тормышта үз урыныңны табарга, гаилә коруга бик җитди карарга һәм гаилә булгач, андагы җылы мөнәсәбәтләрне киләчәк буыннарга тапшырырга чакыра.

**Сәлах Шәрипов.**

Азнакай районы, «Коммунизмга» колхозы.

Атилла Расих — тәҗрибәле олы язучыларыбызның берсе. Нәкъ аның әсәре булганга күрә, «Сынау» әсәрен кызыксыну белән укый башладым. Көткән өметләрем акланды дияргә ярый. Заманыбызда, тормышыбызда очрый торган типларны автор җанлы итеп бирә алган. Җаваплылыктан качарга тырышкан Гатауллин кебек башлыклар да, үзен дөнья үзәге дип санаган Сафуралар да, Рәмзи кебек «күбәләкләр» дә, гомернең асылын җәмгыятькә хезмәт итүдән тапкан Галиәкбәр һәм Закир кебек элекке буын вәкилләре дә тормыштан алынган типик персонажлар.

Әсәрнең исеме дә, минемчә, бик дөрес табылган. Чынлап та, сүз фабрикада оештырылган сынау турында гына түгел, башлыча шул сынауны оештыручы Фәритнең тормыш куйган сынауларны күтәрә алмавы турында бара. Авторның катмарлы образ тудырырга тырышуы, әлбәттә, мактауга лаеклы. Тик шунысы кызганыч: Фәрит образы ышандырып бетерә алмый. Автор аның ничек эчкечегә әверелүен күрсәтми, без Фәрит белән юл чатында аерылабыз, ә аның трагедиясе турында ишетеп кенә беләбез. Ә минә Фәритнең Әлфиягә язган хаты бөтенләй гаҗәпкә калдыра. Фәрит белән булган мондый метаморфозаны аңлап та, аклап та булмый. Аның өстәвенә, бу хат әсәрнең төзелешен дә боза. Әгәр ул хат булмаса, укучыга аз булса да уйланырга урын калыр иде, һәркем Әлфиянең язмышын үзенчә күз алдына китереп карар иде. Эпилогта исә язучы укучыны Әлфиянең бәхетле булуына, ә калганнарның андый бәхеткә ирешә алмаячагына ышандырырга тырыша. Кирәкми иде ул эпилог, чөнки ул авторның укучысына ышанмавын, бөтенесен ярып салмасаң, укучы авторның нәрсә әйтергә теләвен аңламас дип уйлаганын күрсәтә.

Әсәрнең ошамаган якларын сөйләү — аны инкарь итү дигән сүз түгел. Киресенчә, роман миңа ошады. Тормышны тирән белүе, үткен мәсьәләләр күтәрерлек кыюлыгы язучыга әйбәт әсәр язарга ярдәм иткән. Романның басылып чыгуы әдәбиятыбызда күренекле вакыйга булды диясе килә.

**А. Ибраһимов.**

Ульяновск.

**Апас районының Сатмыш авылында узган укучылар конференциясендә әйтелгән кайбер фикерләр:**

**Нурсинә Әхмәтова:** Эльвира Хәкимовна турында сөйләр алдыннан, күңелдә аңа карата ике караш яшәвен әйтәсе килә. Башта аның мин-минлеге тәмам күңелне биздерә. Соңыннан, яхшы якка үзгәрүен сизгәч, куанып куясың. Тәнкыйтьче И. Нуруллинның «Эльвира Хәкимовна тиз генә яхшы булган» дигән каршылыклы фикере белән дә килешми башлыйсың. Чөнки кешенең яхшылык алдында баш июен гадәти күренеш дип әйтер идем мин.

**Тәнзилә Габдрахманова:** Әлфия — бәхетле. Ул әти-әнисен ярата. Хезмәтне сөя. Мәхәббәтен югалтса да, бөгелеп төшми. Ул, һичшиксез, үз тиңен табар, матур тормыш төзер. Тик авторга гына бер үпкәм бар: кызга кайгыны артык күп биргән. Бераз җиңеләйтергә иде аның язмышын.

**Мәршидә Вәлиева:** әсәрдә Рәмзи тискәре образ буларак сурәтләнә. Ә моның үзенә күрә сере бар. Автор биредә тормышның катлаулылыгын искәрткән, сыгылмаска өндәгән, Рәмзидән гыйбрәт алырга кушкан.

**Равил Бикмуллин:** китап кызыклы. Тиз укыла торган. Тик миңа автор мәхәббәт мәсьәләсен генә җиңел хәл иткән кебек. Шунлыктан кочаклашу, үбешү, интим бәйләнешләрнең язылышы ничектер оятсызрак килеп чыккан. Толстой, Шолохов әсәрләрендәге эпизодлар белән чагыштырып карадым мин — аерма бар шул.

Әсәрдә тискәре типлар күп. Монысын, чын тормышның үзе чагылдырылганга, хуплыйм. Аннан ул вакыйгалар ата белән ананың гаепләрен дә ачалар. Уйланырга һәм нәтиҗә ясарга мәҗбүр итәләр.

Ә инде Сафура образына килгәндә, авторга карата күңелдә яшәгән килешмәүчәнлекне әйтергә кирәк. Минемчә, Сафураны, профессор кызы булган өчен генә, шул кадәр кара буяуларга буямаска иде. Шунлыктан образ бераз тыйнаксызрак килеп чыккан. Фәрит Еникеевны да бераз җитдиләндерү зарур. Югыйсә, ул ничектер ирләр горурлыгын югалткан. Әлфия, исә, артык яхшы булганлыктан, «идеалистка»га охшаган.

*Салих Баттал*

## МИНЕМ ҮЗ КАЛӘМЕМ БАР!

Бик кирәкле әшнәң очрый
урамда, я базарда.
Адресын бирмәкче була —
каләме юк язарга.

— Мә, — димен, — миндә калəм бар!
Минем кебек кешегә
кирәк булып чыга шулай
язу-сызу эшенә.

Була кайчак, ашханәдә
туа минем бер фикер.
— Кызым, мәйтәм, — тәкъдимем бар,
дәфтәрегезне китер!

Аш бирүче каушый, ләкин
дәфтәрне тәкъдим итә.
Аннары ярты сәгатькә
калəм эзләргә китә.

Үз каләмем белән язам,
калəм һәрбер кешегә
кирәк булып чыга шулай
язу-сызу эшенә.

Хатын әйтә: — Күршеләр,— ди, —
паласлы, мебельлеләр,
бай әшнәләләр һичнәрсәгә
ихтыяҗны белмиләр...

Шулай зарлана башласа:
— Бай мыни алар, — димен, —
менә мин бай! Һичкемдә юк
үз каләмем бар минем!

**Нур Әхмәдиев**

# ХӘМДЕНИСА

Хикәя



Орчык кадәр генә шул Гыймадиеңнан ничек тукматып торасың тау хәтле гәүдәң белән?— дип кызыксынуын тыялмаган хатыннар ничә сорасалар да, Хәмденисаның җавабы бер булды:

— Ир бит... Ир хакы — тәңре хакы.

Авылда шундый сүз йөри иде: имеш, яучылап-димләп өйләнгән Гыймади үзенең кәләшен беренче тапкыр зөфаф кичәсендә генә күргән. Күргән дә коты очкан, ди. Көч-хәл белән:

— Син кем?— дип сорый алган. Болай да оялып, тәмам югалып, нишләргә дә белми басып торган кыз:

— Хәмдениса, хәләл җефетең,— дигән, имеш.

Инде эш узган, никах укылган, чыбылдык эченә түшәк җәелгән, чигенергә урын юк, өлешеңә тигән көмешең дип, Гыймадига ризалашырга гына калган.

Озын буйлы, таза гәүдәле Хәмдениса янында Гыймади каклап киптерелгән балыкны хәтерләтә икән. Алар турында сүз чыкса, усалрак теллесе ут сүнгәч киң агач караватта Гыймади үзенә урын таба алмый интеккән, дип тә өстәп куя. Бу кадәресенең арттыру икәнлеген барысы да беләләр, әлбәттә. Чөнки кияү белән кәләшнең зөфаф кичәсендә кайдан килеп шаһитлар булсын да, никахлашкан ир белән хатынның түгел, кыз белән егетнең дә йокларга җай чыкканда, урын табалмауларына кем ышансын.

Икенче көнне чәй эчкәндә белә Гыймади: никахка кадәр ул күреп калган чибәр кыз аның балдызы булган икән.

Кеше ни сөйләсә дә сөйләр, әмма Гыймади абзый белән Хәмденисаттәйне начар яшәделәр дип әйтеп булмый. Икесе дә тырыш, эшкә уңган иделәр, шуңа күрәдерме, тормышлары да мул булды.

Бер-берсенә тәмам ияләшеп бетеп, пар күгәрченнәр кебек гөрләшеп яшәсәләр дә, аларның сәгать сыман көйләнгән тормышын аратирә Гыймади абзыйның чыгырыннан чыгуы бозып куя иде. Моның сәбәпчесе, әлеге дә баягы, буй кыскалыгы һәм кешеләрдәге каһәр суккан тел булды.

Үртәргә яратучылар, җор теллеләр беткәнмени. Ир-атлар эштән соң, берәрсенең бурага дип алып кайтып ташлаган бүрәнәләре өстенә утырып, тәмләп кенә махра суырганда, арадан котыртучы табыла.

— Син, Гыймади ул эскерт хәтле хатын белән ничек торасың, ә? Сәкегә басып үпмәсәң, буең да җитмидер әле? — ди берсе.

— Исең киткән икән! Үбешкән чакта гына хатыны Гыймайны күтәреп тә торырга мужыт,— дип әлеп ала икенчесе.— Менә минем башкасына һич акыл җитми: бер кочакка сыеп бетмәгән хатынның калган җирен икенче тапкыр кочаклый микәнни?

Адәмнәргә шаркылдап көлергә җитә кала.

И үртәлә Гыймади шул сүзләргә, и үртәлә. Сугып кына егар иде дә, көче җитмәсен белә. Ирлеге кимсенә аның, мин-минлеге урыныннан кузгала. Аллаһе тәгаләсен дә әйтер идең! Башы кешенекеннән ким эшләми, кулы ут уйната — тирә-юньдә данлыклы балта остасы. Шунда бераз буй өстәсә, ходайның кодрәте кимер идемени!

Айгыр сыман ыржаеп көләргә яраткан авыл адәмнәренә каршы әйтер сүз тапмый ул. Төпчеген җиргә ачу белән батыра да, җәй көне дә салмый торган малахаен басып киеп, кызу-кызу кибеткә юнәлә.

Көчсезлеген таныган ир-ат нишли дисезме? Йөрәк януын басарлык итеп эчә дә, җырлый, җай чыкса, бәйләнә башлый, карга ачуын чыпчыктан булса да ала.

Гыймади да шулай. Бер чәкүшкәне аудара да, өенә юнәлә. Мондый чакта Гыймадидан да көчле кеше юк инде. Ул үзен һич кенә дә әзмәвердән ким дип хис итми. Өенә килеп керүгә:

— Х-хәмденисау-у! Тетмәңне тетәм мин синең, тукмап үтерәм! — дип, аяк тибеп кычкырып җибәрә.

Карчыгы кая каршы әйтү, каршысына үзе йөгереп килә.

— Үтер, карт, үтер! — ди.

И очып-очып куна Гыймади хатынына. Хәмденисаның үзен якларга исендә дә юк, тик басып тора.

Шулай да аның күзе-чырае кара янып йөргәнен күрүче булмады.

Айныгач, Гыймади шактый вакыт хатыныннан унайсызланып йөри. Ләкин, ирләрнең үртәп теш ыржайтуы була, бу хәл тагын кабатлана. Революциягә кадәр үк башланган әлеге гадәт колхозлашкач та дәвам итте. Әмма иренең кул күтәрүе хакында Хәмденисадан берәү дә зарлану сүзе ишетмәде.

Бер заман колхоз ударникларын шәһәргә цирк карарга алып бардылар. Колхозга беренче булып кергән, яхшы эшләп килгән Гыймади белән Хәмденисага да бу бәхет элəкте.

И ул цирк дигәннәре! Нилəр генә күрмәделәр анда авылдан килгәннәр. Ул тәлинкәне чөюләр дисеңме, һавада атынучылар дисеңме, син тип-тигез җирдә дә әллә ничә тапкыр абынганда, монда нәп-нәзек бауда йөрүләр дисеңме, карауга ук кот очарлык арыслан белән фил дисеңме — барысы да бар иде цирктa. Үз оясыннан чыкмый ятып, кәҗә белән сарыктан, сыердан гайре хайван күрмәгән авыл халкы бу тамашадан телдән калды, авызын ачты да ябарга онытты.

Соңыннан уртага мускуллары туп кадәр, йодрыклары ике потлы гердән һич киме булмаган бер пәһлеван чыгып басты. Алып баручы тамашачыларга мөрәҗәгать итеп:

— Кем дә кем кул көрәштерүдә безнең батырны җиңә, аны зур бүләк көтә! Рәхим итегез, иптәшләр! — дип кычкырды.

Тамашачылар бер мәлгә тынып калдылар. Башта чыгучылар табылмады.

— Кем көчен сынап карый? Җиңүчене бүләк көтә!

Кыюсыз гына иң элек берәү күтәрелде, тора-бара, ни булса да булыр дип, үзен сынап карарга теләүчеләр күбәйде. Ләкин алар батыр

белән чак кына да тартыша алмадылар. Тимер мускул барысын да әйләндереп сала торды.

Һәрбер тартыштан соң тамашачылар гөр килә, халык басып-басып карый иде. Бөтен игътибарын тамашага юнәлткән Гыймадиның бер заман күзләре маңгаена сикерде: чираттагы батыр булып Хәмдениса баскан иде. Гыймади үзен-үзе белештермичә:

— Хәмдениса!— дип кычкырып җибәргәнен сизми дә калды. Ләкин аны итәгеннән тартып утырттылар.

Халык умарта күче сыман гөжли башлады. Әле аннан, әле моннан Хәмдenисага куәт бирүче тавышлар яңгырады. Барысы да Хәмдениса ягында иде.

— Җиң шуны!

— Кызганып торма, кинәтрәк ал!

Хәмдениса бу тавышларны әллә ишетә, әллә юк, аның игътибары батырда. Менә ул озын бөбәй итәкле күлмәген бераз күтәреп куйды, ашыкмыйча гына җиңнәрен сызганды һәм батыр каршындагы өстәлнең икенче ягына килеп утырды. Гыймадиның йөрәге ярылырдай булып тибә башлады: ни әйтсәң дә, үз сөягең үзеңә кадерле дигәндәй, гомер итә торган хатынның бит.

Пәһлеван, ни кырырсың микән дигәнсыман мыскыллы елмаеп, кулын алга сузды. Шуннан соң тамашачылар сизми дә калды: әллә батыр тотып өлгерә алмады, әллә тотып та Хәмдenисага каршы тору хәленнән килмәде, аның кул аркасы шап итеп өстәлгә килеп бәрелде. Батыр, гаҗәпләнүдән ни эшләргә дә белмичә, сикереп торып авырткан кулын селтәп җибәрде.

Тамашачылар берьюлы хәрәкәткә килделәр. Кул чаба, аяк тибә, төрле яктан кычкыра башладылар:

— Булды! Молодец!

— Дөрес түгел, булмас! Сөйләшеп куйганнардыр...

— Позор ирләргә, яшәсен хатыннар!

— Менә ичмасам, бу хатын...

Хәмдenисага тегү машинасы бүләк иттеләр. Машинаны култык астына кыстырып, ул урынына китте. Аны, урынына барып җиткәнче, аягүрә басып, кул чабып озаттылар.

Ләкин Гыймадидан җилләр искән иде. «Тәмәке тартырга чыккандыр»,—дип уйлады хатын. Тик ире һаман да кермәгәч, күңеленә шөбһә төшеп, залны урап керде, алай да тапмагач, авылдашларыннан сорап карады. Чыгып барганын күрсәләр дә, кая киткәнен белүче юк иде.

Ул арада программа тәгәлләнде. Авылдашлары белән цирктан чыгуга, Гыймадиның:

— Хәмдениса!— дигән тавышы ишетелде. Шунда ук хатыны янына ат белән килеп тә туктады. Гыймади шактый кызмача иде. «Ходаем, кеше алдында гына тавыш куптармаса ярар иде»,— дип, белгәнен укып, алласына ялварды Хәмдениса.

Хатыны менеп утыруга, колхозлашканчы үзләренеке булган кашка айгырга Гыймади чыбыркы белән тамызды. Кашка айгыр урыныннан ук куш аяклап чабып китте. Бүләккә бирелгән тегү машинасын урнаштыру белән мәшгуль булган Хәмдениса чанасыннан чак төшеп калмады. Ул толыбына төренебрәк утырды да Гыймадиның бәйләнгәнен көтеп бара башлады.

Менә алтындай утлары белән шәһәр дә артта калды. Кашка айгыр йолдызлы караңгылыкка кереп чумды. Тирә-якта кабер тынлыгы, шомлы ялгызлык. Авылдашлар атларын җигеп, куып җиткәнче, шактый вакыт узар. Гыймади юлда дуләрмы, кайткачка калды-

рырмы, хатын шул турыда уйлап борчыла иде. Каян уртага чыгасы итте! Гыймади шуны яратмагандыр, шуңа эчкәндер. Ә эчсә... Хатын яхшы белә: эчсә иренең бәйләнми калганы юк әле. Дөресрәге, бәйләнер өчен генә эчә дә ул. Кинәт Хәмденисаның уен бүлдереп: — Тр-р! — дигән тавыш яңгырады. Үз көенә генә юыртып барган айгыр туктап калды. «Башлады»,— дип уйларга өлгерде хатын. Ире кинәт аның күкрәгенә капланды һәм үксеп җибәрде.

Хәмдениса моны көтмәгән иде, гаҗәпләнүдән ни әйтергә белмәде. Башын боргалаган Гыймадиның бүреге салынып, чанага төште. Ә январь төне суык, ай-һай суык иде.

— Син, нишләвең бу? Суык тигерәсең бит, — ул картының бүреген алып китерде. — Әйдә, кыйнасаң кыйна да, өйгә кайтыйк инде...

Гыймади башын күтәреп, хатынына карап торды да аның иреннәннән, бәс сарган керфекләреннән үбә башлады.

— Фәрештәкәем, — диде ул, хатынына беренче тапкыр иркәләп эндәшеп. — Гафу ит мине. Юләр бит мин... Эчкәч юләрләнәм. Үртиләр... — диде ул. — Мин сиңа бүтән беркайчан да тырнак белән дә чиртмәм. Ышанасыңмы? Яратам бит мин сине...

Гыймади тагын хатынын иркәләп үбәргә тотынды.

— Кыйнаса, исең киткән икән. Син бит минем ирем, шулай язгандыр тәкъдирдә...

— Юк! — дип бүлдерде Гыймади.— Бүтән ул турыда сөйләшмик — Һәм Хәмдениса колагына тагын берсеннән-берсе матур, ягымлы сүзләр ишетелде.

Гыймади абзый сүзендә торды: карчыгына бүтән беркайчан да кул күтәрмәде. Пар былбыллар кебек сайрашып яшәделәр. Уртача гына буйлы биш кыз, биш малай үстереп кеше иттеләр.

Буйлар аермасына ишарәләп берәрсе сүз кузгатканда, ул хәзер ачу белән төпчегән җиргә төкереп, малахаен басып киеп, кибеткә юнәлми, кет-кет итеп көлә дә бетерә.

Ә цирктан кайтканда булып узган вакыйга турында алтын туйларында Гыймади абзый безгә үзе сөйләде.

## ЯЗУЧЫЛАРНЫҢ АЧЫК ПАРТИЯ ҖЫЕЛЫШЫ

Тукай клубында Татарстан язучыларының чираттагы ачык партия җыелышы уздырылды. Җыелыш КПСС Үзәк Комитетының июнь Пленумы (1980) карарлары һәм республика язучыларының бурычлары турында сөйләшүгә багышланган иде. Доклад белән Язучылар союзы идарәсе председателе, СССР Верховный Советы депутаты Г. А. Ахунов чыкты. Ул үзенең чыгышында июнь Пленумы карарлары яктылыгында Татарстан язучыларының эшләгән эшләре һәм бурычлары турында сөйләде, СССР Верховный Советының өченче сессиясеннән алган тәэсирләре белән уртаклашты. Җыелышта шулай ук Табигатьне саклау җәмгыятенең республика советы председателе урынбасары Р. С. Линахина чыгыш ясады.

Фикер алышуларда язучылардан Н. Дәүли, Р. Мостафин, Р. Ишморатова, Г. Латыйп, Ә. Гаффар, С. Хәким, Р. Ишморат, Л. Ихсанова катнашты.

Шушы ук җыелышта Сугыш ветераннарының Совет комитеты Казан секциясе председателе, запастагы полковник Т. Сәлмәнов та чыгыш ясады. Ул Сугыш ветераннары Советы комитетының Бөек Җиңүнең 35 еллыгына булдырылган истәлек медальләрен тапшырды. Әлеге бүләкне алучылар арасында Сибгат Хәким, Зәки Нури, Риза Ишморат, Тихон Журавлев, Мөхәммәт Садри, Нури Арсланов, Нәби Дәүли, Геннадий Паушкин, Мәхмүт Хөсәен бар.

## ТАТАРСТАННЫҢ 60 ЕЛЛЫК ЮБИЛЕЕ ХӨРМӘТЕНӘ

«Новый мир» журналы үзенең 6 нчы санын, Татарстанның 60 еллык юбилее уңае белән, татар шигъриятенә багышлады. Шигъри сәхифәдә Габдулла Тукай, Муса Җәлил, Хәсән Туфан, Сибгат Хәким, Шәүкәт Галиев, Илдар Юзеев, Рөстәм Кутуй, Ренат Харис, Равил Фәйзуллин, Разил Вәлиев, Фәнкур Сафин һәм Марсель Галиев шигырьләре бирелгән. Шигырьләрне Р. Бохараев, В. Бәширов, Э. Блинова тәрҗемә иткән.

* * *

Ленинградта чыга торган «Звезда» (СССР Язучылар союзы органы) журналы да үзенең 6 нчы санын татар шагыйрьләренең шигырьләре белән ачып җибәрә. Әлеге шигырь бәйләме Сибгат Хәким, Зәки Нури, Әхсән Баянов, Марс Шабаев, Шамил Анак, Гәрәй Рәхим, Роберт Миңнуллин, Шамил Маннапов, Фәннур Сафин, Госман Садә, Әмир Мәхмудов, Рашат Низамиев һәм Рамазан Байтимеров шигырьләреннән тора. Шигырьләрне Ленинград шагыйрьләре Вячеслав Кузнецов, Сергей Макаров, Олег Цакунов, Ирэна Сергеева, С. Гуляев һәм Л. Барбас тәрҗемә иткән.

Татар шагыйрьләренең шигырьләре «Совет Татарстанына — 60 ел» исемле девиз астында бирелгән.

* * *

СССР Элемтә министрлыгы Татарстан АССРның 60 еллыгына багышлап яңа почта маркасы чыгарды. Анда автономияле республиканың гербы, В. И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университеты, Муса Җәлил исемендәге опера һәм балет театры, «КамАЗ» автомобиле сурәтләнгән. Марканың түбәнге өлешендә «Татарстан АССРга 60 ел» дигән сүзләр язылган.

Марканың рәсеме татар милли орнаментларыннан ясалган рамка эченә алынган. Художнигы — Н. Колесников.

## ИҢ ЯХШЫЛАР ИСЕМЛЕГЕНДӘ

Казанда төсле негатив кинопленкаларга төшерелгән нәфис фильмнарның V Бөтенсоюз конкурсы булды. Конкурска 13 киностудиядә төшерелгән 27 фильм тәкъдим ителгән иде. Бу смотрда республикабыз башкаласындагы «Тасма» производство берләшмәсе пленкасына төшерелгән «Шәфкатьлеләр» («Мосфильм»), «Гусарны кодалау», «Сөеклеләрегез белән аерылышмагыз» (М. Горький исемендәге студия) исемле фильмнар төсле пленкаларны файдалану ягыннан иң яхшылар исемлегенә кертелде.

## «ДЕФА» ФИЛЬМ ТӨШЕРӘ

Татарстан башкаласына ГДРның «Дефа» киностудиясеннән бер төркем кинематографистлар килде. Алар арасында режиссер Конрад Вайсс һәм кинооператор Микаэль Леше дә бар иде. Тугандаш ил кино сәнгате эшлеклеләренең Казанга килү максаты бөек пролетар язучы Максим Горький турында фильм төшерүдән гыйбарәт.

Кунаклар Идел буенда Красновидово авылында булдылар, бирердәге М. Горький музееның Алексей Пешковны «хәтерләүче» экспонатлары белән таныштылар һәм яшь тамашачыларга адреслана торган әлеге

фильмны шушында төшерергә ният итте ләр. Кинокартинада Татарстанның М. Горькийга бәйле башка урыннарында төшерелгән кадрлар да чагылыш табачак.

### МОРДВА АССРда РОССИЯ ӘДӘБИЯТЫ КӨННӘРЕ

23—27 июньда Мордва республикасының 50 еллыгы уңае белән, республикада Россия әдәбияты көннәре уздырылды. Анда РСФСР Язучылар союзы идарәсе секретаре, шагыйрь Н. Доризо, әдипләр М. Колосов, Е. Антошкин, П. Железнов, Е. Храмов, И. Арсентьев, В. Разумневич (Мәскәү), «Волга» журналының баш редакторы Н. Палькин (Саратов), О. Поскребышев (Ижевск) килгән иде. Татарстаннан бу бәйрәмдә шагыйрь Рәдиф Гатауллин катнашты. Ул Саранск шәһәрендә, Чамдин районында студентлар, эшчеләр һәм колхозчылар белән очрашуларда катнашты һәм шигырьләрен укыды, татар совет әдәбияты турында сөйләде.

Рәдиф Гатауллин Россия әдәбияты көннәрендә катнашу уңае белән, партиянең Мордва өлкә комитетының һәм Мордва АССР Министрлар Советының Почет Грамотасы белән бүләкләнде.

### КЫЗЫКЛЫ ОЧРАШУЛАР

Язучы Шамил Рәкыйпов «Казанский» санаториендә ял итүчеләр белән очрашты. Ул үзенең халык арасында киң танылган «Чәчәкләр ни сөйли?», «Таңнар һаман матурмы?», «Кайдан син, Җан?» исемле китапларының язылу тарихлары турында сөйләде, яңа иҗат планнары белән таныштырды, бик күп сорауларга җавап бирде.

* * *

Тәнкыйтьче Рафаэль Мостафин һәм шагыйрь Фәннур Сафин Мәгариф хезмәткәрләре йортында республикабызның рус теле укытучылары белән очрашу уздырдылар. Р. Мостафин җәлилчеләрнең каһарманлыгы, эшчәнлеге, бу өлкәдәге яңалыклар, табышлар турында сөйләде. Тамашачылар шулай ук яңа шигырьләр тыңладылар. Әдәби кичәдә укытучыларның күп санлы сорауларына җаваплар бирелде.

* * *

Язучы Кояш Тимбикова, шагыйрь Фәннур Сафин Казанның механика заводында булып, завод эшчеләренең кызыклы һәм үзенчәлекле хезмәтләре белән таныштылар. Биредә уздырылган әдәби кичәдә тамашачылар әдәбият дөньясы, язучыларыбызның яңа әсәрләре, иҗат эше турындагы фикерләрне кызыксынып тыңладылар. Завод эшчеләре әдипләрнең яңа әсәрләрен алкышлап каршыладылар.

* * *

Язучы Мәгъсүм Насыйбуллин җәй айларында Актаныш районында булып кайтты. Ул анда районның комсомол активы алдында, Шаймәрдәнов исемендәге колхоз механизаторлары каршында, Байсар һәм Актаныш урта мәктәпләрендә, Актаныш һөнәр-техник училищесында чыгышлар ясады.

Язучы шулай ук Казанның милиция мәктәбе курсантлары белән, аннары Васильево һәм «Казанский» санаторийләрендә дә очрашулар уздырды.

### УКРАИНАДА ТАТАР МУЗЫКАСЫ ЯҢГЫРЫЙ

Украина радиосының музыкаль редакциясе илебезнең тугандаш республикалары композиторлары турында тапшырулар циклы алып бара. Шундый тапшыруларның берсе татар композиторлары Фәрит Яруллин һәм Рөстәм Яхин иҗатына багышланды. Украина радиотыңлаучылары әлеге композиторларның тормыш һәм иҗат юллары белән таныштылар, төрле жанрдагы музыкаль әсәрләрен тыңладылар.

### ГАЛИМНӘР — ХЕЗМӘТ ИЯЛӘРЕНӘ

СССР Фәннәр академиясе Казан филиалының Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институты әдәбиятчы галимнәренең промышленность предприятиеләрендә лекцияләр белән чыгыш ясаулары күркәм гадәткә әверелде. Шундый коллектив чыгышларның берсе Х. Ямашев исемендәге мех производство берләшмәсендә булды. Ул көнне предприятие эшчеләре филология фәннәре докторы Н. Юзеев, филология фәннәре кандидатлары Ш. Абилов, Н. Гыйззәтуллин, Ф. Мусин, З. Рәмиев, Ф. Ибраһимова һ. б. ларның совет Татарстаны әдәбиятының үсеше һәм анда В. И. Ленин, шулай ук революция, Бөек Ватан сугышы темаларының гәүдәләнеше турындагы лекцияләрен тыңладылар.

### ХАЛЫК ИҖАТЫ КИЧӘСЕ

Әгерҗе районының Иске Эсләк авылы Культура йортында Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институтының фольклор секторыннан филология фәннәре кандидаты И. Надиров җитәкчелегендәге бер төркем фәнни хезмәткәрләр тарафыннан әзерләнгән халык иҗаты кичәсе үткәрелде. Кичәдә фольклорчылар халык иҗатының актуаль проблемалары турында сөйләделәр.

Залда шулай ук авылда язып алынган фольклор әсәрләр дә яңгырады. Кичәдә Иске Эсләктәге кул эше осталарының тегүчигү әйберләреннән күргәзмә дә оештырылды.

### ЯКТАШ ШАГЫЙРЬ ХӨРМӘТЕНӘ

Актаныш районының Пучы авылы кешеләре үзләренең якташы—шагыйрь Нур Баянның тууына 75 ел тулуны Культура йортында тантаналы шартларда билгеләп үттеләр. Фронтовик шагыйрьнең тормыш һәм иҗат юлы турында Пучы урта мәктәбенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы Фәния Бәдретдинова сөйләде. Аннары әдипнең туганнары, авылдашлары үзләренең истәлекләре белән уртаклаштылар. Соңыннан Нур Баянның шигырьләре яңгырады.

### ҖӘЛИЛГӘ БАГЫШЛАП

Ташкент шәһәрендә яшәүче галим, филология фәннәре кандидаты Җәлил нҗатын өйрәнүче Исхак Забиров, «Белем» җәмгыятенең республика оешмасы чакыруы буенча, Башкортстанда булып кайтты. Ул эшчеләр, колхозчылар, студентлар һәм укучылар алдында «Герой-шагыйрь Муса Җәлил һәм аның Башкортстаннан чыккан сугышчан көрәштәшләре» дигән темага лекцияләр укыды. Туймазы, Октябрьск шәһәрләрендә, «Зеленая роща» һәм Йоматау санаторийларендә чыгыш ясады.

### «ДУСЛЫКНЫҢ ТОРМЫШЧАН КӨЧЕ»

Азербайҗан Язучылар союзы органы булган «Литературный Азербайджан» журналының 4 нче саны В. И. Ленин тууына 110 ел, Азербайҗан Компартиясе һәм Азербайҗанда Совет власте төзелүгә 60 ел тулуга багышлап чыгарылды. Материаллар арасында Н. М. Мурадымовның «Дуслыкның тормышчан көче» исемле мәкаләсе дә урнаштырылган. Ул татар һәм азербайҗан халыкларының культура һәм әдәбият багланышларына багышланган.

### КАЗАН ТАМАШАЧЫЛАРЫ АЛДЫНДА

Июль аенда Казан шәһәрендә Әлмәт Татар дәүләт драма театрының гастрольләре булып узды. Гастрольләр барышында театр коллективы Ф. Бурнашның «Таһир-Зөһрә» трагедиясен, Туфан Миңнуллинның «Ай булмаса, йолдыз бар» драматик хикәясен, «Яшьлегем-җырларлегем, яшьлегем-гүзәллегем» исемле моңсу комедиясен, Аяз Гыйләҗевнең «Әгәр бик сагынсаң» драмасын, Х. Ибраһимовның «Җизнәкәй» комедиясен, Ризван Хәмиднең «Иске йорт кешеләре» исемле сатирик комедиясен, Фоат Садриевның «Ач тәрәзәң» драмасын, Юныс Сафиуллинның «Мена без дә үсеп життек» комедиясен, В. Черныхның «Кулда власть булгач» пьесасын, шулай ук француз драматургы Ж. Ануйның «Антигона» трагедиясен күрсәттеләр.

Спектакльләрне Казан тамашачылары яратып карадылар.

### ЯКТАШЛАРЫБЫЗ ТУРЫНДА

«Советская энциклопедия» нәшриятында «Олимпия энциклопедиясе» дигән китап басылып чыкты. Ул «80-елгы Олимпиада»ны оештыру комитетының дипломына лаек булды.

Китапка меңъярымлап мәкалә урнаштырылган. Алар кышкы һәм җәйге Олимпия уеннары, дөньядагы бу спорт хәрәкәтендә катнашучы илләр һәм чемпионнар турында сөйли. Энциклопедиягә Татарстанда туган байтак Олимпия чемпионнары да кертелгән. Алар — чаңгычы Федор Симашев, биатлончы Ринат Сафин, фехтование осталары Ольга Князева, Валентина Никонова, Наилә Гыйләҗева, велосипедчы Валерий Лихачев, штангачы Николай Колесников һәм башкалар. Аларның һәркайсы совет спортының Олимпия уңышына зур өлеш керткән спортчылар.

### ЧАЛЛЫ ЯЗУЧЫЛАР ОЕШМАСЫНДА

«Орфей» әдәби берләшмәсе үзенең бер утырышын «Бер шигырь кичәсе» дигән исем астында үткәрде. Кичәгә килгән һәр яшь автор үзенең иң яраткан, иң уңышлы дип тапкан шигырен укыды. Кичәдә байтак кына яшь һәм башлап язучылар иптәшләреннән файдалы киңәшләр ишеттеләр.

* * *

«Орфей» берләшмәсенең чираттагы утырышында яшь шагыйрь Владимир Паршинның шигырьләре укып тикшерелде. Тикшерүдә чыгыш ясаган А. Попов, Артур Не, Л. Васильчук, А. Чурбанов иптәшләр яшь шагыйрьнең иҗатына уңай бәя бирделәр, кимчелекләрен күрсәтеп уздылар.

* * *

Бер төркем Чаллы язучылары һәм яшь авторлар шәһәрнең Үзәк китапханәсендә әдәбият сөючеләр белән очрашу уздырдылар. Очрашуда Кадыйр Сибгатуллин, Хәниф Хөснуллин, Мансур Сафин, Әхәт Гаффуллин һәм башка яшь авторлар катнашты. Алар үзләренең шигырьләрен укыдылар, иҗат планнары белән уртаклаштылар. Очрашуны «Ләйсән» әдәби берләшмәсе җитәкчесе Газиз Кашапов алып барды. Ул кичәдә катнашучыларга язучыларның Чаллы оешмасы, аның эшләре турында сөйләде.

* * *

КамАЗның 60 нчы тулай торагында да шундый ук әдәби кичә үткәрелде. Очрашуга Мәхмүт Газизов, Николай Алешков, Мансур Сафин, Рина Асылбаева, Газиз Кашапов, Надежда Дмитриева килгән иде. Алар һәркайсы үзләренең яраткан шигырьләрен укыдылар. Шигырьләр рус һәм татар телләрендә яңгырады. Очрашуны бүлек җитәкчесе, язучы Эдуард Касыймов алып барды.

* * *

Оешма җитәкчесе Эдуард Касыймов, «Ләйсән» берләшмәсе җитәкчесе Газиз Кашапов Алабуга педагогия институтында булдылар. Алар институттагы яшь әдәби көчләрне тагын да активлаштыру турында сөйләштеләр, фикер алыштылар, планнар билгеләделәр. Сөйләшүдә институтның ректоры, тәнкыйтьче Тәлгат Галиуллин, әдәбият галиме Фатих Урманчеев, шулай ук институттагы «Чулпан» исемле әдәбият түгәрәге җитәкчесе Әнвәр Шәрипов та катнашты.

* * *

Чаллының «Энергетика» Культура сараенда КПССның шәһәр комитеты һәм халык депутатларының шәһәр Советы Татарстанның 60 еллык юбилее уңае белән тантана-

лы утырыш уздырды. Анда котлау сүзләре белән КамАЗның танылган кешеләре чыкты. Тантанада язучы Эдуард Касыймов та чыгыш ясады. Ул тантаналы утырышта катнашучыларны иҗат интеллигенциясе исеменнән данлы юбилей белән котлады. Кама буе иҗат көчләренең, аерым алганда, язучыларның киләчәктә дә сынатмаячакларын, республикабыз һәм КамАЗ данына тиң әсәрләр иҗат итү өчен сәләтләрен дә, энергияләрен дә кызганмаячакларын белдерде.

## ШӘЙХИ МАННУРНЫҢ ИҖАТ МИРАСЫ КОМИССИЯСЕ

Татарстан Язучылар союзы идарәсе президиумы күренекле татар совет язучысы Шәйхи Маннурның иҗат мирасы комиссиясен төзеде: И. Юзеев (председатель), Г. Бәширов, Х. Ярми, Ш. Галиев, Р. Даутов, Х. Камалов, Л. Хәмидуллин, М. Маннурова, Р. Мөхәммәдиев (секретарь).

## МИРСӘЙ ӘМИРНЕҢ ИҖАТ МИРАСЫ КОМИССИЯСЕ

Татарстан Язучылар союзы идарәсе президиумы күренекле татар совет язучысы Мирсәй Әмирнең иҗат мирасы комиссиясен төзеде. Комиссия составына түбәндәге иптәшләр кертелде: А. Расих (председатель), М. Маликова (секретарь), Х. Госман, В. Нуруллин, Ф. Әмирова.

## САҖИДӘ СӨЛӘЙМАНОВАНЫҢ ИҖАТ МИРАСЫ КОМИССИЯСЕ

Татарстан Язучылар союзы идарәсе президиумы танылган шагыйрә Саҗидә Сөләймановaның иҗат мирасы буенча комиссия төзеде: З. Нури (председатель), Р. Рәкыйпов (секретарь), Ә. Маликов, К. Тимбикова, Н. Юзеев.

* * *

Мирас комиссияләре Шәйхи Маннурның, Мирсәй Әмирнең һәм Саҗидә Сөләймановaның хатларын, фоторәсемнәрен һәм алар хакындагы истәлекләрне түбәндәге адрес белән җибәрүне үтенә: 420084, Казань, ул. Баумана, 19, Союз писателей Татарии.

## МАКТАУЛЫ ИСЕМ

Совет театр сәнгатен үстерүдәге хезмәтләре өчен **Габдулла Рухулла улы Шамуковка**, СССР Верховный Советы Указы белән, **СССРның халык артисты** дигән мактаулы исем бирелде.

## ХЕЗМӘТКӘ ХӨРМӘТ

Совет әдәбияты өлкәсендә күрсәткән хезмәтләре өчен һәм илле яше тулу уңае белән, балалар язучысы **Мәрзия Низам кызы Тәрҗеманова (Фәйзуллина)** КПСС өлкә комитетының һәм Татарстан АССР Министрлар Советының Почет Грамотасы белән бүләкләнде.

# ЗӘЙНИ ШАҺИМОРАТОВ



Шушы елның 25 августында 68 нче яшендә озакка сузылган каты авырудан соң танылган драматург Зәйни Шаһиморатов вафат булды.

Зәйни Әхмәт улы Шаһиморатов 1913 елның 7 мартында Оренбург өлкәсенең Тоцк районы, Кондызлытамак авылында туа. 1933 елда Ташкентта икееллык педагогия институтын, ә 1936 елда Казанда театр техникумын тәмамлый. Бөек Ватан сугышына хәтле Республика халык иҗаты йортында методист булып эшли. 1941 елдан 1945 елга кадәр ул Бөек Ватан сугышында була, орденнар, медальләр белән бүләкләнә. 1943 елда Зәйни Шаһиморатов Коммунистлар партиясе сафына керә. Сугыштан соң күп еллар буе Республика халык иҗаты йортының директоры булып эшли.

Зәйни Шаһиморатов әдәби иҗат эшен курчак театры өчен пьесалар язудан башлый. Аның «Шүрәле», «Мәч-Мәчин», «Айтуган», «Кечкенә партизаннар», «Бәхет кошы» кебек пьесалары курчак театры сәхнәләрендә күп еллар буе зур уңыш белән бара. Ул курчак театры драматургиясенә нигез салучыларның берсе булды.

Зәйни Шаһиморатов — үзешчән сәнгать коллективлары һәм профессиональ театрлар тарафыннан күп еллар буе кат-кат уйналган егермедән артык драма һәм комедия авторы. Аның «Хәзрәт үгетләргә килә», «Тугыз гашыйк», «Хаят», «Йөрәк давыллары», «Уеннан — уймак» кебек пьесалары театрларыбыз репертуарында төп урынны алып торды. Алдынгы нефтьчеләрнең, колхозчыларның тулы образларын тудыруда, революция каһарманнарын сурәтләүдә ул мактауга лаек эш башкарды. Шуның өстенә З. Шаһиморатов үзен оста тәрҗемәче итеп танытты, башка миллләт драматургларының пьесаларын тәрҗемә итү эшенә зур өлеш кертте. Үзенең бөтен иҗат эшчәнлеген партиябез идеяләрен тормышка ашыру өчен көрәшкә багышлаган киң күңелле, тыйнак табигатьле каләмдәшебезнең якты истәлеге күңелләрдә озак сакланыр.

## ХӨРМӘТЛЕ УКУЧЫЛАР!

Вакытлы матбугатка язылу башланды. Билгеле ки, бездә һәркем үзе теләгән газета-журналга алдан ук язылып куя һәм аңа ел әйләнәсендә шул газеталарны, журналларны китереп торалар. Әмма укучылардан килгән кайбер хәбәрләргә караганда, еш кына көтелмәгән тоткарлыклар килеп чыга. Кызыксына башласаң, барысының да сәбәбе бер генә була: язылу чарасына соңга калып керешкәннәр, укучыларны газета-журналлар белән тәэмин итәргә тиешле «Союзпечать» оешмасы вәкилләре исә үз эшләрен түгәрәклəп куйганнар, планнар үтәлгән, отчетлар бирелгән. Бу очракта журналны алдырырга теләгәннәргә ярдәм итү катлаулана, хәтта бөтенләй мөмкин дә булмый.

Мондый күңелсезлекләр чыкмасын өчен, «Казан утлары» журналына язылуны алдан ук рәсмиләштереп куярга киңәш итәбез. Журнал Бөтенсоюз каталогына кертелгән. Индексы, ягъни каталогтагы күрсәткеч саны — 73 210. Димәк, «Казан утлары»на илнең теләсә кайсы шәһәр, авылында язылырга мөмкин. Бу эшне почта бүлеге һәм «Союзпечать» агентлыгы хезмәткәрләре башкарырга тиеш.

Урыннарда, нинди дә булса берәр сәбәп табып, журналга яздырмасалар, еллык бәяне түбәндәге адрес белән җибәрә аласыз:

420066, г. Казань, ул. Декабристов, 2. Татарское республиканское агентство «Союзпечать» (для подписки на журнал «Казан утлары»).

Бу очракта да соңга калырга һич ярамый, адресыгызны бик төгәл һәм тулы итеп язарга кирәк.

Журналның еллык бәясе — 6 сум.

«Казан утлары»на язылган укучыны тирән эчтәлекле, чын сәнгатьчә иҗат ителгән берсеннән-берсе кызыклырак, мавыктыргычрак яңа әсәрләр белән танышу шатлыгы көтә. Алар арасында Татарстанның күренекле өлкән әдипләренең дә, урта буын һәм яшь язучыларның да, әдәбиятта әле беренче адым ясаучыларның да язмалары булыр.

Прозаиклардан Г. Бәширов, Ә. Еники, Ф. Хөсни, Г. Ахунов, А. Гыйләҗев, М. Мәһдиев, Ш. Бикчурин, М. Юныс, Б. Камалов, М. Хәсәнов һәм башкалар редакциягә кулъязмаларын тәкъдим иттеләр дә инде.

Шигырь сөючеләр яраткан шагыйрьләренең яңа әсәрләрен укып шатланачаклар.

Очерклар бүлеге укучыларны Татарстанның промышленносте, авыл хуҗалыгы һәм культурасындагы проблемалар, алдынгыларның эш ысуллары белән таныштырып торачак.

Әдәби тәнкыйть мәкаләләрен язуга республиканың иң көчле тәнкыйтьчеләре тартылачак.

Җыр яратучыларга республика композиторларының иң матур әсәрләре тәкъдим ителәчәк.

Кыскасы, журналдагы уннарча рубриканың һәркайсы укучыга сөенечле яңалык, рухи байлык алып киләчәк. Укучылар исә танышкан әсәрләргә карата туган уй-фикерләрен шулай ук журналга язып чыга алачаклар. Моның өчен «Укучылар сүзе» исемле махсус бүлек бар.

Редколлегия һәм әдәби хезмәткәрләр журнал алдыручыларны канәгатьләндерү өчен көчләрен кызганмаячаклар.

Бәясе 50 тиен
Цена 50 коп.

# КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал

ОРГАН СОЮЗА
ПИСАТЕЛЕЙ
ТАТАРИИ

ИНДЕКС 73210